
ISSN 0206—41

# КАЗАН УТЛАРЫ

1. 1998







**Шиһабетдин Мәрҗани**
(1818—1889)

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**(903)**

**1998**

КАЗАН

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

М. ГАЛИЕВ. Догалы еллар. *Эссе* . . . 3
Г. АФЗАЛ. Мин картайган саен усалланам. *Шигырьләр* . . . 59
Р. ФӘИЗОВ. Ике әни. *Повесть* . . . 64
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Әй, бу яшәү!.. *Шигырьләр* . . . 92

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ДУНАЙ. Заманына күрә заны . . . 99

ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВАГА 70 ЯШЬ

Р. ГАТАШ. Моңнар бәйрәме . . . 115
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Мәхәббәт турында уйланулар. *Шигырьләр* . . . 116

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВКА 70 ЯШЬ

Г. АХУНОВ. Язучы һәм заман . . . 119

ХӘТЕР

Я. АБДУЛЛИН. Шиһабетдин Мәрҗани . . . 127
Т. ГАЛИУЛЛИН. Кабатланмас шәхес . . . 150
Ф. ИБРАҺИМОВА. Галимҗан Ибраһимов фатирлары . . . 175

ТӘНКЫЙТЬЧЕ МАНСУР ВӘЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Н. ГАМБӘР. Аккош күлендә утлар . . . 137

СӘНГАТЬ

Н. ШӘЙДУЛЛИНА. «Театрда гомер үткәне сизелми...» . . . 142

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. ШӘРӘФИЕВ. Үзең шатлана белмәсәң . . . 156

КИТАП КҮЗӘТҮ

Н. САФИНА. Җиргә төшә сөю йолдызлары . . . 163

ШАМИЛ БИКЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Ш. МАННАП. Килә икән хатлар... үткәннән . . . 167

Ш. ГАЛИЕВ. Хикмәтле сүзләр . . . 179
Латин имласында уку үрнәкләре . . . 181
Имеш-мимеш түгел . . . 186
Безнең календарь . . . 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 191

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнен адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: отрывки из книги М. Галиева «Книга века», повесть Р. Фаизова «Мои матери»; стихи Г. Афзала, Р. Файзуллина.
«Публицистика»: Ф. Дунай. Размышления о сегодняшнем времени. «К 70-летию Г. Зайнашевой»: статья Р. Гаташа о творчестве поэтессы и стихи юбиляра.
«К 70-летию А. Гилязова»: статья Г. Ахунова «Писатель и современность».
«Память»: статьи Я. Абдуллина «Шигабутдин Марджани», Т. Галиуллина «Неповторимая личность», Ф. Ибрагимовой «Дома, где жил Г. Ибрагимов».
«К 50-летию М. Валиева»: статья Н. Гамбара посвящена творчеству критика.
«Искусство»: беседа Н. Шайдуллиной с народным артистом Татарстана и Российской Федерации Р. Тазетдином.
«Литературная критика»: статья Р. Шарафиева «Если не умеешь радоваться».
«Книжное обозрение»: Н. Сафина рецензирует книгу стихов Р. Шарипова.
«К 70-летию Ш. Бикчурина»: Письма юбиляра адресованные Ш. Маннапу.
Дневник культурно-общественной жизни.
На наших обложках: из сокровищниц хана Кубрата; поэт Ахмет Адель.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the fragments of M. Galiew's book «Century's book», P. Faizov's narrative «My mothers»; the verses of G. Aphzal, R. Faizullin.
«Publicism»: Ph. Dunay. Reflection about today's time.
«Commemorating the 70 th Anniversary G. Zainasheva»: R. Gatash's article about poetess's creative work and verses of G. Zainasheva.
«Commemorating the 70 th Anniversary A. Gilyazov»: G. Ahunov's article «Writer and moderness».
«Memory»; Y. Abdullin's article «Shigabutdin Marjany», T. Galiullin's article «Unique person», F. Ibragimov's article «Houses where lived G. Ibragimov».
«Commemorating the 50 th Anniversary M. Valiev»: N. Gambara's article which devote to critic's creative work.
«Art»: conversation N. Shaydullina's with popular artist of Tatarstan and Russian Federarion R. Tazetdin.
«Literary Criticism»: R. Sharaphiev's article «If you can't rejoice».
«Book's review»: N. Saphin's review of K. Sharipov's book of verses.
«Commemorating the 70 th Anniversary of Sh. Bikchurin»: the letters Sh. Bikchurin's letter's which address to Sh. Mannap.
The diary of social and cultural life.
In our covers: From Kubrat Khan's treasure – house; the poet Ahmet Adel.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Камил Сәгадәт, Марс Шабаев.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 3.12.97 ел. Басарга кул куелды 14.01.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 14 000. Заказ Н-652.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1998 ел.



## Марсель Галиев

# ДОГАЛЫ ЕЛЛАР

ЭССЕ

### Чатыр тау җиле

Исәнме, мәгърур тау!
Туган як тәхете — Чатыр тау, исәнме!..

Бакый заманнарда, дәһшәтле бозлык чорында мамонтларның күз карашын хәтереңә сеңдереп калыккансың да, бүген инде, туган ягымның йөзек кашы булып, күпме күңелләрне әсир иткәнсең.

Янәшәңдәге дулкын-дулкын таулар иңенә басып меник әле синең ияреңә.

И бу җиһанның гадел минутлары...

И бу җанның убылыр упкыннары...

Уй-хыялларыңа канат куяр өчен шушындый лаек биеклек кирәк икән. Кочагыңда — рәшә сулышыннан тибрәнгән япан киңлекләр. Бу кодрәт каршында үзеңнең бик кечкенә зат икәнеңне беләсең, әмма тау, үз биеклеге белән исертеп, сиздермичә генә олылау хисе — юаныч бирә, күңел дөньяның чиге офык сызыгына тоташа да... йөрәгең тау йөрәге белән бер аһәңдә тибә башлый...

Ә җиле...

Чатыр тау җиле үз катына кешеләр менгәнне нинди ярата, зарыгып көткән була; уйнаклап килеп кочаклап ала да, шатлыгыннанмы — әле җырлый, әле көлә, әле үкси... Аннары, үлән өстенә ятып мәтәлчек ата, билеңнән алып көрмәкләшә, аягыңа сөт тешле көчек булып сарыла, куеныңа кереп, суык борынлы песи булып мырылдый, сабый булып чәчеңне тузгыта, йолыккалый. Юк, мондый җил, мондый да саф, мәҗүси җил бүтән беркайда да исми, валлаһи исми.

Рәхмәт сиңа, Чатыр тау җиле! Күңелдәге юшкынны, гөнаһларны тараткан өчен мең рәхмәт сиңа!

Җирсегән чакта җилне дә сагынасың икән...

Тауларга карап күк тирәнлеген күрергә була. Башын күтәреп, күк йөзенә карый белгәннәргә күпне белү язган. Шушы тауның текә маңгаеннан торып күпме шагыйрьләребез Стәрле, Ык буе тугай-кырларын тамаша кылдылар. Андагы хозурлыклар!..

---

Дәвамы. Башы 9 нчы санда (1996) чыкты.

Балыклары сикереп чыгып, арба тәгәрмәченә урала торган күлләреме, еракларга китәсе килмичә, бормаланып кайта-кайта тау куеныннан иркәләнеп аккан елгаларымы, билгә каеш итеп урарлык йөгерек юлларымы, аяк тавышын ишетүгә, үлән арасына поса белгән мут-кызыл җиләкле аланнарымы, чатлы мөгезе белән муенын кашыйкашый, ыспай гына атлап су эчәргә төшкән пошиларымы, саллы имәннәр янәшәсендә чытлыкланып бөтерелгән көяз каеннарымы — бу ганимәтләр һәммәсе дә шагыйрь каләме кытыклап алуын көтеп тын калганнар. Тау кашагасына басып, җил алкышыннан ләззәт кичереп торган шагыйрьләргә кара син. Шушындый илһамлы мәлдә шагыйрьләр күңелендә киләчәктә таудан калыккан һәйкәл буласы килү теләге туса да гаҗәп түгелдер...

Еллар үтсә дә онытмыйлар Казанлы дусларым, туган якка кайтам дисәм, «Чатыр тауга сәлам әйт!» — дип, нәүмиз-кызыгып калалар.

Тау артында таулар бар, дигәнгә мин, юл йөреп, үз күзләрем белән күреп ышандым. Җил-Су-Кояш берсеннән-берсе гүзәлрәк манзаралар хасил иткән икән. Якынайган саен ерагая барган кар чалмалы Кавказ сыртлары дисеңме, канлы язмышлар шаһиты — Кырым даглары дисеңме, Андалузиянең мәрмәр күкрәкле Сьерра-Невада өркәчләре дисеңме, самолет канаты астыннан үрелеп калган Альп кыялары дисеңме — болар һәммәсе дә кешедән өстен горурлыкта, хәтәр упкыннар сагында...

Ә Чатыр тау — башка...

Идел-йортыбызның иң биек түбәсе саналса да, иңенә ятып еларлык яшел мендәр дә ул, рухыңа дәрт өстәрлек мәгъруp биеклек тә ул, балачак иленә кайтара алган җил ияре дә ул. Чатыр тау сине, учына алып, күк гөмбәзенә чөя дә яңадан үз биеклегенә төшереп бастыра. Син шул мизгелдә бөтен уй-вөҗүдеңнән аерылып, Алла катына якынаеп алганыңны, күзгә күренмәгән сәмави затның җил-канат белән башыңнан сыйпап алганын, һәм, үзеңнең бер карышка олыгаеп киткәнеңне тоясың. Димәк, син бу тауның мәңгелек чишмәсеннән кәүсәр нуры эчтең. Моннан соң инде, бер-бер эш кылыр алдыннан, яхшылыкмы, яманлыкмы бу, дип, икеләнгән күңелеңне Чатыр тау биеклегенә куеп кара, бөтен күзәнәкләреңә кадәр сыйпап искән самими җилен исеңә төшер. Шул мәлдә син күләгәсез яктылык белән туганлашырсың.

Түбәсендә кылганнар йөгергән Чатыр тауга менеп син Тарих хәтерен уятасың. Кара диңгез ярындагы Чатыр даг белән Урал бусагасындагы Чатыр тау — табигатьнең игезәкләре, иксез-чиксез киңлекләрне биләгән төрки-татар мәмләкәтенең тере маяклары...

Саубуллашыр алдыннан, күңел догаңны укы да, иелеп, тау маңгаен сыйпап ал. Күпне күргән олпат таулар да юатуга мохтаҗ...

Ераклашкач, Чатыр тауга соңгы тапкыр борылып кара син. Тик бер генә тапкыр борылып күз сал. Олы юлга фатиха алып чыкканда капка төбендә озатып калган әниеңә дә шулай бер генә тапкыр борылып, кул болгый идең бит... күз яшеңне күрсәтмәс өчен.

Һәр хушлашуда — бәлки бу соңгысыдыр... дигән бәхилләшү төсмере бар... Әмма саубуллашкан чакта безгә бу хакта оныту бәхете бирелгән, соңыннан инде татлы үкенер өчен...

Йә, хуш, Чатыр тау!

Бәхетем дә, ләхетем дә синдә булсын, туган җир...

Ә син, эчкерсез тау җиле, яшеннәр оясын туздырып уйна шулай, без-кешеләр уенына кызыгып төшә күрмә, илаһи биеклектә кал!

Ярабби...

# Туфанлы хәтер

Мәгънәләр өстәленнән ширбәт алган кеше
Ничә Әму-Дәръялар эчсә дә,
канәгать булмас.
Г. Утыз Имәни

Әгәр күңелендәге Алла урынына шом-курку галәмәте кереп оялаcа, каләм иярләре өчен бу — тере килеш үз кабереңң өстендә йөрүгә бәрабәр. Юк, мин утызынчы еллар мәхшәрен исән кичеп чыккан өлкән язучылар истәлегенә күләгә төшерергә җыенмыйм. Бары тик акны — ак, караны — кара, дигән дөреслеккә якынаерга тырышып уйланам, үкенечле гамьгә биреләм. Мәскәүнең тимер йодрыгы тәэсирендә һәр шаукымга сукырларча иярү, күндәм ышану, җан асрау өчен йөрәгең кушмаганны язу — болар бар да дәүләтсез ятим калган халыкның рухын сүндерүгә, гореф-гадәтеннән, дененнән, милли холык хаятеннән читләштерелгән ясалма әдәбият тудыруга китерде. Әгәр дә, егерменче еллардан алып бүгенге көнгәчә сузылган әдәби мирасны вакыт иләгендә җилгәрсәң, ул мирастан киләчәккә алып барырлык чын бөртекләр күпме калыр иде микән?..

Юк, минем бу дәверне кичкән әдипләрне һич тә гаеплисем килми. Гарасатлы дәвер күпме сораса, шул кадәрле корбан канлы җәмгыять тегермәнендә тартылырга тиеш булган. Чын сәләт иясе, чын зыялыларыбызның күбесе төптән киселгән, алар урынына тиз арада денен алыштырганнар яисә олуг максатлар хакында бөтенләй хәбәрдар булмаган (завод-фабрикалардан йолып алынган «эш атлары») такмакчылар калыккан. Табигый сайланышка корылырга тиешле әдәби мөхиткә очраклы юлаучылар кереп тулган, өстән астыртын күзәтеп торган хакимият куенында җылынып, яңа корифейлар, мөтәнәббиләр (ялган пәйгамбәрләр) пәйда булган.

Өлкән әдипләр мәсләген рәнҗетми генә безгә бу хакта уйлану кирәкме? Хәер, күрмәмешкә салышып дәшмәсәк тә, килер буыннар бу дәверне салкын акыл белән үзләренчә сүтеп җыячак, әдәбиятны табигый ярларына кайтарачак. Без дәшмәсәк тә... Девон тирәнлегендә калган тарихыбыз, аянычлы хәтер актарылып чыкканда вакыт барысын да үзе җилгәрә, буш-ялган кибәкне җил итәгенә көри тора.

Бу очракта дәшмәү — алтынга тиңләнмидер...

Әмма үз-үзен хәл кадәри саклап кала алган әдипләргә карата рәхмәтле дә булыйк. Алар, гамәлдә, әдәбиятның чисталыгы сагында тордылар. Бүгенге талымсыз вагаю белән чагыштырганда бу бигрәк тә ачык күренә. Мин аларны сагынып, еракка түгел — үр артында гына калган офыкка — җитмешенче-сиксәненче елларга борылып карыйм. Хәтеремнең түрендә, йомшак мендәр куелган урында — Хәсән Туфан утыра.

Туфан — бөек Тукайның имгәтелгән дәвамы иде.

Туфан — канаты киселгән җәяүле кош иде.

Туфан — эчке әрнүен җиңгән, ак уйлы, үтәли күренгән өрфия җанлы шәхес иде.

Яшьлек давылы тынган күперенке чәч. Самими елмаю таралган озынча йөз. Гүя ул дистә еллар буена кичергән михнәтләрен, Уралның зәмһәрир кышларын гомеренең икенче яртысына чыккач онытырга теләп еш-рак елмая, әмма күзләрендә мәңгелеккә оеган тыенкы сагыш. Тавышы да, яңгыравын җуеп, иңен баскан язмыш ташлары арасыннан тоныкланып чыгадыр сыман.

Чордашлары белән дә, үзеннән яшьрәкләр белән дә ул оялган кебек сөйләшә. Гүя ул халкыннан, әдәби җирлектән аерылып, озак гомерләр читтә яшәргә хөкем ителүе өчен үзен гаепле саный, шул эчке әрнүен якты йөзе, самими сүзе, оялчан елмаюы белән дәваларга, онытылырга тырыша кебек иде.

Утызынчы елларда ул, чын күңеленнән ышанып: «Мә, партия мине!» дип идея амбразурасына күкрәген куйган. Эчке хасияте, мәкерле максаты белән татарга бөтенләй чит-ят партия исә талымлап тормаган. «Китер!» — дигән дә, гаярь шагыйрьне Урал аръягына ташлап, мәхбүс тә, көтүче дә иткән.

Туфаннар буыны — әдәби гаиләнең атасы булырдай шәхесләр иде. Ак кәгазьне кулыңа алуга, аларның сынаулы карашын, күпне кичергән кулларының иңгә орынуын тойган кебек, каләмеңә җитди-таләпчән егәр салып, хис кырына тирәнрәк буразналар салырга тырыша идең. Сиксәненче елларда әле әдәби мөхиттә итагатьлелек, чама белү, кечелекле хөрмәт, олыны олы итү кебек сыйфатлар җуелмаган, гадел ата кулы, гаилә җылысы сизелә иде. Хәзер ул дәвернең эчтән таркалган йорты янында сүнгән учак көлен җил актара, берән-сәрән калган хәтер күмерләре генә шыкырдап уала инде.

Юка, җиңел гәүдәле Хәсән ага, беләгенә кәкре башлы таягын элеп, Мөнҗия апа белән култыклашып, Тукай клубына еш килә иде. Алгы рәтләрдә җыелыш вакытында «якты башлар» күп була: Мирсәй Әмир, Афзал Шамов, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Садри — тагын кемнәр...

Әдәби кичәләрне дә Хәсән ага калдырмый, яшьрәкләр арасында да берүзе ап-ак булып утыра иде. Кичәгә хәмер тәэсиреннән кызыбрак килгән яшь шагыйрьләр ишек төбеннән үрелеп карыйлар да, Хәсән аганы күреп алгач, тавышларын басып, арткы рәтләргә чүмәшәләр иде.

Күпме шигырьләргә кергән Аккош күле... Аккош күленең маягы — чәчәкләр белән сөйләшә торган ак җанлы Туфан иде. Менә алар йөзъяшәр чыршылар арасыннан сузылган дымлы сукмак буйлап икәү килә: Туфан һәм Хәким. Ике аксакал дуслыгы. Бу ике олуг зат бер биеклектә шикелле тоелсалар да чынбарлыкта алай түгел иде. Хәсән ага сәхнәгә чыгып басса, зал тулы халык үзенә бер кайнарлык белән кул чаба, алкышлый, аның шигърияген әче язмышы белән тәңгәл куеп кабул итә иде. Халыкның йөрәк тибеше кушылган мондый тетрәнүле алкышлар бүтән бер генә шагыйрьгә дә насыйп булмагандыр. Сибгат ага Хәким исә башкарак... Ул барган бер җиреннән олы тәэсирләр белән кайта, хисләрен бик теләп уртаклаша иде. Ул чорда Тукай клубында шаулы җыелышлар еш була, трибунага чыгып, артык тирәнгә кермичә генә, фикер тоягын кыздырып алырга мөмкинлек бирелә иде. Сибгат аганың кәгазьгә карамыйча гына ясаган үтемле чыгышлары безне әсир итә, кайбер хикмәтле сүзләрен отып алып, соңыннан сөйләп йөрер өчен җирлек була иде. Радио-телевидениеләрдән көне-төне эчпошыргыч нотыклар сөйләнгән заманда язучыларның Тукай клубы җанга рәхәт тере сүздән кинәнү алган бердәнбер утрау иде. Сибгат ага һәр чыгышында Тукайга әйләнеп кайта. Казан артыннан башланган мәгърур эзләрне яңартып, галим-голямәләрнең дә йокымсыраган аңын уятып, з а м а н ы Тукайга борылып карарга алгысыткан шәхес, чынлап та, Сибгат ага Хәким булгандыр.

Туфанның алай оста сөйләү куәсе юк иде шикелле. Аның бер-ике мәртәбә трибунага күтәрелгәнен хәтерлим. Тонык тавыш белән, хискә бирелеп, хәмер эчүнең язучы өчен никадәр зыянлы икәненә ышандырырга тырышкан иде. Гыйбрәт өчен, Шәрәф Мөдәррис, Әнвәр Давыдов кебек шагыйрьләрнең язмышын мисалга китерде. Шул чакта кайсыдыр усал теллесе, арткы рәттән: «Туфанның дәшми утыруында фикер күбрәк...» — дигән иде. Ул елларда бер кыйсса да телгә кергән иде: Язучылар союзына әгъзалыкка алу утырышында, Мәһдиев әйтмешли — «бер иптәш» үзенең тәрҗемәи хәле, язачак әсәрләре хакында сөйләгәч, Хәсән ага Туфан аңардан: «Сезнең хәмер эчү ягы ничегрәк?» — дип сораган. Шул чак Мөдәррис Әгъләм сикереп торган да: «Монда без, Хәсән ага, ашау-эчү турында сөйләшмибез, сүз — әдәбият турында бара!» — дигән, имеш.

Әлбәттә, күпне кичергән, төрмәдән атарга алып чыккач, күкрәгенә төбәлгән карабинга карап, мизгел эчендә гомер йомгагын сүтеп караган, шулай сындырылып исән калган кешедә әллә нинди асыл фикерләр булгандыр, әмма аларны чәчеп ташламыйча, сабыр-түземлелек юшкынында тота белергә замана чыбыркысы өйрәткәндер. «Дөнья бирде кирәкне, еламаска өйрәтте...» — дигән юлларга Туфанның бәгырь сулкылдавы сыйган түгелмени!

Ашыктылар шул — гасыр яшьтәшләре... Сүз иреге алырга күп тә түгел, бары берничә ел калган иде бит. Гүя язмыш нәкъ менә күпне кичергән ил агаларының китеп бетүен генә көтеп торган да... мәгънәсен дә, кадерен дә аңлап бетермәгән без — кыйбласыз буын каршында ирек капкаларын ачып ташлаган. Хәер, соңлап килгән ирек тойгысын сыйдырырга аларның йөрәге чыдамас иде, бәлки...



«Туфан» Марсель ГАЛИЕВ.

Хәтерлим әле: Хәсән аганың җитмеш биш яшьлек бәйрәмен үткәрергә әзерләнәбез. Афиша ясатырга фотосы кирәк. Киттем өенә. Бераз каушыйм да шикелле. Аксакал белән якыннан аралашканым юк. Шигырьләремне күрсәтеп, аннан киңәш алуны күз алдыма да китерә алмыйм. Бәлки ул миңа вакытның аргы ярында торып калган борынгы, иске фикерле шәхес булып та тоелгандыр.

Альбомнар карый-карый Хәсән ага белән гәпләшеп утырдык. Мин берничә фото сайлап алдым да китәргә кузгалдым. Хәсән ага стена буйлап сузылган ялтыр шкафның бар капкачын ачып куйды. Көзгедә чагылып, икешәргә әйләнеп чагылган шешәләре белән бу бар бик бай күренде миңа ул чакта.

Хәсән ага кыюсыз гына итеп, каршы килсә ярар иде, дигән кебек:

— Әзерәк тотып куясыңмы? — диде.

— Юк, Хәсән ага, эш вакытында тотсаң, романтикага тарта, андый гадәтем юк, — дидем мин. Хәсән ага, сөенеп, яктырып китте:

— Менә рәх-мәәт... Безнең поэзиягә ш ы н д ы й аек егетләр кирәк, — дип ул мине ишеккәчә озата килде. Инде саубуллашабыз дигәндә, тавышына аталарча кайгырту чыгарып, көтелмәгән сүз әйтеп куйды:

— Нинди шәп шагыйребез, Мөдәррис Әгъләмовны әйтәм, хәмер белән бик мавыга диләр, харап була бит болай булса...

Өлкән кеше әйтүенә карамастан, үземә ошамаган фикерне, кайберәүләр кебек, «әйе» дип, баш селкеп, җөпләп тору гадәтем юк иде, бу юлы да үземә хыянәт итмәдем. «Мөдәррис барыбыздан да күбрәк укый, барыбыздан да күбрәк яза, көнчеләр сүзедер ул, Хәсән ага», — дидем. Аксакал, сабыйларча елмаеп, «шылай дисеңме?..» — дип, кулымны куш учына алып, йомшак кына селкеп, бер тын җибәрмичә торды. Эчкерсез сөенү иде аның күзләрендә. Күрәсең, үзенең дәвамчысы итеп күргән яраткан шагыйре хакында өзлексез тукып торган гайбәтләрдән ул гаҗиз булгандыр.

Туфан ачкычы... Аның үз кулыннан алган фатир ачкычын мин биш ел буе югалтмыйча кесәмдә йөрттем. Бу талисман ничек соң әле минем кулга килеп керде? Сәбәбе бик гади — фатирсызлык мохтаҗлыгы. Университет бетереп, Язучылар союзында эшли башлау гына әле аз иде. Казанны яулау өчен миңа берәр таш йортта үз фатирым булу кирәк иде. Дөньяны каргамыйча гына, яшьлекнең кадерен белеп, теләсә кайда кунып йөргән чорда ишетеп калам: Хәсән Туфанга ике бүлмәле фатир бирәләр икән. Аның бер бүлмәлесе... Бик әйбәт тыныч урында... Икенче катта. Классик яшәгән бу фатир кемгә кала икән дигән сорау минем тынычлыгымны алды. Әлбәттә, бу сорауга җавапны Язучылар союзының сәркатибе Мөсәгыйт Хәбибуллиннан гына белеп була. Ул һәммәбезнең дә гозерен «юк!» дип кистереп әйтмичә тыңлый, бик тә җайлы холыклы шәхес иде. Мин армия хезмәтеннән кайтып төшкән дәвердә ул Азнакай редакциясендә эшли иде. Беренче хикәямне ул бастырып чыгарды. Дөрес, ул язмада минем бер җөмлә дә калмаган иде, вакыйгасы гына... Постта торган солдатка һөҗүм итәләр, күкрәк кесәсендәге комсомол билетына ядрә тиеп, канга буяла, имеш...

Мөсәгыйт ага картая белми торган чибәр кыяфәтле, яхшылыкны чырай сытмыйча, үз юмартлыгыннан үзе кинәнеп эшли белә, кешене сөендерүдән тәм таба иде. Андый шәхесләр, бигрәк тә язучылар арасында, бик сирәк була. Аның юмартлыгы хакында шаяртып, болай диләр иде: «Мөсәгыйт, язучылар йортының почмагын сүтеп алыйм әле, кирпече әйбәт күренә... дисәң, Мөсәгыйт, башын кашып алыр да: «Сүтеп ал инде бик ошагач», дип әйтер, имеш.

Шулай итеп Туфан фатиры хакында мин Мөсәгыйт агага кармак салып куйдым. Язның матур бер көне иде. Әдипләр Муса Җәлил һәйкәленә чәчәк салырга җыелдылар. Чүлмәкле гөлләр юнәтеп йөргән арада мин җәяүлеләр төркеменнән артта калдым. Кара «Волга» да Язучылар союзы рәисе Гариф Ахунов, Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм мин Кремль каршындагы мәйданга дип кузгалдык. Шунда Мөсәгыйт ага сүз башлады:

— Марсель бездә елга якын эшли, сынатканы булмады. Хәсән агадан калган фатирны аңа бирсәк, Гариф абый?.. Хатыны Динә университетның бишенче курсында... Ике айлык кызлары бар...

Гариф ага борылып, үткен-кара күзләре белән миңа сынаган кебек карады да:

— Шулай дисеңме... егет ипле күренә. Мин каршы түгел. Фәйзуллин белән дә киңәшик тә...— диде.

Җәлил һәйкәле янындагы чыгышлар, җыр-музыка колагыма әллә керде, әллә кермәде — баш түбәмә олы шатлык убылырга торганда нинди тантана ди! Халыкның тарала башлавын чак көтеп тордым да, союзга кайтып, Равил Фәйзуллин кабинетына атылдым. Ул иҗат эшләре буенча сәркәтиб — Ахуновның уң кулы иде. Мин килеп кергәндә, гадәтенчә, ирен арасында онытылып калып юешләнгән тәмәкесенең сүнгән очын кайчы белән кисеп тора иде, гозеремне тыңлаганнан соң:

— Аңлыйм инде хәлеңне, үземнең фатирымда да ничә тапкыр кундырып чыгардым... Гариф абый әйткәч була инде. Миллионлы шәһәрдә үз түбәң булу — зур бәхет, зур бәхет,— дип, кабатлый-кабатлый, үзенең риза-бәхил икәнен сиздереп алды.

Бер-ике атна үтте микән, Казанның тулы канлы гражданины булуымны раслаган ордер кесәмдә кыштырдый иде. Ләкин бусы әле башы гына икән. «Болай йөрсәң, Хәсән ага ел буена да күченмәс, ордерыңны тотып калырсың, барып сөйләш үзе белән»,— дип бер көнне Мөхәммәт Мәһдиев мине литфонд машинасына утыртып, Аккош күленә алып китте. Мин шунда беренче тапкыр күлен түгел, ә урман уртасындагы аланны, верандалы йортларны күрдем. Уртада — дворян ихаталарындагы кебек агач колонналы түгәрәк беседка күзгә чалынды. Монда әдәбият-

ның аксакаллары яшәгәнгә күрәме, тын табигать куенында олы бер сер, сулышын тыеп, ешкынлыклардан күзәтеп торадыр сыман тоелды миңа.

Менә без чыршылар күләгәсенә сыенып утырган бүрәнә йорт янында туктадык. Ишектән Гомәр ага Бәширов күренде. Саран гына елмаеп чәчәкле аллеядан килә. Төз гәүдә. Үгез койрыгы кебек үҗәт-каты муен. Кайчандыр депутат буларак, тройка атлар кукрәге белән җил ердырып йөргән Гомәр аганың бу тормышта «астан менеп» йончымаган, «өстән төшеп» сәламәт олыгайганлыгы йөз-кыяфәтендә, гәүдә тотышында сизелә иде.

— Гомәр Бәшировның «Намус» романын язганда кигән кырык җиде ямаулы чалбары шушы йортта саклана инде,— дип пышылдап кына әйтте Мөхәммәт Мәһдиев. Юл буе машинада ул бер төркем язучылар каршында әллә нинди мәзәкләр сөйләп, башын дәртле чөеп, «мәйдан тотып» килгән иде. Кияү балакай буларак, Гомәр ага каршында капылт йомылып калды. Кырын-кырын басып кына, иренеңә өч бармагын куеп, тавышын «сүндереп» сөйләшә, ике сүзнең берендә «әткәй» дип кенә тора.

Өйгә кереп, табын янына утырышкач, Гомәр ага:

— Мөхәммәт, бусы синең шөгыль,— дип «Столичная» шешәсен сузды. «Мондый нәрсә белән дуслыгым юк та инде... Сез әйткәнгә генә инде, әткәй...» — дигән шикелле, Мөхәммәт ага, шешәне ятсынып кына тоткандай, чәркәләргә сак кына коеп чыкты. Ул арада шешә табын уртасына кукраеп килмичә, әллә кая гына гаип булды. Гомәр аганың карчыгы барлыгы сизелә дә, сизелми дә, үзе күренә дә, күренми дә шикелле. Бары тик табынга ризык китергән куллар гына чагылып киткәли. Монда бөтен хәрәкәт, сүз сөреше, хәтта стена сәгатенең келткелт йөрүе дә Гомәр аганың күзенә карап эшләнә, монда бар да патриарх рухына көйләнгән иде.

Минем Аккош күленә нинди ният белән килүемне белеп алгач, чәйдән соң Гомәр ага:

— Син ашыкмый тор, мин үзем башта кереп Хәсән аганы әзерләп чыгыйм әле,— дип Хәсән Туфан яшәгән пыяла верандалы йорт ягына китеп барды.

Бераздан безне кавыштырдылар. Хәсән ага иңемнән кагып:

— Үзебезнең егеткә тигән икән фатир. Бик мәслихәт. Миңа ошый иде анда... Обоен алыштыра күрмә, төсе бик матур,— диде. Әзрәктән Мөнҗия апа мине читкәрәк алып китеп, уңайсызланып кына:

— Хәсән абыең сүзенә карама. Дөньялыкныкын белеп бетерми ул. Бөтен нәрсәне яңартасы бар инде анда. Сез — яшьләр, булдырырсыз,— диде.

Шулай итеп, Гомәр аганың аягы җиңел булды, күчену бер-ике көндә хәл ителде. Һәм мин Хәсән Туфан кулыннан фатир ачкычын алып калдым (яңа җиргә күченгәнче, биш ел буе ишек йозагын алыштырмадым).

Хәсән ага гаиләсен Вишневский урамындагы ак кирпеч йортка күчерешкәннән соң, бер-ике ай үтте микән, өй котлау мәҗлесенә бер төркем язучы белән мин фәкыйрь дә эләктем. Яшьләрдән берүзем идем. Уңайсызланып, оялып кына утырдым. Табында сүз иярә сүз китеп, Хәсән аганың сөргендәге еллары хакында да гәп кузгаттылар. Сәясәткә кагылмыйча гына... Стеналар да колаклы заман.

Хәсән ага Себердә көтү көткәндә бер үгез бозауны кулга ияләштерә, үзенең авызыннан өзеп аңа ипи сыныклары бирә, муенынннан сөеп, иркәләп кенә тора. Кара көз көнендә малларны тояп ерактагы ит комбинатына алып китәләр. Туфан яраткан үгезе белән хушлаша да алмый кала. Төнлә ул тәрәзә чылтырап ватылган тавышка дерт итеп уянып китә. Торып караса... шаккатып кала: тәрәзәдән аның яраткан малкае башын тыккан, кызганыч тавыш белән «коткар мине...» дигән кебек башын сузып мөгри. Муенындагы чылбырын өзеп качкан бозауның мөлдерәп караган күзләрендә яшь... Шулай итеп, охшаш язмышлы ике бәхетсез, ятим җаннар башны башка куеп җылашалар.

Бу хәлне сөйләгәндә (һәммәсе азмы-күпме үзеннән өстәп әлбәттә) Хәсән ага җөпләп, ара-тирә генә сүз каткалап утырды. Аннары, үзе дә хискә бирелеп, бер вакыйга сөйләп алды:

— Бервакыт гәзитләр бәйләме яткан кызыл почмакка эләктем. Комсызланып актарам гәзитләрне, кайсын укырга белмим, ашыгам, күз йөгерә; бу бәхетне тизрәк миннән тартып алырлар кебек. Шул чак башны күтәрсәм, кемдер миңа карап тора, кем — һич танымыйм. Мин башымны селкеим, ул да селки, бераздан соң гына мин ул ят кешенең үзем икәнен аңладым. Биш ел буена көзгегә караганым юк иде, үз кыяфәтемне бөтенләй оныткан мын. Оныту бер хәл, биш ел эчендә әллә күпмегә үзгәргәнмен дә...

Хәсән агага карыйм да, Сталин чорының җәбер-золымнарына ничекләр түзгән бу йөрәк, ничек каты бәгырьлегә әверелмәгән, сабыйлыгын саклап калган, дип гаҗәпкә калып уйланам. Кулга алыну... Атарга хөкем ителү... Аннары — сөрген. Хатыны — татар театры артисткасы Луиза Салиәскарованы эшеннән куалар. Иреннән — «халык дошманыннан» ваз кичәргә өндәп рухын изәләр. Ачтан үлмәс өчен ул донор булып, үз канын бирү хисабына килгән акчага яшәргә мәҗбүр була, Туфанга да ярдәм кулын суза.

Шагыйрьнең «Тамчылар ни сөйли?» дигән әсәрендә сызланулы мондый юллар бар:

Посылкалар белән ярдәм иттең:
— Без бит илдә... өйдә бит...— дидең.
Ә ул ярдәм
Каныңа алыштырган
Паекларың икән бит синең...

Сугыштан, совет концлагерьларыннан исән калган язучы-әдипләр илленче еллар уртасында Туфанның Казанга әйләнеп кайтуын түземсезлек белән көтәләр. Аны татар шигърияте көтә. Әмма хатыны Луиза Салиәскарованың, кавышу бәхетенә аз гына калганда, чыдамый, гомере өзелә.

— Кайт! — дип хатлар килделәр...
Юллар... озын иделәр.
Кайттым,
— Бусы алкалары,
Бусы — кабере... диделәр.

Мин Туфанга карыйм. Гомер дисбесенең уналты төймәсен Урал арты җилләренә сибеп калдырган. Тулы бер яшьлек гомере...

Бу тыйнак табында Хәсән ага, ачылып китеп, әлеге еллардан истә калырлык бүтән вакыйга сөйләмәде. Бик чәчеләсе килмидер, үзе өчен генә язадыр, дип уйладым мин ул чакта.

Әмма ул күргән-кичергән гыйбрәтле хәлләрен кәгазьгә төшерә алмады. Сәбәбе нидә иде соң? Бәлки ул җәбердә узган гомерен кабат йөрәгеннән үткәреп, яра-җөйләрен ачарга, әрнетергә теләмәгәндер? Хәтәр еллар тагын кабатланыр дигән курку бәлки аның кулын бәйләгәндер? Бәлки замана шаукымына артык ышанып карау аны «ярамый!» сагында тоткандыр. Кем белә... Гаепләп тә булмый кебек. Тик кызганыч, тарихы үзе белән китте. Аннан инде — теге бозау кебек, чылбырыңны өзеп, кире кайта алмыйсың...

Кесәмдә — Туфан ачкычы... Аның кул җылысы тоткаларда, күз карашы тәрәзәләрдә калгандыр. Олуг шагыйрьдән калган Өй иясе миңа рәнҗемәгәндер, шәт. Монда бит исемле, дәрәҗәле күпме шагыйрьләр булган, күпме сүзләр сөйләшенгән, нинди генә гыйбрәтле тостлар әйтелмәгән. Боларга минем чордашларны да кушсаң... Бу диварлар арасында тибрәнгән никадәр фикер чолганышында яшәвемне үз вакытында мин аңлап та бетермәгәнмендер.

Вакыт-вакыт Туфанның китабын кулга алам да гасыр башында дөньяга килгән шагыйрьнең хисси бишегендә тирбәлеп карыйм. Җан җылына башлый. Сүзләрнең агышы, тәме башка... Исәпле акылны бусага артында калдырып, самими дөньялар ишеге ачыла.

Юк, яңа гасыр башында татарның йөрәге болай типмәс инде. Башка аһәң, башка сыктаулар булыр... Шигырь кысаларына сыеп хискә бирелү бәлки яңа гасырда бөтенләй кабатланмас, кешелек гомеренең садә балачагы булып, тарихның аргы ярында калыр. Компьютерлы замана адәми затны, әчке нур-җылысын суырып алып, бүтән яссылыкларга ташлар.

Шигърияткә акыл керә бара. Борынгы Мисырның Әбү-Сәмбел мәгарәсенә язылган хикмәтле сүзе искә төшә: «Әгәр йолдызларны ни хәрәкәткә китергәнен белсәләр, сфинкс шаркылдап көләр дә, яшәү туктатыр...» Мин бу гыйбарәне искә төшереп, тетрәнеп китәм.

Тынып торчы, галиҗәнаб акыл! Мин бу мизгелдә Туфан дулкынына күчеп, дөньядан аерылам. Рәхәт тибрәнеш... Ләйсәнле шифа... Үкенечле моң... Ялгышу ызаннары... Гомер кыясының гөлләргә туфрак булып уалган с и к с ә н  б е р ташы... Кайсы гөл, яшел җил булып, талгын гына пышылдый: «Талантлы син, Кеше Туганым...»

Тәэсирләр, күңел сурәсе булып, бер тыннан сүзләргә әверелә:

«Агыла да болыт агыла».

## Тәңренең тамгасы белән

*Ишетсеннәр моны олылык иялөре*

Утыз Имәни

Кая китте соң әле дога урынына шигырьне өстен күргән еллар? Тукай клубында бер-бер артлы сәхнәгә чыккан шагыйрьләрнең фикер ярлылыгына бай булуыннан арып, янәшәдәге кызлар белән сүз уйнатып утыра идем, кинәт... залның арткы диварын да уятырлык итеп тәгәрәп килгән көчле,яңгыравык тавыштан сискәнеп, башны күтәреп карадым. Сәхнәгә — кара мыеклы, ялтырап торган пеләш башлы озынча йөзле шагыйрь чыгып баскан. Тар иңсәле ыспай гәүдәсендә костюмы да чат килешле утыра. Дөнья кайгысын иңенә салган шикелле җитди кыяфәт... Якты баш, дим, кызларның игътибарын җәлеп итәргә тырышып (Яшьли пеләшләнгән кешедән көлү безнең милли сыйфатыбыздыр мөгаен). Ә эчемнән уйлыйм: бу кыяфәт белән ул кемне дә битараф калдырмас. Эллада скульпторлары да бу башны өлге итеп алырга кызыгырлар иде.

Без мәңгегә, без мәңгегә монда,
Эх, бу җирләрне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары.

Әллә ничек, моңлы көй сүрүенә төреп укый, моңдый шигырьне кабул итәр өчен җирдә — яфрак белән яфрак сөйләшкән, күктә исә йолдыз белән йолдыз серләшкән шартлы мизгелдә, табигать кочагында самими халәткә керү кирәктер. Ә минем, яшь кан типкән тәнемне андый талгынлыкка дучар итеп, замана шау-шуыннан читтә калырга исәбем юк. Нинди кыңгырау, нинди атлар — архаизм! Чабаталы чордан китә алмаган шагыйрьләр кавеменнәндер бу, дип, эчтән вәкарь белән хөкем чыгарам. Маңгайны җир шарына тиңләп, «планетар» фикергә «ирешкән» ак шигырьләр язып йөргән беренче курс студенты әнә шулайрак «фәһемле» иде ул чакларда.

Чынбарлыкта исә Шагыйрь үзе йөгәнләгән аргамакларда алдагы чорларга томырылып чапкан икән. Үз вакытында аңламавыбызга үпкәләми генә, юлга маяклар тезеп, безнең килеп җиткәнне көтеп торган...

Җитмешенче елларда кат-кат тыңланган бу шигырьне, менә хәзер гасыр бетәргә аз гына калган бер дәвердә, кулыма алып, яңадан укыйм. Колагымда — шагыйрь тавышы, һәр сүз артыннан эзәрлекләп, озата бара. Укыйм да... гамьле сокланам. Курку һәм өмет арасында яшәргә мәҗбүр ителгән бу тормышта, ятим калган хәтереңне уятып, дәүләтле халыкның варисы икәнеңне аңларлык горурлыкка ирешкәч кенә бу шигырьне үз олылыгында кабул итәргә мөмкиндер. Әгәр инде кыңгыраулы атлар күңел капкаларыңнан сыеп керә алмый икән, тояк тупырдауларының дәртле кайтавазы әсәрендерми икән, син — коллык бөкресе чыккан гәүдәң әсирлегендә тезләнгән рухыңны аягүрә бастыра алмыйсың инде... Тәкъдиреңә язылган җан асрау халәте белән килешергә мәҗбүрсең.

Әйе, халкыбыз язмышына караган бүгенге мәгълүмат аша шагыйрьнең әсәрләре яңа бер тирәнлектә ачылып китә. Аның шигъри ноталарга хилафлык китермичә, кыю-тәвәккәл фикерләве үткен күңел күзе төшәрлек хисси ярага кагыла. Ул искәрткән чәчәкне күтәреп карасаң... таҗлары астында — канлы хәсрәт...

Болан күзе сыман моңлы итеп,
Карый ласа монда һәр тамчы!

Җитмешенче елларда Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрен укыганда мине ризасызлык биләп ала иде: нинди мифик дошман? Нинди көрәш? Нигә бәргәләнә бу җан? Галибанә матурлыкка сокланып илһамланыр өчен яратылган үз аһәңе бар югыйсә, нигә канәгатьләнеп, тыныч хасияткә күчә алмый? Әрнү... Сагыш... Бетмәс хәсрәт... Юк, болар мине ардыра, гаҗиз итә, һәм мин, сыктаулы шигырьләрне читкә куеп, бөтәннәрнекен, канәгатьлек хисе өстенлек иткән әсәрләрне кулга алам. Мондыйларны уку рәхәт, җанны талкытмый, ваемсыз тойгылар аша вакытны рифмаларда тирбәтеп йоклатырга була.

Зирәк шагыйрь исә шул елларда ук халыкның күз яшьле тарихы сакланган җиде йозаклы мәгарәләренә белем аша түгел, ә шигъри тойгылар дулкынында үтеп керә алган һәм андагы коточкыч фаҗига-афәтләрнең гарасатлы шәүләсен сиземләп, шуны якты дөньяга чыгарып фаш итүне максат итеп куйган икән.

Иске бу дөньяга күп хәлләрне
Сөйләмәгән әле яшь йөрәк.
Ә сөйләсәм... канга буялыр күк,
Өстемдәге шушы ак күлмәк.

* * *

Илленче еллар ахырында татар поэзиясендә «шинельле шигырьләр» өстенлек итә, Европагача җитеп, яу кырларыннан исән кайткан фронтовиклар әдәбият мәйданын тота иде. Әмма яшь шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов бу агымга ияреп китмичә, яралы җаннарга шифа бирерлек чәчәк җылысын, кимсенгән күңелләрне юатырлык сүз тәгъбирен «туфанлы хис», «туфанлы моң»га төреп, йөрәк биеклегенә күтәрергә алынды. Әгәр ул истәлек-хатирәләр язса, иҗатына Хәсән Туфанның никадәр бәрәкәтле йогынтысы булуын тәфсилләп сурәтләр иде. Хәер, олуг остазына рәхмәте аның күп кенә шигырьләрендә чагыла, ак кәгазь каршында ул аның чал яктысын һәрчак тоеп яза иде.

Әлмәттә ташчы булып эшләгән яшь егет — Рәшит белән танышуын Хәсән ага болай дип теркәп калдырган:

«...1957 елда 16 яшьлек Рәшит Әхмәтҗанов нефтьчеләр газетасы редакциясенә беренче шигырен китерә. Редактор белән секретарь укып карыйлар да, бераз гаҗәпләнеп, үзара ымлашып алганнан соң:

— Үзең яздыңмы бу шигырьне? — диләр. Уналты яшьлек малайның шундый шигырь язуына ышанып бетмиләр.

— Безгә менә хәзерге күз көне турында бер шигырь кирәк иде, язып кара әле,— дип Рәшитне бер буш бүлмәгә кертеп, ишекне бикләп куялар. Нигә язмасын, ачык һавада,— яңгырлар астында да ташчы булып эшли башлаган бу егеткә Әлмәт көзе бик таныш ич,— яза, һәм бу — сыналу шигыре газетада басылып чыга.

Алтмышынчы еллар башында Сибгат Хәким белән Әлмәт ягына, халык арасына чыккан идек. Безнең номерга кыяфәте һәм холкы белән Шәүкәт Галиевне хәтерләткән сөйкемле егет килеп керде. Рәшит исемле бу егет үзенең шигырьләрен укып карарга, киңәш алырга теләвен әйтте.

Укыдык. Шигырьләрен дә, үзен дә яраттык. Ләкин без дә Әлмәт газетасы редакциясендәге вакыйганы белмәсәк тә, сынап карарга теләгәнбездер, күрәсең: шигырьләрнең кайберләрен төзәтеп-үзгәртеп, яңадан язып китерергә киңәш бирдек. Икенче көнне үк үзе төзәткән вариантларны алып килде. Шактый таләпчәнлек белән тагын бер кат күздән кичердек һәм әдәби табыш икән бит бу егет, дигән фикергә килдек».

Казан дәүләт университетында укыганда ук Рәшит Әхмәтҗановның беренче китабы дөнья күрә. Шул уңайдан, бер вакыйганы алардан соң без укырга кергәч тә көлеп сөйлиләр иде әле. Имеш, Рәшит атна буе университетка барып күренмәгән, укырга йөрми икән. Кафедрадан моның хәлен белергә дип старостаны җибәргәннәр. Яңа китабы белән хозурлану көннәре кичергән Рәшит Әхмәтҗанов аңа болай ди:

— Нигә барып йөрим, укытучылар үзләре әнә минем китапны укысыннар...

Шаянлык аңа тумыштан бирелгән иде. Нинди дә булса хикмәтле сүз әйтә дә, үзе үк, түбәдән кар ишелгән кебек итеп, гөмбердәтеп көлә башлый. Мондый да сәхнәви көлүгә иярми кара! Ул, җәмгыятьнең ясалма кануннарына ярашып, сәләте чамалы килеш тә йолдыз тотарга үрелүчеләрдән ачы итеп көлә белә, әгәр күзәтүләрен проза итеп язса, чордаш шәхесләрнең сурәтен нечкә юмор белән елмаю диварына кадаклаган булыр иде. Кызганыч, юморның цензура тарафыннан кысылган көлү дәрәҗәсе ул дәвердә кәрлә биеклектә генә иде шул. Бәлки шуңадыр, сәнгатьле көлә белү сәләтен кәгазьгә гарипләндереп төшерәсе килмичә, редакция коридорларында тәмәке тарткан арада чордашларының күзенә төтен җибәрү белән канәгатьләнә иде ул.

Ә бәлки... гаҗәеп нечкә зәвыклы лирик өчен югары шигърият серләрен телбизәкләргә төреп бирә белгән каләмен юмор карасына ману — килешеп тә бетмәгәндер. Чөнки ул үз бәясен үзе белә иде!

* * *

Дуслар җыелган җирдә ул бер шигырен бигрәк тә яратып сөйли иде. Әле генә шаярышып-көлешеп утырган була, әмма шул хикмәтле шигырен сөйләргә дип баскач, бөтенләй үзгәреп китә, гүя җаны тәннән аерылып, хәвефле ерак дөньялар белән тоташа, күз карашында шомлы моң оеп кала...

Туган илдә чәчәк җылысыдыр.
Эх, шул җиргә ятып җылыйсы бер!
Кайтма диеп озатмадылар.

Йөзләр генә сары, баш исән.
Аккошлардан корбан чалыр идем,
Туган илгә кайтып житәлсәм.

Корбан буласы кошың һавада,
Илгә җитсен... Минем юлны бүлеп,
Каф таулары ята арада.

Бу шигырьдән соң бермәлгә уңайсыз тынлык урнаша, сүз җебе ялгана алмый, кырлы стаканнарда кыжраган утлы хәмер генә утырдашларның тел куәсен әкренләп әүвәлге хәлгә кайтара иде. Шигырьне күпләр кабул итә алмый, «...корбан чалыр идем» дигән юлына төртеләләр дә, шагыйрьне каты бәгырьлелектә гаепләп, кан чыгару фәлсәфәсен куерталар иде. Андый чакта Шагыйрь «Наданнар сез!» дип усалланып куя, әмма шигыренең бөтенлеген таркатып, үзенең хаклы икәнен исбатлаудан ерак тора иде. Шәхсән үземә бу шигырь сәерлеге белән ошый, «корбан чалыр идем»е эффект өчен кертелгән, шагыйрьнең кылануыдыр дип карыйм, эчтәлеге хакында ныклап уйланганым юк иде.

Еллар үткәч, вакыт-вакыт хәтергә төшеп, аңымны сызып үтә торган бу шигырь, кинәт күк капусы ачылган кебек, зиһен офыкларымны яктыртып җибәрде.

Йә Ходай!

Кеше җанының Иблис кодрәте җитмәслек упкынына, акыл һушсыз калып убыла торган тирән упкынына каләм иясенең күз салуы бит бу! Нигә соң әле мин аккошны сузып салып корбан чалу мизгелен күз алдыма китереп гөнаһланам?! Нигә мин чит илдә калып, туган иленә мәңге кайталмыйча яшәргә мәҗбүр ителгән Исхакый кебек мөһаҗирләрнең каһәрле, хәсрәтле, өметсез язмышын йөрәгемнән кичереп карый алмыйм?! Шигырьнең исеме «Сагыш» дип атала ич. Өмете өзелгән ирнең гасабиланып кычкыруы — «Аккошлардан корбан чалыр идем...» — ирексез җанның нәгърә оруы булып яңгырый. «Идем...» — никадәр ачы хәсрәтнең актарылып чыккан сыктау-сулкылдавы... Әрнүле газап авызы, сагышның тере сурәте!

Юк, бу шигырь ак кәгазь битенә төшмәгәндер, аны адәм баласыннан өстен күк һәм җир сагышы, иелеп, дәһшәтле тылсымын пышылдагандыр сыман...

Бу шигырь — аң-зиһен галәменә буйсынмый торган хисси бөеклек, реквием, көтелмәгән ачыш түгелмени!

* * *

Бәләкәйдән, буразнага күмелерлек чактан ук ачлык-ялангачлык кичергән, сугыш барган яклардан качып килгән явыз бүреләрне, ак өмет вәгъдә иткән ләкләкләрне күреп, Кандыз суында коенып үскән, бәлигъ булгач инде шәһәрләшсә дә, авыл-табигать ләүкәсендә һәрчак пакъланып алып, рух сафлыгын кайгыртып яшәгән шагыйрьнең тышкы кыяфәтен дә, холык-фигылен дә берничә сызык белән ашыгыч кына сурәтләү мөмкин түгелдер. Вакыты белән ул беркатлы, вакыты белән меңкатлы күренә. Үзен бәяли белмәгән заманга усалланып та алгалый, аннары, тиз арада тынычланып, мөлдерәп караган сабый хәлендә кала. Көндәлек тормышта юмарт, кунакчыл булса да күңел дөньясы ишекләрен һәркемгә ачып куярга ашыкмый; керләнгән уйлы, хөсетле затлар өчен аның бусагасы биек иде.

Аның кебек тә килештереп, тәмле итеп зарлана белүче бүтән булыр микән? Менә шундый чакларда аның артистлык сәләте ачылып китә иде.

Бервакыт мин аны кызык итәргә булдым. Гадәттәгечә күрештек. Сайрар алдыннан кош канатларын төзәткән кебек, сизәм, Рәшитем иркенләп зарланырга әзерләнә. Шуны сизенеп мин үзем башлап «Һөҗүмгә» күчтем:

— И-и Рәшит, карап торам да... бигрәкләр дә бәхетсез кеше инде син, әй! — дип башлап җибәрдем дә тезәм генә.

Рәшитемнең күзләре зур булып ачылды, гәүдәсен җитез генә калкытып:

— Син нәрсә, багърем, мине мыскыл итәсеңʔ! Минем андый көнгә калганым юк, Аллага шөкер! Мин әле!..

Әһә, ачтыңмы асылыңны, дигәндәй эч тотып көлүемне күреп ул туктап калды, аңлап алып, үзе дә кушылып көләргә кереште, ике колагы берьюлы кызарып чыкты. Шуннан соң ул мине күргәч, хәтерлим, дигән шикелле елмаеп куя да берәр мәзәк хәл искә төшереп сөйләргә тотына иде. Зарлануы исә калкан гына, миңа да тормыш җиңел бирелми, берүк көнләшеп күз тидерә күрмәгез, дигән кебек, кешеләрдән саклану чарасы иде бугай. Шулай итеп Шагыйрь кешеләр арасында әвәрә килә: шаяракөлә, кемгәдер ялгыш бәрелә, рәнҗи, сөенә-көенә, таба-югалта — тормыш кайный, әмма күнеле һәрвакыт уяу, кагылгысыз биеклектә сүз дәрьясыннан телбизәкләр эзли... Ходайның һәр бирмеш көне аңа, бал корты кебек, сүз таҗларыннан микъдарлап нектар җыю өчен багышланган. Тамчылап җыелган илһам касәсен чайпалдырмыйча үз түбәң астына кайтырга да, вакыт белән бергә-бер калып, шигъри буразналарга тәһарәтле уйларың белән кереп китәргә... Бусы инде — газаплы сәгадәт. Киләчәк гомер өлешеңә кереп, йөрәгеңне рәхимсез талау... Башкача булмый. Тәңренең тамгасы белән тугансың икән, сиңа бу җирдә олы миссия йөкләнгән.

Ашыгырга кирәк...

* * *

Сүз сәнгате чарлана башлаган бакый заманнардан бирле дастаннар, поэмалар Шәрык шигъриятенең мең еллык тарихын билгели. Поэма язалмаган шагыйрь, бөркет булалмаган кош кебек, әдәби мирас тәхетеннән читкәрәк этелеп карала. Безнең гасырда үзе хакында легендалар тудыруга сусаган тоталитар җәмгыять эпик поэмаларга бигрәк тә мохтаҗ иде. Күп кенә өлгер шагыйрьләр, әлеге хакими теләкнең кендегенә басып, дан-дәрәҗәләр яулап, кинәнеп яшәп калдылар. Әмма житмешенче еллар азагында инде йөрәк кушканны язарлык мөмкинлекләр дә яуланган иде.

Поэма язу — мамонтны терелтергә тырышу кебек заяга сарыф ителгән көч түгү, дип карасам да, бу авыр жанрны иярли алучыларга барыбер, аерым хөрмәт белән карый идем. Рәшит Әхмәтҗановның исә поэма язарга алынуы ничектер көтелмәгәнрәк булды (Бәлки ул моңа гомере буе әзерләнгәндер).

Беренче поэмасын укырга дип ул Эльс Гадел белән мине өенә чакырды. «Килегез, багырьләрем. Луиза апагыз өйдә юк. Аулак өй. Соңыннан бераз утырып та алырбыз...» — диде.

Бүгенгедәй күз алдымда: кояшлы, матур көн иде. Иркен кухняның җылы идәненә җәелешеп утырдык. Рәшит бераз каушый да, бераз уңайсызлана да шикелле. Әле кәгазьләрен рәтли, әле борынынннан тып-тып тамган су кранын борып куя, тамак кырып ала — шулай итеп корыла бу, корыла... Менә ул безгә яңы беләнрәк утырып, поэмасының беренче битен ачты. Без тынып калдык. Ул борынгы көйгә салып укый башлагач, еракта калган балачак искә төшкәндәй булды. Гүя мин буранлы, шомлы төндә, бүре улаулары ишетелеп торган кышкы төндә, сукыр лампа яктысында Сак белән Сок бәетен тыңлыйм. Юк, миңа боларны күз алдыма китерергә якты тәрәзә, кафельле стеналар комачаулый. Рәшит һаман укый, ә без, вакыт исәбен югалтып, тыңлыйбыз да тыңлыйбыз. Моның азагы булмас шикелле иде, кинәт, коткаручы табылды бит! Зал ягыннан көтмәгәндә бер бала җылаган тавыш ишетелде. Тыны да чыкмагач, искәрмәгән дә идек, анда Рәшитнең дүрт-биш яшьлек малай тыңлап утыра икән лабаса.

— Нәрсә булды икән блондин улыма? — дип Рәшит җәлт кенә сикереп торды. Аксыл-сары чәчле улын «блондин» дип йөртә иде ул. Аның, олы бүлмә ягына чыгып: «Нәрсә булды, улым Айдар?» — дигәненә каршы сабыйның:

— Кызганыч бит, әти... — дигән җавабы ишетелде.

Бу сүзне ишетеп без, Эльс белән бөкләнеп көлә-көлә, идәнгә тәгәрәштек. Шулай итеп буа ерылды.

— Малаең иң көчле тәнкыйтьче булып чыкты! — диде Эльс.

— Сезне чакырган мин җүләр... Көләргә генә булсын сезгә! — дип Рәшит үпкәләвен белдереп турсайган иде, Эльс, бәрхет-баритон тавыш белән, дикторларча һәр сүзне табигый йомрылыгына җиткереп, поэманың барып чыкмаганлыгы хакында сеңдереп сөйли башлады. Тора-бара сүз табынга күчеп, хәмер ялкыны да кушылгач, баштарак мәлне нык үҗәтләнеп каршы торган Рәшитебез әкрен-әкрен генә бирешә башлады. Кичкә таба инде өчебез берьюлы сөйләр дәрәҗәгә җитеп кызышканда ул поэмасын бөгәрләп чүп савытына ыргытырлык булып өлгергән иде.

Аннан соңгы дистә ел буена Рәшит Әхмәтҗанов берничә поэма язды. Борынгы Шәрык акыннары кебек, олпат яшькә җиткәч тә саекмаслык шигъри куәте бар иде аның. Халыкның данлы пәм шанлы язмышын тарих анналларыннан казып алып, искиткеч бай һәм гыйбрәтле татар эпохасын поэмаларга сыйдыру осталыгы аңарда җитеп ашкан иде.

Хәтеремдә: «Бишташ» поэмасын ул, серле кош тоткан кебек, сак кына кулыма тоттырып, редколлегия әгъзасы буларак, журнал өчен фикер язып килүемне үтенгән иде. Язганмын. Төп нөсхә, гадәттәгечә, каядыр уралып кереп китеп югалган. Менә хәзер, Рәшит Әхмәтҗанның әсәрләрен сайлап, җыентык төзеп утырган көннәрдә, кәгазьләр арасыннан килеп чыкты. Андагы кайбер юлларга яңабаштан күз салу хилафлык булмас дип уйлыйм.

«...Ташка табыну күп халыкларга хас. Японнардагы ташлар бакчаларын гына искә төшерик. Бездә дә нигез ташы дигән хикмәтле сүз бар. Гомумән, табигатьтә, ташлар каршында адәм баласы үзе дә сизмичә сүзсез кала. Әйтерсең лә ташларның җаны бар. Син аны өнсез калып тыңлыйсың. Галәмнең яралышына шаһит булган ташларга җирнең дә, кешелекнең дә бөтен тарихы сыйган. Аны ишетә, тоя, сизә белү һәркемгә бирелмәгәндер.

Рәшит Әхмәтҗанов бу поэмасында ташлар белән җан телендә сөйләшә. Гадәти хикәяләү, проза чалымнарына төшәргә бөтен мөмкинлекләр бар югыйсә: әсәрнең үзәгендә — Әлмәттә йортлар салучы ташчы егет. Яңа шәһәр салынуга багышлап сокланулы, купайтулы күпме әсәрләр вакытлы шаукымга ияреп язылмагандыр. Рәшит Әхмәтҗановның бу поэмасы — бөтенләй башка... Ул ташчы-төзүче чагында кайнаган хисләренең шагыйрь дәрәҗәсенә җитеп олыгаюын көтә белгән. Һәм шушы сабырлык, хисләрнең кайнарлыгын җиңү аны, лирикасына хилафлык китермәгән хәлдә, фәлсәфи, тыгыз мәгънәле әсәр язуга китергән.

Үзәктәге каһарман — ташчы кешеләргә оя кора, аның кулында кешене җылытучы таш. Ә шагыйрь күңелендәге — тарих. Ул җылы таш рухын аңлап, дәверләр буйлап сәяхәт итә. Таш — дошманга ыргытыласы корал да, дус каберенә куеласы истәлек тә, бизәнү әйбере дә. Кеше кулында таш көчле дә, көчсез дә икән әле.

...Югары кимәлдә, шигъри куәт белән язылган бу поэма телнең төмен белеп, игътибарлы укуны сорый. Сәләтле укучы аны аңлап, яратыр дип уйлыйм.» (1986. 2 октябрь).

Ул елларда яңа поэма тәгәлләгән шагыйрьдән каләмдәшләре арасында көнләшү хисе туу да гаҗәп түгел иде. Ярый ла ул көнләшү маңгайга сырлар уйдырырлык каршылыклар китереп чыгармаса...

Бервакыт Рәшит Әхмәтҗанов «Карачкы» дигән поэмасын бастыру хафасы белән йөри. Борчыла, шикләнә, әллә нинди фаразлар уйлап чыгара. Шундый мәрәкә килеп чыгуга үзе эчтән канәгать тә шикелле...



*Рәсемдә: (сулдан-уңга) язучылар — Рәдиф Гаташ, Рәшит Әхмәтҗан, Диләрә Зөбәерова, Кояш Тимбикова. 1990 ел, җәй.*

Поэмасын шулай кулдан-кулга йөртә торгач, эчке рецензия язарга дип миңа бирделәр. Тиз генә укып чыгып, фикерләремне яздым да, хәзер килеп җитәм, дип үзенә телефоннан шалтыраттым.

Нәшриятның унынчы катына менеп җитеп лифт ачылуга каршымда басып тора бу:

— Багърем, сине дүрт күз белән көткән арада газиз акчама алган бер пачка сигаретны тартып бетердем,— дип, язган кәгаземне кулдан алды да, авыл агайлары сыман чүгәләп, аркасын стенага терәп тарта-тарта, укып та чыкты. Аннары, сикереп торып, кулымны кысты:

— Рәхмәт, багърем. Бу яхшылыгыңны ил онытмас... Артыграк та чөйгәнсең бугай, дусларны көнләштереп...

Аның кыяфәтенә, йөрешенә, бөтен гәүдәсенә таралган сөенүен, чын-чынлап куануын күреп мин гаҗәпкә калдым. Минем язу булмаса да поэмасы басыла бит инде югыйсә... Бәлки хикмәт анда түгелдер, бу халәтнең асылы тирәндәрәктер... Күпме айлар, күпме йокысыз төннәр буе илһамланып, үз-үзен аямыйча шушы әсәр вакыйгалары хәятендә яшәп ул, тәмам арып, таланып, йончып, бүгенге көнгә җиңүче булып кайтып төшкән бит. Яңадан туган кебек, бу тормышка сабыйларча күнегеп кенә барган мәлләредер. Поэмадан бушанган Шагыйрьнең, фәрештә кебек, бер гөнаһсыз калган таркаунәүмиз халәте...

Шул чакта ул җәһәт кенә машинкада бастырып алмаган булса, үзем өчен югаласы язмамда мондый юллар булган икән:

«Ярый әле... бу дөньяда акыл һәм хис тәңгәллегенә тере сулыш биргән шигърият бар. «Мин кеше!» дигән затның гаҗәеп сәнгать җәүһәрләре тудыра алуына сокланып карыйм да... икенче кулы белән меңнәрчә еллар дәвамында үз кавемен изәр, юк итәр өчен акыл ирешмәслек явызлыклар кылуына шаккатып, чарасыз калам. Кем син, Кеше? Каян килдең син бу Җир-Анага? Явызлык һәм миһербанлыкны үлчәр бизмән

каршында аптырап калган мизгелдә адәми затның җан авазын, илаһи хисләрен исәпли алмый торган рухи урталык — тел куәсенең галәми тәэсире — шигърият ярдәмгә килә. Шигърият сүрүенә кергән моң, сагыш, әрнү җирдәге кырыс кануннарга сыеша алмыйча, адәмнең асылын, яшәешен, рухи халәтен табигый чынбарлыктан өстен яссылыкка менгерә ала. Менә шул чакта инде син, чистарынып, көнкүрештәге болгавыр ваклыклардан арынып, яңадан туа аласың.

Поэзиянең көче — гомерне яңарта алуда.

Мин әле һаман «Идегәй» дастанының шифалы кайтавазында яшим. Күңел чикләрен соңлап булса да мең авазлы оркестр киңәйтеп җибәргән халәттә, яңа әсәрләргә дә шул тәэсирләрдән чыгып карыйм.

«Карачкы» поэмасына мин әнә шундый фикерләр белән янып килдем һәм алданмадым. Әсәр, чынлап та, телебезнең югары кимәленнән торып язылган. Олы мәхәббәт турында: заманның фаҗигаләре аша җирдәге тормышны, илне яратуга, иманны сакларга чакырган шагыйрьнең бәгырь авазы җанның акыл сыялмый торган тарлавыкларына хис яктылыгы алып керә. Югарыда телгә алынган дастанның йогынтысын, тәэсирен мин бу поэманың аерым бүлекләрендәге борынгыдан килгән әйләнмәләрдә, фикерне мәкаль тыгызлыгына җиткереп, саллы әйтә белүдә, көй агышында тойдым.

Поэманың эчтәлеген сөйләргә тырышу, аерып, таркатып карау — оста каршында гөнаһ дип саныйм. Аны ялгызың гына укырга, шул дөнья белән яшәп алырга һәм иң гадел шаһит — күңелең белән кичерергә кирәк.

Кеше хисләре җәяүле дә, канатлы да. Таяну ноктаң җирдә чакта күкне онытмыйча, кунаклар ноктаң күк катларында чакта җирдәге тамырың тибешен онытмыйча, асыл урталыкны табып, телнең нечкә җан тибрәнешләрен тоеп яза белү — шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның бөтен иҗатына хас сыйфат. Бу поэмасы белән тагын ул үзе генә тапкан моң чишмәсен кешеләр хөкеменә юллады». (1989 ел, 13 апрель).

* * *

Исәннәрне исәпләгән чакта
Сөю мине таба алмаган.

Мәхәббәттә Шагыйрь — назга сусаган кадерле ятим. Үз холкына хас булганча, хис-тойгыларның моңлы баласы. Бәхетен җилдереп алып киткән аргамаклар артыннан, күз яшенә чыланып, эчтән ялварып йөгерә, тәмам өметен өзеп туктап калган мәлләрендә иң садә хисләрен дога итеп пышылдап, хәл ала да, тояк, тәгәрмәч эзләре калган юл тузанын учына кыса.

Хушлашмыйча еракларга күз төбәп киткән олуг мәхәббәтенә үпкәләгән чакларында ул гади җир кызын искәреп ала, сагыш томаннарын ерып аңа эндәшә:

Гомерне саклый бу җирдә
Кавышыр мизгел генә.
Йөрәгем ярылып үләрмен
Шушы мизгелнең үткәнен
Тик миңа сиздер генә.

Мәхәббәттә Шагыйрь — үзе уйлап тапкан матурлык иленең иркә бер колы; гөлгә — туфрак, җилкәнгә — җил, керфеккә — яшь, дулкынга яр була белә.

Ничек соң мин яшь шаһзадә булып,
Киләлмадым сиңа ак атта?

Мәхәббәттә Шагыйрь — үзе билгәгән дүрт фасыллы дөньяның шаһы; тәхет биеклегеннән әмер генә бирсен, сандугачлар сулавыннан яз, яшел ялкыннардан — җәй, күзләрдәге яфрак төсеннән — көз, аккошлар аклыгыннан кыш туа. Шушы фасыллар арасында ул гүзәл юклыкны эзли, чакыра, алгысына, тагын моңга бирелеп, ләззәтле газаптан бермәлгә чарасыз кала.

Кулыма алтын богаулар
Кил әле, кидер, иркәм.
Югыйсә сазын кылларнын
Өзәрлек итеп чиртәм.

Юк, бәхетен җилдереп чапкан аргамакларны куып җитәсе килми аның. Эзләгәненне табу — югалту мизгеле дә икәнен аңлаган йөрәк ярга якынаюга, кире борылып, үз-үзен сындырып сынаган дулкыннар кочагына кабаттан ыргытыла.

Дулкыннан-дулкынга, йолдыздан-йолдызга, шигырьдән-шигырьгә күчәр өчен аңа туктаусыз сагыш нуры белән өртелгән үкенечле хис, татлы әрнү, җилләр телендә ялвару түбәнчелеге кирәк.

Ләйләле-Мәҗнүнле төрки-татар шигъриятендә Рәшит Әхмәтҗанов лирикасы — әлегә ачылмаган энҗеләр ганимәте, таш диварлар арасында кысылып сула барган күңелләрне коткару-терелтү дәвасы.

Сөю-сәгадәт хәятында үзеңне бәхетсез тойганда гына бәхетле язмышлы шигырь туадыр, мөгаен.

Ә аргамаклар, шигърият алиһәсен җилдереп алып киткән аргамаклар, чакрымнарны, елларны тәгәрмәчләренә урап, һаман алга томылалар. Каләмле хыялга аларны куып җитәргәме-юкмы?.. Тояк эзе саен шигырь...

Менә Шагыйрь офыкка бәрелеп туктап кала. Күзләрендә — яфрак төсе. Йөрәге күкрәк читлегенә сыеша алмыйча тибә. Олы юл тузанын иярткән Сөю аргамагы отыры ерагая, ерагая бара... Дала читенә таянган кояшның моңсу шәфәгынә кереп югала.

Шагыйрьнең соңгы аккорды, бәхилләшү авазы, кош булып күккә күтәрелә дә, иңрәп, дала күкрәгенә егылып төшә...

Дәшәрмен теге дөньядан:
«Без һамандамы бергә? —
Бергәме?! Үлмә, бәгырем,
Мин кердем синең гүргә.

* * *

Казан күге аязлыктан гаҗиз.
Күктә кояш кайный, мәйданда — халык.

Бер төркем язучылар, сәясәтчеләр, ачлык игълан итеп, Ирек мәйданында урын биләп алдылар. (1991 елның май ае). Җөмһүриятебездә Россия президентын сайлауда катнашмау турында сәяси шау куз-гатып, бу тарихи сәгатьнең укларын борып җибәрүче Жанна Д'Арк — «Газиз халкым!» — дип, бәгырьгә үтәрлек чыгышлар ясап, меңнәр күңелен бер итүче Фәүзия Бәйрәмова иде.

Казан күге коргаксыган көннәр.

Аяз күктә кояш зеңләп тора. Эсселеккә чыдар әмәл юк. Аяк астында асфальт эри. Афәтле эсселеккә чыдар да идең — иңнән кагып, «Мәрхәбә, егетләр!» дип китүчеләр артыннан ук, тупас йодрыклы манкортлар кал-

кынып, төнлә һөҗүм оештырабыз дип янап китәләр. Үзен бәхетле санап йөрүче коллар чиркандыра. Ярый әле, үз сәламәтлеген яндыру хисабына көрәшүчеләр арасында Зәки Зәйнуллин бар. Балтиканың тозлы җилләрендә чыныгып, империянең асылын башка халыклар язмышында да күреп кайткан полковникның гаярьлеге кайнар башларны, таш диварга килеп бәрелгәндәге кебек, кире чигенергә мәҗбүр итә.

Болай да ябык Рәшит Әхмәтҗан ничә көннәр буена зәһәр кояш астында ач торып, тәмам какланып, каралып бетеп бәткән. Күзләре генә утырып калган. Ат күзләре кебек — әле ярсу, әле моңсу. Эчендә гүя бер гөнаһ калмаган, шигъри кисәүләр генә көйри...

— Улым, арагызда иң ябыгы син. Менә, каймакка гына тугылап, төче коймак пешереп килдем, бисмилла әйтеп, авыз ит әле, бәбкәм...

— Рәшит улым, минем өчпочмакларымның тәмлелеген Яңа Бистәдә белмәгән кеше юк. Бер төенчек алып килдем, алып кал...

Болар — нурлы йөзле, эчкерсез апалар. Чын-чынлап, Шагыйрьнең хәленә керергә тырышып мәш киләләр. Ач торган чакта ашарга ярамаганлыгын Рәшит Әхмәтҗанов аларга һич кенә дә төшендерә алмый. Елмаеп шаярта-шаярта, елмаеп битәрли-битәрли аларны озата.

Бераздан халык төркеме өстендә анык микрофоннан көчәйтелгән тавышы яңгырый:

Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча
Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.

Шул җәйдә, Декларация кабул ителәсе көндә дә Шагыйрь халык белән бергә иде (1991 ел, 30 август). Ирек мәйданының беркайчан да болай кеше диңгезеннән тыгызланганы булмагандыр. Халык ташкынын тыяр өчен катлы-катлы милиция чылбыры тезелгән. Һәр адымны үлчәп яшәргә өйрәнгән йончу ирләрне уздырып, алгы сызыкка хатын-кызлар, әбиләр чыккан. Ак яулыклы әбекәйләр кирәк чакта гавамны үссендереп җибәрәләр, кирәк чакта — ак намазлык өсләрендә Ходайдан ярлыкау-сабырлык сорыйлар.

Мәйданда — д о г а л ы читекләр.

Мәйданда — д а г а л ы итекләр.

Әнә ул, яшел байрак асларында Шагыйрь халыкка сүз кодрәте чәчә. Шигырьләре — тышауларын өзеп, күкрәге белән тарих араннарын бәреп чыккан юргалар кебек. Сулышсыз калып тыңлаган мәйдан йөрәгендә дәүләтле, ханлы һәм канлы гасырлар кайтавазы уяна, коллык йокымсыравына күнеккән тәннәрдә татар каны уянып кычкыра башлый.

Халкым бүген ирек алалырмы,
Богавында әллә калырмы?
Көчкә сулыш алып яткан бөркет
Көтә шулай соңгы давылны...

Кинәт мәйдан, тылсымлы кул ишарәсенә ияргән кебек, дәррәү каерылып өскә карый. Югары Совет бинасының алтынчы кат тәрәзәсендә булачак президент басып тора икән. Артында бер төркем яраннары да шәйләнә. Хәлиткеч Декларация кабул ителер алдыннан озын тәнәфес вакыты бу.

Ялгыш сызылган бер шырпыдан кабынырга торган халык бер мәлгә тын кала. Тыкрык саен ябык машиналарда корыч мускуллы ОМОНчылар, бронежилетлы, резина таяклы, нурсыз күзле бу егетләргә кеше тәнен һәм рухын таптау фәне өйрәтелгән — бу мизгелдә алар да тып-тыныч.

Булачак президент биектән, тәрәзә аша мәйданга төбәлгән. Гүя сүзсез дуэль бара. Корридадагы кебек хәвефле секундлар. Тореодор ике үлем арасында... Каршында — шашкан үгез үткен мөгезләрен төбәгән. Үгездән — канлы үлем. Халыктан — рухи үлем. Әгәр тореодор үгезне, сәнгатьле итеп, нәкъ вакытында аудара алмый икән, халык аны сыз-

гырып, мыскыллап аренадан озатачак. Әгәр инде оста итеп, нәкъ вакытында сыртына яткырса, халык тореодорны милли каһарман итеп пьедесталга менгерәчәк. Тореодор — хәтәр ике көч арасында...

Булачак президент тәрәзә каршында торараш калып басып тора. Менә хәзер аның бер бармак селкүе житә, куәтле ташкын халыкны тапап чыгачак. Кайсы хакимнең тарихта мондый ләззәттән ваз кичкәне бар?! Кайсы хакими затның, меңнәр жанын кыеп, кан чыгарып, даһи титулын аласы килмәс икән?!

Тарих явызлыкка табына, яхшылыкның хәтере кыска...

«Камыр булма, Минтимер!» дигән плакатлар арасыннан халык аңа төбәлгән. Бу мизгелдә аның күңелендәниләр кайный, бер үзе генә беләдер... Мин үземчә фикер чыгарам: дүрт гасырдан соң, ниһаять, чын татар моңыннан яратылган татар хакиме... Әнкәсенең бишек жыры, чалгы тавышлары, сандугачлы Агыйдел әрәмәлекләре... Аның тән күзәнәкләренә таралып, сезме мәрхәмәт сорап пышылдадыгыз? Югыйсә, әмер генә көтеп, тәкатьсез торган шундый көч, тимер ташкын көл астында була торып! Юк, мондый мизгелдә кан чыгарып дан алудан шәһәр ташында туып үскән, ят тәрбия алган салкын жанлы шәхес чирканмас иде, тәхет биеклегеннән бурзайларга явыз әмерен ташлар иде.

Ә ул «иде»гә таянмыйча халыкка карап тора. Чыгышы белән ханнар нәселенең турыдан-туры дәвамы булмаса да, язмыш-әнкә аңа солтанатлы исем куштырган. Күп кенә олуг ханнарның исемендә «тимер» булу юкка түгелдер: Төп Тимер, Туган Тимер, Мәңге Тимер, Тимер Котлык, Тимер Мәлик, Тимер Хужа, Тукай Тимер, Баш Тимер, Шаһ Тимер һ. б.).

Шулай итеп... Мәйдан көтә. Тореодор — аренада...

> Буйсынма! Буйсынма! Нәкъ сиңа
> Жир-күкнең әмере бирелгән:
> Илеңне азат ит иң элек,
> Жан азат бары тик Ил белән.

Декларация кабул ителгән ул көн һәм төн Рәшит Әхмәтжан өчен утлы шигырьләрдән генә тукылган иде. Аның «Ачлык мәйданы» дип исемләнгән шигырьләр бәйләме — кылыч йөзеннән йөргән хәвефле көннәр, төннәр биргән аһ-зарлы, газаватлы илһам кодрәте, гомеренең истә кала торган шомлы тантанасы иде.

* * *

Бер гаилә булып түгәрәкләнгәнбез. «Казан утлары» редакциясенең гадәти генә бүлмәсе — бәйрәмчә. Иске елның соңгы көне (1994) Табын мул. Иң уртада — һәртөрле салатлар, шәрап шешәләре арасында — кыздырылган кыр куяны, хуш исле яшеллек, лимон кисәкләре арасыннан күз карашын тартып тора. Кама ярының ак карлы тугайларыннан атып алынган. Баш редактор Равил Фәйзуллинның Яңа ел күчтәнәче.

Табын сандугачы — Рәшит Әхмәтжан. Кәефе шәп. Һәрвакыттагыча, пөхтә киенгән. Эчтән балкып, гәүдәне төз тотып, очынып кына йөри.

Телләр язылып килгәндә, иң өлкән кунагыбыз — ашау-эчүнең төмен, рәтен, кадерен белгән Аяз ага Гыйлажевка куян түшкәсен бүлүне тапшыргач, Рәшит Әхмәтжанов тост әйтергә дип басып, табынны йөгәнләп кенә алды. Һәр сүзнең кытыгын китереп, шау көлдереп үзе уйлап чыгарган мәкальләр белән сипләп, шаян тост әйтте дә, житдиләнеп: «Моны истә калдырыгыз, багырьләрем, бүтән ишетмәссез» дип, беребез дә моңарчы ишетмәгән сәер бер жыр жырлады.

Үзе дә белмичә, шулай жиңел, рәхәт итеп, безнең белән бәхилләшүе булган икән...

Яшьләр коридорга бүселеп чыгып биегәндә ул, бармак арасына кыстырган тәмәкесе белән киңәшеп, көч биреп торды:

— Бик кызмагыз, багырьләр. Рудольф Нуриев кебек бию осталарына да көнгә өч тапкыр гына чүгәргә рөхсәт ителгән. Яңа елга керәсе бар.

Шулай диде дә... үзе... Яңа ел бусагасында...

Шунысы гаҗәп, ул әйткән тостның да, җырының сүзләрен дә, никадәр бәргәләнсәк тә, кабат искә төшерә алмадык. Әйтерсең лә соңгы көнен Иске ел хәтерләрдән юып алган, гүя серле төш күреп, без аның өнсез рухы белән генә аралашканбыз.

Бер уй тынычландыра: аның иҗаты үзеннән башка да ятим була алмый икән. Актык сулышынача гомерен шигърияткә багышлаган шәхесләр сирәк була. Рәшит Әхмәтҗан шундый могътәбәр сирәкләрнең берсе иде.

Ул — матбугатта һәрбер тәнкыйтьче саный торган тутәл-тутәл исемлеккә сыя алмыйча, үзе бер дөнья булып иҗат итте.

Әгәр аңа Күк иясе:

— Шигъриятнең пәйгамбәре итәм, калган гомереңнән ваз кичәсеңме? — дисә, ул сүзсез риза булыр, халык бәгыренә тәңгәл килгән чын шигърият хакына җирдә бүтән мәңге кабатланмаячак тормышын мәхрүм итәр иде.

Иртәрәк китте... дибез.

Күкрәк читлеген аерып чыгып, галәми чиксезлеккә очарга дип талпынган җан кайчан өлгереп җитә? Моның белән кем идарә итә? Бәлки... иҗат гөмбәзең билгеле бер кимәлгә җиткәч, үз зурлыгында күрсәтү өчен аны шәхестән аерып алуны Тәңре үзе хәл итәдер.

Казанның Татар зиратында, гасырның мәртәбәле затлары куелган урында, бөек Тукай янында күмелү бәхете... очраклылыкмы? Ике шагыйрьнең янәшә килүе — алдан билгеләнгән тәкъдирме?

«Минем гасыр таңымдагы шигъриятемне гасыр азагына менә кем ялгар!» — дип Тукай рухы дәшеп китергәндер бәлки...

Җавап эзләп мин аның китабына иеләм. Тормыш агачына сәҗдә кылган Шагыйрьнең юату сүзе шамаилгә күчә:

Мин җылытам әле, дөньям сине,
Җаным суынганчы җылытам.

## Мизгел

*Санама үзеңне зур итеп, ә зурны хур,*
*Ахырда хурлык күрерсең, булма мәгърур.*

Утыз Имәни

Еллар саргайткан фоторәсемнәрне карарга яратам. Билгеле бер чорның сурәт-рәвеше киемнәрдә, чәч тарауларда, күз карашларында чагыла. Нәкъ шушы төркемне кабат беркайчан да җыя алмыйсың инде. Сурәттән бигрәк мине шул кешеләрнең ничегрәк туплануы, нинди сүзләр сөйләшеп ыгы-зыгы килүләре кызыксындыра. Сурәттәге шәхесләрне терелтәсе, хәрәкәткә китерәсе иде дә... Ни кызганыч, еллар һәм юллар аларны инде әллә кайларга сибеп ташлаган, кайсыларыннан инде кабер ташлары гына хәтер маягы булып калган.

Шулай итеп мин, нәүмиз сагышланып, иңемә баскан Вакыт кодрәтен тоеп, иске фоторәсемнәр карарга яратам.

Менә тагын бер сурәт... Саргаерга әле өлгермәгән. Таныш йөзләр. Кичә генә тезелешеп төшкәннәрдер кебек. Бакый китсәң, ун ел гомер үтеп тә киткән икән шул. Раиса Горбачеваны уртага алып фоторәсемгә төшкән татар язучылары, шөкер, бар да исәннәр... Баксаң, ун ел эчендә ил

күләмендә нинди генә үзгәрешләр булмады да, нинди генә язмышлар дер селкетелмәде.

Ә ул чакта... Дөньядагы иң зур илнең Олимп тавындагылары мәңге шулай иярдә калыр кебек иде. Әмма нигәдер, генераль секретарь хатыны Раиса Горбачева белән фотога төшүен язучылар үз вакытында бик мактанып сөйләп йөрмәделәр. Ул фотоны кайда да булса бастырып чыгарырга да ашыкмадылар. Сәбәп нәрсәдә иде? Тыйнаклыкмы? Куркуданмы? Бу илнең тәхет тирәсе тотрыксыз икәненә күнегеп беткәнгә күрә дәшмәскә уйладылармы?

Әлеге фото тарихын бер кулга җыярга теләп мөрәҗәгать иткәч тә әле кайбер язучылар икеләнеп-шикләнеп калдылар. Ярар микән... дигән сагаюны таратыр өчен тел ачкычлары кирәк иде. Мәйданнан киткән шәхескә түбәнсетеп карау Россиядә гадәткә кергән, бу очракны көлеп язмас микән, дип, кайберәүләр миңа ышанмыйчарак та карадылар бугай. Ләкин бу гадәт мөселман тәрбиясе алганнарга хас түгел, шуңа күрә мин, баштан ук, мондый караштан ерак тордым. Минем өчен әлеге фоторәсем бәхетле очрак кына түгел, ә ил тарихының кешеләр йөзендәге бер мизгеле иде.

Сүз — югары даирәдәге хатын-кыз шәхесе хакында...

## Президент хатыны

Испания башкаласы Мадридта корольләр сарае бар. Аның берберсен кабатламаган, искиткеч зиннәтле, дөньяның әкияти байлыгын туплаган меңнәрчә залын карап та, акылга сыйдырып та бетерерлек түгел. Идәне, түшәме, диварлары «Алла кулы» белән чигеп эшләнгән сәнгатьле залларның берсе — «Тәхет залы» минем аеруча хәтердә калган. Калкурак урында алтын белән нәкышләп, бормалы бизәкләр уеп эшләнгән ике кәнәфи янәшә тора. Алдарак, як-якта, табигый зурлыгында, алтыннан коелган ике арыслан дәһшәт салып тәбәлгән. Кәнәфиләрнең арка терәгеченә король Хуан Карлос һәм королева Софиянең барельефы ясалган. Мине гаҗәпләндергәне шул булды: ни өчен соң әле король хәкими биеклектә үзе генә утырмый, ә хатыны белән янәшә...

Шуннан соң инде мин тарихи әсәрләр укыганда игътибарлырак була башладым һәм бер нәрсәгә төшендем: хан, патша, король, солтан һәм шаһларның хәләл җефетләре ил белән идарә итүдә хәлиткеч урын тотканнар икән. Аларның күбесе тәхеттәге иренә иң якын киңәшче, иң ышанычлы терәк булганнар. Әлбәттә, арада мәкерлеләре дә табылган, астыртын эш йөртеп, иренең башын кистереп, тәхеткә сөяркәсен утырту яисә үзе хакимлекне алу кебек күренешләр дә тарихка ят түгел.

Русның монгол-татарлар хакындагы ялган әдәбияты кыргый санаган хан даирәсе ничегрәк булган икән соң?

Монголларның югары киңәшмәсендә (әгәр ул хәрби максатларны күздә тотмаса) бөек хан һәм түбән башлыкларының хатыннары катнашканнар. Корылтайларда киңәш-табыш бирү хокукына ия булганнар.

Менә бер мисал, Сарай-Бату шәһәрендә булган Европа кешесе Плано Карпини хан сараенда үз күзе белән күргәннәрен болай дип язып калдыра: «Батый тәхеттә хатыннарының берсе белән янәшә утыра. Аның энеләре, уллары һәм сарай әһелләре аста, арырак утыралар. Калганнар — келәмдә. Ирләр уң якта, хатын-кызлар сулда».

Менә шуларны белгәннән соң инде, әле бу гасыр башында гына Англиядә хатын-кызларның сайлауга катнашу хокукы яулап, митингларга чыгуын хәтерләп, их, Европа... дип мыскыллы көлеп куясың. Үз кыргыйлыгын күрмичә, гаепне гел Шәрыктән эзләгән Европаның, тарихи фактлар белән бәреп, күзен ачырыр чор җиткәндер ниһаять.

Тагын тарихка күз салыйк...

Каракорумда Чыңгыз ханның оныгы Көек хан үлгәннән соң, аның урынына бөтен монгол мәмләкәтенә ханбикә булып хатыны Аккүл-Камыш кала.

Яшүсмер хан Улакчы урынына Алтын Урда белән Батыйның тол хатыны Баракчина идарә итә.

Тарихта шактый мәртәбәле эз калдырган Бөек Үзбәк ханның хатыннарына игътибар итик: беренчесе — Кытай императоры Буянтуның сеңлесе — икенче хатыны — Византия императоры Андроник кызы Байалун була. Өченче хатыны — Тайдула.

Урданың атаклы төмән башлыгы (кенәз дип тә йөртәләр) Нугайның хатыны — Византия императоры Михаил Палеолог кызы Ефросинья була.

Җанибәк ханның хатыны Тайдулага Мәскәү янында бүләк итеп бирелгән җирдә калыккан Тула шәһәренә исем дә шул ханым хөрмәтенә кушылмады микән әле... Күрәсез, аксөяк нәселеннән булган бу ханымнарның аң-белем, культура дәрәҗәсенең ничек югары булуын күзаллау кыен түгел. Гаскәр белән килеп, иреннән калган тәхетне яулаган Түләбәк ханым хөрмәтенә XIV гасырда Сарайда акчалар сугыла.

Шулай ук тарихта исемен калдырган Хөршидбәк, Нурсолтан, Сөембикәләр турында да романнар язарлык.

Алтын Урда һәм Казан ханлыгының дәүләт системасын үзләштергән Россиянең тәхетендә әби патшалар пәйда булу — Шәрыкнең турыдан-туры йогынтысы ул. Ә Испания — Европа бит, дияр кемдер. Әмма бу илнең берничә гасыр гарәпләр кул астында яшәвен онытмыйк. Европаның учында — Шәрык биргән фәлсәфә ташы ята...

Бөек Октябрь мәхшәреннән соң тәхет даирәсендәге гореф-гадәтләр буталды. Большевикларның хатын-кызга карашы, аларны дәүләт идарәсе эшләреннән читләштерә башлавы бернинди этик нормаларга да сыймый иде.

Тора-бара партия җитәкчеләренең хатыннары гадәти кухаркаларга әйләнеп калдылар.

Халыкара килешү буенча, ил башлыклары югары даирәдә очрашу үткәргәндә хатыны беләнме, ялгыз киләме — бу алдан уртак фикергә килеп эшләнә. Михаил Горбачевның төрле илләргә эш визиты белән барганда хатыны Раиса Максимовнаны үзе белән алуы — халык өчен башта яңалык иде шикелле. Белгәнебезчә, мондый визитлар бик кыска арада, гаять киеренке шартларда үтә, ә без экраннан аның тантаналы өлешен генә күрәбез. Һәр нәрсәгә чырай сытып, шикләнеп карарга өйрәнгән совет кешесе ил башлыгы парлашып, кәеф-сафа корып йөри, дип уйларга да мөмкин иде...

Власть тирәсендә борын-борынгыдан бүре законы хөкем сөрә. Сәясәттә дус-иптәш дигән төшенчә юк. Тарихи борылышларда көрәштәшләрең дә тапталып калырга мөмкин. Кешелек яңадан-яңа акыл туплап, күпме генә алга барса да, хакими даирә шулай булып калачак.

Сәясәтнең менә шундый мәкерле әйләнешендә Генераль секретарь (соңыннан Президент) Горбачевның үз хатынына иң якын сердәше, киңәшчесе, ышанычлы кешесе итеп каравы табигый түгелмени! Әгәр телеоператорлар, әрсез журналистлар Раиса Горбачевага объективны артык еш юнәлтмәгән булсалар, әгәр Президент Горбачевның үз элгәрләренә караганда, хатын-кызга мөнәсәбәте күпкә әдәплерәк икәнен совет халкы аңлый алырлык культурага ирешкән булса... Кыскасы, без әле моңа тора-бара ныклап төшенербез. Раиса Горбачева бу илнең изелгән, болгавыр көнкүрештән йончыган хатын-кызлар кавеменә нindидер үзгә бер рух бирде, хакими даирәдә Шәрыктән килгән олы гадәтне кайтарды, хатын-кызны үз биеклегенә куя алды.

Әдәбият-сәнгатьтән ерак торган Горбачевка бу өлкәгә аерым игътибар итәргә кирәклеген, хатын-кыз йомшаклыгы белән, бәлки нәкъ менә Раиса ханым сеңдерә белгәндер. Югыйсә, Максим Горький заман-

нарыннан бирле талантлы язучылар белән дәүләт җитәкчеләре һәрчак каршылыкта яшәделәр. Акыллы хан-патша белә: чорны хикмәтле итеп бары тик язучы-әдип кенә теркәп калдыра ала, сурәтен таш булып калмасын дисәң, әдип күңеленә каты кагылма... Күп хаталары бардыр әмма Галиҗанәб Сүзгә, Акылга азатлык капкаларын ачкан Михаил Горбачевның, бөтен Политбюро әгъзаларын ияртеп, язучыларның зур форумына килүе күрелмәгән хәл, әмма табигый адым иде. Бу — СССР язучыларының соңгы, VIII съезды иде (1986 ел). Бүгенге дәүләт эшлекләренә хас «малайлык»тан аермалы буларак, һәрберсе үз исемен истә калдыртып, һәрберсе үз шәхесе хакында тотрыклы культ булдырган Политбюро әгъзалары президиумнан урын алуга, зал чүгеп, тантаналы тын кала. СССР Язучылар Союзы рәисе Георгий Марков, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое булуга карамастан, каушап кала, докладыннан ике җөмлә укуга, йөрәген тотып, сыгылып төшә. Аны Советлар Союзы Герое Владимир Карпов алыштыра...

Тәнәфес вакытында Татарстан язучылары-делегатлар, Раиса Максимовна Горбачеваны (Титаренко) уртага алып фоторәсемгә төшәләр. Әгәр башка җирдән килгән язучылар да аның белән фотога төшә алган булсалар, бу рәсемнең кыйммәте алай ук игътибарны җәлеп итмәс иде һәм мин дә бу истәлекне язып та тормас идем. Хәер, сүзне шунда катнашкан язучыларның, галимнәрнең үзләренә бирик әле.

**Ренат Харис:** Ике мишәр, сез генә булдырасыз, иң шәп урыннарны алып куегыз, дигән максат куелганлыктан, без, Тәлгат Галиуллин белән бергә, съезд ачыласы көнне иртән иртүк торып киттек. Кремльнең Зур Сараенда зур зал ачылмаган, ишек төбендә сакчылар гына тора иде әле. Күпмедер вакыттан соң «Сим-Сим ишекләре» ачылып китте. Керәбез, зал буш, уртада, алгы рәттә, бер кеше генә утыра. Шул турыда, нәкъ трибуна каршыннан без бөтен делегациягә җитәрлек урыннарны биләп алдык. Бераздан халык тула башлады. Барысы да безнең урынга кызыгалар, әмма без нык торабыз. Мәскәү шагыйре Сергей Островой үзенең үҗәтлеген монда да күрсәтеп алды. Теге кеше рәтенә килә дә урын даулый, килә дә даулый. Ахырда теге кеше гафу үтенеп, бу рәт Үзәк Комитетның культура бүлеге өчен, дип әйтеп салды. Булмагае, язучылар съезды ич бу, дип Островой барыбер шул рәткә килеп утырды.

Минем бер ягымда — Дания Хөсәеновна Зарипова (КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире), икенче ягыма Сергей Петрович Кошечкин («Правда» газетасының культура бүлеге мөдире) туры килде. Съезд башланырга биш минут кала озын буйлы ике ярдәмчесе белән Раиса Максимовна килеп керде һәм нәкъ минем каршыдагы урындыкка утырды. Киенүе бик пөхтә, килешеп тора, бик затлы да, бик гади дә сыман иде. Артка борылып, ул миннән съезд документларын сорап алды. Исемлекне карады-карады да: «Вот посмотрите, опять несправедливость, ни одной женщины за столом президиума. Везде и всюду у нас зажимают женщин. А ведь есть прекрасные писатели-женщины», — диде.

Чынлап та, сәхнәгә президиумга сайланганнар чыгып утыргач карыйбыз — гел ир затлары гына. Раиса Максимовна тагын безнең якка борылды да, әнә карагыз, нәкъ исемлектәгечә, бизәк өчен генә булса да ник бер хатын-кыз булсын, — диде.

Съезд барышында минем башка бер уй килде. Дания Хөсәеновнага әйтәм, безнең бик матур сувенир китабыбыз бар, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре», барыбыз да кул куеп, бүләк итик Раиса Максимовнага, дим. Тәнәфестә шулай эшләдек тә...

Чыгышлар вакытында Раиса ханым, артка борылып, теге яки бу язучы хакында сорый, Мәскәүнекеләрне яхшы белгән Кошечкин аның шәхси консультантына әверелде. Милли әдәбият вәкилләре трибунада күренә башлагач, мин дә әңгәмәгә кушылып алгаладым.

Озын тәнәфес алдыннан Дания Хөсәеновнага әйтәм, әйдәгез, бөтен делегация белән истәлеккә фотога төшик, сез аңа тәкъдим итеп карагыз,

дим. «Бездән күрмәкче башкалар да чакыра башласа... Уңайсыз булмасмы, син үзең тәкъдим итеп кара»,— ди Дания ханым. Тәнәфескә чыккан-да мин: «Раиса Максимовна, делегация татарских писателей обращается к Вам с убедительной просьбой... Не сможете ли Вы с нами сфотографироваться на память?» — дип мөрәҗәгать иттем. Ә ул гади генә итеп: «А почему бы и нет»,— дип җавап бирде. Шуннан соң инде без Гәрәй Рәхимне фотограф артыннан йөгерттек. Георгиевский залда көтеп тор, дидек. Раиса Максимовнаны уртага алып вестибюльгә чыктык. Георгиевский залга керергә тәкъдим ясагач, ул, ә нигә анда керергә, шушында гына басып төшик, диде. Шул мизгелдә әллә каян гына фотографлар пәйда булды. Раиса Максимовна янәшәсеннән урын алу мәсьәләсенә килгәндә...

Хәер, анысы башка хикәя...

«Анда безне фотограф көтеп тора, әйдәгез тизрәк!» — дип Гәрәй Рәхим килеп җиткәндә соң иде инде. Башка өлкәләрдән килгән делегатлар да фоторәсемгә төшәргә талпынып караган иделәр дә...

Раиса Максимовна, саубуллашып, президиум бүлмәсенә кереп китте.

Башкорт туганнарга җитә калды. «Да, егетләр, сезнең хәзер һәр адымыгыз күзәтү астында булачак...» — дип шаяртып алгаладылар.

Икенче көнне, төшке аш вакытында, берәү килеп, җилкәмнән кага. «Сез Казаннанмы, тәрәзә янына барыйк әле» — ди. Йөрәгем «жу» итеп китте. Башкорт дусларның кинаяле шаяртуы искә төште... Тәрәзә янында ул кесәсеннән бер конверт чыгарды. Анда безнең фото иде. Артына барыбызның да исем-фамилияләрен яздыртып чыкты. Тагын бер көн үткәч, янә берәү килеп: «Сез Татарстаннан бит әле, менә, Раиса Максимовна сезгә тапшырырга кушты»,— дип, зур конверт сузды. Анда безнең күмәк төшкән шушы фотолар иде.

Ә Сергей Островой, безнең Раиса Максимовнага китап бүләк итүебезне күргәч, кызыгып, үзенекен алып килмәгәнгә бик офтанып торган иде. Икенче көнне ул тагын да шәбрәк киенеп килгән, кулына калын-калын ике томлыгын тоткан иде. Съезд беткәнче күтәреп йөрде ул китапларын, ләкин Раиса Горбачева бүтән күренмәде...

**Тәлгат Галиуллин:** Съезд ачылды. Бездән алдагы рәттә ниндидер ханым япон ручкасы чыгарып яза башлады. Мин аның үзеннән битәр шул затлы ручкасына игътибар иттем. Безнең арадан беренче булып аны Ренат Харис танып алды. «Егетләр, бу — Михаил Сергеевичның хатыны түгелме соң?..» — ди. Шуннан соң инде минем өчен доклад, съезд кайгысы бетте. Күзләр — Раиса Максимовнада. Ул, артка борылып, безнең кайдан килүебез хакында сорады. Докладчы Виктор Астафьевның «Ловля карасей в Грузии» дигән әсәрен телгә алгач, грузиннар ярсып, урыннан кычкыра башладылар. Шулчак; Раиса ханым борылып: «Сез ул әсәрне укыган идегезме?» — дип сорады. Язучы халкы укымаган булса да, һәрчак укыдым, дип әйтә. Без дә шулай, әсәрне мактаган булып, сүзне икенчегә борырга тырыштык. Докладта телгә алынган башка әсәрләр турында да ул сүз кузгаткалап торды.

Тәнәфестә безнең язучылар аңа бүләк итәргә дип үз китапларын алып килделәр. Илдар Юзеев кулында да китап бар иде бугай... Шунда мин кинаяләп: «Егетләр, Михаил Сергеевичның китапханәсен юк-бар белән тутырмагыз инде»,— дигән булдым.

Озын тәнәфестә без Раиса Максимовнага фотога төшәргә тәкъдим иттек. Ул, әлбәттә, риза булды.

Башкорт язучылары: «Сез анда апай белән бик елмаешып, сөйләшеп утырмагыз. Президиумнан Михаил Сергеевич гел сезнең якка карап утырды, көнләшмәгәе!» — дип шаярып, үзләренең арткырак рәтләргә эләгү «бәхетен» капларга тырыштылар.

**Миркасыйм Госманов:** Раиса Горбачева ул кадәр игътибарны җәлеп итәрлек чибәрләрдән түгел. Әмма кеше белән мөгамәләсе йомшак, сөйләшә башлагач бик ягымлы күренә иде.

Фотога төшәргә дип җыелышкач, мин аның янәшәсенә туры килдем. Карыйм, аксакалыбыз Әмирхан ага читтәрәк калган, уртага керергә теләге дә бар шикелле... Муеныма кайнар тыны да бәрелгәч, урынымны морзага бирергә туры килде. Раиса ханымның беләген ычкындырып ин кырыйга чыгып бастым.

Язучыларның киләчәктә таркалачагы ачык күренеп торган бу шаушулы, болгавыр съездның бер истәлеге булып шушы тарихи сурәт калды.

Актыктан Әмирхан аганың үзалдына сөйләнеп торуы әле дә күз алдымда: «Патша хатыны белән фотога төштек дисез инде... Понимаете... Моның соңы ни белән бетәр икән, соңы...»

**Әмирхан Еники:** Раиса ханымның әле зенитта, шөһрәтле чагы иде бит. Аның хакында Башкортстанда яшәгән икән, милләте татар икән, дигән сүзләр йөри иде. Съезд вакытында «Сез милләтегез белән татар түгелме?» дип кемдер сораган имеш. «Юк, мин татар түгел, ләкин татар-башкорт арасында яшәдем, ул ике халыкны да бик хөрмәт итәм»,— дип әйткән имеш.

Бүләккә дип әзерләнгән Муса Җәлил китабына мин дә үз имзамны куйдым. Фотога төшкәндә бер читкә баскан идем, син олы кеше, карт кеше, дип, Раиса Максимовна янына ук китереп бастырдылар. Ул арада сурәткә дә төшереп алдылар. Теге (Әмирхан ага кеткелдәп куя) фотограф эзләп киткән Гәрәй Рәхим генә килеп җитешә алмый калды... Шуның белән эш бетте. Бүтән берни дә кирәкми, шул җиткән, дигән идем, ләкин күрәм... Әле берсе китабын китереп төртә, автограф куеп, әле икенчесе... Шагыйрьләр инде... Раиса ханым ала инде, рәхмәт әйтеп, нәрсә дисен...

**Илдар Юзеев:** Кайчан да булса, Кремль сарайларына барып, патша хатыны белән фотога төшәрмен дип төшләремә дә кермәгән иде. Бу — тарих бит...

**Гәрәй Рәхим:** Мин, бәхетсез, шулай итеп бер фотога да эләкмәдем. Фотограф табып килеп җиткәндә таралыша башлаганнар иде инде. Ятып калганчы атып кал, дигәндәй,Раиса Максимовнага Мәскәүдә чыккан шигырь җыентыгын бирергә булдым. Ашыгам, нәрсә дип язарга да белмим. «Товарищу Михаилу Сергеевичу...» дип булмый бит инде, ул бит зур кеше... Шәхсән үз исемемнән генә язсам да яхшы түгел кебек... Шуннан: «Раисе Максимовне и Михаилу Сергеевичу, выражая уважение татарского народа. Г. Рахим»,— дип куйдым. Раиса ханым рәхмәт әйтеп кулын бирде. Китабымны нәни сумкасына салып тормады, янәшәсендә үткер күзле чибәр-чибәр егетләр бар иде, шуларга бирде. Соңыннан дуслар: «Кулыңны ап-ак чүпрәк белән урап йөр, Раиса ханымның кул җылысын сакла»,— дип көлеп тә йөрделәр.

## Эпилог

Бу язмага нокта куяр алдыннан уйларым ике ярымшарга бүленде. Әмма ниндидер бер хакыйкатьнең асылын ачасы килеп тә, гамьле сүз кодрәте җитмәүдән гаҗиз калдым. Уйлар агышын эзлекле сүз тезмәсенә әйләндерергә җитешә алмаган каләмгә үч итеп, шул фикеремнең кайтавазларын гына бирәм.

Бәлки бу гомерлек сораудыр?

Дөньяда хатын-кызның тоткан урыны нинди?

Күпме акыл көчен мең еллар буена җимерүгә сарыф иткән ирләр кавеменә Тәңренең күңеле суынып бара түгелме! Җир-Ана тәнендәге тирән яраларга хатын-кызның шифалы кулы кирәгрәк түгелме! Шулай булмаса... Технократия гасырының икенче яртысында күпме Ил иярәнә Алла учыннан гына төшеп, Галиҗанәб хатын-кызлар утырмас иде... Бөек могҗизалар, ак чалмалы таулар арасында туган философлар иле, һәммә

төрле диннәр бишеге — Һиндстанның мәгъруР анасы Индира Гандины гына искә төшерик. Ул җирдән киткәч... дөньяның изге бер нуры сыктап сүнде шикелле...

Ярымшарның бер ягында — ир-егетләр... Ирләр генә булган җирдә йодрык кысыла, усаллык чикләре киңәя. Ир-ат кына торган йорт, алтынга төрсәң дә, ягымсыз, нурсыз, җансыз була. Идарәче даирәдә ир-атлар гына эшләгән ил-йорт-дәүләт тә шулай... Хатын-кыз исә, дәрәҗәле урында эшләсә дә, үзенең ана икәнен, тормышта илаһи хис — наз барын беркайчан да онытмый.

Саный китсәң, олы эшкә алынган хатын-кызлар аз дисәң дә, бар бит әле дөньяда. Алар, авыр постаментларга менеп, һәйкәл булырга кызыкмыйча гына, якты хатирә булып, тарих хәтеренә керә баралар. Бүгенге, без шаһит дәвердә дә шулай...

Американы гына алыйк. Элеккеге (хәзергесе дә шулай) президент хатыннары бүген дә әле сәясәттә катнашалар, җәмәгать эшләре алып баралар, шәфкатьле ярдәмнәре белән телгә керәләр, илләр белән илләр арасында кешелекле, җылы мөнәсәбәт урнаштыралар. Әле кайчан гына... күпме илләрнең зәңгәр экраннарында елмаеп күренгән «беренче леди» — Раиса Горбачеваның да дөнья каршында үз абруе бар. Мин аның нинди дә булса җәмәгать эшендә үзен күрсәтеп, шәфкатьлелек үрнәге булырга бөтен мөмкинлеге дә җитәрлек дип уйлыйм.

XXI гасыр башыннан күп кенә дәүләтләр тәхетен хатын-кызлар биләячәк. Күренекле эш урыннарында хатын-кызлар утырачак. Бу — табигый зарурилык. Чөнки Җир-Ананы саклап калырга, каты бәгырьләнә барган кешелекне юатып дәваларга кирәк.

## Оҗмах бакчалары хозур

*Чумып диңгезгә, күп энҗеләр алдым,*
*Гамәл өчен барсын күңелгә салдым.*

Г. Утыз Имәни.

И-и, и генә лә! И генә! Эшем дә булды чи генә! — дип язган Кандалый галиҗанәбләре. Кайчакларда шундый бер халәткә тарыйсың, кулың эшкә бармый, сәбәпсездән күңеленә сыгылып моңсу-өметсезлек иңә, җылыйсы килә, эч поша, хәтта терек табигатьнең җете төсләре дә тымызыкланып кала. «Җан тарыга... Җанымны кая куярга белмим...» — диләр мондый халәтне безнең якларда. Шәһәр моңсулыгы башкачарак шул, ә менә авылда, табигать белән күзгә-күз калган мәлләрдә... бигрәк тә кичке шәфәкъ офык иңенә һәммә төсләрен таратып оеган чакта... Чабынганнан соң алма кебек пешеп, ләүкәдә изрәп утырган хатын-кыз шикелле, мәмрәп тулган кояшның тауга таянып, юашланган нурларында баеган мәлендә әлеге җан тарыгу халәте бәгырьдән аеруча сызып күтәрелә башлый; көнең сүнеп бара, төнгә дә керәсе килми, күкрәк читлегендә әсирлектә яткан җаның, өнсез сыктап, канатларын киерә башлый, каядыр еракка, билгесез киңлекләргә алгысына.

Әллә соң җирнең кайсыдыр кыйтгасында нәкъ менә синең белән бер мизгелдә туып үскән игезәк сыңарың була микән? Аңа нинди дә булса бәла-каза киләсен сизенеп, аны йолып калырга, яки киресенчә, аңа сыенып, үзеңә юаныч алырга дип ашкынасыңмы әллә? Җир йөзендә һәммә кеше, үзе дә сизмичә, гомере буе игезәк җанын эзли, юксына, өметләнә, иң якын иптәшен табып, ике ярымшар бергә кушылып, тәңгәл килгән кебек, рухның камил бөтенлегенә ирешү уе белән янадыр бәлки?! Мондый бәхетле очраклылыкка тиенүче сирәкләр — Хак тәгаләнең мең-там-

гасы белән туалардыр. Ә күпләр өчен соңгы сулышынача барган бу теләк, җирдә нәүмиз кала алмыйча, җан сүрүе белән бергә, теге дөньяга күченәдер.

Әнә шулай, җаным тарыккан вакытларда мине мәзәк бер уй — Урта диңгезгә барып тиз генә су коенып кайту хыялы биләп ала торган иде. Элек чит илгә чыгу җир тарту көченнән ычкынып, галәмгә ыргылу кебек акыл ирешмәслек могҗизага тиң иде. Әгәр мин, хәл-әхвәл сорашып, нигә моңсу күренәсең? — дигән кешегә Урта диңгезгә барып тиз генә су коенып кайту теләгем барлыгын әйтсәм, егет ычкынган... дип шактый аптырашта калырлар иде. Шуңа күрә мин бу уемны кемгә дә әйтмичә эчтән генә сызып йөрим. Кемнәргәдер бөтен мөмкинлекләр дә бирелгән бит югыйсә, димәк без шул кемнәрдер кинәнеп яшәсен өчен бил бөгүче, җан асраучы коллар... Сабыр, акыл! Тирәнгә кермә, юкса гомер агышыңа чик куярга көчең җитәрлек фикерләргә юлыгырсың. Әнә, тирә-юнеңә кара, бәрәңге ашап туйганнан соң, шагыйрь ни дип бәян иткән: «Дөнья матур, дөнья киң! Шуны кабат-кабат әйткәч, дөнья чынлап та матурая түгелме?!

Ә нигә Урта диңгез? Җир йөзендә башка океан-дәрьялар беткәнмени? Соңгы диңгезгә кадәр дип омтылган чакта, Әдрән диңгезгә җиткәч кире борылырга мәҗбүр булган Бату ханның гамәлгә ашмый калган максаты миндә пыскып уянамы әллә? Юктыр, мин тирбәлеп үскән бишек тарих матчасына асылмаган булган шул. Бу хыял чишмәсенең башы — балачакта. Мәктәптә укыганда класс диварына катлы-катлы булып биниһая зур карталар эленгән иде. География, тарих дәресләрендә без шушы карталар аша дөнья буйлап хыялый сәяхәткә чыга идек. Миңа Африка белән Европа материгын аерып торган Урта диңгез ошый, исемнәрен атаган чакта яңгырашы белән күңелдә рәхәт кытыклану уяткан илләр — Испания, Греция, Төркия ярларын югангадыр бәлки? Бер үк диңгез югыйсә, әмма һәр халык үзе яшәгән ярларны юган су-дәрьяны үзенчә атаган: Альборан, Болеар, Әдрән, Эгей, Мәрмәр һәм тагын әллә нинди исемнәр...

Ниһаять, миңа борынгы аргонавтлар йөзгән Урта диңгез дулкыннарына колач салу 1981 елның май аенда насыйп булды. РСФСР Язучылар берлеге оештырган туристик сәяхәт өчен хәләл акчамны түләгәч, уннарча кәгазь-белешмәләр тутырып, хәтта, әткәң-әнкәң исән түгел икән, аларның кабере кайда икәнлегенә хәтле күрсәтәсең дә... ул кәгазьләр син белмәгән әллә нинди яшерен иләкләр аша сөзелеп чыга калса... Бауман райкомының иркен кабинетында, биниһая озын өстәл тирәли утырган корыч салкыны бөркелеп торган партия чиновниклары һәм өлкәннәр советы әгъзалары каршына бастырып сине рентген нурлары аша үткәрәләр. Төрле сораулар биреп, капиталистик илләргә карата бик үк мәрхәмәтле карашта тормавыңа тәмам инангач кына хәерле юл теләп сине чыгарып җибәрәләр.

Шулай итеп Казаннан без өчәү — Аяз ага Гыйләҗев, хатыны Нәкыя апа һәм мин Испаниягә баручылар төркеменә эләктек. Калган язучыгалимнәр Мәскәү һәм Ленинградтан иде. Исеме таныш язучылардан тыш монда Бонч-Бруевичның оныгы, Ярослав Смеляковның хатыны, Максим Горькийның җиде яшенә кадәр Соррентода үскән оныгы Нина Пешкова да бар иде.

Күк тәхетеннән күзәтеп торучы Хак тәгалә ерак сәяхәттә мине Хәвеф-хәтәр сагалап тормыймы дип йөрисе юлларымны «тикшерткән» арада чак кына соңга калмадым. Чемоданымны иртүк, эшкә барышлый, вокзалга илтеп, автомат камерага куйган идем. Кичен Язучылар союзында бильярд уйнап, дуслар белән хушлашып (Ни дисәң дә Пиреней ярымутравына, җир читенә китеп барам бит), ике кулны селкеп кенә, поезд китәргә биш минут кала вокзалга килеп җитсәм... чемоданымны куйган камера ачылмый гына бит, код номерларын кабат-кабат җыеп

карыйм — юк, һич кенә дә бирешми. Ә минутлар котылгысыз тизлек белән йөрәк кагышына күчеп вакытны куалапмы куалый. Ничек кирәк алай милицияне, кирәкле хезмәткәрләрне табып, камераны ачтырдым. Көндез ачып тикшергәнлеккә эчтә язу ята, кодны бутап япканнар икән...



*Рәсемдә: (сулдан-уңга) Аяз Гыйләҗев, Равил Фәйзуллин, Мостай Кәрим, Марсель Галиев, белорусь язучысы Леонид Прокша. 1979 ел, май.*

Шулай итеп, поезд инде кузгала дигәндә килеп җиттем. Аяз ага перронда, вагон ишеге төбендә көтеп тора, борчылуы йөзенә чыккан иде.

— Ну слушай-парин, гамьсез дә икәнсең, бу кадәр төгәллек белән хәтта Муса Җәлил дә йөрмәгәндер.

Бу мизгелдә мин тыштан бик сабыр күрендем микәнни, эчем тулы ут иде югыйсә. Купеда урнашып бетеп, поезд Мәскәү тарафларына күңелле теркелди башлагач, каклаган каз боты белән сыра эчеп барганда Аяз ага баягы сүзенең мәгънәсен аңлатып бирде: «Мусаны сәгать унга чакырасың булса, сигезгә кил диген, ул, һичшиксез уникегә килеп җитәр, дигәннәр чордашлары...»

Мәскәүгә җитәрәк, чиркәү урманнары башланды. Алтын гөмбәзләр, мәһабәт манаралар... Уңга карасаң да, сулга карасаң да чиркәү. Кайбер урыннарда авылы беткән, ә кола ялан уртасында саллы чиркәү кукраеп утыра.

— Безнең татар, кызыл авызларга утызынчы елларда ышанып, мәчет манараларын аударып чыккан, эзе дә калмаган. Ә боларның — исән. Бүтән халыклар диннән тәмам бизеп беткәч, беркөн килер да урыслар бу чиркәүләрен ачып җибәрәчәкләр әле,— дим мин ачынып.

— Бүтән нәрсәгә маһирлыгы булмаса да урыс чиркәүне төзи белә... Таштан, мәңгелеккә дип!

Аяз ага дин турында сүз озайтмый уйга кала, ул да догалардан ерагайган инде, сабыр дәверләр өчен яратылган Ислам галәме бу болгавыр дөньяда бөтерелгән адәми затларның йөрәк тибешен тынычландырып, акыл казанына зиһен уты өсти алмый шул. Ялгыш агымда бәргәләнгәнебезне аңлыйбыз, әмма аны бер-берәңә кычкырып әйтү күңел төбендәге әрнүне отыры арттыра гына бара. Шулай, тирәндә калып, догалардан шифа аласы илаһи хисләр гомерлеккә сүнәрме, әллә инде, вакыты җиткәч, соңлап булса да сыктап уянырмы?

Шушы сәфәргә барып кайтуыбызга ун ел үткәч, беркөнне Аяз агадан хат алдым. Анда мондый юллар бар:

*«...Кичә Зәйдән кайтып төштем. Президент Буш белән ярышка чыга алмасам да (ул быел 32 илгә сәяхәт кылып 550 мең чакрым җир узган!), Сарманнан башланган сәфәрем, уравыч юллар аша Зәйгә барып тәгәлләнде. Быелгы сәфәрем хатирәләр дөньясына кайту иде. Югары Әхмәт зиратында һаман-һаман иҗатымны, әсәрләремне җылытып, нурландырып торган Сөләйман бабам белән Зөләйха әбием йоклый. Каберләренә барып башымны идем... Зират шактый йончыган, адәмнәр үлеме бер хәл, зиратлар үлеме аяныч, аннан да зур һәлакәт юктыр... Әтиемнең атасы Сәхәбетдин хәзрәт, Сарман мәчетенең имамы, утызынчы еллар башында Алабуга төрмәсендә эзсез югала... Яшьли ятим калган әтидән әбинең исемен сорарга башка килмәгән. Әти үлгәч, кәгазьләре арасыннан туу турындагы таныклыгы килеп чыкты. Гыйлембаян исемле булган икән атама гомер биреп, үзе дөньялыкны куйган изге җан! Сарман зиратлары таланган, мәсхәрәләнгән, юк алар. Әби-бабайларның исемнәрен яд итәсе, аларны тере итеп күрәсе килә. Төзелергә тиешле Сарман мәчете хисабына 1000 сум акча күчердем. Сарман янында гына Яңа Әлмәт дигән җыйнак, сөйкемле авыл бар, безнең белән утыз ел яшәгән, өч улымны үстерергә искиткеч көч салган Нәүбәһар әбиебез шул авылдан. Анда бардык (Нәкыя белән кайткан идек), матур итеп таш мәчет салып яталар. Мәчеткә 100 сум тапшырдым. Догада булсыннар! Сарманнан туп-туры Зәй ягына тәгәрәдек. Дөнья нык үзгәргән, дөньяны мин таный алмыйм, ә дөнья миңа арты белән борылгандыр сыман тоела. Алтмыш еллыгымда Урта Багражда «Минәй чишмәсенә» таш куйдырып, «Кадерле әти-әнием: Мирсәет белән Мөгаттәрәне озак еллар сыендырган Баграж халкына рәхмәт йөзеннән куйдым бу ташны», дип яздырган идем. Куючылар игътибарсызлыгы аркасында чишмә суы читкә ага башлады. Байтак вакыт шуны уйлап янып йөрдем! Күр инде, иң изге'ниятләр белән башкарылган эшең кирегә китә. Ниһаять, авылдашлар мине көтмәгәннәр, чишмәне рәтләгәннәр. Суы, күңелләрне тузгытып, моң гына агып ята! Шул чишмә каршысында, безнең элеккеге ындыр артында, биек-биек каеннар шыбырдый. Без аларны моннан 25—30 еллар элек әти белән утырткан идек... Хәзер әти-әнием Зәй төбәгендә, гүзәл тынлыгы белән күңелне кайната торган Бигеш зиратында йоклыйлар... Аларга кагылып чыктык, каберләренә матур көз сачкәләре салдык. Алар догадан аермасын дип, төзелеп ята торган Зәй Мәчете хисабына, банкка 1000 сум, Бигеш мәчетенә 100 сум акча күчердем».*

*1991 ел. 18 август.*

Шул сәфәреннән кайткач, тәэсирләрен уртаклашып, Аяз ага белән гапләшеп утырган идек. Мәчетләр торгызылуы куанычлы хәл, әмма... тизрәк төзеп калыйм, дип, күп җирдә бизәү-матурлау ягын бик үк җентекләп тормыйча гына салалар шул, дип мин сүз кузгаткач, Аяз ага сызланып:

— Әйе шул... бу изге эшкә ашыгып, алдан уйлап бетермичә тотыну сизелә. Югыйсә, мәчетләрнең чын архитектура үрнәге булып, гасырларга калырлык итеп төзелергә тиешлеген онытмаска иде.

Такташ әйтмешли, «кем уйлаган шушы сөйләшүләр...» кайчан да булса безнең гомергә дә язгандыр дип. Ә ул чакта, чиркәү гөмбәзләренең алтынлы салкын төсен «Татарстан» поездының тәрәзәләрендә чагылдыра-чагылдыра златоглавый Мәскәүгә кереп барган мәлдә безнең тәндә күзәнәкләр башка, эчке иман күңелләребез төпкеленә тирәнтен яшерелгән иде...

* * *

Искә төшсә, хәзер дә чирканып куям. Ширәмәт (2) аэропортында «чик»не узганда ян-яклары тоташ пыяладан торган бәләкәй генә камерага килеп керәсең. Борын астына мыек та чыкмаган яшь солдат документларыңны ала да, пыяла аша, салкын күзләрен төбәп, гәүдәңне кадаклап куя. Бөтен күңелеңне актарып чыгарырлык итеп, керфек тә какмыйча үтәли тишеп карарга кайда өйрәткәннәр, нинди яшерен мәктәптә укытканнар бу империя солдафонын? Яшь кенә бит югыйсә, ә күзләре коточкыч җансыз, ник бер саплам нур әсәре булсын. Өмер генә бирелсен, әнкәсенә дә төбәп атачак бу! Өшеткеч караш вакыт-

вакыт өскә төбәлә (чыгышлый күреп алдым, түшәм белән арткы стена тоташкан урынга кыеклап күзге куелган икән), арт чүмечемнән нәрсә эзли бу истукан?! (руска каяндыр кергән шәп сүз — истукан...) Зәһәр эт иснәүгә тиң әлеге караштан бөтен тәнгә чиркангыч дулкын тарала, менә хәзер солдат «Син түгел бу!» — дип кычкырып җибәрсә, мин үземнең үзем икәнен исбатлый алмас идем шикелле.

Әлеге кабинада алган тискәре нурланыштан мин самолетыбыз һавага күтәрелгәч кенә арынып, тынычлана алдым бугай.

Унбер чакрым биеклектән җир өсте томанлы гына шәйләнә. Бармагыңны әгәр иллюминатордан чыгару мөмкинлеге булса, җитмеш градус салкында ул шунда ук бозга әйләнер иде. Мондый биеклекне күргән бар, ә менә ил чиген җирдән дә, һавадан да үтеп чыккан юк иде әле. Аңымда Татарстан, бер ноктага әйләнеп, кечерәя-кечерәя ераклаша бара.

Үрелеп кнопкага басам, чибәр стюардесса кыз җәлт кенә яныма килеп җитә.

— Ил чигенә җитәбезме әле? — дип сорыйм аңардан. Әйтерсең мин, галәмәт зур карта өстеннән очам, иелеп кенә барсын да күреп булыр шикелле.

Баштарак әйтергә иде, без хәзер Польша өстеннән очабыз, — ди ул елмаеп. Минем сабыйлыгымны кызганды ахрысы, яңадан үзе яныма килеп, кайсы ил өстеннән очканыбызны әйткәли торды.

Салон буйлап эреле-ваклы шешәләрдә затлы эчемлекләр, сигаретлар, шоколадлар, тагын әллә нинди ялтыр каплар тезелгән нәни арбаларны этеп йөртәләр. Бар да — долларга. Бу нигъмәт-байлыклар безгә төс түгел икән. Алыштырырга рөхсәт ителгән 35 әр тәңкә фәкыйрь акчаларыбыз җитәкче кулында, доллар хәлендә. Мадридта испан акчасы песетага алыштыргач кына ул аны безгә таратачак. Кесәңдә акчаң булып, әйбер алалмау түбәнчелегенә инде күнегеп беткән идек, сыгылып торган байлыкка карап акчасыз тору да шундый ук мескенлек икән...

Аэрофлот компаниясенең затлы ризыкларын шәраб белән сипләп куйганнан соң озак та үтмәде, самолетыбыз Люксембург аэропортына төшеп утырды. Монда алай документлар тикшереп мәрәкә килмәделәр. Вокзалга кергәч, тар гына аралыктан үтәсең, кырыйда полисмен карапкүзәтеп тора. Менә без унлап кеше тоткарлыксыз гына үтеп чыктык. Аяз ага килеп кергәч, полисмен кинәт калкынып килде дә, ике учына да нindidер прибор кигән куллары белән Аяз аганың гәүдәсен баштан-аяк сыпырып төшерде, аннары гына үткәреп җибәрде. Бераз каушап калган Аяз ага, аптыраулы елмаеп:

— Минем тюремщик икәнне монда да белделәр, слушай-парин, — дип куйды.

— Жан-Вольжан икәнеңне беләләр, Аяз ага.

— Шулайдыр. Тимер рәшәткә шәүләләре күзләрдә мәңгегә каладыр. Күр инде, бүтән берәүне дә тикшерми бит... Киттек, әнә тегендә безнекеләр бушка гына капиталист сырасы эчәләр түгелме!

Озын стаканнарда сыра бирделәр. Ул дәвердә чит ил сырасын киноларда гына күрә идек. Менә хәзер эчәргә дә насыйп булды.

— Минем сырага ис китми. Йә ничек, шәпме? — дип Аяз ага гәрәбә кебек сыралы стаканны күзлегенә якын китереп карый.

— Артык юка боларның сырасы. Безнекенең бит закускасы да үзендә була.

Аэровокзал эче бик бай универмаг кебек, нинди генә товарлар юк монда, күз камашырлык. Безнең аэропортларда, гадәттә, ислангән пәрәмәч, кофесыман сөтле сыеклык та салкын йомыркалар тезелгән буфет кына була. Ә монда... Безнең белән Мадридка очучы дипломат хатыннары кечкенә магнитофоннар сатып алалар. Бусы инде минем хыял. Кызыгып карап торам. Их, шушындый магнитофон юнәтеп, өлкән язучыларның тавышын яздырып калырга иде...

Чит илдән рәтле магнитофоннар кертелә башлаганда соң иде инде, мин хөрмәт белән караган өлкән әдипләребезнең күбесе, бу дөньялык белән алыш-бирешен бетереп, төп йортка күчкәннәр иде.

Люксембург — картадан карасаң, микроскоп аша гына күренерлек нәни бер ил — үгез мөгезенә кунган чебен кебек... Гаҗәп бит, без Люксембург аэропортына төшеп утырганда очкыч канаты астында Германия җире иде, күтәрелеп китүгә, Франция башланды.

Иллюминаторга маңгаемны терәп, уйланып барам. Әх, Люксембург, Люксембург, аз гына көнчыгыштарак урнашкан булсаң, яшәтерләр иде сине аерым ил итеп, хәзергечә әйтсәк: «...в составе России...»

* * *

Төнге Мадрид...

Шәһәр кайный, реклама утлары бии, уйный-көлә, күз кыса, чакыра — төсле аһәң булып нур чәчә, төнне бизи. Мин үзалдыма елмаеп барам. Рәхәт. Төнге Мадрид. Рәхмәт сиңа, язмыш. Иркен сулап, борынгы шәһәр урамнары буйлап барам. Менә ул кайнар йөрәкле испан халкының мәшһүр башкаласы! Кайчандыр дөньяны яулап алырга хыялланып, җилкәнле кораб-галеркаларда диңгез-океан давылларын авызлыкларга чыккан гаярь ир-егетләре үлмәс легендалар тудырган испанлылар — бәхетле, күпне кичергән бай тарихлы милләт.

Төнге Мадрид...

Кичке сәгать уннар. Без кечкенә генә рестораннан капкалап чыктык та, үзәк урамга күтәрелдек. Атлантик океаны буендагы Кадис шәһәренә поезд белән китәчәкбез, шуңынчы әле тагын ике сәгать вакытыбыз бар: ашыкмый гына тамаша кылырга була — төнге Мадрид безнең аяк астында... Урам тулы кеше. Күбрәк — яшьләр. Машиналар тукталган. Ап-ак чалбарлы кызлар-егетләр чиста урам ташларына җәелеп утырганнар. Кайсы гитара чиртә, кайсы җырлый. Бер төркем икенчесенә кычкырып дәшә, күрешәләр, кочаклашалар. Испан теле бик тә йөгерек, елгыр тел, сүзләре сәйлән кебек сибелеп кенә тора. Шундый тойгы: гүя өч ярым миллионлы халык яшәгән бөтен шәһәр бер-берсен белә, гүя якын тугannardan торган уртак гаилә. Урамның як-ягыннан тезелеп киткән бар-кафелар, ишекләре шар ачык, эчтә куе тәмәке төтене (испанлылар тартуның кирәген бирәләр), музыка, кызган кофе, шәраб исе агыла.

— Нинди бәйрәм бүген? — дип сорыйбыз гидтан.

— Гадәти көн. Эштән соң кичен Мадрид халкы шулай ял итә, — ди ул.

Хәйран калып, сокланып, кызыгып карап йөрибез. Ачык-көләч, эчкерсез чырайлар. Арада ник бер тупас кыланучы, ник бер сәрхүше булсын. Кафеларда югыйсә йөзләгән төрле эчемлек шешәләре тезелеп тора бит.

Хозурланып йөри торгач, мин шушылай ваемсыз күңел ачып та яшәп була микәнни, дигән гаҗәпләнүле уйларымнан арынып, Мадрид ритмына табигый кушылып китәм. Кинәт иңемнән авыр таш кубарылып төшеп киткәндәй була. Бу — минем илемдә туып-үсеп, картаеп үлгәнче һәркем иңендә йөртә торган каһәрле таш. Менә мин шул тоталитар таштан бүген беренче мәртәбә арындым. Рәхәт җиңеллек — кычкырып җырлыйсы килә. Үземне кеше итеп тоям. Илемдә мине чолгап алган яшерен күз, яшерен колак, яшерен хәсет, мәгънәсез тәртип-тупаслыклардан азат булып, хозурлык иркенә биреләм. Кешеләр менә шушылай кинәнеп яши, күңел ача белә икән бит! Төнге Мадридта мин бәлигъльк дәверемдә, беренче тапкыр әнә шулай итеп җан ирегең тойдым, хөрлек тәмен татыдым.

Төнге Мадрид...

Ничә еллар узган инде, ә барыбер күз алдымда. Россия шәһәрләре гадәттә кичке уннарда сүнә башлый, караңгы урамнарда сине шомлы өметсезлек биләп ала. Яшәүгә дәрт сүнү, кабер салкынлыгы җанны өшеткән мондый чарасыз минутларда мин дөньяның кайсыдыр ноктасында Мадрид, Истанбул, Стокгольм, Парижлар барлыгын күз алдыма китерәм дә, ерактагы әкият тәэсиреннән хозурлык алгандай: кайдыр кешеләр җан асрамый, ә яши бит әле, димәк, дөнья юкка яратылмаган... дип үз-үземне юатырга көч таба алам һәм гомер шәмен сүндермәү юанычы белән алдагы көнемә атлыйм...

* * *

Океан яры. Эре дулкыннар. Каршыда — галәми чиксезлек. Монда аргы яр дигән төшенчә була алмый. Мин беренче тапкыр Атабайда аргы яры рәшәле томан эчендә югалган Идел киңлекләренә исем китеп карап торганым бар. Әмма анда аргы ярны күзләрең белән күрмәсәң дә, күңелең белән тоясың. Ә монда... адәми зат акылы океан өстендә нәни күбек булып пышылдап сүнә. Дулкыннарның йөрәк тибеше, ялларын чайкаулары башка... Зиһенгә сыймаслык кодрәт, күкрәк читлеге эчендә җан канатларын киерә башлый, ирексездән күзгә яшь килә, гүя син шушы чиксезлеккә чумар алдыннан җир белән бәхилләшү мизгелен кичерәсең...

Океан ярындагы Кадис шәһәрен бераз караганнан соң Гибралтар бугазына чыгабыз. География дәресендә, карта алдында торган малайның,— тәнәфестә шпага итеп уйный торган күрсәткеч таягының очы,— шушы Гибралтар бугазыннан күпме тапкырлар шуып узгандыр. Урта диңгезне Атлантик океанга ялгаучы шушы тар гына сызык гамәлдә алай ук тар да түгел икән. Утыз чакрымнан артык ара югыйсә, каршыда кызгылт-комлы Африка ярлары, Марокко илендә калган испан шәһәре Сеута да уч төбендәгедәй ап-ачык күренә.

Янәшәдә генә Гибралтар утравы. Материкка күпер-юл белән тоташкан бу нәни генә утрау Англия кулында икән. Аларның хәрби базасы урнашкан әлеге утрауга без туристларның гына түгел, испанлыларның да керергә хокуклары чамалы иде бугай.

Гибралтар утравын кайтарып алу хакында Испания вакыт-вакыт сүз кузгатып караса да, элеккеге империя колачын җуйган Англиянең җиңел генә кайтарып бирәсе килми ахрысы. Әмма утрау язмышы бәхәсле калса да бу ике ил кан дошман булудан өстен торалар.

— Дамаск утравы моннан күпкә бәләкәйрәк иде,— ди Аяз ага.— Кытай белән безнекеләр шуны бүлешә алмыйча күпме бәхәсләштеләр. Мәйданы Гибралтар кадәр булса... Атом сугышы чыгасы булган икән...

Кытай чигендә, Амур елгасы уртасындагы Дамаск утравы өчен Кытай белән СССР арасында низаг чыгып, күпме кеше кырылуы безнең хәтердә шул. Ахырда, Мәскәү Кремленең политбюро бурзайлары әмере буенча, Дамаск утравы ракеталар белән тетелеп, җир йөзеннән бөтенләйгә юк ителде: «безнеке түгел икән, сезнеке дә булмасын!..»


Шул хәлләрне искә төшергән уңайдан мин Аяз аганы читкәрәк алып китеп, урыс холкы турында каяндыр ишеткән гаҗәеп бер анекдот сөйлим. Син дә тыңла, Гибралтар җиле, тыңла да дөньяга тарат...

«...Аллаһ катына бик күп халыклардан вәкилләр килгән, имеш. Һәрберсенең үз гозере, үз борчуы... Әйтик, яһүд бөтен яһүди халкына җәннәти тормыш бирүне сорый. Татар хәвеф-хәтәрсез сәүдәгәрлек итәргә мөмкинлек бирелсә, дөнья базарларын товар белән тәэмин итәр идем, барча халыклар да әйбәт яшәр иде, ди. Аллаһы тәгалә боларның теләген канәгатьләндереп җибәрә тора, шулай итеп, урыска чират җитә:

— О господи! — дип урыс, гөнҗәлә сакалын сыпырып. — У моего соседа Степана есть две коровы, у меня же ни одной. Сделай так, чтобы и у соседа не было коров...»

Аяз ага, анекдотны ошатып, ялкау гына көлеп куйды. Сизеп торам, аңа да рәхәт: аяз күк, саф һава, кояшлы Гибралтар җиле, тән-аң изри — яшисе килә!

Югыйсә, Аяз аганы бер кыздырып җибәрсәңме — чыдап кына тор: куллары канат булып калкына, кыска тәпиләре белән ярсып-ярсып йөренә, күзлек ырмавы астыннан борыны ыргып күтәрелә, катлы-катлы сүгенү белән утлы сүзләрне аралаштырып сибә генә! Андый чакта Аяз аганы беркем дә бүлдерә алмый, үз-үзен ыргытып сүккән утлы йомгак каршында озын буйлы кеше дә күз алдында кечерәя бара. Аннары, бөтен гарасатлы ялкынын сибеп бетергән Аяз ага кинәт туктап кала, төтене генә калган корбанының күләгәсен таптап, бөтенләй юк итеп китеп бара. Нәсел нәсәбе актарылып чыккан, мәңге кичермәслек сүзләр әйтелгән кеше берничә көннән соң гына айнып, тормышка кайта. Икенче вакыт карыйсың, Аяз ага теге кешене кочаклаган, күкләргә чөеп мактый: сүккән чактагы «бездарь... доносчы... надан... мокыт...» дигән эпитетлар урынына — «чорыбызның акыллысы... талант иясе! Бөегебез!..» дигән саллы сүзләр сибелә. Күпләр белә: Аяз ага кемнедер күкләргә чөеп мактый икән, димәк, көт тә тор, бераздан салып таптаячак. Ә кемнедер юк иткән икән, димәк, күпмедер вакыттан соң ул аны җирдән күтәреп алып, тузанын кагачак... Нишлисең, Аяз аганың сөргендә чарланган холкы шундый, безгә аны башкача кабул итү мөмкинлеге бирелмәгән...



*Гибралтар утравы.*

Гибралтар җиленнән хозурланып йөргән арада Аяз ага пар ромашкага тап булды. Шаккатып иеләбез — татар кебек оялчан гына утырган чып-чын ромашкалар. Мондагы магнолияләр, пальмалар кебек купшы үсемлек-агач дөньясына каян болай адашып килеп чыкканнар болар — безнең якның ак балкышлы чәчәкләре. Әгәр шушы мәлдә Хәсән Туфан янибызда булса, иелеп, «...И сеңелләрем», дип ул тыйнак ромашкаларны сыйпап, чәчәкләр телендә бер сөйләшеп алыр иде.

Яңадан без Аяз ага белән күпме генә эзләсәк тә бүтән бер ромашка да очратмадык. Чынлап та, адашып кына килеп чыкканнардыр алар җир читенә.

Йә, хуш, Гибралтар җиле!

Океан капкасыннан бүтән кыйтгаларга чыгып барышлый син безнең баштан сыйпап, юлга кузгалырга фатыйха бирдең. Ә юлыбыз — Урта диңгез ярыннан оҗмах тарафларына; дөньяның мәртәбәле байлары бәрәкәтле кояш астында җыелып ял итә, тән изрәтеп кәеф-сафа кора, азартлы уеннары белән бу гомернең тик бер генә бирелә икәнен оныттыра торган рәхәтлек иле — Коста дель Соль. Җил-су-кояшның шифалы талгынлыгы монда Тәңре үзе күктән төшеп ял итәргә көйләгән кебек...

Без заманча шәһәрнең туристлар өчен төзелгән бик шәп һотелендә тукталабыз. Шәһәр буш. Бай илләрнең байлары май аенда ял итүне хуп күрми ахрысы. Урамнар тып-тын. Казинолар ябык. Пальмалар күләгәсендә түгәрәк бассейнлы (әлегә сусыз), курчак өе кебек чирәп түбәле йортларда да һичкем күренми. Бу — ФРГ немецларының җәй көне ял итә торган фазендалары икән. Шулай итеп, бөтен шәһәргә без — Алмания, Франция, АКШ кебек илләрдән килгән туристлар хуҗа. Күп илләрне күргән язучылар әйтә: кайсы илгә барма, анда алманнар, эшләсә эшли, ял итсә, ял итә белгән гаҗәеп халык, диләр.

Безнең группада да язучылар, сәнгать белгечләре арасында берничә өлкән кеше — җитмештән узганнар бар. Ә инде чит ил туристларын карасаң... тоташы белән карт-карчыклар. Бай илләрнең картлыгы да ярлы булмый икән шул...

Ювелир кибетендә бер америка карчыгына исем китеп карап торуымны беркайчан да онытмам. Җилдә җилфердәрлек юка гәүдәле, туксан яшьләрдәге бу карчык кечкенә сумкасыннан Мәхмүт Хәсәнов романнары калынлыгында доллар пачкасы чыгарды да, учлап, витринадагы алтын әйберләрне үлчәүгә алып салды, электрон таблодагы бәягә карап алгач, үтә күренмәле нәзек бармаклары белән долларларны санарга кереште. Шушы кадәр долларларны минем үз гомеремдә беренче күрүем иде, үчле ярлылык халәтен шунда татыдым. Достоевскийның акчалы карчыкны балта белән бәреп үтергән Раскольниковы искә төшеп, кул кырые кычытып куйды. Долларлы карчыкның кавыксыз тән тиресе күренеп торган сирәк чәчле баш түбәсенә төбәлеп, кул кырыен балта тутәсенә тиңләп, бер мәл шулай басып тордым. Алтын әйберләрне үлчәү тәлинкәсеннән сумкасына койгач, карчыгым, миңа күз төшереп, әчтән яктырып елмайды. Тәрбияле яшәгәнлектән чит ил картлары, гадәттә, йончу йөзле булмыйлар, ягымлы, чибәр йөзле карчыкның күз карашыннан мин шул мәлдә оялып куйдым. Булган акчаңны да алырга рөхсәт итмичә, шыр ярлы хәлендә чит илгә чыгарып җибәргән партия түрәләренә карата өсталгән тагын бер уч нәфрәтем шыкырдап йодрыкка кысылды.

Кунакханә каршындагы бассейнда рәхәт чигәбез. Диңгез суы бер яктан керә, икенче яктан агып чыгып тора. Төбенә түсле кафель җәелгәнгәдер, су өслеге күз камаштыргыч фирүзә төсендә. Суның тәнне кочып, сыйпап алуында ук ләззәти сафлык сизелә.

Кичен диңгезгә төшәбез. Мин хыялланган Урта диңгез искиткеч тозлы икән. Су өстендә хәрәкәтсез ятсаң да төпкә китмисең.

Мин Мәскәүдән салкын тидереп киткән идем. Ирендә — кутыр. Борын тыгылган. Урта диңгез суы бөтенесен юды да төшерде. Кунакханә номерына мин Ленинградның зур галиме, профессор Скатов белән урнашкан идем. Төннәрен ул төртеп уята, борын тыгылу сәбәпле гырлавымны абайлап мин борылып ятам, уңайсызланудан шактый озак йокыга китә алмый идем. Ә инде диңгездә коенуның икенче көнендә Скатов болай диде:

— Төнлә ике-өч тапкыр яныңа барып карадым, әллә үлде микән, йөрәге туктады микән, дим, сулыш алуың да сизелмәде...

— Диңгез томауны бетерде, әллә инде борыннан баш мие дә агып чыкты,— дигәч, Скатов рәхәтләнеп көлде.

Көндез диңгез порты — Малага шәһәренә сәяхәт кылдык. Пикассо яшәгән йорт янынннан үтеп, Испаниянең дөньяга тарала торган атаклы шәрабларын татып карарга дип барабыз. Салкынча мәгарә утыз градуслы эсседән пешкән тәннәребезне шәраб кабул итәрлек хәлгә китереп җиләсләтә. Озын-озын өстәлләрдә нинди генә шәраблар юк — кайсын телисең, күпме эчә аласың, рәхим ит! «Христосның тууы», «Кояш тамчысы», «Херес» — тагын әллә нинди эчемлекләр. Әмма бу затлы шәрабларның тәэсире безнең күпне күргән каннарны уйнатырлык түгел, шуңа күрә, Аяз ага белән күз кысышып алгач, катырагына — брендига күчәбез.

Шәп кәеф белән кайтыр юлга чыгабыз. Малага артта кала, кырлартугайлар башлана. Юл кырыенда еракта ук күренерлек, бик озын итеп эшләнгән һәйкәлләр күренә. Һәйкәл дигәнем — биленә таянган көяз егет шәраб шешәсе булып чыга. Димәк, монда йөзем кырлары, шәраб кайнату үзәкләре...

Таң белән мин кунакханәнең уникенче катыннан диңгезгә карыйм. Тын су өслегеннән әкрен генә кояш күтәрелеп килә. Юк, бу безнең авыл күгенең кояшы түгел. Бу — борынгы кояш. Борынгы диңгез. Шушы гомердә янадан бу төбәккә кабат килеп булырмы? Юктыр шул, өлгереп булмас... Ә икенче гомергә ни язган? Диңгез ухылдап куя — ярга килеп сыенган тәүге таң дулкыны...

* * *

Севилья — гүзәл шәһәр. Мәшһүр испан шагыйре Гарсиа Лорка шигырьләренә кергән матур кала. Шәһәрне урталай бүлеп, Гвадалквивир елгасы ага. Пушкинның «Шумит, бурлит Гвадалквивир» дигән юллары искә төшә. Бәлки башланган җирендә, таулар арасында шулайдыр, ә монда Гвадалквивир җәелеп, тып-тын гына агып ята. Гвадалквивир — гарәпчә олы елга дигән сүз имеш (әмма мин гарәб сүзлегендә андый сүз тапмадым).

Севильяның үзәгендә күгәрчен паркы бар. Меңләгән күгәрченнәр күбесе ак төстә. Гаҗәп күндәм кошлар, учка куналар, иңгә, баш түбәсенә. Бер мизгелдә син меңләгән күгәрчен «яңгыры» уртасында каласың. Шунда ук кошларны сыйларга арзанлы гына бәягә җим сатыла. Бала-чагаларга юанырга искиткеч күңелле урын бу. Җим чыгардыңмы — «кәҗә рәхмәт әйтә, сакалын селкетә», дигән шикелле... Күгәрчен рәхмәт әйтә, томшыгын селкетә.

Урамнарда гөлләр, балконнарда гөлләр. Һәр бинада хуҗасының йөз чалымы, холык рәвеше, рухы чагыла. Хуҗалы йортлар затлы нәселле эт-песи кебек күркәм-пөхтә күренәләр. Шомарган урам ташларында тояк тавышлары яңгырый. Аллы-гөлле итеп бизәлгән фаэтонда сине юрга атлар үткән гасырларга, легендалар иленә алып китәрләр шикелле. Шәһәр үзәгендә испан корольләренең җәйге резиденциясе. Король ял итмәгәндә һәрбер туристка капкасы ачык. Ишегалдында 900 яшьлек бинилһая карт агач үсә (исемен хәтердә калдырмаганмын. Һәрхәлдә баобаб түгел). Кәүсәсе буынлы-буынлы галәмәт юан агач, тугыз гасырны башыннан кичергән аксакал шикелле, сабыр гына күзәтеп утыра: әйдә, ашыккан булыгыз, дөнья куыгыз, әлләниләр кыланыгыз — барыбер, сез китәсез, мин калам...

Татар шанлы, дәүләтле чагында ук үсә башлаган олуг агач кәүсәсенә учны куям: сөйлә, агач, яфракларың телендә пышылда миңа яшәү мәгънәсен, синең гомер каршында үземнең тузан бөртеге генә икәнемне беләм. Әмма күпме корольләрне, җиһангир булырга хыялланган әмирләрне күргән олпат агач дәшми, акыл-хәтере аның тамырларында...

Севильяда католикларның зурлыгы ягыннан дөньяда өченче урында торган (Ватикан һәм Лондондагыдан кала) храмы бар икән. Бу кафедраль собор тыштан алай алтын гөмбәзләре белән кукыраеп утырмый, ә инде эченә керсәң, зурлыгына, мәһабәтлегенә хәйран каласың. Буынлы-буынлы итеп эшләнгән колонналар өскә менеп китә дә, очлаеп тәмамланганда гөмбәзгә кушыла. Баш әйләнмәле биеклек. Мин, тавышыма көч биреп, ютәлләгән булам, гөмбәзләр арасыннан күкрәү-гөрелте тарала.

Бай бизәкле борынгы мәрмәрдән эшләнгән диварларга мәшһүр рәссамнарның зур-зур картиналары эленгән. Урта бер җирдә кара-каршы итеп ике орган куелган. Кырык биш метр биеклектәге бу органнар уртасында калгач мин, сокланудан, тынсыз калып, эскәмиягә утырдым. Идәннән түшәм гөмбәзләренә кадәр эреле-ваклы скульптуралар тезелеп менә, алар һәммәсе дә дини вакыйгалардан чыгып сурәтләнгән. Кешелекнең меңнәрчә еллык тарихының сәнгати гәүдәләнеше. Нинди куллар тылсым өреп, күпме гомерләр буе иҗат иткән бу могҗизаи галәмәтне? Югары кимәлдәге осталык, камиллек тантанасы! Бу ганимәтне карап чыгарга гына да бер гомер генә аздыр, валлаһи, аздыр! Акыл-зиһен көчсез калган бу могҗиза каршында мин сулышыма кабып, өнсез утырдым да... сугыш, кан кою, җимерү өчен генә туганмы әллә адәм балалары бу җиргә, дигән өметсез уйлар тулган күңелемә яңа бер юаныч-өмет алып, мондый сәнгать тудыра алгач, адәми затлар җирдә яшәргә хаклыдыр бәлки, дигән яңа бер хакыйкатька баеп урынымнан кузгалдым.

Храмның бер уентыгында Христофор Колумб табуты тора. Аны Колумбның үз чорында утлар-сулар кичкән иң якын аркадашлары иңенә күтәргәннәр. Балавыздан эшләнгән бу сыннар нәкъ тере кебекләр. Америка материгын европалылар өчен ачып, индусларның цивилизациясен кырып бетерүгә юл сапкан Колумбның монда өченче кабере икән. Беренче тапкыр аны Франция белән ике арада сугыш чыккач, чик буендагы кабереннән казып алып Кубага илтеп күмәләр. Кубада тынычлык беткәч, Севильяга алып кайталар. Майя, ацтекларның каһәрле күз яше Колумбны һаман эзәрлекли, җәсәденә дә тынгылык бирми күрәсең.

Храмның билгеле бер урынында, пыяла шкафларга чын алтыннан эшләнгән сәнгати җәүһәрләр тезеп куелган. Кыйммәте алтын булуда гына түгел, бу зиннәтләрне Испаниянең милли каһарманнары — атаклы тореадорлар бүләк иткән.

Севилья — тыныч, ягымлы, яшәр өчен бик тә уңайлы шәһәр. Заманында гарәпләр эз калдырган бу каланың исеменнән үк шигърият аңкып тора.

Севилья — тәмле авазларның төсле яңгырашы.

Севилья — зәйтүн агачына кунган яшь испан сандугачының таң нурында коенуы.

* * *

Андалузия киңлекләре... Йөгерек юл безне Гранада шәһәреннән Испаниянең мәшһүр шагыйре Федерико Гарсиа Лорканың туган җиренә алып бара. Еракта кучкарланып торган мәрмәр күкрәкле таулар күренә. Юл кырыенда кулларын җәйгән карачкы шикелле биек кактуслар кала. Чиста, төпсез күк йөзенең биеклеген тагын да искәртергә теләгәндәй, очынып үскән эвкалиптлар, кояш тамчысы сыман янып утырган җимешләре белән чуарланган әфлисун агачлары, тау битләрендә зәйтүн куаклары. Кырыгынчы параллель... Монда елның өч йөз егерме көнендә бер генә болыт та күренми, бер генә тамчы да яңгыр төшми икән.

Ызаннар белән бүлгәләнгән кырларда эшләүче крестьяннар чагылып кала. Уенчык шикелле кечкенә тракторлар кыймылдый. Бер якта өлгергән бәрәңге җыялар (май ае бит!), икенче яктан яңаны утыртып та

киләләр. Кәлсу туфрак, сугарулы кырлар. Чехов әйткәнчә, тартә кумсән, тарантас үсеп чыгарлык чем-кара туфраклы җирләрдә туып үскәнгәме, бу җирләрнең төсе миңа ят тоела.

Урыны белән буш яткан кырлар да күренә. Боларның хуҗалары чит илгә чыгып киткән, хуҗасы кайтмый торып бу җиргә беркем дә кагыла алмый икән. Монда инде, бездәге кебек, автобусны теләсә кайда туктатып, хатын-кызлар уң якка, ир атлар сул якка, дип әйтә алмыйсың, һәр карыш хуҗалы...

Автобус эссе кояш астында әлсерәп яткан юлдан күләгәсен ияртеп алга ашкына. Шундый тойгы: гүя без берничә дистә язучы, тәялешеп, Казаннан Тукай-Кырлайга, шагыйрь мәккәсенә дип юлга чыкканбыз. Юл буенда, сыек яшеллек арасында уйдык-уйдык булып ут кызыл чәчәкләр кала. Бу кыргый чәчәкләр чәчрәп киткән кан тамчылары сыман... Фалангист пулясы тигәч, Лорканың йөрәгеннән тамган кан тамчылары гүя утлы чәчәкләр булып бөтен Андалузия киңлекләренә сибелгән. Шәфәкъ вакытында көмеш гөмбәзле тау түбәләренә шушы чәчәкләрнең шәүләсе кызарып төшәдер сыман. Әллә соң борынгы таулар бөек улларын вакытсыз җуйганны бик соң аңлаган тарихның үзе шикелле кызара микән...

Лорканың туган авылы Фуэнто Вакироска җитәрәк сусыл-дымлы тополь урманы башланды. Ябалдашлары бер тигез биеклектәге гаскәр кеби яшь урман. Билгеле бер яшькә җиткәч, тупылларны кисеп, сувенир фабрикасына озаталар икән. Димәк, Лорка дәверендә һәм аннан соң бу урман берничә тапкыр киселгән, яңадан утыртылган инде. Лорканың күп кенә әдипләр эпиграф итеп ала торган шигырь юлларының хикмәте менә кайда ята икән!

Тупыллар да китә,
калдырып безгә җилен генә...

Менә без бер-ике катлы җыйнак, шикәр кебек ак йортлардан торган Фуэнто Вакирос авылында. Авыл дию дә гөнаһ, пөхтә, һәр карыш җире чәчәктән, җимеш агачыннан торган, тротуарлы, мәйданлы уенчык кебек шәһәрчек бу! Безне алькальд (административ җитәкче) Франциско Мартин Гарсиа каршылады. Урындагы муниципалитет бинасында Лорканың якташлары белән очрашу-сөйләшү, истәлекле бүләкләр алмашу булды.

— Теге елларда миндә Лорканың китабы бар иде,— диде Мартин Гарсиа.— Ләкин мин аны кешегә күрсәтергә курыктым. Лорканың исемен телгә алырга да ярамый торган еллар иде. Әмма тыюга да карамастан, чын испанлылар шагыйрьнең иҗатын күңелләрендә сакладылар.

Мәскәү тәнкыйтьчесе, профессор Феликс Кузнецов:

— Сездә Лорканың исемен дә телгә алырга ярамаганда, аның китаплары безнең совет илендә рус һәм башка халыклар телендә күпләп басылды, шагыйрьнең икенче ватаны безнең ил булды,— диде.

Генералиссимус Франко үлгәннән соң Лорканың китаплары кабаттан күпләп басыла башлый. Туган җирендә шагыйрь истәлегенә мемориал төзелгән. Укыган мәктәбенә исеме бирелгән. Шагыйрьнең торган йорты каршына килгәч, ирексездән аның шундый юллары күңелгә килде...

Мин үлгәч,
Балкон ишекләрен япмагыз —
кырдагы игенчеләр тавышын тыңлармын.

Шушы мизгелдә студент елларыннан бер хатирә искә төште. 1969 елда, беренче курска укырга кергәч, Фәннур Сафин кулында китабын күреп: «Нинди шагыйрь соң ул Гарсиа Лорка?» — дигән идем. «Лорканы да белмисеңмени!» — дип Фәннур миннән ачыктан-ачык көлгән иде. Мин

үземнең наданлыгымнан шул чакта бик үртәлеп, оятымнан үҗәтләшеп, болай дигән идем: «Лорканы мин белеп кенә калмаячакмын, күреп торырсың, аның туган җиренә — Испаниягә дә барачакмын!». Бу сүзләремнән Фәннур да, моны тыңлап торган курсташларым да шаркылдап көлгән иде. Фашистик ил дип саналган Испаниягә бару — ул елларда акылсыз хыял иде бит.

Менә мин, шул сөйләшүгә нәкъ ун ел үткәч, испан кояшы астында, Гарсиа Лорканың өе каршында басып торам. Мондагы йортлар да, урамнар да үзгәрмәгән, Лорка исән чактагыча икән. Бу ташлар аның аяк тавышларын хәтерлидер әле. Бу тәрәзәләрдә аның уйчан йөзе чагылып үткәндер, диварларга күз карашы сеңеп калгандыр. Шагыйрь сүзгә әйләндерергә өлгерә алмый калган хисләр бу тирәлеккә күчеп, табигать белән кушылгандыр. Шушы табигатьне үз күзләрең белән күргәч, аның мәгълүм шигырьләре дә яңа яктан ачылып китә, моңарчы тоеп, искәреп өлгермәгән төсләрдә үзгә яңгыраш таба.

Монда берничә еллар элек Лев Ошанин белән Евгений Евтушенко сугылып чыккан. Совет иленнән безнеке кебек зур группаның Фуэнто Вакироска беренче тапкыр килүе икән. Безне күрергә килгән крестьяннарның кызыксынуы йөзләренә чыккан. Кыяфәтләре белән нәкъ безнең авыл кешеләре, киемнәре генә үзгәрәк... Җир кешесе, нинди генә милләттән булмасын, табигать белән янәшә яшәгәнлектән, рухы-кыяфәте белән бер-берсенә охшаш була күрәсең.

Саубуллашыр алдыннан без авыл агайларына значоклар, истәлекле сувенирлар биреп калдырдык. Алар, кулын бөгеп, йодрыклары җилкә тигезлек күтәрделәр:

— Компаньэро!

Бу — биш бармакны бер төенгә җыеп, теләктәш булыйк, гадел булыйк, без бит бер планета уллары, дигән мәгънә иде.

Кузгалабыз. Алда — яшь тупыл урманы буеннан сузылган юл. Сандугач канатында төнге чык тамчыларына кадәр күрә белгән шагыйрь шушы юлдан Гранадага чыгып киткән. Соңгы мәртәбә... Лорканың истә калган хикмәтле юлларын күңелдән кабатлыйм, ул сулаган һаваны сулагач, ул күргән күкне тойгач, ул табынган табигать төсләреннән хозурлангач, шигырь юлларына сүз җаны иңә... «Мәхәббәттән үлә чәчәкләр»... Өзәргә дип үрелсәң, шагыйрь авазы белән кисәтер кебек нәзберек гөлләр. «Куаклыкта елады кайтаваз», «Ә җил, түбәгә атланып, мышнап, чирәпне ялый».

О, кайда ул авылым —
Минем күз яшьле Андалузиямдә.

* * *

Кар чалмалы Сьерра Невада кыялары итәгендә, Андалузия киңлекләрендә кызган һава агымы юашланып, җиләс сафлык белән алмашынган урында мәһабәт диварлы хисар ерактан ук күренеп тора. Бер үк вакытта кырык мең яугир сыярлык хисар да, гарәб әмирләренең истирахәт чигеп яшәгән оҗмах бакчалы, фонтаннар белән бизәлгән тәхет сарае да булган ул Әлһәмра.

Дага сыман эшләнгән төп капка өстенә ике ачкыч һәм баһадир кулы ясалган. Моның мәгънәсе болай аңлатыла: Давыд ачкычлары — дин һәм хакимлек билгесе, кулның биш бармагы — Исламның биш канунын белдерә: иманга килү, намаз уку, ураза тоту, зәкят бирү, хаҗ кылу.

Әлһәмра кальгасына нигез салучы хаким — Мөхәммәд ибн-әл-Әхмәр (Архонда 1195 елда туган) булган. 1333 елда Гранада тәхетенә менгән Йосыф Әбел Хаҗи гасырлык төзелешне — Әлһәмра кальгасын төзетеп, бизәкләп бетертә. Сарай, хакимият тирәсендә беркайчан да

тынычлык булмый. Йосыф Әбел Хаҗины мәчеттә дога кылып утырган мәлендә чәнчеп үтерәләр. Ул мәчет Әлһәмра эчендә әле дә саклана. «Бөек хаким, Исламның үткен кылычы, байракчысы» дип язылган ак мәрмәр кабер ташын гына вакыт каядыр юкка чыгарган.

Искиткеч сәнгатьле итеп төзелгән кальга бу!

Акыл адашырлык таш диварлар безгә, баксаң, язулар икән бит. Ташны үтә бер нәфислек белән чокып, гарәб хәрефләрен могҗизаи үрә-үрә меңләгән шигырьләр язылган монда. Боларны укып чыга алучы бар микән, укып чыгарга бер кеше гомере генә җитәр микән?.. Әлһәмра кальгасы төрле яуларда, төрле гасырларда кемнәр генә кулына төшмәгән, әмма шушы кадәр сәнгатьле эшләнгән язмаларны кырып, җимереп юк итәргә берәүнең дә кулы бармаган. Безгә, кабер ташларыннан да үч алучы славян кавемен күргәннәргә, бу бигрәк тә гаҗәп һәм гыйбрәтле иде.

Менә без нәфис колонналар арасыннан арысланнар аранына керәбез. Урта бер җирдә түгәрәк фонтан. Фонтан тирәли унике мәрмәр арыслан утыра. Элекке заманнарда җәзага хөкем ителгән бәндәләрнең шушы урында башларын кыйганнар. Шома идән ташларындагы каралҗым таплар җуелмас кан эзләре, имеш.

Астан идәне җылытмалы галиҗанәб әмир мунчасына кергәч, стенадан чыгып торган арыслан авызларыннан агып торган су челтерәвен, гарем ягыннан кәс-кәс атлап кереп килүче берсеннән-берсе назлы кызларның толымын сүткәндә ишелеп төшкән чәч шарлавыгы тавышын ишетерсең сыман. Шул меңнәрчә гүзәлләрнең назлы аяк табаннарын үбеп калган чәчәкле идән ташлары бүген дә әле бакый дәверләрдәге бәхетле төш тәэсиреннән уяна алмаган кебек.

Кайчандыр монда Шәрыкъ дөньясы кайнаган.

Шушы мәһабәт диварлар эчендә фонтаннар шавын тыңлап, оҗмах бакчаларына хозурланып, таштан гаҗәеп җәүһәрләр төзегән osталар булганлыгына сокланып торганда син Ислам галәменең никадәр мәртәбәле гасырлар кичүен хис вә акыл-зиһенең белән тоясың. Эчтә горурлык хисе, нәүмиз моңсулык уяна.

Йокымсыраган, тымызык Европаны дер селкетеп, кылыч яшьнәтеп, җирләр билән, сәнгатьле кальгалар, храмнар, шәһәрләр төзетеп, елгатау-үзәннәргә җырлы исемнәр кушкан гарәбләр испан халкының яшәү рәвешен, йөзен, рухын үзгәртеп, теленә-моңына үзгә яңгырашлар биреп, үзләре хакында үлмәс легендалар калдыралар да тарих сәхнәсеннән төшеп калалар.

Искиткеч чор була бу!

Толедо, Кордова, Севилья, Гранада университетларына төрле тарафлардан гарәб фәнен, тарихын өйрәнергә, белем эстәргә яшьләр агыла. Гаярь егетләр корал тотарга, егетлек һөнәренә, рыцарьлыкка өйрәнергә дип Гранадага омтыла. Шәрыкъ аһәңен тыңлап, дастаннарны өйрәнергә килгән шигырь сөючеләрне дә Гранада үз кочагына ала.

Дәрт уятып, гарәпләр Испанияне шагыйрьләр ватанына әйләндерәләр.

Әмма... Бар да беткән, җилләр искән, комнар күчкән инде... Узганнардан сабак ала белми мөселман. Тәре йөртүчеләр мәкерле, астыртын, явыз алымнар кулланып, Шәрыкның кайнар холкына ут өсти-өсти, үзара чәкештереп, хәлсезләндерә-хәлсезләндерә яшел байракларны таптап үтәләр.

Гранаданы испанлыларга калдырып, үзенең яраннары белән чигенә-чигенә тауга күтәрелгән әмир Боабдил турында легенда әле дә халык хәтерендә. Боабдил соңгы тапкыр Әлһәмра кальгасына инәлеп караган биеклек «Күз яшьле калкулык» — La Cuesta de las Lagrimas дип атала. Әлһәмра белән хушлашу аның өчен тәхетне югалту гына түгел, ә бөтен нәсел-нәсәбенең горурлыгын да җую була. Боабдил хакимнең бәгыреннән сулкылдап куюын ишеткән кыя el Ultimo Suspiro clel Moro «Маврның

хушлашу сулышы» дип йөртелә. Шул мәлдә янәшәсендә торган әнкәсе Айшә улына болай ди: «Оялыр идең. Ир булып саклый алмадың да, хатын-кыз булып җылап торасың».

Әлһәмраның иң биек манарасына күтәрелеп, гөлбакчаларга күмелгән киңлекләрне тамаша кылган император Карл V җиңүче горурлыгы белән болай ди:

— Бу байлыкларны җуйган адәмнең язмышы кызганыч...

Гранаданың йөзек кашы — Әлһәмра, синдәге мәҗара-истәлекләр мең дә бер кичәгә торырлык. Мөселманнарның табынырга килә торган икенче кәгъбәсе син, изге чишмәңнең суын татып карыйк та кузгалыйк әле...

Съерра де-Әлкафар кыялары күренеп торган урында Виснар тарлавыгы бар. Фуэнте-Гранде чишмәсе шул тарлавыктан бәреп чыга. Суы күбекләнеп, кайнап чыкканга күрә гарәпләр аны Айнадамар (Айну-әл-адамар — Күз яшьле чишмә) дип атаганнар. Бу шифалы суны Гранада шәһәренә кадәр җиткерү өчен гарәпләр Айнадамар каналы төзеткәннәр һәм канал тирәсенә җиңел-зифа колонналы җәйге ял сарайлары корганнар. Җир тетрәүләр һәм гасыр җилләре бу зиннәтле сарайларның эзләрен дә калдырмаган, бары тик Гранада Археологик музеенда гына сурәтләрен һәм сакланып калган таш чәчәкләрен күреп сокланырга мөмкин.

Әлеге чишмәнең матурлыгына мәдхия җырлаган гарәп шагыйре Әбу әл Бәракә әл Балафикыйның шигъри юллары сакланып калган:

«Айнадамар белән аерылгангамы, кан тибешем сүлпәнләнә, күзләрем тирәнлегеннән кайнар яшь ташкыны кайнап чыга.

Мәхәббәт колы булсаң, йөрәгеңне мәңгегә җуясың, дип Айнадамар сулары әрнеп сулкылдый.

Ярларында сайраган кошлар Маусили[1] аһәңнәре белән генә ярышырлык моңнар сибә. Ул моңнар мине узган яшьлегемә кайтара.

Чишмәгә килгән сылулары нинди — һәр мөселманны, Йосыф кеби, үз динеңне алыштырып, мәхәббәт диненә табынырга мәҗбүр итә».

Бу юллар язылганга алты гасыр үткән, ә чишмә, һаман шулай, йөгереп-уйнап ага. Шушы хозурлыкларга карыйм да... ышанасы да килми... Виснар чокыры тирәли йөзләрчә каберлекләр тезелеп киткән. 1936 елда атып үтерелгәннәр каберләре... Ачык йөзле, чибәр, күзләрендә гарәптән калган иман нуры көйрәгән испанлыларга карыйм да... болар да идея белән алданды микәнни, бер-берсенә карата явызлык кыла алды микәнни, дип аптырап уйланам.

1936 елның 19 август төнендә бернечә көн генә элек кулга алынган Гарсиа Лорканы төрмәдән машинага утыртып алып чыгып китәләр. Виснар тарлавыгы янында машина туктый. Винтовкалы фалангачылар тәмәке тарта-тарта йөренәләр — таңны көтәләр. Ә Лорка берни сизми, кая алып барасыларын да белми әле.

Таң беленеп килгәндә... ерактагы кар түбәле тауларның түбәсенә кояшның тәүге нурлары кагылганда... Шагыйрьнең йөрәгенә винтовкаларның кара күзләре төбәлгән. Соңгы мизгелендә Лорка ниләр уйлады икән? Цикадалар бер-берсен уздырып җырлады микән? Андалузия күгеннән үрелеп алып, шигыреннән-шигыренә күчереп йөрткән Ай аны соңгы мәртәбә күреп калырга дип таулар артыннан калыкты микән?

Бернечә пуля тиюгә карамастан, шагыйрь әле һаман аягына басарга тели, үлем белән тартыша. Шул чак фалангистларның берсе аягы белән аның гәүдәсен җиргә кыса һәм терәп диярлек атып җибәрә. Атаклы шагыйрьне атып үтерүдән ул гомере буена җитәрлек гөнаһлы ләззәт ала.

Гарсиа Лорканың гәүдәсе шушы Айнадамар чишмәсеннән ерак түгел зәйтүн куагы төбенә күмелгән диләр.

---

[1] Исхак әл Маусили — гарәп дөньясының атаклы музыканты.

Испан шигърияте борынгы гасырлар тибрәнешен көйгә салган олпат тарихлы, кабатланмас дөнья. Гонсало де Берсео (1195—1264), Хуан Руис (1283—1350) кебек бакый заманда иҗат иткән шагыйрьләреннән башлап, Яңарыш эпохасында Хуан де Мена (1411—1456), Хиль Висенте (1465—1540), Мигель де Сервантес (1457—1616), Лопе де Вега (1562—1635) кебек дөньяга танылганнары гына да дистәләрчә.

Идел-Дунай арасында татар цивилизациясе җимерелә барып, канлы афәт халыкның илһам чыганагын сүндергән гасырларда Испаниядә йөзләрчә шагыйрьләр йолдызлыгы калкып чыга.

Африканың кайнар каны, гарәп аһәңе өртелгән испан шигърияте дөнья поэзиясенә үз тылсымы белән килеп кушыла. Соңгы гасыр шагыйрьләре арасыннан бигрәк тә Мигель Эрнандес, Рафаэль Альберти, Гарсиа Лорка әсәрләре рус теле аша безнең киңлекләргә дә килеп җитеп, күңелләрне биләп алды. Гаҗәп бит: Гарсиа Лорканың иҗаты белән кызыксынмаган, аңа шигырь багышламаган татар шагыйре сирәктер. Хикмәт монда Лорканың Муса Җәлил кебек үк утыз сигез яшендә фашистлар тарафыннан үтерелүендә генә түгел, ә шигъриятеннән Шәрек моңын, Шәрек хасиятен тоеп, кандаш якын күреп үз итүдәндер мөгаен. Без аның тылсымлы шигъриятендә күктән Ислам нуры иңдергән Ай яктысын да, кара салават күпере шомын да тоябыз.

Лорка — гаҗизанә язмышлы испан халкының йөрәге ярылган гитарасы...

Испания алты революция кичергән ил. Алтынчысы, коммунизм афәте йоккан иң хәтәре — 1936 елда башлана һәм канлы ватандашлар сугышына әйләнеп китә. Революция, гадәттә, ярлы илдә кабынмый. Халыкны матур идея белән исертеп, канга батырып, саташтырып йөргән арада ул илнең милли байлыгын талап алып чыгып китәләр. Колонияләр биләп баеган илләрнең язмышы шундый: башта ул халыкларны талый, аннары империянең үзен талыйлар...

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, безнең үсмер чакка туры килгән илленче еллар уртасында да әле Испан шаукымы халыкта сизелә иде. Җир читендәге ерак, серле бер илдә канлы бәрелешләр булганлыгы, генерал Франко дигән явыз диктаторның бу илне бәхетсезлеккә дучар итүен еш ишетә идек. Шул ук вакытта Испан революциясе безне кызыктыра да иде. Каһарман очучыларыбызның анда һава сугышларында катнашуы... Ут астыннан алып чыккан испан балаларын үзебезнең «бәхетле» илгә алып кайту... «Гренада, Гренада, Гренада моя» — дип җырлана торган җырның күңелләрне биләп алуы...

Их, нигә соң иртәрәк бетте микән анда сугыш, егет булгач, мин дә шул Дон Кихотлы илгә китеп яу кырында батырлыклар кылыр идем бит, дип ачынып уйланганым хәтеремдә. Испания дигән кояшлы сүздән үк мин тел өстендә сусыл апельсин тәмен тоям, күңелем рәхәт кытыкланып ала, күз күрмәгән таулар, серле диңгезләр томан аръягындагы хисси манзара булып хыял аша уза иде.

Испаниядә кабынып киткән ватандашлар сугышында совет иленнән дә шактый кешеләр катнаша. Без андагы вакыйгаларны күбрәк язучы Илья Эренбург һәм журналист Михаил Кольцов язмаларыннан беләбез. Чынбарлыкта башкачарак булган икән шул. Монда җибәрелгән хәрбиләрнең күбесе НКВД агентлары була. Мәскәү кулы — Испаниядән таралган шпионнар челтәре бөтен Европага үзенең ятьмәсен кора. «Совет коткаручылары»ның мәкерле эшләре хакында әледән әле, соңлап булса да, яңа фактлар ачыла тора. Моңа бер генә мисал китерик: совет эшкуарлары бик арзан хакка алып, кулланырга яраксыз, бозык азык-төлекне корабларга төяп республикачыларга җибәрә торалар. Кораб диңгезгә чыгып киткәч, координатларын дошман ягына белдерәләр. Кораблар бер-бер артлы батырыла. Зур суммалар совет коммунистлары кесәсенә агыла тора. Бервакыт бу кыңгыр эш очраклы рәвештә фаш ителә. Чираттагы кораб, штормга эләгү сәбәпле, юлын үзгәртеп, башка портка

керергә мәҗбүр була. Шунда трюмны ачып карасалар... «Совет каһарманнары»ның ни эш кырып ятканлыгы әнә шунда мәгълүм була.

Әлбәттә, совет иленнән килгәннәр арасында чын мәгънәсендә батырлык күрсәтеп, үз-үзен аямыйча көрәшкәннәре дә күп булгандыр. Әмма төп көч яшерен максатлар белән җибәрелгән була. КГБ генералы Судоплатов Испан сугышында кайчандыр Россиядән киткән иммигрантларны троцкийчылык тарафдарлары, шпионнар дип кыру-аттыру НКВД агентларының төп шөгыле булуын яза. Соңрак боларны Сталин берәм-берәм Мәскәүгә чакырта тора һәм Лубянка стенасына терәп аттыра тора. Гөнаһ кылып кайткансың икән, мин гаепсез идем, дип лаф орма — маңгаеңа пуля ал...

Бу җәһәттән генерал Александр Орлов (Лев Фельдбин) язмышы кызыклы. Аңа бик тә яшерен миссия йөкләнгән була. Бу хакта Эдвард Радзинскийның «Сталин» дигән китабында мондый юллар язылган: «Франко гаскәрләре Мадридка якынайган көннәрдә Орлов «Иван Васильевичтан» шифрлы телеграмма ала (кайчакларда Сталин яшерен телеграммаларны үзенең яраткан каһарманы — Иван Грозный исеме белән җибәрә торган була). Орловка алтын запасын СССРга алып чыгу турында Испан республикасы хөкүмәтен күндерү бурычы йөкләнә һәм ул аны уңышлы үтәп чыга. Алтын — диңгез буе шәһәре Картахена мәгарәсендә саклана. Гомеренең соңгы көненә кадәр Орловның күз алдыннан китми: мәгарәгә килеп кергәч ул тау кебек өелгән әрҗәләр күрә — 600 тонна алтын хәзинәсе. Хуҗа (Сталин) алтынны кузгаткан вакытта берникнди дә «урыс эзе» калырга тиеш түгеллеген искәртә. Орлов аңлый: Сталин бу хәзинәне кире кайтарып бирергә җыенмый.

...Орлов АКШның милли банкы кешесе Блэкстон исеме белән испан алтынын алып чыга».

XVI гасырда испан конкистадорлары Мексика майяларын — ацтек һәм инкларны рәхимсез кырып, йөзләрчә тонна алтын әйберләрен корабларга төяп материкка алып кайтуын искә төшерсәң, Картахенадан алып кителгән бу алтынга майяларның каһәре төшкәндер һәм аңа орынган бер генә адәми зат та мантымас, дип уйларга кала...

Ул чакта диварларга зур хәрефләр белән «коммунистлар — террористлар» дигән язуларга аптырабрак карап, Гранада урамыннан барган мин боларны белгәнмени! Без — туристлар, бәхетле халык, тамаша кылудан гайре берникнди борчуыбыз юк. Кемдер тыенкы гына җыр башлый, калганнар аңа кушыла. Мин Мәскәү профессоры Федор Семенович Наркирьер янынарак елышам. Күңелемдә аңа биреләсе сорау бөреләнеп килә. Наркирьерга сиксән яшьләр тирәсе. Самолетка утыруга ул кинәт үзгәреп китте: читлектән ычкынган елгыр җәнлек шикелле салон буйлап йөри, һәркем белән таныша, сабый кебек юкка да сөенә башлады. Шуннан бирле гел хәрәкәттә. Бәхете чыраена ташып чыккан.

— Федор Семенович,— дим аның беләгенә кагылып.— Шәһәрнең исеме Гранада бит. Ни өчен Михаил Светлов аны Гренада дип язган икән? Шәһәр исемен үзгәртергә ни хакы бар аның?

— Шулай кирәк...— ди Федор Семенович, яһүдләргә хас осталык белән фикерен алсу томанга төреп бирә.— Рус теленең фонетик үзенчәлеген истә тотып шулай язган аны шагыйрь...

Сугышка маһир урыс аны «граната, граната моя», дип җырларга мөмкин, диме бит, ә...

Гранадада соңгы төн — истә калырлык кадер киче.

Менә без бар-клубның тәбәнәк өстәлләре янында утырабыз. Түшәмгә асылган вак көзгеле, мозаикалы шарлар әйләнә, серле караңгылыкка галәми нурлар чәчелә. Алдыбызда — көмеш чиләккә, эре боз эченә батырылган шампан шешәләре кукыраеп утыра. Арткы стена ягы ачык. Аннан кар түбәле кыялар күренә. Шул турга баскан егет гарәпчә моңлы итеп җырлый. Шул кайгылы аһәңгә бөтенләй ярашмаган үтә дә дәртле ритмда фламенко биюе башлана. Нечкә билле, сылу гәүдәле кызлар

учларында кастаньетлар шакылдатып, үткен үкчәләре белән янгыравык идәнне чыкылдатып, дәрт-кодрәт чәчәләр. Шашкын ритм. Гәүдә бөгелешләрендә, кул хәрәкәтләрендә, күз карашларында никадәр кыюлык, эчке дәрман, горур ыргылыш, шушы ритмда яшәү тантанасы! Йөрәк кайнар ритмга яраширга теләп ярсына: ярый әле, ярый әле, шушы мәлдә күкрәгеңне бәреп чыгасы җан канатын тыеп калырга Шәрыкъ моңы бар. Бу җуләр, исерткеч, рәхәт-зәһәр ритмнан игътибарыңны кар түбәле кыялар эргәсендә җырлап торган егеткә юнәтәсең дә... ул сине моңы белән тынычландыра, җан белән тән аерыласы мизгелдән коткарып кала. Фламенко — испаннарның мактанычы, милли холкы, бөеклеге, кайнарлыгы, азат рухы. Мондый сәнгать белән теләсә нинди халыкны уятып китәргә була...

Биюдә — безнең татардагы кебек мескенлек колы түгел шул болар. Бию ул — очар кош, аргамак булып үз-үзеңнән ыргытыла алу, аяк белән келәм чигү, яшим икәнеңне раслау сәнгате. Ә безнең егетләребез башында — сай түбәтәй, кызларыбыз башында — тоз савыты чаклы гына калфак дигәне... Яшел күлмәк тә казаки. Кая ул ук-җәя тоткан яугирләр?! Хан сараеның җарияләре, сугыш каһарманнары, алтын путасына булат кылыч таккан гаскәр башлары кая? Алтын Урда кебек мәмләкәткә ия булган халык, кеше ишетмәсен дигәндәй, аяк очына куркып кына басып «мунча биюе»нә калганмыни?!

Фламенко...

Диңгезле, таулы, чәчәкле Испаниянең хәрәкәттә чагылышы.

Әнә бит, бер карасаң, күбекләнеп торган затлы күлмәк итәкләрен тавис койрыгыдай сузып, икенче карасаң, авыр, бөтерелмә итәкләрен диңгез дулкыныдай шаулатып кызлар бии. Утлы карашлар, төсле авазлар... Бу атаклы мавритан стилендәге фламенко биюе каршында вакыт тез чүгә, дәверләр бөтерелеп кала.

Фламенко... мәңге истә калырлык сокландыргыч бию. Африка һәм Европа рухы кушылган кыргый давылның кеше дәрәҗәсенә төшеп сәнгатькә әверелүе.

Хуш, Гранада!

Андалузиянең кайчандыр мөселман йөрәге типкән башкаласы. Һәрчак җиренң бай, күгеңдә Ай булсын!

* * *

Толедо — күк астындагы бик борынгы шәһәр-музей, Кастилия Ла-Манча автоном өлкәсенең үзәге. VI—VIII гасырларда вестготлар, XVI гасырда исә берләшкән Испания башкаласы булган.

Мадридка якын гына урнашкан бу шәһәрдә мәңгелек һәм мизгел төшенчәләрен карт диварлар сулышыннан сизәсең. Монда заманында нинди генә халыклар, бер бөтерелеп алып, гасырларны авызлыкламаган да, мәңгелеккә табына-табына, онытылырга дучар ителмәгән.

Тамаша кылабыз: кызгылт көрән җирләр, кызгылт көрән диварлар... Менә ул — римлеләр төзегән цирк бинасының җимерекләре... Триумфаль капка, Алькасар замогы... VI гасырда төзелгән Санто-Кристо де ла Лус чиркәве, X гасырда аны гарәпләр мәчеткә әйләндерәләр, XII гасырдан — яңадан чиркәү...

Мәйдан түрендәге Санто-Доминго әл-Антигуо чиркәвенә кергәч, мәшһүр рәссам Эль Грекоының бинигһая зур картинасы каршында тынсыз калып басып торабыз. «Маркиз Оргасны җирләү» дип исемләнгән бу картинада Эль Греко үзе дә, Сервантес кебек бөекләр дә сурәтләнгән. Өстән, күк катларыннан төшеп килүче канатлы фәрештәләр арасында изге Мәрьям ана балкып утыра. Дини эчтәлекле картиналарында Эль Греко Мәрьям ана сурәтен үзенең хатынынан карап ясаган.

Бер читтә Эль Греко картиналарының киндергә ясалган нәни күчермәләре сатыла икән. Мин кайсын алырга белмичә сайланам-сайланам да, нәкъ менә шушы мәһабәт картина күчермәсенә тукталып, кесәмнән бумажнигымны чыгарам.

Шул чак безне кабул иткән «Мундитур» фирмасының вәкиле Солидад ханым, елмаеп, кулымнан тота, мин аңышканчы, әлеге картина күчермәсен сатып алып миңа бүләк итә.

Мадридта беренче танышкан көнне Солидад ханым минем татар икәнемне белгәч, бик аптырап калган иде. Татарларны ул мөгезле дип уйлаган ахрысы. Киресенчә, Европада Тевтон ордены рыцарьлары мөгезле каска киеп дөньяны куркытырга уйлаган лабаса...

Тәрҗемәче Лина ханым ярдәмендә сөйләшеп торган арада мин Солидад ханымга Казанның затлы папиросын — «Алтын чәч»не бүләк итәм. Сигаретка гына күнеккән ханым папиросның кайсы башыннан кабарга белми аптырый.

Икенче көнне ул кызының фотоларын алып килеп миңа күрсәтте. Кызы университет студенты икән. Моны күреп торган Аяз агага шаяртырга җитә калды:

— Слушай-парин, синең Мадрид кияве булып калырга бөтен мөмкинлегең бар. Күрәсеңме, Солидад ханым гел тирәңдә бөтерелә.

Алтмыш-сиксән яшьлекләр арасында, группада иң яшь кеше булу рәхәт икән шул. Гел игътибар үзәгендә буласың. Әмма яшьлекнең кадерен аңлау соңлап килә, соңлап, каһәр төшкере!

Толедода сәяхәтебез дәвам итә. Менә без Эль Греконың музей йортында. Берничә зур-зур бүлмәле, бер катлы йорт. Идәнендә келәмнәр дә булса, Сәмәркандтагы үзбәк һәм таҗик классигы Садретдин Айни йортына охшаган дияр идем. Бер бүлмәдә идәннән түшәмгә кадәр урын алган сәер картина каршында тукталабыз. Моны Эль Греконың дус рәссамы бүләк иткән булган. Бала һәм сакаллы ике ир сурәтләнгән бу картинаның сәерлеге нәрсәдә соң? Хикмәт шунда: игътибар беләнрәк карый торгач, сакаллы ирләрнең берсе хатын-кыз икәнлеге аңлашыла башлый. Тел белән аңлата алмаганга күрә, рәссам аның изүен ачып, йомры имиен сурәтләгән. Тормышта булган хәл икән бу. Бала тудырганнан соң әлеге хатынның кинәт кенә сакалы үсә башлый. Ярлы гаилә нишләсен, бу фаҗигадән чарасыз калмый, ә табыш алырга була. Шулай итеп, ире Феликс гөнҗәлә сакаллы хатынын шәһәрдән-шәһәргә, авылдан-авылга кешеләргә күрсәтеп йөреп акча җыярга мәҗбүр була. Гид «Феликс» диюгә, без Мәскәү профессоры, сакаллы Феликс Кузнецовка елмаешып карап куйдык һәм картинадагы сурәт белән охшашлык тапкандай булдык...

Эль Греко рәсемнәрендә кешеләр галәмәт озын буйлы, зифа гәүдәле итеп сурәтләнгәннәр. Руханилар нәкъ менә шуның өчен, табигый түгел дип, аның картиналарын кабул итмәскә тырышканнар.

Эль Греко иҗатының мәһабәтлегенә сокланмый мөмкин түгел. Ул сурәтләгән кешеләрнең гәүдәсендә үк яшәүгә кодрәт, көчле рух сизелә, юк, сизелеп кенә калмый, тәэсир итә, йөрәк тибешенә күчә, киерелеп, үз-үзеңнән ыргыласы, биеккә сикерәсе килә башлый. Сәнгатьнең илаһи сихере! Бәлки испан милләте шушы мәһабәт картиналардан рух-тылсым алып бер башка үсеп киткәндер...

Толедоның урамнары бик тар, лабиринт кебек, әз генә игътибарыңны читкә юнәлттеңме — адашасың. Шома диңгез ташлары түшәлгән бу урамнардан узган гасырларда алпарлар (рыцарьлар) йөргән. Имеш, яудан хәлсезләнеп, яраланып кайткан рыцарь бер кулы белән бер як стенага, икенче кылычлы кулы белән икенче як стенага тотынып өенә кайта торган булган. Менә ни өчен тар итеп эшләнгән икән урамнар (моны шагыйрьләр уйлап чыгаргандыр мөгаен). Менә шул мәңгелек ташны шпоралары белән чыкылдатып очкыннар чәчрәтеп рыцарьлар үткән урамнан икәү — берсе Зәй, икенчесе Стәрле буенда туып, казылык

ашап үскән ике татар рәхәтләнеп, кычкырып үзебезчә сөйләшеп барабыз. Испаниядә татар һәм рус телләре тигез хокукта, чөнки бу ике телне монда берәү дә белми.

Шулай иркенләп сөйләшә-сөйләшә затлы сувенирлар тезелгән кибеткә килеп керәбез. Безнең илдәге министрларга охшаганрак рәвешле сатучы, елмаеп, безгә баш кага, чит ил кешеләре икәнебезне чамалап:

— Сез Англиядәнме? — дип сорау бирә.

— Ноу,— ди Аяз ага.

— Франциядәнме?

Юк, дигәнне аңлатып баш селкибез.

— Италиядәнме?

Мин шул чак Аяз агага төртәм, Монголиягә таба китеп барганчы әйтеп калыйк, дим, алгарак чыгам да, тавышыма горурлык төсмере биреп:

— Унион советика,— дим.

— О-о, рус, рус! — ди кибет хуҗасы.

Аяз ага түзми, мине этебрәк алга чыга да, күкрәген төеп:

— Юк, без — татарлар! Татар, аңлыйсыңмы — та-тар!

— Тар-тар...— хуҗа кеше куркынган кебек күзләрен зур ачып, муены тирәли элмәк ясап, дарга асылган рәвеш чыгара.

— Ах капиталист! Бездән көлгән буласыңмы! Анаңның кабер тактасын уңнан санаганда өченчесен каерып алып... Кадак тишегеН кинәйтеп...

Аяз аганың сүгенүенә каршы «капиталист» баш кага-кага елмая. Юктан да кинәт үзлегеннән кабынып китә торган гадәтле Аяз ага чын-чынлап туарылмасын тагын дип мин аны тынычландырырга ашыгам:

— Сөен син, Аяз ага, беләләр бит! Татар, дигәч, андый халык турында ишеткәнем юк, дисәләр ни эшләр идең? Безне, димәк, рус тарихы аша беләләр. Элек бит Европа русны да татар дип белгән. Үзен аерым милләт итеп күрсәтү өчен аңа нәрсә кала? Татарга яла ягып, каралтып, ялган тарих язарга мәҗбүр булган. Аның да хәлен аңларга кирәк. Монголмы сез, дисәләр — без дә бит әйе, дия алмыйбыз.

* * *

Урта диңгез буйларыннан сәяхәт кылып янә Мадридка кайтып кердек. Безне дүрт йолдызлы «Веласкес» кунакханәсенә урнаштырдылар. Мәрмәр колонналар, мәрмәр диварлар. Мондый да куе, җете төсләргә бай мәрмәрне күргәнем юк иде әле. Әкияти бизәкләреннән күз камаша. Җир яратылышыннан алып бөек шартлаулар, ут һәм су аркасында нинди катаклизмнар булган — шулар эзе каты токымга, вакыт үзе генә аңларлык телдә, төсле сурәтләр белән язылып мәрмәргә әверелгәннәр.

Һотельның киң баскычыннан күтәрелгәндә үк сине һәртөрле скульптуралар, вазалар, картиналар каршы ала — музей диярсең.

Бүлмәмне ачып кына кергән идем, телефон чылтырады. Ашыгып барып алган булам.

— Совет илчелегеме бу?

Тәрҗемәчебез Линаның тавышын танып көлеп җибәрәм. Баксаң, минем бүлмә номеры белән илчелекнеке бер үк диярлек икән, соңгы санында гына аерма бар.

Исем китеп ванна, туалет бүлмәсен карап йөрим. Мондагы купшылык, мондагы затлылык — үз күзләремә ышанмыйча, әле бер кранга, әле икенчесенә тотынам, чынмы бу, минме бу? — дип көзгегә карап куям. Ул елларда евроремонт, чит ил җиһазлары дигәнне төштә дә күрә алмый идек, андый хозурлыкка бары тик Мәскәү Кремленең партия бүреләре

гена ирешсә ирешкәндер. Унитаз турында, стенада берничә ялтыравык кнопка тора, шуның берсенә баскан идем, ишектән атылып-бәрелеп чегәнгә охшаган ханым килеп керде. Испаннар татар авылы хатыннары кебек, шүредән борчак сипкәндәй, үтә кызу сөйлиләр, теле телгә йокмый моның. Икебез ике телдә аңлаштык ахырда: мин ярдәмгә чакыра торган кнопкага басканмын икән...

Тиз генә юынып, киемне алыштырдым да,— йөрәк түзми,— Мадрид урамына чыгып киттем. Тизрәк шәһәрнең үзәген күрәсе килә.

Муниципалитет бинасы грекларның антик чорда салган Парфенон сараена охшаган — саллы колонналардан гына тора. Бина каршында да, урамның теге якларында да кечкенә автобусларда кыска автоматлы хәрбиләр утыра. Аллага шөкер, бездә мондый хәл юк, тыныч, хәвефсез илдә яшибез икән, дип эчтән горурланып куйдым. Күп булса, ун ел үтәр дә, Мәскәүдә чуалышлар башланып, «Ак йортка» автоматлардан гына түгел, танк пушкаларыннан атачаклар әле дигән кешене акыллыга санаучы булмас иде ул чакта.

Муниципалитет янында хәрби сак торуының сәбәбе бик гади: монда өч ай элек кенә хәтәр вакыйгалар булып узган. Шул шаукымнан Мадрид әле суынып кына киләдер мөгаен.

Конгресс депутатларының утырышы вакытында (1981 елның 23 феврале) ишекләрне киереп ачып, сакны бер якка бәреп ташлап, пистолет, автомат, пулемет тоткан жандармнар бәреп керә. Җәмгысы өч йөзгә якын хәрби. Боларның башлыгы Антонио Техеро Молина дигән подполковник була. Куркыту өчен түшәмгә каратып, берничә мәртәбә атканнан соң болар депутатларны идәнгә яткырып куялар да Молина мөнбәргә чыга, Испаниядә гражданнар хакимлеге бәреп төшерелде, шушы минуттан ил белән идарә итү хәрбиләр кулына күчә, дип белдерә. Бу минутта Мадридны чолгап аласы танк дивизияләре, башка төр частьлар приказ гына көтеп торалар. Әмма кайбер генералларның икеләнеп калуы, хәрби кием киеп алган король Хуан Карлосның тәвәккәл адымы баш күтәрүчеләрне таркатып, бирелергә мәҗбүр итә.

Аюлы фонтан торган түгәрәк мәйданнан, нурлар кебек, төрле якка урамнар кереп китә. Шушы мәйданны гына тамаша кылам да кире борылам, дип мин бөтенләй кире якка китеп барганмын. Байлар урамы, супермаркетлар башлангач кына мин шаулы шәһәр урамында берьялгызым адашып калганымны аңладым. Ничек аңлашырга? Тел белмим. Кесәдә бер документ та юк дисәм... Кунакханәнең визиткасы бар икән! Әгәр мине тотып алып, Испаниядә кал, иленнән ваз кич дип, мәҗбүр итсәләр... Кинәт тыным кысыла, әти-әнине, дус-ишләремне, уйнап үскән кыр-тугайларымны бүтән беркайчан да күрү насыйп булмаячагын күз алдыма китергәч, тормышымның утыз дүрт еллык катламы булмаган да кебек убылып төшә, һәм мин, чит дөнья уртасында япа-ялгызым басып каламмы? Бөтенесен яңадан башлау мөмкинме? Бөтен тәнне кызыштыра башлаган бу коточкыч уйдан мин тизрәк арынырга тырышам, кемгә кирәгең бар синең монда? Кем алып калсын сине! Андагы университет белемең... монда ашханәдә савыт-саба юарга да ярамый ич!.. Үземне шулай мыскыл итә-итә юатып барам. Рудольф Нуриев ничек Франциядә кала алды икән? Ул — башка... Поезда туган. Бәләкәйдән үк күченеп йөргән. Аның рухы береккән тамырлары юк. Без татарлар, яһүдиләр кебек үзебезне дөньяви кавем итеп тоя алмыйбыз, җир йөзенең кай ноктасында да тернәкләнеп китәрлек мөмкинлегебез юк. Без артык хисчән, җирсү дигән тойгыга бирелүчән, тугрылыкка хыянәт итми торган халык.

Туктатып, берничә кешедән «Веласкес» һотеле кайсы якта?» дип сорап карадым, берни аңламыйлар, күрәсең мин «Веласкес» дигән сүзне татарчарак итеп әйтәмдер. Аптырагач, бер полисменга барып визиткамны суздым, русча эндәшкән булам, бездә теләсә нинди эткә русча эндәшеп аңлашуга күнегелгән. Полисмен мине караңгы тәрәзәле бинага

алып кереп китте. Визиткамны икенче полисменга күрсәтеп нидер сөйләштеләр дә, урамга алып чыгып, кай тарафка таба барырга икәнен күрсәттеләр. Шулай итеп мин зур-зур мәйданнарны урап чыга-чыга ике сәгать ярымда кунакханәгә кайтып егылдым.

«Мадрид сараеның серләре» дигән әйтем дөньяга таралган урынны — корольләр сараен да тамаша кылу бәхетенә ирештек. Әлбәттә, мондагы ике мең залны карап чыгу мөмкин хәл түгел, аның өчен кимендә король булу кирәктер. Истә калганнары — ике йөз илле кешелек банкет залы, илчеләр кабул итү һәм тәхет заллары, менә ничек була икән бүгенге көннең король тәхете... биектә, янәшә куелган озын аркалы кушпы кәнәфиләргә Хуан Карлос, хатыны королева София барельефы ясалган. Тәхетне ике яклап мәрмәр арысланнар саклый.

Сарай залларындагы зиннәт, затлылыкка исең китәрлек. Идән, түшәм-диварлар әкияти сәнгатькә төренгән. Король сарае — испан халкының милли байлыгы; дәүләтле илнең хәтере, горурлыгы, узганы һәм киләчәге. Санкт-Петербургтагы рус патшаларының Кышкы сарае, Петергоф һәм Павел сарайлары да шундый ук мәгънәгә ия. 1941—1945 елгы сугышта шартлатылып, тәмам җимерелеп беткән Петергоф һәм Павел сарайларын дистә еллар буена ташын ташка, бизәген бизәккә бик җентекләп сәнгать осталарының яңадан коруы, моңа шауламыйча гына фантастик суммалар тотылу юкка түгелдер. Чөнки бу байлыклар рус милләтенең дәүләтчелек символы, менә без кем! дигән мактанычы, гасырлар көзгесе.

Мадридның король сарае музей, тамаша кыла торган урын гына түгел, монда бүгенге көндә дә казна эше бара. Ләкин, шуңа да карамастан, билет алып эчкә керү бик җиңел хәл ителә. Мәскәү кремлендәге кебек сер-сагаюга корылмаган. Ишегалдында ыспай киемле хәрбиләр күренә, алар күбесенчә, борынгыдан килгән корольлек ритуалын гына чагылдырып торалар шикелле.

Һич онытасым юк, 1976 елда яшь язучыларның бөтенсоюз семинарында катнашкан без яшьләрне Мәскәү кремленә алып барганнар иде. Шактый мәрәкәле тикшерү-барлауларны узганнан соң, ишек төбендәге хәрбиләр әле паспортка, әле чырайга текәлгән хакими-тимер карашыннан энә күзе аша чыгып, Ленинның фәкыйрь, әмма истәлекле эш кабинетын карарга кергән идек. Янәшәдәге фатирында иске одеал ябылган караватын, кухнядагы калай кружкаларын да күрсәттеләр. Ышаныгыз. Менә ничек гади яшәгән безнең Ильич, имеш. Соңрак, Ленинның чит илдән әнисенә язган хатларын укыгач, мин шаккаткан идем. Без төштә дә күрмәгән нигъмәтләр салынган посылкалар алып, банклар талап җыелган партия акчасына кәеф-сафа кылып, мебельле фатирлар алыштырып, илдән-илгә күченеп, йончу Россиягә кайтырга чирканып, Европаның иң мәртәбәле башкалаларында унбиш еллап кинәнеп яшәгән икән безнең «бөек юлбашчыбыз».

Ничә буын испан корольләрен күргән мәшһүр сарайның вестибюлендә Хуан Карлосның плакатлары сатыла иде. Хәрби киемнән, смокингтан, костюмнан. Чибәр, яшь, озын буйлы. Безнең Айрат Арслановка тартымрак. Мәскәүлеләр, дәррәү кубып, Хуан Карлосның сурәтен сатып ала башладылар. Аяз ага белән минем генә ис китми. Димәк... Испаниянең дә корольләр династиясе яһүдиләргә барып тоташа... Бу фикеремне Аяз агага әйткәч, ул, гадәтенчә, өч төрле мәгънә салып елмайды да: «Син башкача уйлый идеңмени...» — дип куйды.

Без әнә шулай король «тоягы» эзләренә басып йөргәнгә өч ел үтте микән, Хуан Карлос үзенең хатыны гречанка София белән СССРга визит ясады. Мин ул чакта Мәскәүдә Максим Горький исемендәге әдәбият институтының Югары курсларында укый идем. Илнең төрле тарафыннан килгән, төрле милләттән утыз өч кеше без. Олы вакыйга булган көннәрдә кичен «кызыл почмакка» телевизор карарга җыелышып тыгызланабыз. Менә экранда — Испан королен каршы алу мәрәкәсе. Эскорт. Кремль

ишегалдында фотога төшү мизгеле. Протокол кушканча, КПСС генераль секретаре Черненко да, бахыр, үзенең хатынын алып чыккан. Яшь, горур, мәһабәт Хуан Карлос кырыенда муен һәм бил бөгелешләрен күптән оныткан, тоташ мул гәүдәдән генә торган Черненко хатыны басты. Кыяфәте белән карт чукчаны хәтерләткән Черненко янәшәсендә эре борчак төшкән бөтерелмә итәкле, биек үкчәле туфлиләрдән, нечкә билле София тора. Бу күренештән көлеп җибәрмәс өчен авызны учка яшердек. Бер-беребезгә карамаска тырышабыз. Шул вакыт... Шолоховның якташы, Ростов-Дон егете, шагыйрь Игорь Кудрявцев ярып салды:

— За державу стыдно...

Хуан Карлос генералиссимус Франкога туганлык җепләре белән тоташа. Без Испаниянең дәүләт җитәкчесе, каудильо Франсиско Баамонда Франко (1892 елда туган) хакында үз илебездәге рәсми мәгълүмат әйткәнгә ышанып, һәр сүзне җим көтеп авызын ачып утырган сары томшыклы кош баласы кебек кабул итәргә күнеккәнбез. Ә испан халкы өчен ул утыз биш ел тәхеттә утырган ил хуҗасы. Ихтимал, хаталары да күп булгандыр. Мин испан тарихын махсус өйрәнгән кеше түгел, әмма шуны ачык тоям: 1936—1939 еллардагы чуалышта Франко каты кулына дилбегәне алмаган булса, төрле милләткә, төрле партиягә таркалган Испания җирлегендә кан коеш коточкыч хәлләргә китергән булыр иде.

Кемнең кем икәнен, гадәттә, җеназасын соңгы юлга озатканда беленә. Авылдагы көтүчедән башлап, ил иярендә утырган хакимгә кадәр шулай: соңгы юлга озатырга сине кемнәр, күпмеләр килә...

Франконың табутын озатучы халык (1975 елның 23 ноябрендә) Орьенте мәйданыннан башлап, һәлак булганнар үзәнендәге төрбә-мавзолейга кадәрге арада илле чакрымга сузыла. Каудильоның табутын кабергә төшереп, өстен тоннаярым авырлыгындагы плитә белән каплаганнан соң, собор каршында йөз мең егет, рәт-рәт басып, «Франко безнең белән!» дип кычкыралар һәм бертавыштан «Кояшка йөз белән» дигән фалангачылар гимнын җырлыйлар.

* * *

Испания — бөек рәссамнар иле. Аның табигате, кайнар тарихы үзе үк төсле җыр сорап тора. Дини храмнарына кадәр картиналар белән бизәлүе дә юкка түгелдер. Мадридның Прадо музеена кергәч, мин әлеге фикеремә икеләтә ышандым. Моңа кадәр Эрмитажда, рус һәм Пушкин музеенда, Третьяковкада булганым бар иде. Алардагы картиналар байлыгына сокланып, бу өлкәдә үзебезнең милли ярлылыкка эчтән әрнеп йөргән идем. Бәләкәй күләмле картиналар, гадәттә, кечкенә бүлмәдә матур күренә. Зур залларда исә зур күләмле картиналар үзенә тартып тора. Мин онытылып, «Христосның халыкка килүе» (Александр Иванов), «Помпейның соңгы көне» (Карл Брюллов), «Иван Грозный һәм аның улы Иван» (Илья Репин), «Сугыш апофеозы» (Василий Верещагин) кебек картиналар каршында озаклап басып торганым бар.

Прадо музее бөтенләй башка икән. Чагыштырулар көчсез. Зурзур заллардагы картиналарның күплегенә, мәһабәтлегенә хәйран каласың. Күңел үрсәләнә. Акыл тез чүгә. Боларны кемдер кул белән ясаган бит дип уйлыйсы килми, дөнья күренешләре гүя Ходай сулышы ярдәмендә киндергә сеңдерелгән. Дини, тарихи вакыйгалар, бакый җиһанның кеше аңыннан өстен серләре илаһи төсләрдә моң булып өртелгән.

Итальян, нидерланд, фламанд осталарының шедеврлары... Веласкес, Ван Гог, Эль Греко, Пикассо әсәрләре...

Нәгыйшь сәнгатенең бөеклегенә, Күк иясенең аерым тамгасы белән туган галиҗанәб рәссамнарның кешелеккә икенче гомер иңдерә алучы гали затлар икәненә мин, ниһаять, шушында төшендем. Әгәр син Прадо музеендагы картиналарны җентекләп, бөтен мәгънәви тирәнлегенә төше-

неп, шулар эчендә яшәп чыга аласың икән, алдагы гомереңнен инде кирәге калмас сыман. Әмма, безгә бирелгән сәгать ярым эчендә мондый хәтәр бәхеткә ирешү мөмкин фал түгел иде. Безне озатып йөрүче гид бер картина каршында гына да ярты сәгать сөйли. Димәк, җәмгысы биш әсәр карарга өлгерәчәкбез.

Мин икенче, тагын да өметсезрәк юлны сайладым, йөгертеп кенә бөтен залларны карап үттем дә тизрәк музейдан чыгып китәргә ашыктым. Йөрәк кага. Картиналарның тәэсире, нурланышы шулкадәр көчле ахрысы, алар сине үз упкынына тартып алырлар шикелле...

Баскычка чыктым да тәмәке кабыздым. Янәшәдә генә кыска автомат тоткан сакчы йөренә. Студент чактагы бер егетнең шигыре искә төште: «Утырам, тартам, тартам да тартам гына. Мин мескен татар гына...»

Үзебезнең рәссамнарның (1981 ел!) арзанлы кантар-кантар буяу сылап эшләнгән картиналарын күз алдыма китерәм дә... Җан тарыга башлый. Кешене битараф, ваемсыз халәткә төшерә торган сурәтләр. Европа бөекләре каршында безнең рәссамнар буяулы пумала белән уйнап утырган маймыл халәтендә түгелме?!

Эш аты сурәтләүдән ерак китә алмаган, мескенәйтелгән сәнгатьле, әдәбиятлы халыкның улы икәнеңне белү — котылгысыз йөрәк ярасы. Моның ахыры булырмы, уяныр6ызмы, аягүрә баса алырбызмы? — дигән сорау күңел төпкелендә сулкылдый.

Әгәр безнең шанлы, бай, гыйбрәтле тарихыбызны шушындый олуг картиналарда чагылдырсаң, дөньяда чагыштырып карар тиңнәр табылмас иде мөгаен. Милли рух кечкенә күләмле сурәтләргә бөкрәеп сыя алмый шул, аңа киңлек-иркенлек, тирәнлек, вакытны гасырлар учына кыскан кодрәт кирәк. Халкыбызның киң ябалдашлы гомер шәҗәрәагачы төбендә моңа җирлек-мәйдан бар. Төрле милләтләргә таркалган төрки галәменең фәлсәфә ташы — татар куенында югыйсә...

Шулай уйлана-уйлана Прадо музееның биек баскычында, группаның чыкканын көтеп, туктаусыз тәмәке төтәтәм. Өметсезлектән күзгә яшь килә. Илаһи төсләр, дөньяви хис чолганышында, — аз гына микъдарда алсам да, — тетрәнеп чыктым да... сәнгать кыясы каршында тузан бөртегенә әйләнгән җан менә хәзер чарасыз бәргәләнә, таяныч эзли, күңел төбеннән күтәрелгән әрнүле яшь кайнарлыгы тәмәке төтененә кушылып, Мадрид һавасына тарала.

Еллар үткәч, үземне изалап, борчып йөргән сорауны мин сынап карар өчен Аяз агага бирермен:

— Алласыз һәм тарихсыз проза вәкиле булу Сезне куркытмыймы?

— Менә мин «Йөгез, бер дога!» дигән әсәремне тәгәлләдем. Анда сүз кырык ел элек булган вакыйгалар турында бара. Үткәнемә һәм тарихка хилафлык кылмыйча, үзем кабул иткән дөреслекне сурәтләргә омтылдым, — дияр ул.

Аяз ага соравымны тарайтыбрак кабул итте. Мин һәркем тарихи әсәрләр язарга тотынырга тиеш дип санамыйм. Аннары... большевиклар һәр үткән көнгә тарихи дип мөһер сугарга безне күнектереп бетерделәр. Чын тарихның кан тибешеерактарак, тирәндәрәк бугай шул...

Хикмәт башкада... Татар сандугачы белән испан сандугачының сайравында аерма бар. Берсе — зәйтүн куаклары аша, икенчесе — таллар аша ишетелә.

Ерак бабаңның яуда кылыч очы яралаган урыны синең тәнеңдә вакыт-вакыт сулкылдап куямы?

Догасыз булсаң да, бер-бер гөнаһ кылыр алдыннан күңелеңдәге үзаллаң кулыңнан тотамы һәм син, оялып, күккә багасыңмы?

Юк, мин Аллага табыну, тарихны турыдан-туры язу хакында әйтмим. Һәр сүз сөрешендә, һәр сурәтләүдә тарих дымын, тарих исен-төсен сирпелдереп, Күк һәм җир арасында мәртәбәле гасырлар кичкән олуг тарихлы халыкның тарихлы улы булу хакында иде сүз...

* * *

Менә без Мадридның Испания мәйданында Сервантеска куелган мәһабәт һәйкәл янында басып торабыз. Мигель де Сааведра Сервантес — испан милләтенең йөзек кашы. Һәйкәле дә әнә ничек сәнгатьле итеп куелган. Гасырлар кичеп тә үткенлеген җуймаган кешелек романы язган әдип биектә уйланып утыра. Астарак каһарманнары: Дон Кихот — атта, Санча Пансо — ишәккә атланганнар. Боларны язучы уйлап чыгарган, тормышта булмаган, дип испан халкын ышандырып кара хәзер.

— Бездә мондый һәйкәл куела алмый, — дигән идем, Аяз ага, кызып, фикерләрен актарып ташлады:

— Романнардан үз аягы белән чыгып, халык күңеленә күчкән геройларыбыз кая? Шерлок Холмс, Квазимодо, Обломов кебек геройларыбыз бармы? Конан Дойль әнә үзе уйлап тапкан Шерлок Холмсның үлеме турында хикәя язгач, Англия королевасы бер атналык траур игълан итә. Язучы Шерлок Холмсны яңадан терелтергә мәҗбүр була... Без бит, үзебез тудырудан битәр, тормышта яшәп киткән әзер геройлар итәгенә тотынып язарга яратабыз!

Кичкырын, кунакханәгә кайтып барганда Аяз ага сабыр-салмак кына янә шул хакта сүз башлады:

— Сервантес туганга да дүрт йөз елдан артып киткән бит инде. Испаннар өчен җиңүләр гасыры, ә безнең коллыкка төшү дәверләре. Латин Америкасының унтугыз иленә рәсми испан телен таккан милләт булыр ул... Әдәбияты да карт, олпат әдәбият. Аларны куып җитү өчен безнең запаста тагын өч йөз ел бар әле... Шаяртам, әлбәттә. Безгә ашыгырга кирәк. Дөнья халыклары арасында билгесез булып, тапталып калмас өчен! Әгәр без бер телле, оешкан, булдыклы милләт булсак, күптән инде... Карамзиннар, Державиннар, Куприннарыбыз читкә китмичә, үзебездән калыккан булыр иде...

* * *

Кайчандыр гарәпләр Мансанарес елгасы буенда Мәҗирит кальгасы төзегән булганнар. 1083 елда бу кальга испаннар тарафыннан яулап алына. Һәм шул урында Мадрид каласы төзелә башлый. Менә шул озын гомерле, чал башкала белән танышуыбызның соңы да җитте. Кичен саубуллашу банкеты һотельның ресторан залында булды.

Ашау-эчү, шау-шу. Каршыдагы телевизор экранында коррида бара. Йөзмеңнәрчә кешелек стадион күз уңын тореадорга, алтын белән чигелгән ыспай киемле мәйдан батырына төбәгән. Стадион гүли, үкерә, кайный. Мәрмәр маңгайлы кара үгез аның саен ярсый, җитмәсә, бандерильеролар аренага йөгереп чыгып, төсле тасмалы кечкенә сөңгеләрен үгез сыртына кадый торалар. Кан күреп, акылдан шашкан стадион бер-берсен таптап, укмашып бетәр шикелле.

Коррида — испаннарның милли тамашасы, пар чыгару мәйданы. Революциягә кадәр Казанда урыслар һәм татарлар Кабан күле бозында йодрык сугышы оештырып шулай пар чыгара торган булалар.

Аяз ага белән янәшә утырабыз. Мул яшелчәле ризык тәлинкәләре бер-бер артлы алышына тора. Менә мин гәрәбә кебек сап-сары дөге арасында яткан диңгез кабырчыкларын ачам да... эчендәге лайлага чәнечкемне батырырга чирканып торам. Аяз ага көлә, ашау ягына килгәндә ул — гурман. Ризык турында сөйли башласа, ашказаны бизләреңне котыртып, тәкатьсез калдыра, баш миеңә кан йөгерергә мөмкин.

— Син аны, слушай-парин, тиз генә кабып йот та артыннан сыра эчеп куй. Устрица — деликатес, кайчан әләгә ул сиңа. Бәрәңге корсаклы илгә кайтасыңны онытма!

Мин тәвәккәллим. Әйтерсең лә авылда шушындый нәрсә ашап үскәнмен.

— Ике көннән безнең «Татарстан» поездын нәшрият директоры Гарәф абыең каршы алачак. Сөйләшенгән. Мәскәүдән аңа әрмән коньягы алырбыз, — ди Аяз ага.

— Мадрид сырасы алыйк. Шешәсе бик матур, сувенир кебек бит. Бездәге яшел төстәге аңгыра шешә түгел.

— Кесәңдә сукыр бер тиен акчаң калмаган. Өлешеңә биргәнне эчеп бетердең. Хыял синдә, слушай-парин...

— Хәзер эшлибез аны, Аяз ага. Акчага җүләр дә ала аны... — дигән булам. Безнең өстәлне җиһазлаучы метрдотель бер читтәрәк күз кырые белән генә һәр хәрәкәтебезне карап-күзәтеп тора. Бармакны изәүгә, ук кебек атылып килеп җитте егетебез. Мин аңа бер фужер аракы салып бирәм. «Рашен водка!» — дип баш бармагымны чөям. Шул вакыт экранда мәхшәр куба: тореадор бишенче үгезне нәкъ вакытында (ун минут дигәндә) сәнгатьле итеп аудара. Шуның хөрмәтенә эчеп куярга тәкъдим итәм. Метрдотель, елмаеп, иренен генә тидереп куя, әлегә эш вакыты, соңыннан эчәрмен, дигәнне аңлатып фужерны үзе белән алып китә.

— Менә хәзер бу капиталист — минеке... Бераз гына сабыр итик тә, — дигән булам Аяз агага. Ул, карап-карыйк, дигән сыман рәхәт елмаеп утыра.

Тореадор (испанча: матадор яисә тореро) аренада җиденче, соңгы үгезне хәл иткәндә мин тагын бармакны изим. Метрдотель бармак юнәлешендә, җепкә тартылган кебек килеп җитә. Буш сыра шешәсенә күрсәтеп:

— Москау, сувенир. Ача күрмә! Башыңны бетерәм. Убью, аңлыйсыңмы! — дим көлеп. Метрдотель бик матур сүз әйтә бу, дип уйлый ахрысы, бөгелә-бөгелә елмая. Тел белмәү дә шәп кайчагында: син сүгенәсең, сиңа елмаялар.

Метрдотель затлы шешәне китереп тоттыргач, Аяз ага тел шартлатып куйды.

— Да-а... Слушай-парин...

— Маркс«ның «Капитал»ын укырга кирәк, Аяз ага... — дип мин мактанып алам, гәрчә ул китапның ике-өч битеннән ары китәлмаган булсам да.

Банкеттан соң, төнге уникеләрдә шагыйрә Маргарита Ногтева, Федор Семенович Наркирьер һәм мин шәһәргә чыгып киттек. Урамда кешеләр талгынайган. Бар-кафелар эшләп тора. Безнең кәеф шәп. Төнге шәһәр һич тә куркытмый. «Ник тудым» чырайлы кешеләр очрамый. Мин кычкырып җырлап барам.

— Табигать баласы син, Марсель, — дип куя Наркирьер. Аның бүгенге хыялы — безгә кайчандыр Эрнст Хемингуэй яшәгән кунакханәне күрсәтү.

Биш йолдызлы бу һотельның ишек төбендә смокинг кигән ике чибәр ир-егет безне каршы алып, эчкә озатып куйдылар. Эчтә калын келәмнәр җәелгән зур залның пыяла ишеге төбендә順 торучылар Маргарита ханымны үткәргәннән соң, мине туктатып калдылар. Ул арада Наркирьер плащын беләгемә салып, тегеләргә нидер әйтте дә эчкә кереп китте. Мин, бернинди тупаслык кылмыйча, елмаеп кына шулай эчкә үткәрмәүләренә аптырап басып калдым.

Соңыннан, чыгып киткәндә барыбызга да һотельның бик матур бизәлгән китапчыгын бүләк иттеләр. Наркирьер моңа балаларча куанды. «Хемингуэй яшәгән һотель бит бу! Аның янына Илья Эренбург килеп йөргән...»

— Ә сине ни өчен эчке залга кертмәгәннәрен аңладыңмы? Чөнки син галстуксыз идең. Аптырагач, минем хезмәтчем дип, сиңа плащны тоттырып калдырдым.

— Хикмәт галстукта түгел, Федор Семенович...

— Ә нәрсәдә?

— Татар икәнемне белделәр. Революциягә кадәр Казанда «Татарлар һәм этләр кертелми» дигән язулы парклар булган. Менә монда да татар икәнемне сизеп алдылар.

Наркирьер, эчен тотып, сабыйларча көлә башлады.

— Булмас ла. Арттырасың...

— Чынлап... Татарларны ни өчен кертмәү сәбәбен әйтимме, Федор Семенович? Татарлар бит бик чиста, пөхтәлек яратучан халык. Парктагы шакшы-пычраклыкны күреп кәефләре бозылмасын дип кертмәгәннәр аларны урыслар.

— Ну ты, дитя природы,— дип Наркирьер көлеп алды да иңемә кулын салды:

— Марсель, син сөннәтләнгәнме?

— Әйе.

— Мин дә. Димәк, яһүд белән татар арасында борынгыдан килгән уртаклык бар. Кызганыч, мин татарча белмим.

— Кирәге чыкса, бик тиз өйрәнеп алыр идегез, Федор Семенович. Немецлар төрки әсирләрдән Идел-Урал легионы төзиләр бит әле. Муса Җәлил турында ишетеп беләсездер?

— Ишетеп кенә түгел, укып беләм!

— Менә шунда татар әсирләре бер яһүдне үз капеллаларына алып, исемен дә, милләтен дә татар итеп үзгәртеп саклап калалар. Җырларга да, сөйләшергә дә өйрәнә теге...

— Мәскәүдә очрашкач, Марсель, мин сиңа шундый нәрсәләр сөйләрмен әле...

(Соңыннан Наркирьерны Малеевка, Переделкино иҗат йортларында берничә тапкыр очраттым. Әмма мин уенчык холыклы, очынып йөрүче, бераз исәр Федор Семеновичны таный алмадым. Алыштырып куйганнар диярсең. Һава суларга чыккан чакларында беркем белән сөйләшми, бер ноктага текәлеп тора да тора, күзләре моңсу, сүнгән. Гүя аның җаны каядыр Испания киңлекләрендә адашып калган, монда бары кабыгы гына...)

— Җырлыйк әле, Федор Семенович, Маргарита ханым! Безнең татарлар, француз партизаннары белән немецларга каршы сугышып, заманында Парижны алганнар. Аккордеонда уйнап Париж урамын дер селкетеп, җырлап узганнар. Мадрид кына читтә калмасын!

Безгә рәхәт. Без — бәхетле. Төнге Мадрид. Өчәү җырлап барабыз. Таң беленеп килә...

* * *

— Хуш, Мадрид!

Оҗмах иле, Испания, купшы агач-куакларың, кояш зурлык чәчкәләрең туйдырды, тизрәк кайтып, үзебезнең каен урманнарында, абагалар арасына чалкан төшеп, агач ябалдашларының күк йөзен назлы кытыклап талгын җилдән тибрәнгәнен күрәсе килә.

Ниһаять, төрле төстәге, төрле телдәге милләтләр букетын төягән Боинг самолеты испан күгенә күтәрелде. Иллюминатор кырыенда Нәкыя апа, уртада Аяз ага, Кырыйда — мин, өч татар шулай янәшә урнаштык. Бераздан урындыкка беркетелгән өстәлләребезгә ризык китерделәр. Кара уылдыктан башлап шәрабка кадәр бар да җиту.

Күңел — фәрештәләр катында. Көчле тәэсирләрдән вакыт төшенчәсе сызылган, өйдән чыгып киткәнебезгә еллар үткәндер кебек. Без әле Мадрид янындагы Америка хәрби базасыннан нинди дер хәтәр чир таралганын да, шуңа күрә безне Мәскәү аэропортында табиплар каршы алып, «чикне» дүрт-биш сәгать чыгармыйча тикшерәчәкләрен дә, үзәк кунак-

ханә янында салкын күзле, шешенке чырайлы егетнең егерме тиен сорапталәп итеп торачагын да, төнге унбердә буш ресторанга төшкәч, керләнгән җәймәле өстәлгә «Менә шушы калды, ашагыз!» — дип бройлер тавыкны лаҗырайтып ташлаган тәмсез телле ханымнан чирканып чыгып китәчәгебезне дә, «Йә Хода, кая кайттык без?!» дип өметсез чынбарлыкка чарасыз кушылып китәсебезне дә уйламый идек әле. Кеше аңы тиз томалана икән, кайтып төшүебезгә бар да үзгәргәндер, якты чырайлы ил каршы алыр кебек иде югыйсә. Аннары... Тоталитар таш яңадан иңгә менеп кунаклар. Таныш таш... Безгә башны горур чөеп йөрергә базмыйча гомер буе шул ташны күтәреп йөрү хокукы бирелгән.

Самолет канаты астында Альп кыялары, серле упкыннар.

— Слушай-парин, бу мизгелне бүтән кабатлап булмый, кабатлап булмый моны, әйдә, күтәрик әле шуның өчен! — дип Аяз ага фужерын кулына ала. Чәкештерәбез. Икебезнең дә йөзләрдә сәбәпсез елмаю... Севильяда Аяз аганың миннән рәхәтләнеп, эчен тота-тота көлгәнен искә төшерәм. Мәйданда төрле илдән килгән йөзләрчә турист кайный, ә аяк киеме чистартучы малайлар, «шарманкаларын» асып, өерләре белән минем арттан йөриләр. Чебен куган кебек, чәбәләнә-чәбәләнә чак котылам үзләреннән. Аяз ага көлеп рәхәт чигә:

— Сине яраттылар болар. Бөтен кешедә чүпрәк туфли. Күн туфли, җитмәсә ясалма күннән — бөтен Испаниядә бер синдә генә. Интектермә, слушай-парин, эш бир малайларга!

Самолетта эчкән шәрабнең тәме башка... фәрештәләр үрелеп кенә бармагын тыгып ала күрәсең. Менә хәзер, хәмер канга тарала башлауга, үз чиратымда мин дә, Аяз агадан көләргә илһам җыям...

— Дөньяның җиде могҗизасы бар диләр бит әле, Аяз ага... Әйтик Мисыр пирамидалары, Семирамиданың асылмалы бакчалары, Галикарнас мавзолее... Без күргән хисар, әмирләр сарае Әлһәмра...

— Ул сигезенче могҗиза була инде,— дип бүлдерә мине Аяз ага.

— Юк... Сезнең өчен тугызынчысы, Аяз ага,— дигәч, аксакал, төшенеп бетмим, дигән шикелле миңа карап куя.

— Сез бит, Аяз ага! «Зәй энҗеләре» дигән әсәрегездә Зәйдә төзелеп яткан ГРЭСның төнге утларын күргәч, менә ул дөньяның сигезенче могҗизасы! дип язгансыз...

Аяз ага сүрән генә көлеп куйды, ыргылып торган борын өстендәге күзлеген төзәтте, йөзенә кызгылт рәшә сирпелде.

— Безнең Урта Баграж авылында Пауыл дигән бер карт булган. Аны армиягә дә алмаганнар, авылдан бер яры да чыкмаган. Шуннан бер заман моны Чаллыга ияртеп алып баралар. Элеватор тавына менеп бу Кама өстен күзәтә икән. Еракта Алабуга, куе урманлы ярлар күренә. «Болар да безнең патшалыкмы?» — дип сорый икән бу. «Безнеке, безнеке...» — дигәннәр авылдашлар. «Биләгән дә икән Рәчәй җирләрне!» — дип әйтә ди Пауыл. Шуның кебек... Мин кайда, ни күргән ул чакта. Юньлебашлы ат та җигә алмаган кеше каршында йөзләрчә машиналар, меңнәрчә утлар пәйда булсын әле... Әйткәнмендер инде, могҗиза дип тә ычкындырганмындыр. Кемгәдер ярарга да тырышканмындыр бәлки. Безнең әдәбиятның зур ялгышы — ул халыкка ярарга тырыша, аның алдында тез чүгә, үрмәли, вагая.

Еллар узгач, Аяз ага белән әдәбият турында сөйләшеп күңелдәге фикерләребезне барларбыз.

— Миргазиян Юныс татар әдәбияты турында хөкем чыгарганда моннан мең ел элек башланган Европа әдәбиятлары белән чагыштырып карый. Ә бер уйласаң, безнең проза бик яшь әле, аңа йөз ел гына тулып килә. Әдәбиятны караңгыга кысрыклап кертү җиңел ул... Бер генә әдип тә, бер генә әдәбият та үз халкының дәрәҗәсеннән югары сикерә алмый,— дияр ул.

— Киләчәктә Европа һәм Шәрык философиясен, Ислам тарихын яшьтән өйрәнгән, Коръән, Тәурат, Инҗилләрне яхшы белгән, фикри

әзерлекле яшь талантлар әдәбиятка килерме?—дип сорау биргәч, бер чордашым: «Юк, юк, булмаячак!» дип, әллә шатланып, әллә куркып әйткән иде. Ул да, күрәсең, Афзал Шамовлар шикелле, без соңгылар, бездән соң кулга тотарлык язучы булмаячак, дип, арттан килгәннәрне өнәмәүче каләмкуар затыннан иде. Аяз аганың җавабыннан башка тәрбия сизелә иде шул:

— Әгәр якын елларда татар бетмәсә... Чын татарлар туу өчен тагын ике-өч буын үтү кирәк. Безнең бүген Исламиятнең бөеклеген аңлатып бирер галимнәребез юк. Диннең өстә яткан кануннарын аңлатудан башка тирәнгә керә алган шәхесләр күренми. Дин әһелләре чыгыш ясаганда да үз сүзләрен кемгә, нинди катлау кешеләренә юнәлдергәнен ачыклап бетермиләр. Дин — милләтнең, халыкның бөтенлеге сагында торган зур көч ул. Милләт өчен уртак дин алган халыклар гына дәүләтчелеккә ирешкәннәр.

— Алда өмет күрәсезме?

— Без җиде миллионлы халык дибез. Кайберәүләр аны егерме миллионга җиткерә. Бу бит — миф. Катнаш гаиләләр күбәя барган чорда нинди миллионнар булырга мөмкин! Алдырма син сан белән, алдыр эш-хезмәт белән! Гомумән без милләткә хезмәт иткән шәхесләргә бәя бирә белмибез. Башкортларны гына алыйк: Салават Юлаев ышыгында күпме еллар яшиләр. Шундый зур шәхесләр милләтне җылытып, тамырларына дым биреп тора. Югыйсә бездә ул чорның Бәхтияр Канкаевлары, Батыршалары юкмы? Тарих алга барсын өчен шәхесләрдән калыккан баганаларга гына күпер салып була. Безнең уртак милли батырыбыз бармы бүген?

— Тарихка тирән кермичәрәк карасак, бүгенгеләрдән — Муса Җәлил?

— Ул ачылып беткән шәхес түгел... Мин Җәлил һәм аның иптәшләре турында шик уятырга теләмим. Яшьләргә йогынты ясауда үз вакытында аларның байрагы югары булды. Ләкин... милли геройлармы алар? Татарның киләчәге өчен һәлак булганнармы? Уртак ватан өчен һәлак булулары белән тарихта калырлар бәлки... Әгәр яңа заман яңа дәлилләр табып, аларның батырлыгын батырлык дип таныса...

— Сталин чорында доносчылык хөкем сөргәндә кем нинди юл белән исән калганлыгы хакында хөкем йөртергә безнең буын кешеләренең мораль хокукы да юктыр бәлки... Бүген шундый чор кабатланса, совет чорында тәрбия алганнар тагын да явызрак, тагын да түбәнрәк җанлы булып чыгарлар иде. Бу дәверне хәтерегездә кузгаткан өчен гафу үтенеп, үземне бимазалап йөргән бер сорау бирсәм... Сезне саткан, төрмәгә утырткан кешене беләсезме? Аны очраткач исәнләшәсезме?

— Хәзерге мәгълуматларга караганда, ул чорда һәр өч кешенең икесе теге яки бу күләмдә җәзалау органнары белән бәйләнештә торган. Мине төрмә сукмакларына этәргән кешеләрне моннан ике ел элек (сөйләшү 1993 елда бара) белдем. Исәннәре белән күрешеп-сөйләшеп йөрим. Аерым шәхесләргә караганда чорны гаеплим. Беләм, ул гаеплеләр шушы елларда тәүбәгә килде. Тәүбәгә килү, күңеләңне сафландыру — үзе бер батырлык ич.

— Сезнең дә намус-вөҗданыгызга күләгә төшерергә тырышкан имеш-мимешләр, хәтта матбугатта язмалар да булды. Моңа каршы Сез ачыктан-ачык җавап бирмәдегез шикелле?..

— Кешеләргә гаеп ташлау, шик-шөбһә белдерү көнчелек галәмәте. Әгәр мин әдәбиятта кайсыбер уңышларга ирешә алмаган булсам, ай-һай, мондый кара хәбәрләр шытып чыгар иде микән...

— Әгәр без житмеш ел буена эзлекле, чын-гадел мәгълүмат алып килгән булсак, Сезнең «Балта кем кулында?» дигән романыгыз башкачарак тумас иде микән. Сез читлектән кинәт иреккә чыгарылган арыслан кебек, бөтен нәрсәне таптап, каударланып, бәргәләнеп, барысын да тизрәк әйтеп калырга ашыгасыз. Язучыдан һәрчак сабыр акыл сорала бит...

— Ул романны мин моннан ун-унбиш еллар элек язарга уйлаган идем. Син әйткәнчә, тынычрак агышлы булырга тиеш иде. Ләкин әсәр башкача өлгерде һәм мине дә өлгертте. «Балта кем кулында?» — минем иң житди әсәрләремнең берсе дип уйлыйм. Монда минем чорга, халкыма мөнәсәбәтем чагыла. Балта кем кулында? Балта ленинизм, совет режимы кулында. Бу режим ике катлауны да имгәтте. Югары катлауны чиксез чамасыз байлыгы белән, бернинди җаваплылык тотмый торган иркенлеге белән, бөтен бозыклыкка юл ачып, талауга, халыкны мыскыллауга йөз тотып имгәтте. Ярлы-ябагайны исә ач тотып, салымнар белән сытып, кешелек хокукларын тартып алып имгәтте. Мин соңгы әсәрләремнең бөтенесендә дә шушы режимның татар халкын ничек изүе, талавы хакында фикер йөртәм. Милләтнең һәлакәте алда әле... Без бит бәхетсез заман җимеше...

Мин Аяз ага янымда булмаганда да, вакыт-вакыт әлеге роман хакында уйланам. Нигәдер ошата алмыйм мин аны. Аяз агага купайту, ярпачлык хас. Менә бу әсәрендә дә ул бәләкәй генә авыл мунчасы оялдына дөньяда үзе татыган, ике йөз кешелек банкетка әзерләнгән барча ризыкны дыңгычлап сыйдырган. Кечкенә җирлеккә соңлап килгән кыюлыкны сыйдырырга тырышу бөтен әсәр рухында. Балталы кырмыскаларны хәрәкәткә китергән көчнең, с и с т е м а н ы ң асылы кайда? Русь дәүләте борынлап кына килгәндә ушкуйниклар, ягъни, юлбасарларга таянган. Новгородта чит ил бурзайларыннан әзерлек-кунегү алган, баштанаяк коралланган ике мең гаярь ир көймәләрдә көтмәгәндә килеп төшәләр дә, Идел буе шәһәрләрен күз ачып йомган арада кан елатып талап китәләр. Тора-бара ушкуйниклар җирләр яулый башлыйлар. Шундый юлбасарларның берсе — Урал арьягында һәйкәл булып калыкканы — Ермак.

Бүгенге заман ушкуйниклары — башка... Әйе, балта — эш аты татарлар кулында. Замана ушкуйниклары Канар утрауларында кәеф-сафа корып, кит мыегыннан кыздырылган антрекотны сандугач шәхүәтеннән эшләнгән соуска мана-мана ашап, янәшәсендәге сылукайның тыгыз имиләре арасына кыстырылган телефоннан спутник аша дөнья белән бәйләнешкә кереп, компьютер экраны аша финанс ятьмәләре корып халыкны таларга мөмкиннәр. Эре финанс акулалары, колачлы бизнес галәменә балталы татарга керүе кыен. Ә кызыктыра, каһәр! Ул милли йөзен югалтып кына иң түбән баскычка менеп тез чүгә ала. Замана икътисады милли үзенчәлекләрне таптап бара. Җир бәгырендә табигый байлыклар беткәнче яшәеш шулай барачак: яңа алдавыч идеялар туып, революцияләр, сугышлар кабынып торачак. Ә безнең әдәбиятта символлар: балта, болын сөрү, агач аударуга кайтып кала. Андый әсәрләрнең төше — йомырка кабыгын ватарга азапланган хәлсез кош баласының томшыгы кебек түгелмә...

Матбугатта моңа кадәр күрү насыйп булмаган иркенлек: көн аралаш тетрәндергеч детектив вакыйгалар, хәтәр кыю фикер, үткәннәрдән чәч үрә торырлык документлар, киләчәккә баш җитмәслек тәвәккәл караш ташлау гаять мулдан бирелә. Мондый кайнар агым белән әдәбият ярыша алмый. Әмма сәнгатьле, сабыр әдәбиятның юлы башка. Мин чорыбыз шавыннан арып, Аяз ага, Сезнең илаһи тын белән язылган «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар», «Җомга көн, кич белән» кебек чын сәнгати кимәлдә язылган әсәрләрегезгә кайтам. Һәм шул табигый, сагышлы, үкенечле, кадерле дөньялардан бер чистарынып чыгам. Европа үлчәменнән караганда алар менә дигән романнар ич!

Тормышта Аяз ага вакыт-вакыт усалланып алса да эчтән юаш, нәзберек хисләрен күңелендә калдыра белә. Шуңа күрә ул яшьлегендә язган дүрт мең (үзе әйткән сан) шигырен якты дөнья йөзенә чыгармыйча, сандык төбендә тоткарлык ихтыяр көченә ия. Әдәбият-сәнгатьтә төп мичәүгә җигелгәнсең икән, кайбер янәшә жанрлардан ваз кичә белү дә

кирәктер. Бернард Шоу: «Саксофонда уйный белеп тә беркайчан да уйнамаган егет — чын егет!» — дип шаярып әйткән бит әнә.

Аяз ага Сибгат Хәкимнең шигыренә язылган «Өянкеләр» җырын ишетсә, күңеле актарылып чыга, күңеленнән генә кушылып, җырның самими дулкынына башын куя да савылып җылый.

Су буенда өянкеләр,
Минем дә житте бугай бит
Картайдым дияр көннәр.

Үзе кешеләр янында хискә бирелеп, беркайчан да күз яшен күрсәтмәгән Мөхәммәт ага Мәһдиев «Ачы тәҗрибә авазы» китабында Аяз аганың бу йомшаклыгыннан саксызрак көлеп язган иде.

Тагын кемне сүгеп ташлар икән, дип җыелышларны тетрәтеп торган, каты бәгырьле булып тоелган Аяз ага җыласын әле. Моңа ышану авыр, әмма аны якыннан белгән кешегә ышанмый мөмкин түгел.

Алтмыш еллыгы якынлашкан көннәрдә миңа аның өендә булырга туры килде. Иртәнге сәгать уннар иде. Аяз ага үзенә багышланган язмамны йөгертеп кенә укып килде дә, азакка, шул өянкеләргә җиткәч, лышык-лышык җылый башлады. Мин үземнән өлкән кешене ничек кенә дә юатырга белмичә өнсез калдым. Ә ул бик кадерле әйбереннән мәхрүм калган сабый кебек җылый да җылый.

Альп кыялары өстеннән «Христосның тууы» шәрабен тәмләп сүз арасына сеңдереп, мин Аяз агадан әлеге җырдан ни өчен шулай күңеле йомшавының сәбәбен сорадым.

— Аны аңлатып булмый. Бу — ниндидер сер, әлбәттә. Сибгат аганың 60 еллык юбилеенда, Рөстәм Яхин мине чакырып алды да: «Аяз, син бит әле карт түгел, нигә шулкадәр бу җырны бәгыреңә үткәреп кабул итәсең?» — дигән иде.

Үз гомерендә җиде язу машинкасы туздырган, бөтен көч-зиһенен әдәбиятка багышлаган Аяз ага белән бәхәс-әңгәмәне итагатьле итеп гомер соңына кадәр дәвам итәргә була. Үтеп барганда секундларның кадерен тотып ала белгән шәхес кенә «бу мизгелне кабатлап булмый...» дип кырыс хакыйкатьне искәреп әйтә ала.

* * *

Мадрид — Мәскәү самолеты болытларны аралап җиргә якыная. Гүя без еллар тавыннан төшеп киләбез. Аста урман-күлләр — сусыл яшеллек. Төсе ят чит ил туфрагыннан соң җанга якын манзара.

Тәгәрмәчләр җиргә тигән мизгел бөтен вөҗүдең аша үтә, исәнимин кайтып җиттек бит, дигән уй-шатлыгыңнан күңел мөлдерәп тула. Ул арада салон, тыйнак кына «Ура!» кычкырып, дәррәү кул чаба башлады. Матур булса да Испаниясе, һәркемнең үз Исламиясе...

Әнкәң кебек үк, туган илне дә сайлап алып булмый, ничек бар, шулай яратырга хөкем ителгәнсең. Кыйнап һәм кыйналып яратырга...

# ШИГЪРИЯТ



## Гамил Афзал

### МИН КАРТАЙГАН САЕН УСАЛЛАНАМ

### Уңышлар телим сезгә

Хәтфә кебек үлән үсә
Каеннар тирәсендә.
Яшь гомерләр искә төшә—
Төшләргә керәсең дә.

Болгавыр заманнар килде,
«Уф», дисең искә төшкәч.
Хәзер ялгышмыйсың инде,
Ялгышыр хәлең беткәч.

Яшьләрнең канат ныгысын,
Елмаю кунсын йөзгә.
Онытыйк ыгы-зыгысын
Бу егерменче йөздә.

Кояшлы, җылы җәйләрдә,
Яңгырлы, соры көздә
Бәхетләр телим, кардәшләр,
Уңышлар телим сезгә!

* * *

Безнең халык батыр, диеп,
Горурланасы килә.
Алда еллар матур, диеп,
Алга барасы килә.

«Мин татарча низнай» диеп,
Татар баласы килә.

Минем балам үлгән, диеп,
Солдат анасы килә.

Илем диеп, халкым диеп,
Дөрләп янасы килә,
Җаным белән җир сөрерлек
Күңел ярасы килә.

Элеп аласы килә дә,
Селкеп саласы килә,
Бер гомердә ун гомерлек
Эшләп каласы килә.

## Үз кыйблам

Сер-сәясәт дигән әрәмәдә
Нинди сәер кошлар күрмәдем!
Дуслык-дуслык диеп сөйләнәләр...—
Властьлар ярата үзләрен.

Үз кыйблама карап барам шулай,
Юл хәтәр буласын алдан беләм,
Бик акыллы вәхи бирде Ходай:
«Егылганчы сугыш ялган белән!»

Айсберг кебек тора иде...
Асты өскә килде дөньяның.
Тагын ун кат асты өскә килер,
Күчәренә ябыш син аның!

## «Без шәп»

Без чабата киеп җир сөргәндә
«Без — шәп халык» диеп белә идек.
Умач ашап, кукыраеп йөргәндә
Капитализмнан көлә идек.

Эшли-эшли бөлгенлеккә төшкәч,
«Без — шәп микән?» дигән шик уянды.
Телеңне аркылы тешлә дә, иптәш,
Урыс урманында ку куянны...

* * *

Мин картайган саен усалланам,
Заман белән якалашып барам.
Һәр ялганның коерыгына басам,
Усал шигъри чарам.

Мин картайган саен юашланам.
Матур сүзгә тәмам эреп китәм,
Үти алмас йөкләмәләр алам,—
Усал булмам бүтән.

Чынбарлыктан алган акыл белән
Әнием биргән аклыгымны куштым,
Сокланырлык гөлләр алып киләм,—
Авыр киләм, дустым.

Изге максат белән бу барышта
Читкә тайпылмадым бер карыш та...
Син дә, дустым, гомер дигән юлда
Тамак колы булма!

## Олы шагыйрь

*«Идегәй» дастаны чәчәненә*

Олы шагыйрь килгән, орышкан, ызгышкан,
Дөньяны пакьләргә тырышкан:
«Пакь булыгыз!» дигән, «саф булыгыз», дигән
Әүлияләр белән берочтан!

Олы шагыйрь киткән, каберенә үскән
Алабута белән кычыткан.
Дөньяда шом калган, олыста ым калган
Ялкынлы, ярсулы сулыштан.

* * *

«Коммунизм кыры күренә», диден,
Күренмәде әлегә, Һади Такташ...
Ничек итеп ул күренер икән.
Капитализмга кайткач?

## Тик торганда

Синдәй сәясәтче сирәк иде:
Трибунада тауга-тау орасың.
Азатлык вә бәхет кирәк иде,
Түрә булгач нигә тик торасың?

Әле танылмаган даһи, дисең,
Шаккатарлык эшең юк шөйлә.
Бик акыллы булып күренер өчен,
Серле вәгъдә салып сүз сөйлә.

Үзе надан килеш акыл сатып,
Заманны һәм илне болгатып,
Ике кулы нахак канга батып,
Тираннар да китә бер вакыт.

Сабыйларның башларыннан сөеп,
Иркен яшәр еллар киләдер.
Миллионнарның күз яшьләре кебек,
Ачы ләгънәт явар кемгәдер...

## Коры куаныч

Бәйрәм дә тантана,
Бәйрәм дә тантана,
Эшләргә вакытлар әз кала.
Кызларны җырлатып,
Кызларны биетеп,
Күңелен күтәрә башкала.

Бәйрәм дә тантана,
Бәйрәм дә тантана,
Кемнәрдер сөенә, шатлана.
Хәерче көенчә,
Күңеле сөенсә,
Ясалма елмая ач кала.

Бәйрәм дә тантана,
Бәйрәм дә тантана,
Күңелләр чүпләнә, ваклана.
Утырттым боларны
Төп башына, дип,
Сөенә, шатлана таш кала.

* * *

*Укытучым Әхмәт абыйга*

Яратты ул күңелләрне
Ераклардан уратырга,
Хыялында йөргәндер ул
Карфагенда, Урартуда.

Гарасатлы җилләр искән
Кайсы якта, кайсы чорда;
Каян килгән, кая киткән,
Нигә беткән Алтын Урда?

Рим дисен, Мисыр дисен,
Авыз суы кибә иде,
Аргиштиен, Озирисен
Борчак кебек сибә иде.

Инде канлы юллар урап,
Безнең якка килеп чыксак,
Авыр сулап, ясак сорап,
Җәйрәп ята Дәшти Кыпчак.

Бату диеп, Чыңгыз диеп,
Авыз суы корый иде,
Усал карап, күзлек киеп,
Шуны бездән сорый иде.

Әхмәт абый дөнья куйган,
Бик ямансу булып калды;
Күңелләрдә чыңлап торган
Илләр янды, еллар янды...

## Гаделсез власть

Туган авылга илле ел кайтмадым,
Таш йоттым, яшь түктем, бизендем шулай...
Урал далалары күгендә дә
Шул Кояш, шул ук Ай.

Шул ук Алла карап тора күктән,
Шул ук патша, түрәләре бүтән.
Таштан-ташка сикереп сулар ага,
Без дә адәм ләса бу дөньяда.

Безне кимсетергә власть кушкан,
Мин — ун яшьлек малай, кемгә дошман?
Халыкларны җирдән мәхрүм иткән
Бу аждаһа власть куркак икән.

Ул калтырый, күн тужурка киеп,
Наган сабы белән өстәл төеп...
Ничек әйттем шул җәлладны сөеп,
«Рәхмәт сиңа, Бөек Атам», диеп?!

## Бер әбинең догасы

Аллаһеммә саллигала салҗидәнә...
Юньле генә кияү җибәр Саҗидәгә,
Юньле кияү тартмасын да, эчмәсен дә,
Акчаларын биреп барсын бичәсенә...

Коммунистлар мулла булган бу заманда
Мәчет белән иман кайтсын дөньяларга.
Ашка йөрим, вәгазь сөйлим, бик ыспай мин,
Партионный түгел инде, абыстай мин.

## Минем догам

Кырык эшем кырык җирдә кырылып ятсын,
Гомер үтсен, җилләр иссен, сулар аксын,
Ата-бабам гомер иткән Идел-Йортта
Алтын айлы иманлы ил чәчәк атсын!

## Фал ачу

Чегән хатыны миңа фал ачты:
«Син бик күп серләр беләсең, диде;
Күңелең ачык, әҗәлең ачы,
Казенный йортта үләсең, диде.

Матур елмаеп еллар үтәрләр,
Хыяллар очар иркендә,
Якын дусларың хыянәт итәрләр,
Юксынмас сине беркем дә...»

Өс-баш чуар, сүзе акыллы,
Елтыр күзләре — терекөмеш...
Дөрес сөйлисең, чегән хатыны,
Мә сиңа, фалчы, бер көмеш!..



**Радик Фәизов**

# ИКЕ ӘНИ

ПОВЕСТЬ

## Кереш сүз

*Әни! Шушы исемне әйтү белән кеше күңеленә никадәрле җылы хисләр килә, нинди нурлы яктылык сирпелә. Бала чактан ук, әле әниебезнең муенына сарылып үскәндә үк, без бу исемне чиксез ярату, гамьсез шатлык, ләззәтле куаныч белән әйтәбез. Инде еллар үтеп үзебез дә олыгаеп килгәндә бу кадерле исем сагынуга, моң һәм сагышка төрелә. Бу олы исем безне гомеребез буена озата килә һәм, мөгаен, инде соңгы сулышыбызны алып ятканда да безнең сүнеп барган рухыбызга әни дигән мөкатдәс зат үзенең соңгы хәер-фатихасы белән нindидер бер җиңеллек бирәдер.*

*Гадәттә һәркемнең әнисе берәү генә була. Тик, тормыш дигән бу бик катлаулы иҗтимагый күренештә табигать үзе куйган бу катгый кагыйдәдән дә тайпылу бар икән. Кайберәүләрнең әнисе икәү, сирәк очракларда аннан да күбрәк булырга мөмкин икән.*

*Шәхсән, минем үземнең ике әнием булды. Һәм, бераз гаҗәп ишетелсә дә, шуның белән мин үземне бәхетсез дип санамыйм. Гаҗәп ишетелә дип шуңа әйтәм, бәс яшьли килеш үз әнисе вафат булып ятим калгач, икенче, үги әни кулларында үскәч, бу кеше инде үзен бәхетсез санарга тиеш иде кебек. Ә менә мин алай дия алмыйм. Һәм ни өчен болай икәнен укучым ары таба, сүз барышында төшенер, күңеле белән сизеп алыр дип өметләнәм.*

## Үз әниебез

Мине шушы якты дөньяга китергән, күкрәк сөтен биреп үстергән газиз әнием! Син нинди булдың икән? Мин синең чәчләрең чем кара булуын, дулкынланып иңнәреңә таралып төшүен, зур соры күзләреңнән нурлар сирпелүен генә хәтерлим. Синең йөз чалымнарың, атлап йөрүләрең, елмаю, сөйләшүләрең нинди булды икән? Менә боларның берсен дә белмим һәм инде мәңге белә дә алмам. Әмма минем күңелем түрендә, бик тирәндә, синнән иңеп калган җылылык, шәфкать нурлары, ана мәхәббәте әле дә булса саклана. Алар инде минем өчен синең гомерлек изге ядкарең.

Кайчан шулай уйланып, сагышланып утырам да, күңелләге үткән еллар томаны тарала төшә. Алар артыннан балачакның кадерле хатирәләре калкып чыга...

Гадәти авыл өе. Түр якта өч, ян стенада ике тәрәзә, ишекне ачып кергәч тә, сулда зур мич җәелеп утыра. Түрдә, ике тәрәзә арасында тагын бер кечкенә мич. Өйдә тагын зур агач караватъ, кечкенә карават, өстәл һәм урындыклар. Матчада даими рәвештә талчыбыктан үрелгән, шыгырлы-мыгырлы бала бишеге эленеп тора. Үзегез исәпләп карагыз әле, шуннан соң да инде бу өйдә азрак хәрәкәтләнү, яшәү һәм йоклау өчен күпме генә урын бүленеп кала? Ә ошбу кысан, фәкыйрь өйдә без, аз да түгел, күп тә түгел, унбер җан көн итеп ятабыз. Әни белән әти, тагын тугыз бала, минә сиңа җәмгысе унбер җан! Әле сугышка кадәрге елларда да авыл җирендә фәкыйрьлек бик мулдан булган, күрәсең. Безнең әтиебез укытучы, авылдагы башлангыч мәктәпнең мөдире, ягъни авылның үзенә күрә зур бер кешесе иде инде. Шулай була торып та ул үзенең бу тикле ишле гаиләсен яшәтер өчен бер юньле, иркен йорт та салып чыга алмаган.

Кич. Хәзер инде әти дә эшләрен бетереп мәктәптән кайткан, уку яшендәге балалар, урамда уйнап йөргән кечкенәләр дә, барчасы өйгә җыелган. Өй эче шыгрым тулы! Кучкарга менеп кунаклаган бердәнбер керосин лампасының тоныкяктысында анда шәүлә, монда гәүдә шайләнә. Әнә әтиебез үзе. Ул аягыннан ямаулы киез итекләрен дә салмаган килеш түргә, агач караватның башына ук менеп кунаклаган. Бер кулы белән мыегын тоткан, икенче кулында гәҗите. Ул шулай, көн саен кичен гәҗит укый. Мәктәп яшендәгеләр өстәл тутырып утырганнар да дәресләрен әзерлиләр. Алар арасында әледән әле төрткәләшү, урын өчен үзара ызгыш булып ала:

— Колак төбендә мышкылдама әле!
— Карале, ал бу терсәгеңне.
— Кая алыйм, урын юк бит.
— Менә берне салып җибәрермен!
— Дәфтәремә кара тамызды, кәгис!

Монда «Кәгис!» дигәне бернинди чит ил сүзе түгел, ә үзебезнең гап-гади «сигәк» дигән сүз. Алдын артка әйләндереп әйтү генә бу. Бу инде бик тә ачу килгәндә әйтелә һәм хәтерне дә бик тә калдыра торган сүз. Аны ишеткән кеше гадәттә елап ук җибәрә:

— Син үзең кәгис, үзең кә-ги-ис!

Без кечкенәләр исә кайсыбыз кайда, идәндә, почмакта, хәтта карават астында ду-чат киләбез. Безнең арада шулай ук үзара бәдәшкәләү, урын өчен көрәш бара. Өй эче шаулап, гөрләп тора. Кечкенә бер ярминкә кеби. Әмма шушы хезмәт, шау-шу арасында, өйнең төрле почмакларыннан олысы-кечесе һәркем бер кешене — әнине күзли. Әни учак янында, әни ашарга пешерә! Аның бу изге гамәле кайсы ноктада булуын һәркем игътибар үзәгендә тота. Менә әни тарафыннан хәбәр килә:

— Аш пеште!

Дәрес әзерләүчеләр күз ачып йомганчы әсбапларын җыеп алалар. Әни өстәлгә зур табак белән аш китереп куя. Һәркем зарыгып көткән, шулкадәр тәмле исләре килеп торган ашны. Тагын бер шау-шу кабынып ала:

— Әни, карале, Фаяз минем кашыкны алган.
— Әни, минем тәлинкәм кайда?
— Әни, миңа ашны аз салдың...

Һәркемнең үз тәлинкәсе, үз кашыгы бар. Һәм һәркем үзенең бу шәхси милке өчен ахырынача көрәшә, шыңшый. Тик әни сабыр, түземле. Ул йомшак сүзләре белән һәркемне тынычландыра:

— Хәзер, улым, сиңа үз тәлинкәмне бирәм.
— Хәзер кызым, аш өстим сиңа.

Әмма өйдәге җайсызлыкны, кысанлыкны әнинең сабырлыгы да җиңә алмый шул. Өстәл янына утырып ашарга безнең һәммәбезгә дә урын җитми. Кемнәрдер тәлинкәсен кечкенә караватка куеп, җайсыз урында, идәнгә тезләнеп ашарга мәҗбүр була.

Инде йокларга ятар вакыт җиткәч, өйдә тагын бер мәхшәр куба. Һавада мендәр-юрганнар, иске көрпәләр, сырмалар оча башлый. Һәркем үзе ятып ияләнгән, яраткан урынын алып калырга ашыга, урын-җирнең дә йомшагын эләктерергә чамалый. Бәхетлеләргә — почмактагы кечкенә караваt, көрпә, бәхете кимерәкләргә — идән, ә бәхетсезләргә инде ишек каты, иске сырма эләгә. Кемдер хәтта өстәл өстенә җәя урынын. Монда җылы, әмма сак йокларга туры килә, күп боргаланып ятсаң, идәнгә тәгәрәп төшүең дә бар.

Әй Алламның эшләре!

Идәндә зур караваt белән кечкенә мич арасында калган тар гына бер урын бар. Мин, өч-дүрт яшьлек малай, инде үземне белә башлаганнан бирле әнә шунда төн үткәрәм. Астымда әтинең иске сырмасы, гаҗәеп каты кечкенә мендәр, өстемдә кечкенә генә, юка гына юрган кисәге. Миңа идәндә җайсыз, каты, салкын, якында гына мич астында чикерткә сайрый. Әле өйдә ут сүнгәч тә, йоклап китә алмыйча ятам. Шунда кемдер өй ишеген ачып җибәрсә, яныма хәзер суык бабай йөгереп килеп җитә, юка юрганымнан үтеп керә, шыксыз куллары белән тәнемә кагыла.

Әнә шулай җәфа чигеп йокылы-уяулы ятканда минем өстемдә ниндидер бер шәүлә, сихри зат пәйда була. Тәрәзәдән төшкән тонык яктылыкта мин аның дулкынланып иңнәренә таралган чәчләрен күрәм, зур күзләрен генә шәйлим. Ул тавышсыз-тынсыз гына минем өстемә иелә, куллары белән кармаланып минем юрганымны рәтли, як-ягымнан астыма кыстырып куя. Аның чәчләреннән, бөтен гәүдәсеннән минем өстемә ниндидер йомшак җылылык коела. Аннары ул йөзен минем битемә тидерә язып түбән иелә. «Улым шул син минем, сары пышлагым шул син минем! Йокла инде, йокла!» — дип пышылдый һәм тагын бер шәүлә сыман тавышсыз-тынсыз гына бүтән туганнарым янына китеп бара. Ә аннан сирпелеп калган җылылык юрганым аша минем гәүдәмә, эчемә үк үтеп керә. Мин инде җылынып, тынычлап, рәхәтләнеп йокыга китәм. Әле бик нәни чагымда мин бу шәүләнең кем икәнен төгәл белми, төн йокламый безне кадерләп йөри торган бер сихри зат дип уйлый идем. Инде үсә төшкәч белеп алдым, көн дә саен кичен яныма килеп, үзенең җылысын биреп, йоклатып китә торган бу зат минем әнием икән.

Үсә барган саен мин тагын күп кенә яңа нәрсәләрне дә белдем әле. Әнием минем Зәкия исемле, авылдагы Мифтахетдин дигән хәлле генә бер кешенең кызы икән. Безнең Мифтахетдин бабай авылның бер ихтирамлы кешесе булган, күрәсең, әле советлар чыкканчы байтак еллар авылның старостасы да булып торган. Аны бик диндар, мәрхәмәтле кеше иде дип сөйләделәр, тик мин белгәндә ул күптән вафат иде инде. Ә менә тәбәнәк кенә, түгәрәк йөзле, аяк асты салынып төшкән, җете зәңгәр күзле Латифабану әбине әйбәт хәтерлим. Әби тәгәрәп киткән йомгак төсле тиз-тиз йөри, кискен итеп сөйләшә һәм... галәмәт тә усал иде. Белмим, бәлки бу миңа шулай тоелгандыр гына, әмма әбинең безгә килеп-тәрәзәдән күреп алу белән без, өйдә тузан тузгытып уйнаган бала-чага, шунда ук шым була идек. Өйгә килеп керүенә әби иң беренче гамәле итеп кулына мич алдыннан тимер кыскыч алыр иде.

— Һәйт, кяферләр!.. Тик кенә утырыгыз. Тузгытмагыз бу кадәр тузан. Карагыз аны!.. — дип, безгә кыскычны күрсәтер иде. Аннары алар әни белән бик озак сөйләшеп утырырлар иде. Кем белә, бәлки әйбәт кенә әби дә булгандыр ул. Тик минем хәтергә әнә шулай зәһәр карашы белән, кулына тимер кыскыч тотып кереп калган. Ә мин үсә төшкәндә ул да вафат иде инде.

Әтием Хәбибрахман ярлы крәстиян Фәйзерахман малае. Әтием ягыннан әбиләремне мин бөтенләй дә белмим. Әбиләрем дип күплектә

итеп шуңа әйтәм, бабайның беренче җәмәгате үлеп ул тагын өйләнгән һәм бу гаиләдә аз да түгел, күп тә түгел, җәмгысе унөч бала дөньяга килгән! Шәйтан белсен, алар нинди тәрбиядә үскәндер инде. Фәйзрахман бабайның үзен яхшы хәтерлим, аның хакында ары таба сүз булыр. Аның олы улы — әтием Хәбибрахманны — яшь чагында озын буйлы, зәңгәр күзле, мыеклар үстереп җибәргән бик чибәр егет иде дип сөйләделәр. Хәбибрахман патша солдаты булган, беренче Герман сугышында атлы гаскәрдә хезмәт иткән. Алар сугыштан тәмам туеп, аның мәгънәсезлеген аңлап, фронтны үзбуйла ташлаганнар да авылга мылтыкларын күтәреп кайтканнар. Андыйлар безнең авылда тагын берничә кеше булган. Мин дәү булып үскәч, әтинең сөйләгәне булды. Шашы тау башыннан бик зур бер бүре үтеп бара икән. Әти тиз генә мылтыгын күтәреп чыккан да, бик ерактагы бүрегә атып җибәргән. Аннары, тимәде бугай дип уйлап, үз эше белән китеп барган. Ә икенче көнне кешеләр тау астыннан үлгән бүрене табып алганнар. Шуннан бүтән максатларда әти бу мылтыкны кулланмагандыр, күрәсең. Мин исә аны күп еллар үткәч, инде әтинең вафатыннан соң, сыер абзарын чистартканда тирес астыннан табып алдым. Мылтык тәмам череп, яраксызга чыккан иде инде.

Хәбибрахман солдат һәм иптәшләре фронттан авылга мылтыкларын күтәреп кенә түгел, большевиклар мәсләген дә ияртеп кайтканнар, күрәсең. Безнең әти янына шундый ук фронтовиклар Закирҗан, Рәхимҗан, Халиклар җыелып, анысын-монысын сөйләшкәннәр. Авыл җыеннарында моңарчы куелган тәртипләргә каршы чыга башлаганнар.

— Ни эшләп әле иң печәнле болыннар мулла абзый кулында? Ул кадәрле болын биләргә ниткән права?

— Җир бүлгән чагында ни эшләп ел саен хәрам китә?

— Монда староста үзе ни карый?

Эш сүз белән генә калса, бер хәл иде әле. Бер җыенда болар кызып китәләр, хәрамгә кергән авыл түрәләренә янауга ук барып җитәләр. Ә кич белән инде шул чагында авыл старостасы Габдерәуф абзыйны, аулак урында сагалап, яхшы гына кыйнап та ташлыйлар. Әмма ләкин авыл картлары да тик ятмый. Икенче көнне үк саллы гына күсәкләр белән коралланалар да, теге «кызыл авызлар»ның башлап йөрүчесе Хәбибрахман солдатны ишегалдында яшеренеп, көтеп торалар. Берни абайламаган егет авыз эченнән күңелле көйләр сызгырып килеп керде. Һәм шул мәлдә үк, шулай ук күңелле сызгырып, аның баш түбәсенә бик бәрәкәтле каен күсәк килеп тә төшә... Бик ихтимал, женнәре тәмам кузгалган картлар шул чагында безнең булачак әтиебезне хәл итеп ташларлар һәм менә хәзер бу юлларны язып утыручы да дөньяга килмәгән булыр иде. Тик фронтларда мең үлемне кичкән солдат, яралы башыннан кан акса да, ниндидер могҗиза белән биек койма аша сикереп чыгарга өлгерә. Лапас артларыннан югары очка таба йөгерә һәм тиз арада шунда гаип тә була. Картлар аны дөнья бетереп бик яман эзлиләр. Өй борынча кешеләрнең лапасларына кереп, салам-печән өемнәрен сәнәкләр белән чәнчеп, актарып бетерәләр. Тик, безнең булачак балаларның бәхетенә инде бу, күпме эзләсәләр дә, таба алмыйлар.

Бактың исә Хәбибрахман солдатны, авылда бунт күтәреп коткы таратып йөрүчене кайчандыр авыл старостасы булган Мифтахетдин картның кызы Зәкия үз лапасларына, анда да аулак почмактагы базга ук төшереп яшергән була. Шушы хәлләрдән соң әтиебез гомере буена маңгаенда яхшы ук беленеп торган яра эзе йөртте. Монда бер искәрмә ясап үтим. Әти безнең бөтен җаны-тәне белән революция, халык власте яклы кеше булган. Авылда совет властен урнаштыру, ә аннары колхоз оештыру өчен җан атып, бар халыкны үгетләп йөргән. Авыл җыеннарында:

— Колхозга керсәк, хәзерге кебек хәерче булмабыз. Менә мондый-мондый ак күмәчләр ашарбыз! — дип, сөйләп йөргән. Башындагы ак бүрекне кулына тотып, һавада селтәп сөйли торган булган ул. Шуңа күрә

«Ак бүрек» кушаматы да алган. Шулардан чыгып мин бер нәрсәне һич кенә дә аңлый алмыйм. Менә шундый кеше булса да, безнең әти гомере буена партиягә кермәде, коммунист булмады. Алай гына да түгел, инде мин үсеп бу дөньяны азмы-күпме аңлый башлагач, үзара яшертен генә сөйләшүләрдә ул еш кына шул ук коммунистларны «алдакчы булып чыктылар, хәрәм юлына бастылар», «бер дә болай башланмаган иде бу...» дип, тирги дә иде әле. Ни өчен шушылай иде бу? Монысын мин әлегә кадәр төшенә алмыйм. Кем белә, үзе яшь чагында, шушы властьны урнаштыру өчен көрәшеп йөргәндә ул бу властьны бәлки башкарачак күз алдына китергәндер.

Менә шул үзен үлемнән алып калганнан соң, Хәбибрахман солдат кичләрен еш кына югары очтагы Зәкияләр капкасы тирәсендә чуала башлаган. Аннары инде алар үзара яратышып киткәннәр, йоласын туры китереп туй иткәннәр һәм тора-бара безгә — бер дистәгә якын балага әти-әни булдылар.

Әйткәнемчә безнең әти авылның ярлы, сабакның әлифен таяк дип тә белмәгән надан бер кешесе — Фәйзерахман малае булган. Авылда совет властен үз тырышлыгы белән урнаштырып йөргән. Үзлегеннән укырга-язарга өйрәнгән, бик күп китаплар укып белем алган, аннары инде, Арчада авыл укытучылары әзерли торган курслар ачылгач, йөрәге җитеп шунда барып кергән. Кабул иткәннәр моны. Аннары инде ул тагын зур тырышлыклар куеп, авылда мәктәп ачылуга ирешкән, шунда үзе укыта да башлаган.

Бәс Фәйзерахман бабай хакында сүз чыккан икән, көчтән килгәнчә аны да беразкүрсәтеп китәргә кирәктер инде. Менә безнең капка келәсе челтерәп куя һәм аннан гәүдәсен бик төз тотып бер карт килеп керә. Өй ишеге аша үткәндә ул урталай бөгелергә мәҗбүр. Башы түшәмгә тиеп торган озын буй, күкрәктәй киң ап-ак сакал, салынып төшкән кылыч борын. Киң маңгаен җыерчыклар сырлаган, тик менә күзләре җансыз, ап-ак Бабай дөм сукыр. Ул кулындагы озын, авыр таягы белән идәнне хәтәр тукылдатып ала, каяндыр тирәннән чыккан, күк күкрәгәндәй гөрелдәвек тавыш белән аваз сала:

— Зәкия килен, син өйдәме?

Безнең әни бабайны бик ихтирам итә, хәтта аннан шактый гына шүрли дә бугай. Бабай капкадан килеп керде исә ул бар эшен ташлый, ишектән кергәндә инде кулларын алъяпкычына куеп, әзерлектә тора.

— Өйдә мин, әткәй, өйдә.

— Миңа дигән бәрәңгең бармы? — дип сорый бабай, һаман да хәтәр төстә.

— Бар, әткәй, бәрәңге калдырган идем мин сиңа,— ди әни һәм өстәлгә тулы бер бадьян мичкә тәгәрәткән бәрәңге китереп куя, калын итеп ипи кисә. Бабайны җитәкләп йөрисе юк, ул өстәл янына үзе килеп утыра. Аның олпат гәүдәсеннән урындык таралып төшә язып шыгырдый. Бабай тамырлары бүртеп чыккан галәмәт дәү куллары белән өстәлне шакылдатып бадьянны эзләп таба һәм бисмилласын әйтеп, эшкә дә керешә. Без дә, кулларын алъяпкычы астына кушырган әни дә исләребез китеп карап торабыз, бабай әллә ни арада гына бер табак бәрәңгене, зур-зур ике телем ипине ялмап та куя. Куллары белән битен сыпырып амин итә.

— Рәхмәт яусын сиңа, килен! — ди ул һәм урыныннан кузгала. Артыгын берни дә сөйләшми.

Без, бала-чага, бабайның мондый кыяфәтеннән, гөрелдәвек тавышыннан ук шактый шүрлибез. Шул ук вакытта аның ачуын чыгарасыбыз, үртисебез дә килә. Бервакыт болай эшләдек: аның ишек төбенә салып калдырган кәвешен бер читкә алып куйдык. Кармаланып та кәвешен таба алмагач, бабай кып-кызыл булды. Кулындагы таягы белән ишеккә шундый итеп китереп сукты, инде стеналар җимерелеп төшә икән дип торабыз. Аннары безне дер селкетеп кычкырып җибәрде:

— Кяферләр! Минем кәвешләрем кайда?

Без ник шаярганыбызга үкенеп, дәррәү караватʼ астына кереп постык. Ярый әле, әни тегенә тизрәк кәвешен китереп бирде. Юкса, эшләр харап иде.

Безнең нәселнең авылдагы кушаматы «кырмышлар». Нәкъ менә Фәйзерахман бабайның яман да кызу канлы, гайрәт чәчә торган, җенле кеше булуыннан килә бу. Кем дә кем әйткән сүзенә каршы төшеп җеннәрен кузгатса, кул астына эләккән һәр нәрсәне вата, җимерә, кыра торган булган ул. Яшьрәк вакытларында бик көчле-куәтле дә булган үзе. Алар, авылдан шундый кешеләр җыйналып, кышларын Казан каласына барып, байларга ялланганнар. Шунда ломовой извозчик булып, унар потлы әрҗәләрне ат арбасыннан җилкәләренә алып ташыганнар. Бик тә авыр хезмәт булган бу. Бабайның сукыраюы да шуннан, авыр күтәреп эшләгәнлектән, күзләренә көч килгән, диделәр. Мин белгән чагында ук бабай инде җитмеш яшен үткән карт иде, тиз арада вафат та булды. Хәтеремә әнә шулар гына кереп калган...

Әле яңа гына өйләнешеп бергә тора башлаган елларында безнең әти белән әни бердәм, тату яшәгәннәр. Өлкәннәр, күршеләр сөйләгәннәрдән чыгып минем күз алдыма алар тормышыннан кайбер күренешләр килеп баса. Менә җәйнең кояшлы, матур бер көне. Бабайлар өе каршындагы гына диярлек урнашкан бер иске йортның капка төбендә әле генә урманнан алып кайтылган нарат бүрәнәләр таралып ята. Әти озын буйлы, яшь, таза ир, ак күлмәгенең җиңнәрен сызганып куйган да, кулларына балта тотып, шул бүрәнәләрнең кайрысын чистарта. Ак яулыгын артка бәйләгән, ак алъяпкычлы әни дә шунда гына. Ул әтигә булыша, йомычкалар җыя. Алар бәхетле, гел сөйләшәләр, көлешәләр. Шулай булмыйча, үзләренә яңа йорт торгызалар, тиздән башка чыгасылар бит.

— Бу иске коймаларны сүтеп алырбыз, Хәбибрахман. Күз көеге булып тормасыннар. Яңа өебезне менә монда куярбыз. Менә бу якта агач бакча ясарбыз. Анда алмагачлар утыртып җибәрербез, Алла боерса,— ди әни, куллары белән күрсәтеп.

— Ә беләсеңме, Зәкия! Урам як койма өстенә челтәрле рәшәткәләр куйдырам әле мин. Әллә каян, ерактан ук күренеп, матур булып торсын! — ди әти.

— Лапасны ә-нә тегендә, арырак илтеп саласы булыр, Хәбибрахман. Ишегалдыбызда урын иркен булып калсын. Анда бәбкә үләннәре үсәр, Алла боерса. Мин шуларны яратам,— ди әни.

— Шулай итәрбез, Зәкия, барысы да син дигәнчә булыр,— дип килешә әти һәм кулындагы балтасын куеп, маңгай тирләрен сөртеп ала. Шунда алар иңгә-иңне терәп бүрәнә өстенә янәшә утыралар, бер-берсенә карап елмаялар. Ә тирә-якта йомычка исе, тәмле сагыз исе аңкый. Көн шундый матур, шундый рәхәт. Алда әле якты еллар, яңа йорт, балалар үстерәсе бар. Йә, Аллам, безнең әти белән әнинең дә нинди матур, бәхетле, нинди тату вакытлары булган бит!

Менә осталар килеп, яңа өйне күтәреп тә куялар. Шушы без хәзер яшәп яткан өйне. Юкса, ул берничә генә кешеле гаилә өчен бер дә кысан түгел. Әти сүзендә торган, чыннан да безнең өй каршысындагы койма өстенә бик матур челтәрле рәшәткәләр куелган, капкабыз да биек, түбәле итеп ясалган. Агач бакчасы да бар, ишегалды иркен, анда бәбкә үләне, хуш исле песи үләне үсә. Җәй көннәрендә каз бәбкәләре, тавык чебиләре рәхәтләнеп йөри.

Әти белән әни шушында көн итә башлыйлар. Әни беренче баласы Гомәрне, аннан бер ел үтү белән Әхмәтне дә таба. Болардан әтинең куанычы эченә сыймый, ул Әтнәгә барган саен балаларга, әнигә дә кочагы-кочагы белән бүләкләр алып кайта. Ул елларда безнең әти балаларны бигрәк тә яраткан, Гомәр белән Әхмәтне нәни вакытларында кулларыннан төшермәгән, сөя-сөя туймый торган булган.

Тик менә алар бергәләп ун-унбиш еллап гомер кичергәч, мин үз-үземне белә башлаганда хәл һич кенә дә алай түгел иде шул инде. Гаиләнең бик ишле, күп балалы булуы ул беренче карашка гына күңелле күренеш. Әгәр эчкәрәк кереп китсәң, бу хәл гаиләне авыр тормышка, фәкыйрьлеккә дучар итә. Ул элек тә шулай булган, хәзер дә шулай. Үзе кайчандыр балаларны бик яраткан, аларның бер-бер артлы дөньяга килүен хуплап кына торган әтиебез дә тора-бара бу ачы хакыйкатьне төшенеп алган, күрәсең. Төшенеп алган да, ни гаҗәп, төп гаепне үзеннән түгел, ә әниебездән, хәтта бездән — балаларыннан да күрә башлаган. Ул, үзе укымышлы, зиһенле кеше, ничек алай иткәндер, мин монысына әлегә кадәр төшенә алмыйм. Ни генә булмасын, ул безне дә, әниебезне дә яратмый иде инде. Без, өй тулы бала-чага, кич белән әтиебез мәктәптән төшкәндә куркып торабыз. Ул ишектән килеп керешкә уйнаулар, көлү тавышлары шунда ук туктала. Ул ишектән килеп керешкә бер вакытта да, беребезгә дә «улым!» яисә «кызым!» дип әйтмәде, башыбыздан сыйпамады. Кая ул! Безне күрәсе дә килми иде, ахры.

Кайчак юлында очрасаң кычкырып, тибәреп җибәрергә дә күп сорамый иде.

Бик беләмен ки, үз әтиең хакында болай сөйләшү килешкән эш түгел. Әмма ләкин хакыйкать барысыннан да кыйммәт. Эшнең асылы шунда ки һәм бу булачак аталар колагына керсен иде, әтиләрнең балаларына каты бәгырьле, тар күңелле булуы балаларның холкына, аларның киләчәк тормышларында бәхетле яисә бәхетсез булуларына зур йогынты ясый. Тискәре йогынты. Мин, әйтик, гомерем буена кыюсыз, куркак табигатьле булдым, үз-үземне яклый алмадым һәм, иң аянычы, үз бәһамны үзем белмәдем. Шушындый йомшак холыклы булуым белән күпме биеклекләргә күтәрелә алмыйча калдым, күпме мөмкинлекләрне югалттым мин?! Санап бетергесез. Һәм боларны әтиемнең үземә биргән «тәрбиясе» нәтиҗәсе дип саныйм. Инде дә килеп дөресен язганга үпкәләп ятмасын, урыны оҗмахта булсын. Аннары, үз холкыңны, үз йомшаклыкларыңны, үзең бик яхшы белә торып та, ансат кына үзгәртеп тә булмый бит әле. Сиңа бала чактан ук иңдерелгәнне үзгәртүе ай-һай кыен. Йомшак булмаска, тупас, нахал бәндәләр алдында каушап калмаска кат-кат сүз бирәсең дә, берәр кискен хәл алдына килеп юлыксаң, элеккеләреңнән дә битәр ахмаклык, кыюсызлык ясап куясың. Уйлыймын, монысын кайберәүләр үз тәҗрибәсеннән дә чыгып беләдер... Әти кешенең балаларына деспот булуы, аларның киләчәге хакында кайгырта белмәве ахыргы чиктә бик кыйммәткә төшә ул.

Безнең ишле гаиләбездә хәлләр менә шушылай иде. Кем белә, бәлки боларга әниемнең яшьләй килеш сәламәтлеген югалтуы, бик еш авыруы, Әтнәдәге сырхауханәгә барып ятулары, өйдә дә еш кына урын өстенә менүе дә сәбәпче булгандыр. Мин белгән елларда безнең әни үпкәсе белән төзәлмәс хаста иде инде. Бервакыт мин, биш-алты яшьлек малай, тетрәндергеч күренешнең шаһиты булдым. Әни урын өстендә яткан җиреннән әтигә эндәште:

— Хәлләрем бик авыр бүген, Хәбибрахман. Миңа аз гына ярдәм итсәң иде...

Авыз эченнән нидер мыгырдана-сукрана әти әнинең караваты янына килде, аңа урыныннан торырга да булышты, ишек катындагы чиләк янына алып килде. Шулчак әтиемнең әниемә әйткән сүзләре әле дә булса онытылмыйча йөрәгемә кадалып тора.

— Син... чирләшкә булдың. Син монда көтүе белән балалар үрчеттең. Сез минем бар тапканымны бетереп барасыз. Мин бу дөньяда рәхәт күрмим,— диде ул. Әллә нинди каты, рәхимсез тавыш белән әйтте.

— Менә мин үләрмен. Шуннан соң күрерсең рәхәтне,— диде әни, хәлсез тавыш белән.

Шунда әти иң авыр, рәхимсез сүзләрен әйтеп җибәрде:

— Тизрәк үлмисең дә ич ичмасам!

Йә, Аллам! Уйланам уйланам да, монда мин бөтен гаепне әтиебез өстенә генә дә ташлый алмыйм әле. Бу да хаклык булмас иде... Шулкадәр ишле гаиләне туйдыру хакына ул кысан, тузанлы авыл мәктәбендә балалар укыткан, шунда ук иртәнге дәресләренә әзерләнгән. Көннәр буе авыр хезмәт тыккән. Шуннан соң да аның да иркен, чиста, тыныч өйдә ял итәсе килгәндер. Укытучылар төсле итеп азрак матур киенәсе, хезмәтенә күрә тәмле ашыйсы, рәхәт күрәсе дә килгәндер. Болар бит әле адәм баласының бик гади, табигый, бик тыйнак кына ихтыяҗлары, алар өчен генә кешене гаепләү үзе бер гөнаһ булыр. Менә инде хәзер, бу вакыйгаларга күп еллар үткәч, мин күптәннән вафат әтиебезнең рухына үпкәли алмыйм. Юк, юк! Монда ул гына гаепле түгел. Монда тормыш барышы, бездәге мәңге яшәгән һәм яшәячәк, каһәр төшкере фәкыйрьлек, дөньяның авырлыгы гаепле.

Әлбәттә һәм Ходайга шөкер дип әйтәм, безнең әти белән әни гел алай булып кына яшәмәделәр. Минем күңелдә бүтән, якты хатирәләр дә саклана.

Җәйнең матур көне. Өйалды баскычында әти белән әни янәшә басып тора. Бәйрәмчә киенгәннәр, әти ап-ак күлмәктән, кара кәчтүмен иңенә салган. Әнинең өстендә ул заманда әле бик кыйммәтле һәм сирәк, үзенә бик килешеп торган вельвет кәчтүн. Алар бүген икәүләп Әтнәгә баралар. Зур акчалар алып кайтырга! Күп балалы булган өчен хөкүмәт әнигә елына бер мәртәбә пособие түли. Ул вакыттагы акча белән әллә өч, әллә биш мең сум. Ул заманда базарда сыер бер мең сум торганны исәпләсәң, чыннан да зур акча булган бу. Әни безнең башлардан сыйпый:

— Без кайтканчы әйбәт кенә торыгыз. Сугышмагыз, елашмагыз. Һәммәгезгә дә бүләк алып кайтырмын.

Без инде алар Әтнәдән әйләнеп кайтканны дүрт күз белән көтеп алабыз. Менә алар кайтып та җитәләр. Икесе дә елмая, икесе дә кочагы белән бүләкләр күтәргән! Кемгә матур күлмәк, кемгә чалбар... Тәмле конфетлар, прәннекләр... Бу көнне бөтен дөньясында бездән дә бәхетле кеше булмый инде.

* * *

Әниебезнең хәле тәки әйбәтләнмәде, ул сәламәтләнеп китә алмады. Дөрес, сугыш алды елларында ул яткан урыныннан торгалады, өй эшләрен карады, кайчак хәтта колхоз эшләренә, басуларга да чыгып йөри башлаган иде. Сугыш кузгалып китү белән безнең олыбыз Гомәр абыйны, унсигез яше тулмаган егет килеш, армиягә алдылар. Тиз арада фронтка, ут эченә җибәргәннәр. Авылдан китеп берничә генә айлар үткән иде, абыйдан хатлар килү кисәк кенә тукталды. Безнең йомшак күңелле әниебезгә шул җитә калды. Ул тагын урын өстенә егылды.

Әниебез 1942 елның җәй урталарында, чалт иткән аяз, кояшлы бер көндә, иртәнге сәгать уннар тирәсендә вафат булды.

Ул көнне әни бик иртә, әле Зәйтүнә апай көтү куган вакытта ук урыныннан торып, өйалды баскычына чыккан. Зәйтүнә апай безнең иң олы кыз туганыбыз, унбиш яшьләрендә иде.

— Әни, ни эшләвең бу? Ник бу кадәр иртә торып чыктың? Көн дә бик салкын ич әле,— дигән ул.

Әни аңа җавап бирмәгән. Хәлсез куллары белән таянып баскычка торып баскан. Аның йөзенә әллә нинди куркыну, газап билгеләре чыккан булган.

— Кызым! Балаларым минем! — дип кычкырып җибәргән ул җан ачысы белән һәм калтыранган куллары белән башындагы ак яулыгын тартып алган да, аны авыру кешедән һич тә көтелмәгән, гайре табигый көч белән читкә атып бәргән. Аннары тәмам хәлсезләнеп, киң баскыч

тактасына авып төшкән. Бу хәлләрне күреп торган Зәйтүнә апай да ни эшләргә дә белмичә, үкереп елап, өйгә килеп керде.

— Торыгыз, җәтрәк торыгыз! Әниебез... баскыч төбендә ята. Әнигә әллә ни булды! — дип кычкырып җибәрде ул.

Без, җыен бала-чага, бик куркынып, йокыбыздан уяндык. Ул көнне әти дә өйдә түгел, бик иртә торып, колхоз эшенә менеп киткән иде. Җәтрәк баскыч төбенә чыктык та, як-ягыннан күтәреп, әнине өйгә алып кердек, түрдәге үз караватына салдык. Әниебезнең күзләре йомык, ул инде суламый да, ул инде үлгән кебек иде! Без шым булып, тавышланып суларга да куркып, аның караваты янына тезләндек. Без өмет белән тилмереп шактый көтеп торгач кына, әни күзләрен ачып җибәрде.

— Минем караватымны бакчага чыгарып куйсагызчы, балалар. Мин кояшны карап ятар идем,— диде ул, чак кына ишетелерлек итеп.

Без аны бакчага чыгарып салдык. Әни аяз, чиста зәңгәр күккә карап ятты. Анда очкан карлыгачларга, бик биектә анда-санда күренгән ак болыт йомарламнарына бик озаклап, туймаслык булып карады ул. Аннан кояш нурларына коенган түбәләргә, агачларга, бакчадагы түтәлләргә, чәчәкләргә карады. Боларның барчасын да яңа гына, беренче тапкыр күргәндәй сокланып, рәхәтләнеп карады. Әниебезнең йөзендә инде бернинди сагыш та, уфтану билгеләре дә юк, ул инде тып-тыныч, сабыр иде. Ул инде, күрәсең, үз язмышына буйсынган иде. Озак вакытлар шулай яткач, ул безгә күз төшерде.

— Барчагыз да мондамы? Балаларым!.. Һәммәгез дә монда килегезче,— диде.

Без аның караваты янына түгәрәкләндек. Сеңлебез Асия бишегендә өйдә ята, Әхмәт абый каядыр өйдә юк иде. Әни безнең һәркайсыбызга аерым текәлеп, озак итеп карап ятты. Аннары керфекләрен түбән төшерде.

— Шиһап абыегызны чакырып төшегез. Миңа ясин чыксын. Мин үләм инде,— диде. Шушы сүзләрне тып-тыныч, гади итеп, ачык итеп әйтте.

Шиһап абзый, әниебезнең бертуган абыйсы, кулына Коръән тотып, тиз арада килеп тә җитте. Әллә нинди бик моңлы, безне тетрәндерә торган, шул ук вакытта шомлы да тавыш белән ясин чыга башлады. Тик ул үзенә тиешлесен укып бетерә алдымы икән, белмим. Әниебез кисәк кенә урыныннан аз гына күтәрелде дә күзләрен зур итеп ачты, безгә карады. Аннары гәүдәсен ничектер сузып, озын булып ятты. Бернинди хәрәкәтсез калды.

— Әниегез үлде, балакайлар,— диде безгә Шиһап абзый.

Ул арада югары очтан әти дә кайтып җитте. Шунда мин үземне тетрәндергән тагын бер хәлне күрдем. Әтиебезнең дә йөзендә тирән кайгы, күзләре тулы яшь иде!

Инде әниебезне бик күп кешеләр күтәреп капкадан алып чыгып киткәндә Зәйтүнә апай белән Фаяз абый бик яман җылый башладылар:

— Алып китмәгез безнең әнине... Бирегез безнең әнине!..

Аларга кушылып без, кечерәкләр дә елый башладык. Яшьләй мәрхүмә булган әниебезне, өелешеп ятим калган безне дә җәлләптер инде, шунда ишегалдына җыелган апалар, бар халык елый иде.

Тугыз балага тормыш биреп, үзе бу якты дөньядан китеп барганда безнең әниебез Зәкиягә нибары кырык ике яшь булган икән...

## Әнисез тору

Үзе ятимлекне кичермәгән, гомере буена әни җылысын, аның даими ярдәмен тоеп яшәгән кеше ана дигән бөек затның чын кадерен дә, аның асылын да беркайчан да белеп бетерә алмыйдыр. Әни бит әле ул авыр минутларында син килеп сыена алган, назлы

куллары белән башыңнан сыйпап сине юаткан, күңелеңне тапкан бер шәфкать иясе генә түгел. Ул синең вакытында тамагыңны туйдыручы, өс-башыңны караучы, ертылса-ямап, керләнсә юып кидерүче, сине үстереп, гакыл һәм хәер-фатиха биреп, олы тормыш юлына чыгарып җибәрүче. Җыеп кына әйткәндә, ул сине бу дөньяда яшәтүче! Карагыз сез, ошбу Җиһанда адәм баласы гына түгел, ә төрле җанварлар, терлекләр, кош-кортлар — барчасы, барчасы да ана ярдәменә таяна. Әгәр аннан мәхрүм кала икән, зур авырлыклар кичерә, хәтта һәлак булырга да мөмкин.

Әнисез торып калгач, безнең тормышның да рәте-чираты китте дисәм, бу һич тә арттыру булмас.

Ул еллардагы хәлләрне билгеле бер тәртипкә салып, эзлекле генә итеп сөйли алмам. Һәм моның кирәге дә юктыр. Кая, ун-унике яшьлек бер малай идем. Андый чагында әле адәм баласы гамьсез, илтифатсыз, язмышы ни җибәрсә, шуңа риза булып торган бер мәхлук бит. Ул еллардагы вакыйгаларны мин күптән күргән, инде онытылып та килгән төшләр кебек, өзек-өзек итеп кенә күз алдыма китерәм.

Ягылмаган салкын, яман да шыксыз, күңелсез өй эче. Кыш булса кирәк: тәрәзәләр бозланып каткан, ярым караңгы. Әти көнозын үзенең мәктәбендә, инде Әхмәт абыебыз да сугышка китеп барды, ундүртунбиш яшьлек Фаяз абый да өйдә түгел, ул эштә, колхоз атларын карый. Уналты яшьлек, йортта иң олы булып калган һәм безне карарга тиешле Зәйтүнә апай да өйдә түгел, каядыр шунда урамда, күршеләрдә йөри. Өйдә без — кечкенәләр генә. Алты-дүрт яшьлек Ләлә белән Кларaның үз дөньялары. Алар өсләренә әти белән Әхмәт абый киеп туздырган иске, таланып беткән пинҗәкләрне киеп, идәндә утыралар. Озын җиңнәре кулларыннан үтеп салынып төшкән, алар бу озын җиңнәрне әледән-әле кош канаты төсле итеп һавада җилпеп алалар, һавада әйләндерәләр. Салкыннан кызарган ялан тәпиләрен пинҗәк итәкләре астына яшереп, җылытмакчы булалар да, әмма бу бик кыен эш шул. Аяклар итәк астыннан чыга да китә, чыга да китә. Алай да Ләлә белән Клара тик кенә утырмыйлар, аларның үз шөгыле бар. Ләлә үзе бик яраткан нәни, бик матур һәм йомшак песи баласын күкрәгенә кыса, сыйпап кадерли. Шунда авыз эченнән генә көйләп утыра:

— Вуйвуема димәгей, Вуйвуема димәгей...

Бу чит тел сүзләре түгел, Ләләнең «матурыма тимәгез!» дигән сүзе. Ул аны мәче баласын яратуыннан, аны бүтәннәр тиюдән саклап, төрлечә кабатлый-кабатлый әнә шулай адәм аңламаслык сүз тезмәсенә әйләндергән. Ләләнең чәчләре бөдрә, як-якка тырпаеп торалар, ул сиңа зур соры күзләрен тутырып карый, бик тәэсирләнүчән, йомшак, сабыр күңелле кыз. Әгәр дә кем дә булса шул мәче баласын аягы белән тупас итеп төртеп җибәрсә, яисә бүтәнчә рәнҗетсә, Ләлә ул кешегә кычкырмый, тавышын күтәрми. Күзләрен тутырып ул кешегә бер карап кына ала да, мәче баласын күкрәгенә кыса, бер кырыйга китә, шунда аны сыйпап, кадерләп утыра. Кайчагында шыпырт кына итеп елап та ала. Менә шуның белән ул синең күңелеңне әйләндереп куйгандай итә. Мәче баласыннан бигрәк Ләләнең үзен җәлләп күзләреңә яшь тула. Нәни чагында Ләләне әниебез ялгышлык белән бишегеннән идәнгә егып төшергән. Шуннан бирле аның бер аягы бераз зәгыйфьләнеп калган. Ул йөргәндә бу хәл сизелеп тора.

Сеңлебез Клара төрле әйберләрне, хәтта утын агачларын да чүпрәккә төреп, бер башына иске оеклар чорнап, курчак итеп уйнарга ярата. Кларабыз бик матур, түгәрәк йөзле, кашлары сызылып киткән, коңгырт күзләре бик тере, ялт та йолт итеп уйнаклап кына торалар. Шау-шуны ярата торган батыр кыз. Аның инде шул курчагына тия дә, кулыннан тартып та ала алмыйсың. Юкса әлеге курчак булып хезмәт иткән утын агачының шап итеп маңгаеңа менеп төшү ихтималы да бик зур. Клара ул курчаклары белән туктаусыз сөйләшә, үзе чырык-чырык көлә, аларны

тәртипкә чакырып, тиргәп, кыйнап та ала. Яисә аларны бөтенләй читкә атып бәрә дә, үзе сикерә-сикерә читкә китеп уйный башлый.

Иң кечкенә, әле ике яше дә тулмагандыр, сеңлебез Асия гел бишектә ята. Әле үзе кечкенә булса да, ул инде ошбу дөньяның ни икәнен сиземләгән, ни дә булса сорап, таләп итеп, елап ятуның бернинди файдасыз, мәгънәсез бер эш икәнен төшенеп алган. Юк, инде ул хәзер кешеләрне борчымый. Бишегендә кайчагында авыз эченнән нидер сөйләнеп, шыпырт кына ята. Ни хәл итсен, аны караучы да, тәрбия кылучы да юк шул. Тик ул бер җаен тапкан, йокысы килә икән, бишегендә гәүдәсен сикертеп үз-үзен тирбәтә башлый һәм тиз арада йоклап китә. Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү менә шушы була торгандыр инде.

Никадәрле салкын, күңелсез, тамак та ач булмасын, бала дигәнең гел каңгырып, тик кенә утыра алмый. Нинди дә булса шөгыль таба. Миннән кече энем Рифат белән без өй эчендә тау шуабыз. Ничек итеп дигәндә бик ансат һәм гади генә. Ул замандагы агач караватларның төбе вак такталардан тора иде. Без шул такталарны сүтеп алабыз да, авыш итеп сөяп куябыз, аннары шул такталардан менеп, идәнгә шуып төшәбез. Табаныбыз белән. Иң әүвәле мин, аннары Рифат. Күпме тапкыр кем шуганы санап барыла, хәрәмләшү юк. Дөрес, мин кайчак берьюлы ике мәртәбә рәттән дә шугалыйм. Тик Рифат моңа бер дә ачуланмый, ул бүтәннәргә юл куя белә торган, әйбәт күңелле малай. Аңа бер кызыклы нәрсә сөйли башласаң, ул инде алдан ук елмаеп тора, күзләрен кысып, дәү итеп көлә. Рифат, гомумән, җыен юк-бардан да кызык таба белә, күп көлергә ярата. Әмма аның шактый сәер гадәтләре дә бар. Еш кына ул бар уенын, шөгылен, безне дә ташлый да, бер читкә китеп бара. Анда стенага таба борылып, бер үзе генә утыра. Мондый чакта инде Рифат үзенең бер аерым, сихри, хыялый дөньясына чума. Ул инде берни күрми, ишетми, күзләрен йома да башын як-якка селтәп әйләндерә. Авыз эченнән ниләрдер көйләп тә утыра. Тик бу көйләү ничектер, ыңгырашу кебек килеп чыга.

Безнең салкыннан, янибызда олылар, дөресен генә әйткәндә, әниебез булмаудан да әллә ни кайгыбыз юк. Соң, бала кеше әле тегесен-монысын уйлап хәсрәтләнә беләмени? Алай да барыбызның да гел исенә төшеп, борчып торган бер нәрсә бар. Ул да булса тамак, тамак! Даими рәвештә ашыйсы килү. Менә монда инде әни бар вакытлар, ул пешергән әйберләр, әни үзе дә әледән-әле искә төшә. Өйдә төрле хыяллану сүзләре ишетелә:

— Их, әле дә безнең әниебез булса икән ул.

— Әни үзе бар чагында мичкә дә ягып җибәрә иде. Мич янып торса, өйдә шундый җылы була ич.

— Мичкә бәрәңге тәгәрәтсә икән диген син!

— И, пәрәмәч пешерсә икән диген син. Иң тәмлесе пәрәмәч инде аның. Әни аны күп итеп пешерә иде, бөтенебезгә дә җитә иде.

— Их, бер сынык кына ипи булса икән ул.

— Әни безнең ипи дә сала иде...

Без әнә шулай хыялланабыз. Тик, юк шул, безнең өйдә берни дә юк. Җылы да, пәрәмәч тә, сыңар сынык ипи дә юк. Әни үзе дә юк. Без инде әниебезне онытып та бетердек бугай. Без хәзер инде Зәйтүнә апайга гына карап торабыз. Көн дә саен аның җәтрәк өйгә кайтканын көтәбез. Ул кайтып керсә, хәлләр бөтенләй үзгәреп китә. Ул учакка ягып җибәрә, ашарга әзерли. Кайчак Рифат сагаеп кулын күтәрә, әйтеп куя:

— Туктагыз әле!

Без уйнаудан тукталып, барчабыз аңа текәләбез.

— Нәрсә бар?

— Капка ачылган тавыш ишетелде. Зәйтүнә апай кайта бугай.

Барыбыз да шым булабыз, тыңлап торабыз. Юк шул, тышта җил генә ул капканы шыгырдатып уйный. Ә Зәйтүнә апаебыз әле кайтмый да кайтмый.

Без шулай көтә, зарыга торгач, кич тә килеп җитә, өй эче караңгылана, тагын да салкынлана. Рифат инде безнең белән уйнамый, бер читкә китеп, башын әйләндереп утыра. Ләлә белән Клара да тынып калалар, аякларын пинҗәк итәгенә яшереп, тезбашларын кочаклап тик кенә утыралар. Аларның дәү булып ачылган күзләре караңгылыкка текәлгән. Шулай утыра торгач, Ләлә кисәк кенә шыпырт итеп, әллә нинди шомлы итеп әйтеп куя:

— Абау, нәрсә бар анда?

— Кайда? Кайда ул?—дибез без, дәррәү әсәренеп.

— Әнә анда, мич артындагы кәзәлектә...—ди Ләлә. Аның тавышында курку ишетелә.

Без барыбыз да шомланып, мич артындагы кәзәлеккә текәләбез. Ә анда караңгыдан бүтән берни дә күренми.

— Бернәрсә дә юк анда. Юкны сөйләп торма!—ди Клара.

— Бар инде, бер кеше бар анда. Ул күзләрен ялтыратып бая миңа карап торды. Аның күзләре шундый да зур, аның күзләре ачулы иде...—ди Ләлә һәм шунда инде безнең барчабызны да курку тотып ала. Без тып-тын булабыз. Тик бишектәге Асиянең генә бернинди дә хәбәре юк. Ул «ыггы-ыггы» килеп, үзе белән сөйләшә, үз дөньясында ята бирә.

— Әй лә, бу Зәйтүнә апайны! Кайтмый да инде җәтрәк,—ди Ләлә еламсырап.

Инде өй тәмам караңгылангач, без туңып зарыгып беткәч, барыбыз да шыңшый башлагач, киң итеп ишек ачылып китә. Бик ашыгып, атылып-бәрелеп Зәйтүнә апай кайтып керә. Өйдә мич кучкарында торган бердәнбер җиделе керосин лампасына ут алына. Зәйтүнә апай инде бит урталары алсуланган, буйга җитеп килгән кыз, күз карашлары бик тере, хәрәкәтләре кискен.

— Ни эшләп ятасыз сез бу өйдә?! Ул караватны ник сүтеп ташладыгыз? Такталарын хәзер үк урынына куегыз. Әти төшеп килсә, хәзер кирәгегезне бирә бит, ристаннар!—дип тиргәп ташлый ул безне һәм әйтеп куя.— Хәзер бәрәңге пешерәм.

Менә бу сүз инде безнең өчен куаныч, безнең эчләргә җылы сала. Хәтта сап-салкын өй үзе дә җылынып киткәндәй була.

— Радик хәзер үк лапастан утын алып керә. Рифат идән астыннан бәрәңге алып менә!—дип, безгә боерыклар бирә Зәйтүнә апай һәм учакта ут тергезә башлый. Өйдә олы хәрәкәт куба. Рифат дөбердәтеп идән асты капкачын ача да түбәнгә чума. Мин ялан аякларыма иске, зур галошлар киеп, лапаска чыгып китәм. Бергәләп эшкә керешәбез.

Инде учакта ут дөрләп өйдә хәйран күңелле булып киткәч кенә, мәктәптән өйгә әти кайтып җитә. Безнең әти үзе озын буйлы, зәңгәр күзле, матур кеше. Аның туры борынлы йөзе кызарган, озын мыекларына ап-ак бәс кунган. Әмма әти өйгә килеп керде исә без ничектер куркынып, чикләнеп калабыз. Аның зәңгәр күзләре кырыс итеп карыйлар. Без аның бу күзләренә бик чалынмаска тырышабыз. Анысы, әти кешенең йортта кырыс, абруйлы булуы да кирәктер. Тик аның күңелендә, шул кырыслык янәшәсендә, үз балаларына карата ярату, шәфкать хисләре дә булырга һәм балалар бу җылы хисләрне сиземләргә дә тиештер. Тик әтиебез белән безнең арада бернинди җылылык, чын күңелдән аңлашу, яратышу, сөйләшү юк иде шул. Бу хәл безнең ятимлекне тагын да тирәнәйтә төшкәндер инде. Юкса, киләчәк тормышыбызда күңелләргә ул кадәр тирән уелып калмас иде.

Әти өстен чишенә дә беркемгә бер сүз дә әйтмәстән янган учак каршысына килеп утыра. Зур итеп тәмәке чорнап кабызып җибәрә. Без аның учак янына килеп утыруын яратмыйбыз. Ул йөткерә-йөткерә тәмәке тарта, бездән учакның җылысын каплый, инде учак үзе дә бик начар яна, ашарга да озак пешәдер кебек тоела безгә... Әтинең бөгелгән аркасына курку белән, төрле үртәлүле уйлар белән карыйбыз.

Ай бу дөньялар!

Ул арада Фаяз абый да өйгә кайтып керә. Көнозын конюшнидә, атлар арасында, салкында, тирес-салам ташып йөргән җиреннән. Ул тәмам ачыккан, туңган, өстендә юка гына иске сырма, аякларындагы чабаталары шакырдап каткан. Талчыбыктай нәзек булып үсеп килгән бер яшь егет. Аз гына сипкелле аксыл йөзе ачулы. Ул ишектән килеп керешенә кулындагы чыбыркысын мич артына атып ташлый да кычкырып та җибәрә:

— Ашарга булдымы әле?!

— Бик ашыкма әле, өлгерерсең,— ди әти.

— Мин монда эштән кайткан кеше! Мин анда... көнозын атлар карап, ач көе...— дип тузына башлый Фаяз абый еларга җитешеп. Ул өйдә әтидән курыкмыйча үз сүзен әйтеп сөйләшә алган бердәнбер кеше. Фаяз абыйның килеш-килбәтендә инде хәзердән үк бабай чалымнары бар, холкы да бабайныкына тартым, бик тиз кызып китә.

Менә берзаман өстәлгә зур табак белән бәрәңге килеп утыра. Ярып пешерелгән, парлары чыгып торган, галәмәт тәмле бәрәңге. Җәтрәк барчабыз да өстәл янына җыелабыз, беркемне дә чакырып торасы түгел. Һәркемнең кулы җитез эшли, тиз-тиз генә табакка үрелә. Һәм шундый зур табак әллә ни арада гына бушап та кала. Тамаклар туймый инде безнең, кая ул, тик алай да эчкә кайнар ризык кергәч, күңел була.

Көндезләрен бишегендә хәйран тыныч кына ята торган Асиябезгә кичләрен әллә ни була. Ул ни сәбәптәндер тиктомалдан көйсезләнә, борчыла башлый. Аңа ана тәрбиясе, ана назы кирәк булгандыр инде, күрәсең. Ул тавыш күтәрә, елый. Зәйтүнә апай каткан ипи кисәкләрен чәйнәп, марляга төрә, имезлек ясый, аны Асиягә бирә. Аптырагач, астын да корытып сала. Юк, барыбер тынычланмый, елавын белә нәни бала... Без аны төннәрен чиратлап тирбәтәбез. Асия сеңлемне багып, аны тирбәтеп мин үзем дә күп төннәрне йокысыз үткәрдем.

Безнең өчен айга бер тапкыр бәйрәм була иде. Ул да булса күрше Сәет абзыйларның мунчасын ягып кергән көн. Аны инде барыбыз да көтеп алабыз. Фәкыйрь киемле, көннәр буе салкында туңып йөргән балалар өчен эссе мунчага кереп юыну үзе зур рәхәт бит ул. Мунчага без, кечкенәләр, әти белән барчабыз бергә керәбез. Әти безне юындыра, башыбыздан су койганда әмер биреп тора:

— Күзләреңне ю!

— Колак тишекләреңне...

— Бот араларыңны ю!

Аннан берәм-берәм киендереп, чыгарып җибәрә. Мунчаның тәмле исе тәнгә, киемнәргә сеңеп кала, берничә көн бетми йөри.

Әнидән башка без әнә шулай яшәдек.

Авырмы-җиңелме, ачмы-тукмы, бу тормыш та ярыйсы иде әле. Бик каты сугышлар барса да, безнең өйдә әти бар, шулай булгач, билгеле бер тәртип тә, безне оештырып яшәтүче дә бар иде. Әмма ләкин бу ярты, китек бәхет тә озакка бармады. Әнинең вафатыннан соң бер ел үтteме икән, җәйге көннәрнең берсендә әтиебез өйгә бик күңелсез, борчулы төстә кайтып керде.

— Эшләр бик хөрти бит әле, балалар. Сез үзегез генә торып каласыз бит әле. Мине дә солдатка алалар...— диде ул. Бу юлы йомшак итеп, ничектер, безне үз итеп әйтте. Безнең өчен бик кайгырганы күренеп тора иде. Бу инде сугышның иң кызган чагы, авылдан фронтка китүчеләр дә, инде үлгән хәбәре килгәннәре дә хисапсыз, безнең Гомәр абый белән Әхмәт абый да инде күптән сугышта, хәтерем ялгышмаса, алардан хат-хәбәр килү дә туктаган иде. Һәр йортны, бөтен авылны кайгы-хәсрәт баскан иде.

Әти куллары белән башын тотып, гаять аптыраган төстә, бик озак уйланып утырды. Ул күзләрен бер ноктага текәгән дә әллә үзенә, әллә безгә бер үк сорауны кабатлый иде:

— Үзләре генә ничек көн итәрләр икән инде болар. Нәрсә була соң инде бу? Нәрсә була бу, балалар?

Соң, без балалар нәрсә әйтик инде.

Шулай үзалдына сөйләнеп утыра торгач, әти урыныннан торды, ишекле-түрле йөренде. Аннары кулына дәфтәр алды.

— Мин инде өлкән яшьтәге кеше. Ут эченә үк илтеп кертмәсләр дә әле... Фронтларда хәлләр үзгәреп китсә, бәлки исән килеш әйләнеп тә кайтырмын. Сезнең бәхеткә...— диде ул һәм аның йөзе, сүзләре тагын кырыс төс алды. Һәр сүзен боерык биргәндәй саллы итеп әйтте.— Ә сез монда мин киткәч, тәртипле генә буласыз! Тырышып эшлисез, йорт-җирне, мал-туарны карыйсыз, бер-берегезнең сүзен тыңлыйсыз. Мин өйдә чакта булган шикелле итеп... Хәзер мин сезгә барысын да язып калдырам. Өйдә кемнең нәрсә эшләргә тиеш икәнен күрсәтеп. Сез шуларны яттан өйрәнәсез, барысын да үтисез. Мәктәптәге эчке тәртип кагыйдәсен үтәгән шикелле. Карагыз аны!— дип кисәтте ул безне һәм, өстәл янына утырып, дәфтәренә нидер яза башлады. Аннары түрдәге ике тәрәзә арасына, иң күренә торган төшкә кушбит кәгазь ябыштырып куйды. Анда кемнең нәрсә эшләргә тиеш икәне язылган иде. Бик ваклап-төякләп. Бик үк төгәл түгелдер, әмма ул язманы мин әле дә булса хәтерлим.

«Кемгә ни эшләргә:

**Фаяз.** Өйдә баш кеше, аны барысы да тыңлый. Утын әзерли. Айга бер тапкыр мунча яга. Кара аны, мунча исле була күрмәсен, анысын җентекләп тикшер. Радик белән Рифатны үзең юындырып чыгар. Карагыз аны, бетләп ятмагыз! Фаяз сыер белән сарыкларга азык бирә. Кабатлап әйтәм, ул өйдә баш кеше, аны тыңлагыз.

**Зәйтүнә.** Сыерны сава, ашарга пешерә, кер юа, су китерә, өс-башыгызны ямап кидерә. Асияне карый. Синә эш күп, кара аны, иренмә! Урамда озаклап биләмдә йөрмә. Син әниегез урынында калган кеше, шуны бел. Зәйтүнә апаегызга барыгыз да булышасыз, аның да сүзен тыңлыйсыз.

**Радик.** Өйдә идәнне себерә, чиста тота. Терлек абзарларын җыештыра, лапасны себерә, тәртиптә, чиста тота. Өйгә утын кертә, йомычка җыя, Рифат белән бергәләп алар бәрәңге чүбен утыйлар, төбенә өяләр, ашка яңа бәрәңге казып алалар. Олылар ни кушса да, карышмыйча үтиләр.

**Рифат.** Бәрәңге әрчи, тавыкларны ашата, йомыркаларын җыеп ала. Бәрәңге бакчасын карауда Радикка булыша.

Радик белән Рифат мәктәптә тырышып укыйлар. Рифат, кара аны, ялкауланма, беләм мин сине...

***Ләлә белән Клара.*** Өйне, өйалдын, чиста, тәртиптә тоталар, идәнне себерәләр, савыт-сабаны юалар, мәчене ашаталар. Асияне карауда Зәйтүнә апайларына булышалар.

Карагыз аны, мин әйткәннәрне барыгыз да тыңлагыз! Үзегез өчен бит!»

Әти менә шушыларны язып калдырган иде.

Үтәдек микән, тыңладык микән без бу кагыйдәләрне? Юктыр, гәрчә өйне, лапасларны чиста тотарга тырышсак та, абзардагы малларны карасак та, без әти кушканнарның барысын да үтәп бетерә алмаганбыздыр. Инде әти дә солдатка китеп өйдә үзбуйлы булып калгач без, дөресен генә әйткәндә, шактый иркенлеккә чыктык. Рифат белән мин, үзебезгә дигән эшләрне аннан-моннан башкарабыз да, җәтрәк урамга, иптәш малайлар янына чыгып таярга ашкынып торабыз. Ләлә белән Кларaның үз дөньялары, алар шул мәче балалары, курчаклары белән мәшгуль. Зәйтүнә апай, җанашым, ул чагында үзе дә биләмне бик ярата, кайчак аны ашарга әзерләргә дә урамнан эзләп кайтырга туры килә. Фаяз абый исә көнозын колхоз эшендә... Безнең өстәге киемнәр юылмаган, керле, ямалмаган. Үзебез дә битне-кулны юньләп юмаган, даими ач. Ни кыл-

сак, кая барсак та үзбуйлы, шактый кыргыйланып киләбез бугай. Кайбер күрше хатыннар, аеруча каршыдагы тыкрыктан бер апай бездән курка ук башладылар. Бакчаларына, ачык тәрәзәдән өйләренә кермәгәйләре, базларына төшеп катык-сөтләрен эчмәгәйләре дип курыктылар инде алар. Бездән гел шикләнеп йөрделәр. Теге «тыкрык апай» берничә тапкыр безгә килеп зәһәрен чәчеп тә китте.

— Сез... җиберләр! Алла боерса сез ачтан үләрсез әле. Сез чукынчыклар кырылып бетәрсез әле. Аллаһы боерса! — дип теләде ул.

Кемдер бу «тыкрык апайлар»ның ачык тәрәзәсеннән өйләренә кереп, өстәлдән бер телем ипиләрен урлап чыккан. Өй бүрәнәсендә ялан аяк эзләре калган. «Тыкрык апай» шул эзне безнең Рифатныкына юрап йөрде. Хатыны үлгән бер абзыйга икенче хатын булып килгән бу апай үги балаларын каһәрләп, елатып ятты. Һәм ул безнең Рифатка карата да нахак сүз сөйләде. Көннәр буе урамда уйнап, койма башларына менеп ач көе йөрсәк тә, без адәм баласы бара торган иң түбән адымга, караклыкка бармадык. Безнең гаиләдән беркем дә, бер вакытта да!

Ничек кирәк алай без бу җәйне үткәреп җибәрдек. Көз кергәч, үзебез бәрәңгеләрне дә җыйдык. Ул елны бәрәңге бик күп булды, аның бер өлешен лапас янына тирән баз казып, шунда күмдек. Кыш чыгар өчен. Әмма менә үзебез кышны ничек чыккан булыр идек, анысын әйтә алмыйм.

Көзге көннәрнең берсендә безнең өйгә мәрхүмә әниебезнең бертуганы Алма апай төште. Алма апай түгәрәк йөзле, тәбәнәк кенә хатын, бер күзенә ак төшкән иде. Аның ире инде күптән вафат, олы улы Сәлимҗан сугышка киткән, шактый иркен өйләрендә алар кызы Сабира апай белән икәүләп кенә торалар иде. Алма апай безнең идәне күптән юылмаган, теләсә кайда теләсә ни аунап яткан тәртипсез, шыксыз өебездә әрлебирле йөренде. «Ай, Аллам, ай, Аллам!» дип авыз эченнәнниләрдер сөйләнде. Аннары караватта утырып ниләрдер сөйләнде, куллары белән йөзен сыпырып алды.

— Сез... сентябрь чебешләре! Монда болай яшәп ятсагыз, кырылып та бетәргә ихтимал лабаса. Тәмам керләнеп, бетләп бетәсез икән...— диде ул һәм тагын бераз уйланып утыргач, тәвәккәл төстә әйтеп куйды.— Кышны чыгарга безгә менәрсез, балакайлар! Сезне монда калдырып булмый икән. Җәфагыз күп булса да, бергәләп торырбыз шунда. Үлмәбез әле,— диде ул һәм эшне озакка сузмыйча, өйдәге кайбер әйберләрне төенли дә башлады.

Алма апайларга күченеп менәбез! Бу шыксыз, салкын өйдән җылы, матур өйгә күчәбез. Безләрдәге шатлык-куанычның иге-чиге юк иде. Ләлә белән Клара баскан урыннарында сикергәләп такмак әйтә башладылар:

— Мен-әбез, мен-әбез! Алмапайлар өенә...

Бу хәбәргә Фаяз абый белән Зәйтүнә апайлар да каршы килмәделәр, куандылар гына бугай. Фаяз абый тиз арада конюшнядан ат та җигеп төште. Кайбер кирәк-ярак әйберләрне ат арбасына төядек тә без шул көнне үк үзебездән өч-дүрт өй аша гына торган Алма апайларга күчендек.

Хәзер бик ачык хәтерләмим, безгә Алма апайларда да әллә ни иркен дә, рәхәт тә булмагандыр инде. Өйләре дә үзебезнекеннән әллә ни дәү түгел, җитмәсә, түрдәге караватта авыру Сабира апай да гел ятып кына тора иде. Әмма мин әле дә булса гаҗәпләнү һәм рәхмәтле хисләр белән исемә төшерәм, әрле-бирле дин сабагыннан бүтәнне берни укымаган, гомере буена бил бөгеп эшләүдән башканы белмәгән шушы гади авыл хатыны менә дигән педагог булган бит! Дөрес, аның тәрбия ысулы да бик үзенчәлекле, монда сине нинди дә булса үгетләүләргә, сорап-юмалап торуларга бернинди урын юк. Өлкәннәр әйткәнне һичсүзсез һәм кичекми үтисең. Әгәренки сүз озайтып, каршы килеп торасың икән, яңагыңа берне чалтыратып җибәрү. Билгеле, педагогия фәне тарафыннан ике куллап

кире кагылган, каты тәнкыйтьләнгән ысул. Тик, үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, бик үтемле дә ысул. Юкса, бездә нәрсә иде? Без инде өлкәннәрнең сүзен тыңлау гына түгел, бер-беребезне олылау, үзеңнән зурларга «абый» яисә «апай» дип әйтүләрне дә онытып бетергән идек. Безнең арада «Фаяз» дә «Зәйтүнә!» генә иде. Алма апайларга менгән көнне үк мин үземнән дүрт яшькә олы туганым Фаяздан нидер сорамакчы идем.

— Фаяз, кара әле монда...— дип әйтә башлавым булды, яныма җилтерәп Алма апай килеп тә җитте. Аның ак төшмәгән сыңар күзе хәтәр ялтырый иде.

— «Абый» дигәне кайда аның, кяфер? Абые кайда? — дип сорады ул.

— Фаяз, кара әле...— дип кабатладым мин, күнегелгән гадәттән тайпыла алмыйча.

— «Абые» кайда дим? Әйт хәзер үк! — дип боерды Алма апай һәм мин ык-мык килеп торган арада... үзенең катып беткән нәни йодрыгы белән маңгаема берне кундырып та алды. Йодрык нәни, әмма күздән яшел утлар күренде.

— Фаяз... абый...— дидем мин, көч-хәл белән. Беләсезме, шулай әйтеп иялэнмәгәч, яман да кыен икән ул. Һич кенә тел әйләнмичә азаплый.

Алма апайның бу бәрәкәтле кулы, язмыш бабай үзе җибәргән яшен кебек, әледән-әле бүтәннәрнең дә баш очында уйнаклап алгалады. Һәм ни диярсез? Күп дигәндә бер атна эчендә без һәммәбез дә бер-беребезгә «абый», «апай» дип эндәшергә тәмам күнегеп тә җиттек. Аллага шөкер, ошбу сабак безгә гомерлек булды, әле дә булса шулай эндәшәбез.

Аларга менгәч, беренче мәртәбә өстәл янына ашарга дип килеп утырган идек, Алма апай безне дәррәү урыннан торгызды.

— Ул шапшак кулларыгызны кем юар? Әнә бит мич янындагы комган, җылы су салынган. Ни эшкә дип куелган ул? Юылмаган кул белән өстәл янына утыру гадәтсезлек, зур гөнаһ ул. Моннан ары кулларыгызны юмый торып табын янына килмисез! — дип белдерде ул катгый төстә. Һәм менә инде ярты гасырдан артык вакытлар үтеп китте. Минем бер генә очракта да кулымны юмыйча торып, аш өстәле янына килеп утырганым юк.

— Ризык җыйгач, ашап тамагын туйдыргач, адәм баласы дога кылсын, дигән. Табын катыннан дога кылмыйча, Аллага рәхмәт әйтмичә торып китү зур гөнаһ. Аллаһы тәгалә бер дә ярлыкамый аны. Моны һәрчак исегездә тотыгыз, балакайлар! Аш артыннан кыска гына булса да бер дога укыгыз! — дип тукыды Алма апай һәм безгә дөньядагы иң кыска доганы өйрәтте. Мин аны әле дә булса онытмадым. Менә ул:

— Шөкерана бәрәкәт, Шәриф даган, Бакый иман, Аллаһу әкбәр!

Билгеле, мин моның мәгънәсен аңламыйм, әмма нинди кыска һәм ансат кына бит.

Бишмәтең яисә күлмәгең ертылып китә икән, син инде кемнеңдер өстенә салынырга чамалап, ямап бирүләрен таләп итә алмыйсың.

— Җанашым, синең үз кулкайларың кайда? Ниткән ул кеше өстенә салыну? Үзең эшләп өйрән. Хәзер үк утыр да яма. Әнә теге төшкән төймәңне дә тагып куй. Менә сиңа инә, менә сиңа җеп! — ди Алма апай һәм сиңа үзенең инә-җепләр саклана торган тартмасын китереп бирә. Вакыты булганда эшеңә күзәтчелек тә итеп тора әле. Ул булганда инде хәйлә кора алмыйсың.

Безнең кечкенә генә, җыйнак кына, сыңар күзле, бик тә усал, әмма бик тә гадел һәм әйбәт күңелле, якты рухлы Алма апаебыз! Чын исемең Фәйзәбану синең. Күптән, күптән инде вафат булсаң да, без сине әле дә булса хәтердә саклыйбыз, сиңа әле дә булса рәхмәтле. Әле дә булса өс-башларыбызны син боерганча пөхтә, чиста йөртәбез, ертылса, үзебез ямап киябез. Син кушканча кеше әйберенә тимибез, хәрәмгә кермибез. Урының оҗмахта булсын! Амин!

Әнә шундый матур гадәтләргә күнектерү өстенә Алма апай безнең тамакларыбызны да сыйлы итте, төрле тәмле әйберләр, пәрәмәч, күзикмәкләр дә пешереп ашатты әле. Әтиебез укытучы булганлыктан хөкүмәт безнең гаиләгә ай саен күпмедер он, тагын кайбер ризыклар бирә иде. Тик без аларны барыбер юньле ризык итә белмибез, әрәм-шәрәм итеп кенә бетерә идек. Алма апайларга менеп беренче мәртәбә табын янына килеп утыруга без «аһ!» иттек. Һәркайсыбызның алдына тәлинкә-кашык куелган, ә ул тәлинкәдә ак токмачлы, сөтле, өстендә май күзәнәкләре дә елмаеп торган гаҗәеп тәмле, җелек кеби аш салынган иде. Бик күптән күргәнебез юк иде безнең мондый ашны! Алай гынамы әле, һәркемнең тәлинкәсе янына түгәрәк төче күмәч тә куелган иде.

Бүтән туганнарым ничек булгандыр, хәзер инде ачык хәтерләмим, мин үзем, шәхсән, Алма апайларда билгеле бер тәртип белән, әйбәт кенә яшәдем. Иртән иртүк торам да лапаска чыгып китәм. Анда сыер-сарык асларын чистартам, азык салам, утын әзерләп куям. Барча эшне наять итеп керәм. Алма апай исә моның өчен мине һәрдаим мактап тора:

— Менә егет кеше шулай була ул! Йоклап ятмый ул, иртә баштан үз эшен белә,— дип куя.

Аннан мин төче күмәч белән тәмләп чәй эчәм дә, китаплар салынган киндер букчамны күтәреп, мәктәпкә менеп китәм. Алма апай, рәхмәт төшкере, букчага тагын бер төче күмәч сала әле.

— Тамагың бик өзелеп киткәндә алып кабарсың. Ачка тилмереп йөрмә инде, балакай,— ди ул.

Мәктәптән кайткач, Алма апай миңа бер тәлинкә кайнар аш салып бирә. Аннары мин тагын мал-туарны карап керәм дә, аягыма чаңгы тагып алам, тау шуарга чыгып китәм. Әптерәмән, Шашы тауларын әйләнеп, рәхәтләнеп саф һавада йөреп кайтам.

Мондый тәртипле, җайлы тормыш, тамакның да тук булуы үзенекен итте. Алма апайларда торган шул бер кыш эчендә мин хәйран үсеп, ныгып, тазарып киттем. Мәктәптә, тәнәфес вакытларында без уйныйбыз, көрәшәбез. Мин, билгеле инде, гел җиңелүчеләр рәтендә идем. Хәзер исә үзем кебек кайбер малайларны атып кына бәрәм.

— Кара син бу Радикны! Көчлеләнде ул хәзер. Егып кына сала ул хәзер!— дип, иптәш малайлар миннән шүрли, ихтирам итә башладылар.

Бу инде сугышның аз гына булса да җиңеләя барган, ә авылда исә тормышның тагын да авырая төшкән вакытлары иде. Мәктәптә даими салкын, укулар да авырлык белән бара. Кайбер көннәрне без дәрестән соң укытучыларыбыз Сания һәм Галия апайлар белән бөтен укучылар җыелып, болынга, зирек агачлары үскән урынга төшеп китәбез. Тирән карны ерып, шул агачларны кисәбез дә, баулар белән тартып менәбез. Шул чи агачларны ягып, мәктәпне аз-маз җылытабыз. Бу исә кайчак төрле маҗаралы хәлләргә дә китерә. Бервакыт Сания апабыз дәрестә класс тактасы янына басып безгә нидер аңлата иде, кисәк чайкалып китте дә идәнгә авып та төште. Җәтрәк йөгереп аның янына килдек. Укытучы апабызның күзләре әйләнгән, ул һушыннан язып бара иде.

— Миңа... ис тиде... Урамга... саф һавага... чыгарыгыз,— дип пышылдады ул көч-хәл белән.

Җыйнаулашып аны күтәрдек тә, мәктәп ишегалдына алып чыктык. Шунда кайбер малайлар, кызлар да бер-бер артлы карга түнә башладылар. Мичтә янып бетмичә кисәү башы калып, күбебезгә ис тигән икән. Ярый әле, беркемгә дә ул-бу булмады. Бераз яткач, түнүчеләр хәл алып аякларына бастылар.

Ул чакта тагын бер вакыйга хәтергә уелып калган. Кыш көне Америка Кушма Штатлары балалары хәйрия җыеп, Советлар Союзы балаларына өс-баш киемнәре җибәргәннәр икән, дигән хәбәр килде. Без моңа ышанып та бетмәгән идек. Әмма моннан безгә, хәтта минем үземә дә өлеш чыгып куймасынмы! Беркөн иртән мәктәпкә килсәк, Сания апай өстәлендә бер кочак кием-салым өелеп тора. Галәмәт матур киемнәр!

— Менә бу, укучылар, сезгә Америка укучыларыннан килгән бүләк,— диде Сания апай һәм киемнәрне аралый башлады. Безнең жаннар тасырдый иде инде, кемгә нәрсә тияр? Шунда Сания апай барыбызны да кызыктырып, иң өстә яткан кыска тунны кулына алды.

— Иң алдынгы укучыбыз Радикка бу тун! — диде ул.

Ул чактагы Америка малае! Син дә минем яшьләрдә булырга тиеш, бик ихтимал, син дә исәндер әле. Син әле аз гына киелгән яңа диярлек туныңны үз иңнәреннән салып, миңа бүләк итеп жибәргәнсең. Мең-мең рәхмәтләр сиңа! Ул чем кара, мамык кеби йомшак, гаҗәеп жылы тунны мин тагын күп еллар кидем әле, үземә тәмам кыскарып беткәнче кидем. Әле дә булса хәтеремдә, аның төймәләре төшмәслек итеп тагылган, ә элгече һич тә өзелә торган түгел, сәгатьнеке төсле чылбыр иде. Рәхәтләндем бит мин ул тунга! Аны киеп тә йөрдем, йоклаганда юрган итеп өстемә дә ябындым. Кинәндем генә инде. Өстәвенә миңа тагын бер күлмәк тә эләкте әле. Кызыл шакмаклы, бик тә матур күлмәк. Минем моңарчы өстемә андый матур күлмәкне кигәнем дә юк иде.

Без Алма апайларда торган кышны мин үзем өчен бик тә мөһим тагын бер гамәлне башкардым әле. Оят булса да әйтим, мин — инде дүртенче класс укучысы, шушы яшемә житеп сөннәткә утыртылмаган килеш идем. Утызынчы елларда дин тоту, төрле гореф-гадәтләрне үтәү бик хәтәр эш иде. Ә безнең әти укытучы... Тиешле, уңай вакытында ул мине сөннәткә утыртырга курыккан, күрәсең. Хәзер инде мин үсеп киләм, су коенганда иптәш малайларның күзе миңа төшә башлады.

— Чирмеш икәнсең син... Киселмәгән чирмеш икәнсең! Коенма безнең белән. Әнә читкә китеп коен,— дип үртәүчеләр табылды. Аннан килеп сөннәтсез булуның бүтән кыенлыклары да бар.

Бервакыт икәүдән икәү генә калгач, мин бу зарымны Алма апайга да сөйләп бирдем. Ул исә монда зур кайгыртучанлык күрсәтте.

— Ай-һай, балакай! Хәлең нигүзәл икән әле синең. Сөннәтсез торып калырга бер дә ярамый инде ул. Бер дә килешкән эш түгел, зур гөнаһ була бу. Син... үзең тәвәккәллә әле. Безнең авылга Масра бабайлар килмичә тормый. Шуларның берсен үзең чакырырсың да кайтырсың, Алла боерса. Син... бер дә куркып торма, улым. Бабайга тиешле хакын да үзем түләрмен. Авыртуыннан да куркып торма, саваплы эш алай ансат кына булмый инде ул. Аның каравы чын мөселман баласы булып үсәрсең. Тәвәккәллә, Алла боерса,— дип, бик кызып үгетләде ул мине.

Менә язмыш түгел диген инде син, шул сөйләшүдән соң күпме генә вакытлар үткәндер, «авылга Масра бабай килгән!» дигән хәбәр таралмасынмы! «Масра» димәктән, эш шунда ки, бу якларда балаларны сөннәткә утыртып йөрүчеләр барысы да бездән шактый еракта гы Масра дигән авыл кешеләре. Бу вакытларда сөннәткә утырту бик хәтәр, тыелган эш, алар зур тәвәккәллек күрсәтеп, бик яшерен генә, шыпырт кына йөриләр, һаман да үзләренең саваплы эшләрен башкаралар. Аларның исемнәрен беркем белми һәм сорамый да. «Масра бабай», диләр дә шуның белән бетерәләр иде. Капка төбенә чыгып, сагалап алдым мин бу бабайны. Аягына киез итек кигән, бик һәйбәт кайры тунлы, ап-ак түгәрәк сакаллы, какча йөзле, күркәм генә бер карт иде бу. Коеп куйган Масра бабай.

— Бабай, безгә дә кирәгез әле...— дидем мин, ул ишетерлек кенә итеп.

Бабай тукталмады, борылып та карамады.

— Безгә дә керегез әле! — дип кабатладым мин.

Тик шунда гына ул бара торган җиреннән туктады, як-ягына карапып алды, аннары гына яныма килде.

— Ни эшкә, улым? — диде ул, шулай ук ярымтавыш белән.

— Сөннәткә утыртырга кирәк иде,— дидем мин.

— Ә... кемне?

— Менә минем үземне!

Карт үзенең җете зәңгәр күзләре белән миңа текәлде, шактый гаҗәпсенеп, нидер уйланып торды. Ул инде нәниләрне генә сөннәткә утыртып күнеккәндер. Мин бит инде малайлыктан чыгып барган үсмер идем.

— Син... уйлама, бабай. Мин үзем теләп! — дидем мин.

Шунда карт елмаеп җибәрде, иңнәремнән сөеп алды.

— Менә маладис икәнсең син, улым. Бик әйбәт итәсең бит син. Гомерең буе иза чигәсең булмас. Аллага тапшырдык, әйдә! — диде ул.

Мин бу картның кулыннан тотып, батырланып өйгә атладым. Почмак якка кереп, урын өстенә дә үзем менеп яттым әле. Урамнан үтеп барган олы гәүдәле Ахун абыйны чакырып кергәннәр иде, шул ике аягымнан нык итеп тотып алды. Шунда теге карт «бисмиллаһ»сын әйтте һәм... мине шундый кискен, көчле, үзәкләргә үтә торган ачы авырту куырып алды ки, чыдый алмыйча кычкырып җибәрдем. Инде бу эшне ник башлаганыма үкенеп елый ук башлаган идем, Алма апай җылы куллары белән башымнан сыйпап алды.

— Хәзер, улым... Үтә дә китә ул. Син инде егет кеше. Син инде сабыр бул! — диде ул.

Чыннан да, тиз арада басыла төште авырту. Масра бабай миңа күзен кысып, дусларча елмайды, янчыгыннан ниндидер порошок алып, ярама сипте. Моның да шунда ук файдасы тиде.

Бабайны өстәл янына чәйгә чакырдылар. Ул утырып өлгерде микән, ишектән бер апай килеп керде. Авылның бик телчән, гайбәтче бер хатыны.

— Алма апай, бу ниткән бабай бу сездә?.. Нинди якыныгыз була ул? — дип кызыксынды ул.

— Күңгәрдәге сеңлемнең күршесе бу. Күәмнән кайтып килеше икән. Менә чәй эчеп чыгарга гына кергән, — диде Алма апай.

Ул хатын чыгып киткәч, теге бабай да озаклап утырмады. Тиз-тиз чәен эчте дә, җәтрәк таю ягын карады бугай. Аңа егерме биш тәңкә эш хакы бирделәр. Ул ишектән чыгып киткәндә мин тынычланган идем инде.

— Рәхмәтләр яусын сиңа, Масра бабай! — дип озатып калдым.

Шунысы җайсыз булды, миңа икенче көнне үк югары очтагы мәктәпкә укырга менәргә туры килде. Әгәренки мин дәресләремне калдырсам, моның сәбәбе белән кызыксына башлаулары, шуның аркасында кемнәргәдер зур бәлаләр килүе дә бик ихтимал иде. Бик авырлык белән, аякларымны ерып атлап булса да мәктәпкә мендем. Тик... авыл җирендә нинди дә булса берәр хәлне яшереп калу мөмкин эшме?! Минем нинди хәлдә икәнемне иптәш малайлар да, Сания апай үзе дә беләләр иде инде. Тәнәфескә чыккач та, малайлар мине бик сакладылар, уйнаганда да берсе дә миңа килеп бәрелмәде. Сания апай үзе дә бер тапкыр да такта янына чакырмады.

— Радик урыныннан гына сөйли! — дип белдерде ул класска.

Кемдер авыл Советына яисә районга барып жалу биреп йөргәндер дип уйларга да урын юк. Беркайдан да килеп иснәнеп, кызыксынып йөрүче яисә кая да булса чакыртулар булмады. Юкса, теләсә нинди закон бозуларга карата бик каты заманалар иде. Хәзер уйлыйм, ул яктан безнең авыл халкы бик бердәм булган икән.

Аз гына булса да урын өстендә ятмагач, миңа бик авырга туры килде бу. Хәтерем ялгышмаса, бер ай үткәч кенә тәмам тазарып җитә алдым. Шулай да үземнең шушы адымым өчен гомерем буена үз-үземнән канәгать булдым.

Без Алма апайларга шулай иялэнеп, җай гына тамагыбыз да ач булмыйча, өстебез дә бөтен булып яшәп ятканда, язга таба әтиебез армиядән кайтып төште. Ходайга шөкер, аны алгы сызыкка, ут эченә үк кертмәгәннәр, ерак Себердә хәрби склад сакларга куйганнар икән. Ул чагында олы яшьтәге солдатларны өйләренә кайтара башлаганнар иде инде, күрәсең. Ә яз җитеп, җирләр кар астыннан чыгу белән, без ияләнгән

урыннан кубып, яңадан үз өебезгә төшеп киттек. Алма апайларда торып калып булмый бит инде.

Һәм... тормыш дигән нәрсәнең яңадан рәте-чираты китте.

Никадәр гаҗәп ишетелмәсен, фронтта хәлләр җиңеләя, өметле була барган саен, авыл халкының тормышы авырая гына барды. Сугышның соңгы елларында инде авылга чын ачлык килде. Хәтта ачтан үлүчеләр дә булды. Безнең өй ишеген дә шакып керде ул ачлык. Үткән көздә без бакчадан бәрәңгене алгач, аның зур өлешен тирән баз казып шунда күмеп калдырган идек. Җәй көне ашар өчен әйбәт саклансын дип. Ярый, яз көне үз өебезгә күченү белән ошбу бәрәңгене казып алырга чыктык без. Эре-эре тәмле бәрәңгеләрне күрергә... Алды Фаяз абый кулына көрәк, казый башлады баз өстендәге туфракны. Ике-өч көрәк туфрак алырга өлгерде микән, Фаяз абыебыз... дөмберт! Бил тигентән түбән төште дә китте. Ул җир упкан урыннан әллә нинди пар, авыр ис бәреп чыкты. Фаяз абый агарынып китте, кулларын түбәнгә тыгып нидер казынды, аннары өметен өзгән тавыш белән әйтеп куйды:

— Бәрәңге... юк ич монда! Бәрәңге... череп беткән ул...

Әти булып күпләрне күргән әтиебез дә бу сүзләрдән хәлсезләнеп, баскан урынында чайкалып китте. Зәйтүнә апай исә илереп җылый ук башлады. Хәтта без кечкенәләр дә тынып, боегып калдык. Шундый ишле гаиләнең бөтен җәй буена бәрәңгесез торып калуы нәрсә икәнен без дә әйбәт төшенә идек.

1944 елның эссе җәен мин әллә нинди ямьсез, авыр, шомлы бер төш кебек кенә хәтерлим. Өй эчендә ачлыктан хәлсезләнгән, ябыгып эштән чыккан шәүләләр йөренә. Әти үзе дә өйалдындагы якты бүлмәдә урын җәйгән дә, күп вакыт шунда ятып кына тора. Аның да йөрер хәле юк. Әле өч яше дә тулмаган иң кече сеңлебез Асия ачлыктан һәлак булды.

Минем Асия сеңлем! Бу якты дөньяда яшәүнең нәрсә икәнен дә төшенергә өлгерми калган сеңлем минем. Менә хәзер синең түгәрәк йөзеңне, нарасый елмаюларыңны күз алдыма китерәм дә, йөрәгемә кан сава. Бетмәс-төкәнмәс хәсрәтемнән, үкенүләремнән, авыр уйлардан үземне кая куярга белмим. Йа Аллам, менә бу юлларны язуы да нинди авыр миңа... Юк, юк, ачлык кына алып китмәде сине бу дөньядан. Кешеләрнең сансызлыгы, битарафлыгы, күрәләтә ялган сөйләве үтерде сине. Мин бу хакта бер яздым инде, тагын да язачакмын әле. Битарафлыкның нәрсәгә китергәнен кешеләр белеп торсын.

Әнинең вафатыннан соң берничә айлар үтүгә, безгә Кышлау авылыннан бер хатын килде. Асияне сорамага.

— Бирегез миңа бу баланы. Минем үз балаларым юк. Үзем карап үстерәм мин аны,— диде ул, бишектә яткан Асиягә кулларын сузып.

Бирмәделәр! Әти ягыннан якын тиешле Һадия, Әмин, Сабира апайлар каршы килгән булдылар. Янәсе:

— Кеше кулларына карап үсмәсен. Үзебез тәрбиялибез аны...

Ана сөте, ана тәрбиясе күрмәгән Асия аягына басып тәпи йөреп китә алмады. Еллар буе бишектә ятып, идәндә утырып бөкересе чыкты. Шуның янына бер кереп хәлен белүче, кулына алучы булмады. Ул апайларга үпкәләрем диңгез кадәр. Кара эш эшләделәр алар! Әгәр шунда бала язмышы турында чын-чыннан кайгыртсалар, аны шул Кышлау хатынына биргән булсалар, Асия исән кала иде бит. Исән кала иде! Безнең Асиябез, матур сеңлебез әле дә исән булыр иде. Бу дөньяда яшәр, гомер кичерер, балалар үстерер иде.

Яшермим, монда үз өстемдәге гаепне дә зур дип саныйм. Ник бакмадым мин Асия сеңлемне, ник һәрдаим аны кайгырта белмәдем? Аңа ничектер ярдәм итә, күтәреп йөрү, урамнарга алып чыга алырлык идем бит инде. Без — кешеләр, нигә бу кадәр сансыз? Хәтта бертуганнар арасындагы мөнәсәбәтләрдә дә... Аһ, үкенүләр дәрья сулары тикле алар. Мин үземне гомерем буена Асия каршысында, аның нәни рухы каршысында зур гаепле дип саныйм.

Нихәл итәсең, җанашымның язмышы да шулай булгандыр инде. Әгәренки әниебез аны сигез айлык килеш калдырып вафат булмаса, ана тәрбиясеннән мәхрүм калмаса, бәлки ул үлмәс тә иде.

Сугыш елларында, нинди авыр вакытларда әнисез яшәү безгә дә җиңел булмагандыр инде. Алма апайлардан төшкәч, безнең өс-башлар тагын керләнде, ертылды. Үзебез тагын шапшак, тәртипсез балаларга әйләнә бардык. Ә алай да... бала халкы нәрсә белә инде ул? Без ничектер, инде әнине юксынмый да, әни кирәклеге турында уйламый да идек.

## Икенче әни

Ниһаять сугыш бетте. Безнең Гомәр абый белән Әхмәт абыебыз, йөрәкләребездән мәңге китмәс моң булып, ерак җирләрдә ятып калдылар. Инде безгә өс-башларыбызны караучы, азрак юньле ризыклар да пешереп ашатучы, олыгаеп килгән әтиебезне дә тәрбия кылып, иртән тамагын туйдырып мәктәбенә озатучы бер кеше — әни кирәк икәне бик тә сизелә башлады. Дөресрәге, гаиләне оештырып, аңа нур сибеп торырдай бер кеше кирәк икәнен без төшенә башладык. Моны күрше-күләннәр, безгә кергән апай-әбиләр дә исебезгә гел төшерә тордылар. Тик аларның бу хактагы сүзләре төрлечә иде.

— Менә, Аллаһы боерса, әтиегез сезгә бер әни алып кайтыр. Бу кадәрле әрсезгә калып йөрмәссез аннары. Тамакларыгыз да тәмле, өс-башыгыз да чиста булыр. Алла кушып шулай булыр,— дип фараз итә түбән очның Әминә апай. Кечкенә генә, күгәрчен кебек җыйнак бу апай бик әйбәт, күңелендәге шәфкате вак сипкелләр төшкән йөзен нурландырып тора. Әминә апай безнең өчен ихластан кайгырта.

Башындагы ап-ак яулыгы өстеннән чем кара камчат бүрек киеп куйган, бик диндар, бик көшкелле Җиһан әби икенче төрле уйда:

— Һай Алла, җанашларым... Бу йортка үги әни килеп төшәр инде, балалар. Нindиләр генә булыр инде ул?.. Сез бичараларга җәберен бик салмасмы? Һи, җанашларым, үги-үги булыр инде ул, үз әниегез булмас. Ничекләр итеп кенә түзәрсез инде,— дип, кайгыра Җиһан әби һәм озаклап догалар укып утыра.

Бик юан гәүдәле, шуңа тиң киң күңелле Камилә апай авыр итеп урындыкка утыра, симез беләкле кулларын югары күтәреп, Аллага ялвара:

— Ярабби бер Ходаем! Шушы балаларны ярдәмеңнән ташлама. Аларга әни булып миһербанлы бәндәң килсен. Үз әниләре мәрхүмә Зәкия шикелле шәфкатьле бер җан килсен. Ярабби Аллам! Шушы ятимнәреңне ярдәмеңнән ташлый күрмә!

Шуннан инде Камилә апай зәңгәр күзләрен ачкалап-йомгалап, догалар укып утыра. Һәм кисәк безгә мөрәҗәгать итеп сорап куя:

— Каяле, ристаннар, чәй куймадыгызмы?

Чәй эчү аның иң яраткан шөгыле.

Без үзебез дә ул әнинең киләсен көттек. Төрле уйлар белән, кызыксынып, өметләр баглап, хыялларга бирелеп һәм бераз куркып та көттек. Бу вакытларда инде мин үзебезнең авылдан өч чакрымдагы Күәм мәктәбенә төшеп, җиденче класста укыйм, җиткән егет булып киләм. Хәзер безнең әти белән үзара мөнәсәбәтләр бик үзгәрде һәм яхшы үзгәрде. Аның белән еш сөйләшәбез, хәтта дуслашып киттек диярлек дә була. Җәй көннәрендә без гел бергәләп эшлибез, ишегалларын җыештырабыз, бакча башындагы инеш буенда картаеп утырган өянкеләрне кисеп, кышка утын әзерлибез. Бу өянкеләрне яшь чагында әти үзе утырткан, хәзер инде картайган, кайсыларының эче куышланып, аварга утыралар. Кисәргә кирәк. Аннары һәр киселгән агач урынына яңасын утырта киләбез.

— Менә бу өянкеләр башларын очлап җиргә кадап куйган ботаклардан үсеп киттеләр. Ул заманнарда мондагы җир шулкадәр әйбәт, йом-

шак иде. Бассаң аяк батарга тора иде. Әнә нинди булып үстеләр! — дип сөйли миңа әти, рәт-рәт булып утырган, башлары күккә ашкан агачларга күрсәтеп.— Ә-әнә тегендә, үр читендә шундый матур түгәрәк күл иде. Язларын кыр үрдәкләре төшәр, бала чыгарырлар иде шунда. Инде дөньялар коруга бара...— дип уфтана әти.

Без аның белән, гомумән, күп нәрсәләр турында сөйләшәбез. Әти Арчадагы укытучылар әзерләү курсларыннан тыш үзлегеннән дә күп укыган, киң мәгълүматлы кеше, күп нәрсәләрне белә иде. Ул вакытта мин үзем дә инде байтак китаплар укыган, кайчак әтигә төрле кызыклар, шул китапларның эчтәлеген сөйли идем. Шундый сөйләшүләрдә мин үзебезгә әни кирәклеге турында да сүз кыстыргалый башладым. Ә бервакыт туп-туры әйтеп куйдым:

— Безгә... ни бит... Бер әни дә кирәктер инде, әти. Бу хакта син ни уйлыйсың?

Моңа каршы әти шактый уйланып торды. Аннары үзалдына сөйләнгәндәй итеп кенә әйтеп куйды:

— Шулай шул. Бер әнисез булмастыр инде...

Инде җиденче классны бетереп, чыгару имтиханнары тапшырып йөри идем. Бер көнне Күәмнән бик соңарып, ачыгып, арып-талып мендем. Үзебезнең капка төбенә килеп җитсәм, анда Мәһирә апай тора. Үзе бик серле итеп елмая.

— Бар, җәтрәк өегезгә кер. Анда... әнә әниең кайтты. Зәкия кайтты,— диде ул.

Бу хәбәрдән мин дерт итеп киттем. Минем әнием Зәкия күптән вафат бит инде. Ни сөйләнеп тора бу карчык? Бер үлгән кешенең кире кайтуы мөмкинме? Бу нинди сүз тагын?

— Син... ни сөйлисең әле, Мәһирә апай? Үлгән кеше ничек кире кайтсын инде ул...— дидем мин, бик аптырап.

— Кем әле сиңа үлгән ди... Бар, әнә кергәч үзең күрерсең. Күп теленә салынып торма! — диде Мәһирә апай һәм аркамнан төртеп җибәрде.

Әллә ниләр уйлап, курка-курка гына өйгә кердем. Ә анда бернинди әни юк, тик бер ят хатын гына йөренә. Үзе тәбәнәк кенә, әмма юантык, нык бәдәнле, аяклары күзгә күренеп торган чатан. Яулыгы астыннан чыгып торган чем кара чәчләре кыска. Йөзе озынча, күзләре җете. Мин ишектән килеп керешкә ул көлемсерәп, миңа текәлеп карап алды. Өйдә күрше хатыннар да бар иде. Шунда кемдер минем аркамнан этәрде.

— Менә бу синең яңа әниең була инде. Барып күреш әниең белән. Ходайның рәхмәте, аның да исеме Зәкия икән,— дип пышылдады.

Мин алгарак үттем, ят хатынга кулымны суздым. Дулкынлануымнан шактый кычкырып:

— Исәнме... әни! — дидем.

— Исәнме...— диде ул, миңа кулын биреп. Аның кулы кечкенә, күп хезмәт күргән кешенекедәй кытыршы, әмма җылы иде. «Исәнме, улым!» димәде. Тик мин нindидер бер эчке тойгы белән сизенеп алдым: әйбәт апай булырга тиеш бу! Белмим нәрсәседер, әллә аз гына көлемсерәүле, эчкерсез күз карашымы, әллә ачык елмаюлы гади йөземе, нәрсәседер аның киң күңелле, уен-көлкене ярата торган, гади мөнәсәбәтле икәнен белгертеп тора иде. Кешене аны беренче күрүдән үк сизмерләп алырга була икән. Шунда минем кайчаннан бирле инде билгесезлек, нindидер авыр уңайсызлыклар, шул ук вакытта өметләнеп тә көтү белән интеккән күңелемә иркенлек, яктылык, куанычлар килеп тулды. Бу хисләрдән шулкадәр дулкынландым ки, күзләремә нindидер татлы яшьләр килеп тулды. Тиз генә ишек катына киттем дә кешегә сиздермичә генә ул яшьләрне сөртеп алдым.

Бу әни безнең өйгә әле күптән түгел генә килеп кергән иде, күрәсең. Өстәлдә аның зур гына төенчеге тора, төенчек әле чишелмәгән дә иде. Менә ул төенчеген чиште, башындагы ак яулыгын икенчесе белән алмаштырды, алъяпкычын бәйләде, күлмәк җиңнәрен сызганып куйды. Тирә-

ягына, авызларын киң ачкан килеш үзенә текәлеп караватта утырган Ләлә белән Кларага, ишек катында бәрәңге әрчеп утырган Рифатка, мич-учак алларына хуҗабикәләрчә бер карап алды. Әле безнең өйдә үзен карап бәя бирергә кергән күрше хатыннар булуына да карамастан, ул хәзер үк йорт эшләренә керешергә җыена иде, күрәсең. Һәм ул ишек катындагы Рифат янына килде.

— Син бәрәңге әрчисеңмени? — диде.

— Бәрәңге әрчим шул. Ашарга кирәк ич,— диде Рифат башын күтәрмичә эшендә булып.

— Бир әле пычагыңны монда. Үзем әрчим,— диде яңа әни.

Сез шунда безнең Рифатны күрсәгез икән! Ул ялт итеп башын күтәрде, ышанасы да килмичә, авызы колагына җитеп елмайган көе үзен бу җәфадан коткарган шәфкать иясенә карап алды да син күр дә мин күр! Урыныннан дәррәү сикереп торды да җәтрәк урамга, анда уйнарга иптәш малайлары янына чыгып тайды. Артыннан ишеген дә ябарга онытып. Моны карап торган Камилә әби бот чабып көлде.

— Һай, җанашым, җанашым! Алланың рәхмәте, көтеп кенә утыра икән ич. Ничек шатланды бит, ничек шатланды. Кошлар кеби очты да китте. Менәтерә, әни кирәк шул сабыйларга. Әни дигән кеше бик тә кирәк шул...— дип сөйләнде.

Әни әллә ни арада гына бәрәңгене әрчеп бетерде дә, учакка ут тергезеп җибәрде. Ул ара да булмады, безнең кайчан юганы да онытылган, төрле касмаклар катып беткән өсләребезне пычак белән кырып юа башлады. Ул инде озак вакытлар чит җирләрдә йөреп, үз йортын сагынып кайткан, анда чисталык, тәртип булдырырга ашкынып кайткан хуҗабикә төсле, безнең өйдә мәш килә, анысын карый, монысын рәткә китерә иде. Кулларында ут уйный иде бу әнинең! Безгә җыелган хатыннар бу хәлне исләре китеп тамаша кылдылар да өйләренә таралдылар. Үзләренең дә өйләрендә эшләре муеннан икәнне исләренә төшерделәр бугай. Алар чыгып китешкә әни минем янга килде дә тезбашы ертылып чыккан чалбарыма текәлеп карап алды, башын чайкап куйды.

— Чалбарыңны салып бир әле, Радик. Хәзер үк үзем ямап бирәм,— диде ул.

Мин өстемә әтинең иске пәлтәсен кидем дә, чалбарымны салып бирдем, үзем пәлтә итәкләрен астыма җыеп, караватка менеп утырдым. Озын пәлтә киюем шуңа, минем чалбар астында бүтән берни дә юк, калганы барысы да анадан тума шәрә иде. Ул заман авыл җирендә балаларның кышын-җәен бер кат чалбар, трусик яисә ыштан киюне без белми дә идек. Әни тиз арада чалбарымның ике тез башын да шоп-шома, бернинди җыерчыксыз итеп ямап та бирде.

— Рифатка да әйт әле, Радик. Өйгә керсен. Аның да күлмәк изүе аерулы,— диде ул.

Монда шунысын әйтим әле, әни беренче көннән үк безнең беребезгә дә «улым» яисә «кызым» дип эндәшмәде. Үзе табып үстермәгән булгач, алай ук якын итеп эндәшүе аның өчен уңайсыз булгандыр инде, күрәсең. Ул гомере буена безгә «Радик», «Ләлә» дип, исемебез белән генә эндәште. Әмма ләкин моның өчен аңа беребезнең дә бер тамчы үпкәсе юк. Чөнки ул шул исемне ниндидер бер әчке җылылык белән, йомшак итеп, күңелгә ятышлы итеп әйтә иде.

Без иртән йокыбыздан кем кайчан тели, шул вакытта торып күнеккән идек. Дөресен генә әйткәндә бу хәл үзе йортта тәртип булмауның башы. Килгәненең икенче көнендә үк әни безнең барыбызны да бер вакытта, гадәттәгедән шактый иртә уятты. Кемнәрдер моңа ризасызлык белдереп, шыңшый да башлаганнар иде, тик бик тиз тукталдылар. Чөнки без торганда инде өстәлдә ак самоварыбыз җырлап утыра, зур табак белән уртага куелган, ярып пешерелгән бәрәңгедән тәмле парлар бөркелеп тора иде. Әни әтиебезне ашатып мәктәпкә үк озаткан иде инде.

— Йокыдан барчагыз да бергә, иртә торып өйрәнегез. Урык-сурык ашап йөрисе түгел. Ходай үзе дә иртә торганга бирермен дигән! — диде әни һәм үз эше белән мәшгуль булып өйдә әрле-бирле йөргән килеш, «иртә торганга бирермен дигән!» дип берничә тапкырлар кабатлады. Ничектер, башка сөйләмнән үзгә, көйле итеп, һәр сүзен аерым-ачык итеп, басым ясап кабатлады. Һәм без тиз арада белеп алдык, бу яңа әнинен үзе әйткән сүзләрен үз алдына кабатлап йөри торган сәер генә бер гадәте бар икән. Ул сүзләрен эш арасында, беркемгә дә атамыйча гына кабатлый. Бу аның үзенә аерым бер фикер йөртү, уйлау үзенчәлеге иде, күрәсең.

— Радик, без синең белән Түбән Шашыга гына барып кайтыйкчы. Анда минем әйберләрем калган иде. Күтәреп кайтырбызмы инде?.. — диде әни миңа иртәнге чәйдән соң.

— Барабыз! Күтәреп тә йөрмибез әле. Безнең «уфалла» бар. Шуны тартабыз да китәбез, алай җайлы булыр... әни! — дидем мин. Менә, «әни!» дигән сүз үзеннән-үзе чыкты да китте. Кичәдән бирле аңа ничек эндәшергә белмичә азаплана идем, хәтта берничә тапкыр телгә «апай» дигән сүз дә килгәләгән иде. Шулай итеп инде законлы төстә әниле булдым да куйдым.

Без лапастан үзебезнең «уфалла» арбасын алдык та, Шашыга киттек. Түбән Шашы безнең Дусымга өч кенә чакрым, әни безгә шул авылдан килгән икән. Ул анда бер хатын белән өйдәш торган, шунда аның кайбер әйберләре, урын-җирләре калган икән. Без хәзер шуларны алырга барабыз. Кул арбасын икәүләп тартып, юл буе сөйләшеп бардык.

— Әни, синең дә исемең Зәкия икән, әйеме? Безнең үлгән әнинең дә исеме Зәкия иде. Бик кызык килеп чыкты инде бу, әйеме? — дидем мин.

— Бу әйбәт инде үзе. Әгәренки бер йортка бер исемдәге ике кеше килсә, ул йорт бәхетле була дигән. Алла боерса, менә бәлки бергә оешып торып та китәрбез әле. Әгәренки сез минем сүземне тыңласагыз, мин дә сезгә әйбәт булырмын. Мине әни дип танысагыз... Менә ничек булып китә бит әле ул. Белмәссең тагын...— диде әни.

— Ни эшләп белмәссең дип әйтәсең аны, әни? Безгә бит синең белән уңайлы да, күңелле дә. Беренче көнне үк шулай булды ич әле. Без әнидән башка бик күп тордык ич инде. Бер дә рәхәт күрмәдек. Алай димә син, әни. Бергә торабыз диген син! — дидем мин.

— И, Радик, син дә алай димә. Алай ансат кына булмас инде ул. Тормыш алып барасы бар ич әле. Әтиегез Хәбибрахман да нинди кешедер тагын? Апаең Зәйтүнә дә мине бик яратып бетермәс инде. Мин инде... бик алай килешле дә түгелдер. Менә, күреп торасың, бу чәчләрем дә бик кыска...— диде әни, моңсу гына итеп. Ул мине инде барысын да төшенерлек, барысын да киңәшерлек, житкән бер егет кебек күреп сөйләшә иде. Ә минем тагын, нәкъ кичә аның белән беренче күрешкәндәге шикелле күңелем нечкәрде, күзләремә яшь килде. Бу тәбәнәк кенә, кәкре аяклы, кытыршы куллы апайны мин күңелем белән әнием кебек кабул иткән идем инде. Киләчәк тормышыбызда аңа өметләр баглаган идем. Әнисез торулары чыннан да кыен бит ул. Әни юклык ул бала чакта гына түгел, ә кеше үсә барганда да, хәтта инде үзе гаиләле, балалы булгач та үзен гел сиздереп тора, зур бер күңел китеклеге булып кала... Ә бу әни бездә калачагына да ышанып бетми, әнә ниләр уйлап тора икән...

— Юк, юк, әни! Ни эшләп инде... Безнең әти дә болай әйбәт кеше. Зәйтүнә апай да үз итәр әле. Үзенә никадәр җиңеллек килә ич аның. Безне карап изаланды ич инде ул да. Әнә кичә Рифат ничек шатланды. Ләлә белән Клара да шатландылар. Син безгә бик, бик кирәк, әни. Син бездән беркая да китмисең инде! — дидем мин, ихлас күңелемнән һәм сүзне икенчегә бору өчен сорап куйдым: — Ә синең бу чәчләрең ни эшләп болай кыска, әни? Син аларны кистереп йөрисеңмени?

— Юк ла...— диде әни, шактый уңайсызланып.— Мин тиф белән авырып киткәнмен. Аздан гына үлмичә калганмын. Шул чагында минем чәчләремне алганнар... Бөтенләй кыркып алганнар. Менә хәзер, Аллага

шөкер, үсеп киләләр инде. Азрак кеше төсенә дә керәм инде,— диде әни һәм миңа үзенең тәрҗемәи хәлен сөйләп бирде.

Ул үзе Мариның Пичуш дигән татар авылыннан икән. Бу авылны мин дә беләм, ул безнең Дусымга унбиш чакрымнар тирәсе. Мари урманнарына Шиншегә утын алырга барганда юл читендә күренеп кала. Әни шул авылда туып-үскән, аннан төзелеш эшләренә язылып, Казан каласына килгән. Ул елларда авылдагы ачлык-ялангачлыктан, колхозда бер тиенсезгә бушка эшләүдән качып китү хәрәкәте халыкта бик көчле иде. Авыл кешеләре тимер юллар салу, сазлыклардан торф, җир астыннан күмер чыгару, шәһәрләрдә йортлар салу кебек авыр эшләргә язылып китәләр, ансат кына Советлар Союзының бинипая еракгагы тарафларына кадәр барып чыгалар иде. Хәтта Мәскәүнең үзенә барып урнашырга да була иде. Шулай итеп кешеләре китә-китә бөтенләй таралып беткән авыллар да булды.

Әни Казанда эшләгән, шунда төпләнеп калырга да нияте булган. Бер татар кешесенә тормышка да чыккан. Әмма ул бәндә белән алар юньле тормыш корып җибәрә алмаганнар. Ул кеше, ә бәлки бичарадыр, тиз арада эчеп-тузып юлдан язган. Әнинең аннан бер баласы да булган, ул нарасый да үлеп киткән. Менә шушы хәлләрдән соң инде әнинең шәһәр җирендә торып каласы килмәгән. Ул кулын селтәгән дә авылга, Түбән Шашыдагы бер якын тиешле кешеләренә кайткан. Колхозда эшләгән, фермада тиз арада алдынгы савымчы булып киткән. Аны колхозда бик яратканнар, гел бүләкләп, мактап торганнар. Соңыннан миңа ул колхозның рәисе, бөтен Татарстанга данлыклы Фәйзи ага Галиев әнине хәтерләп: «Зәкия апаймы? Бик әйбәт иде, алтын куллы хатын иде ул. Синең әниең булган икән. Карале, бәхетле булгансың син!» — дип сөйләде. Шулай әйбәт кенә эшләп йөргәндә әнигә тиф авыруы тигән. Хәзерге яшьләр, Аллага шөкер, аны белми, ул елларда тиф дигән бик хәтәр авыру бар иде. Кайчагында бу зәхмәт киң тарала, аннан күпләп кеше кырыла иде. Мондый сырхау чагында теләсә кемнең, хәтта хатын-кызларның да чәчләрен төптән кыркып алалар, ә тифтан исән калып сәламәтләнгән кешеләрнең исә һәрвакыт акылына зыян килеп кала. Һәм алар берничә айлар буена акылга шактый җиңеләеп, ни эшләгәннәрен белми, теләсә ни сөйләнеп йөриләр. Безнең әни дә боларның барысын да үз башыннан кичергән, берничә айларга акылга да җиңеләйгән. Ул үзләренә кергән күршеләренә:

— Нәрсәгә дип кердең монда? Һи, оятсыз икәнсең син... Менә шушы кайнар бәрәңгене алып күзеңә китереп сугармын берне. Белерсең аннары! — ди торган булган. Әлбәттә инде, ул моны үзе белеп эшләмәгән. Соңыннан сәламәтләнгәч кенә, күршеләре моны аның исенә төшереп, бергәләп көлешә торган булганнар. Әни, Аллага шөкер, ахыргы чиктә бу чирдән исән-сау котылган.

Мин әни сөйләгәннәрне тыңлап бара торгач, без Түбән Шашыга килеп тә җиттек. Кечерәк кенә бер йортның капка төбенә килеп туктадык. Шунда ук безнең каршыга түгәрәк битле, яшь кенә бер хатын йөгереп чыкты. Әнине кочаклап алды да, елап та җибәрде:

— Һай, Зәкия апай, җанкисәгем. Синең мине ташлап китүләрең мени инде бу? Синнән башка ялгызым мин ничекләр көн итәрмен инде? Бигрәкләр дә килешеп яши идек ич синең белән. Һай, җанкисәгем...— дип сөйләнде ул хатын, күз яшьләренә төелеп.

Әни үзе дә елап җибәрде. Аннары яулык чите белән күзләрен сөртеп алды.

— Китәм шул инде, Мәхмүдә җаным. (Ул хатынның чын исемен онытканмын.) Менә... шулай килеп чыкты ич әле. Бер Ходаем шулай кушкандыр инде. Менә бу ятимнәргә әни кирәк икән ич...— диде ул, миңа күрсәтеп.

Теге хатын шунда гына миңа текәлеп карап алды. Ни хикмәт, бер дә яратмыйча, усал итеп карады.

— Кара аны, бүрәнкә авыз, сез анда Зәкия апайга ямьсез сүзләр әйтеп аны рәнҗетмәгез. Сез җиберләргә хезмәткә китә инде ул. Бик әйбәт ул. Без аның белән ничә еллар тордык. Авыр сүзләр әйтеп рәнҗетмәгез аны. Ишетсен колагың, бүрәнкә! — дип тукыды ул миңа. Дөресен генә әйткәндә, аның болай сөйләшүеннән бик хәтерем калды. Тел очыма аның авыз-борыны хакында да бик тасвирлы сүзләр килгән иде дә, әйтмичә калдым инде. Әни хакына түздем.

Ул хатын самавыр куеп җибәрде. Чәй янында алар әни белән сөйләшеп, тагын елашып утырдылар. Аннары без әнинең яшел төсле кечкенә генә сандыгын, урын-җирен, тагын вак-төяк әйберләрен «уфалла»га чыгарып төядек. Алар җәмгысе шул кул арбасына сыеп та беттеләр. Без әни белән арба тартып, тагын юл буе сөйләшеп кайттык. Әни хәзер моңлы күренә, үзе күпме торган авылны, иптәш хатынын ташлап китүе аңа да авыр булгандыр инде.

— Арагыздан син иң акыллысы күренәсең, Радик. Шуңа күрә сиңа әйтәм бу сүзләремне. Әгәренки үзегез тәртипле булсагыз, минем әйткән сүземне тыңласагыз, мин дә сезгә рәхим-шәфкатьле булырмын,— дип сөйләде әни. Мин сизеп бардым, ул ихлас күңеленнән сөйли иде.— Булган кадәр ризыкларны вакытында әзерләп ашатырмын. Өс-башыгыз юылган, ямалган булыр. Тик... сез үзегез дә мине әни дип танырсыз, миңа булышырсыз... Йа, Аллам. Ят-чит балалар арасына керәм инде мин. Бер Ходаем, мине рәхмәтеңнән ташлама инде. Ни хәлләр итим, язмышларым шулайдыр инде минем...— диде әни һәм тагын елап алды. Мин тагын, бар белгән сүзләремне әйтеп, аны тынычландырырга тырыштым.

Шулай итеп, Алланың рәхмәте белән, ничә еллар үксез килеш иза чиккәннән соң, без дә әниле булдык. Һәм тормыш-яшәешләр дә бердән үзгәреп, җайланып китте. Иртән торышыбызга безгә кайнар чәй, бәрәңге әзер була. Ә өйләгә инде әни көн саен барлы-юклы оннан токмач җәеп, тәмле итеп аш пешерә. Кич белән тагын вакытында тукланабыз. Өс-баш ертык көе, аннан-моннан бүселеп, юылмаган керле күлмәкләрдән йөрүләр бетте хәзер. Безнең бу кәкре аяклы, юантык әниебез, Алланың рәхмәте, бернинди ару-талуны белми иде, ахры. Иртүк торып, җырлыйҗырлый күңелле итеп үзалдына шигырьләр сөйләп, бертуктаусыз эшләде ул. Безнең өйалдындагы караңгы бүлмәне, якты бүлмәне, очырмаларны бер ай буе чистартты, тәртипкә салды ул. Әти аның өйалдында, очырмаларда дөбер-шатыр килеп, нәрсәләрнедер ду кучереп эшләп йөргәнен тыңлап тора да, башын чайкап, көлеп куя иде.

— Менә бер бичура килде бит әле безгә. Чын бичура затыннан инде бу...

Әти, үзе озын буйлы, төз гәүдәле, күркәм генә кеше, бу әнигә, гомумән, мыек астыннан көлебрәк карый иде. Кем белә, үзенә бик тиң күреп тә бетермәгәндер инде. Бервакыт шулай без әти белән ишегалдында утын кисәбез. Әни дә шунда гына, тавыклар ашата, тагын ниләрдер эшләп мәш килә. Әти аның чатан аяклары белән вак-вак атлап, туптай тәгәрәп йөргәнен карап торды да, көлеп җибәрде.

— Күр инде син моны... Бигрәк тәбәнәк... Әллә ни килешле дә түгел инде бу. Ни хәл итәсең, кая барасың бу кадәр бала-чага белән...— дип сөйләнде ул үзалдына.

Тик... ошбу дөньяда һәркемнең үз мәнфәгате шул. Әтиебез бәлки яңа әнине үзенә тиң күреп тә бетермәгәндер, икеләнүләре булгандыр. Ә без балаларга исә, шәхсән минем үземә, бу әни бер дә килешсез түгел, бик ягымлы, аннан ниндидер күңел җылысы, шәфкать сирпелеп тора сыман тоела иде. Ул хәтта Тукайның бик күп шигырьләрен яттан белә булып чыкты. Эш арасында аларны сөйләп йөрергә бик ярата иде. Шигырьләрне җырдай сузып, һәр иҗеккә бик килешле итеп басым ясап, гаҗәеп моңлы һәм тәэсирле итеп укый. Аның моңлы тавышы әле дә булса исемдә:

Иртә. Дөнья җанлана,
Мәшрикъ ягы аллана,
Кояш чыгып, нурлары
Төшеп җиргә ялгана.

Яктыра кала. Урамнар
Кырлар, якын урманнар,
Таулар, баглар, бакчалар
Нурга гарык булганнар...

Инде дә әни «Сак-Сок» бәетен укып җибәрсә, үзенең дә, минем дә күздән яшьләр килә.

— Кайда, кайчан өйрәндең син бу кадәрле шигырьләрне? — дип сорадым мин әнидән.

— Кыз вакытымда мин авылда мәдрәсәгә йөрдем. Безнең абыстай Тукайны бик ярата, аны яттан белә иде. Үзе дә шигырьләр чыгарды. Шул абыстай өйрәтте безне. Бик әйбәт итеп өйрәтте. Менә, әле дә онытылмаган ич,— диде әни һәм «Бала белән күбәләк» шигырен укый башлады.

Әни үзе генә туктаусыз эшләп калмады, безне дә йорттагы вак-төяк эшләргә күнектерә килде. Без димәктән, бу вакытта инде без йортта нибарысы дүрт бала торып калган идек. Мин, Рифат, Ләлә, Клара. Фаяз абыйны әле безгә әни килгәнче үк армия исәбеннән алдылар да, әллә кайда бик ерактагы Магнитогорск каласына ФЗӨ мәктәбенә укырга җибәрделәр. Зәйтүнә апай Казанга, төзелеш эшләренә язылып китте. Эшкә өйрәнү димәктән, бу вакытта инде мин җиткән егет, иртән үзем иртүк торып лапаска, мал-туар карарга чыгып китәм, абзарларны чистартам. Ә җәйләрен без Рифат белән «уфалла»га җигелеп алабыз да, җыен коры елгалар, чокыр-чакырлардан печән, чүп үләннәре җыябыз. Кышка малларга азык әзерлибез. Әти белән тау астындагы өянкеләрне кисәбез, яңаларын утыртабыз. Ул киселгән агачларны турап, иңбашына салып өйгә ташыйсы да бар бит әле. Андый авыр йөк белән бакча сукмагыннан үргә менүләре аһ-һай читен. Әле дә булса бик истә бу эшләр... Безнең балачак авыр хезмәт белән үтте.

Ләлә белән Клара өйдә әнигә булыштылар, каз бәбкәләрен карадылар. Әни аларны хатын-кызлар эшләренә, йон эрләп оекбаш, шәл бәйләргә дә өйрәтте. Бернинди эштән чирканмыйча, хезмәт сөючән булып үстек без. Һәм гомеребез буена шулай булып калдык. Мин әнинең «иртә торганга бирермен дигән!», «эшләгәнгә бирермен дигән!» дип кабатлап йөрүләрен әле дә булса хәтерлим.

Бервакыт өйдәге инде искереп беткән, төтен дә тартмый башлаган иске олы мичне сүтеп чыгарырга туры килде.

— Мичне сүтәрбез дә ташларбыз анысы. Тик менә яңасын чыгарганда яңа кирпечләр дә кирәк булыр бит әле. Менә аларын кайдан аласы? — дип хафага төште әти.

— Ком базы Шашы тавында гына. Аста кызыл балчык та бар. Шуларны алып кайтасы да кирпеч итеп сугасы. Ник әле аның өчен генә дә кайгырып торырга,— диде әни.

— Сугасы... Ә кем сугар соң ул кирпечне? — дип көлде әти.

— Ай Алла! Менә Радик белән без тотабыз да сугабыз аны. Аңа кем кирәк соң тагын? — диде әни.

Әти бу эшкә бер дә ышанмаган иде. Әни үзе күрсәтеп, карап торып, миңа кирпеч суга торган калып ясатты. Аннары без шул ук «уфалла»га җигелеп, Шашы тау башына менеп киттек. Комын, балчыгын ташыдык. Бакча башына сай гына чокыр казып, анда ком, балчык салдык, өстенә су койдык. Аякларыбызны чишенеп ташладык та, балчык издек. Һәм, ни әйтерсез, кирпечне суга да башладык. Андый-мондый гына түгел, бөтен фасоны килгән, читләре тип-тигез, менә дигән кирпечләр! Һәм мин тиз арада кирпеч сугу остасына әйләнеп киттем. Без әни белән ул кирпечләрне куышлап өеп яндырдык та әле.

Әни килеп елдан артык вакыт үткәч, безнең тормышта тагын бер күңелле вакыйга булды әле. Беркөн шулай көндез басуда эшләп, кичен өйгә кайтып киләм. Капка төбендә мине тагын шул ук Мәһирә әби туктатты.

— Сөенче, сөенче синнән! Анда синең тагын бер энекәшең булды. Әниегез Зәкия бала тапты. Алланың рәхмәте белән ир бала! — диде ул.

Мин йөгереп өйгә кердем. Анда матчада безнең барыбызны да тирбәтеп үстергән бишек тагын элеп куелган, бишектә яңа туган нәни бала ята иде. Түгәрәк кенә, гаҗәп матур малай. Безнең унынчы туганыбыз!

— Ә исемен Гаяз дип кушабыз. Гаяз! — дип белдердем мин өйдәгеләргә. Мин тапкан исем барсына да ошады бит, рәхмәт төшкере!

* * *

Без шулай әни тәрбиясенә, ана кайгыртуына тиенеп, хәйран гына көн итеп ята идек. Мин Куәмдә җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Олы Әтнә урта мәктәбенә укырга кердем. Әтнә бездән биш чакрым булса да, көн саен барып-кайтып укыдым. Инде урта мәктәпне дә тәмамлыйсы елым иде. Исәбем дә ачык, кулыма өлгергәнлек аттестаты алу белән Казан каласына барып, медицина институтына укырга керәсе идем. Бу уемны әти дә бик хуплады.

— Бик әйбәт, врач булырсың. Менә мине дә үзең дәваларсың. Гомерем буена үпкәләрем авыртып, иза чигәм бит инде, — диде, өмет белән әйтте.

Булмады, булмады! Язмаган икән, миңа табиб булу да, үз әтиемне үзем дәвалау да язмаган икән. Кыш уртасы вакыт, безнең каникуллар иде. Әти Әтнәгә, укытучыларның ел да үткәрелә торган кышкы конференцияләренә барырга җыенып йөри. Аның әллә ни хәлләре үзгәреп, сырхаулары көчәеп йөргән вакытлары иде бу. Ә көннәр бик салкын тора. Шунда Әтнәгә җәяү чыгып китәргә исәп тота бу.

— Җәяү бармыйсың. Үзем ат җигеп илтеп кайтам мин сине! — дидем мин аңа. Ат чанасына күп итеп печән салдым, әтине үзебезнең һәйбәт толыпка төрдем. Әмма ул көннәрнең салкын һавасы әтиебезнең зәгыйфьләнеп беткән үпкәләрен барыбер куырып алган булып чыкты. Әти инде моннан ары мәктәпкә менеп укытып та йөри алмады. Конференциядән кайтып керешенә урын өстенә егылды. Шул елның февраль аенда ук вафат та булды. Әти үлгәч аны карап, тетрәнеп киттем. Бичараның үпкәләре шулкадәр кабарган, менә күкрәк читлеген ерып җибәрерләр төсле иде. Җанашым, вафатында әле ул да карт түгел, илле җиде яшендә генә иде.

Әтиебез үлгәч, ничек яшәгәнебезне, алга таба тормышыбызны мин бер язып чыктым инде. Кабатлап торулар кирәкмәстер. Тик инде үзе дә күптән вафат икенче әниебезнең изге рухына тагын бер кат рәхмәт хисләремне белдерәсем килә. Әтинең вафатыннан соң күпләр аны безне ташлап китәр дип юраганнар иде. Ул алай итмәде. Без үсеп туган йорттан таралып беткәнче тәрбия кылды, хезмәтен кызганмады.

Әни авылда, энебез Гаяз һәм киленебез Рәйсә тәрбиясендә кадерхөрмәттә торып, бик картаеп, сиксән өч яшендә вафат булды. Исәнлегендә без аның янына гел кайткалап тордык, кадерен белдек, соңгы юлына да олылап озаттык...

И минем газиз әниләрем! Берегез безне бу якты дөньяга китерде, икенчегез үстерде, олы юлга чыгарды. Һәркайсыгызның урыны оҗмахта булсын. Йарабби!

*Июнь, 1996 ел.*
*Арча.*

# ШИГЪРИЯТ



## Равил Фәйзуллин

### ӘЙ, БУ ЯШӘҮ!..

### Әзерлек

Һич нәрсәгә гаҗәпләнмим:
күргән-күрелгән.
Шатлык-кайгыларны сөздем
йөрәк төбеннән.

Тамчы көнләшү юк — бездән
алдан өлгергәнгә.
Үзенә язган тиешлесен
барыбер ала бәндә.

Бетте ул әчеләнешү
җыен юкка-барга.
Әле бит азмы-күпме тагын
гомер бар күк алда...

Мал-данга да исем китми,
хәтта — яшь тәнгә.
Төп байлыгың — ул ныклыгың —
Рухың икән лә!

### Гасабилану

*Иҗади яну*

Күрә — күз, кабына — дәрт.
Күңелдә — утлы сурәт!
Моны, дим, бүтәннәр белән
уртаклашырга кирәк!

Шундый олуг уйлар башта! —
Җиһанны каратырлык!

Алар, бәлки, кем өчендер,
бәлзәмгә ярарлыктыр?

Тик ни хикмәт... сүзләр, сүзләр,
сүзләр генә табалмыйм...
Димәк — көч юк... Ник үземне
«Син — фәлән!» дип алдалыйм?

Бәлки, мин — кысыр чәчәкле
алмагачтыр ялангач?
Күңелеңдәген кәгазеңә
күчерә дә алмагач!

## Триптих

I

Туган җирең чүл булса да,
күңелдә ул гөл генә!
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!

II

Акыл да бар, каләм дә бар...
юк шул билдә... балтасы!
...Өтек шул Шартнамәне дә!
Турамакчы мең кайчы!

III

Кылычтан качып, «дуслык»ка —
(колыкка) юл — иелү...
Тарих белми: Ирек өчен
кан түкмичә җиңүне.

* * *

Әй, бу Яшәү!
Шомлы! Тилерткеч кызык!
Илаһ көч йөри Биләүне
Кәфенгә кадәр сузып.

Таң, Шәфәкъ — кызыл. Арада —
Көн — ап-ак, Төн — кап-кара...
Мәхәббәт-нәфрәт эчендә
саваплы булып кара!

Җитсәң дә Акыл тавыңның
биектәге читенә,—
Яшәү дигән Бөек Серне
аңламыйча кителә...

Шул сорау кала киткәндә
балаларның күзендә.
...Шундый ук вәзгыять язган
аларның да үзенә.

## Куян ату

### I

Атуын аттым...
Әтидән тунаттым.
Җанымны канаттым.
Мылтыгымны саттым.

### II

Тиресеннән кан саркыган
ул куяннар мине бик еш эзәрлекли.
(Башта үзем йөрдем эзләреннән, хәзер — алар).
Күзләре һич кылый түгел —
зурлар, җанлы һәм тереләр!
Вәхшилектән гаҗиз калган моңсу күзләр:
«Ничек инде? Кеше кадәр кеше булып...
Җан кыя ала?..»
...Әшнәк өстендәге япан кырның
тере бизәкләре кимеде...
Эскертләрнең төсе үзгәргән күк.
Ябалакның карашында — сагаю һәм мыскыл.
Кырпак кардан чыгып торган сап-камыллар
чын нәфрәт энәләре.
Сагыш баса куе томан булып.
Ямансу...

### III

Әй, сентимент Кешем!
Ярты гасыр яшәп — күрмәдеңме?
Тарихлардан сабак ала белмәдеңме?
Җинаятьләр хәятеңдә йөрмәдеңме?
Син түгелме язган:
«Җирдә халыкларны юк итәләр.
Күк катында кемнәр бар анда?
Йә, Алла!
Ләйсәннәрең җанны юа алырмы
күздән канлы яшьләр акканда?»

### IV

Бу бит ау, дим,
сунарчылык —
бакый гомер ирләр шөгыле;
табигый бер азарт, мавыгу, дим,
ерткыч асылымны яшереп...

## «Җәй — 96»дан бер сурәт

*«Аккош күле» циклыннан*

Урман эчендәге сихри күлдә
йөзә елан.
Йөзә сылу кыз.

Карап торам яр өстеннән.

Сыгылмалы боргаланып «шуышалар»...
Әкияти грация!

Күрде дә кызый тузбашны (аера!),
янәшәләп йөзде бераз,
аннан... аны куып, өркетеп,
кысырыклап алып чыкты комлы ярга.
Табып алды шундук тал чыбык.

Әй, уйната:
чыбык белән әле билен,
әле сары башын күтәрә,
әле чөеп ата...

Елан да шул: «Мин барыбер сыгылмалырак!
Уралуым, сарылуым күпкә өстен!» дигән сыман
Һич бирешми... Әле бөгәрләнә боҗра булып,
дугаланып сыртын күтәрә,
сары таҗлы башын чөеп, ыслап ала...

Әкиятләр искә төшә.
«Кайсы елан? Кайсы аждаһа?
Кайсы юха? Кайсы Сылу Кыз?..»

Бөек фантазия! Чын уен!

—

*Читтән генә карап торам.*
*Тамашага керә алмаган*
*бер ят кеше — мокыт бер ир-ат.*

* * *

Дөрләп янган зиратларны
сүндереп йөрүче без имеш.
Бәгырең меңярып, мең көеп,
иманлы кала ал шул килеш!

...Күккә ашкан җаннарга ялвару:
«Безгә анда ни хөкем, ни өлеш?»

* * *

Әкиятләрен тыңлыйсың,
хәшәплеген күрмисең.

Кичерәсең ялганнарын,
уйгач шигырь өлгесен.

* * *

Кайдадыр сугышлар бара,
Кемнәрдер бетчә сыта...
Нишлисең? Кайчак амеба
тау хәтле филне йота!

* * *

Ваклар эреләнеп калыр...
без киткәч.
Ярлар бер тулышып алыр...
боз киткәч.
Ата йортында гөл шытар...
кыз киткәч.

* * *

Бер карыйсың — Алып.
Бер карыйсың — Сарык...
Дөньяның олтанына
ярый торган халык.

* * *

Кирәксә әйт: «Ташладым!» диң.
Мин ташларга ирендем.
Алма үзе өзелеп төште.
Кемдер әйтте: «җил!» диде.

* * *

Иртәнге җил, кичке салкын...
Яшьлек — җегәр, картлык — акыл.
Тормыш — сызык, яшәү — өтер...
Үткән гомер, калган хәтер...

Кан туңса да, йөрәк ялкын!
Иртәнге җил, кичке салкын...

* * *

Әллә бар да, әллә юк та син.

Вакыт түмгәгендә аяк бөкләп
матур гына оеп йокла син!

Хәер...
җан иңдергән бер тәңре белә
кемнең
кайчан,
ничек,
кайда
туктасын.

Минем өчен күптән
әллә бар да, әллә юк та син.

* * *

Тәннән аерылып чыккач,
кемнең җаны —
Күккә ашып, йолдызларга нур өстидер...

Кемнең — алай үрли алмый,
калай кәрнизләрдә,
карга ояларында каладыр...

Кемнең (хаиннарның, кеше гомерен кыючыларның) —
тәгәридер җәһәннәмгә —
нәҗес аккан торба, чокырлар аша...

...Ә әлегә утыралар бергә
чилем тартып, җырулар җырлап...
«Бөеклекләр!» диеп, лаф орып.

* * *

Төн һәм Суык. Бу икәүдә,
нинди дәһшәт көч ята!
Караңгылык һәм Салкынлык
җиһанны калтырата!

Тик...
Чигенә алар: Шом түреннән
Кеше чыга уртага.
Җир актарып, чакма ташын
яшен итеп, ут таба!
Ут — ул җиңү! Ут — ачык юл
Яктылыкка, җылылыкка,
Язга — Кояшка таба.

* * *

Ул да вафат...
Әйттең шунда куркып-каушап:
«Юк! Юк, юк!.. Мин китмәм!»
«Озакка каласыңмы соң?» дип,
Җил сызгырды ишектән.

Кемгә — җитмеш. Кемгә — туксан.
Кемгә — унсигез генә...
Вакыт, иләп гомерләрне,
Һәммәбезне тигезли.

Җирдә — калган адәм юктыр.
Барыбыз бер үк юлда...
Калса калыр, балам аша
Тәңремә кылган догам.

## Нур

Кеше кулыннан соранып,
алмадым бер чеметем.
Сызылып аткан таң нурында
минем бөтен өметем.

Йөрткәч шул нурны үзеңдә
күңлең кояшлы була.
Нәфрәтем йоклый песидәй,
җанга тынычлык тула.

Таң иңдергән нур-яктыдан
алам илһам-иманны.
Төнен Ярым куенына
алып керәм мин аны.

* * *

Күз яшьләре бизе кипте.
Шаккатулар — бетте.
Тик исемен генә белмим —
ниндидер чак җитте.

Тсс!.. Исемен дә беләм!
Тик әйтмим генә!
Кешеләр бит халәтемне
бүтәнчә дип белә!

Кызык ул: юк тәкә башын
юк казанда бүлү!
...Һәркемгә дә татымаган
яшь аралаш көлү!

*1997*

# ПУБЛИЦИСТИКА



Фаяз
Дунай

## ЗАМАНЫНА КҮРӘ ЗАНЫ

Кеше гомерен агымсуларга тиңлиләр.

Тирә-як мохитыңа, даирәңә карап кына да уйланып китсәң — инанасың: ул замана дигәннәре кеше гомеренә караганда да тизрәк, куәтлерәк агышлы, үзгәрүчән икән бит. Чөнки бер шәхес гомере генә дә ничәмә-ничә икътисади-сәяси, социаль-иҗтимагый, шәригати-әхлакый эчтәлекле елларга, чорларга тап була икән бит...

Әле кайчан гына, менә, кул сузымында гына, без социалистик-коммунистик катгый режимда, кысаларда яши идек, хосусый милекчелекне дошман күрә идек, үзенең шәхси мәнфәгатьләрен дә онытмаган булдыклы эш кешеләрен дә «алыпсатар-спекулянт», «үз җаен гына кайгыртучы индивидуалист, «кулак коерыгы» яки «шабашник» дип, сүгә идек, карикатуралар ясый идек... Ә хәзер күр инде, әнә: кем нинди гамәлне булдыра ала — рәхим итсен! Алсын-сатсын, төзесен-корсын, нәрсәләрдер ясасын, осталыгы бар икән төзәтсен, ремонтлатсын, үз фикер-тәкъдимнәрен, проектларын, сызымнарын, идеяләрен гамәлгә ашырырга тырышсын... Тик һәр даим үзгәреп торучан теге яки бу закон маддәләрен бозмасын да, казнага фәлән-фәлән салымнарын гына түләсен. Аның нининдер шәхес булуына да игътибар багып тормыйлар хәзер.

Зиһен салыбрак уйласаң, бусы да хәтереңә төшәр: ә бит бүгенге мондый иркенлек-ирекле лек, мөстәкыйльлек кинәт кенә, тылсым белән генә уптым илаһи тумады. Беләбез ич инде: бүгенгенең орлыклары узган көннәрдә, елларда ук шыта башладылар. Ә мөстәкыйльрәк яшәргә, эшләргә, үз ризыгын, үз мөлкәтен үзе табарга тырышу гадәте адәм баласының борын-борыннан ук канына, җанына сеңгән.

Мөстәкыйльлеккә омтылуның башлангыч икътисади, социаль яралгыларын күреп, өйрәнеп һәм үзем дә шундый эшләрдә катнашып, инде сиксәненче елларда ук мин матбугат органнарына «шабашник» дип аталган бер социаль тип, төркемнәр турында реаль язмалар тәкъдим иткән идем. Кая ул! «Тапкан кемнәр турында язарга!» — дип, миннән төрлечә көлделәр генә. «Шабашниклар»ның гамәлләренә миһербанлы күз белән карарга ярыймыни, янәсе. Шул язмалар, нәкъ менә үзем күреп белгәннәрне тасвирлаган ул көндәлекләр, кай ара җанымны сызлатып, унҗиде ел буена китап шкафларымның иң арткы почмакларында саргаеп яттылар. Ә бит ул язмаларда, иманым камил, нәкъ менә реаль тормышның реаль хәл-әхвәлләре ихлас тасвирланган иде.

Без үткәннәр белән көлеп аерылышабыз, дибез. Шулай, шулай. Әмма ул үткәннәрне дә күрмәмешкә салышырга, көлсәк-көлмәсәк тә, алардан качарга тырышырга һич ярамыйдыр бит. Чөнки без, үткәннәрсез бүгенге юк, бүгенгесез — киләчәк юк, дигән кадими, акыллы гыйбарәне еш кабатларга яратабыз ич.

Хәзерге хөррияттән, сүз иреганнән файдаланып, мин бу язмаларны бүгенге көн укучысына да тәкъдим итергә булдым әле. Тәэсире дә, мәгълүм дәрәҗәдә игелеге дә, гыйбрәте дә булмый калмас, иншалла...

## Кем иде ул шабашник?

Күк гөмбәзе әлегә якты, биек. Ләкин аның кыраулы сулышы салкынча, зәңгәрлеге куерган инде. Шул зәңгәр гөмбәздән шуып, гомерләрнең кадерен бе-ле-гез, кый, ай, заяга узмасын, кый, дигән сыман каңгылдашып, кыйгач торналар төркеме узды. Көндез соңгы кат бизәнеп, ахыр елмайган көннәре — әбиләр чуагы җиһанда.

Яшь каланың бормалы бер йорты алдында, әле ялтыр буявы да сүрәнләнергә өлгермәгән эскәмиядә, озын, чандыр гәүдәле, җирән чәчле, сипкелле йөзле бер ир-ат утыра. Чырае якты, тыныч. Каршы яктагы яшь каеннарның инде боегып, саргаеп баруларын ваемсыз гына күзәтә дә ул, ара-тирә кул сәгатен капшап куя. Ашыкмый гына кемнедер көтә бугай.

Беравыктан йортның биек дугае аралыгыннан кулына күн букча тотып бер кызчык килеп чыкты. Сипкелле агайны күргәч тә самимилек белән елмаеп җибәрде. Йа, дөнья! Бөтен әйләнә-тирәгә шул кызчыкның соры-яшькелт зур күзләреннән, озын кара керфекләреннән, саф алсу яңакларыннан, хәтта, чигә чәчләренең бөдрәләреннән көмешле нур сирпелеп чәчелде сыман. Әй, тормыш! Шушы бер баланың эчкерсез бер елмаюы белән генә дә ни дәрәҗә ямьлетылсымлы син, газиз-мавыктыргыч, илһамлы син, тормыш...

Әлеге сузан агай да бу сабак баласының табигый матурлыгыннан, якын күреп садә елмаюыннан яктырып, җанланып китте, аның битендәге сипкелтаплары беравыкка юылып, югалгандай булдылар. Агай җилсенеп карлыккан тавышына йомшак моң салырга тырышып, шат кычкырып кызга эндәште:

— О-о! Минем күрше эштән кайтып килә!

Кыңгыраулы-көйле тавышы белән кызчык җавап кайтарды:

— Эштән түгел. Мәктәптән!

Кызчыкның гөнаһсыз бу «төзәтмәсе» әллә агайга ошап бетмәде, ул елмаюын яшереп үчекләшеп дәште:

— Бүген дә «икеле» төяп кайтасыңмы? Ул тәти портфелеңә, дим?

Кызчык, чын мәгәр, кына гөле ботакларыдай ике бармагын тырпайтып, үз сөенечен бүлеште:

— Менә! Ике «бишле»! Берсе географиядән, берсе — рәсемнән.

— Ой, мактанчык! Әнә же, базар түтиләренең кәрзиненнән муеннарын сузган ата казлар кебек, хи-хи, синең «икеле»ләрең дә портфелеңнән сузылып карыйлар, хи-хи...

Кызчыкның кинәт бөтен төс-кыяфәтенә соры күләгә ятты. Ул кинәт тын калып, ни дип җавап бирергә белмичә, әллә чыннан да шулаймы икән дигәндәй, күн букчасын әйләндергәләп карады, аның озын керфекләре еш-еш тирбәлеп, калтыранып куйды, әлеге садә нурлы күзләре ихлас аптырау, гарьләнү яше белән мөлдерәмә тулып, тагын да зураеп ачылдылар.

Агай кызчыктагы бу утлы-бозлы бизәкләрне әллә күрми, әллә санга сукмый, һаман үчекле елмаю катыш үзенекен тукыды:

— Ох, икеле капчыгы син. Ух, икеле капчыгы!

Кызчыкның алсу бөре иреннәре дерелди. Ул тагын бермәл аптырап, үз-үзенә нидер пышылдап торды да, затлы пыяла ватылгандагы кебек тавыш белән ачынып, өзгәләнеп кычкырды:

— Ә син шабашник! Ша-баш-ник!

Шунда ук, мөгаен, елап җибәрүдән куркыптыр, подъезд ишегенә ташланды. Ишекне кире ачты. Әлеге рәнҗүле тавыш янәдән кабатланды:

— Шабаш-ник, ша-баш-ник!

Алюминий ишек кабат шапылдап ябылды. Каршыдагы куактан пырхылдап чыпчык очып китте. Озын, чандыр агай урыныннан күтәрелде. Аның болай да ач яңаклы сипкелле йөзе тутыккан иске бакыр комганга охшап каралды, төссезләнде. Безгә, бер йортта яшәп, ара-тирә күрешеп-исәнләшеп йөрүчеләргә, ялганы фаш ителүдән оялып, ашыгып-кабаланып китеп югалды. Безгә бит ул үзе хакында башкачарак сөйли торган иде. Без бит аны кайсыдыр су хуҗалыгы фәннитикшеренү институтының Чаллыдагы филиалында эшләүче инженер-геодезист дип белә идек. Җәйләрен ул чынлап та калага сирәк кайта, көзгәчә югалып тора. Көзнең кышка күчәр көннәрендә исә өчәр-дүртәр көн сәрхүшләнеп йөри-йөри дә,

кинәт, үзе әйткәнчә, берәр атнага аракыдан «каникулга чыгып», Камага балыкка тая. Орынып торган күрше кызы исә (ата-анасыннан ишетептер, әлбәттә) бу агайның кәсеп-шөгылен яхшырак белә икән бит. Тау чишмәседәй саф хисләре тибеп торган риясыз кызчык, күрәсез, гарьлектән, бала күңелен аңламыйча дорфа үчекләүче, итагатьсез агайга мөһер сүзне сукты да ябыштырды: ша-баш-ник!

Балалар да мыскыл кушамат итәрлек нинди рәвеш — гамәл, нинди кәсеп-шөгыль соң ул, әй, шабашник?..

## Кытлык ачты капканы

Чирмешән буендагы авылларның берсендә колхоз рәисе үзләренең балта осталарын тирги:

— Валлаһи, тәмам бозылдыгыз! Рәхәткә тарыдыгыз. Келим икән, эшкә сәгать унда, кояш кыздыргач кына киләм, ә! Ул да төгел, кара, әбит килеп житкән! Кайтып ылкынганчы ашыйм да, берәр жиләс жиргә ятып, тагын берәр сәгать черем итеп алам. Аш сеңдерергә кирәк бит, янәсе. Инде бер дә ашыкмый гына килеп, өч-дүрт такта юнасыз да — житәр бөгенгә! Әдә, әдә, кайтыйк инде, Рәхимулла, кайтыйк, бер ынайдан кибеткә дә сугылып чыгарбыз. Жай чыкса, берәр стаканны кагәрбез, ә! Үзегез — дүртәү, ыжгырып торган ир-ат! Сабанга жигеп зәб сукаларлык. Булмаса, әнә, шабашниклардан оялыр идегез. Ягадан килүчеләрдән. Алар таң бәбәгеннән аяк өстендә. Кайчан йоклыйлардыр? Шуңа күрә эшләре дә бара шул, күзгә күренеп үсә...

Сагыз тамчылары алтынланып торган нарат бүрәнәләренә утырышкан балта осталарының берсе, керле көрән кепкасын ямьшәйтеп башына кигәне, юан муенын боргалап сүз ката:

— Эш-лә-сен-нәр. Алар бит акчасын да көрәп алалар, әзи. Меңәр тәңкәләп...

Колхоз рәисе янә кабынып китә.

— Ятлар кесәсен кабашлама син, наный. Зур акча телисез икән, соң, факырлар, мин тыяммы әллә? Эшләгез, алайса, сез дә алар кебек, иртәнге таңнан — күз бәйләнгәнче.

Иягендәге зур миңендә озын кара төк тырпаеп торган икенче бер абзый тамак кыргалап сүз сала:

— Эшләгән чаклар да булгандыр инде, яшьти. Хәзер — шөкер. Ул кәсепчеләрдән оят дип, һәмишә без дә теге ни, каторжаннар кебек көчәнмәбез инде. Закуны да алай кушмый. И хажәте дә юк. Булганы — житкән. Дөнья малы...

Колхоз рәисе аның әйтеп бетергәнен көтми:

— Канишны, син шөкерана кылып кына ятасың хазер, булганы ник житмәсен?! Ызбаң — мәчет хәтле. Келәт-паетларың албут уты кебек, ә! Сад-бакчаңда — жәннәт. Сигез оя умартаң, йорт тулы терлегең. Мин бит акча кәгазьләренә үзем кул куям лабаса. Күрәм. Катының белән үзеңә, улыңа-килененә, дүртегезгә, ай саен жиде-сигез йөзне йомарлап барасыз сез. Канишны, сиңа хазер читтән килүчеләр кебек ничу көчәнергә...

— Күпсенмә, яшьти. Орлап жыйган мал төгел, эшләп тапкан халәл малыбыз, шөкер. Ул шабашниклар да ыштансыз-күлмәксез зимагурлар төгелдер әле. Өчәр-дүртәр кумытлы фатирлары да бардыр, дача-мачалары да. Анә, гәзитына, журналга белми язмыйлардыр. Машина или теге ни, кечкенә, карсак парахуд — йөзләп ат куәтле моторный кимә алабыз дип, тир сыгалар, ди. Һәмишә житми адәм баласына...

Күреп калам: сыңар зәңгәр күзле, сап-сары кылчык мыеклы икенче агай тегенең аягына басып алды. Бик туарылып китмә, телләшмә, янәсе, ят кеше барында. Миңле ияк тынып калды.

Сары мыекның бу ишарәсен колхоз рәисе дә шәйләде-абайлады, бугай, килешүчән тату якка күчте:

— Күпсенмим, Миңнулла, алай димә. Дөрестән дә, эшләп таптык малны һәр барчабыз. Шабашниклар акчасына да ничу кызыгырга. Машина да, кимәкатер дип кенә, ирекле көннән чегән кебек йөрмиләрдер әле. Яздан кара көзгә хәтле. Ни яллары, ни бәйрәмнәре юньле түгел. Кеше хәлен кеше белми. Алсыннар тиерен. Эш күп, егетләр, тәэсисе, тәзәтәсе күп, факырларым!..

— Ярар, әзи, безнең өчен бик ватылма. — Сары мыек жәһәт кенә бүрәнә өстеннән күтәрелде. Ул биредә звено башлыгы иде, күрәсең, башкалар да аңа ияреп кузгалдылар. — Бүтәнчә сүз әйттермәбез. Тактасы булмый торды бит. Шунысы кулны тотты...

— Ул терлекчеләр ызбасының, инде бик каһәрләсәң, егерме-утыз квадрат идәне бардыр. Шуны да бит мона атна буе җәясез, ә! Һай, факыр, такта юк, имеш, таптың сәбәп! Кая утырганың арт саның тоймыймы әллә? Боларны соң...— Колхоз рәисе киез туфлясы белән бүрәнәләр әрдәнәсенә тибеп куйды.— Әллә оҗмах капкасына дип апкайттыкмы?! Канишны, мин аларны шабашникларга бирмим. Урмандагы дисәтникның да колагына тукып куйдым. Янадан килүчеләргә, мәйтәм, кәкере-кыегын, ботаклыларын кистереп ташыт. Утынлык диләнкәсеннән ташыт, мәйтәм. Шундыйларны игә кертеп салсыннар телəтникне. Рәтлесен, җитмәгәнен үзләре эзләп тапсыннар, мәйтәм. Акчасын түләрбез. Ну, сезгә инде, факырлар, бер дә сырланырлык төгел. Кара инде бу бүрәнәләрнең шомалыгына — кочаклап сөярлек бит, ә! Такта юк, имеш, ярдырыгыз, ярыгыз булмаса.

— Пиларам буш төгел бит! — Барысы исеменнән әлеге сары мыек сөйли.— Һаман шул шабашниклардан бушамый. Рамщик Хисами да алар яклы. Майлап торалар, күрәсең, дуңгыз яркасың, гел кызмача. Таралган да төшкән. Тегеләр хәзер таң тишегеннән үзләре ачып керәләр пиларамны, трактор да гел аларда...

— Ну ват, мона-мына! Иртә торган — уңган, дип кадимидән юкка әтмәгәннәр.— Колхоз рәисе, мөгаен, миңа сиздермәскә тырышып, уңъяк симез бит алмасын сикертеп ала. Күз кысуы.— Майлыйлармы, юмалыйлармы — әлегә безгә караңгы. Ну, кирәген алалар да, табалар да. Ә сезнең учыгызга китереп салырга кирәк. Янбызыгызга төртеп. Әтәм бит, чыктыгыз рәхәткә!

Миңле Миннулла агай председательнең «алма уйнатып» алуын абайламый калды, бугай, шактый йөрәксенеп әйтеп салды:

— Син, яшьти, үз кешеләр дип, безне генә һаман-һаман хаит итмә. Калхуз мәнфәгате өчен дә ярты-бөтен кыстырып, камыт сыйрак Хасимига ялынып йөрге келәми. Чурту! Пәрәдке булсын пиларамда! Бездән эш тормас. Әт ул дисәтникмачтырга да, сыны катканчы итеп әт. Шабашниклар тирәсендә генә бохар мәчесе кебек сыргаланып-сыпыргаланып йөрмәсеннәр!

— Йа, алла! Каныктың тәки шул шабашникларга.— Председатель Миннулла агайның җилкәсенә кулын салып алды.— Ярар, ярар, чәпчемә юкка. Алай бик узынып китсә, пилорамщик Хисамины да тотып чагарбыз. Бөген кич үк мастерны да керендерермен. Йөрмәс бүтән бер мәхәллә мәчетен генә кайгыртып. Бездә телəтник кенә төгел, анә, кругом тәзисе, төзәтәсе күп. Трактор, машиналарга да чиратын билгеләрбез. Давай, ярдырыгыз бу бүрәнәләрне. Тәҗел кирәк!

Балта осталары башка сүз катмыйлар, әлеге ишек-тәрәзәләре дә куелмаган зур агач өй эченә кереп югалалар.

Без колхоз рәисе белән җәяүләп кенә ындыр табагына юл тотабыз. Куе яшел «УАЗ» машинасы акрын гына арттан килә. Юлдашым тастымал хәтле кульъяулыгын чыгарып, елтыр пеләш башын, пешеп җиткән карбыз эчедәй кызылсусыл түгәрәк йөзен, сырлы муеннарын сыпырып ала. Яше илленең өске ягында, үзе аяклы дәү глобус сыман түгәрәк, карсак бәдәнле булса да, әлегә галәмәт җиңел, җитез атлый председатель.

Мин сүз яңартам:

— Балта осталарыгыз читтән килгән төзүчеләрне өнәмиләр шикелле...

— Төрлесе бардыр инде, наный. Тормыш бит. Адәм баласына ярап бетеп булмый. Калхуз малын ятларга җибәрергә дә теләмиләрдер...

— Соң, үзегезгә зуррак, куәтлерәк төзелеш бригадасы булдырырга җайчама юкмы?

— Юк шул, наный, юу-у-ук. Шыңа аптырамыш. Авылда хәзер ир-атның күбесе машинага утыру ягын карый. Нишлисең, заманасыдыр шыңдый. Анә, бездә генә дә йөзгә якын шуфирдыр, тракторчы, комбаенчыдыр бар хәзер. Кулалмашлап эшләү дә гадәткә кереп бара. Ә бит аларына өстәп, инженеры, механигы, токаре, сварщигы, электригы... Һәй, хуҗалык итим, көн итим дисәң, барчасы кирәк. Фермаларга, сушилкаларга, кыр-басуларга су сиптерергә дә унар төрле машинасын, җиһаз-насосларын куябыз хәзер. Ир-ат тагын шыңда атлыгып тора. Ә менә балта-пычкы, өтерге-ышкы, алмаз тота белүчеләр кәми бара. Кәми! Ташчылар юк авылларда, рәтле-юньле пич чыгара белүчеләр юк. Мәктәп балаларына да кору-төзү һөнәрләрен бер дә өрәтмиләр...

Колхоз хуҗасының бу сүзләре тәэсирендә, мөгаен, шушы кыска минутлар агышында ук мин бу хакта үзәк матбугатның да борчылып язып чыкканлыгын исемә төшереп алам.

— Авылыгызда хатын-кызга кытлык юктыр. Эш бармы үзләренә?

— Кыз-катын җи...тәрлек. Ну бит, наный, аларны, анә, хәзер чалбар кисәләр дә, бура бурарга да, таш-кирпеч үргә дә куша алмыйсың. Кыскасы, наный,

син әткән стройбригад тәзерлек әмәл юк бездә. Кешесенә катлык. Күп хуҗалыкларда хальләр шылай, мөшкел хәзер...

— Районыгызда уртак төзелеш оешмасы — СМУ бар...

— Барын бар да — колачы бик чамалы шул хәзергә. Ни техникасы, ни стройматериалы. Авылларда төзисе-корасының яртысын да булдыралмыйлар әле.

— Ә бу, теге «Сельстрой», «Агрострой» кебек трестларның күчмә-механик колонналары ишәя бара. Мактыйлар да, мал кадерен белмиләр, алдау-йолдау күп дип, эт итеп сүгәләр дә үзләрен. Сезгә файдалары тияме?

— Утсыз төтен чыкмас, наный. Гөнаһлы булгым килмәми, кайбер якларда бәлки чүеп-чөеп мактарлык эшләре дә бардыр. Ну, безнең тирәдә пока әллә ни кинәндермиләр. Бәк кукыраеп, зур акчалы корылышка гына алынган булырлар, факыр. Берьюлы өч-дүрт хуҗалыкта. Нигез-эргәсен дә казып куярлар ул корылманың, берничә рәтен дә салырга можетлар. Ышанычка кереп, ул хуҗалыклардан акча дауларга кирәк бит. Процент алырга! Бирәсең, алдан артыгын да бирәсең күңелләрен күреп. Ну ват, шыннан, бирнәне бөрмәгә бәйләгәч, китә, факыр, кояшта, җилдә кызыну. Җәен бик кызу, кышын — салкын дигәндәй, ту эшләр кешесе килми, ту — техника юк...

— Ә план соң, план? Шартнамә сроклары?

— Өч-дүрт җирдә маташканны илаһи уптым кушкач, дога кылырлык буладыр ул, аларның планы. Ну, башкарып-очлап чыкканнарын көтүе әҗәл. Клуб бирсәң, — клубын, абзар дисәң — абзарын салып бетергәнче яртылай картаясың...

Председатель кинәт кенә барган юлыннан туктап, зәңгәрсу алмаларында кызгылт кан җепселләре беленеп торган зур күзләре белән миңа сынап карый:

— Син, наный, берүк боларны мин сөйләде дип, калхузның да, минем дә исемнәрне атап, газетка яза күрмә. ПМК абзаңнар безнең якны... савсим кыеклап узарлар. Корт чагудан яны бизгән төлке кебек, коерыкларын кысып. Кирәген баштин ашканда әтәч сугыштырмау хәерлерәк. Анә, берчак аягын сындырган сыерны, төзәлмәслек булгач, суйдырган идем. Шул хәбәрне ишетүгә РАПОсыннан, милиция бүлегеннән ит сорап килеп җиттеләр. Авылда да иткә мохтаҗ кеше аз төгел. Бирә алмыйм, дип, тегеләрне кире борган идем — атна-ун көн узмагандыр, юк гаепләрне бар итеп, кәмиссия артыннан кәмиссия җибәрделәр. Теңкә корыды!..

Елмаю катыш мөмкин кадәр ихласлык белән рәис аганың шик-хәвефләрен таратам да, сүз йомгагын үзем үк ары сүтә барам:

— Хуҗалыкта, мәйтәм, комплекслы эре объектлар салу гына түгел, үзгәртеп төзисе, ремонт ясыйсы яки күчереп утыртасы биналар да шактый бит инде сезнең. Үзегез әйткәнче үк, заманча кибете дә кирәк, хастаханәсе яки медпункты, балалар бакчасы. Мәктәпкә дә булышасы бар. Әнә, күпме кеше яңа йорт житкерә ел саен...

— Шылай, наный, шылай. — Председатель минем салпы якка да саламын кыстырып куя. — Кара, авыл хальләрен дә күреп-белеп яшисең икән бит шәһәрдә дә. Рәхмәт. Дөрес, наный: ват шындый тәжел эшләргә, килеп чыксалар, биш куллап шабашникларны яллыйсың инде. Ягадан килүче сезонлы төзүчеләрне дию ем. Аларны бәк мөкиббән китеп, көсәп торудан төгел. Нужаң куша. Кытлык ача капканы!..

Ындыр табагына килеп житәбез. Ул әлегә тын. Анда әлегә шук малайлар сыман каяндыр койманың ярыгын табып, аулакка узган бозаулар хозурлык кыла. Былтыр түгелеп калган орлыклардан тубыкка житәрлек булып уҗым үскән. Бер якта ашлык җилгәртү, төяү-бушату агрегатлары, озын-кыска транспортерлар. Күпер-баскычлары салынып-сыгылып төшкән, тераүле-ямаулы амбарлар буена киләбез. Председатель агай үзе дә зарлана:

— Амбар-складлар бик тузды, наный. Шыңа да җаным куә шул. Күр инде, әнә, автовесны — кешедән оят бит, ә?

Чыннан да автоүлчәү бинасының түбәсе бөтенләй «эшләпәсез калган», як-яктагы исәп-хисап бүлмәләренең идән-стеналары кәрәнләнеп черегән инде, типсәң — уалып китәрлек.

— Һай, наный, берсе-берсе миллион пот ашлык сыярлык амбарлар корыйк, дисәк тә — акча бар бит безнең. Кирпечен дә юнәтер идем, агачын да. Шынысы кулны бәли шул — хәзер кешесенә кытлык!

Колхоз рәисе исәпле-уйлы караш белән янә бер кат иркен ындыр табагын күзләп-әйләнеп чыга. Аннары, мөгаен, күңеле ачынып кулын селти. Кире капкага таба атлыйбыз.

— Син, наный, Казанда да, Әлмәтендә, Чаллысында еш булам дисең, анә. Җибәр безгә ул сезонлы эшчеләрне юллап, ә? Зинһар, кодалап җибр. Калхузның малы житәрлек, техника бирә, диген. Фатир кайгыртмасыннар. Иткә суяр үгезләре аймут-кибән хатьлеләр, эшегез барса, сарыгын да жәлләмиләр, диген. Персидәтелләре упытлы кеше дип әт. Раюнда абруе бар, кәгазь-килешү якларын үзе үк юллап йөрер, дип әт. Юл ерак дип курыкмасыннар, машина җибәреп алдырырмын...

«Хужа»ның гадәтен яхшы беләдер, шофер алгы ачык ук «УАЗ» машинасын председательнең аягы очына ук китереп туктатты.

— Кара, зиһеннән үк чыккан — төш узып бара икән бит. Әбит вакыты диюем. Ашыйсың-эчәсең дә келидер. Әдә, наный, башта Гариф картка кереп, бал куасы гына булса да эчеп чыгыйк. Әдә, наный, әдә...

* * *

Биредә тасвирланган хәл-әхвәлләрдән соң, әйткәнемчә, унжиде еллап гомер узган инде. Илдә-көндә нинди генә «үзгәртеп корулар» булмады. Бу үзгәрешләр, әлбәттә, әлеге хуҗалыкны да читләтеп узмагандыр. Аларда хәзер эшче кулларга бөтенләй кытлык беткәндер. Киресенчә, үз эшчәннәренә шөгыль таба алмыйча интегәләрдер әле. Өстәвенә төрле төбәкләрдән, калалардан мәҗбүри куылып кайтучылар да аз түгелдер хәзер бу хуҗалыкта да.

## Апалар ни сөйли?

Әлмәт—Чистай юлы читендәге уйсу җиргә таралып утырган икенче бер авыл кибетендә сүз шабашниклар хакында моннан башланды.

Шәһәр кибетләре тулгандырмы, әллә потребсоюз вәкилләре артык өлгерлек күрсәтеп, үз мәнфәгатьләрен чамасыз кайгырткканнар — яшелчәгә һич мохтаҗлык кичермәгән шушы авылга пешәр-пешмәс карбыз китереп тутырганнар. Ул карбыздан бала-чага да гарык булган инде, урамда туп урынына типкәләп уйныйлар. Кәҗә-бозаулар да бик канәгать. Ә сатасы карбыз күп икән әле. Сатучылар, бу карбыз бозылыр бит, дип пошынганнар. Теге, табигый югалту, дигән әҗерле нормадан да узып черер, янәсе. Гамәлдән чыгарабыз дип, акт язучы да булмас. Җитешмәгән хакын кара җилән итеп җилкәңә салырлар...

Бүген исә сатучыларның бу пошаман болытлары таралып, йөзләренә елмаю иңгән. Ирләрен яки улларын-киленнәрен эшкә, бала-чаганы йә сабакка, йә бакчага озаткач та, сату-алу хәҗәтеннән бигрәк, яңа хәбәрләр ишетергә ымсынып, кибеткә җыелышкан апа-җиңгәйләргә сөенечләрен бүлешәләр.

Авыл читендәге кошчылык фабрикасына шабашниклар килгән икән. Тавыкчебеш абзарларның яңартып-сипләп, заманча автоматик җиһазлар монтажларга ялланганнар. «Кереш музыка» шешә-стаканнар чыңына кушылып, бик тә мавыктыргыч-юмарт яңгыраган, мөгаен, «соңгы авазлары тынганын» сизми дә калганнар — мәгәрич-аванс итеп алынган акчадан җилләр искән! Ә яңа ай башына кадәр, килешү кәгазендә язылганча, яңа аванс алганчы, ай-һай, башкаенны кашытырлык ерак икән әле. Гаиләсенә яки таныш-белешенә «акчаны күрәп аласын» вәгъдә итеп китаен агай-энегә артка таба да юл киселгән. Мәгәрич махмырыннан хәл алып та өлгермәгән килеш: «Хатын, акча, җибәр!» дип, ни йөз белән почта бүлегенә бармак кирәк. Нишләргә? Заказчик, әнә, эш даулый. Күркә дә җил белән генә туенып яши алмый, лабаса.

Ни ниятләр, ни планнар корганнардыр бу «осталар» үзара гәп-бәхәс сугып — анысын, мөгаен, кайткач хатыннарына да сөйләмәсләр — бер зирәгрәге кулай котылу чарасын тапкан бит, әй: Эврико! Кибетчеләр белән дуслашырга!

Аксыл житен чәчле, зәңгәр күзле, аек чагында күрер күзгә сабыр, тотнаклы гына күренгән, йомшак-моңлы тавышлы Галимҗан атлы бер иптәшләрен өмә белән кырындыралар, киендерәләр дә, аңа ике «дипломатик киңәшче» дә ияртеп, җибәрәләр авыл кибетенә әлеге «илчеләр»не. Чөнки «авыр миссия» бу! «Кибеткә акчасыз килгәнче, кабергә — имансыз кер», дигәннәр, әнә, борынгылар.

Киңәшчеләр кыеклап кына, янәсе, үзенә дә сиздермичә, тәкъдим итәләр теге Галимҗанны: «Безнең баш инженер!».

Өлкән сатучы апайның үз ире дә кошчылык фабрикасында эшли икән. Шабашниклар килгәнен, аларның «бүксәле генә суммага» килешеп, шартнамәсен төзеп, эшкә алынганнарын икенче көнне үк ишеткән инде ул. Әлегә «мәгәрич мәҗлесенә» дә кирәк-яракны шул кибеттән алганнар лабаса.

Тәмле тел, ихлас вәгъдәләр белән гозерне әйткәч тә, сөйләшүләр, әлбәттә, «дуслык һәм үзара аңлашу шартларында бара». Сатучылар агай-энеләргә кирәк-яракны бурычка җибәреп торырга риза. Әмма килгән-киткән сәрхуш мосафирга товар таратып торырга авыл кибетчесенең дә башына тай тимәгән. «Баш инженерның» әле җилем исе дә очып бетмәгән өр-яңа паспорты иң «ышанычлы урынга» шартлатып бикләп куела. Кара дермантин тышлы дәфтәргә яңа сәхифә ачыла һәм рәхим итегез! Әүвәл берсе-бер унар-унөчәр килолы карбыз! Һәр-берегезгә һәм һәр даим көнне. Әлбәттә, карбыз белән генә эч күпертеп, бетон ватуы да, таш ташуы да җинел шөгыль түгел. Сатучылар анысын да сиземлиләр, шул колач җитмәслек карбызларга ишкә дип, чамалап кына чәй-шикәрен, тәмәкесен, айлап-еллап сатылмый яткан балык консервларын «бик вакланмый» гына биреп-җибәреп торалар икән хәзер. Әмма иң мөһиме: кибеттән карбыз кайгысы киткән! Шуңа хәзер сатучылар көләч-сүзчән, шуңа бүген әңгәмә мавыктыргыч.

Тормыш адымнарына иярә алмый бугай, инде, олы яшьтәге бер әбинең дә җай чыкканда төшенеп каласы килә:

— Кемнәр ул, Хөллия килен, ша-баш-ник дигәнегез?

— Үз җае, үз кесәләре өчен генә эшләп йөрүчеләр, апа.

Нигәдер, чуар яулыгын күз өстенә үк төшереп бәйләгән, челән кошныкына тартым озын-нәзек борынлы бер хатын бу аңлатма белән бигүк риза түгел:

— Әй, алай ук димә лә инде, Хөллия. Аларны да безнең закун зерә узындырмый ди хәзер. Пыдахуд налугын да тотып калалар ди үзләреннән. Өйләнмәгән гидай булса, бездитниен дә түли ди. Бикәчлесе бикәсенә ярамаса, тач артыннан ук әлименте дә килеп җитә ди.

— Һи, сана! Казый кызы диярсең. Син, Сәвия, яхшы атлы булам дип, яклап-каклап маташма! Зимагур белән бер ди инде ул, шабашник дигәннәре. Бер урында һич басылып эшләмәс ди. Көзен кайтып күренүгә, язын тагын китәм дип, гел дәген кабырсып яшәр ди.

— Әйтмә, бер ишесе ай эшләгәнен атна-ун көндә эчеп бетерә икән дә, сөяк эзләгән эт шикелле янә чыгып чаба ди. Ул шабашниклар килгән авылларда, җаным, каз-үрдәк калмый икән. Кайберәүләрнең сарыклары да көтүдән кайтмый, җуела ди.

— Берсе галавный инжинир дип әйтәләр дисеңме, Җәмилә? Янгалыйдыр. Инжинир башы белән тавык тизәге арасында йөрмәс борнын кысып, йөрмәс. Тәмам чуттан чыккан адәм булмаса...

— Бәясен күтәрүе генәдер. Әнәтерәк, күрше Келәүгә дә былтыр шул шабашниклар шушилка салырга килгәннәр икән дә, берсе мин — укытучы, дип әйтә, ди. Җәен шулай эшләп, башны свижиләндерәм, дип әйтә, ди. Теге аксак Метрәйнең утырып калган сазау кызы — Марфушага йортка барып кергән ди.

— И-и, рас икән. Сөйләгәннәр иде шул бермәлне.

— Араларында кулга галәмәт осталары да бар ди бит аларның. Тик эшләре яман да авыр ди инде. Зерә дә ватылып алалар ди акчаларын. Караңгы төшкәнче эшлиләр ди.

— Алай тир түкмәле булса, атналап бикәч түшәгендә ята алмас иде әле, әнә ул, укытучы дигәннәре.

— Төрле урында төрле шартлар, төрле бәя, мөнәсәбәт. Зарур кирәкле дә, эшчән дә, эттән әрсез, чүптән кадерсез дә түгелме соң бу, шабашник дигәнебез.

## Юллар чатында уйлану

...Уңга-сулга, калаларга-салаларга узган зур юллар чаты. Әйтерсең, алга — киләчәккә, кирегә — үткәннәргә таба өзлексез машиналар чаба. Уйлар алардан да житез, узганнарны урап әйләнә дә, бүгенгегә кайта...

Халык борын-борыннан үзенең һөнәр ияләре — маһир осталары белән горурланган. Алтын, көмеш, бакыр осталары, тимерчеләр, миччеләр, балта осталары, тегүчеләр, чигүчеләр... «Осталар килде! Осталар чакырдым» кебек ягымлы сүзләр дә халык телендә һаман сирәгрәк ишетелә бара инде.

Юллар чаты, әнә шулай дәверләр чатын искә төшереп, уйларны алга әйди. Бихисап бормалы юллардан кешеләрнең салалардан калаларга күчүләре — урбанизация процессы, унсигезенче гасырда ничек көчәйсә, хәзер безнең планетада ул, гүя, космик тизлек белән дәвам итә.

Бер «мыгырдавык» якташымның зарлануы хәтеремнән китми: «Шәһәр камфортына кызыктырып, авыллардан халыкны алдалыйбыз, адаштырабыз, саташ-

тырабыз, малай. Матур йола-гадәтләрне, халык педагогикасын, шәригатьне жуябыз шулай. Бу таш-тимер, бетон арасында милли телләр кадерсезләнә, югала бара, халкымның моңы, садә асыл сыйфатлары жуела! Илгә-көнгә бирәр афәт, ачлык, сугыш килә күрмәсен тагы. Бөтен Кама төбәгендә бер куырып ашарлык балыгын, пешерергә — кычытканын да таба алмый башларсың...»

Бу хакта әлеге скептик чордаш кына түгел, әнә, күп галимнәр-биологлар, диңгез-океан белгечләре, социологлар, демографлар... әле дә уйланалар, бәхәсләшәләр бит. Әлбәттә, Аллаһыбыз адәм баласын үз миһербанын-шәфкатеннән ташламаса, кешелекне яшәтерлек акыллы чаралар, чыганаклар табылыр, дип өметләник, юаныйк инде...

Без исә янә юллар чатына кайтып, уйларыбызны дәвам итик. Әлеге урбанизация, никадәр күрмәмешкә салышсак та яки күреп-белеп сүгенсәк тә, инде алтмышынчы-җитмешенче елларда ук табигый-объектив икътисади, социаль кире дулкынны — шәһәрләрдән авылларга эшкә бару кебек и л к ү л ә м хәрәкәтне дә тудырды бит! Шул ихтыяҗ, каршылыклар, кыен-кытлыклар дулкынында «шабашник» дип аталган бер шөгыль-кәсеп-һөнәр иясе калкып чыкты һәм алар ишәя, куәтләнә бардылар. Безнең татарның да «Аңлатмалы сүзлеге» шабашникны йорт салу яки каралты-кура төзәтү, мич чыгару, хуҗалык әйберләре төзәтү, урман кисү һ. б. ш. эшләрне аерым кешеләргә яки колхозларга югары хакка эшләп йөрүче яки «акча, табыш өчен генә эшләүче, җинел кәсепче» дип шәрехли. Бу аңлатмаларда хаклык та бар, әмма нахаклык, кимсетү дә җитәрлек, әлбәттә. Дөрес, ул елларның идеологиясе басымы беләндер бәлки, бу шөгыль ияләренә бирәүнең дә «осталар» дип дип әйтергә теле бармады, кайбер рәсми кәгазьләрдә аларны «договор белән эшләүчеләр» яки «вакытлы төзүчеләр» дип, йомшакягымлырак атарга тырыштылар. Әмма гадәттә, аеруча урам телендә бизәпсырлап тормадылар. Аның исем-шәрифе кыска: ша-баш-ник! — Һәм вәссаләм. Башка телләргә тәрҗемәсе дә кирәкми, урыстан кергән уртак атама ул хәзер. Соңгы чирек гасырда әлеге шөгыль иясе төрле телләрдә басылган күп кенә фельетоннарның персонажына әверелде. Аның файдалы һәм зарарлы яклары турында матбугатта кызу бәхәсләр барды. Ул гынамы? Әлеге «шабашник» әрсезләнеп матур әдәбиятка килеп керде. Әнә, язучы Барлас Камаловның халыкчан гади, табигый, образлы тел белән шактый оста-кыска язылган «Канатлы кырмыска» исемле әсәрендә авторның әлеге шөгыльне тудырган сәбәпләр, ихтыяҗлар турында акыллы фикерләре, уйланулары бар. Язучы Фәрит Гыйльми исә үзенең «Урсай тау итәгендә» исемле повестенда тормышчан юмор, сарказм белән әлеге шабашниклар хәятеннән берничә реаль картинаны күрсәтеп узды. Белеп язды Фәрит-мәрхүм. Бу юлларның авторына да нәкъ менә Фәрит Гыйльми егет булып җиткән Мөслим якларында шабашник әрмәннәрне еш очратырга туры килде. Хәтта, бервакыт газета йомышы белән барып, чын мәгәр, бер колхозның җитәкчеләрен шул «әрмәннәр сабантуе»ннан, «эшне очлап чыгу» мәҗлесеннән табып алдым...

Безнең Идел-Кама-Нократ якларында «шабашниклык хәрәкәтен», әйткәнемчә, алтмышынчы елларның урталарында нәкъ менә шул әрмән агай-энеләр башлады, дисәк — хата булмас. Чөнки көньяк халкы гомер-гомергә таш-балчык, керамика эшенә оста. Дөрес, андый осталар бездә дә булган. Ләкин, әйткәнебезчә, дәверләр агымында югалганнар шул.

Бәй, игътибар белән баксаң, безнең якларда да чокыр авызыннан, үр-яр читләреннән күренеп үк торган табигый таш катламнары фәлән кадәр икән ләбаса! Һәм хуҗалыкларның үз биләмәләрендә үк сай гына күмелеп яткан әлеге хәзинәдән әрмән егетләре зур-зур абзарлар, хәтта мәдәният йортлары җиткерә башладылар. Зәр кадерен зәркән белә, дип тикмәгә әйтми халык. Дөресен язмыйча булмый, тиз эшләделәр, күп очракта тир түгеп, тырышып эшләделәр, шуның белән ышанычка керделәр һәм эшләгәннәренең хакын да тавышсызгаугасыз гына ала беләләр иде бу «кара» егетләр. Әлбәттә, күз буяган, кайбер ачыкавызларны төп башына утыртып киткән чаклары да аз булмады... Һәм аларның шулай «бер җәйдә машиналык акча сугып китүләре», чыны-хыялы белән телгә кереп, безнең җирле агай-эненең дә шактыен канатландырып, өметләндереп, кызыктырып җибәрде.

Белгәнебезчә, еллар дәвамында төзү материаллары да күбрәк җитештерелә барды. Шәһәр төзелешләрендә тимер-бетон панельләр, плитә-субай баганалар эшләп чыгару артты, металл, кавырсын торбалар, почмаклыклар, швиллерлар ишәйде, цементка кытлык кимеде. Һәм бу материаллар бик табигый, төрле юллар белән авылларга да «кайта» башлады. Индустриаль төзелешләрдә яки машина җитештерүче заводларда һөнәргә өйрәнгән, кул шомарткан ир-егетләр,

әлбәттә, гади авыл корылмаларын бер дә баш ватмый гына төзеп куялар. Бу корылмалар индивидуаль проектлар, катлаулы технология-монтаж яки архитектура үзенчәлекләрен, бизәкләрен, нәфислеген таләп итмиләр ич. Әнә, стандарт проектлар никадәр! Сызым танучыга да мохтаҗлык юк. Эшлә генә! Югарыдагы мишәр колхоз рәисе сөйләгәнчә, бар шартларын булдырып, авылларда көтеп алалар иде төзи белгән, монтажлый белгән кешене! Аннары, сыерлар абзары яки яшелчә саклагыч кору, индустриаль төзелешләрдәге сыман, йә завод-фабрикалардагы кебек даими ритм, агым-конвейер эзлеклелеген, вакыт графигын каттый саклауны, «пропуск тәртипләрен» таләп итми.

— Эх, парин, әгәр төзисе корылманы хәерле сәгатьтә очлап чыксак, акчасын берьюлы алачакбыз икән! Шәһәргә түшкә-түшкә итен, бодаен, карабодаен, борчагын капчыклап апкайтучылар бар икән бит. Кайберәүләр симертеп суярга дигән байталына атланып кайталар ди...

Менә шундый кулай шарт, хәл-әхвәлләрне үзе күреп-кичереп тә, фәләннәрдән ишетеп тә иләсләнде агай-эне, елдан-ел житезрәк, ишәебрәк кузгалды ул авыл жирләренә. Җәйләрен республикабызның кайсы төбәгенә, зуррак хуҗалыкка барып чыксак та, «Казан шабашниклары», «Әлмәт шабашниклары» дигән сүзләрне еш ишеттек. Соңгы дистә елларда «Чаллы шабашниклары» да макталып телгә керделәр. «Эшли беләләр! Буш кул белән килмиләр. Бирнәләре — олауолау стройматериал!». Ә бит алар, язларын авыл төзелешләренә «шабашкага китүчеләр» күрше Мари Эл, Чуваш, Удмурт, Башкортстан, Оренбур жирләрендә дә меңнәрчә иде...

* * *

Менә шундый һәм шуңа охшаш куәтле экономик, социаль дулкыннарны, эшкә сәләтле кешеләр резервын дәүләт тә күзләп-белеп, өйрәнеп яшәгән булып чыкты: Горбачев хакимлек иткән елларда «Кооперация турында закон» да кабул ителде. Төзелешләргә хезмәт күрсәтергә тиешле кооперативлар, эре-вак бригадалар ишәеп китте. Тик аларга ин әүвәл әлеге шабашниклар, үзләре телгәнчәрәк эшләргә гадәтләнгән «иркле кошлар» кереп тулды һәм алар теге «кооператив» кысаларын үзләренчә үзгәртә, вата-җимерә башладылар. «Кооператив» атамасы онытыла, җуела барды...

— «Шабашникларның да төрлесе бардыр инде мирдә...» — Авыл кибетендә бер хатын әйткән бу сүзләр дөрес шул. Һәм шактый еллар дәвамында, җай чыгу белән, күзәтеп-өйрәнеп йөргәннән соң, бүгенгегә-киләчәккә гыйбрәт өчен без дә аларны берничә төркем сыйфатларга аерып күрсәтергә булдык. Тормышның нәкъ үзендәгечә...

## Акчалы ял

...Алар бу эшкә алтау алынганнар. Дүртесе фәннәр кандидаты, берсе — инженер, араларында университетның журналистика бүлеген тәмамлаган «житәкче бугор» да бар. Чаллыга орынып кына торган бер колхозның ындыр табакларына бетон җәяргә килешкәннәр. Авыр эш, әлбәттә,— бар техника көрәк, себерке дә, виброрейка гына. Әмма эш бик тә гади һәм бетонны, әнә, күрше хуҗалыкка килгән студент-шәкертләр кебек носилкалап тар бүлмә-аралыкларга күтәреп ташыйсы юк. Килгән измәне машина әрҗәсеннән иркен мәйданга бушат та, комнан-чуерташтан ясалган аслык өстенә 15—20 сантиметр калынлыкта тигезләп җәй. Һәр шабашник кызыгырлык «блатной эш»! Үрчемле дә, акчалы да. Теләсә кемгә тәтеми ул! Аны үзе үк район агропромышленность берләшмәсенең капиталь төзелеш бүлегендә эшләүче озын буйлы әлеге инженер «эләктереп калган». Ә теге әрсез «каләм батыры» исә кәгазь-шартнамәсен, комын-ташын, бетонын табу чыганакларын юллап, «Мәккәгә барып житәрлек юл узган». Колхоз рәисенә нәрсә, пичәтен куен кесәсенә тыккан да, мут, хөрмәтле генә елмаеп, тыныч утыра ул. Кассада акчасы, склалларда — ите, сөте житәрлек. «Рас ОКС кешеләре үзләре үк алынганнар икән, (эшләр кешеләре кемнәр диген әле — доцентлар!) йөгерсеннәр, тапсыннар кирәкләрен. Алар кесәгә саласы меңәр-меңәр сумнарны безнең колхоз да спортлото отып кына алмады...»

Авыл жирендә хәбәр тиз тарала. Кайсыдыр берәү «зернотукны бетуннарга» килүчеләрнең «профиссырлар да, каррииспандит» икәнлекләрен ишетеп алган бит, әй! Хәйлә-йомышын табып, ялгыз-ялгыз да, төркем-өерләре белән дә ындыр табагына килеп, болганып-күзләп йөриләр авыл агайлары. Янәсе, көрәк-себерке

тота беләме икән ул, укымышлы халык? Әллә берәр машина белән генә җәеп салалармы битунны? Икмәк телеменә каймак яккан кебек кенә, ә?

Киләләр-күрәләр: бетон тигез, алдаусыз калын җәелә. Кояш астында ялтырап-җемелдәп ката, тимер белән бәрсәң — очкыннар чәчрәтерлек булып ныгый бара, ярылмый, чәрдәкләнми.

— Әшли беләләр, кордаш! Китап кортлары гына түгел болар. Икмәк кадерен белеп үскәннәр, пожалый...

Чыннан да егетләр, билләренә тикле чишенеп атканнар да, бетон тәягән машина килеп җитүгә, бердәм ташланып, аны бик тиз бушатып озаталар. Измәне соскыч көрәкләр белән ары-бире күчерәләр дә, шул измә-бетон өстеннән виброрейка тырылдап уза. Бер низаг, үзара боерыклар бирешү, әйткәләшү юк, бары көрәкләр һәм мускул-сеңерләре киерелеп калыккан арка-иңбашлар ялтырый. Эш барында берәү дә «сулу алырга» тукталмый яки иптәшләреннән аерылып, тәмәке көйрәтергә базмый.

Җаен чамалап кына бу белемле егетләрне көрәк-лом белән бетон майтарырга мәҗбүр иткән сәбәпләрне белергә тырышабыз. Укытучы-галимнәрнең ял вакытлары икән, отпускалары — озын.

— Ә нигә бу ялны файдалы шөгыль белән уздырмаска?! Саф һавада тир түгеп эшләп йөрүдән кемгә зарар? — диләр алар уенын-чынын кушып. — Тәне сауның җаны сау! Хурлану хисе? Абруй төшү? Әнә, бюрократ чиновниклар үз абруйлары төшүдән хурлансыннар. Безгә хезмәтнең бер хурлыгы да юк!..

Әлбәттә, бу зыялыларның матди максатлары да бар: әйтик, әнә, физик-математик гомере буе суга, Кама-Чулманга гашыйк. Бер-ике җәйдә моторлы көймә эшләп алырга ниятләгән. Философ машинага җыена, «технарь» — мотоциклларга бик һәвәс. Инженер яңа өйләнгән, фатир алган — мебель кирәк. Тормыш бит. Бездә фәннәр кандидаты яки инженер булган өчен генә бер дә юмарт түләмәделәр. Күп очракта урта кул бер бульдозерчы яки кранчы хезмәт хакын «прафиссырдан күбрәк ала» иде шул...

* * *

Бер инженер-конструктор дустым минем, үзенең отпускасы вакытында Алабуга районындагы совхозга барып, Алманиядән кайтарылган ашлык киптергеч агрегатларны монтажлап бирде. Икенче бер танышым, инженер-экономист, фермаларга идән җәйде, ишек-капкалар ясады...

Үз отпуск-ялларын шулай авылларга кайтып, файдалы эш белән уздыручы зыялыларны без илнең, республикабызның күп төбәкләрендә әле дә еш очратабыз. Тик менә хәзер кулай эш табулары кыенрак шул... Мондый белгеч-зыялылар хезмәттә, үз-үзләрен тотуда авыл халкына, бигрәк тә яшьләргә матур үрнәк күрсәтәләр, тегеяки бу төзелеш-монтаж эшенең промышленностьтагы соңгы камил, җайлы ысулларын өйрәтеп калдыралар. Әлеге эшсөяр ихлас белгечләрне авыл халкы да тиз танып ала, аларга кадер-хөрмәтен күрсәтә, киңәшкә килә.

...Безгә таныш әлеге галим егетләребез уртак мәйданы өч мең квадрат метрдан артык булган ике ындыр табагына уналты көндә бетон җәеп чыктылар. Авылның бакча артларында гына аунап яткан табигый ком-чуерташны кирәк урында файдалана белгәч, колхозның (иске бәяләр белән) тугыз меңгә якын акчасы янга калдырылды. Урып-җыюга керешер алдыннан шундый такыр, ныклы ындыр табаклары булдыру колхоз өчен дә сөенеч, башкарган эшнең нәтиҗәсен-гамәлгә ашуын күрү, аның озак еллар игенчеләргә игелек китерәсен яңә бер уйлап кую — егетләрнең үзләренә дә күңелле бит! Димәк, кергән хезмәтнең хакын алырга да, хуҗалык җитәкчеләре белән үзара рәхмәтләр әйтешеп, тыныч, көр күңелләр белән саубуллашырга гына кала да бит — ай, ашыкма, каләм!..

* * *

Әлеге иптәшләргә, эшләрен бетергәч тә, алай без теләгәнчә, «көр күңелләр белән таралышу» насыйп булмаган икән шул.

Хуҗалыкларда, нигездә район буйсынуындагы колхоз-совхозларда төзелгән объектларны кабул итеп алырга тиешле махсус комиссия бар иде. Бу комиссия шактый ишле, аның составына районның янгын инспекторы да, санэпидстанция байтары да (ветеринария белгече) керә. Аларның барысын бергә җыеп, төзелгән корылма янына берьюлы алып килүләре гаять тә читен хәл, дөресе, бикар ният икән бу. Ә комиссия акты булмый торып, банк хуҗалыкларга

акча бирми. Шуңа күрә дә әлеге комиссия «членнарын» эзләп, алардан имза даулап күп чабарга, эчендә эт котырса да, сабырлык, түземлек, итагать күрсәтергә туры килә икән. Чөнки ул әгъзалар арасында да төрле холыклы кеше бар лабаса. Кайсы: «Минем ул объектны күргәнем дә юк. Башкалар кул куйсын әүвәл» дип, борып чыгара икән. Икенчесе: «Исполкомда безнең председатель утыра. Ул чакырып әйтсә, барып карармын»,— ди. Өченче берәү: «Йә, акчаны ярыйсы каердыгызмы?» — дип, гүя, кыек эшне бедә торып, уен-көлке аралаш, сәдакасын салып сөйләш, дигән сыманрак киная белән бер-ике шешә коньяк өмет итә икән...

Әлеге укымышлы танышларыбыз да шундыйрак киртәләр аша сикерә-чаба торгач, тәмам йөгәнеп, ниһаять, райбашкарма комитеты рәисенең төзелешләр буенча урынбасары хозурына килеп җиткәннәр иде инде. Теге комиссиянең җитәкчесе шул урынбасар икән. Бусагасын узып, укымышлы егетләр гозерләрен әйтеп караганнар, әмма урынбасар: «Вакытымның бик кысан чагы. Сез дә буталып йөрмәгез әле»,— дип, ишекне арт ягыннан ябарга кушкан. Уф, алла...

Без барып кергәндә, егетләр аптырашып коридорда таптаналар. «Эше авыр булса да — ләззәт кенә. Тик, сабакташ, хакын теләнеп алулары, ай-һай, проблема икән...» — дип, сынган, кимсетелгән тавыш белән зарланышалар иде. Һәркайсының мәшәкате җитәрлек. Яңа уку елы да — кул сузымында гына.

Инде биш-алты пичәт тә, биш-алты имза белән чуарланган акт кәгазьләрен алып, бик тартынып тормый гына әлеге «урынбасар»ның эш бүлмәсенә барып керәм:

— Сәлам!

— О-о, сәлам, сәлам!

Елмаеп күрешәбез, утырышабыз. Урынбасар күрер күзгә әле утызны да узмаган сылу, нык бәдәнле, күркәм йөзле кеше. Мин элеккеге Чаллы, хәзерге Тукай районының күренекле-ардаклы кешеләрен, әлбәттә, җитәкче иптәшләрне шактыйдан беләм. Бу егетне дә соңгы җыен-җыелышларда күргәнем бар. Райбашкармага кайдадыр яхшы эшләп күтәрелгәндерме, «КамАЗ» төзелешләре башлангач кузгалган зилзилә сөреңендә аны берәр «йонлач кул» бу җаваплы урынга утырткандырмы — һич хәтерли алмыйм.

— Сез, агай-эне, нишләп эш кешеләрен коридорда интектерәсез? Галим халык вакыт кадерен белеп яши...

— Нинди галим халык? Галим-голәмә, иптәш кем, Дунаев, бездән зуррак начальство тирәсендә булса булыр.

— Соң, әле борып чыгарган иптәшләрне аз гына да зиһен салып тыңламадыгызмы?

— Шабашниклар ич алар! Мин, менәтерәк, елки-палки, бер звонокка дәшмичә, квартал отчетларын карап утырам. Совмин ашыктыра! Шундый чакта — алар тагы тана башы! Шабашникка ачык йөз күрсәттеңме, сатулашмый-талашмый котылырмын, димә. Шәрекъ базарындагы кебек. Сабыр итсеннәр. Сукыр чебен сыман янә килеп керерләр әле.

— ?..

— Һе, шулаймы, все-таки галимнәр, дисең алайса. Ну, тогда ни пычагыма, галимлекләрен яшереп, простой киемдә райисполкомга килгәннәр соң? Галим булсалар, үз авторитетларын белеп, толкайт итсеннәр фәнне. Җиткерсеннәр халыкка ул науканың яңа хикмәтләрен. Ә болар шабашкага, значыт. Һаман хатыннарына акча җитмидер әле. Нәфесе тормызсыз аның, хатын-кызның. Әнә минеке дә пальто алсаң, дубленка, тун даулый...

Физик ял да кирәк, дисең. Бе...лəм! Кайбер академикларның да кара эштән курыкмаулары хакында укыган бар аңысы. Әнә, Черчилль, тәмугъ кисәве дә, Англиянең премьер-министры чагында әле, үзенә ике катлы таш йорт салган. Үз куллары белән, значыт! Ну бит алар, апаем, шабашкага йөрмәгәннәр...

...Студент отрядларын чыннан да биш куллап көтеп алабыз без. Чөнки ярдәмнәре тия. Ну, ладны, димәк, ул мәхлүк мөгаллимнәрен дә обижайт итмик, дисең инде. Жалу белән йөрерләр тагы. Кая, китер акт кәгазьләрен! Бит, апаем, бу кәгазь белән аларның үзләренә настроение бозып йөрергә дә кирәкми. Ул комиссияне чакырып, аның күңелен күрү, объектны кабул итү-итмәү хозяйство җитәкчесенең үзеннән үк тора. Өстәвенә, һәр колхоз-совхозда хәзер прораб яки мастер бар. Алар эше бу!

— Алар бит сезгә сылтыйлар. Комиссия килеп карамыйча, актларга кул куймыйча, объектны кабул итмәскә сез боерык биргәнсез бит. Шунсыз банк акча бирми.

— Шулай кирәк. Контроль кирәк! Сез үзегез үк, кем, иптәш Фаязов, шабашниклар халтурить итә дип, газитләргә язасыз түгелме? Хәзер, ни-ча-ва, бу мәсьәләдә директив органнарның строгий указаниеләре бар. Шалишь, халтура! Типовой договорлар бар!

— Сез сүз саен шабашник дисез. Соң, авыл төзелешләренә килүчеләр арасында ихлас эшсөяр яки авылны сагынган вөҗданлы кешеләр дә күп лабаса! Әйтик, сез борып чыгарган ул мөгаллим-галимнәрне мин яхшы беләм. Нигә кимсетәсез? Хурлыйсыз?

— Мин чыгарган бәет түгел! Ну, пока. Кичкәрәк кер, йомышың булса. По душам сөйләшербез. Берәр коньяк кыстырып кер, ха-ха. Чоу!..

* * *

Ләкин миңа бу урынбасар белән бүтәнчә «по душам сөйләшергә» һич насыйп булмады. Нәзәкәтле җиңел машинадан — йозаклы кара «фургон»га утыртып, аны озакка, чәчен агартырлык озак срокка «чыбыклы коймалар артына» алып киткәннәр икән. Айлар буе диярлек бөтен төбәктә аның үзе турында, бигрәк тә контора хатын-кызлары «по душам сөйләштеләр».

Әлеге урынбасар, «Водстрой» дигән төзелеш идарәсенең баш инженеры белән бергәләп, үзе шабашкага керешкән икән. Су астында каласы җирләрдән зиратларны күчерттеләр, янәсе. Фәлән-фәләннәрнең паспорт мәгълүматларен алып (чынлыкта «үле җаннардан»), «бригада төзегәннәр». Бер бульдозерчыдан чардуганнарны, зират өстен анда-монда эттереп, актарттырып, тигезләтәләр дә, теге баш инженер бар «кирәк кәгазьне» әзерли, ә бу урынбасар — комиссия председателе, ул кәгазьләрне раслап печәт сугып бара. Кырыгар меңнән артык (ул чактагы бәяләр белән) дәүләт акчасын бик тиз шулай «сугып алганнар» болар!

Ләкин су күтәрелгәч тә бөтен Кама-Чулман өстенә теге, «күчерелгән зиратлардан» табутлар, мәетләр калкып чыга...

## «Шабашстрой» бар идеме ул?

Алар бу эшкә кыштан ук хәзерләнгәннәр. Юл ерак, чыгымнар күп булачак, дип тормыйча, Чаллыдан Казан артындагы Балтач районына кат-кат барып, башта ук корасы корылманың сызым-проектын, сметасын җентекләп өйрәнгәннәр. Күпме төзелеш материалы, әйтик, кирпеч, цемент, такта, кадак кирәк буласын бик төгәл исәпләп чыгарганнар. Бу кирәк-яракның күпмесен оешма үзе юнәтә ала да, никадәрен үзләренә эзләп табарга кирәк булачак?

Менә шулай шартларын белешеп, иң мөһим сорауларга тулы җавап алганнан соң гына, алар икәүләп бригада тупларга керешкәннәр. Әлбәттә, яшь, таза-куәтле ир-егетләр кирәк! Кайсы һөнәр ияләрен ялларга? Ташчы кирәк. Монтажник кирәк. Сварщиксыз булмый. Балта остасы һәм, әлбәттә, бик тә тырыш берәр кара эшче, «негр» кирәк.

Бригадага шактый еллар төзелешләрдә мастер, прораб, участок начальнигы булып эшләгән инженер җитәкчелек итә. Һәрвакыт чебен-черки кугандай бутанып торырга гадәтләнгән бу «башлыкның» ярдәмчесе, үзенә бик тә фикердәш «вәзире» бар: озын, чандыр буйлы, җирән-җиз йөзле бер геодезист.

Мондый «солидный бригада»да җитәкче — «шеф» чын мәгънәсендә тулы хокуклы хуҗа, «монарх». Әйткәнебезчә, кирәкле һөнәр кешеләрен ул үзе сайлап ала һәм, әгәр ул кешенең берәр ягы аңа ошамый башласа, ул аны бригададан куа. Биредә «эчке тәртип кагыйдәләре»н дә «шеф» үзе теләгәнчә раслый.

«Солидныйлар» күзгә күренердәй зур корылмалар төзергә алыналар һәм аларны бу төзелешнең берничә елга сузылуы да куркытмый. Чаллыдан Казан артына барып су арындыру корылмасы (водоочистное сооружение) төзергә алынган әлеге инженер белән геодезист та бу эшне ике елга суздылар. Игътибар белән баксаң, мондый хәл алар өчен төшемлерәк тә әле. Чөнки гаиләсеннән читтә яшәүдән күңеле сагышланган яки «монарх» таләпләреннән түземе сынган теге-бу ир-егет «үзенә тиерен» ала да, кайтып китә, башка эшкә урнаша. Ә аның «үз тиере» гадәттә һич төгәл исәп-расчет була алмый. Чөнки төзелеп бетмәгән корылма өчен «хуҗалар» соңгы расчетны бирмиләр, димәк, әлеге ир-егетнең фәлән хезмәте түләнми кала. Бу исә «шеф» өчен бигрәк тә файдалы, эшне

тәгәлләп, «калым керәчәк»... Ә кышын ул, теләсә, шул ук оешма-хуҗалыкның штатында кем дә булса саналып, хезмәт хакы алып торачак. Чынлыкта язга үзләренә кирәк буласы төзелеш материалларын юллап йөриячәк.

* * *

Өч-дүрт ел күз салып, белеп яшәдем. Ул чактагы Тукай районы агропромышленность берләшмәсенең капиталь төзелеш бүлегенә җиерчыклы аксыл чырайлы, салмак-сак хәрәкәтле, шикле йомшак тавышлы бер агай еш килә иде. Бар хезмәткәр-хадим белән бик тә алчак, дус булырга тырышыр ул, җай белән берәр мәзәк сөйләп алыр, тәмәке тартырга нияте барларны затлы сигарет белән сыйлар. Аеруча колхоз-совхозлардан йомыш белән килгән прораб-мастерларга сыланыр-сырпаланыр ул. Турыдан да, кыеклап та ул хуҗалыкның төзелеш планнарын, ихтыяҗ-мохтаҗлыкларын сорашып белер. Әңгәмә җаенда серле-мыштым гына итеп, «Бик кирәксә, табарга була...» кебек сүзләр кыстырып куяр да, әлеге йомыш-мәшәкать белән йөрүчеләрнең «колакларын торгызып», игътибарын үзенә җәлеп итәр.

Бүлектә кеше азаеп, телефонлы берәр өстәл бушап калдымы, куен дәфтәрен тартып чыгарыр да кайларгадыр, кемнәргәдер шалтыратырга керешер. Әлеге шикле-серле, әмма җор тавыш белән башта аны — тыңлаучының кәефен, хәл-әхвәлләрен сорашып, кемнәрдәндер сәлам җиткерер. Тик шуннан соң гына, гүя сүз җаенда гына, үзенә кирәк-яракны барлый-теләнә башлар. Үзе дә вәгъдәсез калмас, ым-ишарә белән ул «кирәк»не табучыны буш итмәячәген сиздерер, ит-май, бал кебек авыл күчтәнәчләрен бик тиз китереп җиткерәсенә ышандырыр.

Асылда ул төзелеш бүлегендә беркем дә түгел, чуртым да саналмый. Әмма еш кына идарә алдына яки коридорга җыелышып тәмәке пыскытучы төркем-төркем әзмәвер ир-егетләренең йомышын белешсәң: күр, алар әлеге салмак-сак агайның бушаганын көтеп таптаналар икән ич!

Ниһаять, сүз куешкан минутлар җитә, күрәсең, әлеге агай битендәге бар җиерчыклары белән елмаеп, алар янына чыгар, тавышын кинәт төрлечә үйнатып, катгый әмер-боерыклар бирә башлар. Теге ир-егетләр кайсы нәрсә күтәренеп, кайсы кая, сәфәргә кузгалырлар. Кемгә Минзәлә, Мөслим яки Сарман якларына, кем бирелә, әлеге агайның «резервында» кала...

Чынлап та кем соң ул, төзелеш бүлегендә әлеге «үз кеше»? Бу хакта сүз чыккач, бүлек хезмәткәрләре дәррәү фикердә аерылып, төрлечә җавап бирәләр:

— Авыл төзелешләренә бик кирәкле кеше ул, парин. Әрсез, тырыш кеше. Кайсы стройматериалның кайда ятканын һәрвакыт белеп тора ул. Җаен да таба, юктан-бар итеп тә куя...

— Шабашник ул, толкач! Ну, шабашникның эресе — командир строительного полка! Стратегиясе, тактикасы да бар аның.

— Һәм үзенә дә, кешеләргә дә бар, диген. Яши белә!

— Йа, алла! Командарм түгелме тагын? Шундый зур сүзләрне бер адәм актыгына атап әйтмәсәгез тагы. Харап! Безнең сукырлыктан файдаланып, үзебезнең коридорда ук хезмәт биржасы, «Шабашстрой» оештыручы, диегез, ичмаса. Жулик ул! Бүген төрмәгә илтеп тыгарлык бәндә...

Гадел уртаклыкны табар өчен, әлеге «комполка»ның үткәндәге һәм хәзерге эш-гамәлләрен күз алдыннан уздырыйк. Чыннан да теоретик белемле, тәҗрибәле төзүче-инженер ул. Озак еллар төзелешләрнең һәртөрле объектларында участок начальнигы булып эшләнгән. Димәк, һәр материалның үзгә сыйфатларын яхшы белә, аларны кирәк урынга куллана белә, аларның кайсы трест, төзелеш-монтаж идарәләренә, күчмә механик колонналарга купләп кайтасын алдан белә. Аларны «брак итеп» яки башка сәбәп-сылтау табып «гамәлдән чыгару серләрен» дә яхшы белә. Сак-хәйләкәр холкы, тормыш тәҗрибәсе һәм даими уку-өйрәнү аны кешеләр белән үзенә файдалы, кулай мөнәсәбәттә булырга гадәтләндергән. Чаллы төзелешләрендә эшләгәндә ул шефлык ярдәме күрсәтү йөзеннән авылларда еш кына булган яки аның үз участогына ук торбасын, шиферын, кирпеч-плиталәр сорап, мәгәричен күтәреп, авылларның «толкач» вәкилләре килеп йөргән. Әнә шулай, авыл төзелешләрендәге кытлыкны белеп, өйрәнеп алгач та ул, әлбәттә, бар килерен-табышын исәпләп, үзе үк шул «өзеклек-кытлык фронтына» күчкән. Башта шул ук Чаллы якларында бер колхозда сыерлар абзары төзергә килешкән. Эшләре җайга салынып, килере арткан, таныш-белешләре ишәйгән саен, аның нәфесе дә үскән, дәрт-җегәре, мөмкинлекләре дә көчәя-киңәя барган. Бер-ике җәйдә ул, чын мәгәр, үз егетләре үк шаярып әйткәнчә, күзгә күренмәс «бар конторасы бер иске портфельгә сыешлы «Шабашстрой» идарәсе башлыгы»на әверелеп алган.

Чыннан да ул әрсез, кыю һәм тәвәккәл. Әгәр Чаллы төбәгендә ул терлекләр абзары төзергә килешсә, шул ук вакытта Минзәләдәге икенче хуҗалыкта яшелчәсаклагыч, Сарманда — гараж, Мөслим үзәгенә — кибет салырга алына. Бар җаваплылыкны бер үзе өстенә алып, ул хуҗалыклар белән черки дә борын тыкмаслык итеп, законлы мөһере басылган һәм имзалары салынган килешү документлары яза. Бу кәгазьләрдә рөхсәт ителгәнчә, эшне башлап җибәрү өчен дип, элегрәк һәр хуҗалыктан аванс акчасын ала һәм төзүче бригадалар туплый башлый иде. Аралар ераклыктан, юл йөрүләр күплегеннән кыенлыклар кичерми ул — шул ук хуҗалыкларның үз транспортында кирәк җиренә бара һәм табылган материалны да шул транспорт белән үк ташыта. Әгәр эшкә кирәкле теге-бу агрегат хуҗалыкларның үзләрендә булмаса, башка җирдән табып, чит экипаж яллый. Әлбәттә, колхоз-совхозларның үз акчаларына!

Объектларда эшне оештырып җибәрде исә, аның хәле җиңеләя. Ул хәзер бер төзелештән икенчесенә «күзәтүче начальник» булып йөреп кенә тора, теләсә — атна-ун көн «ял итеп ала». Әмма бик таләпчән, сизгер «шеф», шактый оператив маневрлар ясарга сәләтле «комполка» ул. Әйтик, Сармандагы хуҗалыкта, тегебу сәбәп аркасында, эш тоткарланып торырлык булса, төзүче егетләрне ул бик тиз Минзәләгә күчерә. Яисә бүтән хуҗалыктагы төзелешкә бетон, кирпеч яки тәҗел кирәкле башка материал ташып калырга мач килде исә, мондый чакта барлык көч белән «төп ударны» шунда юнәлтә. Күрәсез, эшне оператив җитәкли белә!

Ә хезмәт хакын ничек ала? Әйткәнебезчә, һәр хуҗалык белән ул берүзе шартнамә-килешү төзеде. Димәк, төрле районддагы һәр объект өчен тулы өлешен, хәтта, бригадирлык өчен дип, өстәмәсе белән эш хакын алып бара. Димәк, аңа өч-дүрт хуҗалык акча түли! Ә салым инспекциясе бу хәлләрне тикшереп-күреп йөри ала димени инде?! Пенсия фонды һ. б. ш. хәйран-хәйрия фонды кебекләрне ул бар дип тә белми, тегеләр дә аның кайларда һәм ничек кәсеп кылып йөргәнлеген белеп тормыйлар, лабаса. Ул гынамы? Тегесен тапкан, бусын җайлаган өчен дип, ул әле чын-чыннан тирләп-пешеп эшләүчеләрнең дә хәләл өлешенә керә. Чөнки ул, күргәнегезчә, эшне табучы да, оештыручы да, инженер-консультант та, материаллар һәм транспорт белән тәэмин итүче дә бер үзе. Кыскасы, «берүзе бер идарә, «Шабашстрой» начальнигы!»

Менә шундый елгыр, тырыш-булдыклы, комсыз һәм хәйләкәр «шеф»ларны, «комполка»ларны сезгә дә, шат, шактый төбәкләрдә очратырга туры килгәндер. Укып та, ишетеп тә калгансыздыр, андыйларның кайберләрен, теге-бу җинаятьтә фаш итеп, «чыбыклы коймалар артындагы төзелешләргә» дә олактырмадылар түгел. Әмма күрер күзгә галәмәт эшлекле, кирәкле «алтын сыйфатлары» булган мондый әрсезләр ишәя генә бардылар...

Хәзер исә, илнең-көннең һәм икътисади, һәм социаль-иҗтимагый тәртипләре, хакимият структуралары җимерелгәч, андый «комполка»лар тагын да дәртләнеп киттеләр, төрле кыяфәткә кереп, «приватизация» дигән галәмәт төшемле чаралардан, йөгәнсезлектән файдаланып күп кенә техника-җиһазларны, производство мәйданнарын «үзләренеке» итеп эләктереп калдылар яки «арендага алдылар». Кибет-лареклар, ашханә-кафелар кебек үк хәзер төрле исемнәрдәге «Шабашстрой» гөмбәләре дә котырып үсә...

## Кәсептән кайта...

Җемелдәп торган июнь көннәренең берсе. Җылы дым сарган түтәлскверларда чәчәкләр керфекләрен ачкан, бар агачлар сусыл яшел яфракларга уралганнар. Бар җан иясе, мөгаен, яшь каланың иркен, чуар бизәкле урамнарына чыгып таралган. Бала-чага өлкәннәр кидереп чыгарган юка кечтеки майка-кәвешләрен дә берәр куак төбенә салып ташлап, яланәс мәш килә.

Бермәл килеп туктаган трамвайдан иңенә печән чүмәләсе хәтле рюкзак күтәреп, колгасар гәүдәле, какча кызыл йөзле, зур борынлы бер ир-ат ашыгып төште. Башында колакчын иске бүрек, аякларында резина тугылган киез итек тә, өстендә — сырган чалбар белән калын солдат бушлаты. Вәт әкәмәт, шундый челләдә, диген, ә!

Күр, таныйм ич мин бу сәфәрчене. Үзеннән кечеләргә дә «абый» дип эндәшергә гадәтләнгән Илгиз атлы бу ир уртасы кеше дүрт-биш ел элегрәк Чаллының йортлар төзү комбинатында зәвыклы балта остасы, маһир ташчы буларак телгә кергән иде. Тора-бара исеме дә телдән төште, үзе дә сирәк очрый

башлады. Эчүгә сабышты, хатынынннан, балаларыннан аерылды, дип сөйләделәр. Кибет чатларында махмырдан дерелдәп, кемнәрнедер көткән чакларын үзем дә күргәләдем. «Хәленә кереп» бишәр-алтышар сум акча тәрткәләп киткән чаклар да булгалады бугай. Әмма аның белән якыннан танышырга, башына баскан бәласенең бар сәбәп-сылтауларын белергә җай чыкмады шул.

Менә шушы кеше хәзер, шат, кыяфәте-килбәтеннән оялудандыр, мине күрмәмешкә салынып үтәргә атлыкса да, кычкырып сәлам биргәч, ухылдап каршыма килеп басты.

— Каян болай күтәренеп кайтып киләсең?

Ул башта беләүләнеп каткан бушлат җиңнәре белән лачма юеш битен, керле муенын сыпырып алды, бүреген салып култык астына кыстырды — баш түбәсеннән кайнаган казан өстендәгедәй бу-пар күтәрелде. Сакал-мыек төкләрендә, укмашып беткән чәч бөртекләрендә бөрчек-бөрчек тир ялтырый.

— Әй, абый җаным, шабашкага барган идек лә. Тартырга бир әле?

— Себер ягына ук бармагансыздыр бит?

— Иһи-һи! Көлмә инде, тишек борын. Юк ла. Монда, ындыр артында гына. Зәйдәге бер совхозга каравник салырга исәп иде. Кыш көнүк инде, март башында ук киткән идек.

— Шуннан бирле бер дә кайтып китмәденме әллә? Алтмыш чакрым араны соң. Һаман, мәйтәм, кышкы киемнәрдән.

Ул бер кулбашын артка каерып, иңендәге рюкзагын дыңгылдатып җиргә төшерде.

— Кайтып китеп булмады шул. Вакыт тимәде, дуңгыз орсын.

— Эш каты булды, алайса. Очлап чыга алдыгызмы соң? Тиерен түләделәрме? Акчасын, дим.

— Бар бирнәсе — бөрмә тулы беттер, абый. Электр дрелен бер чуваш мужигына сатып, шул акчага кайтып киләм менә. Бизар булып, балта сабына атланып. Чукынсын шабашкасы! Бүтән аяк атлыйсым юк. Өч аем заяга узды. Сасы кәҗә тәкәсе дә суеп ашатмыйча, ау-һаулап куып тараттылар. Бөтен әртилне.

— Төзер материаллары юк идеме әллә?

— Бар ла. Ташы да бар, тактасы да. Эшлә генә.

— Соң, нигә куып тараттылар?

— Бәй, эшләми, эчеп яткач. Җыелган, дуңгыз орсын, килде-китте әтрәк әләм. Күбесе эштән куылган алкаш икән, абый, или алиментщик. Аз-маз авансы алдылармы, җир астыннан да табалар — салалар егылганчы. Тәмам мәрткә киткәнче. Аннары, ике-өч көнсез эшкә чыгалмыйча, яталар тере мәет булып, сырхаулап. Калдык-постыкка яки бурычка алган акча белән бераз игә килеп кузгалсалар да, эшләренең ибе-ябе юк, ордым-бәрдем генә. Совхоз хуҗалары да бигүк томаналар түгел, күрә торып зәнки брак эшләтәселәре килми бер дә. Китә бәхәс, талаш-кычкырыш. Кәефләр җимерелә, эшкә гайрәт чигә. Берәүләр кулын селтәп, янәдән «тайный гастроном» ягына каера. Икенчесе, бал куасына өметләнеп, ниндидер Фатыйма түтәйгә кар базы казып бирергә ялланган. Өченче берәүсе: «Самогоның булса, кая, каралты-куранны янартам», — дип, итәгенә ияреп йөри-йөри, тол җиңгәчәй Мәтрүнәнең ризалыгын алып кайткан. Каравникны ташлап, шунда качалар... Йәле, абый, тагын берне кабызыйк әле?..

Вәт шундый эшләр... Бер ишләре бар, абый җаным, гомер кара эш эшләмәгән. Салып алганда «Мин начальник отдела идем!» яки «Мин — художник!» дип, кылтайган булалар җыен купшы чыпчык. Факытта балта да тота белмиләр, уң кирпеч күтәрсәләр — куыкланып куллары кабара. Ә бит эшкә дип чыккан, аяклы каза. Авылда кукраеп ләчтит сатып йөргән өчен дә акча түлиләр, үгез дә, куй суеп ашаталар дип, исәп иткән, күрәсең, имгәк...

— Әй, корымлыйсың да инде. Әҗерен учлап алгансыздыр әле. Яшерәсең генәдер. Юкса, гарантия-ышаныч булмагач, өч ай буе анда нишләп ятмак кирәк?

— Кояштыр, арттырмыйм, абый. Өметсез — шайтан, диләр. Узды инде шунда авансыдан авансыга өмет багып. Шөкер әле, бәла-казага юлыкмый, башың исән кайтуына куанырсың. Андагы төрле дуамал дурак белән...

— Нәрсә, эчте исә якага ябышучылары бар идеме?

— Бар, андый болагайлары да бар. Серкәләре су күтәрми бер дә. Нервылары сүсәргән эчеп. Акчалары беткәч, абый җаным, иман кача кытлыктан дигәндәй, бер комагае совхоз тавыкларын урлап суярга гадәтләнеп китте. Кем санаган аларны, алар анда — миллион! — ди дә, эңгер төшүгә тимер ыргагын кыстырып китә кетәклеккә. Чүп-чарыннан арындырып тору да юк, күршедәге ташландык бер мунча пичендә тән ката тавык өтәбез...

— Син дә шуларга аумакай иш булдыңмы?

— Бәй, бүтәннәр әтәч кимергәндә, бер мин генә авызны чөйгә элеп утыр-ыйммы әллә? И-и, абый җаным, сөйли китсәң...

— ...Үзен «Мин бывший артист!» дип йөрүче җирән сакаллы бер капылт адәм, гомер битен юмаган нәрсә, кичкә калып, азынып йөргән бер кәҗәне чалбар каешына бәйләп киткән дә, Зәйгә илтеп саткан! Авызын ерып сөйли кайткач: «Базарга җиткәч, сөтбикәнең сарут сарган сакалларын расчуска белән тарап җиф-фәргән идем — йә, тәкъсир! — мулла кыяфәте керде кәҗәгә, ди. Алтмыш сумга олактырган мескен хайванны бер картка. Мәгәриче белән...

— Соң, исәр башлар, бу бурлыкларыгызны авыл халкы күреп-белеп алса, измәгезне изеп кыйный яки милициягә озата бит.

— Күрүен факытта күрмәделәр дә, ну, сизенделәр булыр. Чегәннәрдән хуже болар! — дип каһәрле башладылар. И шуңадыр да якадан тотып, артка типкән-дәй итеп, зир-зәбәр китереп, куып җибәрделәр.

Һөнәрле-маһир егет чалбарын бәйләгән сүс ычкырын тарткалап куйды, авыр биштәрен ике куллап янә иңенә салды да биек йортлар күләгәсенә сыеныб-рак, кача-поса өенә юл алды.

* * *

Әлеге замандаш дөресен сөйләде, шабашник дигәннәрнең әнә шундый-лары да бар иде. Нәкъ шундый кәсепче-сукбайларны авыл халкы өнә-мәде, аларга шикләнеп карады, хурлап-көлеп сөйләде. Һәм шундый кәсепчеләрнең эшсөяр җаннарга да кара күләгәсе ятты, зыяны тиде...

Хәтерлик! Ярымфеодаль, ярымкапиталистик Рәсәй державасы безгә, рево-люция-инкыйлабтан соң, «тормыш төбендәгеләр»не аз калдырмады. Һай, кыз-ганыч, андыйларның әле дә кимегәне юк. Киресенчә, арта торалар шул...

Без үзгәртеп коруларны да революциягә тиңләгән идек түгелме? Кеше шәхесен тормышның сәхнәсе алдына куймакчы булдык. Димәк, эшләргә теләге, сәламәтлеге, һөнәре булган ул «әтрәк әләм»не дә без чүп базларына себереп түгә алмыйбыз, янәсе. Акыллы чаралар табып, аларны да күге аяз, һавасы саф, тәртипләре — кешечә булган бердәм-фикердәш җәмгыятьләргә тупларбыз, илне-көнне җилләтербез, янәсе...

Юк шул, алда якты маяклар, аяз офыклар бер дә күренми әлегә. «Әтрәк әләм»нәр генә түгел, холкы-фигыле әйбәт, ихтыяры көчле, һөнәре — кирәкле булган кешеләрнең дә эшсез, шөгыльсез калулары күңелләрне, зиһенне һәмишә борчый, сызлата бара. Тормышларыбыз үзе үк әллә нинди «шабашниклык фетнәсенә» әверелә бара түгелме? Хәзерге шабашниклар турында соңрак язар-быз, шәт, бу эшкә башкалар да алынырлар. Яхшыны яманнан аермый торып, илдә-көндә кояш чыкмас, ай — калыкмас бит, замандашларым...



# ШИГЪРИЯТ

*Гөлшат Зәйнашевага 70 яшь*

## МОҢНАР БӘЙРӘМЕ



Үземнән өлкәннәргә, бигрәк тә егерме җиде-егерме сигезенче елларда туган әдип-шагыйрьләргә аерым бер мәхәббәт саклап үстем, дисәм, бу аңлашылырдыр. Нинди исемнәр бит: Әхсән Баян, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мәхмүт Хәсәнов, Аяз Гыйләҗев, Рәис Даутов, Шәүкәт Галиев, Нурихан Фәттах, Гөлшат Зәйнашева... Халык язучысы, халык шагыйре дигән мәртәбәле исем яулаганнары да бар; күбесе — Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт бүләге лауреаты. Әйе, бу бүләккә лаек булган шагыйрә Гөлшат апа да бар; бу яктан да әлеге буын үзенчәлекле булды бугай. Безнең — 60 елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләрнең бер «кимчелеге» — арабызда шундый бер шагыйрә булмады, ахры. Бу турыда заманында Ренат Харис еш кына искә төшерә иде. Чыннан да ул елларда Саҗидә апабыз Сөләйманова, Клара Булатова кебек шагыйрәләр Әлмәттә иде; ә бүгенге, бик кызыклы шигъри дөньясы булган талантлы шагыйрәләребез соңрак мәйданга чыкты, ахрысы...

Шулай, без Гөлшат ханым Зәйнашевага аерым бер якты мөнәсәбәттә булдык. Шәхсән минем үземә бу шагыйрә, ничектер, татар сәнгате, мәдәнияте белән шигъриятне тоташтыручы рухи бер ялганыш шикелле тоела: ул каядыр югарыда, сәхнәдә йә күңелләр мөнбәрендә мөлаем итеп сөйли, җырлый, каядыр чакыра кебек. Әйе, Сарман районының Иске Теләнче авылында туган, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында үскән, Хуҗәмәт авылында җидееллык мәктәп, Минзәләдә педучилище бетергән, 1945—1949 елларда укып Казан педагогия институтын тәмамлагач, китап нәшриятында, радиода редактор булып, һәм язучыларның Г. Тукай исемендәге Клубында директор булып эшләгән Гөлшат апаның тормыш юлы гади генә кебек... әмма моңлы, җырлы, шигырьле, сәхнәле бу гомер! Беренче шигырьләре, скетч-пьесалары да «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Клуб сәхнәсе» кебек җыентыкларда басыла; ә 1958 елда «Тыңларсыңмы җырымны» исемле беренче шигырь китабы дөнья күрә, халык театрында «Рамай» исемле пьесасы куела. Аннары башка китаплар, пьесалар дөнья, сәхнә күрә (сүз җаеннан: быел гына да К. Тинчурин театрында аның өч пьесасы репертуарда — «Гайфи бабай, өйлән давай», «Җаным җәл түгел сиңа», һ. б.). Сәхнә, эстрада белән дуслык Ә. Афзалова, И. Шакиров, Ф. Кудашева кебек олуг җырчыларыбыз турында матур очерклар, Г. Сөләйманова, С. Садыйкова кебек мәшһүр затлар турында китаплар язуга китерә. Әйе, Моң, Җыр юлында яшь шагыйрәбез. Нәкъ менә үзенең дә популяр илле җырын туплаган китабы өчен алды ул Тукай премиясен. Һәм нинди җырлар! «Туган җирем Татарстан» (А. Ключарев

музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М. Мозаффаров көе), «Китмә, сандугач» (Р. Яхин), «Үз илемдә» (С. Садыйкова), «Яшь гомер» (З. Гыйбадуллин музыкасы) һ. б. Бу җырлар Башкортостанда — Уфада да яңгырый, күп җырчыларны таныткан, үстергән көйләр. Бу турыда аның Уфадагы дуслары Нажар Нәҗми, Шәриф Биккол, Ф. Чанышевалар мәкалә-хатлар яздылар.

Ә җырлар — дәвам итә. Халыкчан нигезле, язмышларны, гасырның кара урманнарын кичкән моңнарны хәтердә яңарткан якты җырлар алар. Ә сандугач китми, сайрый — җитмештә дә уяу, яшь, моңлы булып кала ахрысы...

Бу санда тәкъдим ителә торган шигырьләре дә, барыннан да бигрәк, әнә шул җыр сүзләре — гади, халыкчан шигърилек һәм садәлек билгесе булып, әлеге сәхнә-сәнгать мәнбәреннән яңгыраган моңнар булып кабул ителсә икән. Әйе, ихлас, якты моңнар бәйрәме булып...

*Рәдиф ГАТАШ*

# Гөлшат Зәйнашева

## МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

* * *

Сулар ага, сулар нигә ага?..
Аккан сулар нигә болгана?..
Чишмә челтерәп агар иде микән —
Мәхәббәт булмаса дөньяда?..

Җир әйләнә, нигә әйләнә җир?..
Ә йолдызлар күктә ник яна?..
Ай түгәрәк булыр иде микән —
Мәхәббәт булмаса дөньяда?..

Таңнар ата, сызылып ата таңнар,
Таң атканда кошлар уяна.
Сандугачлар сайрар иде микән —
Мәхәббәт булмаса дөньяда?..

Җырлый кеше, нигә җырлый кеше?..
Җырларына каян моң ала?..
Нигә яшәр иде икән кеше,
Мәхәббәт булмаса дөньяда?..

* * *

Дөнья иркен, дөнья тулы кеше,
Кемдер кемне сөя, ярата.

Гашыйк була, үз дигәнен таба,
Бер генә күз сирпеп карап та.

Язмыш шулай: кеше гашыйк була,
Мәхәббәтен тапмый калмый ул.
Ләкин кайчак кемне яратканын —
Үзен-үзе аңлый алмый ул.

Үзен-үзе аңлый алмаганда,
Кемнәр җанын кемнәр аңлар соң?..
Үз-үзеңне аңла: шул чагында
Җаныңны аңлаучы табарсың...

* * *

Кара төндә күккә карап,
Йолдызларны күзлисеңдер?..
Чәбәләнгән язмышыңның
Төеннәрен эзлисеңдер?..

Чәбәләнгән, төенләнгән,
Язмыш җепләрең чуалган...
Эзләнәсең, тулганасың,
Җан тынычлыгың югалган...

Таллар тибрәнер төн узгач,
Сандугачлар килеп кунса.
Җан тынычлыгың табылыр,
Яннарыңда ярың булса...

* * *

Идел буенда йөрерсең,
Бер ялгызың каңгырып.
Пароходларны көтәрсең,
Күзләреңне талдырып...

Дулкыннарга карап торып,
Ике күзең чагылыр...
Күзең чагылыр, ә йөрәгең
Берәүне өзелеп сагыныр...

Берәүне сагыныр йөрәгең,
Сызлап куяр сагыштан.
Тәкъдиреңдә шул язылган,
Узалмассың язмыштан...

Язмышлардан узмыш юктыр,
Ходай шулай кылгандыр.
Кем белән гомер итәсең —
Язмышта язылгандыр...

* * *

Базарларга чыксаң, базар кайный,
Базар шундый — базар тын булмый.
Мәхәббәтне сатып алалмассың,
Сатып алынса ул — чын булмый!..

Ефәкләрдән тегеп бирсәләр дә,
Килешмәгән кием кимәссең.
Алтыннарга төренеп килсәләр дә,
Җан тартмаган ярны сөймәссең.

Җан тартмаган түгел, җан тартканың —
Үз дигәнең бардыр синең дә.
Насыйп булсын яшәү — сөйгәнеңнең
Җылы кулын тоеп иңеңдә!..

* * *

Язлар үтте, җәйләр җитте,
Тиздән салкын көз җитәр.
Идел буенда камышлар
Сулып, саргаеп бетәр.

Тормыш юлын ялгыз үткән
Гомерләр зая икән...
Кеше камыш булмаса да,
Сула, саргая икән...

Көз дә җитәр, кыш та җитәр,
Гомерләр үтәр-китәр.
Ялгыз түгел, парлы-парлы
Яшәүләргә ни җитәр?..



# ЯЗУЧЫ ҺӘМ ЗАМАН

Язучыны дәвер тудыра. Әгәр без моны республикабызның гаять туры сүзле, ачы телле, бары тик үзенчә генә яза белгән әдибе — Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев иҗатында тикшереп карасак, моның шулай икәненә тагын бер тапкыр ышанырбыз.

Мин каләмдәшебез иҗатына берничә мәкалә һәм әдәби портрет багышлаган идем инде. Әдәби портретым «Ян, учагым, ян!» — дип атала иде. Һәм ул портрет минем «Әсәрләр»емнең дүртенче томында моннан унбиш еллар элек басылып та чыккан иде. Әлеге зур мәкаләдә Аяз Гыйләҗевның иҗаты тулырак чагылыш тапканлыктан, аларны кабатлап тормыйм, әдипнең ике әсәренә тукталуны кулай күрәм. Болар — «Өч аршын җир» повесте һәм «Йөгез, бер дога» романы. Икесе дә каләмдәшебезне югары күтәргән, аның иҗат кредосын ачып биргән әсәрләр. Дөресен әйткәндә, шушы повесть Аязны киң катлау укучыларга язучы итеп танытты, ә роман аңа зур популярлык алып килде.

Әгәр Аяз Гыйләҗевның илле елга сузылган илһамлы иҗатын игътибар белән күздән кичерсәк, аның барлык әсәрләренә — хикәя-повестьларына да, романнарына да, күпсанлы пьесаларына һәм публицистикасына да нигез булып яткан баганалар — Мәхәббәт һәм Нәфрәт икәнен күрербез. Изге күңелле кешеләргә булган мәхәббәтен ул яшерми, ямьсезлеккә, гаделсезлеккә карата ачы нәфрәтен белдерә. «Берәү», «Дүртәү», «Урталыкта», «Күзгә-күз», «Зәй энҗеләре», «Язгы кәрваннар» повестьлары, ниһаять, турыдан-туры шул хисне әсәрнең исеменә үк чыгарып куйган «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» повесте — болар барысы яхшы белән яманны, изгелек белән явызлыкны, ак белән караны кешеләр язмышы аша, югары сәнгать законнары белән сурәтли. Соңгы елларда әдәби әсәрләрнең теленә игътибарсыз карау гамәлгә керде — тәнкыйтьчеләребез моңа битараф булып калдылар. Ә баксаң-күрсәң, әдәби әсәрнең сәнгатьчәлеге язучының нинди тел белән, ни рәвешле язуына бәйле.

Мине иң сөендергәне — Аяз каләмдәшебезнең сурәтләү чараларына үтә дә җитди карап, җаваплылыкны тоеп язуы. Аның әсәрләрендә татар теленең үткенлеге, тапкырлыгы, образлы сөйләме тулы чагыла. Еллар узган саен, яңа бер әсәрен иҗат иткән саен, ул тормыш материалына тирәнрәк үтеп керә, тел бизәкләренә таләпчәнрәк, төгәлрәк була бара. Беренче иҗат чорындагы күз камаштыргыч буяуларны, киеәксез мажараларны чын булулары белән үзәккә үтә торган вакыйгалар, логик фикерләүләр, язмышларның табигый үсеше алмаштыра.

Аяз Гыйләҗевны язучы итеп күтәргән «Өч аршын җир» повестен әйткән идем инде. Күләме белән бәләкәй, әмма ифрат тыгыз язылган бу повестьта «туган туфрагына төкереп китүче» кешенең йөрәк яргыч фаҗигасы ачыла. Заманында әлеге әсәр тирәсендә кылычлар чарпылышты, ул күрә карау тәнкыйтьчеләр һәм партиянең өлкә комитеты житәкчеләре тарафыннан тетеп салынды, шул ук вакытта «Дружба народов» журналының дәрәҗәле бүләгенә лаек булды. Дөресен әйткәндә, бу әсәр нык уйландыруы, туган җиргә булган мәхәббәт хисен уңай мисалда түгел, гыйбрәтле язмышта раславы белән бәхәсле иде. Әлеге әсәрдә Аяз Гыйләҗевның колхоз төзелешенә, хәллерәк кешеләрне кулак дип авыллардан сөрүләренә карата мөнәсәбәте чагылды. Аның ул мөнәсәбәте Аязга кыйбатка төште, колхозларны яратмаганы, күмәк хуҗалык төзүне ялгыш сәясәт дип санаганы аркасында ул, сәяси гаепле саналып, биш ел төрмәдә утырып чыкты. Бу мәсьәләдә татар язучысы урыс язучылары («авыл прозасы» вәкилләре) — күренекле әдипләр В. Белов, Е. Носов, В. Распутин белән янәшә яши, яшәячәк.

Авторның соңгы елларда иҗат иткән әсәре — «Йөгез, бер дога» романы, исталеге Аязның шәхси тормышына — төрмәдә үткәргән биш елына багышлан-

ган. Димәк, «Өч аршын җир» белән соңгы роман арасында уртаклык бар. «Йәгез, бер дога»ны мин ансат укылмый торган романнар рәтенә кертәм. Бу роман зур фәлсәфәгә, Совет хакимияте заманындагы башбаштаклыкларга, замана агышына яраклашкан яки яраклаша алмаган шәхесләрне ачып бирүгә корылган.

Романның сюжет-композиция кору ягына килсәк, бу әсәрдә өч төрле агым бар. Беренчесе — төрмә камерасына килеп кергән һәр кешенең портретын язу. Мин заманында Әмирхан Еникинең кешеләр портретын, йортлар портретын, хәтта ки шәһәрләр һәм авыллар портретын күңелгә кереп калырдай итеп сурәтли алуына таң калган идем. Әгәр безнең бүгенге акыллы тәнкыйтьчеләребез яшьләрне өлкәннәр тәҗрибәсендә осталыкка өйрәтергә телиләр икән, алар каләм осталарының барлык ирешкән уңышларын — сурәтләү чараларын, табигать манзараларын җанландыруын, портрет ясау осталыкларын, сюжет-композиция кора белү сәләтләрен ачып салырга тиешләр. Шул чагында гына без яшь прозаикларны югары сәнгать биекләренә алып чыга алырбыз.

«Йәгез, бер дога!»дагы беренче агым — портретлар, дидек. А. Гыйләҗев роман дәрәҗәсенә күтәргән истәлек-хатирәләрендә әсәрнең 50 битенә кадәр гел портрет яза. Камерага килеп кергән бер кешенең тышкы һәм эчке портретын сурәтләп бирә. Романның композициясен кору ягыннан бу алым бик үк уңышлы булмаса да, Аязның күзәтүчәнлеге, сүздән камыр ясый алу куәте (камырдан теләсә нинди фигура ясап була!) барыбер үзенекен итә. 50 биттә байтак кешенең сурәте уза, әмма алар бер-берсен һич кенә дә кабатламыйлар. Бу алымда Аяз Гыйләҗев үзе гомер буе сокланган әдибе Мөхәммәт Мәһдиев белән гүя ярышка чыга.


Менә беренче портрет: «Нигъмәт Халитов — уртачарак буйлы, базык татар — передачаларны өзмәс ала... Сәяси тоткын түгел, Ташаяк урамындагы «Динамо» фабрикасының баш бухгалтеры. Аны хатыны иркәли, төрмә хадимнәре дә аның саулыгы, кәефе өчен туктаусыз борчылалар, казна исәбеннән аңа ак калач та эләгә, майда йөзгән карабодай боткасы, пар атып торган коймаклар сәгате-минуты белән өеннән безнең камерага килеп җитәләр. Еш кына ботканың майлы күл уртасында, ботын чөеп, безнең ач күзләрне кызыктырып тавык ята!»

Ботын чөеп яткан тавык та, майлы боткалар да, пар бөркегән коймаклар да төрмә шартларында, ачтан интеккән тоткыннарга контраст итеп тасвирлана. Шушы тышкы атрибутларга карап, Нигъмәт Халитовның нинди кеше икәнен шәйләп өлгерәсең. Фактта ул Аязларны, Кәбир Мөхәммәтшинише легионерларны тел яздырту өчен юрамалый утыртылган кеше булып чыга.

Менә тагын бер портрет — Инженер Кулешовныкы. «Була бит урысның бик борынгыдан, затлы токымнан килгәнен раслаучы олпат ирләре! Биек, төп-төз буй, затлы дәү танау, киң мәгърур маңгай, алгарак чыгып торган, металлдан коелгандай калын нык ияк. Саллы, салмак хәрәкәтләр, капса өзә торган көчле, чиста тешләр... Кулешов инженер-химик булу өстенә әдәбият-сәнгатьне үлеп ярата торган нәзакәтле, тәрбияле вә укымышлы кеше дә икән!»

Тагын бер портрет. «Сәер кеше иде Шамраев!.. Паекка тигән ипине урталай сындырып, ике генә каба. Ашау такы-токы булса да, шатыр-шотыр кашына, төчкерә, төкрекләрен чәчеп пошкыра. Тәмәкене уба, ике суыруда бер папируз юк була. Шамраев безнең як кешесе түгел. Татарстандагы урыслар да, татарлардан күреп, әз-мәз әдәпкә өйрәнгән булалар. Моңа бармы кеше, юкмы — дөньяга ул хуҗа! Оятсыз анекдотларны, хатын-кыз белән булган шәхси маҗараларын иң әшәке ваклыклары белән бизәп алып китә, ят та үл! Ул бер чакта да үзенең кем булуын, кайсы яктан килеп чыгуын телгә алып сөйләмәде... Хәер, без аның кемлеген чамалый идек: ...без аның йә полицай жандарм булуын абайладык. Татарстанга качып килеп берәр мич башында посып яткан явыз бәндә иде Шамраев».

Бая әйткәнемчә, романда йөзләгән портрет: сәясиләр, легионерлар, законлы караклар, кеше үтерүчеләр, репатриантлар, тагын-тагын әллә кемнәр. Милләтләр төрле, татар, урыс, яһүд, молдаван, чегән, гәрҗи, төрекмән, казакъ, әрмән... Һәр кайсының бите-чырае, эш-гамәле, үзен тотышы, аяк-кул хәрәкәтләре, рухи дөньясы яки рухисызлыгы ачып салынган. Арада миңа шул йөзләгән портрет, йөзләгән шәхес арасында иң ошаганы, җанга ятышлысы Мәүлә Солтан булды. Ихтимал, әсәрнең баш героена, мин дип сөйләгән һәм вакыт-вакыт зур гомумиләштерүләргә тикле барып чыга алган Аяз Гыйләҗевка иң зур йогынты ясаган кеше шул булгангадыр. Ихтимал, аның артистлыгы, шагыйрьлеге тәэсир иткәндер. Әсәрдә портрет ягыннан ул иң зур урынны ала. Автор аның Әчтерханга китүеннән башлап, милиция идарәләрендә булуына тикле, төрмә камераларына тикле кабатлап килә. Дөресрәге — кабатланмыйча, гел яңа яклары белән ачыла. Тоталитар



*Сулдан уңга: Мөдәрис Вәлиев, Аяз Гыйләҗев, Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев. Сентябрь, 1985 ел. Пицунда.*

системада үзенә урын таба алмагач, ирек дигән татлы сүзнең гамәлгә ашырылуын күрмәгәч, ул әллә Горький, әллә Орел төрмәсендә асылынып үлә. Үз туган ягында да түгел, үз туфрагында да түгел. Бигрәк тә шунысы аянычлы, шунысы җанны тетрәтә.

Портрет турындагы төшенчә тулырак булсын өчен, әйтәсе сүзне әйтеп бетерим инде. Остазы Әмирхан Еники төсле, автор портретның гаҗәеп төрлесен бирә. Әйтик, тәмәке портреты. «Тәмәке димәктән... Утыз алтынчы камерада даими биш-алты кеше утырабыз. Күпчелек легионерлар, авыл кабартмалары. Аларның берсе дә передача-күчтәнәч алмый. Тәмәке — дефицит! Берзаман ул күзгә кырып салырлык кына кала! Дөньяда Колумблар юк, Америкадан кайтарта алмыйсың тәмәкене! Ә тәмәке... солдат белән ристанның аерылмас юлдашы! Тәмәке түгел, аның төпчеге генерал дәрәҗәсендә йөри. Урыс аны олылап: «чинарик» дип атый. Төпчек кулдан кулга күчә, бармак пешмәсен өчен уртак бер мөштек ясала. Мөштекне шырпы кабын ватып, йомычкасын кәгазь белән урыйлар, ипи йомшагын изеп ябыштыралар. Шобага салына, кем беренче булып тәмәке суыра? Ул мул итеп суыра да янәшәсенә чиратка баскан тоткынның авызына өрә. Авыздан авызга күчә барган төтен чират азагына җиткәнче сыеклана, аның инде бары тик исе кала. Нәни төпчек шулай авыздан-авызга бәхет өләшеп әрле-бирле йөри. Чират саклана, хәрәмләшергә уйлап арага керсән — беттен, тәмәке төтене өчен буып ыргытырлар. Ходай сакласын. Ниһаять, тәмәкенең соңгы бөртеге дә яна, камерага шомлы тынлык китмәскә кайта. Тәмәкесез калган җиде ир — тозакка төшкән җиде арслан, өчәр башлы җиде дию парие! Берзаман тәмәкенең бөртеге дә калмый, кесә төпләре кагылган, тумбачка почмаклары кат-кат себерелгән! Мәскәүнең Кызыл мәйданын да шулхәтле тырышып себермиләрдер. «Берәүдә дә юкмы?!» Хөкем авазы яңгырый: «Берәүдә дә!» Чират кулдан ясалган, җиде авыз арасында хәрәкәт иткән мөштеккә җитә. Никотин сеңгән сары йомычканы, кәгазь кисәкләрен бик вак итеп турыйлар. Һәм үзен тәмәке итеп төрәләр. Бу гаят әче төтенле, зәһәр исле «йомычка-сигараны» бер генә суыра аласың, шундук күздән яшь коела башлый, бөтен камера төчкерәйөткерә. Зәһәре коридорга ук чыга, надзиратель дә йөткерә-төчкерә, ул тимер ишекне дәү ачкыч белән төеп: «Мин сезне!... Сусыз, бәдрәфсез калдырырмын! — дип яный.»

Менә сезгә тәмәке портреты. Мин әдәби әсәрләрдә тәмәке турында бик көчле тасвирлар укыганым бар, әмма бу хәтлесен укыганым юк иде әле. Без әлеге

язмага тәмәкенең портреты итеп кенә дә карамаска тиешбез. Бу тасвирлауда төрмәнең эчке тормышы, төрмәнең атрибуты ята. Моны төрмә хакында әдәби китаплардан укыган кеше түгел, шул хәлләрне үз башыннан кичергән кеше язган. Шуңа күрә роман-хатирә ышандыра, роман чынлыгы белән күңелне биләп ала.

Кыска гына тагын бер портретка тукталыйк. Анысы җәзалаучылар портреты. Җәзалаучылар дигән сүзгә автор системаны да, җәзалау өлкәсендә эшләүчеләрне дә кертә. «Җәзалаучылар» дигән күмәк исем белән барысын бергә туплап бирүе — авторның зур уңышы.

«Адәм баласын кырыкка төрләндерү ысуллары бар Черек күл хөкемдарлары кулында! Карышып кара син аңа!.. Передача-күчтәнәч бирдерми. Янына быткыч, явыз, тешләк, әчәрвах, тилемсә, вак, ахмак, өчләтә юньсез тоткыннарны китереп тыга. Берәвесенең исе үк синең күңелеңне кайтара. Берәү дөнья бетереп гырлый, буыла, сикереп торып сине тәпәли башлый, күзен акайтып тешләргә итенә. Берәүнең арт шәрифе туктаусыз тегермән тарта... исенә чыдар әмәл юк, тешкә сылана. Берәү тәмәкене убыр урынына ашый».

Җитәр дип уйлыйм. Китерелгән мисаллар — нибарысы биш мисал — Аяз Гыйләҗевның портрет остасы икәнен исбат итәргә җитә. Йөзләгән портретның берәве генә дә кабатланмый.

Романдагы икенче агым — публицистика, фәлсәфә һәм совет властен сүгүнең кушылмасы. Публицистика белән фәлсәфәсен хуплыйм мин каләмдәшебезнең. Анарда бик акыллы гомумиләштерүләр, тоталитар системаның явызлыгына бәя бирүләр бар. Әмма шушы агымдагы сүгенүләрне, тиргәнү түгел, нәкъ менә сүгенүләрне мин әдәби әсәр тукымасына кермәгән, гайре табигый нәрсәләр дип кабул итәм.

«Беләм,— ди автор,— бармак буыннарыңны ишек ярыгына кыссалар, тырнак асларыңа инә кадасалар, утлы тәмәке төпчеге белән колак бөдеркәләреңне көйдерсәләр, бот араңа — нәзек җиреңә шапылдатып типсәләр, сынмас җирдән сынарсың. Төрмә үзенең барлыгы, сулышы, тәртибе белән адәм җанын имгәтүгә көйләнгән». Менә бу чын фәлсәфә, ышандыра торган зур фәлсәфә.

Шуннан соң китә: «Ленин-Сталин, аларның канэчкеч яраннары...» «Канлы тиран Сталинның кылган җинаятьләре...» «Большевиклар хакимияте канлы Октябрьдән башлана...» «Большевиклар партиясе — асылда караклар, ришвәтчеләр, талаучылар, үтерүчеләр, шымчылар һәм җәзалаучылар фиркасы ул» «...канлы, җимергеч байлык Ленин кулыннан тар маңгайлы Сосога күчкән». «Кәҗә сакаллы Калинин...» «...чирләшкә, бөкшәйгән, акылы зәгыйфьләнә башлаган Черненко да бүксәсен киереп маташа иде!» «...хәзерге заман кәрләләре, сәяси аренага үрмәләп чыккан ерткычлар...» «Маркс тәгълиматы — «XX гасырның иң куркыныч ерткычы» («урыс рәссамы Илья Глазунов сүзләре!» — дип автор җәяләр эчендә аңлатма бирә), Ленин эшчәнлегенең канлы эчтәлеге, большевиклар хакимиятенең чикләнмәгән явызлыгы...»

Боларны мин ни бары 30—40 биттән җыеп алдым. Моңа тагын «палач» дигән, «тиран» дигән сүзләрне, «куштан коммунистлар» дигән сүзләрне, 18 миллион коммунистка берьюлы кара буяу сылаган урыннарны өстәргә кирәк. Болар Аяз Гыйләҗевны бизәмиләр, шуның өстәвенә романның сәнгатьчә сурәтләнүенә зыян китерәләр. Шулар янына тагын барлык колхоз рәисләренә карата: аналы-кызлы ятимнәрнең алдын-артын мүклиләр, дигән, чапты-рып сиям дигән, күт дигән сүзләрне дә өстәсәк, шактый ук күңелсез картина күз алдына килеп баса. Ярый әле бу сүгенүләр роман-истәлекнең чагыштырмача аз өлешен генә билиләр...

«Йәгез, бер дога!» романындагы өченче агым — лирик агым. Юк, язгы жилләрдән, тургай сайрауларыннан гына тормый ул агым! Ул агым — мин дип сөйләгән баш геройның, ягъни Аяз Гыйләҗевның үз тормышы. Монда инде сүгенү юк. Бу агымда бар нәрсә югары сәнгатьлелеккә корылган. Укучыны тотып, мавыктырып тора торган агым да — романның шул шәхси язмышка, баш геройның язмышына бәйле урыннары. Бабасы мулла булган, әти-әниләре укытучылар, Сарман, Зәй яклары, керәшен авылы Баграж, андагы ихлас күңелле, ярдәмчел керәшеннәр, Зәйнең комсомол райкомолында эшләгән чакта сугыш еллының һәм аннан соңгы елларның күрер күзгә үк кызганыч авыллары, университетта укулар, Гурий Тавлин, Нил Юзеев, Мәҗит Рафиков, Ибраһим Нуруллин, бая мин әйткән фаҗигалы язмышлы Мәүлә Солтан. Сарманнан Зәйгә, Зәйдән Сарманга йөргән «Язгы кәрваннар» күз алдыннан кино кадрлары кебек тезелеп узалар.

«Кыршылган бригадир букчасын иңемә асып, кирза итегем белән яңа сукмаклар салып, Зәй комсомолларын тирән йокыдан уятырга, җан өрергә, ком-

мунизмның иң алгы сызыгына алып чыгарга дигән бурыч-заданиеләр төяп чыгып киттем. Ямьле яз! Күзеңне чынлыкка йомсаң, ул язда да матурлыклар табып була! Менә сызылып кына юллар төште, сирәк-мирәк ватык арбалар таккан арык алашалар очраштыргалый... Авыл араларында җылы җил, ярсып-ярсып сайраган тургайлар белән юанып әз-мәз онытыласың. Авыл урамына барып керү белән җан өшеп, куырылып кала. Һәр йорттан, күгәннәре каерылган капкалардан, өлгеләре кырылып, такта-токта белән кадакланган сукыр-букыр тәрәзәләрдән, өй түбәләреннән ишелеп аккан черек саламнардан, җимерек күперләрдән, ауган кое чыгырларыннан бөлгенлек, фәкыйрьлек, ятимлек күзне кисә, зиһенне томалый. Былтыргы бәрәңге басуларында тездән балчык ерып, карт-коры, бала-чага кәлҗемә җыеп йөри. Йөзләр сүрән, чырайлар сытылган, күз чокырларына өметсезлек кереп тулган. Укра тишеп бетергән, янбаш сөякләре тырпайган, ябагаларын коя алмаган сыерлар, кояш бәрәкәтеннән көч алырга өметләнеп, нигез тирәсенә чыгып басканнар да, менә авам, менә түнәм дип як-якка чайкалып, өй ишегеннән хуҗаларны чыкканны көтәләр. Югары очтан түбән очка, аргы яктан бирге якка арык биштәрләрен аскан хәерчеләр йөри. Ятимә әбиләр, ятимә әниләр, кашык сабы юанлыгы беләкләрен ачып-сузып йөрүче ятим-ялпы балалар...»

Менә кырык җиденче елгы авыл шушы. Шундый да зур осталык белән колхоз авылының сугыштан соңгы чорын, Сталин хәерчелеккә калдырган авылны гаҗәеп көчле итеп сурәтләп биргәннән соң, Сталинны палач дип, тиран дип, явыз дип сүгеп утыруның нигә кирәге бар? Билгеле бит инде болай да...

Яки Аязның Казагыстанда лагерьдан карцерга ябылган күренешләрне генә искә төшерегез. Бәс белән капланган таш стеналар, йөрәкләргә төшкән салкынлык, ә иң үкенечлесе — бер гаепсезгә — бары тик кояш яктысына ачык ишектән алданрак чыккан өчен генә шундый җәза алу — болар бит Сталин ялчыларының палачлыгы икәнен шәрран яра әйтеп торалар. Укучы аңламас дигәнгә юл куймаска кирәк, минемчә. Хәзерге заман укучысы сизгер, зирәк. Ул ярты сүздән сине аңлап ала, бер үк нәрсәне, инде сурәтләп биргәннән соң да үз сүзең белән, маңгайга бәреп аңлата башласаң, аның кәефе китә. Боларын мин каләмдәшем Аяз Гыйләҗев өчен түгел, әдәбият мәйданына әлерәк кенә аяк баскан яшь һәм башлап язучылар өчен әйтәм. Заманында Афзал Шамовлар, Гомәр Бәшировлар, Ибраһим Газилар безне шулай өйрәтәләр иде. Безгә дә өлкән әдип вазифаларын үти башларга, яшьләргә киңәшебезне әйтеп торырга вакыттыр.

Романда югары сәнгать законнарына таянып язылган картиналар күп. Моның өчен каләмдәшебезне «нык куллы язучы» дип әйтергә кирәк. Сүлпәнсалмак бер генә җөмләсе дә юк аның. Төрмә вәхшәтләре, лагерьлардагы «законлы караклар» оештырган мәхшәрләр, бөтен лагерьны дер селкетеп тоту, конвой солдатларның, офицерларның, надзирательләрнең, хәтта ки гади генә техник хезмәткәрләрнең дә кешелексезлеге, милли хис һәм горурлык уянып, тоткыннарның аерым төркемнәргә тупланулы, бандеровчыларның лагерь атаманнарын тезләндерүе, КГБның түләүле агентлары, Казагыстан далаларында котырынган бураннар, качып китқән ике немецның язмышы, соңыннан ялгызы гына качкан бер әсирне канга батырып кыйнау һәм баш түбән асып кую, тоткыннарны барлаган чагында күз ачкысыз буран астында, үзәкләргә үтәрдәй суык җилдә көне буе ач тоту, гаепсез тоткынны бер солдатның тиктомалдан атып үтерүе, шуннан соң лагерьларда купкан грандиоз забастовка, тоткын егетнең башта латыш кызына, аннары украин кызына гашыйк булып, язган хатлары, егет йөрәгендә утлы өермәләр кузгаткан мәхәббәт ялкыннары — болар барысы үз урынында, роман канвасына төп-төгәл кереп утырганнар. Кеше күңеленең төпкелләренә төшә алу, сурәтләү чараларында татар теленең барлык байлыгын берьюлы күтәрү, хисләр-тойгылар чарпылышын иң кайнар ноктасына меңгезеп җиткерү — менә нәрсәләр шатландырды мине бу романда.

Кайбер документлар һәм җырлар мәсьәләсе. Төрмәдән кайткач, «Чаян» журналында эшләгән чагында Аязга коллегасы Мөнирә Гатауллина истәлек сөйләгән, хат итеп язып биргән. Ул җаннарны тетрәтә торган документ. Сугышның бер елында көзен җыела алмый калган игеннәргә кагылырга рөхсәт итмиләр. Язын кар астыннан кышлап чыккан ашлыкның башагын җыеп, кул тегермәнендә, он итеп тарталар. Менә шуннан авыл кырыла башлый, кешеләрнең авыз-борыннарыннан кан китә, ә менә Мөнирә Гатауллиналар йортындагы гаиләнең кырылып бетә язуы җаннарны тетрәтә. Мин бу документны романга кертүне урынлы дип саныйм. Сталинга яхшатланып, төчеләнеп язылган Ромен Роллан хатын романга кертү дә урынлы. Шундый зур әдипнең, Европага атаклы романнары белән танылган мәшһүр язучының Сталинга төче хат язуы безне аптыраштa

калдыра. Татарстанның күренекле галиме һәм язучысы Ибраһим ага Нуруллинга — «Атаклы кешеләр» сериясендә (Казанда, Мәскәүдә, Ташкентта һәм башка калаларда) Тукай китабын чыгарган, Гаяз Исхакыйны туган иленә кайтару өчен көне-төне чабып, фирка әһелләре белән әчелешле булып беткән Ибраһим агайга гаеп ташлау белән мин килешмим. Әгәр ул социализмны яклый икән, марксизм-ленинизм тәгълиматына иман китергән икән, нигә аны гаепләргә? Үз иманы белән калсын! Бездә бит гасыр буе табынган пәйгамбәребез Тукайны Исхакый белән алыштырырга, Такташны юкка чыгарырга азапланучылар да булды. Халык үзенең Тукаен беркем белән дә алыштырмаячак һәм ул эшне эшләргә берәүгә дә юл куймаячак. Алар — үз заманының раушан көзгеләре, алар — җанлы тарих. Без тарихны Тукайдан, Такташтан, Галимҗан Ибраһимовтан, Хәсән Туфаннан укып беләчәкбез. Килер буыннар да шулай белерләр.



*Сулдан уңга: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Шамил Маннапов, Аяз Гыйләҗев, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Гомәр Бәширов һәм Флүн Мусин. 1 август, 1978 ел.*

Пожардан соң шланг селкеп йөрүчеләр күбәйде. Элек чәрәшә-чәрәшә социализмны, аның җитәкчеләрен мактаган әдипләр хәзер эт койрыгыннан тәзрәк булып кыланалар. Мин Аяз Гыйләҗевны алар рәтенә кертмим. Ул кырык җиденче елларда ук колхоз строена каршы чыккан кеше. Америка фермерларын яклаган студент. Мин бу сүзләрне тулы җаваплылык белән әйтәм. Ул заманнар өчен берәүне дә гаепләргә ярамый. Система гаепле булган. «Йөгез, бер дога» романы азакка таба тыгызлана төшә: анда мәгълүматлар бик ишле, истәлек сөйләүченең кичергәннәре дәһшәтле, фәлсәфи уйланулары тирән. Законлы каракларның биш чеченны үтереп-суеп чыгулары, лагерь зонасында купкан зилзилә-гарасат, җәзалаучыларның законлы каракларны зонада калдырып, «каралярны» этапка кууы («каралярга» кавказлылар да, Урта Азия тоткыннары да, татарлар да керә) — менә шул этапка, кан кардәшләре белән бергә, мин дип сөйләүче баш геройның да кушылмавы мине баштарак аптырашта калдырган иде. Уйлый торгач, мин баш геройның «каралар» белән этапка китмәвен дөрес дип таптым. Сталин төрмәсендәге җәзалау ысуллары исемә төште. Әгәр баш герой, кан кардәшләремне яклыйм дип, «каралар» белән этапка китсә, аның исеме барлык лагерьларга алдан ук хәбәр ителеп, ул законлы караклар тарафыннан юкка чыгарылган булыр иде. Хәзер дә әле бу бүре законы яши. Паспорт алмаштыруны гына алып карагыз: Русия хакимияте безне милләтсез калдырырга күпме тырышты!

Романда Петр Скороходов һәм Гордей исемле урысларның игелекле эшләре күрсәтелә. Болар Сталин дәверенең коточкыч гаделсезлеген, башбаштаклыгын, адәм баласын эт урынына да күрмәвен укучыларыбызга, бигрәк тә яшь укучыла-

рга аңлату өчен кирәк. Романда урыс халкына карата бик ачы сүзләр әйтелә, әмма урыслар арасында бик көттә затлар булуын аерым кешеләрнең кылган гамәлләрендә автор әледән-әле калку итеп күрсәтә килә.

Татарның гасырлар буена уяна алмый интегүен телевизион тапшыруларда булсын, «түгәрәк өстәл» сөйләшүләрендә булсын, гел әйтә килде Гыйләҗев, башкалардан аерылып, тырпаеп чыгып әйтә килде. Ә менә хәзер бу романында ул аңа аерым бүлек багышлаган. Роман тукымасындагы Александр Васильевич Мерзленков образы кызыклы. «Беркайчан да Россия империясенә аяк басмаган, татарның ничек-ничек изелгәнен, мыскылланганын Лондоннан торып черки боты хәтле дә белә алмаган Маркс: «Россиянең татарларны яулап алуы үтә дә унай күренеш»,— дип нидер мыгырдаган»,— ди ул. Александр Мерзленков нәкъ менә шундый теорияләрнең ялган булуын тоткын Гыйләҗевкә аңлатып бирә. Баш герой аны романда «Мерзленков сабаклары» дип бәяли.

Бу — моңарчы татарда күрелмәгән роман. Безнең унтугызынчы гасыр урталарында ук барлыкка килгән романнарыбыз да, егерменче гасыр башында язылган романнарыбыз да нигездә романтик стильдә. Аларда тормышның үтә авыр, үтә ямьсез якларына керү юк дәрәҗәсендә. Тормышның төпләренә төшү беркадәр Мәҗит Гафури, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә бар. Кабат әйтәм — беркадәр генә. Татар романы, гомумән прозасы, әдәп саклап, укучы колагын ерта торган натуралистик гамәлләрдән, затсыз сүзләрдән сакланып килде. А. Гыйләҗев романында барысы да бар. Параша өстендә ачы быкырдап утырулар да, гарип-горабалар да, конвой солдатлар кочләгән кызлар да, с и ю сүзе дә, ч ә п т е р ү сүзе дә — барысы да төрмә мәхшәрләренә сылтап язылган. Бу яктан А. Гыйләҗев үз иҗатына татар романы традицияләрен генә түгел, урыс романы һәм Көнбатыш прозасы традицияләрен дә алып керә. Профессиональ тәнкыйтьчеләр моны ничек бәялиләр, белмим, аларның ул мәсьәләдә сүз әйткәннәре юк әле.

«Йөгез, бер дога» — контрастлар романы. Шундый ямьсезлекләр белән янәшә ягымлы лирика урын ала. «Кызлар җырлый, кызлар!... Әнә алар, ерак та түгел, аларның иңрәвен безгә сагайган җил ирештерә! Тоткын күзе очкындай, аның ишетү сәләте төнге ябалакныкы белән бер. Кодрәтле җыр иямәре кызлар! Сезнең ирне сөеп, сөендереп, кайнар сулышыгыз белән тилертеп, кавышу кичләрендә, бәхетле таңнарда күккә чөеп, аңардан ир ясап, дөньяны бер бәби белән куандырып кына яшәр чакларыгыз бит!»

Каләмдәшебез — пейзаж остасы. Язны, кояшны, каеннарны төрмә дигән караңгылык патшалыгында әзелеп-әзелеп сурәтләвен әйтәсе дә юк. Таш базларындагы атмосфераны кыска гына бер-ике җөмләдә күз алдына бастыра ала әдип: «Сиксән метрлы кыя ярлар белән уралган базга җилләр үтеп керә алмый. Таш тузаны касмакланып тамак төпләренә утыра. Дөнья кызу, бер җирдә бер күләгә юк». Миңа калса, аз сүз белән шундый пейзажны тудыра алу һәркемнең дә кулыннан килми.

Роман дога белән тәмамлана. Чөнки әле бүгенге көндә дә, дөньялар яхшы якка үзгәрер дип уйлаган яңарыш заманында да, Әүлияләр зираты өстеннән, изге каберлекләрне актарып ташлап, таш юл сузалар. Автор әйтә, «коммунист-түрәләрнең мәкеренә, явызлыгына исләрең китәрлек!» — ди.

Соңгы сүзем итеп шуны әйтәм: күп мәгълүматлы, тирән фәлсәфәле, полифонияле, әллә ничә агымлы бу роман татар әдәбияты өчен бик тә кирәк иде. Һәр империянең ахырзаманы була. Аяз Гыйләҗев урыс империясенең ахырзаманына әлеге романы белән бәддога укый, аның төзәлмәс чирләрен ачып сала, фаш итә.

* * *

Аяз Гыйләҗевның кодрәтле таланты татар әдәбиятына бик күп үзенчәлекле әсәрләр бирде. Ул бит — утызга якын пьеса авторы. Аның драматургиясе арзанлы шаккатыризмга корылмаган, акыллы, тирән мәгънәле фикерләр драматургиясе ул. Татар дәүләт Академия театрында аның байтак әсәре куелды. Габдулла ага Юсупов режиссерлыгында «Көзге ачы җилләрдә», Празат Исәнбәт режиссерлыгында «Әңгер-меңгер» спектакльләре генә үз тамашачысын таба алды. Шуңа күрә мин бүген Татар дәүләт академия театры мәгънәгә, акыл сөрешенә корылган әсәрләрне куя алмый, аларга карата театрның мөнәсәбәте юк, дип әйтер идем. Академия театры тамашага корылган әсәрләрне генә кую ягында тора. Киләчәк буыннар алдында әлеге мөнәсәбәт өчен театр җавап бирергә тиеш булыр әле.

Аяз Гыйләҗев иҗаты — көрәшче иҗат. Ул беркайчан да такыр юлдан бармады. Рәхмәт әйтсен, тоталитар система заманында Гарәф Шәрәфетдинов, үзенә авырлык алып булса да, аның китапларын бастырып килде. Юкса партия өлкә комитеты җитәкчеләре Аяз каләмдәшебезнең язган бер әсәреннән гаеп эзләделәр. «Өч аршын җир» белән «Язгы кәрваннар» кире яктан мисалга алындылар. «Күзгә-күз» повестена карата аның каләмдәшләре гәзит аша погром оештырды. «Югалган бер көн» спектакленә Казанның урыс Зур драма театры куйган спектакльгә, өлкә комитет секретаре ничек ярсып ташланды. Мин язучыларның рәисе идем ул чакта, әлеге спектакльне яклагач, секретарь миңа да: «Хватит!» — дип кычкырган иде.

Хәтеремдә әле, Каракалпакстанда Аяз, ишәкне кочаклап: «Синең дә, минем дә бер бүләгебез дә юк. Этләргә, күргәзмәдә катнашып, койрык болгаган өчен, медаль тагып җибәрәләр»,— дип җылаган иде. Сабыр иткән морадына җиткән, ди бабаларыбыз. Мин рәис булып эшләгәндә (1983 елны) ул Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Туфан Миңнуллин ана РСФСР Дәүләт бүләген алуда булышты. «Йөгез, бер дога» романы һәм күпъяклы җәмәгать эшчәнлеге өчен ул Гаяз Исхакый бүләген алды. 1993 елның декабрендә аңа халык язучысы дигән дәрәҗәле исем бирелде.


Аязның берничә әсәре, әйтик, «Урманнар артында яшел болын», «Язгы кәрваннар» Чыңгыз Айтматов әсәрләре белән аваздаш. Ләкин аларны А. Гыйләҗев дөньяның мәшһүр язучысыннан алдарак язган иде.

Быел, гыйнвар аенда, Аяз Гыйләҗевка 70 яшь тула. Якташлары, Зәй хакимияте аны бик зурлады: моннан берничә ел элек Югары Баграж авылында аның әти-әниләре яшәгән йортны Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевка бүләк итеп бирделәр, ә өченче ел Зәй каласында күп бүлмәле, ике катлы коттеджны аңа тапшырдылар. Мин ул коттеджда Шәһидә ханым белән бергә булдым. Искиткеч уңайлы — бакчалы, мунчалы һәм теплицалы йортта ял иткәч, күңелемнән уйладым: «Менә бит татар язучысына да адәм рәтле яшәргә язган икән. Рәхмәт Зәй хакимиятенә, аның башлыгы Рәшит Сәет улы Хәммәдиевкә».

Ә Аяз каләмдәшнең үзенә, хатыны Нәкыя ханымга, укытучы-педагог дустыбызга, аларның берсеннән-берсе булдыклы балаларына — игелекле егетләргә — татарны арттырып, өч булдыклы егет үстергән гаиләгә бәхет, бәхет телим.

Гомер буе ат урынына эшләгән, картаймыш көнендә күп төрле дәрәҗәләргә ирешкән кодрәтле каләм иясенә — Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевка — Ходай Тәгалә күп итеп сәламәтлек бирсен. Ул әле тагын безне яңа әсәрләре белән сөендерсен.

**Гариф АХУНОВ,**
Татарстанның халык язучысы.



**Яхъя Абдуллин,**
шәрәфле академик, фәлсәфә
фәннәре докторы, профессор.

# ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ



Күренекле галим һәм мөтәфәккир (фикер иясе) Шиһабетдин бин Баһаветдин әл-Мәрҗани мәдәниятыбыз тарихында һәм иҗтимагый фикеребез үсешендә тирән эз калдырган олы шәхес. Ул 1818 елның 16 гыйнварында Казан артында урнашкан Ябынчы авылында киң белемле рухани гаиләсендә дөньяга килә. Тиздән аның әтисе Баһаветдин бин Собхан Казан артындагы икенче бер авыл — Ташкичүгә имам итеп тәгаенләнә. Баһаветдин хәзрәт бу авылда зур мәдрәсәгә нигез сала. Шиһабетдин мәхдүм шушы мәдрәсәдә фәннәр үзләштерүдә тәүге адымнарын атлый. Үзенең кызыксынучанлыгы, өйрәнелә торган фәннәрнең асылына төшенүгә омтылышы белән ул башка шәкертләрдән аерылып тора. Дәресләрдә бирелгән китаплардан тыш ул күп кенә өстәмә әдәбият укый, ә 17 яшеннән әтисенә шәкертләрен укыту-өйрәтүдә булышлык күрсәтә башлый.

1838 елда Ш. Мәрҗани — инде житкән егет — укуын дәвам итү өчен сәүдә кәрванына ияреп Бохарага китә. Бирәдә ул иң абруйлы мөдәррисләрдән дәресләр ала, күп вакытын шәһәрнең китапханәләрендә үткәрә, дини, фәлсәфи, тарихи, филологик әдәбият дөньясына чума, шул ук вакытта мөстәкыйль фикер йөрткән шәхесләр белән аралашырга да тырыша.

Уку елларында яшь Шиһабетдинның нинди дә булса матди чыганаклары булмый. Шуңа күрә аңа күп кенә вакытын тормышын материал яктан тәэмин итүгә бирергә туры килә: ул шундагы байларның балаларын укытырга яллана, китап күчерү белән шөгыльләнә, ә җәйләрен мөгаллимлек итү өчен авыл җирләренә чыгып китә.

Биш ел Бохарада укыганнан соң Ш. Мәрҗани Сәмәркандка күчеп килә һәм укуын дәвам итү өчен «Шердар» мәдрәсәсенә урнаша. С. Айни китергән мәгълүматларга караганда, булачак галим-мәгърифәтче бу адымын Бохара әмире Насрулланың эзәрлекләүләре аркасында ясарга мәҗбүр була. Монда ике ел укыганнан соң Ш. Мәрҗани янадан Бохарага әйләнеп кайта һәм заманының атаклы мәдрәсәләреннән булган «Мир-Гарәп» тә укуын дәвам итә. Бирәдә ул укуын татар, төрекмән, үзбәк шәкертләренә дәресләр бирү белән чиратлап алып бара һәм үзенең мәгыйшәтен шул юл белән тәэмин итә.

Бохарада һәм Сәмәркандтә укыган елларында Ш. Мәрҗани мөселман дине тәгълиматы белән бер рәттән фәлсәфәне дә, тарихны да, гарәб һәм фарсы телләрен дә бик нигезле итеп өйрәнә, математика, бигрәк тә геометрия һәм астрономия белән шөгыльләнә. Бирәдә ул шәрекънең әл-Фараби, әл-Бируни, Ибн Сина, Ибн Рошд, әл-Кинди, әл-Мәгарри һәм Ибн Халдун кебек олы фикер ияләренең мирасы, Сәгъди, Фирдәуси, Руми, Хайям, Низами, Навои кебек күренекле шагыйрьләрнең әсәрләре белән таныша.

1849 елда Ш. Мәрҗани ватанына әйләнеп кайта, беренче Казан мәчетенең имамы һәм аның каршындагы мәдрәсәнең мөдәррисе вазифаларын үтәүгә керешә. Бирәдә ул киң планлы уку-укыту һәм фәнни эшчәнлеккә чума, мәдрәсәнең эш

тәртибен тәртипкә салу һәм уку-укыту процессын камилләштерү юнәлешендә тәвәккәл адымнар ясый. Ул үзе биргән дәресләр, күтәрелгән проблемалары ягыннан тирән анализлы булуы һәм фәнни мәгълүматларның байлыгы белән аерылып торалар. Шул вакыттагы мөселман уку йортларына хас традицион фәннәр белән бергәттән Ш. Мәрҗани үзенең шәкертләренә тарихтан, географиядән, математикадан, астрономиядән дә төпле мәгълүматлар бирергә тырыша, аларны шәрекъ фәлсәфи вәкилләренең һәм шагыйрьләренең әсәрләре, шулай ук үз халкының мәдәни мирасы белән таныштыра.

Казанда эшләү Ш. Мәрҗани алдында урыс һәм Көнбатыш Аурупаның мәдәнияты һәм фәнни-фәлсәфи фикере белән танышу өчен дә зур мөмкинлекләр ача. Биредә ул А. Казембек, В. Радлов, И. Готвальд кебек күренекле галимнәр белән якын мөнәсәбәттә була. Үзенең шәкерте Х. Фәизханов аша ул Петербургта эшләүче шәрекъ белгечләре Вельяминов-Зернов һәм Дорн белән дә элемтәгә керә. Бу исә аңа урыс һәм көнбатышның фәнни фикере белән танышып тору мөмкинлеген бирә.

Нәтиҗәдә Ш. Мәрҗани киң диапазонлы галим булып формалаша. Аның йөзендә безнең күз алдыбызга ныклы хәзерлекле философ, тарихчы галим һәм мәдәниятның төрле тармакларыннан хәбәрдар белгеч буларак килеп баса. Ул әдәбият һәм тел гыйлеме проблемалары белән дә яхшы таныш, археология, этнография, нумизматика, математика, астрономия, география, медицина, фармакология, музыка, фән һәм сәнгатьнең башка төрләре буенча да бәхәс алып бара һәм аларның һәркайсы буенча төпле фикерләр бәян итә ала.

Ш. Мәрҗанинең фәнни-иҗади эшчәнлеге Бохарада укыганда ук башлана һәм бөтен гомере буенча дәвам итә. Үзеннән соң ул бай фәнни мирас калдырды. Аның тарафыннан барлыгы 30 дан артык фәнни хезмәт язылды. Аларда фәлсәфә һәм илаһият тәгълиматы (богословие) проблемалары, тарих һәм мәдәният мәсьәләләре яктыртыла. Аның күпкырлы мирасында «Мөкаддимәте китабе Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхләф» дигән фәлсәфи-теоретик хезмәт аерылып тора. Бу зур күләмле китап 1883 елны Казанда гарәп телендә басылып чыга. Ул тирән эчтәлекле теоретик әсәр. Анда автор үзенең тарихи процесска, төрле фәннәрнең барлыкка килүе һәм таралуына карата булган карашларын бәян итә, фәлсәфи-методологик проблемаларны, илаһият тәгълиматына кагылышлы мәсьәләләрне яктырта. Китапта Ш. Мәрҗани шулай ук фәннәргә классификация бирә, аларның роль һәм функцияләре турында сүз алып бара. Мөселман дөньясында урнашкан традициягә бинаән ул фәннәрне ике төркемгә — рациональ фәннәргә (гыйльме гакылия) һәм традицион фәннәргә (гыйльме нәкылия) бүлә. Әмма үзенең элгәрләре белән чагыштырганда аерым фәннәрне характерлаганда үз заманының фәнни казанышларына таяна. «Мөкаддимә» дә гарәпләрнең борынгы тарихы, ислам тарихы, габбасилар һәм госманилар тарихы, гарәп теле һәм әдәбияты мәсьәләләре дә үзләренең чагылышын табалар.

Ш. Мәрҗани каләме белән шулай ук «Вафийәт ал-әсләф вә тәхийәт аләхләф» исемле 7 томлык капитал хезмәт тә язылды. Бу биобиблиографик характердагы зур әсәр гарәп телендә язылган, әмма нәшер ителмәгән. Хәзер Татарстан Фәннәр академиясе тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы һәм ислам белеме бүлегендә аның урыс телендә кыскартылган варианты хәзерләнде. Әмма әлегә ул да үзенең нәшер ителүен көтеп ята. Ә хезмәтнең кульязма оригиналы исә Казан дәүләт университеты китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана. Анда VI гасырдан алып Мәрҗанинең үз заманына кадәр яшәгән мәгълүм шәхесләрнең тормышы һәм иҗади эшчәнлегенә һәрьяклап анализ бирелә. Бу шәхесләрнең тормышы һәм эшчәнлеге яктылыгында автор тарихи вакыйгаларны тасвирлый, җәмгыятьнең рухи тормышы һәм мәдәният үсеше мәсьәләләрен күтәрә. Бу әсәрдә шулай ук социал-экономик һәм тарихи үсешне күзалларга мөмкинлек бирә торган бик бай мәгълүмат та тупланган. Төркия тарихының аерым сәхифәләре, мәсьәлән, Сәлим I, Сөләйман әл-Кануни, Сәлим II, Мәхмүт I һәм башкаларга багышланган очерклар аша бирелә. Әсәрнең соңгы томындагы күп кенә сәхифәләр үз жиребездә яшәгән галимголяма һәм башка тарихи шәхесләрнең тормышын һәм иҗади эшчәнлеген яктыртуга багышланган.

«Вафиият...»кә кертелгән биографияләр аша мөселман дөньясында иҗтимагый фикер үсеше дә, төрле идеологик юнәлешләр арасында барган көрәш тә, исламда төрле мәзһәбләр формалашуы тарихы һәм алар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр дә, ислам дөньясы фәлсәфи фикеренең үзенчәлекләре һәм аның илаһият тәгълиматына (богословиегә) мөнәсәбәте дә, мөселман җәмәгатьчелегендә суфичылыкның урыны мәсьәләләре дә үзләренең ачык чагылышын табалар.

Әсәрнең кулъязмасы Әл-фәраби, Ибн Сина, Әл-мәгарри, Әл-Кинди, Ибн Рошд кебек ислам дөньясының олы мөтәфәккирләре һәм башка мәдәният эшлеклеләре турында да бик кыйммәтле мәгълүматлар саклый.

«Нәзүрәтел-хах» (Казан, 1870), «Әл-Хикмәтел-Балига» (Казан, 1888), «Хаккыл-мәгърифәт» (Казан, 1880), «Әл-Барк әл-вәмүд» (Казан, 1888), «Әл-Газб ул-Фурат» (кулъязма) исемле гарәп телендә язылган хезмәтләрендә Ш. Мәрҗани фәлсәфәгә һәм илаһият тәгълиматына кагылышлы мәсьәләләр күтәрә һәм аларга һәрьяклап анализ ясый. Бу әсәрләрендә мәгърифәтче галим мөтәкәллимнәрнең дөньяга караш мәсьәләләренә кагылышлы фикерләренә тәнкыйди анализ ясый һәм чынбарлыктагы процессларны фәнни яктан аңлауга юл ярa.

Ш. Мәрҗанинең фәнни мирасында «Мөстәфадел-әхбар фи әхвәви Казан вә болгар» исемле хезмәте аерым урын алып тора. Бу ике томнан торган әсәр татар телендә язылган. Аның беренче томы Казанда ике мәртәбә — 1885 һәм 1897 елларда нәшер ителә, ә икенче томы 1900 елда дөнья күрә. Галимнең бу китабында Идел Болгарстанының дәүләт буларак оешуы яктыртыла, аның халкына кавеми (этник) һәм мәдәни яктан характеристика бирелә, бу халыкның тормыш шартлары карала, анда хакимлек иткән иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-идеологик мөнәсәбәтләр тасвирлана.

Әсәрнең икенче кисәгендә явыз Иванның Идел буен яулавының нәтиҗәләре, татарлар арасында мәгърифәт эшенең торышы, белем таралышы анализлана һәм уку-укыту йортларының торышы характерлана. Бу томда татарлар арасында эшләгән, танылган мөдәррисләрнең, укымышлыларның һәм башка күренекле шәхесләрнең эшчәнлеген яктыртуга да зур урын бирелгән. Китапның һәр ике өлешендә Идел-Кама болгарларының һәм аларның токымы булган татарларның материаль һәм рухи культураларын характерлауга да зур игътибар бирелгән. Китапта шулай ук болгарлар белән якын мөнәсәбәттә булган халыкларның тарихы һәм мәдәнияты да үзенең чагылышын таба. Укучы бу әсәрдә хәзәрләр, кыпчаклар, бортаслар, башкортлар, казакълар, Урта Азия, Себер, Кавказ халыклары турында да кызыклы мәгълүматлар таба ала. Анда шулай ук урыс тарихының да мөһим сәхифәләре яктыртыла.

Үзенең эчтәлеге һәм яктыртылган проблемаларының характеры белән «Мөстәфадел-әхбар...»га Ш. Мәрҗанинең тарих буенча тагын бер әсәре — «Гыйляләт әз-заман фи әхвали Казан вә Болгар» да якын тора. Мәгърияфәтче галимнең бу әсәре 1884 елда татар һәм урыс телләрендә «Труды IV археологического съезда в России» дигән китапның беренче томында басылып чыга.

Тарихчы галим буларак Ш. Мәрҗани җирле тарихны өйрәнү белән генә чикләнми. Бер үк вакытта ул фән дөньясында күренекле шәрекъшнас (востоковед), Мөселман халыкларының тарихы һәм мәдәнияты буенча күп санлы хезмәтләр авторы булып та танылa. Инде телгә алынган «Вәфийәт-ел-әсляф вә тәхийәтел-әхляф» дигән хезмәтендә дә ул киң диапазонлы шәрекъ белгече (шәрекъшнас) буларак чыгыш ясый. Шәрекъка турыдан-туры кагылышлы аның башка хезмәтләре дә дөнья күрә. Аларның күп өлеше Урта Азия халыкларының тарихын һәм мәдәниятын яктыртуга багышланганнар. Әле Бохарада укыган елларында ук ул «Иламе әбнаи әл дәһр фи әхвали вә әһел Мәвәрәэннәһер» («Заманының уллары Мәвәрәэннәһердәге эшләр һәм кешеләре турында») дигән китап яза. Анда ул Урта Азиядәге шул вакытта булган хәлләргә, Бохараның дәүләт эшлеклеләренең һәм голямәсенең эшчәнлегенә тәнкыйди анализ бирә. Мөгаен Бохара әмире тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителгән үзенең элгәре Габденнасыйр Курсавиның язмышын күз алдында тотып ул бу хезмәтен үзе Урта Азиядән киткәч кенә таратырга васыять әйтеп калдыра.

Ш. Мәрҗанинең Урта Азиянең тарихын һәм географиясен яктыртуга багышланган хезмәтләре дә бар. Шундыйлардан берсе «Гурфат әл-хавакин ли Арфат әл-хавакин» («Хаканнарның тораклары һәм аларның тормышларын өйрәнү») дигән китап. Бу китап 1864 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга һәм фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәя ала. Мәгърифәтче галимнең бу хезмәтен «Аң» журналы болай дип бәяләде: «Әгәр «Мөстәфад әл-әхбар...» Идел буе халыклары тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булса, «Гурфат әл-хавакан...» Урта Азиянең X—XII йөзләргә караган тарихын өйрәнүдә шундый ук роль уйный»[1]. Бу хакыйкый бәяләмә. Чөнки ул вакытта Урта Азиянең монгол чорына кадәрге тарихын яктырткан хезмәтләр әлегә булмый.

---

[1] Шиһаб хәзрәтнең Урта Азия тарихына караган бөек хезмәте. «Аң», 1914, 4 сан, 74 б.

Ш. Мәрҗанинең «Әл-Фаваид әл-мөһиммә» («Олы файда») исемле хезмәте дә турыдан-туры Урта Азиягә карый. 1878 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан бу хезмәтендә ул куфи язуы белән язылган уникаль Коръәнгә тасвирлама бирә. Бу Коръән элек-электән Сәмаркандда саклана, ә урыслар Урта Азияне яулап алгач Русиягә алып кителә һәм Санкт-Петербургтагы император китапханәсенә элгә. Ул мөселман дөньясының изге ядкярьләреннән санала һәм зур абруйга ия була. Риваятьләргә караганда, Госман Хәлифә аны үзе яза һәм янына үтерүчеләр бәреп кергәндә аның кулында була һәм анда хәлифәнең кан тамчылары саклана. Мәрҗани инде 1856 елда ук, урысның шәрекъне өйрәнүче галиме В. Ф. Шебуниннан 36 ел элек, Россиядә беренче булып бу истәлекнең бик борынгыдан калуын, шулай да Госман хәлифә кулында була алмавын ышанычлы дәлилләр китереп раслый. Әсәрдә шулай ук Русиядә Коръән басылу тарихына да тирән анализ бирелә.

Ш. Мәрҗанинең «Ихтисар китаб ән-Нәджүм аз-за һира Фи әхвәли Мисыр вә әл-Каһирә» (кулъязма) дигән хезмәте дә шәркый проблемаларны тикшерүгә багышланган. Бу әсәрендә автор Мисырда яшәгән һәм иҗат иткән күренекле галимнәрнең тормышын һәм эшчәнлеген яктырта, аларның мирасына фәнни характеристика бирә.

* * *

Шулай итеп күпсанлы хезмәтләре аша Ш. Мәрҗани безнең күз алдыбызга зур галим-тарихчы һәм Фәлясиф-мөтәфәккир (мыслитель) буларак килеп баса. Фәлсәфә һәм илаһият тәгълиматы проблемаларын яктыртканда да, фәнни проблемаларны тикшергәндә дә ул рационализм позициясендә тора һәм аек акылга таянып фикер йөртә, фәлясиф-рационалист буларак мөтәфәккиребез схоластик уйдырмаларны катгый рәвештә кире кага һәм хөр фикерлелекне яклап чыга. Ул, әлбәттә, ислам тарафдары һәм үзенең оппонентлары белән бәхәсләшкәндә Коръән һәм хәдисләргә таяна. Шул ук вакыт ул фанатизм белән мистицизмны да ачы тәнкыйть утына тота һәм бу очракта изге китапларны аларның позицияләрен какшату максатында файдалана.

Ш. Мәрҗани кәлям һәм мөтәкәллимнәр (кәлямчеләр) тарафдары булмады. Кәлямне ул фәлсәфә белән илаһият гыйлемен ясалма рәвештә кушудан хасыйль булган спекулятив корама дип санады. Кәлям һәм мөтәкәллимнәр турында сүз йөрткәндә, ул алар мөселман халыкларның рухи үсешендә тискәре роль уйнадылар дип фикер йөртте. «Кәләм әһеле,— дип язды ул,— фәлсәфәнең бәгъзе гыйбарә вә истыйляхләренең мәгънәләрен аңламый алып, әһел сөннәт вә әлҗәмәгать гакаидына катыштырдылар. Вә үзләренең буш хыяллары, хата кыяслары илә күп мәсьәләләрне чуалттылар, һәм сәләф салихин мәзһәбенә дә, фәлсәфә мәсләгенә дә муафикъ булмаган яңа бер мәзһәб ихдас итеп, гакаид хакны тәшвиш иттеләр»[1].

Фәлсәфәдә рационализм позициясендә торган Ш. Мәрҗани тәкълидчелек белән дә килешә алмады. Тәкълидчелек идеясе ул заманнарда консерватив карашта торган дин әһелләренең һәр төрле яналыкка, хөр фикерләүгә каршы көрәшү коралы вазыйфасын үтәде. Бу идея белән коралланган искелек тарафдарлары үз замандашларын борынгылар әйтеп калдырганнарга һич ни уйламыйча иярүне таләп итеп чыктылар, адәм баласының иҗади эзләнүләргә хакы барлыгын инкяр иттеләр. Алар фикеренчә, иҗади көчәнүләр һәм эзләнүләр заманы инде артта калды (иҗтиһад мөнкарыйз), мөҗтәһидләр (мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле шәхесләр) юкка чыкты. Борынгы заманнарда яшәгән мөҗтәһидләр дөнья тәртипләре турында бөтенесен әйтеп калдырганнар, хәзерге бәндәләр шул мөҗтәһидләр сүзенә унга-сулга карамыйча ышанып эш итәргә тиешләр. Бу идеянең җәмәгатьчелек фикерен яулап алуы иҗади эзләнүләргә богау салды, уй-фикердә торгынлык тамыр җәюенә китерде. Бусы исә җәмгыять тормышында урта гасырдан калган традицияләр саклануының мөһим терәгенә әйләнде.

Әле Ш. Мәрҗанинең элгәрләреннән булган Г. Курсави бу практикага каршы кискен протест белән чыкты, тәкълидчелекне иҗтимагый үсешне тоткарлый торган традиция буларак гаепләде. Әмма үткәннәргә сукырларча иярү һәм догматизм күренешләренә каршы хәлиткеч һөҗүм Ш. Мәрҗани тарафыннан ясалды. Үзенең «Нәзүрәтелхак» («Хаклыкны күзәтү»), «Әл-хикмәтел-балига» («Җитлеккән фәлсәфә»), «Хаккыл-мәгърифәт» («Мәгърифәттә хаклык»), «Мөкаддимәте... («Кереш») һәм башка хезмәтләрендә ул тәкълидчелек һәм аңа бәйлән-

[1] Мәрҗани. Казан, 1915, 228—229 бб.

гән догматизм безнең арада һәр төрле тәгассыблыкның һәм катып калганлыкның терәгенә әйләнде, дигән фикер үткәрә. Безнең өстебезгә төшкән зур афәтләрнең берсе,— дип язды ул зур ачыну белән,— «иҗтиһад гасыры үтте, мөҗтәһидләр бетте, дәлил китереп сүз сөйләү, фикер әйтү бары мөҗтәһидләр эше, хәзер мөҗтәһидлек дәрәҗәсенә ирешү юллары киселгән» дигән фикер таралу[1].

Бу фикерне кире кагып мәгърифәтче галим кешелек җәмгыятенең танып-белү куәсенә һәм актив иҗади эзләнүләргә һич нинди киртә булуы мөмкин түгел дип күрсәтә. Кеше үзенең фикерләвендә дә, эш-гамәлләрендә дә һәркайчан ирекле булып кала. «Истидлял (фактларга таянып дәлилле нәтиҗә чыгару) куәсен тәхсил кылырга иҗтиһад итмәк,— дип яза ул,— һәр кемгә тиешле. Китап, сөннәткә иттибаг (иярү) белән бергә һәр кемдә истидлял куәсе булмак та лязим»[2]. Бәхетсәгадәт гасырыннан ераклашкан саен мәгърифәт нурлары тоныклана бара. Ә ахырда ул бөтенләй сүнәчәк дигән киң таралган фикерне кире кагып ул «Кирәк кай заманда булсын кыямәт көненә кадәр һәрбер мөэмингә Коръән вә хәдис нәбуягә тәмәссек (тотыну) белән бергә иҗтиһад юлында булу лязимдер», дип кисәтте[3].

Мәрҗани шулай ук ул заманнарда мөселман дөньясында нык тамыр җәйгән тәкъфир практикасын, фәнни эзләнүләр белән шөгыльләнүче һәр кемсәне дәһрилектә гаепләү күренешләрен дә бөтен кискенлеге белән кире кага. Тәкълидчелек кебек үк тәкъфир дә аның фикеренчә алгарыш юлында яткан коточкыч киртә булып тора. Бу мәсьәләдә үз карашларының догматик позициядә торган мөтәкәллимнәрнең фикерләренә капма-каршы булганлыгын ассызыклап, ул болай дип язды: «Без хәкимнәр вә әһле мәгърифәтне, гакыл вә хикмәтне дошман күрмибез һәм аларның дәлил илә исбат ителгән нәрсәләрен шәрә мөтәссыб (фанатизм) вә дошманлык белән инкяр итмибез. Әһле мәгърифәтне, гакыл вә хикмәтне дошман күрмәк, дәлил белән сабит булган нәрсәләрне шәрә мөтәгассыйб белән инкяр итмәк әһле кәлям вә мөтәфәләсифләр (ялган философлар) гадәтедер. Әһле кәлям вә мөтәфәләсифләрнең сүзләре гаять зәгыйф һәм хаклыктан ерак»[4].

Ш. Мәрҗанинең кәлям һәм мөтәкәллимнәр, алар белән бәйләнгән тәкълидчелек һәм тәкъфир турында әйтелгән сүзләре дини реформаторлык юнәлешендә иделәр. Әмма шуның белән бергә алар мәгърифәтчелек рухы белән дә сугарылган булдылар. Татар иҗтимагый фикерендә дини реформаторлык кәнбатыштагы кебек мәгърифәтчелектән вакыт ягыннан аерылып тормады, алар XVIII гасыр азагыннан алып XX гасыр башына кадәр бер-берсенә бәйле рәвештә, үзара үрелеп үстеләр. Чөнки татар мөтәфәккирләренең реформаторлык идеяләре кешеләрнең аңына юнәлдерелгән иде, аларны тирә-юньгә, традицияләргә һәм иҗтимагый практикага аек акыл белән, тәнкыйть күзе аша карарга чакырып тордылар. Ә иҗтимагый практикага, традицияләргә тәнкыйди караш, аларны аек акыл күзлеге аша үткәрү билгеле булганча мәгърфәтчелек хәрәкәтенең мөһим үзенчәлеге.

Брокгауз һәм Эфрон энциклопедиясендә, мәсәлән, мәгърифәтчелек нәкъ шул мәгънәдә аңлатыла[5]. 1957 елны Штутгардта (Германия) немец телендә чыккан фәлсәфи сүзлектә дә аңа карата шундый ук бәяләмә бирелә. «Мәгърифәтчелек,— дип язалар соңгысының авторлары,— мәдәни һәм рухи тормышны бәяләгәндә дини һәм сәяси авторитетларга гына таянган фикерләрне кеше акылына таянган һәм тәнкыйть сынаулары аша үткәрелгән карашлар белән алыштыруны максат итеп куючы мәдәни хәрәкәт»[6]. Тегесендә дә, монысында да мәгърифәтчелекнең үзенчәлеге буларак рационализм идеяләренә, аек акылга таянып дини, әхлаки, хокукый һәм сәяси мөнәсәбәтләрне тәнкыйди күзлектән үткәрү кирәклеге алга сөрелә. Марксизм да соңгы чиктә мәгърифәтчелекне аңлауда шушыңа охшаш позициядә тора. Мәгърифәтчеләр, дип язды Ф. Энгельс, «Нинди дә булса тышкы авторитетны танымадылар. Дин, табигатьне аңлау, җәмгыять тормышы, дәүләт төзелеше алар тарафыннан аяусыз тәнкыйтькә тартылды: бөтенесе дә гакыл хөкеменә тартылырга, аның алдында үзенең яшәргә хаклыгын расларга яки яшәүдән туктарга тиеш иделәр. Алар тарафыннан фикер йөртүгә сәләтле акыл чынбарлыкның бердәнбер үлчәме дип саналды»[7].

---

[1] Тел, әдәбият, тарих институты архивы, ф. 22, тасвирлама 1, саклау берәмлеге 20, 106 б.
[2] Мәрҗани. Казан, 1915, 509 б.
[3] Шунда ук, 275 б.
[4] Шунда ук, 247 б.
[5] Кара: Энциклопедия Брокгауза и Ефрона, т. XXV, С.-П., 1898, с. 469.
[6] Философский словарь, М. Литература иностранной литературы, 1961. с. 477.
[7] Маркс К. и Энгельс Ф. Соч. т. 20, М. 1961, с. 16.

Ш. Мәрҗани да шушыңа охшаш позициядә торды һәм аның мәгърифәтчелек белән аваздаш фикерләре реформаторлык идеяләре белән сугарылып үстеләр. Ш. Мәрҗанинең иҗатында мәгърифәтчелек һәм дини реформаторлык идеяләренең тыгыз бәйләнештә үсешен Г. Ибраһимов та күрсәтеп үтә. Ул моңа үзенең «Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре»[1] исемле мәкаләсендә Ш. Мәрҗанинең «Назурател Хак» дигән әсәренә биргән анализында бәян итә. Мөтәфәккирне бу китабын язарга этәргән нәрсә, дип күрсәтә Г. Ибраһимов, заманында зур бәхәсләр тудырган ястү намазы мәсьәләсе, шәфәкъ батып җитмәс борын таң ата башлаган җирләрдә ястү фарызмы, түгелме? Берәүләр бу сорауга фарыз түгел, ә икенчеләр — фарыз дип җавап бирәләр. Мәгърифәтче галим шәригатьне хәреф буенча гына аңлап җәйнең озын көннәрендә ястү намазын фарыз түгел дип санаучыларның фикерләренең дөрес түгеллеген ышанычлы дәлилләр белән ачып сала.

Бу мәсьәләнең дини реформаторлыкка кагылышлы ягы. Шул ук вакыт Г. Ибраһимов бу мәсьәлә буенча Ш. Мәрҗани тәнкыйтенең дини реформаторлыктан киңрәк һәм тирәнрәк икәнлегенә дә басым ясап үтә. Монда, дип ассызыклый ул, ислам дөньясын каплап, акылларны богаулап яткан барлык тоңлыкларга, барлык тәгаесыб вә караңгылыкларга каршы гаюранә протест кылучы куәтле мөтәфәккирне, фикердә вә игътикадта хөр булмак һәркемнең табигый хокукы дип игълан кылу үрнәге күрәбез. «Аллаһ азат яраткан акылга богау салмагыз,— дип яза Г. Ибраһимов Ш. Мәрҗанинең әйтелгән мәсьәлә буенча китерелгән фикерләренә йомгак ясап,— мөэминнең фикере хөр, менә Коръән, менә хәдис — шуларны мөталәгә итсен дә үзе аңлаганча игътикад вә гамәл кылсын. Мин үземне кемнеңдер фикер вә мәзһәбенә иярергә мәҗбүрмен дип белмим»[2].

Бу инде мәгърифәтче фикере; мәгърифәтчеләргә хас гакылга ирек даулау, хөр фикерлек даулау үрнәге.

Дөньяга караш мәсьәләләрендә дә Ш. Мәрҗани мәгърифәтчелек позициясендә торып, рационализм идеяләренә таянып фикер йөртә, фәлсәфи проблемаларны аек акыл калыбына салып карарга чакыра. Бу очракта да ул, әлбәттә, Ислам позициясендә кала һәм илаһи көч булган Аллаһны таный. Шул ук вакыт кеше яшәгән чынбарлыкның асыл нигезләре турында фикер йөрткәндә мөтәкәллимнәрнең фикерләре белән килешмәгәнлеген дә белдерә. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, Аллаһның асылы һәм сыйфатлары, дөнья һәм аның барлыкка килүе, дөньяның чикләнгәнлеге һәм чикләнмәгәнлеге, барлык һәм юклык мөнәсәбәте кебек фәлсәфи мәсьәләләрдә мөтәкәллимнәрне рационализм позициясендә торып ачы тәнкыйть уты астына ала. Әлбәттә, ул Аллаһны үзгәрүчән дөньяның (мөмкинатның) төп сәбәпчесе булуын таный. Бу сәбәпне Ш. Мәрҗани вөҗүдел-вәҗиб (зарури барлык) һәм кыйдәм (мәңгелек) дип атый. «Аллаһ тәгалә,— дип яза ул,— заман вә заманияткә вә барча мөмкинлекләргә мөтәкаддим вә сабикъ (беренчел); бу беренчелек Аллаһка хас булган мәгънә белән кыйдәм (мәңгелек) дип атала. Ул бөтен нәрсәләрне чолгап алган, аңа нисбәтән һәр әйбер, үткән һәм киләчәк бәрабәр»[3]. Аллаһ, Мәрҗани фикеренчә, табигатьтән аерылган һәм аннан алда яшәүче нииндидер шәхси зат түгел. Барлыкның гомуми асылы буларак ул һәркайчан һәм һәркайда мөмкинлекләрнең, конкрет күренешләрнең нигезендә ята һәм үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне үтәләй үтеп чыга. Чиксез мәңгелек, ягъни Аллаһ, барлык вакытлы мөмкинлекләрне чолгап алган һәм аңа карата һәрбер нәрсә, үткән, бүгенге һәм киләчәк берүк дәрәҗәдә, ә «күренешләр (мөмкинат) арасында заман вә мәкянда (урын, пространство) каршылык фәкать берсенең икенчесенә нисбәтән генәдер. Барлык мөмкинат вә күренешләрнең Аллаһы тәгаләгә нисбәте бер чик заманда булган ноктаның нисбәте кебектер»[4].

Мәрҗани дөньяның заманда (билгеле бер вакытта) яратылуы турындагы фикерләрне дә кире кага. Бу уңайдан ул мөтәкәллимнәр арасында киң таралган «хөдус замани» (заманда барлыкка килү) төшенчәсен тәнкыйть уты астына ала. Аның өчен һәрдаим хәрәкәттә булган реаль нәрсәләрдән (әйберләрдән) аерылган заман юк. Вакытлы яшәүче әйберләрдән башка күзалланган заман аның өчен бары буш хыял гына. Шулай булгач реаль чынбарлыкка кадәр булуы мөмкин дигән заман турында сөйләнүләрдә уйдырма гына булып кала. «Гадәмнең (небытие) вөҗүдкә (барлыкка) карата заманда алда булуы белән ходус заманының (заманда барлыкка килү) үзен эченә алмыйдыр; чөнки заманның гадәме вөҗүденә

---

[1] Кара: Ибраһимов. Бөек остазыбызның кайбер тәэлифләре. «Аң». 1915, 2 сан.
[2] Шиһабетдин Мәрҗани (җыентык), Казан, 1968, 51 б.
[3] Мәрҗани. Казан, 1915, 243 б.
[4] Шунда ук, 238—239 б.б.

заман эчендә алда булса, заман барлыкка килүдән элек заман булу лязим (тиешле) була, бу, әлбәттә, мөмкин булмаган нәрсәдер»[1].

Аллаһ, дип хисаплый Ш. Мәрҗани барча мөмкинлекләрдән алда килә, әмма бу аның табигый дөньяга карата замандагы беренчелеге түгел, ә асылда (зати, по сути) беренчелек. Күренешләр, мөмкинлекләр дөньясы да, Аллаһ кебек үк чиксез һәм мәңгелек. Бу мәңгелек вакытлы яшәүчән әйберләрнең (мөмкинатның) туктаусыз алышынып торуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Шулай итеп Ш. Мәрҗани «үткәндә һәм киләчәктә чиге булмаган вә туктауыз яңарып торган җөзьиятның (кисәкчәләрнең) нәүбәтләшүе нәтиҗәсендә саклана торган өзлексез табигать барлыгы, бу өзлексез табигать үзенең дәвамчыллагы вә өзлексезлеге җәһәтеннән мәңгелек иҗат итүчедән бәйле»[2], дигән нәтиҗәгә килә. Моның белән Мәрҗани, күренүенчә, бер яктан Аллаһ белән табигатьнең дә мәңгелек бердәмлеге, ә икенче яктан Аллаһның табигатькә карата беренчелеге идеясе тарафдары булуын күрсәтә. Аның карашынча Аллаһ яшәешнең гомуми сәбәпчесе, ул һәр кайда һәм һәр кайчан барлык нәрсәләрнең (мөмкинатның) дә нигезендә ята. Ул үткән, бүген һәм киләчәкне үтеп чыга һәм берләштерә. Аның асылы һәр кайчан һәм һәр кайда материаль чынбарлыкта да, рухи чынбарлыкта да үзенең чагылышын таба.

Әйтелгәннәр Ш Мәрҗани дөньяга караштa пантеизм позициясендә торды дигән фикер әйтергә мөмкинлек бирә. Ничек кенә булмасын Аллаһны ул табигый галәм белән куша һәм шуннан чыгып табигать күренешләрен аңлата. Аның «Безләр галәм барлык өлешләре илә күренеш, санигъ (иҗат итүче) вә халикый вахид (бердән бер яратучы) вә ул халыкъ гяләм барча камал сыйфатлары белән сыйфатланган, мәхлукларда булган кимчелекле сыйфатлардан пакъ вә чиста булуга игътикад кылабыз»[3], дигән сүзләре дә шушы фикерне раслый.

Аллаһның табигатькә мөнәсәбәтен пантеизм рухында кабул итү Ш. Мәрҗанига чынбарлыкны аңлатуда фәннилек позициясенә басарга мөмкинлек бирде. Аллаһ белән бергә ул маддәне дә зарури барлык дип таный, соңгысы аның фикеренчә үзгәрүчән түгел, бер төрле һәм бүлгәләнмәгән (недифференцирован). Шушы бер төрле һәм бүлгәләнмәгән маддәдән (материядән) үзгәрүчән табигатьнең конкрет әйберләре барлыкка килүен аңлату өчен мәгърифәтче галим шәкел (форма) төшенчәсен ала. Бер төрле һәм бүлгәләнмәгән һәм өзлексез маддә билгеле бер шәкелгә кереп табигатьнең конкрет күренеш һәм әйберләренә әйләнә. Һәрбер гәүдә рәвешен алган әйбер маддә һәм шәкелдән тора һәм шушы ике башлангычның бердәмлегеннән башка яши алмый. Галәм исә мадди табигатьтәге чикләнгән әйберләрнең (мөмкинатның) туктаусыз алышынып торуы белән яши. Ә бу чикләнгән әйберләр үзләре һәм аларның төрләре исә чиксезләр. «Маддәнең хәлләрендәге төрлелек шул кадәр күп,— дип яза Ш. Мәрҗани,— аларның барысын кеше гыйлеме чолгап бетерә алмый»[4].

* * *

Шиһабетдин Мәрҗанинының иҗади мирасында төп урыннарның берсен тарих фәне проблемалары алып тора. Ул безнең күз алдыбызга киң диапазонлы тарихчы — тикшеренүче булып та, тарих фәненең тирән фикер йөртүче теоретигы булып та килеп баса. Үзенең хезмәтләрендә ул тарихның фәннәр системасындагы урынын бик нигезле итеп ачып сала, кешеләр тормышында аның ролен тәгаенли һәм тарихи эзләнүләрнең методологик нигезләрен яктырта. Мәгърифәтче галим, мәсәлән, җәмгыять тормышында тарихның тоткан урынын ачыклап «бел, ул (тарих) — хикмәтләр диңгезенә чумган чын гыйлем һәм башка фәннәрне дә үзара бәйли торган, хөрмәткә лаеклы фән»[5], дип яза. Тарих фәненең бурычын исә Ш. Мәрҗани халыкларның тормышы өчен көрәшен ачып салуда, тарихи шәхесләрнең эшләрен тикшерү һәм бәяләүдә күрә, «Тарих,— дип яза ул тарих гыйлеменең максатын ачыклап,— халыкларның үткән хәлләрен сөйләп, аларның күркәм эшләрен белдерергә, элеккерәк заманда яшәп тә дөрес һәм изге юлдан баручыларга ияреpгә өнди... Тарихта төрле халыкларның һөнәрләре, зарарлы һәм файдалы эшләре күрсәтелә. Тарих — ул халык һәм

---

[1] Мәрҗани, Казан, 1915, 239 б.
[2] Шунда ук, 244—245 б.б.
[3] Мәрҗани, Казан, 1915, 247 б.
[4] Г. Ибраһимов исемендәге институт архивы. Ф. 22, тасвирлама 1, саклау берәмлеге 20, 97 б.
[5] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи-хвали Казан вә Болгар, Казан, 1959, 42 б.

кабиләләрнең башларыннан үткәнне, патшалар һәм гомумән житәкчеләрнең дуслашу һәм ызгышларын сөйли торган гыйлем. Бу өстән караганда, ә эчтән, ныклабрак уйласаң, тарихның төбе тирән хикмәткә ирештерә торган тикшерүләр үткәрү һәм жентекләү, ул вакыйгаларның ни рәвешле булганлыкларын, тирән сәбәпләрен, барның ничек бар булуын һәм аның нечкә нигезләрен ачу[1].

Тарих фәненең методологик принциплары турында сүз алып барганда Ш. Мәржани объективлыкка басым ясый, фактларны һәм вакыйгаларны, ничек булсалар, шулай яктыртырга кирәклеген күрсәтә. «Тарихчының вазыйфасы,— дип яза ул,— үзе хәбәрдар һәм игътибарга лаек сүзләрне, хәбәрләрне арттырмыйча, киметмичә, ничек бар шулай китерү, эчтәлегенең төп өлешен төшереп калдырмыйча һәм берәүнең файдасына яки икенчесенең зарарына тарафдар булмыйча аңлатып бирү. Булганны, яхшымы ул, яманмы, булганынча бәян итү»[2]. Аның фикеренчә, тарихчының тарихи дөреслектән тайпылырга, тарихи вакыйгаларны яктыртканда субъектив беръяклылык күрсәтергә, аларны бәяләгәндә гаделсезлек юлына басарга хакы юк. Шул ук вакыт ул объективлыкның тарихи фактларны һәм вакыйгаларны гадәти хикәяләү генә түгел, ә аңлатып бирү икәнлеген дә күрсәтеп үтә. Тарихчы, дип хисаплый ул, фактларның һәм вакыйгаларның асылына төшенергә һәм алар арасындагы бәйләнешләрне ачып та бирергә тиеш.

Татар мәгърифәтчелегенең формалашуы һәм үсеше милли аңның уянуы белән параллель рәвештә барды һәм бу Ш. Мәржанинның ижади мирасында да үзенең якты чагылышын тапты. Милләт һәм халыкның тарихи язмышы бу мирасның үзәк урыннарының берсен били. Милли аңның төшенкелеге, үз халкының тарихи үткәнен һәм мәдәни мирасын белмәү, аның фикеренчә, социаль һәм милли алгарыш (прогресс) юлында житди киртә булып торалар.

Шуңа күрә дә тарихчы-галимнең игътибары үзәгендә үз халкының, ул яшәгән төбәкнең тарихы тора. Ш. Мәржани бик урынлы рәвештә татар халкының фәнни тарихына нигез салучылардан санала. Татар мәдәниятының күренекле вәкиле Ж. Вәлиди юкка гына аны «безнең Геродотыбыз», дип атамады. Дөрес, татарлар арасында тарих гыйлеме аңа кадәр дә яхшы ук тамыр жәйгән иде, халкыбызның хәтерендә тарихи үткәнебез турында киң генә мәгълүматлар сакланып киленде. Тарихка кагылышлы язма әсәрләр дә бар иде. Әмма аларда теркәлгән мәгълүматлар әле таркау һәм алар эзлекле бер системага китерелмәгән иделәр. Татар халкының тарихы системалаштырылган, эзлекле язылышын беренче мәртәбә Ш. Мәржани мирасында үзенең чагылышын тапты. Аның «Мөстәфадел-әхбар...» һәм «Галялят аз-заман...» исемле әсәрләре турыдан-туры шушы мәсьәләгә багышланган. Татар халкының тарихи үткәне турында аның «Вәфийәтел-әсляф вә тәхийәтел-әхляф» дигән әсәрендә дә бай гына мәгълүмат тупланган.

Үз халкының тарихын язганда Ш. Мәржани гарәп тарихчыларының хезмәтләренә таяна, шәрекъ илләреннән чыккан сәяхәтчеләрнең истәлекләренә һәм урыс чыганакларына мөрәжәгать итә. Әмма аның фәнни тикшеренүләрендә үзәк урынны үзе эзләп тапкан мәгълүматлар алып тора. Тарихи дөреслекне торгызу өчен ул күп кенә беренчел чыганакларга — борынгы тәңкәләргә (акчаларга), ярлыкларга, телдән һәм язма рәвештә килеп ирешкән риваятьләргә, дәүләт эшлеклеләренең һәм аерым шәхесләрнең язмаларына, кабер ташларында теркәлгән хәбәрләргә, борынгы китапларның кырларындагы язмаларга һ. б. таяна. Үткәннең шуларга охшаш шаһитларын жыю өчен ул авылларга чыгып йөри, озын-озак сәяхәтләр ясый. Шулай итеп тупланган борынгы заманнар турында хәбәр итүче беренчел чыганакалар һәм борынгы китаплар аша килеп ирешкән мәгълүматлар өстендә ул жентекле тикшеренүләр үткәрә һәм тупланган мәгълүматларын тәнкыйть күзлеге аша үткәрә. Шул юл белән ул үз халкының тарихи үткәнен торгыза. Татар халкы, дип саный ул, зур тарихи юл үтте һәм бик күркәм мәдәният ядкарьләре тудырды һәм бу фикерен ышанычлы дәлилләр китереп раслый.

Ш. Мәржани хезмәтләрендә үзенең яңгырашын тапкан татар халкының тарихи үткәненә кагылышлы проблемаларның берсе — аның этник (кавеми) чыгышы һәм этник тарихы мәсьәләсе. Бу мәсьәләне ул X гасырда Идел буенда мөселман дәүләте төзегән болгар кавеменнән (этносыннан) башлый. Ибн Фадлан, Әл-Истархи, Ибн Халдун, Ибн Хаукал, Әл-Гарнати, Ш. Идриси, Әл-Мәсгуди, Ш. әд-Димәшки һ. б. гарәп авторлары китергән мәгълүматларга таянып, ул Идел-Кама болгарларының төрки кабилә булуларын раслый һәм «аларның

---

[1] Г. Ибраһимов исемендәге институт архивы, ф. 22, тасвирлама 1, саклау берәмлеге 20, 52 б.

[2] Мәржани Ш. Мөстәфадел-әхбар, 45—46 б.б.

телләре дә, калдырган әсәрләре дә, әхлаклары да, йолалары да, гореф-гадәтләре дә барсы да төрки иде»[1], дип яза. Ә хәзерге Идел буе татарларына килгәндә исә — алар шушы төрки кавем токымы. Болгарлар белән хәзерге татарлар арасындагы кавеми-мәдәни (этно-культурный) бәйләнеш һәм күчүчәнлекне ул тарихи мәгълүматларга, язма чыганакларга, тел материалларына, әдәби әсәрләргә, йола һәм гореф-гадәтләргә таянып дәлилли. Ахырда үз халкының тарихи үткәне буенча китерелгән мәгълүматларга йомгак ясап, ул болгар халкы «иң әүвәл кыпчак һәм хәзәр хаканнары хөкүмәте, соңыннан болгар әмирләре хөкүмәте, аннан соң Татар ханнары хөкүмәте карамагында булып, хәзерге вакытта өч йөз елдан артык инде Русия хөкүмәте идарәсендә»[2], дип яза. Димәк, Идел буенда яшәгән халык төрле чорларда төрле исемдә була һәм аның өстеннән төрле вакыт төрле хөкемдарлар идарә итә. Әмма болар бер үк халыкны тәшкил итәләр. Урта гасырларда бу халык Болгар дәүләте оештыра, ә хәзер урыс хөкемдарлары хакимлеге астында яши һәм хәзерге татар халкын тәшкил итә.

Искәрмә рәвешендә шуны да әйтеп үтәргә кирәк, бик катлаулы булган этник (кавеми) тарих проблемасына тарихчы галим бер яклы гына якын килми. Ул Идел буе һәм Урал татарларының оешуында башка этник группаларның да, шул хисаптан кыпчакларның һәм угро-фин кабиләләренең катнашуын да читләтеп үтми. Шул ук вакыт ул халыкның этник чыгышы мәсьәләсе бер канкардәшлеге белән генә чикләнмәгәнлеген дә яхшы аңлап фикер йөртә. Канкардәшлеге белән беррәттән этник тарих ул мәдәни процесс тарихы да, этник-мәдәни тарих. Мәсьәләне менә шушы киң яссылыкта карап, Ш. Мәрҗани хәзерге Казан татарлары Идел-Кама болгарлары токымы дигән фикергә килә. Болгар иле өстенә «төшкән һәртөрле бәла һәм фетнәләр сәбәпле, (Болгарның) яхшы вакытлары узып, (тарихи роле) Казанга күчә башлый һәм ахырда үзе бөтенләй харап булып, югарыда әйтелгән аның мактаулы хәленә Казан варис булып калды»[3].

Ш. Мәрҗани тарихка тормыш мәктәбе дип карый, аның танып-белү һәм әхлакый тәрбиядәге роленә басым ясый һәм шуңа бәйле рәвештә тарихи үткәнне һәм әдәби мирасын өйрәнү һәм пропагандалауны татар халкының киләчәк язмышын билгеләүдә мөһим шарт дип саный. Ул татар халкының зур тарихи үткәне һәм бай әдәби мирасы бар, дип хисаплый. Кол Галинең «Йосыф китабы», Мәхмүт әл-Болгариның «Нәхҗ әл-Фарадисы», «Нәсыйхәт әс-Салихин», «Бәдавам» кебек ядкарьләр, «Нәүрүз», «Шәһри Болгар вазилары» бәетләре кебек әдәби һәм әхлакый әсәрләр бу мирасның мөһим өлешен тәшкил итәләр. Боларның кайберләре «бик иске язу белән язылган... һәм Болгар шәһәрендә табылган кабер ташларындагы язуларга бик охшаган. Мондый китаплар бу мәмләкәттә басма һәм язма хәлдә бик күп табыла. Башка мәмләкәтләрдә күренгәне һәм ишетелгәне юк. Бу китапларның теле госманлы, чыгтай, төрекмән һәм казакъ телләреннән аерылып тора»[4].

Шулай итеп Ш. Мәрҗани бу әдәби ядкарьләрнең татар халкының рухи мирасының аерылгысыз өлеше икәнлеген раслап чыга.

* * *

Ш. Мәрҗанинең фәнни иҗаты һәм эшчәнлеге мәгърифәтчелек юнәлешендә иде һәм татар иҗтимагый фикере үсешендә бик мөһим роль уйнады. Аның иҗади мирасы туган халкын феодаль-патриархаль мөнәсәбәтләр һәм уртагасырчылык идеологиясе капкыннарыннан коткаруга, аны дөнья мәдәнияты казанышларына бәйләүгә юнәлдерелгән иде. Аның әсәрләре, дип язды Г. Ибраһимов, «фикер азатлыгын яклау, киләчәккә якты ышаныч һәм кеше акылына хөрмәт белән сугарылган... Беренче юллардан алып соңгысына кадәр, алар фикер коллыгына һәм аның үле традицияләр белән богаулануына каршы көрәшкә, кеше акылына салынган чылбырларны өзүгә, ватуга юнәлдерелгән идеяләр белән сугарылган»[5]. Ш. Мәрҗанинең иҗади мирасын һәм эшчәнлеген шулай ук татар мәдәниятының күренекле вәкилләре М. Акмулла, Г. Чокрый, Г. Тукай, М. Гафури, язучы-публицистлар Ф. Әмирхан, Н. Думави, галим-иҗтимагый эшлеклеләр Р. Фәхретдинов һәм Җ. Вәлидиләр дә югары бәялиләр. Үзенең «Шиһаб хәзрәт» исемле

---

[1] Мөстәфадел-әхбар, 11 б.
[2] Мөстәфадел-әхбар, 53 б.
[3] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар, 50—51 б.б.
[4] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар, 58 б.
[5] «Аң», Казан, 1915, № 1, 14 б.

шигырендә Г. Тукай, мәсәлән, аны «мәгърифәткә әүвәл башлап адым салган, милләт өчен бәһа җитмәс әйбәт хәзрәт» дип атады.

Ш. Мәрҗанинең фәнни эшчәнлеге урысның укымышлы даирәләрендә дә югары бәя алды. Күренекле шәрекъ белгече академик В. В. Бартольд, мәсәлән, аны «татарлар арасында прогрессив агымга нигез салучылардан», дип атады. Ә Казан университеты профессоры Н. Ф. Катанов тарихчы галимнең «Мөстәфадел әхбары...» тарих һәм этнография ягыннан урыс теленә генә түгел, Европадагы башка телләргә дә тәрҗемә итәргә лаек; монда автор Болгар һәм Казан патшалары турында төгәл һәм фәнни рәвештә яза» дип күрсәтеп үтә[1].

Күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Садретдин Айни һәм таҗик профессоры Богоуддинов татар мәгърифәтче галименең Урта Азиядә иҗтимагый фикер үсешенә тәэсире зур булганлыгы турында да язалар. Аның шулай ук казак мәдәниятының күренекле вәкилләреннән булган Акан-сере, Абай Кунанбаев һәм М. Сералиннарның фикри үсешенә дә йогынтысы бәхәссез. Соңгысы Ш. Мәрҗанины «халыкка хезмәт иткән олы шәхес»[2], дип характерлады. Мөхтәр Әуэзов Абай Конанбаев әсәрләре җыентыгына кереш сүзендә бу казакъ язучысының «беренче татар мәгърифәтчесе — яңалык кертүчесе булган Шиһабетдин Мәрҗанине яхшы белгән»[3], дип күрсәтеп үтте.

Ш. Мәрҗани үзен Россиядә генә танытмады. Көнчыгыш илләрендә дә һәм көнбатышта да аны белә иделәр һәм аның турында һаман кызыксынып тордылар. Мәсәлән, 1874 елның 30 мартында аңа Лондоннан энциклопедия өчен тәрҗемәи хәлен һәм фотосын җибәрүен сорап хат белән мөрәҗәгать итәләр. Аның белән Төркия, Тунис, Каһирә, Мәдинә, Һиндстан галимнәре кызыксынып тора, «Язылуына берничә ел үткәннән соң,— дип язды Мисырда чыга торган «Әл-Моктатыйф» журналы,— безгә галим Шиһабетдин бин Баһаветдин бин Собхан бин Габделкәрим әл-Мәрҗанинең «Вәфийәт әл-әсләф вә тәхийәт әл-әхләф» исемле китабы килеп иреште. Ул Аурупа Русиясенә буйсындырылган Казан өлкәсендә яшәүче татар укымышлыларыннан. Ул безгә һиҗринең 1293 елы белән теркәлгән китабы аша килеп җитте. Шуңа күрә аны әле исән-сау дип фаразларга була. Аның китабы сүзләр сайлауның уңышлылыгы, әйтелгән сүзенең синтактик төзелеше һәм фикер тирәнлеге ягыннан Мисыр, Димәшк яки Гыйрак галимнәренең әсәрләреннән һич кенә дә калышмый». Бу бәяләмә Ш. Мәрҗанины башка мәмләкәтләрнең фәнни даирәләрендә дә танылу тапканлыгы турында сөйли.

Ш. Мәрҗани кешенең гакылын һәр төрле рухи богаулардан коткару кирәклеген аңлап эш итте. Ул бөтен гомерен алгарыш идеаллары өчен көрәшкә, кешеләрнең дөньяны аңлавын киңәйтүгә һәм рухи нурланышына багышлады. Ул милләтәшләре аңының ачылуы һәм яңарышы турында хыялланды һәм бөтен көчен, иҗади сәләтен шушы хыялын тормышка ашыруга бирде. Шуңа күрә татар иҗтимагый фикере һәм мәдәнияты тарихында ул күренекле урын алып тора да.

---

[1] Кара: Катанов Н. Ф. Известия общества археологии и истории... т. XIX, вып. 4, Казань, 1898, 47 б.

[2] Сералин М. Мәрҗани. «Айкап», 1915, № 2.

[3] Конанбаев Абай. Лирика и поэмы, М. 1940, с. 26.

# АККОШ КҮЛЕНДӘ УТЛАР...

Шулай да Ходай тарафыннан сихерләнгән урындыр бу язучыларның Аккош күлендәге иҗат йорты. Алай булмаса, анда бер-берсенә охшаш сәер хәлләр кабатланып тормас иде. Әллә, югыйсә, язучылар үзләре тылсымлы көчкә ия булган, юктан да барны эзләүче гаувас затлармы соң? Тел төбем әйбәтрәк аңлашылсын өчен, фикер йомгагымны ерактанрак сүтә башлыйм әле.

Әдәбиятта «күчмә сюжет» дигән төшенчә бар. Теге яки бу әсәрдән икенчесенә күчеп йөри торган, кабатланучан сюжет-вакыйга охшашлыкларын, идея-мотивларның бердәйлеген, эстетик принципларның тәңгәллеген аңлата торган төшенчә ул. Көтмәгәндә, уйламаганда шушы «күчмә сюжет» дигән җилкәнле көймә минем пристаньга да сугылып үтәсе итте бит әле. Бу хәл болайрак булды.

Чордашым Мансур Вәли иҗатын, тормыш юлын кабаттан күздән кичереп, уй-хисләремне тәгаенләп, бер төенчеккә төйнәп шушы язмамны язарга җыенып йөргән көннәрнең берендә аның белән Сибгат ага Хәким арасында булган гыйбрәтле бер вакыйга кылт итеп исемә килеп төште. «Шагыйрьнең уты» дигән җылы рухлы, «якты тәрәзәле» бер мәкаләсендә ул болай дип язып үтә:

«— Быел без, яшьләргә дә, аннан урын бирделәр. Ләкин ул әле яңа гына салынган булганлыктан, тулысынча көйләнеп, тиешле бөтен нәрсә белән дә җиһазландырылып бетмәгән. Шуңа күрә ут та юк.

...Үзем дә аңышып житмәгән әнә шул халәттә утырганда, әкрен генә тышкы ишек ачылып китте һәм берәү өйгә үтте.

Аңа каршы чыккач, мин күршебез Сибгат ага Хәкимнең таныш тавышын ишеттем.

— Төн караңгы, ут кирәк булыр...— диде ул, кулындагы шәмен миңа сузып.

Шулай итеп, бу август кичендә Аккош күленең тагын бер йортында ут кабынды!»

Ни хикмәт, әйткәнемчә, шушы хәлләрдән соң шактый еллар узгач, Мансур белән безнең арада да «шәм шәрифләренә» бәйләнешле рәвештә шушыңа охшаш бер очрашу булып алды — моны «күчмә сюжет» димичә ни дисең. Бу очракта Мансур үзе Сибгат ага ролендә иде инде.

Шулай бервакыт, җәйдән көзгә авышып килгән көннәрнең берендә, Мөдәррис Әгъләмов мине, ай-ваема карамыйча, Аккош күленә кунакка кыстый башлады.

— Әйдә әле, дустым,— диде ул гадәтенчә җилкенеп, җилфердәп.— Соңгы вакытта шәп әйберләр яздым, җәелеп бер шигырь укып утырырбыз.

Шагыйрьләр арасында бер-береңә кычкырып шигырьләр уку түгел, язганнарын да караштырып бармаган бер заманда, мин сиңа әйтим, көтелмәгәнрәк тәкъдим иде бу. Хәер, Мөдәррис хәйләкәр кеше ул, минем шигырь тыңларга яратканлыгымны белә, бигрәк тә аның үзенең укуында тыңларга яратканлыгымны. Шулай да икеләнә калдым, ник дисәң, пыскаклап яңгыр сибәләп тора иде.

— Көне бигрәк шыксыз бит.

— Мичкә ягып җибәрербез.

— Автобус йөриме соң?

— Гөмбә дә тозлап куйдым, опяталар мыжлап торган чак бит.

— Шулаен шулайдыр да...

Инде болай да көндереп булмаслыгын аңлагач, Мөдәррис соңгы «снарядын» да җәлләмәде:

— Күңелле булыр, Мансур Вәли дә килә. Өчәүләп, шәплэп утырырбыз.

...Хуҗаның такта алачыгын җылытып, табын хәстәрләгәнче караңгы да төште. Тышта яңгыр сибәли, әмма бүлмәдә рәхәтлек хөкем сөрә — томаланган

мич авызындагы куызлардан, җанны изрәтеп, кызгылт шәүләләр тарала. Өй тулып, почмаклардан-почмакларга бәрелә-бәрелә шигырь агыла. Менә шулай хозурланып утырганда гына, кинәт ут сүнде. Караңгылык эчендә утырып калдык. Мөдәррис сикереп урыныннан купты:

— Хәерсез, тагын ни булды икән инде?

Шулчак күрше йорт ягыннан тавыш ишетелде:

— Әһе-һе-һәй! Мө-дәр-рис!..

Болдырга чыгып бастык. Мансур Вәли икән.

— Калдыгызмы утсыз? — Үзе шаркылдап көлә. — Үзегез — моңлы балалар, ә үзегезнең шәмегез дә юктыр әле...

Мөдәррис, сукмакка ук чыгып баскан манма-су кураларны ера-ера, тавыш килгән якка китеп югалды; күп тә үтмәде тагын, Мансурны ияртеп әйләнеп тә кайтты. Ул төнне без өчәүләп, мәгарә эчендә яшәгән мәҗүсиләр кебек утка табынып, Хәсән ага Туфан, Сибгат ага Хәкимнәрнең Аккош күлендә яшәгән чакларын искә алып, өлкән әдипләребезнең рухларын тергезеп, галиҗәнап шигырь хозурында сәҗдә кылып утырдык... Шушы бәхетле минутларда яктылык сирпеп торган шәм миңа теге чакта Сибгат ага Мансурга кертеп биргән шәмнең үзедер кебек тоелып китте; Мансур бары аның утын шушы кичкә хәтле сүндермичә генә саклап алып килгәндер: нәкъ менә «Шагыйрьнең уты» дигән мәкаләсендә язылганча, «мондый утлар, сүнмичә, буыннан-буынга күчеп килә»дер.

Бүген исә мин шушы ут яктысында Мансур әфәнденең гомер китабының сәхифәләрен укып утырам. Укыйм, укыйм да, язмышларда уртак мизгелләр табып, тукталып уйга калам.



*Рәсемдә: Мансур Вәли Әмирхан Еники белән. 1997 ел.*

Татар әдәбиятына язучылар, башлыча, авылдан килә. Ә авыллар инде алар, ни дисәң дә, бер-берсенә охшашлар, андагы тормыш-көнкүреш тә, кешеләренең «язмышлар яры» да охшаш. Күзаллыйм: әнә, Әгерҗе районының Барҗы авылында бер малай үсеп килә... «Мәктәпкә кергәнче үк хәреф танырга өйрәндем бугай. Авыл агайларының кибет почмагында көлә-көлә миннән афиша укытулары хәтердә калган, — дип яза Мансур Вәли әле беркайда да басылып чыкмаган «Үзем турында» дигән язмасында. Ул миңа аны, бәлки кирәге чыгар, дип укырга биреп торган иде. Хәзер, кирәге чыккач, бик теләп, автор рөхсәте белән, әлеге язмадан кайбер өзекләр китереп үтәм. — Билгеле, китаплар бик күп укылды инде. Барҗы авылының китапханәсе минем өчен иң кадерле, иң якын урынга әверелде. Авыл китапханәсе ул инде сирәк ачыла, шуңа күрә кышкы салкын көннәрдә аның ишек төбендә сәгатьләр буе ачылганын көтеп торасың».

«— Ә инде эшкә уза алсаң, синнән дә бәхетлерәк кеше юк бу дөньяда. — Бусы Мөслим районының Бүләк авылында туып үскән Наис дигән берәү авызыннан әйтелгән сүзләр. — Авылның китапханәчесе Мирфәез абый Галиев иде...

Китапханәдә һәрвакыт чиста, пөхтә, кояшлы иде, иҗади мохит хөкем сөрә иде. Мөдир кинәшче, өлкән сердәш, фикердәш иде. Китапның изге җан иконлегенә беренче булып ул төшендерде. Ул сиңа китапларны үзе тәкъдим итә, кире тапшырган вакытта үзенә күрә бер имтихан кебек нәрсә дә уздырып ала: китапның асыл мәгънәсен аңларга тырышып укыгансыңмы син, пычратмагансыңмы, таушалган булса, төпләгәнсеңме, ябыштыргансыңмы? — барысы да аның күз уңында. Аның болай төпченүенә китап җене кагылган малай-шалайларның кәефе кырылмый, киресенчә, үзеңә аерым игътибарны сизеп, китап тапшырасы көнне дүрт күз белән көтеп аласың. Әйе, элегрәк укый иде авыл халкы. Һәм, әлбәттә, кечкенә генә авылдан бер чорда дистәләгән егетнең югары уку йортлары ишеген керә алуында китапханәченең дә йогынтысы булмый калмагандыр.

Мансур Вәлиев яза:

«— Мәктәптә беренче укытучым Хәдичә апа Шәрифуллина булды. Аннары Әстерхан ягыннан кайткан һәм безнең авыл кешеләренең яраткан кешесенә әйләнгән Гөлсем апа укытты. Ул минем язуга әвәслекне сизеп алды һәм Казанга радиога, балалар өчен тапшыруларга хәбәрләр җибәрергә киңәш биреп (бигрәк беркатлы булган инде), «гариза язып сал, хәбәрче итеп алсыннар», диде. Гариза язуын язмадым, әмма тиздән хәбәрче булып киттем.

Өченче-дүртенче сыйныфта укыганда, Красный Бор район гәзитәсенә мәкаләләр җибәрә башладым. Алар басылып чыкты. Күңел үсеп китте. (Хәтерлим, таныш халәт, беренче шигырем район гәзитәсендә күренгәч, мин дә кош тоткан кебек очынып йөргән идем.— Н. Г.)

Безнең Баржы авылында атаклы драматург Юныс абый Әминевнең яшәве ничектер, үзем дә сизмәстән, мине шундыйрак шөгыльгә тартты, ахрысы. Башлангыч сыйныфларда укыганда бугай, дәфтәрләрне бергә теркәп китап шикеллерәк бер әйбер оештырып куйдым. Беренче хикәяләрем шунда язылган. Әле дә булса сакланалар. Колхоз радиосы аша «Мәктәп тәрәзәләре» дигән радиогазета оештырып, бик мавыгып йөргәннәр дә истә калган. Мәктәптәге күңелле хәлләр турында Әгерҗе район гәҗитенә дә күп яздым. Актив хәбәрче идем.

1966 елда X сыйныфта укыганда, минем турында Мәскәүдә чыга торган «Рабоче-крестьянский корреспондент» дигән журналда фоторәсем белән бергә язып та чыктылар.

Урта мәктәпне бетергәч, ни өчендер, тагын да уку теләге булмады. Уку туйдырган кебек булды. Мине Әгерҗе район гәзитәсе редакторы Тәүфыйк абый Рәхмәтуллин үзенә эшкә алды».

Шушы юлларга килеп төртеләм дә, эсселе-суыклы булып китә. Мин дә бит, моннан күп еллар элек, хезмәт юлымны район гәзитәсеннән башлап киткән идем. Күрде инде күрәчәк башлар... Язгы юл өзеге дип торылмаган, җәйге чиллә яки кышкы зәмһәрир суыклар да туктатып кала алмаган, ачлытуклы килеш хәбәр эзләп авылдан-авылга чабылган... Олыларча кыяфәткә кереп, бик тә әһәмиятле сүз әйткән кебек редакция бүлмәсендә төнгә кадәр мәкаләләр язылган. Акыл өйрәтүләр, кыекны турыларга ясканып йөрүләр... Без идек микән соң ул, Мансур дус?

«Әгерҗедән 70 чакрым ераклыктагы Баржы дигән туган авылыма күмер төягән трактор чанасы өстендә төн буе кайтулар бик тә хәтергә сеңеп калган. ДТ-54 тракторы кырмыска кебек кенә үрмәли: төн салкын, ара бик ерак, өстә юка... Шыкраеп катасың... Әле җитмәсә, батып та ятасың. Салкын трос сөйрәп әрле-бирле чабасың. Таң аткандарак кына авылыңа кайтып керәсең. Анда сине, борчылып, әти-әниең көтә инде, ачулана-ачулана...

Әнә шулай үз башыңа үзең кыенлык табып, хәбәрче булып йөрисең. Атаң яшендәге колхоз рәисләренә дә авыр сүзләр әйткәләргә туры килде, гаделлек өчен дип. Кешеләргә кирәк дип.

Казан гәзитәләрендә дә усал-усал мәкаләләр, фельетоннар бастырырга туры килде. Ике ел эшләгәч, әнә шулар белән Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керү җиңел булды».

Бүш сүз түгел бу. Яшь каләм иясе үзен киләчәк өчен әнә шулай чыныктыра килгән. Һәм 1968 елдан башлап, Әгерҗенең колгасар егете, студентлык кысаларына гына сыеша алмыйча, гәзитә-журнал редакцияләре бусагасын да таптый башлый. Бүгенге көндә исә без әнә шул егетне үҗәт, максатчан, хәр фикерле, компромиссларга бик авырлык белән бара торган тәнкыйтьче Мансур Вәли дип күреп беләбез. Әйе, үз гомерендә ул бик күп язучы агай-апайларның күңеленә хуш килерлек ягымлы, җылы, хакыйкый сүзләр әйтергә өлгерде, бик күпләрнең яраларын төзәтешергә ярдәм итте һәм вакыты белән, кирәк чагында, узгынчыларның канына тоз салырга да тайчанып тормады. Шулай, Мансур әфәнде

каләмдәшләренең аз гына уңышын да күреп сөенә белә, аңа ярдәм кулы сузарга ашыга. Кайчак, үзсүзле кешеләргә хас булганча, бәяләмәләрендә бер яккарак ташланган чаклары да булды, әмма күпме генә тырышма, син аны сайлап алган юлыннан, инанган фикереннән кире чигендерә алмыйсың. Һәрхәлдә, бу җинел эш түгел. Кыскасы, әдәбиятка караш мәсьәләсенә килгәндә, максималист ул, кирәк кадәр генә башбаштак та. Шушы сыйфатлары өченме, әллә төс-кыяфәтендә берәр охшашлык табыпмы, Гариф абый Ахунов аңа яратып, үзаралай-юрамалай гына «татар Белинские» дип эндәшкәли, ә Мансурның исе дә китми: «Үз илең булган булсамы, матбугат иреге булган булсамы... кем белә...» — дип куя, колакка рәхәт сүзләрдән хуш килеп. Сүз дә юк, мөмкинлекләр, колачлар бөтенләй башка, чагыштырып карарга да куркыныч, әмма аның җанында «тәнкыйтьче» дигән гайяр ат ятуы бәхәссез: фикер сөреше белән ул «бәйләнчек»; ул әдәби хәрәкәтнең үзәгендә булырга тырыша, яшьрәк чагында аның бу сыйфаты аерата күзгә ташлана иде. Хәер, тәнкыйтьче өчен моннан башка мөмкин дә түгелдер, күрәсең,— үзеңне тәнкыйтьче итеп хис итсәң мөмкин түгелдер. Мансур әфәнде, моның шулай икәнлеген яхшы аңлап, җаваплы миссиягә үзен яшьтән үк хәзерләп килә; бу хакта ул болай дип искә ала:

— «Бәләкәй вакытта үзебезнең оч бала-чагасын җыеп, концерт сыман нәрсәләр дә оештыра торган идем.

Казанда, университетта укыганда да татар журналистларының түгәрәге «Яңавәз» оештырып йөрергә туры килде. Аның стена гәзитәсен чыгардык. Укучыларга буйсынып та бетми идек, чөнки алар куркалар — ә без әтәч кебек инде, калай әтәчләр! Ләкин ул бик романтик, ямьле, истәлекле чор булды. Атаклы язучыларны очрашуга чакыра идек, кыю-кыю мәсьәләләр күтәрә идек.

Шул кыюлык белән 1971 ел ахырларында атаклы язучы Фатих ага Хөснигә бер ачык хат та язып ташладым. Һәм ни гаҗәп, өлкә комитеты гәзитәсе «Социалистик Татарстан» аны бастырып та чыгарды. Студент малай зур күсәк күтәрә — «сез тормышны бизәп, буяп язасыз!» димәк була... Ул чагында татар язучылары Мансур Вәлиев дигән кеше барлыгына ышанмыйча, бу берәрсенең ялган исемедер, псевдонимыдыр дип уйлаганнар икән. Соңыннан миңа моны сөйләп күрсәттеләр, минем фамилияне хәрефләп тарката-тарката чынлыкта кем язганын белергә теләгәннәр. Үземә күрсәттеләр анысын».

Язучы-тәнкыйтьче булырга теләгән яшь кеше әнә шулай бераз гына әрсезрәк тә, кыю-актив та, амбицияле дә булырга тиеш. Әдәбиятта үз кишәрлегеңне даулау өчен бу аеруча зарур. Әйтергә кирәк, Мансур әфәнде әлеге язылмаган законны бик яхшы үзләштереп юлга чыкты, бәлки шуңа күрәдер беренче адымнарыннан ук гавам күзенә ташланды:

— «Аннары тагын бер китапка рецензия язган идем, анысы озынрак килеп чыкты да, «Казан утлары» журналына кертеп кара, диделәр.

Таптым ул редакцияне, беркемне дә күреп белми идем, әлбәттә. Язмамны калдырып чыктым. Байтак гомер үтте, барырга куркып йөрим. Ә бер кичне тулай торак коридорында егетләр сөйләшеп тора: алар арасында редакцияләргә еш барып йөри торган Марат Сәгъди дигән егет тә бар иде, аңа мин язганнарны журналда эшләүче Фәрваз абый Миңнуллин бик мактап сөйләгән, имеш. Шулай итеп, мин «Казан утлары» белән танышып киттем. Фәрваз абый Миңнуллин исә (ул миңа иҗади үсешемдә бик зур ярдәм күрсәтте, урыны җәннәттә булсын), гомере буе минем остазым, бик якын дустым, ярдәмчем булды. Соңгы курста укыганда, мин ул редакциядә бер ел чамасы эшләп тә алдым әле.

1973 елда мине бер айга язучыларның Мәскәү янындагы иҗат йортына җибәрделәр. Гариф абый Ахунов тырышлыгы белән. Мин шунда исемнәре бөтен илгә билгеле булган, атаклы язучылар арасында берүзем бер бүлмәдә яшәп, бушлай ашап дигәндәй (әле студент чак бит), бәхетле көннәр кичердем; чын иҗат ләззәтен татып, әдәбият мохитын күреп-тоеп кайттым. Валентин Катаев, Евгений Евтушенко, Мостай Кәрим, Андрей Вознесенский, Мирза Торсын-задә, Сильва Капитукян, Фазу Алиева, Мариэтта Шагинян кебек шагыйрь-язучылар белән очрашу күңелдә тирән эз калдырды».

Ничек кенә булмасын, менә шушы хәлләрдән соң Мансур күзгә күренеп житдиләнеп, олыгаеп китте; шушы чордан башлап ул «әдәбият ахшамы»нда тәнкыйтьче буларак катнашу өчен тавышын көйләп, җиңен сызганып куйды.

— «1975 елда, Ерак Көнчыгышның Спасск-Дальний шәһәрендә ике ел армиядә хезмәт итеп кайткач, Язучылар союзына әдәби консультант итеп эшкә алдылар. Бер елдан «Идел» альманахына мөхәррир итеп күчерделәр».

Һәм шушы чордан «Идел» альманахына журнал статусын яулау өчен, нәкъ менә яулау өчен эпопеяга тиң (алырсың тартып эт авызыннан сөяк!) көрәш

башланды. Бүгенге көндә, чат саен шикле басмалар дөнья күргән бер мәлдә, бу сүз, бәлкем, кайберәүләр өчен, бигрәк тә «тегеелар»ны күреп үсмәгән яшьрәк буын язучылар өчен купшы бер аклану, арттыру булып та ишетелер, ләкин империя тарафыннан халыкларның тимер кыршау белән уратып алынган (черек булса да!) агач мичкәдә сөрсеп ятарга мәхкүм ителүен истән чыгармасак иде (сабак алу өчен!). Шөкер, кыршау өзелде... «Идел»ебез дә иркен сулыш белән, ярларга тулып ага. Димәк, көрәш бушка китмәгән. Ә ул чакта...

— «Без, яшьләрне оештырып, татарча яшьләр журналы ачу өчен көрәш башладык,— дип искә ала Мансур Вәли.— Мәскәү рөхсәтеннән башка моңа ирешү мөмкин түгел иде, шунлыктан КПССның Үзәк Комитетына хәтле барып җиттек. Үземне КПСС Үзәк Комитетының матбугат бүлеге мөдире кабул итте. Хәтта Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Ә. Табеев белән Россия Язучылар берлегенең җитәкчесе, кайда да үз сүзе үтә торган С. В. Михалков илнең төп идеологы М. А. Суслов янында булып, шушы мәсьәләне күтәреп карадылар, әмма аларның да аргументлары яклау тапмады: Мәскәү өчен бәләкәй генә милли журнал чыгарырга рөхсәт бирү «стратегик әһәмият»кә ия иде. Ләкин «эт өрә тора, бүре йөри тора» дигәндәй, «Идел» альманахы хәл кадәренчә үз миссиясен әйбәт кенә үтәп килде. Ул үзенә күрә хөр фикерле яшьләр үзәгенә әверелде: аның битләрендә табадан гына төшкән әсәрләр урын алды, «Дискуссион клуб»та яшь әтәчләр чәкәләште. Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев белән булган очрашуларга урта буын язучылар да «рөхсәт сорап, кача-поса» арткы рәтләргә кереп утыралар иде. Күрәсең, аларга безнең фикерләү рәвеше кызык тоелгандыр һәм үзләренчә безне сынап, җиз иләктән үткәреп тә йөргәннәрдер — әдәбиятка кемнәр килә, янәсе».

Бу тормышта күп нәрсә кабатлана. Хәзер Мансур Вәли инде үзе урта буын вәкиле. Ә аның иҗат кредосы нәкъ менә «Идел»дә эшләгән чорда тәгаенләнде. Күптән түгел миңа аның шәхси китапханәсендәге китаплары белән танышырга туры килде. Шунда «Яшьләр мәйданга чыга» дигән беренче китабындагы «Яшьләр» исемле мәкаләгә күзем төште: анда «картая барган саен кешене рәхәтлекләр берәм-берәм ташлап китә икән. Ләкин хакыйкать өчен көрәш һәм хезмәт ләззәте — кешенең иң ышанычлы юлдашы, алар кешене мавыктырып, юатып яшәтә. Яшьлектә менә шуны аңламыйй икән кеше, кулында шул ике нәрсә калачагын, әгәр инде аларны да югалтса, гомумән, япа-ялгыз каласын уйламый икән... Менә нәрсә икән ул яшәү серләренең берсе!» дигән сүзләрнең астына сызылып куелган иде. Димәк, Атилла Расихның «Каһарманнар юлы» романындагы Хәбибрахман карт авызыннан әйтелгән әлеге сүзләр аның өчен гади бер персонаж сөйләме булудан битәр, авторның дөньяга карашын, уй-хисләренең асылын билгеләүче концепция дә икән. Бүген шулай дип әйтергә тулы нигез бар: чөнки Мансур Вәли, ярты гасырлык иҗат гомерендә әдәби әсәрләргә әнә шундый идеаллардан чыгып бәя бирде; ул эстетик категорияләр белән артык «вакланып» тормады, күбрәк социаль-иҗтимагый проблемаларны үзәккә алып эш итте. Әлбәттә, «фәрештә»нең дә ике канаты булган кебек, мондый алымның да уңай һәм тискәре яклары булгандыр, әмма ул иҗатында әдәби мохиттә барган процессларга битараф булмады, әдәби процессның тирбәнешләрен йөрәге аша уздырып — сөенеп һәм көенеп яшәде.

— Кем ул тәнкыйтьче? — Мансур Вәли гомере буе шушы сорауга җавап эзләде. Бу хакта ул болай уйлана:

— «Тәнкыйтьче дә, кайберәүләр уйлаганча, бик алай куркыныч кеше түгел — гел кусәк күтәреп кенә тормый. Ул кайнар йөрәкле һәм тәҗрибәле, югары зәвыклы укучы. Билгеле инде: дөнья булгач ул укучыга ошамаган, ачуын китергән әсәрләр дә очрый. Менә шул чагында инде әлеге югары зәвыклы, намуслы укучының йөрәге дәшми кала алмый. Ул борчылып, әрнеп, бу хәлнең сәбәпләрен аңларга һәм ачарга теләп яза. Аның болай чыгыш ясавы һич тә «күсәк күтәрү» булмый, ә бәлки әдәби иҗат эшендәге түбән сыйфатка, «бракка» каршы төшү була. Бу Мансур Вәлинең үзе инде.

**Наис ГАМБӘР.**

# «ТЕАТРДА ГОМЕР ҮТКӘНЕ СИЗЕЛМИ...»



Хөрмәтле Артист галиҗанәпләре!

Сәхнәдә йөзләрчә гомер яшисең. Һәр язмышны йөрәгеңнән үткәрәсең. Җаннарыбызга — җылы, күңелләребезгә — нур, йөрәгебезгә мең төрле хиссият бүләк итеп, безне биеккә — камиллеккә өндисең. Тамашачыны көлдереп, елатып, җырлатып, уйлатып дөньяны яхшыга үзгәртергә тырышасың. Гамең, гамәлең изгедә синең.

Тәкъдир ителерлек авыр хезмәтеңнең кадерен, бәясен беләбезме соң? Мәгънәсенә төшенә алабызмы? Уй-хыялларыңны аңлар дәрәҗәдәме без?

Бүген Артист галиҗанәпләре ролендә —
Татарстанның һәм Россиянең халык артисты,
Татарстанның Театр әһелләре берлеге рәисе,
Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының мәшһүр иҗатчысы **РИНАТ ТАҖЕТДИН**.

Аның белән әңгәмәбез сәнгать белән заманның хикмәтле бәйләнеше турында.

*— Ринат әфәнде, хәзер кино, видео, телевидение заманы. Бу нисбәттән милли театрның киләчәгенә куркыныч яный диган фикернең нигезе бармы?*

— Татар — гаҗәеп халык, ул сәхнә тамашасы ярата. Мәсәлән, хәзер нинди генә җырчылар юк, ә халык һәммәсен кабул итә, концертларга йөри. Ә инде безнең халкыбыз шикелле яратып, үз итеп театрга йөрүче халык гомумән юк диярлек. Мин моны чын күңелемнән әйтәм. Качалов исемендәге рус драма театры артистлары белән сөйләшкәнем бар. «Сез гастрольгә рус авылларына йөрисезме?» — дим. «Юк, татар авылларына,— ди алар,— чөнки анда кеше күбрәк килә, аңласа-аңламаса ак яулыклы әбиләр дә килеп утыра хәтта». Тамаша карау кызык, димәк.

*— Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?*

— Моның сәбәбе — тарихыбызда. Татар театры гасыр башында ук оешкан. Аны Ходай Тәгалә үзе артист итеп яраткан фидакарь шәхесләр тудырган. Бу гаҗәеп күренеш. Беренче труппалар татар яшәгән бөтен җирләргә йөреп, татарны театрга өйрәткән, зәвык тәрбияләгән. Әлеге тәрбия, буын-буыннан күчеп безнең бүгенге тамашачының да күңеленә сеңгән. Шунысы кызганыч, менә без хәзер алар йөргән кадәр йөри алмыйбыз. Бу, минемчә, зур җинаять. Милләтебезнең телен саклаучы, аңа акыл иләрен бирүче саф татар авылларына театр сәнгатен җиткерә алмыйбыз. Ә театрга ихтыяҗ зур. Миңа калса, татар халкы яшәгәндә һәм тәрәккыятькә омтылганда аның театрына куркыныч янамый. Чөнки ул гасырлар буена формалашкан милли үзенчәлегебез, гореф-гадәтебезгә әверелгән. Мин милли геройларыбызга әйләнгән беренче артистларыбыз — Хәлил Әбҗәлилов, Гөлсем Камская, Хөсәен Уразиков, Камал III, Хәким Сәлимҗановларны шәхсән күреп калуым белән бәхетле. Бер-берсенә һич охшамаган искиткеч талант иияләре иде алар. Алардан соң начар театр булуы мөмкин түгел. Г. Камал исемендәге театр аларга бурычлы. Шуңа күрә дә без беренче театр истәлеген сакларга, аның рухын яшьләребезгә дә күчерергә тырышабыз. Бик матур гадәтебез бар: һәр сезон ачылганда һәм ябылганда без аларның каберен зыярәт кылабыз.

*— Сез театрга килгәндә алар уйный идеме әле?*

— Әйе, безне 1956 елда Мәскәүгә, М. С. Щепкин исемендәге театр училищесына Хәлил ага Әбҗәлилов үзе озатып җибәрде. Училищены тәмамлап кайтуыбыз да кызыклы чорга туры килде. Ул вакытта театрга никтер кеше аз йөри иде. Шундый чор булган күрәсең, яшь артистлар юк. Ә тамашачының барыбер яшь рольдә яшь кешене күрәсе килә. Бу — табигый. Әлеге күренекле, тәҗрибәле артистлар безне яратып каршы алды. Гүя театрга яңа сулыш өрелде. 1961 елдан башлап халыкның театрга йөрүендә тагын бер күтәрелеш булды, дисәм дә ялгыш түгелдер. Шуннан бирле театрдан кеше өзелгәне юк.

*— Шушы чор эчендә, Сезнең күз алдыгызда ничә буын артист алышынды икән?*

— Төгәл генә әйтүе дә кыен, дүрт-биш буындыр. Иң мөһиме — һәр буын үз яңалыгы белән килде, театр сәнгатен үзенчә баетты. Хәзер инде Мәскәүләргә җибәреп укытып булмый, хәер аның кирәге дә юк дип саныйм. Чөнки хәзер үзебездә тәҗрибәле остазлар, искиткеч режиссерлар өлгереп җитте. Сәнгать Академиясе ачылды, анда режиссерлар һәм актерлар әзерли торган махсус бүлекләр бар. Аны тәмамлаган беренче чыгарылыш студентлары, мәсәлән, Мәскәүдә укыганнардан ким-хур түгел. Милли сәнгать ягыннан әле күбрәк тә белем алалар. Дөньякүләм танылган осталарның иҗатлары белән танышу мөмкинлекләре дә зур.

*— Соңгы вакытта театр сәнгате дөньякүләм кризис кичерә дигән фикер киң таралды. Мәскәү театрлары чаң суга, дөнья яңалык көтә...*

— Шулайдыр да. Әмма безнең милли театр кризис хәлендә дип әйтә алмыйм. Тамашачы йөри — бу иң мөһим күрсәткеч. Әлбәттә тормышның матди ягы начарлану, кешеләрнең тамашага акчасы булмау да үзен сиздерәдер. Яңа спектакль кую да зур чыгымнар таләп итә. Әлеге шартларда исә театр җитәкчелегенең нинди булуы мөһим. Безнең театр директоры Шамил Закиров театрны, артистларны ярата торган җитәкче, иҗат мөмкинлекләре тудыру өчен бар көчен куя. Кызык бит: кайбер җитәкчеләр, гайре табигый тоелса да, артист яратмый. Бу яктан без бәхетле. Баш режиссерыбыз Марсель Сәлимҗановка режиссер таланты өстенә, оештыру сәләте дә бирелгән. Ул театрны бер гаилә итеп туплауга ирешә. Ә гаилә инде ул очраклы төркем түгел, аның кануннары үзгә. Гаиләдә бер бала да чит түгел.

*— Театр әһелләре берлеге рәисе буларак, башка театрлар эшчәнлеген ничек бәялисез?*

— Казанның үзендә алты драма театры бар. Дәүләт театры булмаган яшь коллективлар туа тора. Республика буенча җәмгысы 16 га җыела. Күп кенә чит республикаларда театрлар саны кимүгә барганда, әлеге күренеш халкыбызның үз гореф-гадәтләренә тугрылыгын гына түгел, милли узаң ныгый баруны да дәлилли. Әлбәттә, камиллек, осталык ягыннан бу театрлар төрле дәрәҗәдә, әмма аларның яшәп килүе сөенечле хәл. Түбән Камада өч театр эшли. Чаллы театры уңышларга ирешеп килә. Минзәлә театрын саклап калуга ирештек. Әлеге дә баягы, шул артист ярата торган җитәкче табылды. Әлмәт театры да күтәрелеш чорында.

*— Димәк, милләтебез талантка бай...*

— Бусы шулай. Әмма алар үсешенә матди кыенлыклар киртә булып тора. Театрлар үтенеч белән, әлбәттә, Театр әһелләре берлегенә мөрәҗәгать итәләр. Ә ярдәм итү җиңел түгел. Хәзер хөкүмәт тарафыннан планлы ярдәмгә исәп тота алмыйсың. Үзебезгә эзләргә, табарга туры килә. Артистларның пенсиясен телгә алырга да оят. Халык артистлары Шәүкәт Биктимеров, Марсель Сәлимҗанов 320 мең сум пенсия ала. Көлке! Адәм хуры. Иң борчыганы шушы. Гомерен халыкка багышлаган артист үз хезмәтенә тиң нәтиҗәсен күрми. Кайберләре авырый, картлык көнендә караучысыз, мескен хәлдә кала. Шундыйларга булдыра алганча ярдәм итәргә тырышабыз. Ярый әле Президент фонды бар, квартал саен унбишләп ветеранга әйбәт кенә матди ярдәм биреп киләбез. Шунысын да әйтәсем килә: Президентыбыз артистларның Идел буендагы ял базасын төзекләндерүгә дә ярдәм итә. Дөресен әйтик, хәзер артист ял итәргә Кырымга яки чит илләргә бару мөмкинлегеннән мәхрүм. Шуңа күрә, 40 ел элек төзелгән булса да, үзебезнең ял йортларын төзекләндерүне кулайрак дип таптык. Бу мәсьәлә буенча безне Президентыбыз үзе кабул итте, гозеребезне тыңлады.

*— Сезнең исемегез ук күп ишекләрне ача аладыр?*

— Мин театр әһелләре берлегендә хезмәт хакына эшләмим. Җәмгать эшлеклесе буларак җитәкчелек итәм. Анда гел утырып та торалмыйм, чөнки күп вакыт театрда уза.

Мине күбрәк кая да булса барырга, ни дә булса табарга чакыралар. Мин барсам, житәкчеләр таный, хөрмәт белән кабул итә. Мин моннан һич тайчанмыйм — үземә сорарга түгел, ләбаса. Шунсыз булмый. Аннан соң, Президентыбызның театрга еш йөрүе дә кулай, турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Минтимер Шәрипович бер генә яңа спектакльне дә калдырмый. Әгәр дә инде республика житәкчесе, ил башы театрга йөри икән, димәк театрга да караш башка. Аңардан калышасылары килмичә, башка житәкчеләр дә килә дигән сүз. Әдәбият, сәнгатьне белгән житәкчеләр белән киләчәк тә өметлерәк тоела башлый бит ул.

*— Мәгълүм булганча, Татарстан Театр әһелләре берлеге Россия берлегенә карый. Алар белән араны өзеп, мөстәкыйль берлек төзергә исәбегез юкмы?*

— Без хәзер дә мөстәкыйль берлек, әмма иждди яктан алар белән араны өзмибез. Сәнгать ялгыз калырга тиеш түгел. Иҗат кешесенә аралашу кирәк, мәгълүмат кирәк. Халык әйтмешли, үзеңне күрсәтергә, кешене карарга, гыйбрәт алырга. Минем хәтердә әле. Молдавия театры заманында гомумберлектән китте һәм театр үз казанында гына кайныйкайный, акрынлап сүнде. Соңыннан үкенеп йөрделәр, хәзер инде аралаша башладылар, яңадан туып киләләр. Гомумберлек булуның бар кыйммәте шунда: җыеласың, фикер алышасың, фестивальләрдә катнашасың, бераз ял күрәсең. Сөйләшеп кенә утыру да әллә никадәр иҗат идеяләре туугa сәбәпче булырга мөмкин.

*— Хәзер үткәреләме соң ул фестивальләр?*

— Үткәрелә. Әле күптән түгел Казан курчак театры Ярославльдә булып шактый уңышлы күренеп кайтты. Уфада бөтен мөселман театрларының «Туганлык» дигән җыенында катнаштык. Урта Азиядә, Үзбәкстанда үткәрелүче «Нәүрүз» фестиваленә безне махсус чакырдылар. Үзбәк, казакъ театрларын тудыруга безнең әнә шул сәяхәт кылып йөргән беренче артистларыбыз ярдәм иткән дә инде. Аларның элеккеге сүзсез киноларын күргәнем бар, анда төп рольләрдә Хәлил ага Әбҗәлилов төшкән. Безне Урта Азия белән дә әнә шундый тарихи җепләр бәйли. «Нәүрүз» — халыкара фестиваль иде, анда Төркия, Греция, Япония һәм башка илләрдән мәшһүр театрлар катнашты. Эстониядә узган зур халыкара фестивальдә режиссерларыбыз күп кызыклы нәрсәләр күреп кайттылар. Ә инде Островский, Чехов, Шекспир кебек драматургларга багышланган Мәскәү җыеннарында, күрсәтерлек спектакль булса, без даими катнашабыз.

*— Әйткәнебезчә, безнең замана матди кыенлыклар белән билгеләнә. Инде рухи якны карасак, яңа идеяләр, яңа спектакльләр җитәрлекме?*

— Театр драматурглар иҗатына бәйләнгән. Ә алар хәзер бик авыр хәлдә дип саныйм. Нәрсә язарга белмиләр дию дөресрәк булыр, мөгаен. Бүгенге әсәрләрдә еш кына тормышның кара якларына игътибар ителә, яисә үткән заманны тәнкыйтьләүгә кайтып кала. Ә халык болардан туйган. Авыр тормыштан ул болай да гарык. Аңа тамаша, комедия кирәк. Миңа калса, безнең театр күбрәк тамашага корылган спектакльләр куеп дөрес эшли. Әлбәттә, моның белән халыкны җиңел юлга кертәбез дә шикелле. Бу якка ныграк авыштык, монысы белән дә килешәм. Әмма хәзерге заманда бу үз-үзен аклый дип саныйм. Өлкән артистларыбыз кызыклы факт турында сөйләделәр: Ватан сугышы вакытында театрда гел комедияләр генә уйналган. Ут та юк, керосин лампасы яктысында халык көлешеп, бераз онытылып торган. Хәзер дә кешенең күңелен күтәрергә кирәк дип уйлыйм.

*— Бүгенге драматурглар өчен төп кыенлык нидә соң?*

— Алар замана герое эзли һәм һич таба алмый. Чыннан да, кем герой бүген? Совет заманында ул ачык иде: коммунизм төзүче, тормышка яңалык кертүче, ватанпәрвәр... Бүген халык егылып китеп чит ил сериаллары карый. Ә анда бары тик кеше язмышлары: мәхәббәт, кавышулар, аерылышулар, нәфрәт, дуслык, туганлык. Сәясәт тә, җәмгыять тә юк. Шекспир әсәрләре дә нәкъ шуңа күрә мәңгелек, ләбаса. Мәңгелек кыйммәтләр нигезендә сюжет корыла: һәммәсенә якын, һәммәсенә аңлашыла. Бәлки хәзер шундый темаларга игътибар кирәгрәктер...

*— Чит ил, Мәскәү театрлары бу юнәлештә әллә нинди авангард алымнар уйлап табалар, шедевр тудыра алмасалар да, иҗади эзләнү бара. Бу яктан татар театры сүлпәнрәк димме...*

— Бездә алардагы шикелле була алмый. Бездә милли тыйнаклык яши. Ни генә уйлап тапсак та, тамашачы барыбер үз табигатенә килешерлек әсәр карый. Безнең халык мелодрама ярата. Минемчә, мелодрамалар иҗат итүдән куркасы юк. Гомумән әйткәндә, әлбәттә,

соңгы елларда «Эх, уйнасы иде!» диярлек әсәрләр, кызганычка каршы, юк. Моны танырга кирәк. Әмма тормыш алга бара, театр тик тормый. Мәсәлән, башкорт драматургы Флорид Бүләковның «Мәхәббәт хатирәсе» әсәре буенча куелган спектакльне мин онытылмаслык дип саныйм. Бер немец режиссеры Ибсенны куярга әзерләнә. Театр шаулап тора. Марсель Хәкимович әйтмешли, театрга килеп кергәч, моннан — җыр, тегеннән — бию, сәхнәдән репетиция тавышы ишетелеп торса — күңелле. Димәк, театр яши. Килеп кергә тып-тын булса, куркыныч булыр иде.

*— Ринат абый, артист халкы шундыйдыр инде ул: акчасы булса да, булмаса да шаулый, нидер уйлап чыгара...*

— Акча артыннан куучылар театрда озак тормый алар. Чын артистның театрга мәхәббәте риясыз. Хәтта безнең сәхнә эшчеләре дә акчалы башка эшкә күчеп озак тормыйлар, сагынып кире әйләнеп кайталар.

*— Хәзер яшьләр күбрәк эшкуарлыкка, акча эшләргә омтыла. Сез ничек уйлыйсыз: артист һөнәре абруен югалтмыймы?*

— Хәзергә мин моны сизмим. Сәнгать Академиясендә чыгарылыш имтиханнары кабул итәм. Яшьләр күп килә. Бигрәк тә режиссерлыкка. Элек сәхнә герое, билгеле шәхес булырга теләк көчлерәк булып, актер бүлегенә гаризалар күбрәк бирелә иде. Бу хәл сөендерә, димәк театр сәнгатенең асылына төшенергә, тирәннән белергә теләк зур. Ләкин борчыган күренешләр дә очрый. Мәсәлән, авыллардан, чит өлкәләрдән килгән яшьләрнең кайвакыт сәнгать турында мәгълүматы сай. Көләргә дә, еларга да белмисең. Сорыйсың: «Кем ул Габдулла Кариев?» Кыяфәтеннән инде күренеп тора: әлеге исемне беренче тапкыр ишетүе. Хәзерге заман драматургларыннан, шагыйрьләрдән бер генә исем дә әйтә алмый, үзе артист булырга хыяллана. Мәктәптә боларга игътибар ителми микән? Без укыганда, мәсәлән, мөмкинлекләр чикле иде. Муса Җәлил, Кәрим Тинчурин кебекләр телгә дә алынмый, китапта да юк. Хәзер бит җаның ни тели шуны карау, уку мөмкинлекләре бар. Җыеп әйткәндә, мин яшь буын өчен борчылмыйм. Эшкуарлыкның бүген криминаль икәнлеген аңлаучылар да аз түгел. Яшь буын артистларыбызны да яратам. Алар иртән килә театрга, кичкә кадәр шунда кайнаша. Хәер, без дә шундый идек. Бер айга утыз ике спектакль куйган чаклар да булды.

*— Чагыштырып карыйк әле, театрга яңа гына аяк баскан яшь актерга бүген кыенмы, әллә Сезнең заманда кыенрак идеме?*

— Безгә авыр булды дип әйтә алмыйм. Без — көтеп алынганнар, шуңа күрә үзебезгә карата һәрдаим җылылык сизеп тордык. Хәзер дә элеккедән зур аерма күрмим. Хикмәт заманда түгел, яшь артистның театрга шәхси мөнәсәбәтендә. Мөнәсәбәте начар булган артист, ничек кенә талантлы булмасын — театрдан китә. Андый очраклар булды бездә. Кайберәүләре үзен театрдан өстен күреп, «йолдыз чире»нә бирелште. Кайбер кеше мактауны күтәрә алмый, башка юлга кереп китә.

*— Ринат абый, Сезгә «йолдыз чире» бер дә кагылмадымы?*

— Бөтен рольләр дә шедевр дәрәҗәсендә булмый. Моны яшереп-нитеп торасы юк. Хәтта бер үк роль дә көн саен шәп килеп чыкмый. Моны аңларга һәм кабул итәргә акылы житкән артистка «йолдыз чире» янамый. Хәтта бик популяр чакларда да бу нәрсә башыма кермәде. Хәзер инде бигрәк тә.

*— Ә хәзер Сез үзегезне бик популяр түгел дип саныйсызмы?*

— Юк, популяр, әлбәттә. Һәрхәлдә, урамда исәнләшеп үтәләр. Шуннан да беләм. Араларында яшьләр булуына сөенәм. Димәк, йөриләр театрга, карыйлар. Тормыш бертөсле генә бармый бит ул. Менә моннан берничә ел элек миңа туры килә торган, күңелемне җылыта торган рольләр очрамады. Әллә шундый әсәрләр куелды, әллә күбрәк яшьләр уйнады... Тәки биш еллап элеккеге рольләр белән генә яшәп килдем. Хәзер, Аллага шөкер, яңа әсәрләр куелды. Минем табигатемә ярый торган яңа рольләр килеп чыкты.

*— Шул исәптән, Туфан Миңнуллин әсәрендәге шук һәм сабыйларча ихлас күңелле баш мишәр — Аләүетдин роле. Дөресен әйтим, бу спектакльдә мин үзем өчен әр-яңа Ринат Таҗетдиновны ачтым. Шәхсән Сезнең Аләүетдин белән күзгә бик үк ташланып тормый торган рухи охшашлыгыгыз бар сыман тоелды.*

— Аләүетдин — хыялый кеше, кызыклы шәхес. Авыл буйлап гармун тартып, җырлап йөрисе килә аның. Китәм, Япониягә китәм, ди. Авыл кешеләренең тирә-юньдәге матурлыкны, бер-берсен күрмичә телевизорга багып, сериаллар карап утыруына, тормышта җырмоң, күңел җылысы югала баруына борчыла. Бәлки безнең охшашлык та шундадыр.

*— Героегызның сөйләме, холык-фигыле таныштыр, Ринат абый. Сез бит үзегез дә — Чүпрәле мишәре.*

— Таныш әлбәттә. Сөйләм генә бераз үзгәрәк. Чөнки әсәр Сергач мишәрләрен өйрәнеп язылган. Без дә анда барып, аларны тыңлап, күзәтеп кайттык. Әйе, мишәр бит ул үзен чын татарга саный. Шамкай әйтмешли, мишәр — татарның каймагы.

*— Мишәрләрдә бердәмлек һәм туганлык хисе көчле диләр...*

— Минемчә, мишәрләрнең туганлык җепләрен, милли гадәтләребезне кадерләп саклавы бездә диннең көчле булуыннан килә. Мин Чынлы дигән зур авылда үстем. Урамның аргы башында мулла абзый күренсә, бирге башыннан аңа итәгать белән сәлам бирә идек. Бу гадәт совет заманнарында да үзгәрмәгән. Мин белгән вакытта әле Чынлыда җиде мәчет эшли иде, димәк җиде мәхәллә — күпме кеше мәчеткә йөргән. Безнең гаилә дә ишле иде. Әти белән әни биш малай, бер кыз үстерде. Бер абыебыз яшьли вафат булды. Хәзер бишебез дә Казанда яшибез.

*— Нәкъ спектакльдәгечә: «Укыган мишәр Казанда кала».*

— Әйе, барыбыз да югары белемле, төрле өлкәләрдә эшлибез. Өлкән абыебыз укытучы, абый-энеләремнең берсе — Татарстанның баш терапевты, берсе — училище директоры, берсе — химик. Арабызда бүтән артистлар юк. Хәер, мин дә яшь вакытта артист булырга хыялланмаган идем.

*— Ә ничек килеп чыкты соң болай?*

— Җырлыйсым бик килә иде, тавышым да әйбәт иде (бәлки үземә генә шулай тоелгандыр?). Егетләр армиягә киткәндә, мин — кечкенә малайны, яннарына утыртып, солист итеп җырлаталар. Гармун уйнарга да гел чакырып торалар. Өстәлгә бастырып шигырь дә сөйләтәләр. Сәхнәгә омтылыш шуннан сеңеп калган, күрәсең. Унынчы классны тәмамлагач, туп-туры консерваториягә киттем, җүләр. Шунда авылда ник берәү әйтсен: консерваториягә шунда ук алмыйлар, аның өчен нота, сольфеджио белергә кирәк, дип. Консерваториядә ныклап аңлаттылар: «Юк энекәш, элек музыка училищесына кер»,— диделәр. Шуннан училищега әзерләнеп килдем, берочтан театр училищесына да имтиханнар тапшырдым. Икесенә дә үттем бит. Ул елны Мәскәүгә, Щепкин училищесына студентлар җыялар иде, бәхетемә каршы. Актерлыкны сайладым.

*— Диалект белән кыенлыклар булмадымы соң?*

— Ничек кенә әле! Ул минем өчен зур киртә булды. Имтихан биргәндә Муса Җәлилнең «Җырларым» шигырен укыдым. «Ил кырында цәцәк атыгыз» диюгә кабул итү комиссиясе шаккатты. Искиткеч чибәр ханым Рәшидә апа Җиһаншина зәңгәр күзләрен текәп: «Белмим, энем, бу телеңне рәтли алырсыңмы икән?» — дип җәлләп тә куйды. Үҗәтлек көчле булгандыр: «Өйрәнәм, апа, өйрәнәм!» — дим. Шулай киттек Мәскәүгә. Бергә укыган Туфан Миңнуллин, Батулла мин авыз ачып бер сүз әйтүгә тәгәрәшеп көләләр. Гарьләнәм инде! Үзләре шундый матур сөйләшәләр. Аларны тыңлап ятам. Кеше юк вакытта кычкырып-кычкырып китап укыйм. Мәскәү урамнарында кычкырып татарча укып йөрүләремне хәзер дә елмаеп искә алам. Тәки ярдәм итте шул, өченче курска мишәр икәнем инде сизелми иде.

*— Авылга кайткач аңлыйлар идеме соң?*

— Шунысы кызык: авылга кайткач үзеннән-үзе мишәрчәгә күчелә иде шул. Әнине күрәсең дә, гүя күңелдә нидер кинәт борылып куя. Туфан әйтә: «Кайтма авылга, телең бозылып килә»,— ди. Туфан үзе үк мишәрләр турында пьеса язар да, мине мишәрчә сөйләшергә мәҗбүр итәр дип кем уйлаган ул чакта?

*— Сез театрда үз гомерегездә ничә роль уйнадыгыз икән? Санап караганыгыз юкмы?*

— Карале, чынлап та санаган юк икән, ләбаса. Санарга кирәк әле, кызык өчен. Һәрхәлдә, йөздән дә ким түгелдер. Аның барысын да искә алып чыгу гына да бик озакка сузылыр иде, мөгаен. Иҗатымда яңа борылышларга этәргән берничә мөһим рольне әйтеп китсәм генә инде.



Яшьрәк вакытта уйналган Муса Җәлил роле, әлбәттә. Туфанның «Моңлы бер җыр» әсәре. Хәтта Җәлилне шәхсән белгән язучылар да сәхнәдә мин тудырган образны гына түгел, тәс-кыяфәтемне дә Җәлилгә нык охшаталар иде. Гомумән, мин бу дөньяда ике кешегә охшаган булып чыктым. Берсе — Җәлил булса, икенчесе Әфганстан короле — Аманулла. Бер Ленинград режиссеры үзенең «Миссия в Кабуле» дигән фильмына, Аманулла роленә чакырды. Баксаң, без бер тамчы су сыман охшаш икән. 1970 ел иде. Киттек Әфганстанга, кино төшерергә. Әфганга азатлык яулап биргән Аманулла хан бу илдә безнең Ленин кебегрәк популяр, кадер-хөрмәт иясе икән. Миңа әфганнар әйтә: «Сезнең Ленинныгызны әфган барып уйнамый бит, нишләп безнең Амануллланы урыс уйнарга тиеш?» (Алар татар дигәнне белми). Режиссер каушап калган. Шулай да, әйтә: «Әйдә грим салып карыйк. Мин аларның хөкүмәт башлыкларын чакырдым, килеп күрсеннәр»,— ди. Грим салдылар, киендерделәр.

Килеп чыктым берзаман, басып торып булмый бит инде. Чыга-чыгышка туп-туры иң баш җитәкчеләр каршына бардым да, кул бирдем. Сикереп торды да теге, ни әйтергә белми, телсез калды. Мин, шалт борылып, кереп тә киттем. Бар да басып катып калды. Шулай итеп, мине бу рольгә икенче тапкыр инде әфганнар үзләре сайлады. Кызык хәлләр әле моның белән генә тәмамланмады. Мине бер кунакханәгә урнаштырдылар, 50 кв. метрлы зур бүлмә, киңлеге өч метрлы зур карават. Йоклый гына алмыйм бит. Администратордан башка артистлар яшәгән кунакханәгә урнаштыруын көн саен үтенәм. Шулай итеп кинога төшүнең беренче көне җитте. Төнге өчтә уятып миңа борын ясыйлар, чөнки көндез борын тормый, эри дә төшә — эсселек илле градус. Шуңа төнлә ясап куялар. Иртәнге алтыда китеп барам, баскычтан төшәм. Шул минутта мине кунакханә хуҗасы күреп ала да «Аманулла!» дип кычкырып аягыма егыла. Соңыннан белдем, бу кеше Аманулла җитәкләгән гаскәрдә хезмәт иткән икән. Шуннан китте рәхәт тормыш, көн саен ни белән булса да сыйларга тырыша иде хуҗам. Мин аннан күчкәч, администраторга елап килгән бу: «Аманулла хан миндә торсын, китмәсен»,— дип. Соңыннан аңа кереп йөрдем, дуслашып киттек. Кайбер рольләр белән миңа шундый хәлләр дә булгалый.

*— Үзегез өчен кадерле булган тагын нинди рольләрегезне атар идегез?*

— Алар бар да кадерле, яхшымы-начармы — күңел көче түгелгән. Мәсәлән, Эзоп ролен уйнау минем өчен яңалык иде. Аннан соң, күңелемдә тирән эз калдырган роль — К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлары»нда — Мәхдүм. Яшь чакта минем беренче, чын мәгънәсендә катлаулы образым — Ильяс (Ч. Айтматов, «Гүзәлем Әсәл»). Бу ролем Тукай премиясенә лаек булды. 1986 елда Н. Островскийның «Бирнәсез кыз» әсәре буенча куелган спектакльдәге Карандышев роле өчен СССР Дәүләт премиясе бирделәр. Әлеге роль иҗатымның яңа офыкларын ачты. Без Марсель Сәлимҗанов белән бу персонажны башкачарак тасвирладык. Әсәрдәгечә вак кеше итеп кенә түгел, бәхетсез, нишләргә белми бәргәләнүче катлаулы образ тудырдык. Мәскәүдә дә шундый бәя бирелде. Иҗатның тагын яңа борылышы — соңгы вакытта уйналган Идегәй роле, әлбәттә. «Идегәй» сәхнә колачы гына җитми торган зур, тирән әсәр. Ләкин килеп чыккан кадәресе дә әйбәт хәл ителде, дип уйлыйм. Иҗат ягыннан мин үземне исkиткеч бәхетле дип саныйм.

— *Артист тулысы белән режиссерга буйсына, диләр. Чынлап та шулаймы?*

— Режиссер — ул күренешләрне читтән күрә белеп, сиңа аңлатучы. Режиссерның бар таланты нидә? Артистка юл күрсәтә белүдә. Ул сиңа рольнең скелетын ясый, ә син, актер буларак, шул сөяккә ит кундырасың. Әлбәттә, режиссерның роле искиткеч зур. Аның эше үтә нечкә, хәтта нәзакәтле. Марсель Сәлимҗанов, Празат Исәнбәт, Фәрит Бикчәнтәев кебек сизгер, итәгатьле, талантлы режиссерлар белән эшләүдән үзең үк ләззәт аласың. Марсель театрга минем чорда аяк басты. Ул өр-яңа идеяләр, яңа режиссура алып килде. «Сүнгән йолдызлар», «Американ» кебек классик әсәрләр ул чорда бөтенләй яңача яңгырады. Хәзер менә Фәрит шулай остарып килә. Аның классикасы — тагын яңалык. Мин аны театрның байлыгы дип саныйм.

— *Теләмичәрәк уйнаган ролегез булдымы?*

— Булгандыр... Мин аны һич кенә дә яшермим. Туры килгәндер... Артистлар арасында бер психологик момент бар. Күпләр кире образларны уйнарга яратмыйлар. Миңа да әйтүчеләр бар иде: «Ринат, сиңа кире рольләр килешми, сине яхшы итеп күрергә күнегелгән». Мин искиткеч артистыбыз Фатыйма апа Ильскаяны хәтерлим. Бер вакыт аңа бөкре хатын роле тәкъдим иттеләр. Көчле образ иде ул. Әмма Фатыйма ханым: «Мин бөкре хатынны уйнамыйм»,— дип, әнә шул шәп рольдән баш тартты. Ә мин, Аллага шөкер, бөкресен дә, турысын да, киресен дә, яхшысын да уйнадым. Мин амплуаны үзгәртүдән курыкмыйм.

— *Кире образны уйнау авыррактыр, мөгаен...*

— Зөлфәт Хәкимнең «Җүләрләр йорты» әсәре буенча куелган спектакльдә мин элеккеге КГБ кешесен — коточкыч рәхимсез образны уйныйм. Соңыннан баш ияргә чыгарга куркам, хәтта. Черек йомыркалар ыргытмасалар ярар иде, дим. Чынлап, чынлап. Ә уйнау процессы кызык. Кире образны уйнау өчен күп өйрәнәсе юк, алар тирә-якта шактый, үрнәк җитәрлек, әллә нинди төсмерләр табарга мөмкин. Уңай образга төсмерләр табу катлаулырак. Шуңа күрә, кире роль ул бер яктан караганда, җайлырак та кебек. Ә тамашачы ничек кабул итәр? Бер кичне, шул «Җүләрләр йорты»нда уйнаганнан соң, ишек төбендә мине өч кыз махсус көтеп тора. «Ринат абый, Сезне мондый рольдә күргән юк иде. Абау, бигрәк әшәке кешене уйныйсыз. Ләкин шәп уйныйсыз, рәхмәт»,— диләр. Шәп уйныйсыз дигәнне ишеткәч кенә, эчемә бераз җылы керде...

— *Артист тормышында иң кыены нәрсә дә, иң рәхәте нәрсә?*

— Иң рәхәте — тамашачының спектакльне яратуы, кабул итүе, сиңа җылы карашы, сәхнәдәге образыңны бар нечкәлекләре белән ача алуың. Шуннан да рәхәт мизгел юктыр. Ә иң кыены... Кайчак төшкә спектакльдә уйнавың керә. Һәм... кинәт сүзеңне онытасың. Эзлисең, исеңә төшерергә тырышасың — тәки искә төшми бит! Тирләп-пешеп, бимазаланып уянып китәсең.

— *Без, тамашачылар, сәхнәне зал ягыннан гына күрәбез. Икенче ягы — сәхнә арты күпкә кызыклырактыр, мөгаен.*

— Әйе, анда тамашачы күрми торган кызык хәлләр дә, кызганыч хәлләр дә булып тора. Хәзергәчә күңелемнән китми бер хәл. Әтием Казанда үлде. Ә мин шул кичне «Зәңгәр шәл»дә ат карагын уйнадым. Нишлисең — үзең сайлаган язмыш... Гомумән, артист һөнәре бик авыр хезмәт. Миңа калса, сәнгать өчен яратылган, театрны яраткан кешеләр генә түзә

артист хезмәтенә. Ә сәхнә артында тормыш һәрвакыт гел кайнап тора: очрашулар, гастрольләр, көн саен ниндидер яңалык... Театрда гомер үткәне сизелми. Менә алтмыш яшькә җиткәнемә дә аптырап йөрим. Йөрәк бит һаман яшь!

*— Артистның шәхси тормышы тамашачы өчен серле дөнья булырга тиеш, диләр. Сез дә, гадәттә, интервьюларыгызда гаиләгез турында аз сөйлисез...*

— Сөбханалла дип әйтик, шәхси тормышымда бар да әйбәт. Әйе, бик сөйләп йөргәнем юк. Җүләр хатынын мактар диләрме әле? Шулай да, хатыным Рәисәне мактамый булдыра алмыйм. Үземне гел формада тотуымда, азмый-тузмый яшәвемдә, иҗат итүемдә аның катнашы зур. Мин бик күп мәхәббәт геройларын уйнадым. Әмма хатыным түземле, акыллы булды — көнчелек чиренә бирешмәде. Өйләнешкән елларны эшеннән елатып кайтаралар иде. Имеш, күрдеңме, ирең сәхнәдә әллә нинди кызлар белән кочаклаша. Соңыннан андый чүп-чар сүзне тыңламый да башлады. Чөнки ул тәгаен белә: минем өчен гаиләмнән дә кадерле нәрсә юк, үз-үземә хыянәт итә алмыйм. Гаиләдә тынычлык булу сәхнә иҗатына бирелгән кеше өчен бик мөһим. Ике кыз үстердек, алар тәртипле, тырыш булдылар. Айсылу да, Руфина да хәзер кияүдә, ике оныгым бар, икесе дә — кызлар. Кем әйтмешли, өй тулы хатын-кыз.

*— Сәхнәдә гомер буе мәхәббәт геройларын уйнаган Ринат Таҗетдин тормышта мәхәббәтен тапкан, димәк?*

— Чынлап та шулай. Эштән ашкынып, сагынып өемә йөгерәм икән — димәк яратам, димәк бәхетле!

*— Ринат абый, мин чын күңелемнән Сезнең гомер юлыгызның да, иҗат юлыгызның да әле озын булуын телим, гади тамашачы буларак, Сездән күңелне кузгатырлык яңа рольләр көтеп калам. Шулай да, тел очында уңайсызрак бер сорау тора. Иртәме, соңмы — килер бер көн — театрдан китәргә уйларсыз. Сез моны ничек күз алдына китерәсез?*

— Беләсезме, бу бик урынлы сорау. Артист моңа әзер булырга тиеш дип саныйм. Ләкин шунысы бар: уйный алган вакытта театрдан киткән артист озак яшәми. Бу — факт. Безнең театрның бер шәп ягы бар: җитәкчеләребез, сәхнәгә чыгарга көче, дәрте, сәламәтлеге җиткән артистны театрдан җибәрми. Сәхнәгә буыннарның кечесе дә, олысы да зарур бит. Уйный алган кадәр уйнарга кирәк дип уйлыйм. Инде уйный алмаганыңны сизсәң, китәргә кирәк. Тамашачы сине көчле, талантлы, бәхетле итеп исеңдә калдырсын. Моннан бернинди дә фаҗига ясарга кирәкми, минемчә. Ләкин театрны ташларга ярамый. Китсәң дә, килеп йөр, карап йөр, яшьләргә акыл өйрәтеп йөр...

*— Ринат абый, ихтимал, җир йөзендә яшәгән һәрбер татар Сезнең сәхнә образларын күрү бәхетенә ирешә алмагандыр. Әмма бер нәрсәне тәгаен әйтергә була: дөньяда Сезнең тавышны танымаган татар булмас. Чөнки радио, телевидение аша Сез сөйләгән шигырьләр, хикәяләр бихисап. Уйлап карагыз әле, шулар арасыннан бүгенге халәтегезгә нинди шигъри юллар туры килә?*

— Һәм барыбер Муса Җәлил искә төшә:

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хакыгыз!

Мин үз рольләрем, иҗатым турында да нәкъ шулай дип әйтер идем. Тормыш та җыр шикелле. Ә инде аның шатлыкларын, кайгыларын, югалтуларын, табышларын, авырлыкларын, бәхетле мизгелләрен уйлый китсәң — ул озын хикәят тә сыман...

*— Берәүләр: «Театр — ул тормыш», — дип саный. Икенчеләр исә: «Тормыш — үзе театр», — ди. Сез кайсысы белән килешәсез?*

— Тормыш — театр дигәне белән килешәм. Чынлап та шулай. Ә театр — тормышның көзгесе. Тормыш — театр һәм һәркемнең Ходай язган үз роле.

*— Артистларга гадәттә күпсанлы рәхмәтле тамашачылар, көчле алкышлар, кочак-кочак чәчәк, кызыклы гастрольләр, уңышлы рольләр телиләр. Болары да булсын, иншалла. Ә мин сезгә журналны укучылар исеменнән иҗатыгызда яңа газаплар, эзләнүләр, табышлар һәм аларга юлдаш итеп бетмәс-төкәнмәс илһам телим. Сезне яшәтүче һәм яшәртүче көч шушы, ахры. Юбилеегыз котлы булсын! Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт.*

Әңгәмәдәш — **Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА.**

# КАБАТЛАНМАС ШӘХЕС

Дөнья мәшәкатьләрен, яшәешне, тирәлекне үзенчә күрә, кабул итә торган шәхесләр була. Яфрак лепердәвендә дә ул тормышның дәвамын сиземли, сандугач җырында да халкының моңын, зарын, шатлыгын ишетә. Бөтнек исе дә аның өчен иң затлы француз хушбуйларыннан кыйммәтрәк. Кайберәүләр фаразынча, алар кыйланмый, нәүмизләнми, Ходай Тәгалә, табигать шулай яраткан андый затларны. Халык үтә сизгер, ихлас, шул ук вакытта тормыш ваклыкларыннан өскәрәк күтәреп торган кешеләрне хыялый, фәнничәрәк әйтсәк, романтиклар дип атый. С. Рәмиев, Һ. Такташ, И. Юзеев, Р. Гаташлар чынбарлыкны яңабаштан корып язылган әсәрләре белән XX йөз татар шигърияте үсешенә мөһим өлеш керттеләр, аңа үзенчәлекле бер агым өстәделәр.

Озак еллар дәвамында татар радиокомитетының әдәбият-сәнгать буенча баш редакторы булып эшләгән Рим Котдус улы Кәримов — нәкъ менә шундый хыял-өметләре артыннан теләсә кая бара торган үзенчәлекле шәхес иде. «Хыялый-романтик» кебек төшенчәләрне дәрвишлек, сәяхлек, сәрхүшлек, булдыксызлык белән бутарга ярамый. Киресенчә, бу төр затларны максатчанлык, алынган эшен җиренә җиткерә белү һәм үзенчә фикерләү бизи.

Рим кешеләрнең күңеленә бары тик үзенә генә охшаган, башка берәүне дә кабатламаган шәхес булып кереп калды. Аның тормыш юлы — рухи дөньясының, холык-фигыленең күчермәсе иде.

Ялгышлыкка меңләгән юллар илтсә дә, дөреслеккә исә берсе генә алып бара, диләр. Ырынбур өлкәсенең Абдулла районы Габдрахман авылында туып-үскән Рим Кәримов Казан каласына ачык, тәгаен максат белән килә. Чыннан да, нинди хис-тойгы, ният-омтылышлар алып килә соң аны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә? Әлбәттә инде язучы, дөресрәге, шагыйрь булу хыялы алып килә аны ап-ак баганалы изге гыйлем йортына. Җыйнаклык, ихтыяр көче җитсә, бар сәләтен, җегәрен бер ноктага тупласа, ул шагыйрь дә булып китәр иде. Өметле шигырьләре һаман да хәтердә. Мәгәр табигать аңа һәр тарафтан сәләтне шул чаклы мул биргән булган ки, Римгә теге яки бу өлкәне сайлау җиңел булмый. Ул — артист, директор, тәнкыйтьче, оештыручы, оста мәзәкче, тагын әллә кемнәр...

Бездән алданрак укыган татар теле һәм әдәбияты бүлеге төркемнәрендә егетләр өстенлек итсә, без группада нибары җиде бөртек булып чыктык. Табигать талантлы ир-затларны фани дөньяда озак яшәтми, Җир-ана аларны үзенә иртәрәк чакыра тора. Белүемчә, безнең белән укып чыккан егерме хатын-кызның барысы да исән-имин гомер кичерә, оныклар үстерә. Ә группадаш егетләребез Әфган, Чечән сугышларында катнашмыйча да, вакытсыз кырылып бетте, өчебез генә — филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыпов, Зеленодол районы Муллаиле авылы урта мәктәбе директоры Равил Сәйфетдинов һәм мин бүген дә күк астында йөрибез. Ай күрде, кояш алды замандашларымны. Соңгылары арасында — яшәргә дә, яшәргә тиешле, яшәргә лаеклы, олы җанлы, матурлыкка сизгер, кешелекле Рим Котдус улы Кәримов.

Теләсәң, теләмәсәң дә яшьлек хатирәләре күңелдә бүгенгедәй булып сызылып калган. Бергә конкурсларны узып, бергә студент дигән исемгә лаек булган группадаш егетләрем Рим Кәримов, Шәүкәт Сәйфетдинов белән мин бик тиз уртак тел таптым, дуслашып киттем.

Уртачадан аз гына калкурак буйлы, тыгыз тәнле, гел кояшлы якта яшәгән кешенекедәй кара-кучкыл йөзле, уртасында өскә кабарып торган очлы борынлы, куе күгелҗем күзле, тәэсири хисле Рим безне тормышка аек карашы белән шаклар катырды. Шулай бервакыт:

— Группаны кулга алырга кирәк,— диде ул борынын өскәрәк чөеп.— Аннан факультетны...

— Ничек, ни рәвешле? Ни пычагыма?

— Шәүкәт группаның комсоргы булыр, син — профоргы. Кемнеңдер табаны астында яшәгәнче, үзебез хуҗа булыйк.

— Сине староста итик, — дидек бертавыштан, бездән генә торган нәрсә турында сүз баргандай.

— Юк, булмый, егетләр. Староста ул деканатның шымчысы. Шпион буласым килми.

Группаның беренче җыелышында ук Рим Кәримов шактый акыллы гына, фикер җебен эзлекле ачып, Шәүкәтне комсорг, мине төркемнең профсоюз житәкчесе итеп сайлатып куюга иреште. Шәүкәт Сәйфетдинов Октябрь районы Яңа Әлмәт урта мәктәбенең комсомол сәркатибы булып эшләп килгән егет, минем дә арка терәгем нык — бер ел буена Урал якларындагы бер заводта алюминий эреттем. Ә Рим, «рәсми урындык» биләмичә генә, безнең белән житәкчелек итәргә тиеш иде.

Рим белән миңа тулай торакта урын житмәде. Киттек тору урыны эзләп. Киров урамының мәчет чатында ук урнашкан почмак йортта яшәүче Фатыйма апа икебезгә киң тимер караватын «сатты».

Миннән аермалы буларак, Казанда Римнең туганнары күп икән. Бертуган ике апасы да, ераграк кардәшләре дә кече энекәшләренә игътибарлы булдылар. Егетнең рухи өлгерешенә, тормышта үз ызанын табуына, минем аңлавымча, җизнәсе, танылган журналист, егерме биш меңче колхоз рәисе, озак еллар дәвамында Татарстан китап нәшрияты директоры булып эшләгән, милләтпәрвәр Гарәф Шәрәфетдинов тирән һәм уңай тәэсир итте. Ул мине дә үз канаты астына алды.

Ярты елдан соң Котдус агайның төпчек малае Казанда үз йортларын житештергән Сәйдә апасы белән җизнәсе янына күчеп китте.



*Татарстан радиосы хезмәткәрләреннән бер төркем (сулдан уңга): журналистлар Карл Фәизов, Наил Гыйззәтуллин, композитор Исмай Шәмсетдинов, радионың баш редакторы Рим Кәримов, журналист Фәләх Насыйров, язучы Флүс Латыйфи. 1969 елгы фото.*

Университетта укуының беренче көннәреннән үк Рим, соңыннан олы тәнкыйтьче булып киткән Фәрваз Миңнуллин оештырган әдәби түгәрәккә йөри, группа кызлары белән мәхәббәттә аңлаша, шигырь яза, яттан әсәрләр укый. Хәтеренә шайтан төкергән, уку аңа җиңел бирелә. Әгәр инде берәр фәнне яратмаса, кабул итмәсә — ул аңа борылып та карамый.

Мәзәк хәлләр — аяк астында. Такташ иҗаты буенча профессор Хатип ага Госман махсус курс буенча лекцияләр укый. Романтик шагыйрьнең мирасын Рим Кәримов кебек яхшы белгән, яраткан кеше группада юк. «Алсу», «Мока-

май»ларны яттан өздерә. Егетебез әллә галим белән үз башына бәхәскә кергәнме, аңа каршы әйткәнме, әллә тегесе артык күп белүен яратмаганмы, Хатип Госман аңа зачет куймады, артыннан шактый йөртте. Горур Рим, табигый ки, гарьләнде. Безгә — бәйрәм. Тычканга — үлем, мәчегә — көлке.

Беренче курсны тәмамлагач, Римнең җизнәсе Гриша дәдәй — ашханә мөдире — безне ашханә өчен сарай салырга яллады. Җәй буе балта осталары, ташчылар булып эшләдек. Шактый акча кулга керде. Шәүкәт белән миңа Рим: «Беренче сентябрь көнне университетка такси белән барып төшәбез» — диде. Без, табигый ки, кысылабыз, тартылабыз, «Нигә акча әрәм итәргә», дип ык-мык килеп карыйбыз.

— Саранланмагыз, бу фани дөньяда бер генә тапкыр яшибез.

Рим үзенекен итте. Ул гына да түгел, элек тарих-филология факультеты урнашкан Химкорпус янында группаның берәр кызы аның белән исәнләшмичә торып, Рим машинадан чыкмады. Шул мәлдә тәкәббер Римнең иреннәрендә горурлык нурлары уйный иде. Нобель премиясе тапшыручы швед королең яисә шул бүләккә лаек булган эре, тәкәббер Иван Бунинның бер якта торсын!

Шул кышны Рим Кәримовны үзгә мавыгу биләп алды. Ул — сәхнәгә менде. Хәер, Ырынбур егете беренче көннән үк оста мәзәкче, башка кеше рәвешенә кереп сөйләүгә ия юморист буларак танылган иде. Аның алты килолы җәен балыгын бер әчмуха тәмәкегә алыштырган чуаш карты Тәбук, сдача сорагач, Ленин башы төшерелгән тимер тәңкәсен кире ташлаган базар сатучысы үзбәк булып кыланулары — үзе бер сәнгать иде.

Ул зурдан купты. Муса Җәлил образын гәүдәләндерде. Егет барлык группаны диярлек сәхнәгә тартты. Мин дә Җәлилнең дусты Абдулла Алиш булып уйнарга тиеш иконмен. Артистлык сәләтем юклыгын тәгаен беләм ләбаса, әмма Римнең коткысына бирелеп, Рәшидә апа Җиһаншина оештырган түгәрәккә йөрим. Күренекле артист Нәҗип Гайнуллин да безнең белән әвәрә килә. Татар халкын милләт булып яшәткән, саклаган бу йолалар, ни кызганыч, юкка чыкты. Хәзер артистлар студент халкы дәрәҗәсенә төшмиләр, вакытлары юк, акча эшлиләр.

Спектакльне татар академия театры бинасында куйдык, ул матбугатта югары бәя алгач, Римне артист булырга да димләделәр. Һичшиксез, аңардан яхшы артист чыгар иде. Ул әлеге тәкъдимнән баш тартты, чөнки аның бөтен барлыгын яңа өлкә — радио биләп алган иде инде. Дүртенче-бишенче курсларда укыганда ул инде танылган диктор иде. Һәр иртән, кичен Котдус агай улының бай тембрлы, тыгыз мәгънәле тавышы халкыбызның колагын иркәли, рухын җылыта.

— Радионың мөмкинлеге чиксез. Аны сукырлар да тыңлый,— ди иде егетбез, үзенең яңа мавыгуын аклап.

Без, уенын-чынын бергә кушып, аны атаклы диктор Левитанга тиңлибез. Ул — киң күңелле кеше буларак, каршы килеп, ризасызлык белдереп вакланмый.

«Рим Кәримов үзен тапты, радиода калыр», дигән фаразыбыз акланмады. Көтмәгәндә-уйламаганда, ул булган китапларын, алмаш киемнәрен биштәренә тутырып, Алабуга якларына, педагогия институтына татар әдәбиятын укытырга китеп барды. Тавышы яхшы, белеме бар, чибәр, нәкъ менә шундый кешеләр укытырга тиеш тә безнең инсафлы, югары әхлаклы татар әдәбиятын, дип озатып калдык.

Кышкы каникулга Рим Кәримов Казанга кунакка кайтты. Элеккеге курсташларын апаларына, Себер трактындагы йортларына җыеп алды.

Егет бик нык үзгәргән, үзен байларча, вәкарь белән тота, бераз җылынып алгач, ишекле-түрле йөренеп, «гавамны» тәрбияләргә керешә. Безне фольклор экспедицияләренә алып йөрткән Илбарис Надиров шәкертенең шулай үзгәрүенә шаклар катып утыра.

Ярты ел эчендә олыгаеп, җитлегеп, бөтенләй башка кеше булган Римебезне җеннәр «алмаштырган», диярсең. Җиңел мавыгучан, ышанучан егетебез Алабуга педагогия институтында үзенә табыныр кешеләр, кумирлар тапкан. Алар — үзеннән өлкәнрәк яшьтәге математика укытучысы, соңгы берничә елда әдәби әсәрләре белән чыгыш ясаган, мәрхүм Тәбриз Мөбәрәков белән шулай ук төгәл фәннәр әһеле Гаяз Сәләхиев булып чыкты. Безне ул арттa калуда, мещанлык сазлыгына батып, сөрсеп ятуда гаепләде, чын ир егетләрне Алабугада гына табуы хакында кызып-кызып, ишекле түрле йөренә-йөренә сөйләде.

— Безнең арада акча санау, бу — минеке, бусы — синеке дип бүлгәләү, бурычны кире сорап алу гадәте юк. Сезгә дә шулай, кешечә яшәргә өйрәнергә вакыт җитте,— диде «тәрбиячебез».

Дөрес, соңрак, Алабугада яшәгәндә үк, ул бу мавыгуларының вакытлы уен, гайре табигый, беркатлы булуын аңлады. Гаилә корып, гадәти көнитешнең тавык чүпләп бетерә алмастай вак мәшәкатьләре җилкәсенә өелгәч, ул да «акча санамау, бурычны кире сорамау» мәсьәләләренә, «мещанлыкка» башкачарак карарга мәҗбүр иде. Соңрак буйдаклык язмышын сайлаган Алабуга егетләреннән читләште, мәгәр барыбер үзең өчен генә яшәү фәлсәфәсен кабул итмәде.

«Замана балалары» (1993) китабымда тулырак бәян иткән әлеге хәл-әхвәлләрне искә алуымның сәбәбе — Рим Кәримовның кеше буларак җитлегә килүен, кабатланмас холкын, фигылен күрсәтү иде. Ул мәхәббәтендә дә, кемнедер, нәрсәнедер кабул итмәвендә дә максималист иде. Гомере буена Рим үзенең матур, идеал, кристалл кебек саф кеше турындагы хыялына җавап бирердәй үрнәк-өлге эзләде, күзаллавына якын килгән берәр затны тапса, аны бай рухи дөньясы белән тулыландырды, бизәде. Ялгыша, үкенә, әмма эзләнүдән туктамый.

Берничә елдан соң, язмыш минем үземне дә Алабугага, шул ук педагогия институтына алып килде. Рим Үзбәкстанда туып үскән, чем кара, озын толымлы, яшь, чибәр Гөлшат белән бик тату гына яшәп ята. Хәзер үзе дә шигырьләр авторы — малайлары — Илдарлары туган. Романтигыбыз җиргә төшкән, Алабуга егетләрен дә элеккегедәй мөкиббән китеп мактамый. Мәдәни мәркәзебез Казанны, театрларны, язучы халкын сагына. Педагогия институтында татар теле бүлегенә студентлар кабул итү туктатылган. Римга биредә тар, кысан. Казаннан чыгып китүләре җиңел булса да, кире кайтулары ай-һай авыр шул. Анда сине берәү дә көтеп тормый, син берәүгә дә кирәк түгел. Ләкин Рим үзе өчен карарны җөпләп куйган. Ул Казанда яшәргә тиеш! Әйләнеп кайтуның бердәнбер ышанычлы юлы — аспирантура. Рим Кәримов Баян Гыйззәт җитәкчелегендә Нәкый Исәнбәт комедияләрендә конфликт дигән темага кандидатлык диссертациясе язарга әзерләнә. Журналда шул темага багышланган тирән эчтәлекле, җырлап торган телле мәкаләсе басылып чыкты. Мәгәр Рим урындыкка кадакланып, чалбар төбен туздырып утыра торган кеше түгел. Аның тынгысыз рухлы, эзләнүчән холкына батмый мондый эш. Беркөнне:

— Тарихи романнар укыйм әле, малай. Үземә яна бер дөнья ачтым, — дип каршы ала мине дустым киң ятагында.

— Диссертацияң ни хәлдә?

— Голубцы пешерергә өйрәндем. Пылауны үзбәгеннән ким әзерләмим. Хатын мактый.

Димәк, Рим диссертация белән чиләнергә уйламый. Аның диссертация язу чорына караган ике кызык хәл-әхвәл зиһенгә сеңеп калган. Римнең үзе сөйләгәне:

— Нәкый Исәнбәткә телефоннан шалтыратып, өенә киңәшкә киттем. Ап-ак, зыялы чырайлы абзый икән. Җылы кабул итте. Кайсы комедияләренә тукталу кирәклеген ачыклагач, хезмәтнең проблемасы турында киңәшергә булдым. Комедиядә конфликтның үзәгендә нәрсә ята? Бу төр драма әсәрләренең эчке пружинасы нидән гыйбарәт? Абзыйның ифрат укымышлы зат булуын белгәнгә, бөтенләй оятка калмас өчен, фәнни әдәбиятны укыштырып килгән идем. Белдеклелекне дә күрсәтеп аласы килә. Комедиянең үзәгендә персонажның тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы белән эчке дөньясы арасындагы каршылык ята, шул нигездә комик ситуация, көлке туа, әмма мин бу төшенчәне ахыргача күз алдына китерә алмыйм, дим.

Абзый хәйләкәр, җавап бирергә, бәхәскә керергә ашыкмый, җиңсез җылы күлмәген сыйпап, агач артлы урындыгында утыра бирә. Кинәт ул, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, уянып китте, болай да кысык күзләрен тагы да йома төшеп, берни белмәгәндәй сорап куйды: «Энем, синең фәнниме, гыйльмиме җитәкчең кем әле?» Шактый аптырашта калып (чөнки ул бу хакта миннән мәгълүмат алган иде инде), Баян Гыйззәт, дим. Шуннан соң ул:

— Комедиядәге конфликтның, көлкенең классик мисалы синең җитәкчең була инде, энем, баш катырып торасың юк, — дип миңа кулын сузды. Димәк, безгә таралышырга вакыт җиткән. Нәкый Исәнбәтнең тәнкыйтьче, драматургия белгече Баян Гыйззәтне кабул итмәве иде бу. Рим фәнни җитәкчесен диссертация өстендә тир түгеп эшләве белән сөендерә алмаса да, аның белән гел дустанә яшәде.

Гайбәткә сусаган халык шундый кызык хәлне яратып, тәмләп сөйли иде шул чорда. Аспирант Рим Кәримов радиога кабат эшкә чакырылгач, җитәкчесен эзләп китә. Исәбе — кешечә саубуллашу. Баян Гыйззәт белән «Заря» рестораныңда бик матур гына «чылаталар». Болар, аңлашалар, күңелләре тула, әмма аерылышасылары килми. Сөйләшә-сөйләшә Горький паркы каршындагы мәй-

данчыкка барып чыгалар. Бер-берсенә такмак әйтеп, бии башлыйлар. Табаннарыннан очкын чыга. Бөтен галәм аларга кушылып бии. Ике метрлы әзмәвер ир янында җиңел сөякле Рим орчык кебек бөтерелә. Гөнаһ шомлыгына каршы, сыбызгылы милиционер килеп житә. Рим югалып калмый:

— Азат илемдә теләсә ни кыйланам. Парк янында да биемәгәч, кая биик соң без?

Ул чорда милициясендә дә акыллы кешеләр күбрәк булган күрәсең, документларын тикшереп, биючеләрне иплән кенә трамвайга утыртып җибәрәләр.

Ул инде диктор түгел, әдәбият-сәнгать бүлегенең мөхәррире. Тапшыруларны үзе алып бара. Егетебез яшәреп китте, җилкәләре турайды, радионың көндәлек эше, өлгер тормышы аның бөтен барлыгын биләп алды. Тиздән ул әдәбият-сәнгать буенча баш мөхәррир итеп билгеләнде. Менә шунда яңалыкка сизгер холкы, дөнья әдәбиятын, татар мәдәнияты тарихын яхшы белүе ярдәмгә килә. Югары зәвыгы аны татар радиокомитетының алыштыргысыз хезмәткәре дәрәҗәсенә күтәрә. Ул үз янына әдәбиятны, сәнгатьне ихластан яраткан яшьләрне туплый, язучы, журналист халкын эшкә тарта, яңа рубрикалар ача, бик күп тапшыруларны үзе иҗат итә. Күбесе әлегәчә хәтердә, зиһендә. Рим Котдус улы үзен радиода тапты. Аның күпкырлы табигый сәләте нәкъ менә шул синтетик жанрда, кояш нурында уянган чәчәк кебек, ялтырап ачылып китте.

Рим үз хыялында туган, ал төсләргә манчылган романтик дөньяда яшәде. Шуңар да аның рухи халәте, эчке яшәеше бай, тулы иде. Ул берәүгә дә аңлы рәвештә начарлык эшләмәде, киресенчә, халкын, җиһанның һәр кешесен бәхетле, тигез итеп күрү хыялы белән яшәде.

Әлбәттә, коммунистик режимның сәяси, әхлакый тәрбиясе, матбугатка куелган катгый таләпләре, кысулары аның да җанын бимазалый. Ул — бәргәләнә, үз фикерен уздыру өчен төрле әдәби алымнар, шартлы сурәтләр эзли һәм таба. Рим бу эшен яратып, чын күңелдән башкарды дип әйтү бик аз. Ул үзенең хезмәтен халыкка, аның киләчәгенә иң кирәкле, иң файдалы шөгыль дип санады. Шул ышанычы аның иң гадәти саналган тапшыруларын да мөстәкыйль, нәфис сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрде. Аларны туплап, нәшер итсәң, укучы аны теләп кабул итәр иде. Аның әдәби-тәнкыйть мирасы да өйрәнүчесен көтеп ята.

Дустым Римнең гомере озын булмады. Татар мәдәнияте күгендә якты йолдыз булып янды да, үзе аңлаганча, үзе белгәнчә милләтенә юлны яктыртты да, сүнде Рим Кәримов йолдызы. Әмма ул безнең йөрәкләрдә мәңге яшәр! Андый шәхес онытылмый ул!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
язучы, галим.



# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ҮЗЕҢ ШАТЛАНА БЕЛМӘСӘҢ...

## ХИКӘЯЛӘР ОСТАСЫ МӘГЪСҮМ ХУҖИН ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Янәшә килгән ике әдәби ел!

Беренчесендә, 1996 ның азагында, «Елның популяр әсәре» сериясендә урта буын әдибәсе Н. Гыйматдинованың «Кыргый» исемле повестьлар җыентыгын кулдан-кулга йөртеп укыдык.

Икенчесендә өлкән язучы Мәгъсүм Хуҗинның «Пшыяцулка» дигән хикәясе, «кече проза»ның уңышлы әсәре буларак, Татарстан Язучылар берлегенең Фатих Хөсни исемендәге бүләгенә ия булды. Без бу хикәяне «Идел» журналының 1996 елгы өченче санынннан укыган идек. Нечкә зәвыклы талымчан бу журнал соңгы чорларда әдипнең «Бәрәңге чәчәге», «Җүләр», «Койма буенда» дигән әсәрләрен дөньяга чыгарды, «Татарстан» журналының 1997 елгы 4 саны аша «Губахадан ике хикәя»се укучыларга барып житте. Әдипнең әсәрләрен дә эченә алган яңа хикәяләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятында басылып ята.

Әгәр миңа Нәбирә Гыйматдинова турында: «ул гадәти җир кешесе, гаҗәп повестьлар язуы кешеләрдә була торган гап-гади талантлан гына килә, гайре табигый берни дә юк» дисәләр, ышанмас идем. Чөнки мин аны күреп белмим, ә могҗизалы-сихерле повестьлары буенча фикер йөртсәк, андыйларны иҗат итү өчен, ай-һай... Дөресен әйткәндә, Казанга баргач әдибәнең эш урынына сугылып чыгасым бик килсә дә, әлегә моны эшли алмыйм. Әгәр чыннан да артык җирнеке, «синдәй-миндәй» генә булып күренсә... .

Ә менә язучы Мәгъсүм Хуҗинны якыннан белмәгән кеше аның хикәяләренә карап, әйтик, җиде дистәне түгәрәкләүгә таба барганда «Пшыяцулка» кебек әсәр язуыннан чыгып, «бу әдип гадәти була белмидер, гел сагыш-моң эчендә, фаҗигале язмышлар өермәсендәдер, мәңгелек уйларга баткандыр» — дисә, миңа гаҗәп тоелыр иде. Бераз беләм бит аны. Хәер, кайвакыт мин дә, хикәясе белән авторны бер-берсеннән аерым итеп күз алдына китерәм дә, бергә куша, бербөтен итә алмыйча интегәм. Менә алар — Автор белән Хикәя — Мәгъсүм Хуҗин белән без бергәләп вак балык чирттереп йөргән Шушма инешенең ике ярында.

Автор үтә гади, сабый акыллы: кармагына бармак буе ташбаш эләктергән дә, сөенеченнән калын пыялалы күзлегенә кадәр елмайган хәлдә, «тагын берәү булды бит!» — дип текә ярдан үрмәли-үрмәли, учак өстендә кайнаган казан янына ашыга. Әйе, Шушманың авыл саен тегермәнле, болынга кадәр күтәрелгән сулы чагын күрергә өлгермәде диярлек ул: Мәгъсүм Хуҗин Балтачта район газетасы редакторы булып эшләгәндә, буалар Салавыч белән Янгулда гына калган иде. Инде алары да күптән юк. Бервакыт мин әдипне Янгул тегермәненең иске бинасы һәм буа калдыклары төшерелгән фотосурәткә озак кына карап торган хәлдә күрдем. Ниләр уйлый, рәсемнән ни эзли ул?

Хәер, бу сорау белән әдипне ашыктырмый торыйк, мөгаен, бер хикәясендә үзе үк җавап бирер. Табигать фаҗигасен дә кешеләрнеке кебек кабул итә, җаны аша үткәреп яза бит ул. Гап-гади кешеләрнең легендаларга тиң матур мәхәббәт кыйссалары, күңел байлыклары, сиздермичә узып киткән гомер сагышлары гына түгел, Табигать-ананың челтер чишмәләре, инеш-күлләре, колыны һәм маэмайлары да аның хикәяләрендә Мәгъсүмчә якты моң белән, яратып-сөеп сурәтләнә бит. Үзе дә бөтен күңеле белән табигатьнеке ул. Эшләгән һәр районында кышын-җәен балык тота торган инеше, язын-көзен ихластан тәм табып казына торган бакчасы, помидор, кыяр, суган, хәтта үзенең ак әнис, кузгалак, бөтнек, какы түтәлләре, үз куллары белән утырткан җимеш куаклары һәм алмагачлары калды. Өенә яз таңында керсәң дә, кыш башында сугылсаң да, табын бизәргә

бер-ике кузгалак яфрагы, ике-өч кыяк яшел суганы була иде бу табигать дустының. Яки урындыкка басып әллә кайдагы шүрлеккә үрелер дә, кызарып килә торган бер-ике помидор тартып чыгарыр...

Хәер, мондый табынны сурәтләү өчен дә Мәгъсүм-әдип хыялы һәм каләм осталыгы кирәк:

«Кечкенә түгәрәк өстәлнең яртысына ризыклар куелган иде. Мин Ваһиб ясаган картина һәм ул әзерләгән табын арасында аерма таба алмадым — алар тиңдәш иде. Муенына чирек ай сурәте уелган кувшинга чәчәкләр утыртылган — болын исе аңкый. Урталай киселгән карбыз янтаеп тора — тел очында тәмен сизәсең. Сабак төбеннән алсуланган дәү алмалар, лимон телемнәре, озын тәпиле вазага тутырылган мандариннар, балкыш төсендәге ике апельсин өстенә сузып салган кыяк суган һәм... бөкесе ачылырга торган коньяк шешәсе бар, шәраб белән яртылаш тулы зәңгәр каймалы ике бокал җемелди...»

Болар Мәгъсүм Хуҗинның «Натюрморт» хикәясеннән. Автор Ваһибның натюрмортын да, табынын да сокланып сурәтли, аның осталыгына баш ия. Мәктәптә укыганда ук «язгы кояш булып нур чәчә» торган икмәк рәсеме ясап, «укытучы Тәслия апаны баш идергән» ул Ваһиб. Туктачы, натюрмортта да, табында да нигә әле икмәк юк?

Хикәя менә шушылай көтелмәгән борылыш алып тәмамлана, укучыны сискәндереп, уйланмаган сорау алдында калдыра. Табынның үтә муллыгын юмартланып сурәтләү авторга менә ни өчен — анда икмәк юклыгын әйтеп, безне йокымсырау хәленнән айныту өчен — кирәк булган икән. Ә бит әсәр моннан өч еллар элек — авылларның һәм район үзәкләренең икмәк кибетләрендә коточкыч чиратлар чорында язылган. Табигатьнең һәм игенче хезмәтенең мәңгелек бер могҗизасы булган икмәккә бервакыт кадер бетәчәген әдип шул чакта ук ничек белгән? Әдип әхлакыбызның җимерелүгә йөз тотуыннан чамалаганмы, мондый җимерелүнең икмәккә, гади хезмәт кешеләренә һәм өлкәннәргә хөрмәт суынудан башланачагын нечкә күңеле белән сизгәнме? Ихтимал, шулайдыр.



*Язучылар Мәхмүт Хәсәнов (сулда) һәм Мәгъсүм Хуҗин. 1989 ел.*

...Шулай итеп, тирән чокыр төбеннән, ерганакны басып килүче таллар һәм чүп-чар арасыннан сай гына аккан инешнең текә ярыннан үрмәле-үрмәле учак өстендәге кайнаган казан янына ашыга Автор. Ә Хикәя, әнә, калды ул. Сабыйлыгына кайткан Авторга иярәсе килмәде, аның игез пары кыяфәтендә, карашын билгесезлеккә юнәлтеп, тик тора. Үзеннән бер яктылыкмы сирпелә, моңмы ишетелә. Ләкин Автор белән Хикәянең ике ярдагы аерым тормышы озакка бармаячак, учак янындагыларга сиздермичә генә, әллә ни арада гына алар бербөтенгә әвереләчәкләр. Һәм, әйтик, «Идел» журналының бер санында, Мәгъсүм Хуҗин имзасы белән озак та үтми яңа әсәр дөньяга чыгар. Хикәя менә

шушы инеш буенда бүген булган, бүген сайланган гыйбрәтле бер вакыйгага нигезләнеп язылырга да мөмкин. Хикәядә, мөгаен, Шушма инеше дә, аргы яктагы Ишморат болыны яисә Бай урманы да, серле Бөркет елгасы яки Йөрәк тау да телгә алыныр, һәм болар, һичшиксез, әсәрнең ышандыру көчен арттырып, тасвирланган легенданы безнең көннәргә якынайтыр. Ә без, ул вакыйгада катнашучылар, хикәядә үзебезне танырбыз да, юк та. Әдипнең күзаллавы чикләрне белми: ул безне, Жирнең гади кешеләрен, һәрвакыт үзебездән яхшырак, ихласлырак, күңелләребезне байрак итеп тасвирлый, димәк, безне шундыйлар итеп күрә, моңа үзебезне дә ышандырырга тели. «Үзең шатлана белмичә, башкаларны сөендерә алмыйсың» — дигән сүзләр бар аның «Оча кошлар» исемле хикәясендә. Хикәя каһарманнарының яхшылыгына, күңелләре аклыгына үзе ышанып житкәнгә күрә генә укучыларны да ышандырырлык итеп яза ул. Хыялый әдип хәтта үткән яшьлекләрнең кире кайтачагына, югалган мәхәббәтләрнең яңарачагына фажигале язмыш корбаннарының бәхет табачагына, корып бара торган жаннарыбызның да бер сулкылдап куячагына өметләнә бугай. Шулай булмаса, нигә дип, кемгә атап шундый әсәрләр язар иде? Әмма әдип өметләре азмы-күпме чынга ашсын дисәк, безгә дә, аның хикәя каһарманнары кебек, бераз хыялыйрак, матурлыкны тоярлык пакъ күңелле, бүтәннәр хәсрәтен аңларлык нечкә жанлы булырга кирәктер. Бу шәфкатьсез дөньяның изү-гарипләвеннән бер-беребезне әнә шулай гына саклаша алырбыз.

Минә әдипнең якташы Фатыйх Хөсни исемендәге иң беренче бүләкне алган «Пшыяцулка» («Дус кыз») хикәясе. Монда мәхәббәт кыйссасы шулкадәр гомумиләштерелгән — баш каһарманнарының исемнәре дә юк. «Витебскиның кара күзле кызы» Пани һәм хикәянең лирик каһарманы беренче танышуларыннан соң унсигез ел узгач кабат очрашалар. Бу очрашуның тыенкы матурлыгын һәм тагын аерылышуның сагышын, сизелмичә дә узып киткән гомернең бернинди ялваруләр хакына да кире кайтмаячагын шушыкадәр кыска хикәядә шулай жан сыкратырлык, вакыйганың чынлыгына ихлас ышандырырлык итеп тасвирлау өчен Мәгъсүм Хужинга, белмим, нинди илаһи көчләр ярдәм итте икән? Ә бит сүзжөмләләрне дә артык бизәмәгән, гыйшык кыйссасына заманча «татлылык» та якмаган, ундүрт яшьлек кызның ымсындыргыч матурлыгын да сурәтләмәгән (аларсыз да шәп язылырга мөмкин икән ич!).

Баш каһарман кыз белән беренче очрашуын һәм шаярып сөйләшүен оныткан да инде: Пани үзе исенә төшермәсә, аны мәңге хәтерлисе булмаган. Әйе, бу — шулай. Үзебезне күмеп киткән тормыш чүп-чары эчендә шуларны искә төшерерлекмени соң без?! Әмма лирик герой ник алайса кырык яшькә кадәрге гомерен өйләнмичә уздырган, күңеле һаман нилектән буш торган? Инде менә өзгәләнә: «Сине гел эзләрмен, калган гомерем буе эзләрмен сине, Пани! Каршыма очрасаң, мәрхәмәтле һәм горур күзләреңнән танырмын! Артыңнан барсам, чуклы мамык шәлең астыннан күренгән толым очларыңнан танырмын! Пани!» Бу үкенечле сүзләрне кабатлый-кабатлый тәгәрәп еласа да, үткән гомерен кайтара, гамьсезлектә югалткан бәхетен таба алмаячак ул. Ә бит теге чакта, унсигез ел элек, шушы кыз аңа «Мин булырмын сезгә Пшыяцулка» дигән иде. Ундүрт яшьлек кызның шаярып кына бирелгән вәгъдәсе шулкадәр нык була алыр дип кем уйлаган соң? Чөнки үзебез бик житди үтәлергә тиешле вәгъдәләребезне дә жиңел генә онытып торабыз. Безгә вөжданлылык үрнәге буласы кешеләр Изге китап яисә Конституция тотып, күзләреннән яшь чыгарып биргән антларын да читенсенми генә бозалар.

«Пшыяцулка» каһарманнары ул чакта нәрсә генә сөйләштеләр соң әле?

— Сез безгә нинди максат белән килдегез соң? — дип сорады ул.

Их-х, телемне корт чаккыры!

— Кәләш эзләп ил гизәм! — дип һич тә уйламаганны әйтеп салдым.

— Таптыгызмы соң?

— Менә сезне ошаттым!

— Мин әле яшь. Миңа ундүрт кенә яшь тулды.

— Ә мин сез үсеп житкәнне көтәрмен! Шул чакта килермен дә сезне урлап качармын!

Кызыма уен ошап китте, ул күзләрен кысып елмайды да:

— Мин сезне көтәрмен... — дип шаяртты».

«Шаяртты!» Никадәр олы хисне шаяртуга санап ничек ялгышкан бит. Киресенчә, урлап качу турында әйтеп, үзе мәгънәсез шаярган икән. Каян килгән Кәжә Шәяхмәт Айдары (Фатыйх Хөснинең мәшһүр «Йөзек кашы» повестена эпиграфны хәтерлик). Әмма Айдарга урлап качкан бәхетен кулында тоту өчен артык дуамаллыгы комачауласа, «Пшыяцулка» каһарманына, киресенчә, бәхеткә тие-

нүдә бераз дуамаллык житми. Инде утыз ике яшькә житкән, ике бала үстерә торган Панины кабат эзләп тапса да, мәхәббәткә һәм бәхеткә ирешерме ул, хәзер үзен-үзе «аңгыра жан» дип битәрләүдән генә зиһене арттымы, жаны жылындымы аның? Ә хикәя, үзәк өзгеч сагышы булса да, әйтелмәгән эчке мәгънәсе белән шулкадәр якты, бу парлар һичшиксез табышыр, узган гомерләр кабатланыр да аймыл үтелгән юллар бер очрашырлар, дигән әкияти ышануга киләсең. Могжизалы көч шушыларга да ярдәм итмәсә инде... Табышкан бәхетле парларның исемнәре, ихтимал, бүтән булыр... Бәлки инде алар күлдә йөзгән пар аккошларга яисә язгы тирәктә сайрашкан пар былбылларга әверелгәннәрдер. Соң, бер могжиза булырга тиештер ләбаса!

Мәгъсүм Хужинны әсәрләрендә диалоглар кору остасы димәс идем. Каракаршы сөйләшү озынга китсә, хикәясендә Мәгъсүмчә сурәтләү көче югала башлагандай тоела. «Жир әйләнә сәяхәт»ендә әнә шундыйрак хәл. Мөгаен, шул сәбәптәндер, бик күп каләмдәшләреннән үзгә буларак, сәхнә әсәрләре язарга талпынганын да күрмәдек, иҗат гомере буена хикәя жанрына тугры калды. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, бәхет һәм фажигаләрен телдән әйтелгән сүзләр белән түгел, күңелләрен сөйләштерү аша жиңелрәк ача ул. Шунлыктандыр, каһарманнары гел дә аз сүзлеләр, уйчаннар. Уйлары аша алар Эт яисә Ат белән дә «сөйләшә», бер-берсен жиңел генә аңлый алалар, чишмә һәм күлләр белән дә серләшәләр — шул мизгелдә үз жаннарын да ачып салалар. Әнә Шушма буенда үскән удмурт кызы Любаша («Соң») баш каһарман Гәрәйшаны хәтта «сөйләшми торган абый» дип йөртә. Ә бит Любаша белән аның әтисе Петрух дәдәйнең бер сүзен дә жавапсыз калдырмый Гәрәйша, күңеленнән һәммәсенә жавап биреп бара: жөпли, бәхәскә керә. «Пшыяцулка» хикәясендәге житкән егет белән үсмер кыз сөйләшүе дә яңа танышкан парларның ул чактагы халәтен тулы ачып бетермәгән, күпмеседер күңелләрендә калган, күрәсең. Нәкъ шул чакта яшь кызның жанында беренче саф мәхәббәт бөреләнгән. Бу бөре бүтән чәчәкләргә жан бирерлек түгел — шуңа күрә балалары әтисез үсә, шуңа күрә унсигез елдан соң кабат очрашкан танышының жилкәсенә жиңел генә итеп баш куя ала. Хәзер алар сөйләшмиләр диярлек: Пани сөйләгәннәрне «аңгыра баш» күңеленнән генә, йә каршылыксыз кабул итә, йә элек шушыларны аңламаган өчен үзен аяусыз битәрли. Хикәя геройларының берни артына яшеренмәгән ап-ачык жаннарын нәкъ шушы мизгелдә укучы яхшырак аңлый.

Мәгъсүм Хужин мәхәббәт хикәяләрендә традицион «гыйшык өчпочмагы» корырга яратмый. Аның өчен Хәлил бар, Галиябану бар, ә Исмәгыйль — артык хан, әсәр каһарманы булу өчен үтә вак зат. Әйе шул, Исмәгыйльләрдән башка да фажига чыганакларыбыз азмы, үз-үзебезне һәм якыннарыбызны бәхетсез итәрлек үкенечле хаталар ясамыйбызмы? Хәер, зур хатасыз үткән гомерләрдә дә сагышлы-моңлы мизгелләр житәрлек ич. Тик күрмибез генә — жирдәгеләр язмышына карата сукыр һәм чукраклар без хәзер. Әдип күрсәтеп биргәннәренә дә илтифатыбыз әлләни түгел.

Мәгъсүм Хужинның «Зөбәржәт әби бирнәсе» дигән хикәясе кул йөзе кадәр генә жыентыкның («Авылым урамнары», 1978) дүрт битенә сыеп беткән. Йөгерешче Нуришан карт белән аның Зөбәржәте турында ул. Чын белән әдип фантазиясе бергә үрелеп сурәтләнгән вакыйгалар! Ышандырырлыкмыни, бервакыт шушы Нуришан, берни белән йөреп булмый торган юл өзегендә, күршесенең авыру баласын күтәреп, сигез чакрымдагы Чепья больницасына ярты сәгатьтә илтеп житкергән. Ә анда, Чепьяда, вакытында килеп житсә һичшиксез терелтә торган хирург бар икән. Чепьяның бик булдыклы хирургы дигәндә, өлкән кешеләр Николай Константинович Родосскийны, урта яшьтәгеләр хәзер республиканың клиник хастаханәсендә эшли торган Рәшит Сафинны күз алдына китерәләр. Хирурглары чын булгач, Нуришан картның да бу дөньяда чынлап та яшәгәнлегенә ышанасы килә. Үлеме, һәрвакыттагыча, бераз үкенечлерәк булган аның. «Көтмәде, тагын бер генә Сабан туе узганны көтмәде бу әжәл!..» — дип әйткән Нуришан, картлар йөгерешендә соңгы кат катнашасы килгәнен сиздереп. Аның шушы әманәтен үтәргә дип, соңгы алышка Зөбәржәт әби чыга. Чыга да, жиңә дә, чөнки бөтен мәйдан аңа теләктәш бүген. Бүләккә үзенең бирнәсен китереп тоттыруларына да гажәпләнәсе түгел, чөнки ул Нуришаны өчен йөгерде, димәк ки, бүләге дә Нуришанга эләкте. Гажәбе, бүгенге көннәр өчен чынбарлыкка охшамаганы шул: йөгереш юлында берәү дә Зөбәржәт әбине таптап-изеп узмый, ычкын моннан, жен карчыгы, әжәлеңне эзләп килдеңмени, дип жикеренми, киресенчә, әби егылгач, кайбер йөгерешчеләр аңа бер тын алып кабат күтәрелерлек вакыт арасы бирәләр. Хәер, ул кадәресе, бәлки хикәя авторына гына шулай күренгәндер. Кешеләр күңелендә башкаларга сизелми торган яктылык нурын һәм

рәхим-шәфкать жылысын күрә алу сәләте бар аның. Безне, үз укучыларын да, үзара миһербанлырак булырга чакыра, безнең арадан ук табып, аның үрнәкләрен күрсәтә. Җаннарны заман кырыслыгы һәм тупас мөгамәләләр корыта барган, сугыш авырлыклары изгән, җәберләрдән һәм кыйбла-имансызлыктан, әхлакый гарипләнгән чордашлар әдип хикәяләрендә фани дөньяның гади генә матурлыгыннан да илаһи ямь табып, соклана һәм гаҗәпләнә белеп яшәүче Шимай («Мәк чәчәге») һәм Биюш («Ак колын»), туган туфрагына һәм үз кыйбласына тугры Юлмәти («Юлмәти бәйрәме»), бүтәннәр хәсрәтен үз күңеле аша кичерүдән куаныч тапкан Зөлфирә («Җитәкләшкән таллар») булып күз алдында гәүдәләнә. Кайбер тәнкыйтьчеләр зур-зур әсәрләрдән милләт каһарманы, халыкка юл күрсәтерлек даһи эзләп изаланган һәм таба алмый интеккән арада, Мәгъсүм Хуҗин үз хикәяләрендә татарның асыл сыйфатларын, әдип-әхлагын, гыйшкын-моңын туплаган гади җир кешеләрен алдыбызга тезеп кенә тора. Нәкъ менә шундый гадиләр булганга һәм оста каләме белән сурәтләнгәнгә, андый кешеләрнең дөньяда чыннан да барлыгына, күплегенә ышанасың, алардагы күркәм сыйфатларны күршеңнең, якыныңның, ниһаять, үз-үзеңнең холкыңнан эзли башлыйсың, бераз тапкан да кебек буласың. Җир йөзе яктырып китә, офыклар киңәя. Күңеленнән шундыйлар белән гел очрашып тору әдипнең үзен дә рухи яктан көннәнкөн байрак итә, аңа иҗат көче бирә. Шулай булмаса, «Пшыяцулка» кебек әсәр дөньяга килер идемени?!

«Тормышта бер генә кешегә начарлык тели язып калганым бар,— дип сөйләгән иде Мәгъсүм Хуҗин, нииндидер күңелсез вакыйганы хәтерләп». Бик авыр чакта сабыйлар хакына кергән адәм турында иде ул. Шуны бер хикәясендә язар әле, дип көткән идем — һаман күренми. Явыз җаннар аның хикәяләренә бик авырдан үтеп керәләр шул. «Җүләр» исемле әсәрен күрегез инде. Укып чыгасың да хәйран каласың — җүләр турында бер сүз юк, чөнки автор бөтенләй бүтән хикәя уйлаган, анда җүләр дә, кешене баз өстендә яшәтү кебек миһербансызлык та кирәсе булган, тик кулы башка вакыйганы язган.



*Язучылар Туфан Миңнуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Рафаил Сафин, Мәгъсүм Хуҗин һәм Илдар Юзеев.*

Иң бәхетсез адәмнәрне дә тәмам беткән кеше итеп сурәтләргә, өметен кисәргә яратмый ул: күңел түрләрендә якты сакларлык бер урын калдыра, әллә нигә бер булса да җаннарын җылытырлык сәбәп бирә. Озак басылмый торганнан соң гына кулларыбызга килеп җиткән «Бәрәңге чәчәге» хикәясен укыгач, моңа тагын бер ышанасың («Идел» журналы, № 4, 1995 ел). Андагы баш каһарман Рәхимне һич тә аклый алмый ул: гаебенә күрә җәзасын да «бирә», шактый гомерен төрмәдә үткәрттерә. Әмма һәр кеше бәхет өчен туа, диләр. Рәхимнең дә аңа хакы бар иде ләбаса. Бар иде, бүтәннәр кебек сөяргә һәм сөелергә дә лаек иде. Әй-й, сугыш чоры үсмерләреннән кем генә бәхеткә һәм кеше кебек яшәүгә тиенде икән соң? Аларның бәхетсезлеген һәм фаҗигасен, эчке дөньясын һәм үзгә холкын аңлаучы да аз хәттә. Шул сугыш аркасында ирсез калган яшь хатын

Минзинә үсмер Рәхимнең чәчәкләрен бөредә килеш койдырды, бәрәңге чәчәгедәй керт кенә өзде. Аннары Минзинә «өйрәтүләре»н («Өйрәтәм, үзем өйрәтәм» диде ул аңа «теге» төндә) аның кызы Зәниядә сынап карау — хөкемгә китереп җиткергән әшәкелек! Икесендә дә балалары — улы белән кызы үсә бу бәхетсез атаның. Менә шул балалар, җитәкләшкән сабыйлар, белән беренче күрешүе аның — кануный һәм әхлакый яктан бозыклык пычрагына баткан яшь атаның — иң бәхетле мизгелләре!

Әйе, автор аны һич тә акламый, гаебен дә кичерми, киресенчә, бу очрашу Рәхимнең фаҗигасен тагын да зурайтыбрак күрсәтә. Шул ук вакытта үз героен күнел почмагындагы кеп-кечкенә яктылыктан, бер гөнаһсыз сабыйлар каршында яшь коеп җылы сүз әйтүдән, бушка узган гомереннән (ул чорларда кайсыбызның яшьлеге буш, түләүсез хезмәттә, кадерсезлектә үтмәде?) бер мәгънәсен табудан мәхрүм итәргә дә теләми. Бу мөнәсәбәттә хикәя авторы белән бәхәсләшү дә кыен. Чөнки Мәгъсүм Хуҗин — үзе дә сугыш чоры үсмере. Үз чордашларының асылын, бүтәннәр өчен ят булган холык-фигылен, зур бәхетсезлеген һәм кечкенә генә бәхетен аннан да тирәнрәк итеп тагын кем аңлар! Юк андый кеше, булса да сирәктер. Әдипнең «Курагай атлары»н укыгач ук (1970) шулай уйларга нигез бар иде инде.

Без Чыңгыз Айтматовның «Бәхил бул, Гөлсары» повестын да хәйран калып укыдык. Мәгъсүм Хуҗин «Курагай атлары»н шушы повесть белән бер елларда язган, ләкин без аның Соры биясен кыргыз далалары Гөлсарысы белән тиң күрә алмадык. Ә бит ике әсәрдә дә кеше холыклары атларга мөнәсәбәттә бик оста ачыла. Табигать бу җан иясләрен камиллек символы итеп яраткан, өстәвенә, аларга искиткеч тырышлык, чыдамлык биргән, язмышларын кешеләрнеке белән бәйләгән. Ил халкы бөтен яктан нормалаштырылган тормыш белән яшәргә мәҗбүр ителгән елларда, беренче эш итеп, йортта ат асрауны тыйдылар. Атларның да, кешеләрнеке кебек, гомер азаклары, шуңа якынлашканда күтәрелгән соңгы үрләре була. Ике әдип Гөлсары белән Соры биянең соңгы үрләрен кешеләр язмышы белән бәйләп, җаннарны тетрәндерерлек итеп тасвирлыйлар. Гөлсарының кечкенә тай вакытыннан бирле килгән хуҗасы һәм яклаучысы Танабай шушы озын үрдә үзенең катлаулы гомер юлын кабаттан узгандай була. Ә Соры бия «хуҗалары»ның алай күз алдыннан үткәрерлек гомер юллары юк әле, авыр язмышлары ачыла гына башлаган. Сугыш чоры үсмерләре ул пычрак көнне Арчадан «неграин дигән ягулык» алып кайталар. Атларның берсе дә үз йөген Курса тавыннан тартып менә алмый, берәм-берәм биш арбаны үр өстенә Соры бия меңгерә. Үзенең соңгы көче, калган гомере бәрабәренә! Авылдагы тае да ятим кала инде. «Әйтәм аны, кичә юлга чыгар алдыннан Бүлтерекне сыртларын кашып иркәләгән иде, колынын соңгы күрүе булган икән».

Малайлар бөтен икмәкләрен җыеп Соры бия хуҗасы Дуслайга бирәләр. Үзләренә берни калдырмыйча! Моны бала кулындагы сугыш чоры икмәгенең ни икәнен башка күпләрдән яхшырак белгән Мәгъсүм Хуҗин яза, шуңа ышандыра белеп яза. «Соры бия, Сорыкай, йә, аша инде, икмәк бит, тәмле бит ул, менә монысы минем үз телемем. Сорыкай, икмәк иң-иң тәмле ризык бит...»

«Чемченә башлады Соры бия! Без аның өстенә кәҗәннәребезне яптык, бозлы-карлы яңгыр аны туңдырмасын, дидек. Без аны егылдырмыйча тәртә арасында тоттык. Мин, аның муенынннан кочаклап, түшеннән сөеп, малайлардан хурланмыйча еладым».

Үзенең Курагай авылына кадәр кайта Соры бия, кайткач кына егыла. Шуннан соң кабат тормасына ышангач, атлар карауяы Шаһмәли аны суярга җыена.

«Бүлтерек колын Соры биянең аякларын бәйләгән дилбегәне тешләп тартып азаплана.

— Суймагыз! — дип кычкырдым мин. Соры биянең аякларыннан дилбегәне чишеп җибәрдем.

Соры бия ыңгырашкан-кешнәгән тавыш чыгарып куйды, аякларын җәеп ташлады, башын артка ыргытты.

— Булмый инде, балалар, соңлыйбыз аннары...— диде Шаһмәл абзый».

«Соңлыйбыз» диюе — әгәр үлүенә юл куйса, сугыш чоры «законнары» нигезендә, кешелексез түрәләрдән нинди җәзалар эләгәчәген искәртеп куюыдыр аның. Автор ул хакта язып тормый. Бу очракта да үз-үзенә тугры кала. Җәзадан, әлбәттә, Дуслай да өлешсез калмас иде.

«Ул мине күкрәгенә кысты:

— Дуслай энем, улым, син моннан китеп тор... Ачуланма син... Малайлар, барыгыз...»

Менә шундый хикәя. Без төрле телдәге китаплардан Гөлсарылар фажигасен генә укып-өйрәнеп һәм аның тасвирлану осталыгына сокланып, үзебезнең Соры бияләрне читтәрәк тә калдырганбыз. Әйе, Гөлсарының үз чоры өчен бер өстенлеге бар: аның Танабае шул соңгы үрдә үзенең гомер йомгагын сүтеп, изгелек белән явызлык, чын белән ялган көрәшендә намуслы исеменә ялгыш ягылган гаепләрдән арыну, ничек итеп партия сафына кире кайту турында уйлана. Ә менә Мәгъсүм Хуҗин каһарманнары беркайчан да ул дәрәҗәдә «партияле» булмадылар һәм аларны язган әдип тә соңгы елларгача әллә ни танылa алмады.

Әле генә чагыштырылган ике әсәр азагында кызык бер уртаклык бар: ат караучы Шаһмәли дә, чабан Танабай да чит кешегә «улым» дип эндәшәләр. Шаһмәли — Соры биядән, малай чагының бик авыр юллары юлдашыннан аерылырга теләмәгән, аны туганыдай якын күргән Дуслайның ул чактагы хәлен тәмам аңлаганга, җаны белән аны рухи кардәше, чынлыкта да улы итеп тойганга, бөтен күңеле белән әйтә бу сүзне. Ә Танабай, улым дип, дусты Чоронның улы Самасурдан партиягә кире кайтуда ярдәм сорый. Замана тәнкыйте Чыңгыз Айтматовның бу әсәре геройларын «эчке дөньялары бай, тирән фәлсәфи фикер йөртәләр» дип югары бәяләде...

Авылларның атлары гына түгел, этләре дә Мәгъсүм Хуҗинның шигырьдәй тирән хис, үзәк өзгеч моң белән мөлдерәп торган хикәяләрендә җан җылысы белән сурәтләнә. Шундый бер хикәясе эт исеме белән «Йөнтәс» дип атала. Хемәйрәнең дусты, сукыр кызның юл күрсәтүчесе булган ул. Хемәйрә хәзер больницадан кайтып килә — күзләре ачылган. Аны каршылаучылар арасында Йөнтәс тә бар. «Әнә ул алга төште. Әле башын, әле арткы санын чөеп-чөеп, уйнаклап чаба. Туктады. Нигә? Ә юк, тагын чабарга тотынды. Күр әле, ничек ялындырып кына каршылый Хемәйрәне. Адымлап кына килә башлады». Юк, бу очрашуның матурлыгын, «Оча кошлар» хикәясендә кешене сөендерүдән тормыш мәгънәсе табучы Шәфыйка белән Тимершаның киң күңеллелеген, «Мәхәббәт бит ул» хикәясендә Мәйсәрә белән телсез Ләбиб бәхетенең түгәрәклеген, «Кеше күңеле — үзе бер кояш» әсәрендә гади һөнәрче җанындагы хыяллар киңлеген сөйләп чыгу мөмкин түгел. Болар хакында әдип язганнарны күңел күзләре белән укып чыгарга, кайта-кайта укырга кирәк. Күп дистәләгән хикәяләренең һәркайсында диярлек безнең үкенеч тулы җаннарыбызга яктылык бирерлек кояш нуры балкый аның.

Мәгъсүм Хуҗинның легенда-хикәяләрендә бер отышлы үзенчәлек бар — фаҗигале язмыш ияләрен сурәтләгәндә дә әсәрен «вакытында» төгәлли белә. Аның каһарманнары мәкерле тормыш баткагында пычранырга, явызлыкка каршы явызлык кылырга түбән төшәргә өлгермиләр. «Курагай атлары»ндагы «баш-кисәр» Дуслай үлеп бара торган Соры биягә үзенең бик кадерле, «иң-иң тәмле» икмәк телемен бары тик бүген генә бирәдер, пычак астындагы атның аякларын бәйләгән дилбегәне дә бүген генә чишәдер кебек... Миһербансыз дөнья, сугыш вакыты кырыслыгы иртәгә шушы нәфис җанны да изәр, тупасландырыр сыман... Әмма мондый авыр уйлар бездә хәзер — хәвефле тормышыбыз чынбарлыгына ияреп кенә киләдер. Кешенең табигатьтән килә торган шәфкатьлелегенә, күңел байлыгына ышанган әдип исә укучының хәсрәтле уйлары артыннан бара алмый, безнең «караңгылык патшалыгы»н яктылык нурларыннан мәхрүм итми. Ул «Мәгарә» хикәясендә («Татарстан» журналы, 1997 ел, № 4) хәтта Миркадәмнең — каһәрле утыз җиделәр һәм кырык берләр баласының — кешелектән чыгып һәм хәтерен тәмам җуеп бетерүенә ышанырга теләми. «Балачакның уены искә төшмәслек булып онытылыр икән, әй... Коточкыч». Әмма Миркадәмнәрнең хәтере җуелуга «балачакның уены» һич кенә дә гаепле түгел. Аны «якты киләчәк хакына» акылсыз хакимнәр корган ипсез җәмгыять, кешелексез тормыш «тәртипләре» шул хәлгә житкерә. Шуңа күрә ул хәзер кешеләрнең исемнәрен дә телгә алырга теләми. Чөнки тормышның шундый юл алуы өчен: ил-көн белән идарә итүне залим хакимнәргә тапшырган, явызлыкның игелекне күмеп китүенә юл куйган кукләр гаепле.

— Мин үз исемемне генә беләм. Башкаларның исемнәрен күптән оныттым. Дөньягызны да, үзегезне дә исемнәрегездән мәхрүм иттем! — ди ул.

Мәгарәдә яшәүче мәхлүк җанның бу сүзләрендә тагын бәхетсезләргә дә өметсез карый белмәгән Мәгъсүм Хуҗинны таныйбыз. Үз каһарманын бетереп ташлый алмый ул, аның иләс-миләс, кинаяле сүзләренә тирән мәгънә бирә. «Миркадәмне кеше исеменнән мәхрүм итәргә маташу — гөнаһ!» — ди үзе дә. Чыннан да, Миркадәм кебек меңәрләгән мәгарә ияләрен кеше исеменнән сызсаң, аларны шушы төшерүчеләр хакында нәрсә әйтергә кала?

Әмма шундый авыр үткәннәр хакында гына уйлап, елап-сыкрап кына яшәү дә мөмкин түгел. Андый халәт әлеге уй ияләрен һаман изәчәк, рухын гариплә-чәк, ким дигәндә, чарасызлыктан үз-үзенә кул салу чигенә китерәчәк. Иң кулае — оныту, гафу итмәсәң дә, оныткандай итү сер бирмәү. Әнә «Куларада кәлтә уйный» хикәясендә үсмер башыннан философларныкы кадәр акыл үстергән «падишаһ кыяфәтле Сәйфера»н үзен милиционерлар үтергәнче кыйнаганда да елау тавышы чыгармый.

Иң җитди вакыйгаларны балалар исеменнән сөйләтү, иң фаҗигале хәлләрне балалар язмышы, аларның самими күңеле аша күрсәтү — Мәгъсүм Хуҗинның яраткан әдәби алымы. «Куларада кәлтә уйный» («Татарстан» журналы, 1997, № 4) әсәрендә — коточкычлыгы әле хәзергәчә беркем тарафыннан аңлатылып җитмәгән утыз ел дәһшәте нәкъ менә үзәктә балалар торганга һәм оста каләм белән сурәтләнгәнгә хәтерләргә уелып кала. «Куларада кәлтә уйный» хикәясендә әдип балаларның кара-каршы сөйләшүен дә Туфан Миңнуллинча оста, аларның һәр сүзенә тирән мәгънә, зур эчтәлек биреп үрә. Вакыйга да сөйләнә, сөйләүченең аларга мөнәсәбәте дә белдерелә:

— Минем әтиемнең бер гаебе дә юк ла! Кулак түгел лә ул! Аны нигә сөрсеннәр ди?

— Нигә? Нигәлеге нигә кирәк төрмәгә утыртуның? Безнең урамда ничә өй буш тора, санаганың бармы? Моннан куылган кешеләрнеке алар... Заман чуалышлары турында сорамагыз. Кирәк чагында үзем сөйләрмен. Сезгә байтак нәрсәне белергә ярамый, энекәшләр.

Соңгы сүзләр — Сәйферанныкы. Менә шушыларны яхшы белгән, бүтән малайлардан тирәнрәк аңлаган, вәхшәтне үз күзләре белән кат-кат күргән үсмер Югаргы Губаха читендә салыначак «шәп йортларда яшәрбез» дигән ак өметләр белән йөри, сеңлесен кулына күтәреп, иптәшләрен шул өйләр буласы ерак урыннарны күрсәтергә алып бара — җәһәннәм шартларында да ак хыяллы бала булып кала. Менә Сәйфераннның бу дөньяда әйтелә алган соңгы сүзләре:

— Әти... әни... сеңлем... Эне... кула... кәл... сә...

Шәп йортлар салынасы куларада малайларның баллы сөт алып килүен көтеп калган шаян кәлтә турында уйлап җан бирә Сәйферан. Чөнки, Мәгъсүм Хуҗин раславынча, чын кеше күңелендәге игелек, шәфкать иң ахырдан үлә.

Шулайдыр, синең хикәяләреңне укыгач, без дә моңа ышанабыз, әдип.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.**

Китап күзәтү

# ҖИРГӘ ТӨШӘ СӨЮ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

## РӘНИФ ШӘРИПОВНЫҢ «ЙОРТ ИЯСЕ» ИСЕМЛЕ ЯҢА КИТАБЫН УКЫГАНДА

Шундый халәт — тамчы суга сусап япа-ялгызым иксез-чиксез чүл буйлап барган чагым. Каршыма Хозыр-Ильяс килеп чыкты да... чүлмәк тутырып салкын чишмә суы салып биргәндер дисезме? Юк! Ул үзе дә сусаудан дөрләп китәр хәлгә килгән иде. Әмма ул миңа су табылачагына өмет бирде. Анда — чүлнең без белмәгән-күрмәгән тарафында — тирәндә, ком-таш таулары астында «чишмә бар икән» дигән сүзләренә ышандым мин аның.

— Ә син моны каян беләсең, әчтеңме үзең? — дип сорадым.

— Мин түгел, әниемнең әнисе эчкән булырга тиеш,— дип гаҗәпкә калдырды ул мине.

— Бәлки ул инде кипкәндер? — дидем мин ачуымны чак яшереп.

— Юк, кеше дә йөзем куагы кебек ул: дым кайда булса, шунда иелә, мин әле шул чишмә телендә, шул чишмә көенә җырлыйм. Әле шунда юл тотуым. Мин яшәгән җирләрдә чишмәләр корыды, җаным хәзер исән чишмәгә тарта. Син дә шунда барасың, тик бу хакта үзең белмисең генә,— диде дә, кулындагы таш кисәге белән пелт итеп кенә бармак очын китеп алды.

— Эч,— диде ул, бармагын минем авызыма якын китереп. Әмма бармактан тамган канның тамчысы да минем авызыма эләкмәде. Әйтерсең, җил исә дә кан тамчыларын читкә сибә, барысын да бер якка!

— Күрдеңме, чишмә анда,— диде ул. Тавышында тирән ышанганлык аһәңнәре яңгырап китте.

Без икәүләшеп кан сибелгән юнәлештә китеп бардык.

Болай да соңгы сулышта бара идем бит, инде аруымның чик-чамасы калмады. Хәлсезлектән егыла башладым. Хозыр-Ильяс уң кулын күтәрде: аның кулында китап иде. Каян нинди кодрәт тапкандыр, китапны ачты да укый башлады.

Бөек хисләр, сөю йолдызлары
Очып йөри хыял күгендә.
Чынбарлыкта бер тамчы наз тапмый,
Эссе чүлдә калдым бүген дә.

Шигырьне ишетүгә башым уйларлык хәлгә килде. Бу шигырь Рәниф Шәриповныкы! Мин бит аны таныган идем, шагыйрь итеп. Мин бит аның җанына шигырьләре аша гашыйк булган идем. Тик мин барыбер хәлсезләнеп җиргә авам. Инде бер дә тора алмам... тора алмамдыр. Чү! Хозыр-Ильяс тагы дәвам итә:

Безнең кебекләргә табыналар,
«Сөбханалла!» — диләр кайвакыт.
Сезнең кебекләргә абыналар,—
Сүгенәләр дөнья шаулатып.

Юк инде! Күтәреләм. Ул китаптан мин дә шигырьләр беләм. Шигырь — минем җан ярам ул...

Авыр сүз әйтеп ташладым,
Усалланган бу димә.
Йомшак булса да кулларың,
Зинһар, ярама тимә.

Шигырьне ишетүгә йөзендәге газап эзләре юылып төшкәндәй булды. Без тагы барабыз һәм... көтмәгәндә кайнар чүл уртасында да каршыбызда таң калырлык гүзәл гөл пәйда булды. Хозыр-Ильяс шул чәчәккә үрелде, «Өзеп бирәм!» — диде. Тик кулларын утка пешергәндәй кире тартып алды. Бармагыннан тагы кан тама иде. Мин бу юлы аның бармагына авызымны куймадым, мин аннан кычкырып көлдем дә аның кулындагы китаптан тагы бер дүртьюллык укыдым:

Шаккатырлык табигатьнең
Сүзсез кисәтү теле —
Җирдә иң матур чәчәкнең
Сабагы чәнечкеле...

Без икәүләшеп көләргә тотындык та туктап калдык: без чишмә эзли идек бит әле! Хозыр-Ильяс кулындагы китапны комга куйды да саклык белән генә тышын — чишмә капкачын ачты. Китап зурлыгында гына чишмәнең мөлдерәмә тирән суын күреп таң калдым. Чишмә һаман җырлый икән:

Җир җыерчыкларын урый
Ташкын сулар толымы.
Кышның ак сөтен суыра
Язның ала колыны.

Ә кояш болыттан качып,
Кырлар белән үбешә.
Ялгыз каен юл буенда
Елый-елый су эчә.

(«Язгы этюд»)

Бу юлларны ишетүгә җаным тетрәнде. Юк, юк, Хозыр-Ильяс, эчмим! Тик ялгызымны гына калдыра күрмә, миңа ата-бабалар җиренә, алар чишмәсе типкән төпкелгә барып җитәргә кирәк... Ач чишмә капкачың — тыңла:

Тел-нәселнең ничек киселгәнен
Аңламыйсың әле үзең дә.
Гомер түгел, алтын мизгел кала
Онытылган һәрбер сүзеңдә.

Еллар үткән саен чит көйләргә
Аз җырлана, сирәк биелә,
Карт агач та еллар үткән саен
Тамырларга таба иелә.

Хозыр Ильяс, сиңа ни булды? Кинәт кодрәтлем сыгылып төште дә:

— Инде син мине алып бар. Кая, ничек икәнен аңладың бит,— диде дә, күзләрен билгесезлеккә юнәлтте. Тик бу кадәр дә куырган кояш астында тагы бер минут кына да тик ятырга мөмкин түгел, ә мин аптыраашта калдым. Мин кая барам әле?

— Кыйблаң кая, кыйблаң? — дип телгә килде ул.— Без бит чишмә эзли идек.

Мин йәнә чишмә капкачын ачтым, Йә Ходам, чишмә шул кыйбланы күрсәтү җырыннан башлана икән бит:

Дүрт юнәлеш җирдә. Тик кыйбла юк
Кимсетелгән иман сагында.
Каның саклап, җаның сатты күпләр
Ай тотылган төннәр ягында.

Якты көннәр көтеп түрәләрнең
Юллар бутап йөргән чагында,
Калдык инде, калдык без адашып,
Ай тотылган төннәр ягында.

Анасын да белми, баласын да,
Карасын да күрми, агын да.
Телсез, денсез үле җаннар йөри
Ай тотылган төннәр ягында.

Якты көннәр өчен уяуларның
Кыйбла эзләп үлгән чагында,
Кем уятыр безне, кем уятыр
Ай тотылган төннәр ягында?..

Ах, йоклап китә күрмик. Хозыр-Ильясны көч-хәл белән иңнәремә салам. Һәм ис-акылларым китә: үзем дә чак бара идем бит әле!

— Зөләйха! Син Зөләйхамы? Йосыфны кая алып барасың?

Минем тавыш килгән якка да борылып карар хәлем юк. Тик барыбер эндәшәм:

— Син кем? Кая юл тотасың? Кыйблаңны беләсеңме?

— Беләм,— ди тавыш,— минем кыйблам — мәхәббәт. Синең кулыңда мәхәббәт чишмәсе, бер йотымын гына эчерт.

Мин китап-чишмәнең капкачын ачам, ә ул эчми, ул укый:

Җирдә бернинди киртә юк
Без генә белгән сергә.
Үзебез кавышмасак та,
Хыялларыбыз бергә.

* * *

Илаһи тойгылар эзләдем
Тынгысыз хыяллар нурында.
Яраттым, ялгыштым, туймадым —
Уйладым мәхәббәт турында.

Тавыш тыела алмый, тагы, тагы укый:

Онытуы авыр булды сине
Килеп керәсең дә уема,—
Җиз кыңгырау тагып атларыма
Кайтам ясалмаган туема.

Хозыр-Ильяс — Йосыфым кинәт җиңеләеп китә дә, иңемнән төшеп аякларына баса. Карасам, ул шундый чибәр егет икән. Мин аңа гашыйк булмаганга гына ул шундый авыр булып, шундый карт булып тоелган икән. Әнә мәхәббәт кыйбласы нинди канатлар бирде үзенә!

Ә тавыш һаман укый:

Көйдем... Сөйдем... Ирештем...
Күкләргә менеп төштем.

Төштем сагыш җыярга,
Кимеп күпме хыялга.

Җир болытлы, күк аяз.
Шулмы сөю? Шулмы наз?

Кая бәхет? Кая моң?
Гүргә иртә... Күккә соң...

Безгә ифрат җиңел булып китә. Укы, тагы укы, дибез бертавыштан. Ләкин ул туктап кала. Чишмә-китап-

ның битләрен куллары белән каплый. «Ачма! Анда су болганчык»,— ди ул безгә монсу караш ташлап.— Анда таш күп».

— Китаптамы? Китап ич ул! Анда нинди таш булсын!

— Җырларында. Чишмә ныграк челтерәсен өчен сүз дип аталган ташларны кирәксә-кирәкмәсә дә салганнар...

— Алар бит поэмалар,— дим мин, китапны үзем актара башлап.

— Ачма! Алар чүлдә ярдәм итмәячәк. Мәхәббәт ясалмалылыкны кичерми. Алар — озын. Тик шагыйрьнең көче — мәхәббәтен йодрык кадәр йөрәгеннән тугыз баллы ярсу белән кысып чыгарганы. Дүрт кенә юллык назлары — шагыйрьнең осталыкка, тирәнлеккә ирешүе. Бу аларның чынлап яратканда җанынннан тамганнары.

— Әй, мәхәббәт җырчысы, син аларны кабул итә алмадыңмыни? Чүлдә дә эчмәслек түгел лә инде. Исемнәре нинди матур! «Алмагачлар сагышы»! Ә бар бит, бар табышы:

...Сыкрап-сыкрап сыгыла ла,
Таштан түгелдер лә ул.
Үткән-беткән, күзләр җиткән,
Үз язмышын белә ул.

— Әйе, әйе, үз язмышын белә ул... Тамчыларына сүз әйтмим, агымнары... Хәзер поэмалар да кешеләрнең сулышлары сыман кысылды. Йә ул саташып сөйләнүләр, йә булмаса артык дөньяви, артык гади фәлсәфә, маңгайга бәреп тора димме. Ә бу олы әсәрнең поэзиясен сүндерә. Шагыйрьнең үз сүзләре белән генә әйткәндә:

Олырак та, моңлырак та иден
Яшь-җилкенчәк сөйгән кешеңнән.
Синең гомер алда, яшьлек — артта,
Сөю — буш уртага эленгән.

Мәхәббәт сөйли, нәфрәт түгел. Булдырыйм дип сөйли, бетерим дип түгел.

— Сөю үз урынын тапмый адашып йөрсә, җыр яңгырамый бит ул. Сездә җырның җыртыгы юк диләр, бәлки аларны да җырлаучы табылыр. Тик мин җыр хакында ялган сүз әйтсәм, «Йорт иясе» ишетеп торыр да, миңа каршы «Җинаять эше» ачар.

— Син ул поэмаларны да беләсеңмени? — дип исем китә минем.

— Беләм,— ди ул,— «Йорт иясе». Аның да ачы хакыйкатькә төрелгән тамчыларын йоттым мин:

Тик шул гына иде әйтәсе сүз,
Безгә шундый тормыш әлегә —
Ишегенә һәркемнең дә инде
Килеп баскан кара күләгә.

Әйе, дим мин,— уйландыра, сискәндерә...

Ә «Җинаять эше»ндә җинаятьнең иң тирән тамырын шагыйрь болай атый:

Бар идек без, бай идек без.
Тик бер генә бездә хурлык —
Телен, денен, илен саткан
Куштаннарга да бай булдык.

Мәхәббәт җырчысының иреннәрендә мыскыллы елмаю барлыка килә: «Шул да булдымы инде байлык? Куштырнаклары төшеп калгандыр инде...» — ди.

Каршымдагы Хозыр Ильяс — Йосыфым йәнә хәлсезләнә башлады. Күзләре йомылды. Ул саташа иде.

— Коткарыйк! — диде мәхәббәт җырчысы.— Ул төшендә җан бирә. Укы! «Төш»не укы!

Укыйм:

Үпкә белән сыкрап үлдем төштә.
Үлдем, ләкин кисәк уяндым!
Уяндым да мескен бер кол кебек
Төш кенә бу диеп куандым.
Әҗәлдән соң тоташ ләззәт, диләр...
Әллә тормыш моңлы төш микән?
Уяныбыз, куаныбыз, ләкин
Җан бирүләр кыен эш икән...

Кодрәтлемнең күзләре ачылды. Аларга нур инде. Һәм ул телгә килде...

— Ә син ник бу чүлдә ялгыз гизапланып йөргәнеңне беләсеңме? — диде ул.

— Мин мәхәббәтемне эзлим! Җирдән тапмадым, бәлки ул күктәдер?

— Син хөкем ителгән,— диде, соңгы шигырьне ишеткәннән соң йәнә гүзәл егеткә әверелгән Йосыф.— Тыңла!

Бу исә Рәниф Шәриповның «Йорт иясе» китабындагы «Хөкем» шигыре иде:

Пар табып та чиксез ялгызлыкта
Аз түгелдер гомер иткәннәр.
Канатларын күпләр яшергәннәр,
Күпләр бөтенләйгә кискәннәр.

Ә кемнеңдер канатлары исән,
Язмыш кына ләкин кителгән.
Мәхәббәт, дип, күккә үрелгәннәр
Ялгызлыкка хөкем ителгән.

— Мин, мин...— дип шашып калды җырчы.

— Әйе, син...— диде, кинәт күз алдыннан юк булган Хозыр Ильяс — Йосыф тавышы.— Син сөю йолдызларының җиргә төшүләрен күрмисеңмени...

Инде август. Әле һаман эссе.
Ява бары йолдыз яңгыры.

Җиргә төшә сөю йолдызлары
Үз-үзләрен юлда яндырып.

— Ишеттеңме? Күрдеңме? — диде тавыш.

— Ишеттем, күрдем, — диде мәхәббәт җырчысы һәм тагы очынып сөйли башлады:

Сүнәм дә тагы кабынам,
Туйсам да кайчак сагынам.
Күрсәм дә, бик еш абынам,
Мин — мәхәббәт.
Ә син кем?
Иреннәрең синең ник тозлы?

Инде икенче күренмәгән тавыш җавап бирде:

— Кабынып, сүнә алмаган,
Сагынып туя алмаган,
Абынып, тора алмаган,
Мин — ялгызлык...

О! О! О! Болары да Рәниф Шәрипов шигырьләре! Мин ялгызлык белән күзгә-күз карашып, бары шушы шагыйрьнең шигырь китабын укыганмын икән. Яхшылары өчен җан атып, кыеннары өчен кыен ашап... Ә миңа җан да, кан да биреп барганы шигырь үзе иде. Һәм ниһаять, мин тып итеп җиргә төшеп бастым. Ә нәрсә? Сөю йолдызлары да җиргә төшкәнне! Ә җир — җир инде ул! Ул сине тиз айныта. Нәкъ шундый мизгелендә язгандыр Рәниф менә бу шигырен:

Безнең гомер озын булыр —
Тормыш көйле.
Сау торабыз иртән, сау ятып.
Гамь чебене тешли икән,
Йә эчәбез,
Йә елыйбыз дөнья шаулатып.

Юк хәсрәтен барлап,
Сасы хәмер эчеп,
Елап яткан татар малаен
Бер әрлисе килә,
Тәртә-тәртә
Тукай каберенә маңгаен.

Шулай! Уртак дулкында без синең белән, Рәниф! Юкка гынамыни мине синең дөньяң адаштыра. Тик җиргә төшсәң, кирәк-кирәкмәс чүп-чарга да абынасың. Бу китапны укыганда моннан ун ел элек бер шигырь юлыннан соң нокта түгел, өндәү билгесе куярга иде дигән тәкъдимем искә төште дә, үз-үземнән мыскыллы көлеп куйдым. Юк, ул өндәү билгесе дә куелуын куелмаган. Һәм өндәү генә булса иде әле... Ул тыныш билгеләренә: «Все знаки препинания, марш по своим местам!» — дип фәрман гына язып куясы калды инде. Өстәвенә, ритм чатаклыклары дигме... Хәзер аңлаган кеше хөкүмәт бакчаларына баласын тәрбиягә дә бирми. Ә без, кем әйтмешли, «поштальон төзәтер әле», дип һаман шигырьләребезне редакторларга тәртә торабыз.

Хәзер «редакторлар кирәкми», дигән сүзләр дә ишетелгәли. Тик мин чын редакторларга мохтаҗлык икеләтә-өчләтә артты дияр идем. Сүзләр дөньясы да дөньябыз кебек буталды бит. Кагыйдәләр дә... Ә редакторлык эше ул гаҗәеп белем таләп итә, вөҗданның иң югарысын.

Заманында редакторлык белән цензурасын бергә бутап адаштырдылар да. Хәзер цензура бетте дигән булып, редакторлыкны да пычратмакчы булалар.

Әйе, йолдызлар җиргә төшә, дибез икән — ник аларны таптап йөрергә?! Чуар тормышыбызны бизәп, хис йолдызлары сибәрдәй шигырьләребезгә игътибарлырак булса идек.

**Нәҗибә САФИНА.**

# КИЛӘ ИКӘН ХАТЛАР... ҮТКӘННӘН...

Адәм баласының җаны шулай яратылган күрәсең: гомер узган саен узганнарны сагынып искә алу хисе арта бара. Артта калган сәламәт яшьлек, язгы яфраклар төсле кер кунмаган хисләр, дөнья алыш-бирешенә корылмаган ихлас дуслык, авыр чакта таянырлык турылыклы дуслар сагындыра... Узганнарны хәтердә яңарту хисе шул вакыттагы игелекле эшгамәлләрне бүгенгә күчереп, киләчәккә калдырасы килүдән дә хасил булмый микән әле?

Узган гомер сәхифәләре хәтергә уелып калу белән бергә, язып барган көндәлекләр, истәлек дәфтәрләре, кайчандыр сөйгәнең бүләк иткән чиккән кульяулык кебек кадерле ядкарьләр, үзара язышкан хатлар рәвешендә дә саклана.

Хатларның төрлесе була. Була рәсми хатлар, дуслык, туганлык хатлары, үзеңнән дә яшереп кенә саклаган мәхәббәт хатлары да була...

Яши-яши шуны искәрәм шикелле: хәзерге вакытта кешеләр бер-берсенә гозере төшмәсә, хатлар язышып артык мәшәкатьләнмиләр дә бугай.

Мин үземнең архивымдагы бернинди исәп-хисапка корылмаган, җан жылысы белән язылган хатларны укып утырырга яратам. Кайта-кайта укыйм мин андыйларны. Еллар узган саен ул хатлардагы фикер-хис агышының яңа якларын аңлаган кебек булам, аларны язган дусларым миңа тагын да тулырак ачыла барган шикелле тоела. Уйлап куям: ә бит хатлар шәхесне тәрбияләүдә, аны формалаштыруда шактый катнашалар икән. Иҗат кешесе өчен мондый хатлар аеруча мөһим. Без иҗат кешеләренең элек-электән бер-берсенә хатлар язышкан булулары турында беләбез инде. Алар көндәлек матбугатта да, китапларда да басыла торалар. Беләсе иде: бармы икән хәзерге вакытта иҗат әһелләренең үзара әчкерсез, бер-берсенең иҗатларына хәерхаһ булып хатлашулары?

Мин сугыштан соңгы еллардагы шагыйрьләрнең остазы булып яшәгән халык шагыйре Сибгат абый Хәкимнең үземә язган хатларын «Казан утлары» журналында игълан иткән идем инде. Бүген мин абыем дип әйтә алырлык тагын бер әдибебез — Шамил Бикчурин хатларын укып, шул елларны, Шамил абый шикелле үк миңа әдәби дөньяга чыгарга булышкан башка мәрхәмәтле һәм таләпчән абыйларны да хәтеремдә барлап, мәрхүм булганнарын да, әле, шөкер, исән булганнарын да рәхмәтле бер сагыну белән искә алам. Безнең буын әнә шушы, сугыштан соңгы әдипләрнең яшь каләм әһелләренә карата остазлык итү гамәлен дәвам итәме соң? Хәзерге катлаулы заманда (ә заман кайчан гына катлаулы булмаган ул?) без — иҗат кешеләре бер-беребезгә карата суынмадыкмы, бер-беребезне, туганнарыбызны оныткан кебек, оныта башламадыкмы? Әдәби тәнкыйть дигәнебез дә иҗатташларына карата битарафка әйләнә бара түгелме? Ә булган тәнкыйть сүзләрен кабул итүдә күңел тарлыгы, яхшылыктан начарлык эзләү өстенлек алмыймы? — Күңелдә әнә шундый борчулы сораулар кайнаша... Сорауларыма, шик-шөбһәле уйларыма җавап эзләгәндәй, мин кабат өлкән Адашымның — Шамил Бикчуринның ихлас хатларына текәләм.

Менә аның миңа — Мәскәү өлкәсендә солдат хезмәтен үтәүче шигърияткә гашыйк егеткә — язган беренче хаты:

*«Адаш! Берничә шигырең басылган «Ильич васыятьләре» газетен җибәрәм. Миңа аларны Әсрар Галиев тапшырган иде. Киләчәктә дә әйбәт әсәрләреңне җибәреп тор. Безнең «Ильич васыятьләре» каршында әдәбият-сәнгать берләшмәсе эшләп килә. Мин — аның җитәкчесе. Тиздән иң әйбәт хикәяләргә, очеркларга һәм шигырьләргә конкурс ачып җибәрергә ниятлибез. Катнаш, давай! Беләм*

*инде, солдатның язу өчен мөмкинлеге күп булмый, мин үзем солдат булган кеше. Җиде ел авиациядә хезмәт иттем. Шулай да тырыш...*

*Сәлам белән, Адашың*
*Шамил Бикчурин.*
*1 февраль, 1959 ел.»*

Биредә шуны да әйтеп узу урынлы булыр: әлеге конкурста минем «Тыңланмаган моңнар», «Ярышта», «Кызыл кәшимир яулык» һәм башка шигырьләрем беренче урынны яулаганнар иде. Бүләк буларак җибәрелгән акчалары (утыз сумлап иде шикелле) миңа кыска вакытлы ялга туган ягыма кайтып килер өчен бик тә ярап куйган иде.



*Адашлар — Шамил Бикчурин белән Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты Шамил Маннапов. Яшь шагыйрьнең солдаттан кайтып укый башлагач, әлегәчә хат аша гына таныш булган язучы абыйсы белән беренче очрашу мизгелләре. Татарстан язучыларының V съезды барган көннәр. Февраль, 1963 нче ел.*

Әнә шулай Шамил абый Бикчурин белән беренче танышлыгым Лениногорскига барып, нефть эшенә урнашкан сабакташым, Әлки район сабан туйлары батыры, үзе дә каләм тибрәткән Әсрар Галиевнең җинел кулдан биргән «рекомендациясе» белән башланып киткән иде. Соңыннан, мин Казан университеты студенты булганнан соң, әлеге танышлык иҗади дуслыкка әверелеп, дәвам итте. Дөрес, Шамил абыйның Казанда башка яшь дуслары да күп иде. Үзе житәкләгән «Чишмәләр» әдәбият-сәнгать берләшмәсендә тәүге чирканчек алган Әхмәт Рәшитов, Җәмит Рәхимов, Нәҗип Мәдияров, Гәрәй Рәхим, Рәшит Бәшәр, Рөстәм Мингалим, Җәүдәт Дәрзаман, Альберт Хәсәнов, Әсрар Гали, Әнвәр Шәрипов, Зиннур Насыйбуллин, Мәхмүт Газизовларның барысын да ярата, һәркайсының иҗатларын җентекле күзәтеп бара, уңышларына куана, кимчелекләрен үзвакытында күрсәтеп, төзәтергә ярдәмләшә иде.

Күңеле киң иде Шамил абый Бикчуринның, ул безне үзенә тиң итеп ихлас әңгәмә кора белә иде. Казанга килгән чакларында, гадәттә, «Заря» кунакханәсенә урнаша һәм тиз арада безне үзенә чакырып ала торган иде. И-и, аның белән бергәләшеп кич утырулар! Үзе бер гомер диярлек. Әмма ул кичәләрдә Шамил абыйның язганнарыбызны яхшук «сүтеп», үзебезне елатканчы кыздырып алган чаклары да булмады түгел, булды. Вәләкин без, үз әтисе «пешекләгәнгә» үпкәләмәгән балалар сыман, аннан читләшмәдек, киресенчә, рухан якынлаша гына бардык. Хәлбуки, без — әдәбият мәйданына юл яра башлаган яшьләр — шигъриятнең үзе сыман ихлас күңелле өлкән иптәш-остазларга бик тә мохтаж идек шул.

«Чишмәләр» әдәбият-сәнгать берләшмәсенең 20 еллык юбилеена ул безнең барыбызны да Лениногорскига чакырып китерде. Шунда үз эшенең нәтиҗәләре,

үз шәкертләре белән горурланып, шатланып-очынып йөрүләре әле дә күз алдымда...

Нефть районнарындагы һәм Казандагы өлкән әдипләрнең күбесе белән без Шамил абый Бикчурин аша танышып, аралашып киттек. Уен-көлкене, җор сүзне ярата торган ачык күңелле кешеләргә хас булганча, ул һәркем белән бик тиз уртак тел табучан, аралашып китүчән иде. Чын мәгънәсендә яраталар иде Шамил Бикчуринны. Ул һәрвакыт яшь талантлар белән уратылып алынган булыр, ул булган җирдә һәрвакыт ихлас, җанлы әңгәмә хөкем сөрер. Аның ялгыз калып, моңаеп утырганын бер дә хәтерләмим... Аны һәрвакыт сагынып искә алучыларның күплегенә иманым камил.

Әнә ул, үзенең хат юлларыннан: «И-и, Адаши-әл Маннапи, дивана, син әллә кайчангыларны хәтерлисең икән! Нигә соң шул сүзләренне миңа элегрәк язмадың хатларыңда)» — дигәндәй башының ике тарафына ишелеп төшкән Тукташныкыдай арыш саламы төсле саргылт чәчләрен тәмәкедән саргая башлаган озын бармаклары белән төзәткәләп, эре тешләре белән балкып елмая кебек. Әй, Адаш абый, без чын кешегә җылы рәхмәт сүзләре әйтергә гел дә соңга калабыз шул. Дөньяның фанилыгын, адәм балаларының бу дөньяда өч көнлек кунак кына икәнен онытып җибәрүдән микән бу хәл?.. Инде үзенә дә, тиздән булачак юбилееңбелән котлап, рәхмәт сүзләремне язып җибәрер идем дә бит, шагыйрь әйтмешли: «Киләчәккә хатлар барып җитә, ә үткәнгә хатлар бармыйлар...» Әмма үткәннәргә бармаса да, үткәннәрдән килә икән хатлар. Әйе, килеп тора узганнардан безнең бүгенгебез өчен бик кирәкле нурлы хатлар. Алар бик интим, бер кеше өчен генә язылган булсалар да, тора-бара аларның әһәмиятләре арта. Шунлыктан мин әдәбиятыбызда «Каты токым», «Тирән катлам» кебек романнары, «Тальян моңы», «Бергә, гомергә» шикелле музыкаль комедияләре, күпләгән хикәя һәм очерклары белән игелекле эз калдырган, әсәрләре украин, словак, урыс һ. б. тугандаш телләрдә басылып, илкүләм конкурсларда җиңүгә ирешкән, «Почет билгесе» ордены кавалеры Шамил абый Бикчуринның үземдә сакланган кайбер хатларын башкаларга да укытырга булдым.

Шамил МАННАПОВ,<br>Ноябрь, 1996 ел.

Шамил туган!

Бу сәламнәрне сиңа Лениногорск каласыннан адашың яза.

Син бераз үпкәлисең дә булыр. Ничаклы хат яздым, ничаклы котлаулар яздым, шунда бер «кош теле» кадәр генә хәбәр дә җибәрми, Казанга килеп тә кермәде, дип ачуланасың булыр. Мин гаепле, гафу ит. Юк әле, бөтенләй үк үземне гаепле дә санамыйм, Казанга килгәч, ике тапкыр укыган җиреңә бардым, очрата алмадым. Сәгадәт *(университет укытучысы Сәгадәт Ибраһимов. Ш. М.)* әйткәндер инде. Мин аны күрдем, сөйләштем.

Җибәргән шигырьләреңне ала торабыз, күңелгә ошаганнарын газетада бирә барабыз. Менә бу әдәби биттә тагын ике шигыреңне урнаштырдык. Калганнарын ошатып бетермәдек. Нечкәләп язып тормыйм.

Әсрардан да *(сүз — язучы Әсрар Гали турында. Ш. М.)* хат алдым әле. Ул хикәя җибәргән. Мин аңа кайбер киңәшләремне яздым. Ул быел синең янга заочно укырга кермәкче. *(Бу вакытта Әсрар Гали Прокопьевскига шахта эшенә киткән иде. Ш. М.)*

Ярый, хатка язып сүз бетмәс. Казанга баргач, күрешеп сөйләшергә язсын. Бәлкем язучылар съездына кадәр килеп булмас.

Хәзер редакциядә эшләмим инде, шулай да, әдәбият түгәрәге җитәкчесе буларак, килеп, әдәби битләр оештырып китәм. Өйдә профессиональ язучы булып эшлим.

Яңа әйберләрең булса, җибәр.

Сәлам белән, Шамил Бикчурин.

21/V—62 ел.

Сәлам Лениногорскидан!

Адаш!

Хатыңны һәм шигырьләреңне алдым. Бик дикъкать белән укып чыктым. Өч шигырең арасыннан икесен бирергә була дигән карарга килдек. Минемчә, шигырьләрең урта кулдан әлләни узмаган. Ярый инде, адаш итеп басарга була. Ну туйдырды инде бу космос турындагы шигырьләр! Бик тапталган тема инде ул ракета һәм космослар. Тик без аны төрле формада, төрле стильдә һәм аз-маз детальләрне куйгалап кына бирәбез. Моннан бит әлләни яңалык ясап булмый. Сиңа тапталмаган темалар эзләргә тырышырга кирәк. Син инде шигырь яза беләсең.

Җыентык әзерләү анысы яхшы нәрсә. Беренче мәртәбә китап чыгарганда аны башта секциядә уку мәҗбүри. Анда яхшы дип табылса гына, нәшриятка бирәсең. Аны балалар-яшьләр редакциясенә бирергә кирәктер. Аның мөдире Кыям Миңлебаев. Сафа Сабиров — зурларныкында. Секциядән үтсә, анысын үзең карарсың. Казанга шушы араларда яшь язучылар киңәшмәсенә барып чыгармын, ахры. Җыентыгыңны шунда карап чыгарбыз, секциягә тәкъдим итәрбез. Минемчә, җыентыкны берәр поэма белән башлап җибәрү яхшы булыр иде. Гадәттә, шулай эшлиләр. Аннан бер иллеләп шигырь кирәк булыр.

Үземнең хәлләр беркөе. Әле берничә көн генә элек яңа пьесаны тәмамлап, Әлмәт театрына тапшырдым. Яңа елга өйрәнә башлыйбыз, диләр. Яңа әйбергә тотынмаган әле.

Әсрардан хат алып торам. Ул Казаннан кайткач, телеграмма да суккан иде. Малае бар икән.

Синең «Совет әдәбияты»ндагы *(хәзерге — «Казан утлары». Ш. М.)* шигырьләреңне күрдем. Анда басыла башлау — чын әдәбиятка юл дигән сүз инде ул. Шулай да синең шигырьләреңне әзрәк кертмәннәр. Яхшылары, анда керердәйләре шактый бар иде бит. Ярый, әз булса да, төкле аягы белән булсын.

Ярый, адаш, хуш.

Казанда күрешүне көтеп:

Шамил Бикчурин.

16/X—62.

Сәгадәт Ибраһимовка һәм мине белгәннәргә сәлам җиткер.

Адаш!

Сиңа күптән-күп сәламнәр!

Вә янә дә килеп, Гөргөри белән Рөстәмгә *(сүз Гәрәй Рәхим белән Рөстәм Мингалим турында. Ш. М.)* минем бетмәс-төкәнмәс сәламнәремне күндерерсең дип ышанам.

Сиңа үзебезнең газетада *(сүз Лениногорскида чыгып килүче «Ильич васыятьләре» турында)* чыккан бер шигыреңне салам. Калган ике шигыреңне үзегезгә багышланган әдәби биттә бирербез дип уйлыйм. Ул әдәби бит шактый соңарды. Әнвәр Шәриповның хикәясен көттек. Ул килде, инде ике фото сорыйлар. Берсе — университет күренеше, икенчесе — әдәби түгәрәгегез белән төшкәне. Минемчә, тырышканда аны эшләп була. Аннан Гәрәй Рәхим берәр генә булса да шигырь салсын иде. Аның «Әнкәйгә» дигән шигырен алдан чыгарып куйганнар. «Үзе юкның күзе юк» бит. Мин хәзер «тиле студиядә» редактор булып эшлим. (Ай ярымнан бирле инде).

Үткән номерларда Р. Мингалимовның ике шигырен бирдек.

Менә минем әйтәсе килгәннәр шул иде.

Үзегезнең барлык әдипләрегезгә сәлам.

Мин Казанга килеп чыгу мәсьәләсен алдан хәбәр итәрмен. Апрель азакларына таба барырга исәп. Тик яңа эштә ничек карарлар?

Ярый, сөйләшербез.

Хуш.

Ш. Бикчурин.

31/III—65.

Адаши әл-Маннапи, исәнме?

«Тамырлар»ыңны, ниһаять, йолкып алдык. *(Сүз минем Татарстан китап нәшриятында 1972 елда нәшер ителгән шигырьләр китабы турында бара. Ш. М.)*

Рәхмәт. Китабың шактый гына солидный чыккан икән, малай. Әле заманында шигырьләр өчен мондый зур урын олы-олы абыйларга да бирелми иде. Ә яшьрәкләрнең күп булса ярты, бер табак булып чыга иде. Шигырьләр өчен ярыйсы гына китап инде бу.

Әлбәттә, хикмәт калынлыгында түгел, жисемендә. Бу җәһәттән караганда да шигырьләрнең сыйфаты элеккеләренә, бигрәк тә «Адымнар»га караганда күп өстен. Монда инде син чыннан да олыгаеп, житлегеп килгән шагыйрь булып атлыйсың, күрәсең, әдәбиятта балалык чорыңны кичерәсең, житди кеше булып барасың. Анысы бик куанычлы. Журналистика өлкәсендә дә бит син башта бик «оялчан» идең (робкий, янәсе). Хәзер мин сине иң оста журналистларның берсенә кертәм. Боерган булса, мондый барьерны шигърияттә дә тиз үтәрсең дип ышанам. Бигрәк тә моны хәзер китабыңа кергән лирик шигырьләрең раслый. Үзеңнең шәхси халәтеңә, язмышыңа, тормышыңа кагылганрак шигырьләрне син бик уңышлы язасың. Алар җылы, алар тирән, алар моңлы. Ә менә риторик шигырьләргә килгәндә, әле алай түгел. Мин ул шигырьләрне язу өчен синең сәбәбеңне (причина түгел, ә повод) сизмим, сине дулкынландырган, кузгаткан нәрсәләр тоелмый. (Ул күренергә түгел, ә тоелырга, сизелергә тиеш). Ул «Петроград — Разлив»та да «Кышкы сарай»да да, башка шуның кебек шигырьләрдә дә сизелми. Адаш, күрәсең, мондый нәрсәләрне житкерә белү, яза белү кешедән зур осталык сорый торгандыр. (Әле бездә аны С. Хәким белән Х. Туфан гына яза ала), шуңа күрә мин сине гаепләп әйтмим. Гомумән, алар урта кул шигырь булырлык, теләсә нинди газета битләрендә урын алырлык. Киләчәктә син моңа аеруча игътибар итәргә тырыш әле. Мондый шигырьләрне язарга өйрәнү, минемчә, ул әдәбиятның югары ноктасы. Синең үзеңнең андый шигырьләрне язарга көнелең ятып тора.

Әлбәттә, бераү кучтәнәч биргәндә, алучы кеше, итагатьлек саклап булса да, аны яманламаска тиеш. Ләкин бит бу кучтәнәч түгел, зур бүләк һәм укыр өчен, уйланыр, борчылыр, шатланыр өчен бирелгән китап. Мин шулай карадым һәм бик игътибар белән укып чыгып шатландым синең уңышларыңа, үсә баруыңа чын-чынлап куандым. Рәхмәт.

Үзем бу араларда тагын «Тальян моңы» белән утырдым әле. Әлмәт театры аны 12 елдан соң, тагын яңартып куярга булды. Заманалар үзгәрүен дә истә тотып, яңача итеп эшләп бирергә куштылар. Хәзер пьеса репетициядә. 15 майга премьерасы чыга. Режиссеры — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Гали Хөсәенов, композиторы шул ук — Әнвәр Бакиров.

Хәзер Әлмәт комсомоллары турындагы китап белән утырабыз. 8 табак язарга дигәннәр иде. Альберт Хәсәнов белән икәү эшлибез. Менә хәзергә яңалыклар шул. Язасы повесть һаман кырыйда утыра әле.

Әсрар Гали дә үпкәләп хат язган иде. Күптән җавап биргән юк үзенә. Аңа да хат язам.

Хуш, адаши!

Сәлам белән: Шамил Бикчурин.

2/IX — 72.

Чак кына ялганчы көнгә әләкмәдем! *(1 апрель — Көлке көнен күздә тотуы инде. Ш. М.)*

Адаши әл-Маннапи!

Безләрдән Сезләргә сәлам!

Мин Жәүдәт белән Барлас китабына карата үз сүземне әйттем. *(Сүз Җәүдәт Кәлимуллин белән Барлас Камаловның КамАЗ төзүчеләргә багышлап язылган очерклар җыентыгы турында бара. Ш. М.)* Кимчелекләре юк икән дип уйламасыннар — алар бар. (Ходаем, алар кайсыбызның әйберләрендә юк!) Ләкин мин газетаның бурычын китап пропагандалау, китап күзәтү кебегрәктер дип уйлыйм. Шуңа күрә тәнкыйть өлешенә тукталмадым. Бу минем, бәлки, очеркларга һәм очерк язучыларга карата аерым бер мәхәббәтемдер. Шул рухта дәвам итсеннәр. Мин аларны котлыйм!

Инде килеп, минем «Трофей» хикәясе турында. Ниһаять, мин аны төзәттем, кыскарттым, кирәк урыннарына өстәдем. Хәзер күнелемә ята төсле — тиешле кондициягә килде бугай. Аны, мөмкин булса, Жину көненә бирәсе иде. Аны аннан газетада кайчан гына биреп була?

Үзебез кылдый-былдый гына килеп ятабыз. Романга төзәтмәләр кертәм һәм шуларга (үземә-үзем) подстрочный тәрҗемә ясап ятам. Мәскәүдә уңышлы гына тәрҗемә итеп яталар. Тәрҗемәчесе — Владимир Чивилихин дигән кеше. Комсомол лауреаты. Хәер, мин аны Мәскәүдән кайткач әйткәнмендер инде.

Башка язардай үзгәрешләр юк.

Үзең ник бер дә безнең якларга килеп чыкмыйсың соң?

Май азакларында тәрҗемәләрне култык астына кыстырып, Мәскәүгә китәргә исәп. 15—20 көнгә. Казан аркылы китәм.

Сәлам безнең егетләргә.

Ш. Бикчурин.

23 апрель, 1973 ел.

«Хәзинә» турындагы әйберне бирүгезгә рәхмәт! *(Сүз Гариф Ахунов романына карата язылган рецензия турында булса кирәк. Ш. М.)* Тик ул статья бик тә начар язылды.

Адаши әл-Маннапи, исәнме?

Бисмилла итеп, сүзне сине Яңа ел белән котлаудан башлыйк. 1976 ел сиңа көтелмәгән бәхетләр, уйланмаган шатлыклар, алдан күрелмәгән уңышлар алып килсен иде, дим! Яңа урында Яңа елның яңа казанышлары килсен, гыйлем дәрьясында үрдәк булып йөз һәм дә ки, үрдәген ашап, суын эчеп бетер! Бу минем сиңа догам. Догада булыйк, амин! *(Шамил абыйның бу хаты миңа Горькийда журналистика буенча югары курсларда укыганда язылган иде. Ш. М.)*

Вә янә дә килеп, шуны әйтәсем килә: синең Яңа ел хатың һәм анда язылган изге теләкләрең мине ифрат та шатландырды. Куанычымны кая куярга белмичә, өйдән чыгып киттем һәм синең белән икебез исәнлегенә ярты литрлы тост күтәрдем. Кешеләрне, дус-ишләрне, шәкертләрне һәм остазларны онытмау бик изге, бик муафыйк эш бит ул!

Соң, укулар ничек бара, тормыш-көнкүреш һәм яшәешләр ничек? Шәт, син укымышлы вә тыйнак шәкертләреңнең берсе, уку һәм ялгыз тору авырлыкларына бик бирешми торгансыңдыр. Инде Указ алып кайтып, зур мәхәлләләрнең берсендә, иң биек мәчетләрдә олуг хәзрәт булып утырырга язсын иде.

Кайгырма, әдәбиятта да югалмассың шөт. Язгалый тор, каләмеңне чарлый тор. Илнең төрле почмакларыннан килгән гыйлем ияләре белән аралашу үзе зур бәхет бит ул.

Үзебез кылдый-былдый гына яшәп ятабыз. Әсраргали әдәби берләшмә белән җитәкчелек итә, ә мин аның янында үгет-нәсихәтче ролен үтим, ягъни, консультант хезмәтен алып барам. 8 январьда Әлмәт председателен сайлау *(сүз Әлмәт Язучылар оешмасы турында. Ш. М.)* өчен бардык. Шул ук Әдип Маликов калды. Аннан алда, декабрьдә Мәскәүдә РСФСР Язучылар съездында булган идек. Докладта минем исемне әйтеп киттеләр. 1977 елда Мәскәү «Каты токым»ны 200000 экземпляр белән чыгарырга планлаштырган. Шушы ук елны Казанда юбилей китабым да басылды. 15 табак хикәя һәм очерклар. «Каты токым» романы ВЦСПС һәм СССР Язучылар союзының иң яхшы проза әсәрләре конкурсында.

1 Майга нәтиҗәсе билгеле булачак. Бирерләрме, юкмы — аны бер Аллаһы тәгалә үзе генә белә. Чит илдә, Чехословакиядә басу өчен рөхсәтемне сорап алганнар иде, әле аннан хәбәр-хәтәр ишетелми.

Хәзер Төмән — Татарстан нефтьчеләре турында роман язып ятам. Быел көзгә тәмамларга исәп. Әлегә «Чакырым баганалары» дип атадым. Исем бит ул бала тугач кушыла. Менә хәзергә «яңалыклар», ягъни, соңгы хәбәрләр шул.

Вакытың булганда хатлар язгала, бөтенләй үк онытып бетермә. Егетләрнең барысыннан да сәлам.

Ш. Бикчурин.

12/I — 76 ел.

Маннапи әл-Адаши!

Хатыңны алып, хәлләреңне белдем, рәхмәт якын итеп хат язуың өчен. Кайткач тик ятмаганыңны газеталардан күреп бардым, молодец. Студент кешегә

бик кирәк ул. Каникулларда мин үзем дә очерклар биргәләп, газетага эшкә кереп көн күрә идем.

Үзебездә артык яңалыклар юк. Егетләр җәй әдәбият белән бик шөгыльләнә алмадылар бугай. Мин дә күбрәк җир чокып, бакчада җиләк җыеп яттым. Шулай да романны бераз сукаладым, балет өчен бер либретто язып ташладым. Әле композитор табасы бар.

Моннан алда да синең бер хатыңны һәм шигырьләр китабыңны алган идем. Шул вакытларда Мәскәүгә бүләк алырга барып, аннан кайткач та бүләкләрне юып, чайкап, киптереп йөри торгач, сиңа җавап хаты яза алмый калган идем. Ул арада синең каникулларың башланды. Бәлки бу минем язуга соңгы елларда бераз ялкаулана төшүемнәндер? Син солдат вакытта мин сиңа еш яза идем төсле. Хәер, уку солдат хезмәте түгел инде.

Ул хатыңда син кемнән дә булса рецензия яздыру мәсьәләсен әйткән идең төсле. Үзем мин шигырьләргә рецензия язарга куркам. «Итекче пешекче булган» диярләр. Әлмәтлеләр җәй айларында кайсы-кая таралып беттеләр. Безнең егетләр дә аны язарга җөрьәт итмәделәр, күрәсең. Шул рәвешчә калды.

Ә китап әйбәт чыккан. *(Сүз «Тугрылык әлиһәсе» китабым турында бара. Ш. М.)* Элеккерәк елларны мондый күләмдә, мондый эчтәлекле әйберләрне Сибгат Хәким, Туфан кебек классиклар да чыгара алмый иде әле. Солидный җыентык булган. Бирсен Ходай, соңгысы булмасын! Моның белән сине Союзга алырга стоит! Ә анда уку сиңа тагын да зуррак дөнья күрсәтер, зуррак илһамнар бирер дип ышанасы килә.

Бездән быел Җ. Рәхимовны һәм Альберт Хәсәновны Союзга алырга җыеналар бугай. Әлмәттән Азат Ганиевне алдылар.

Хат яз!

Хуш!

Сәлам белән — Ш. Бикчурин.

22 август, 1976.

Адаши әл-Маннапи!

Сентябрь башларында язган хатың, Октябрь бәйрәме белән котлаган открыткаң өчен зур рәхмәт! Шәкертләр онытмыйлар икән әле, дип сөенәм.

Хат язарга, ахры, мин бик ялкауландым. Хатларыңны айлар буе өстәлдә тотам да, менә язам дип йөрим дә, ниндидер эш яки берәр җиргә командировка килеп чыга һәм шуның белән онытылып китә. Картлык галәмәте, билгеле.

Сентябрь урталарында «Казан утлары»ның ярты еллык йомгакларында булдык. Шуннан соң А. Расих 60 еллык юбилеена чакырды. Аннан соң С. Сөләйманова юбилее буенча йөрергә, аны уздырырга туры килде. Аннан Лениногорскида әдәби берләшмәнең отчет-сайлауларын уздырдык. Аннан соң бер-ике авылга очрашуларга бардык. Аннан соң...

Менә шулай эшләр муенса төймәләре урынына тезелеп кенә тора. Берләшмә җитәкчесе булып бу сезонга да Әсрар Галине калдырдык. Эше җиңел, телефоны бар, җыелырга урыны да шәп. Мин хәзер карт бүре кебек консультант кына булып, киңәш, үгет-нәсихәт биреп, акыл сатып утырам. Ничек тә акыл сату җиңелрәк икән. «Син болайрак ит, син тегеләйрәк эшлә!» — дип әйтәсең дә котыласың.

Октябрь аенда бездән Союзга Җәмит Рәхимовны алдылар. Без монда хәзер икәү. Әлмәттән Азат Ганиев белән рус язучысы Вл. Мальцев алынды. Казаннан Зиннур Насыйбуллин белән тагын кемдер, шулай үрчеп кенә торабыз.

Үзем каләм кыштырдаткан булып ятам әле. Романны черновойга күчерәм. Аннан акка күчереп, машинкага бирәсе генә кала. Көзгә тәмамларга кирәк. 1978 нең Яңа елы минем юбилей, шуңа тырышырга кирәк. Әле радикулит чире белән билне тотып утырам. Бюллетеньдә.

Әсрар шунда эшләп йөри. Язмый әлегә. Тегеләре чыкмый торып язмаячакмын, дип, үгез урынына киреләнеп йөри. Ул искеләр турында онытып, яңа әйберләр бирергә кирәк иде аңа. Сүнгән учак тирәсендә җылынып йөрергә ничего!

Тагын нәрсә языйм? Бетте кебек.

Хәлләреңне язгалый тор.

Хуш иттек.

Сәлам белән:

Ш. Бикчурин.

*17/XI — 76.*

Исәнме, адаш дус!

Мәктүбеңне алдым, рәхмәт! Шулай да, шәкертләрем онытмый икән әле дип сөендем. Синең яхшы гына, имин генә укып ятуың мине куандыра. Әйдә, безнең егетләр дә кемлекләрен күрсәтсеннәр әле! Хәзер инде алайса, бетерәм дип ятасың, бик хуп!..

Үземдә нинди яңалыклар бар, дисеңме? Бераз бар. Юбилей китабым чыкты. «Алтын җирдә ятмый» исемле. 10 табак хикәяләр һәм очерклар. Иске яңа китап инде бу — переиздание. Чехословакиядә китабым словак телендә чыкты. Һәм дә килеп, «Современник» нәшрияты договор җибәрде. «Каты токым»ны яңадан 200 000 экз. белән чыгаралар. «Серия Российского романа» дигән серия белән. Иллюстрацияләр һәм минем портрет белән.

Чехословакия үзенә чакырган иде. Оформиться итеп беттем, ләкин 2 көнгә соңга калдым. Анда Совет китап айлыгы үткәрелгән икән. Минем китап һич булмаганча тиз таралып беткән (10 көн эчендә) һәм миңа аларның издательствосы бүләк биргән (1500 крон). Кичә генә пакет белән үзләре валюта җибәрделәр. Аны бары тик международный магазиннарда гына реализовать итеп була. Ахры, туздыру өчен Мәскәүгә китергә туры килер.

Ә гонорарны Мәскәү банкыннан үзебезнең акчага алыштырып алырга кирәк. 10000 крон аласы бар. Безнең телдә ничектер инде. Әле миңа тиешле китапның экземплярлары килеп җитмәгән. Җитсә дә, укып булмый инде аны, тик карап утырырга гына.

Яңа роман әкрен языла. Хәзер квартира ремонтта, утырыр урын юк. Кышын чирләштергәләдем. Салкын сукты, каһәр. Романны акка күчереп бетерәсе бар. Кыш бер балет өчен либретто эшләдем. Иске бер пьесаны яңартып, Әлмәт театрына бирдем. Ул әле беркайда да куелмаган. Балетны композитор Луиза Хәйретдинова алып калган булган иде, нишләтер.

Башка яңалыклар юк. Минем «Каты токым»ны кемдер сәхнәләштереп, Академиягә биргән. Сәлимҗанов кабул иттек, яхшы диде. Аның исеме генә минем исемнән барачак, ә әҗере сәхнәләштергән кешегә.

Егетләр әйбәт кенә эшләп, язып яталар. Бездән Җәмит Рәхимов Союзга алынды. Хәзер чиратта Альберт Хәсәнов тора. Тиздән ул да хәл ителәчәк. Рәшит Бәшәровны да тәкъдим итәргә торабыз. 2 китабы чыкты, өченчесен бирде, дүртенчесен язып ята. Әсрар Галинең повестеннән өзек «Ялкын»да чыкты. Яшь шагыйрьләребез дә семинарда уңай фикер алып кайттылар. Димәк, үсәбез!

Ярый, дустым, күбрәк мактанып ташладым бугай. Бу инде үзенә күрә син шәкертемә отчет.

Калганын күрешкәч сөйләшербез. Хуш. Язган хатларыңның, котлау открыткаларыңның барысы өчен дә рәхмәт! Ремонт һ. б. белән булашып, җавап яза алмый калдым.

Сәлам белән: Ш. Бикчурин.

*14/IX — 77.*

Адаши әл-Маннапи!

Сиңа чуктин-чук сәлам белән адашың.

Синең газетага *(«Социалистик Татарстан»га. Ш. М.)* Разим Вәлиуллинның берничә шигырен бирәсе иде бит. Мәсьәлә шунда: күптән түгел Әлмәт язучылары җыелышында без аның 200 гә якын шигырен тикшердек. 100 гә якынын төзәткәләп, эшләп, китап итеп бирергә кирәк, дигән карарга килдек. Шунда Разим Вәлиуллинның, Лениногорск әдәбият-сәнгать берләшмәсе җитәкчесе буларак та, шактый ук үсеп баручы шагыйрь буларак та, матбугатта бик аз катнашуын, ягъни шигырьләрен газета-журналларга бирмәвен тәнкыйтьләп үттек. Аңа бит әле китап чыгару өчен дә матбугатта күренгәли торырга кирәк. Юкса, нәшриятта: «Син кем соң әле, әйберләреңне кайда чыгарганың бар?» — дип әйтүләре мөмкин. Ул инде болай «Идел», «Азат хатын», «Тат. яшьләре» һәм башка урыннарда, «Карлыгачлар»да да бастырганы бар. Әмма болай гына да аз. Аңа күренгәли торырга кирәк. Аның әйберләре яңа, әйбәт, шул турыда син дә уйлап, борчылгалап кара әле, адаш. Кирәк булса, минем кечкенә генә сүз башым да бар.

Үзебез, Ибраһим Гази әйтмешли, кылдый-былдый гына яшәп ятабыз. Язабыз, бозабыз, тавышланабыз...

Сиңа иҗади һәм шәхси уңышлар теләп: Шамил абыең.

*22/III — 81.*

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ФАТИРЛАРЫ



Моннан берничә еллар элек Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының эш планы буенча мин Г. Ибраһимовның хатларын, документларын туплап, бер җыентык итеп төзеп, Татарстан китап нәшриятына тапшырган идем. Шул эш белән шөгыльләнгәндә әдипнең хатларыннан, документларыннан, вакытлы матбугат сәхифәләреннән ул яшәгән фатирларның адресларын җыйдым. Бу эшкә мәрхүм Афзал ага Шамовның да берникадәр өлеше керде.

Г. Ибраһимовның биографиясе барыбызга да мәгълүм, ә менә яшәгән фатирлары турында матбугатта сүз булмады шикелле. Шуны истә тотып, мин бу исемлекне журналга тәкъдим итәргә уйладым. Чынлыкта кешенең яшәгән урыны аның биографиясенең бер өлеше, тулыландыра торган өлеше бит.

Г. Ибраһимов күп йөргән, күп фатирларда, кунакханәләрдә торган, кайсында күбрәк, кайсында азрак яшәгән. Аларның барысының да адресын табып бетереп тә булмагандыр, табылган кадәресе дә аз түгел, егерме дүрт берәмлек тәшкил итә.

Әдипнең туган авылы — Солтанморат. Автобиографиясендә ул туган авылыннан унбер яшендә чыгып китүе, ләкин әнисе Хәсәнә вафат булганчы, 1921 елга чаклы һәр җәй кайтып, кыр эшләрендә өйдәгеләргә булышуы турында яза.

Оренбургта — Вәли хәзрәт, Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыганда мәдрәсәләрнең тулай торагында гомер кичерә.

Егерме ике яшьлек егет Галимҗан 1909 елның көзендә, берәр югары уку йортына керү теләге белән канатланып, Казанга килә. Казанда ул 1909—1912 елларда Спартак урамы (элекке Әрмән), 5 нче йортта яши. Егетнең теләге тормышка ашмый, эшләмичә торып укырга мөмкинлеге булмый.

Г. Ибраһимов бер көнне Казан урамнарында йөргәндә, Киев янында, Казатинда балалар укытучы мөгаллим Каюм Мостакаевны очрата. Мостакаев аңа Киевтә укытучылык эше барлыгын әйтә.

1912 елның көзеннән алып 1913 елның 13 июненә кадәр Г. Ибраһимов Киевтә, Степанов урамы, 18 йорт, 7 нче фатирда яши. Берничә татар баласын татарча укыта. Изге Владимир университетына лекцияләргә йөри. Әлеге университеттагы мөселман студентларының яшерен «Якташлык җәмгыяте» утырышларына катнашканы өчен, 17 апрель төнге сәгать 12 дә 30 минутта, фатирына тентү ясап, кулга алына һәм Бульвар участогы Лукьянов төрмәсенә ябыла. 13 июньдә, гаепсез табылып, төрмәдән чыгарыла.

1913 елның октябре, 1914 елның 13 феврале — Г. Ибраһимов Казанда, Апанаевлар номерында, хәзерге Киров урамы, 60 нчы йортта. Бу вакытта ул «Аң» журналының нашире һәм мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни чакыруы буенча әлеге журналда — җаваплы секретарь.

Г. Ибраһимов бу могтәбәр журналда бик аз эшли, барысын бергә җыйсаң биш айга да тулып җитми. Ул кинәт Сухумига китә. Болай кинәт чыгып китүенең

сәбәбен 1914 елның 25 апрелендә Сухумидән якын дусты язучы Хәсни Кәримгә җибәргән хатында болай аңлата: «Күпләр минем «Аң»нан китүемә гаҗәпләнделәр. Мин «Аң»нан китмәдем, төрле интригалардан туеп, Казаннан киттем».

Интрига дигәндә хат иясе түбәндәгеләрне истә тоткан булса кирәк: аның «Татар шагыйрьләре» исемле китабы 1913 елда Оренбургта Тукай вафат булганнан соң басылып чыга. Китапта «Тукай шагыйрьме?» дип халык талантының шагыйрьлегенә шөбһә уятырлык сорау куюы җәмәгатьчелектә зур ризасызлык, шау-шу тудыра. «Үлгәч үч алу», «Мәрхүмнең каберенә тибә», «Татар шагыйрьләре» китабы Г. Ибраһимовның тәрҗемәи хәленә кара тап булачак» дигән гаепләүләр матбугат битләрендә еллар дәвамында күренеп килә. «Толстойдан урлап яза» дигән сүзләр дә йөри.

Казан жандарм идарәсе документларында Г. Ибраһимов белән Ә. Хәсәнинең бик дустанә аерылышулары хакында язылган. Г. Ибраһимов «Аң»нан китсә дә, аның белән бәйләнешне өзмәгән. Мәкаләләрен җибәреп, журналда бастырган. Ә. Хәсәни аңа, «Аң»ның хезмәткәре хисаплап, ай саен гонорар тәртибендә акча җибәреп торган.

Хәсәни исеме чыккач, читкәрәк китеп, шуны әйтергә кирәк: ул нашир буларак, талантлы каләмнәр үстерүгә сизелерлек өлеш керткән кеше. Г. Исхакый да матди яктан авыр хәлгә калган көннәрендә аңардан ярдәм тапкан. Хәсәни үзенең нәшриятында әдипнең сигез җилдлек «Мәҗмугаи асар»ын чыгаруны үс өстенә ала.

1911—1917 елларда Г. Исхакыйның күп кенә әсәрләре «Гасыр» нәшрияты аша дөнья күрә.

Г. Ибраһимовның Сухумига бару юлында туктаган урыннары төрле шәһәрләрдән алынган жандарм идарәсе язмаларында теркәлеп калган, чөнки ул Киев вакыйгаларыннан соң, февраль революциясенә кадәр, жандармериянең махсус күзәтүе астында яши. Язмаларда әйтелгәнчә, Г. Ибраһимов бу сәфәрендә беренче эше итеп Киевкә кереп чыга. Киевтә фатирына тентү вакытында алынган әйберләренең бер өлешен жандарм идарәсеннән кайтарып ала, бер өлеше югала. Киевтә ул өч атна була. Башта «Москва» кунакханәсендә, аннан соң Львов урамы, 55 нче йортта яши. 11 мартта пароход белән Одессага юнәлә. Одессада «Германия» дип исемләнгән кунакханәгә туктала. Бу вакыты турында Одесса жандарм идарәсе күзәтүендә мондый сүзләр язылган: «Одессада булган вакытында Г. Ибраһимов сәяси яктан үзен фаш итәрлек беркем белән дә аралашмады, ике мәртәбә рус пароходствосы җәмгыяте конторасына барып кайтты, пароходның Кырым — Кавказ юнәлешенә кайчан китүен белеште, берникадәр урамда йөрде дә, кунакханәгә кире кайтты, 13 мартта сәгать 12 дә «Цесаревич Георгий» пароходына утырып, Кырым—Кавказ юнәлеше буенча китте». Ул Сухумига Севастополь, Феодосия, Керчь, Ялта аша бара. 17 мартта Сухумига килеп житә, башта Венеция кунакханәсенә туктый, май аенда Икенче Подгорный урамы, Сигаев йортыннан үзенә аерым бер бүлмә ала. Жандарм идарәсе язмаларында аның бу бүлмәдә торганда беркем белән дә аралашмавы, үз эченә бикләнеп яшәве, һәркөн 12 дән 1 гә кадәр почтага барып корреспонденцияләр алуы, шуннан ресторанга кереп ашап чыгып, яңадан бүлмәсенә кайтуы турында әйтелә. Г. Ибраһимов Х. Кәримгә 1914 елның 15 маенда язган хатында бу бүлмәне мактый: «Аерым бүлмә, якты, тыныч, иркенләп эшләргә мөмкинлек бар». «Безнең көннәр» романын язуы турында әйтә.

Г. Ибраһимовның биографиясе Башкортстан, Уфа белән бәйле. Ул Сухумидан Уфага кайта, 1915 елның көзеннән алып февраль революциясенә кадәр «Галия»дә татар теле һәм әдәбияты укыта. Февраль революциясен дә Уфада каршылый, «Ирек» газетасын чыгара, 3 нче номерлы вилаять мөселман гаскәри Шурасы, татар социалист-революционерлар комитеты исемлеге буенча Учредительный собраниегә әгъза булып та Уфадан бара. Шушы арада ул дүрт фатир алмаштыра: Большая Успенская урамы, 50 нче йорт; Электрический переулок, 3 нче йорт; Казарменная урамы, 58 нче йорт; Пушкин урамы, 68 нче йорт.

Татар-башкорт автономияле республикасы төзү идеясе хакимлек иткәндә, Мәскәүдә Үзәк Мөселман Комиссариатында җитәкче урында эшләүче буларак, Г. Ибраһимов берничә мәртәбә Уфага килә, республика төзелешенең положениесен эшләүдә катнаша, киңәшмәләрдә чыгышлар ясый. Төрле каршылыклар килеп чыгу сәбәпле, бу идея тормышка ашмый кала. Г. Ибраһимов Уфага килгәндә Коммунистическая урамы, 53 нче йортка төшә.

Чех-словак укчы корпусы фетнәсе Казанга якынлашкан көннәрдә Үзәк Мөселман Комиссариатының рәисе М. Вахитов Казанга китә. Г. Ибраһимов 1918 елның 31 июленнән 1918 елның 9 сентябренә кадәр Комиссариатның башында

тора, байтак документлар аның имзасы белән чыга. 1918 елның 9 сентябреннән Комиссариатның рәисе итеп М. Солтангалиев билгеләнә. Г. Ибраһимов башта М. Вахитов белән, аннан соң 1918 елның 17 октябренә кадәр, авырып Казанга кайтып киткәнче, М. Солтангалиев белән Комиссариатта бергә эшли. Шул вакытларда ул Мәскәүнең «Националь» кунакханәсендә һәм Мәскәү елгасы буенда Солодовниковның 9 нчы номерлы йортында, Комиссариат урнашкан бинада тулай торакта тора.

Г. Ибраһимов Казанга кайтканнан соң, Үзәк Бюроның нәшрият бүлеге мөдире, Татар Коммунистлар университетында лектор — татар әдәбияты һәм ВПК(б) тарихы укытучысы. Шушы чорда ул 1918 елның октябреннән алып 1925 елга кадәр дүрт мәртәбә фатирын алмаштыра: Зур мещан һәм Евангелистлар почмагы, 41 нче йорт (хәзерге Нариман һәм Татарстан урамы кисешкән чат), Бристоль һәм Гранд- отель (К. Нәҗми урамы, 10 нчы йорт), К. Насыйри урамы, 10 нчы йорт (Ш. Мәрҗани улының йорты), хәзерге Кремль урамы, 21 нче йорт, 33 нче бүлмә (Советларның Икенче йорты).

Г. Ибраһимов — 1925 елның 7 январеннан алып 1927 елның 17 мартына кадәр Татарстанда фән, сәнгать, әдәбият эшләре белән җитәкчелек итүче Гыйльми Үзәк рәисе. Гыйльми Үзәк рәисе булып эшләгәндә ул Комлев урамы (хәзерге Мөштәри), 33 нче йортка күчә. Бу — Г. Ибраһимовның моңа кадәрге фатирлары белән чагыштырганда иң яхшысы. Әле Советларның Икенче йортындагы 33 нче бүлмәне дә хатыны Гөлсем Мөхәммәдиева үзенең истәлекләрендә болай тасвирлый: «Моржа кебек озын, тар, килбәтсез. Түрдәге бердәнбер тәрәзәне ачсаң, ишек ачылып китә. Ишек төбендә үк уң якта тимер карават. Аның өстенә коңгырт-сары одеал капланган, иске одеал, хәтта уртасы аш тәлинкәсе зурлыгында янган да. Ишектән кергәч тә, сул якта юынгыч. Тәрәзә, ишектә пәрдәләр юк.» Галимҗан үзе дә иске пальтосын ябынып йоклый торган булган, дип тә сөйли иде Гөлсем апа.

Г. Ибраһимов бай фатирларда яшәмәгән, еш алмаштыруы да шул уңайлы булмауларыннан килгәндер. Бик яшьли үпкә авыруы эләктерүен дә үзе начар квартираларда яшәргә мәҗбүр булуыннан күрә. 1927 елның 28 сентябрендә Ялтадан якын дусты Ш. Әхмәдиевкә язган хатында болай ди: «Син минем гомерне беләсең, күпме ачлык, ялангачлык, күпме начар, юеш, сасы квартираларда калтырап кыш чыгулар, кән-төн тырышып укулар, язулар, шулар һәммәсе җыелып, мине аяктан ектылар, туган».

Квартирасы — кешенең яшәү рәвеше. Яшәү рәвеше характерга тәэсир итми калмый. Ярлы фатирларда яшәү, кысынкылык Г. Ибраһимовның сәламәтлегенә генә түгел, характерына да эз салган, аңарда үтә сакчыллык тәрбияләгән. Ул соңгы вакытта яхшы, иркен яшәгән чакларында да акчаның кадерен белгән, аны кирәкле-кирәкмәс вак-төякләргә исраф итмәгән. «Акчаны кысып тота торган кеше иде»,— дип сөйли иде Гөлсем апа.

Комлев урамындагы 90 кв. м дан артык мәйданны биләп торган биш бүлмәле йорт Г. Ибраһимовның үз сүзләре белән әйткәндә, «гомер буе бүлмәсез, квартирасыз яшәгәннән соң» оҗмах төсле булып тоела, аны үзе теләгәнчә ремонтлата. Шушы йортта ул Кырымда дәваланырга киткәнче, 1927 елның 21 апреленә кадәр гаиләсе белән көн күрә.

Г. Ибраһимов белән кызыксынган кеше әдипнең Казандагы бу соңгы фатирын килеп карамый калмагандыр мөгаен. Ләкин хәзер бу йорт Г. Мөхәммәдева истәлекләрендә тасвирлаганча түгел, бөтенләй үзгәртелгән, анда Россия Фәннәр Академиясенең Казан Фәнни Үзәге шифаханәсе урнашкан.

1927 елның 27 апреленнән Г. Ибраһимов — Кырымда.

Әйтергә кирәк, аның әйбәт фатирларда торган, материаль яктан тәэмин ителгән еллары Гыйльми Үзәк рәисе булып эшләгән һәм Ялтада дәваланган чагы, ягъни зур язучы һәм дәүләт эшлеклесе булып күтәрелгән еллары.

Ялтада дәваланганда Татарстан хөкүмәте аңа кирәкле булган бөтен мөмкинлекләрне тудыра. Ялтадагы санаторийларның ишекләре киң ачыла.

Дәвалану өчен Татарстан хөкүмәте аңа ай саен 175 сум, хезмәт хакы итеп 183 сум күләмендә акча җибәреп, 180 сум персональ пенсия билгеләнә. 1936 елда персональ пенсиянең күләме 500 сумга җитә. «Сайланма әсәрләре» бастырылып чыгарыла.

Ялтада өч фатирының адресы билгеле.

Әдип 1928 елның 25 январенда Сәнгать Фәннәре Дәүләт Академиясенә әгъза булып сайлануы турында Мәскәүдән хәбәр ала. Әгъзалар Академиягә барып, нинди дә булса бер темага доклад ясарга тиеш булганнар. Авыру сәбәпле Мәскәүгә бара алмавы турында Академиягә җибәрергә язган хатының ахырына

ул: «Ялта, Барятинская, 5, 1928 ел, февраль» дип куйган. Бу йортта торганмы ул, юкмы — билгесез, башка бер урында да аның турында мәгълүмат очрамый.

Ялтада Г. Ибраһимов белән күрешергә килүчеләр үзләренең истәлекләрендә күбесе Халтурин урамы, 5 нче йортны искә алып сөйлиләр. «Ике катлы ак йорт, ишегалды агачлар белән әйләндереп алынган, урамнан шактый күтәреп, таш кыя өстенә салынган, аннан Ялтаның ерак таулары күренеп торган» бу зур бинаның беренче катында бер бүлмә һәм иркен веранда алып, Г. Ибраһимов гаиләсе белән шунда 1936 елның сентябренә кадәр яши.

Ялтада җир тетрәүләр вакытында бу йорт шактый зыян күрә.

Ялта район комитеты аны тагын да уңайлырак булган Боткин урамы, 23 нче номерлы ике бүлмәле өйгә күчерә. Өйгә телефон кертелә. Ул диңгезгә, почтага, китапханәгә якын урында була. Монда торганда Г. Ибраһимов театрларга баргалый, шәһәр бакчасына чыгып утыра. «Бу йорт аңа бик ошый иде», дип искә ала Ялта район комитеты рәисе Шакир Даутов үзенең «Кырымда» исемле истәлегендә.

Авыру әдипкә бу уңайлы йортта озак яшәргә туры килми, өстенә шәхес культының салкын җилләре исә башлый. 1937 елның 20 июлендә Татарстан Дәүләт иминлеге комитетының дүртенче бүлеге «Г. Ибраһимов кулга алынырга тиешле» дигән фәрман чыгара, 25 августта бу фәрман тагын кабатлана. 1937 елның 29 августында Татарстан республикасының Эчке эшләр Халык Комиссариаты махсус җибәргән вәкилләр (Сөнгатулла Корбанов, Ильяс Юнысов) тарафыннан әдип кулга алына. Партия билетын Ялта район комитетына тапшыра. Аңа Татарстанда милләтче-троцкичы яшерен контрреволюцион оешманың идея җитәкчесе, эсер, дигән мөһер тагыла. Моңа тагын «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән хезмәтендәге совет идеологиясенә туры килеп житми торган кайбер фикерләре, башта латин алфавиты кертүгә каршы булуы (гәрчә, үз вакытында бу «хаталарыннан» ваз кичкән булса да) өстәле.

Симферополь төрмәсендә берничә көн яткырылганнан соң, ул 6 сентябрьдә Казанга кайтарыла.

Г. Ибраһимовның соңгы «фатиры» — Казандагы Пләтән төрмәсе, каты авыруларны яткыра торган изолятор бүлмәсе.

Уң үпкәсендә тавык йомыркасы сыешлы тишек, үпкә элпәләреннән ун-унбиш көнгә бер мәртәбә үлек суыртып яшәгән, ике мәртәбә операция кичергән әдип төрмә шартларына озак түзә алмаган. 1938 елның 21 январенда гүр иясе булган, 27 январь көнне тоткыннар өчен гомуми хисапланган тәртиптә Архангель зиратына күмелгән, күмелгән урыны рәсми рәвештә теркәлмәгән.

Татар халкының хөрмәтле зур язучысы Г. Ибраһимовның мәете яткан мәңгелек йортының адресы юк. Аны А. Шамов житәкчелегендәге гомуми комиссия, шаһитлар раславына таянып, 1966 елда гына ачыклый алды, ләкин моны төгәл дип әйтү кыен.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА.**

## Шәүкәт Галиев

# ХИКМӘТЛЕ СҮЗЛӘР

### Туган җиргә яткан кар да җылырак

Елгалар туган җирне имеп-имезеп үсә.
Таллар талымсыз була, тамыры әрсез була.
Канат — таянырга һава эзли, тамыр — ябышырга җир эзли.
Тамырсыз җир таралыр.
Карга да җиде җилдәге җылы оясын сагына.
Кая барсак та, кайтаваз күңелләр туган якка китә.
Үзәкләр өзелгәндә туган җиргә тарткан җепләр ныгый.
Кыска җырлар да халык белән озын юл үткән.
Халкың — бабаң да, балаң да.
Халкың — иманың, син ансыз — имансыз.
Авызың тулы алтын теш булса да, үткәнеңә төкермә.
Шәҗәрә — нәсел агачың, халкың — урманың.
Бер юньсезгә карап халыктан бизмиләр.
Су тирән булган саен тал биек!
Тукран — урман йөрәге: тук-тук тибеп тора.
Күккүк тавышы балачактан килә кук.
Каен — балкыр аклыгы белән, имән матур ныклыгы белән.
Бу илләрдә чүлләр үсә, күлләр — үчә.
«Кызыл китап» — яраланган табигать каны.
Тамчылар — язның шатлыклы күз яше.
Яз тамчылый — кышны камчылый.
Бөре-биләүне яз җылысы чишә.
Яз сүле йөгергән агач сайрый башлый — сыбызгы яса!
Кояш нурында язын уянып тузаннар оча...
Язгы хисләр чәчәгендә күзгә мәгънә җимеше.
Язның соңаруына күенәсең, кышның — иртәләвенә.

### Дәверне еллар яңарта, заманны — кеше

Йомшак якларыңны белми торып, ныклыкка ирешә алмыйсың.
Көчсезлегеңне танырга да көч кирәк.
Ялгышын кичермәсәң, кеше ничек яхшырсын?
Атаклы кеше дә башта билгесез була.
Горурлар күп, горур яши алучылар аз.
Биеклек яулаганда йөрәк тауны адымлап күтәрә.
Рухың күтәрелгән саен, офыклар киңрәк ачыла.
Үзе янган кеше генә бүтәннәрне җылыта.
Кай кешегә үзен аңлатырга, танытырга гомере җитми кала.
Сынмаган сынатмасмы, сынатмаган сынмасмы...
Туры сүзле дип сагынмасыннар, үзләре кыю булсыннар.

## Күңеле сукырның йөрәге саңгырау

Урам тулы бәйрәм күңел тулы бәйрәм түгел әле.
Күңелең үсмәсә, үзең дә үсмисең.
Салкын сүз — җәен яуган боз.
Кара кайгы чәчне агарта.
Кайгы эзгәндә дә, шатлыкта йөзгәндә дә, сабырлык кирәк.
Үпкәләргә хакың булу — син хаклы дигән сүз түгел.
Көзге яфраклар белән язгы өметләр коела.

## Гомерне озайтыйм дисәң, кыскартмаска кирәк

Саулык-байлыкны туздырганда саран булсаң да ярый.
Тешең сызлаганда йомшаграк сүзләр сайлыйсың.
Авырту булмаса, сызланмаган чакның рәхәтен белмәс идең.
Дару — сырхауга файда, сәламәткә — зыян.
Узып киткәчтен сукырлар әйләнеп карамый.
«Баш сау булса, чәч табылыр»,— диде Парик.
Бүтән шатлыгың булмаса, сәламәтмен дип сөен!
Кешелек үзен үтерергә корал ясый: ашау — яшәү өчен кирәк, ди.

## Тормыш яме — эш тәмендә

Эше үсә — кеше үсә.
Эшләгән — озак яшәгән.
Иң рәхәт ял — яраткан эш!
Мәгънәле эшең булмаса, яшәвеңнән ни мәгънә?
«Мин алдан барам!» — диде Баржа, үзен катер этеп йөртә.
Сөйли торган эшләр була. Эшли торган сүзләр була!
Бер тиенлек җилем йөз сумлык эшне ябыштыра.
Акчаны туздыруы җиңел, табасы кыен.
Җаны тыныч кеше дөньяга сокланып карый.
Чүкеч кулга суга-суга үзен ипле тотарга өйрәтә.
Кырга җәелгән иген җәймәгә җыела.
Кара ипи үстергәннең йөзе ак.
Кыйнап коймак ашатмыйлар.
Җим-еш. Эш җиме шул җимеш!

## Үткәннәргә хаким булу ансат, бүгенгә шаһит булуы читен

Алга бару — кояшка карап атлау гына түгел.
Алга бара-бара да артка калырга мөмкин.
Күңелләр киң, мөмкинлекләр генә тар.
Соңгы сүзне көннең кадагына суккан чүкеч әйтә.
Көннең кадагына гасыр чүкече төшә.
Көнбагышны көнбатышка борылган өчен гаепләделәр. Ә ул кояшка ияргән иде...
Түрәнең тавышы бөереннән чыга, ялагайның — туры эчәктән...
Шымчы — шомчы...
Һәйкәл буласы мәрмәр кемнәр аяк астында...
Ирләр үлә белә, хатыннар ирләрне тудыра да белә.
Үт дигәндә үтми вакыт, кит дисәң дә китми вакыт.
Озак онытылмас минутлар тиз үтә.
Үзенең озак яшисе килә, үзе көнне ничек үткәрергә белми!
Шатлык кына китмә, кайгының да киләчәге бар.
Яңа елга аяк басканда Яңа ел аякка басты...

## Tatarstan çəmhyriətendə tatar telen qəməlgə quju xaqьnda Mərkəz Başqarmasь həm Xalьq Komissarlarь Sovetь Dekretьnnan əzemtələr

*25 ijyn 1921 jьl*

1. Bəten xəkymət sovet məəssəsələrendə (ucrezdenie, ojьşmalarьnda - W.X.) tatar telen məçbyri itep kertergə.

2. Dekretnь tərtiple həm tiz rəweştə qəməlgə qujar əcen Tatarstan Mərkəz Başqarmasь janьnda maxsus komissiə təzergə.

3. ...Istilaxlarnь (atamalarnь - W.X.), tatar əlifbasьn təzy həm telegraf belən xəbərləşy əcen maxsus komissiə buldьrunь təqdim itərgə.

4. Yzlərc teləgənnər həm sovet eşcelərə əcen tatar tele kurslarь acarqa.

7. Tatar telendəge telegramnarnь qabul ity həm tapşьru ьsulьn kertergə, tatarca jazьlqan adreslь xatlarnь qabul itə başlarqa.

8. Bəten dekretlar həm qararlarnь tatar həm rus tellərendə nəşer itərgə.

9. Tatar tele belən berrəttən rus tele də xəkymət tele xoquqь belən jəşi.

10. Xəkymət məəssəsələre arasьndaqь jazьşu həm ecke eş qəqəzlərе məmləkət tellərenen bersendə jərteler.

## Tatarstan Respublikasьnьn dəwlət suverenitetь turьnda Deklaratsiə

(əzemtə)

*30 avgust 1990 jьl*

3. Tatarstan Respublikasь yz territoriəsendə jəşəwce barlьq grazdannarqa, nindi milləttən bulularьna, sotsial' cьqьşlarь, dinnərе, səjəsi inanularь nindi buluqa həm başqa ajьrьmlьqlarqa qaramastan, keşegə tigez xoquqlar həm ireklər garantiəli. Tatarstan respublikasьnda tatar həm urьs tellərenen dəwlət tele sьjfatьnda tigez xoquqlь qullanьluь, başqa millətlərnen tellərеn saqlaw həm ysterу garantiələnə.

## Tatarstan xalьqlarьnьn tellərе turьnda Tatarstan Respublikasь Qanunь

(əzemtələr)

*8 ujyl 1992 jьl*

» 3 maddə

2. Tatarstan Respublikasьnda tigez xoquqlь ike dəwlət tele: tatar həm urьs tellərе qullanьlьşta jərі.

» 9 madde

1. Balalarꝗa tuꝗan telne ɵjrətү ata-analarnьꞑ grazdanlьq burьсь.

» 10 madde

2. Tatar həm urьs tellәre, Tatarstan Respublikasьnьꞑ dәwlәt tellәre bularaq, mәktәpkәcә balalar ucrezdenielәrendә, ꝗomumi belem mәktәplәrendә, urta həm maxsus uqu jortlarьnda bertigez kүlәmdә ɵjrәnelә.

» 11 madde

1. Tatarstan Respublikasь Juꝗarь Sovetьnda, Ministrlar Kabinetьnda, Prezident apparatьnda eş başqaru tatar həm urьs tellәrendә alьp barьla.

2. Tatarstan Respublikasь Juꝗarь Sovetь sessiәlәrendә, Prezidium həm daimi komissiәlәr utьrьşlarьnda Tatarstan Respublikasь xalьq deputatlarь Tatarstan Respublikasь dәwlәt tellәreneꞑ bersendә сьꝗьş jasьj ala.

» 12 madde

Tatarstan Respublikasь zakonnarьnьꞑ həm başqa xoquqьj aktlarьnьꞑ tekstlarь tatar həm urьs tellәrendә bastьrьlьp сьꝗarьla həm alar tigez juridik kɵckә iә bula.

» 14 madde

Tatarstan Respublikasьnьꞑ dәwlәt organnarь predpriәtielәre, ucrezdenielәre həm ojьşmalarь eşcәnlegendә Tatarstan Respublikasьnьꞑ dәwlәt tellәre qullanьla.

» 15 madde

1. Tatarstan Respublikasь territoriәsendәge dәwlәt organnarьnda, ucrezdenielәrendә həm ojьşmalarьnda rәsmi eşlәr Tatarstan Respublikasьnьꞑ dәwlәt tellәrendә alьp barьla.

4. Tatarstan Respublikasьnda grazdannьꞑ şәxesen raslawcь rәsmi dokumentlar jaki anьꞑ turьndaꝗь beleşmәlәr (pasportlar, tuu, ɵjlәneşү həm үlү turьnda tanьqlьqlar, xezmәt kenәgәlәre, uqu jortlarьn tәmamlaw turьnda attestatlar həm diplomnar, xәrbi biletlar həm başqa dokumentlar), keşe isemen jazudaꝗь milli ꝗɵref-ꝗәdәtlәrne istә totьp, tatar həm urьs tellәrendә tutьrьla.

» 16 madde

Tatarstan Respublikasь dәwlәt organnarь, predpriәtielәr ucrezdenielәr həm ojьşmalarnьꞑ xat alьşuь həm үzara rәsmi mɵnәsәbәtlәrneꞑ başqa rәweşe tatar həm urьs tellәrendә alьp barьla.

» 20 madde

1. Tatarstan Respublikasьnьꞑ bɵten territoriәsemdә sәnәꝗәt, transport, elemtә həm energetika ɵlkәlәrendә urьs həm (jaki) tatar tellәre qullanьla.

» 21 madde

Dәwlәt xezmәt kүrsәtү ɵlkәsendә həm kommersiә eşcәnlegendә — Tatarstan Respublikasьnьꞑ dәwlәt tellәre qullanьla.

» 22 madde

Tatarstan Respublikasьnda fәnni eşlәrneꞑ tele irekle rәweştә sajlana.

» 23 madde

3. Mәdәni mirasnь ɵjrәnү həm qullanьşqa kertү maqsatьnnan, tatar mәktәplәrendә, tatar tele ɵjrәnelә torꝗan juꝗarь həm

maxsus urta uqu´ jortlarьnьŋ tatar filologiəse həm tarix fakul'tetlarьnda həm bγleklərendə uqu predmetь bularaq, ƣərəp grafikasь nigezendə iske tatar jazma telen əjrənγ əcen məmkinleklər tudьrьla.

Respublikada ƣərəp həm latin grafikalarьn əjrənergə teləwcelər əcen şartlar tudьrьla: fənni-pedagogik kadrlar əzerlənə, dəresleklər, uqu jardəmleklərə, ədəbi-tarixi istələklər bastьrьla.

» 24 maddə

Tatarstan Respublikasьnda geografik atamalar həm jazmalar, topografik bilgelələr, jul kyrsətkeclərə tatar həm urьs tellərendə eşlənə.

» 26 maddə

2. Torak punktlarnьŋ isemnəren bozьp ataw rəxsət itelmi.

» 27 maddə

1. Tatarstan Respublikasьnьŋ cit il wəkiliətlərə, Tatarstan Respubliasьnьŋ tьşqь səjəsi, tьşqь iqtisadьj həm başqa ucrezdenielərə eşcənlegə tatar, urьs tellərendə həm baƣlanьşqa kergən dəwlət telendə alьp barьla.

» 28 maddə

Juridik həm fizik zatlar Tatarstan xalьqlarь tellərə turьnda Tatarstan Respublikasь zakonnarьn bozƣan ƣəməllərə əcen Tatarstan Respublikasь zakonnarь nigezendə çawapqa tartьlalar.

## Tatarstan Respublikasь Konstitutsiəsendə teigə qaraƣan maddələr

4. Tatarstan Respublikasьndə dəwlət tellərə - tigez xoquqlь tatar həm rus tellərə.

20. Tatarstan Respublikasьnьŋ barlьq grazdannarь tigez xoquqlь həm tigez burьclь. Cьƣьşьna, sotsial' həm məlkəti xəlenə, nindi rasadan həm millətən buluьna, çenesenə, belemenə, telenə, səjəsi qaraşьna, dini məslegenə, şeƣelenen tərenə həm γzencəlegenə, torƣan urьnьna həm başqalarƣa qaramastan, alar dəwlət tarafьnnan jaqlanuƣa tigez xoquqlь.

Grazdannarƣa tuƣan telennən fajdalanu garantiələnə.

48. Tatarstan Respublikasь grazdannarь dəwlət uqu jortlarьnda tγləwsez ƣomumi urta həm maxsus urta belem alьrƣa, şulaj uq məktəptə tuƣan telendə uqьrƣa xoquqlь.

67. Xalьq deputatlarь Sovetlarь, çirle administratsiə həm alarnьŋ organnarь eşne tatar həm rus telendə, ə kirək ocraqta şuşь territoriədə jəşəwce xalьqnьŋ kypcelege qullanƣan teldə alьp baralar həm qabul itkən aktlarnь şul tellərdə bastьrьp cьƣaralar.

96. Tatarstan Respublikasь zakonnarь tatar həm rus tellərendə qabul itelə həm bastьrьp cьƣarьla.

149. Tatarstan Respublikasьnda sud eşlərə tatar həm rus tellərendə jaki şul urьnda jəşəwce kypcelek xalьq telendə alьp barьla.

Sud eşendə qatnaşqan həm sud eşe bara torƣan telne belməgən keşelərgə tərçeməce jardəmendə eşneŋ barlьq materiallarь belən tanьşu, sudta qatnaşu həm anda tuƣan telendə cьƣьş jasaw xoquqь tə'min itelə.

## Дустымны юксынам

Йолдыз атылса — эзе кала.
Шагыйрь үлсә — сүзе кала...

Күптән түгел генә менә шундый шигъри юллар язып, Нократ-Чулман төбәге әдәбияты торышы, язучыларыбызның аянычлы язмышы турында уйланып алган идем. Әйе, ни кызганыч! — дистәдән артык якташларым-каләмдәшләрем бу тормыштан бик яшьләй, көтмәгәндә китеп барды... Кинәт вафат булуларының сәбәпләре дә бер-берсенә охшаш — инфаркт, йөрәкләрнең тибештән тукталуы, канда лейкоцид җитмәү авыруы. Әйе, барысы да йөрәккә барып тоташкан шул... Менә ул ямансу исемлек: Эдуард Касыймов, Газизҗан Кашапов, Альберт Сафин, Вәкил Ахунҗанов, Мөхәммәт Шәйхи, Гомәр Нигъмәтуллин, Афзал Нигъмәтуллин, Леонид Остапенко, Хәниф Хөснуллин, Юрий Малков, Кадыйр Сибгатуллин, Валерий Суров... Һәм менә әле яңарак кына — Ямаш Игәнәй...

Соңгы яра бигрәк тә әрнүле, үзәкләрне өзеп сызлый, диләр. Шулайдыр... Тоям... Игәнәйне югалту минем өчен аеруча авыр... Чөнки Ямаш, вафат булыр алдыннан гына, соңгы айларда, Чаллыдагы «Аргамак» журналы мөхәрриятендә еш була иде — безнең эш урыннары, язу өстәлләре дә янәшәдә генә иде...

Һәр язучының тормыш юлы, иҗади язмышы аның үзенә генә хас, беркемне дә кабатламас була. Берәүләрнең тормышы, язгы ташкын кеби ашкынып, давыл кеби атлыгып, шаулы уза. Ә инде икенчеләренең яшәве — салмак кына, уйчан гына, үзенең тирән, киң колачлы суларын горур рәвештә тирбәтә-тирбәтә еракеракларга юл тотучы елгага охшаган. Андыйлар үз эшләрен тыйнак кына, артык тавыш, шау-шу чыгармыйча, җиренә җиткереп башкаралар. Талантларын, көчләрен, хисләрен җәлләмичә, халыкка тугры хезмәт итәләр.

Шагыйрь, публицист, милләтпәрвәр Ямаш Игәнәй (Ананий Нестор улы Малов) шундыйрак тыйнак холыклы, көчле рухлы, зур талантка ия булган шәхесләрдән иде.

...Мин аның белән җитмешенче елларда танышкан идем: Ямашның Баулыдан әле яңа гына Мамадышка күчеп, биредә район газетасы мөхәрриятенә эшкә урнашкан чагы иде. Мамадышта яши башлавының беренче айларында ул редакция бүлмәсендә, идәнгә матрац җәеп, өстенә пинжәген генә ябынып, «фронтовикларча» йоклый иде — чөнки Баулыдагы фатирын алмаштырып, гаиләсен үз янына күчерүдәниндидер кыенлыклар килеп чыккан иде... Шулай да — ул вакыттагы яшәеш шартларының шактый четрекле-мәшәкатьле булуына карамастан — Мамадышта чакта Ямашның, шагыйрь буларак, иҗади осталыгы күзгә күренеп үсте һәм ул, язучы сыйфатында, нәкъ менә шушында формалашты.

Әйе, без әле ул елларда киләчәкләребез турында иксез-чиксез планнар корып, хыялый дөньяларда инсафлы, тыйнак кына яшәүче яшь әдипләр булсак та, ниятләребез изгедән, олыдан иде: канатлы Тулпарны йөгәнләп, Зур Әдәбиятка кереп китү! — Шигъри Галәмгә сәфәр чыгу!.. Шөкер, Ямаш Игәнәй үз хыялына иреште: сәфәргә генә чыгып калмады, ә үзе дә Шигъри Галәмдә якты Йолдыз булып кабынды. Игәнәйнең бай иҗатын шигырь сөючеләр яхшы белә һәм ярата, аның әсәрләре дәреслекләргә һәм шигъри антологияләргә кертелә, төрле җыентыкларда әледән-әле дөнья күрә килә...

Әйе, Мамадышта яшәгән еллары Я. Игәнәйгә рухи көч бирделәр, иҗатына пар канатлар куйдылар. Бирелә чакта ул олуг әдип — остазыбыз Шәйхи ага Маннур белән якыннан танышты, аның шифалы рухи ярдәмен тойды, бихисап шигырьләр язды (Бераздан — 1981 елда — алар Казанда, Татарстан китап нәшриятында чыккан «Сәфәр чыгам» исемле мөстәкыйль җыентыкта дөнья да күрделәр). Минемчә, Ямаш Игәнәйнең иҗади үсешенә, шулай ук Ринат Мөхәммәдиев, Әхмәт Гадел, Зиннур Мансуров, Вәкил Ахунҗанов, Рафаил Газизов, Нәзифә

Кәримова, Шаһинур Мостафин кебек Мамадыштан чыккан язучыларга, Рим Салихов, Сәмигулла Хәйретдинов, Зәки Хәнәфиев, Зиннур Хәсәнов, Чәчкә Хәснетдинова, Люция Фәршатова, Зөфәр Әгъзәмов, Вәлия Гыйззәтуллина, Вәрис Миннегалиев, Алсу Дияр, Фәнил Миннеханов кебек район-республика күләмендә танылган журналистларга ул заманда бердәнбер газета редакциясе каршында гөрләп эшләп килүче «Агымсу» әдәби-иҗат берләшмәсе зур йогынты ясады. Их, нинди бәхетле, матур мизгелләр кичердек без ул утырыш-җыелышларыбызда! Төн урталарына кадәр шигърият турында бәхәсләр, яңа шигырь-хикәяләр, парча-нәсерләр укулар, бихисап фикер алышулар!..

Укучыларыбызның игътибарын кирәгеннән артык җәлеп итәргә җыенмыйм, әмма Ямаш Игәнәй белән Мамадышта булган гадәттән тыш хәлләрнең кайберләрен искә төшереп үтмичә булдыра алмыйм: чөнки аларда шагыйрьнең ихласлыгы, ярдәмчеллеге, кешелеклелеге ярылып ята.

...Беренче вакыйга җәйге эссе көннәрнең берсендә була. Ямаш, гадәтенчә, җилкәсенә кармак таякларын салып, кесәсенә блокнот белән карандаш кисәген тыгып, Нократ яр буена юнәлә (Ул еш кына Яковка болыннары янындагы «Унсигезенче перекат» турындарак, минем әтием янәшәсендә балык тотарга ярата иде). Кармакларын салып, Ямаш үз уйларына чак кына чумарга да өлгерми, кинәт елгадан кемнеңдер ярдәм сорап кычкырган үзәк өзгеч тавышы ишетелә. Таллыкны аралап, шунда бакса, ни күрсен: бер яшүсмер малай, елга эченә ераграк йөзеп кергән дә, хәзер инде кире ярга чыга алмыйча, батып ук бара икән... Ямаш, чалбарын тиз генә салып ата да, малайга ярдәмгә ашыга. Берничә минуттан соң, ул, яшүсмерне чәчләреннән тотып, аны ярга таба сөйри дә башлый. Бәхеткә, Ямаш бу баланы коткарып өлгерә, ярга чыгаргач, беренчел медик ярдәмне дә күрсәтә, әтием Габдулла чакырырга өлгергән «Ашыгыч ярдәм» машинасына утыртып та җибәрә... Икенче мәртәбә Я. Игәнәй район газетасының җаваплы сәркатибе Әхмәт ага Хуҗиевны балык тотканда боз астына китүдән коткарып кала... Шуннан соң гына Ямашның батырлыгы турында белеп алалар, аның турында республика газетасында язып чыгалар һәм хәтта (бу — сирәк очраклардан берсе!) бүләклиләр дә. СССР Югары Советы Президиумының 1977 елгы 20 август Указы нигезендә, Ананий Маловка (Ямаш Игәнәйгә) «За спасение утопающего» («Батучыны коткарган өчен») медале тапшырыла...

Менә бүген, истәлекле шул вакыйгадан соң инде егерме ел вакыт узгач, Ямашның язмышы турында тагын бер мәртәбә уйланып утырдым. Әйе, төрле хәлләр узган инде аның башыннан ошбу җирдә илле тугыз ел яшәве дәверендә. Әмма шунысы сөендерә: Игәнәйнең бөтен гомере диярлек кешеләргә игелек кылып, «батучыларны коткарып» үткән — монысын инкарь итеп булмый. Гамьле-аһәңле шигъри юллары белән Я. Игәнәй (аның «Йолдыз булып ян!», «Хәзинәләр иле», «Игелекле төбәк» һ. б. исемнәр астында дистәгә якын китабы чыкты) замандашларының рухын терелтергә тырышты. Сөекле халкының тарихын вә мәдәниятен тулырак яктыртырга ашыкты. Кырым татарларына да рухи ярдәм кулын сузды — алар турында чын дәреслекне сөйләүче «Бәддога» исемле ялкынлы публицистик язмалардан торган саллы документаль китап та бастырып чыгарды. Үзе яраткан, якын күргән «Аргамак» журналына да, «Керәшен сүзе» газетасына да олы күңеле җылысын салды ул. Балалар өчен дә күп кенә әсәрләр иҗат итте...

Әйе, йолдыз атылса — эзе кала, Шагыйрь үлсә — сүзе кала, җыры кала... Ә инде Ямаш Игәнәйнең җыры безнең арада калган икән,— димәк, ул һаман да яши — Ватанына, туган халкына игелек кылуын дәвам итә!..

**Мансур САФИН,**
язучы, «Аргамак» журналының баш мөхәррире урынбасары.

# ӘДИПЛӘР ТОРМЫШЫННАН

***Күренекле әдипләр һәм сәнгатькәрләр тормышыннан төрле мәзәк хәлләр турындагы язмалар инде байтактан бирле гәзит-журнал битләрендә күренеп килә. Аларны укучылар яратып кабул итә. «Казан утлары» битләрендә дә язучы Шамил Маннап туплаган байтак кына истәлекләр дөнья күрде. Быел исә без бу рубриканы яңа исемдә һәм яңа шәкелдә яңартырга карар бирдек. Даими бирелеп барачак сәхифәдә әдипләр үз тормышларында, дус-ишләре белән аралашуда һәм иҗат процессында булган кызыклы хәлләр хакында үзләре язган кыска-кыска хикәячек-истәлекләр белән катнашачак. Аның «Имеш-мимеш түгел» дип аталуы да шуннан. Киләчәктә редакция аларны туплап аерым китап итеп бастырып чыгаруны да күздә тота.***

***Бу санда беренче шәлкем тәкъдим ителә.***

## Кыйммәтле гариза

Моннан берничә еллар элек тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, шагыйрь Ренат Харис һәм хәзер инде мәрхүм композитор Александр Ключарев Муса Җәлил юбилеен үткәрергә дип Оренбургка баралар. Очрашулар шыгрым тулы залларда бик җылы, матур үтә.

Кайтырга чыкканда гына бер күңелсезлек булып ала. Заказ бирелгән ике урынына, гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, бер генә машина килә. Аэропортка исә кабул иткән хуҗаларның да барасы килә. Көч-хәл белән шоферны күндерәләр дә алтаулашып утырып чыгып китәләр.

Аэропортка килеп җиткәндә генә машинаны ГАИ туктата. Күп сөйләшеп тормыйча, юл кагыйдәләрен бозган өчен таксистның правасын алып та калалар. Шоферның кәефе кырыла, юл буе дәшмичә генә бара бу. Безнең сәнгатькәрләрнең дә эчен мәче тырный: алар гаебе белән егет бәлагә тарды ич! Аэропортка килеп җитү белән шоферны яклап, бөтен гаепне үз өсләренә алып ГАИ исеменә гариза язалар болар. Бөтен дәрәҗә-титулларын күрсәтеп кул да куялар. Кем халык артисты, кем атказанган сәнгать эшлеклесе, кем Җәлил премиясе лауреаты.

Кәгазьне кулына алгач, шофер күзләренә ышанмый:

— Сез, чыннан да, атаклы композитор Александр Ключаревмы? Сез Ренат Харисмы? Ә сез Муса Җәлил турында язган Рафаэль Мостафинмы? — дип сорашырга тотына.

— Әйе, — диләр.

Шофер татар кешесе икән, кәгазьне бик пөхтәләп бөкли, эчке кесәсенә сала да әйтеп куя:

— Мондый кыйммәтле автографларны ГАИга бирәмме соң! Үземдә калсын әле...

## Язганыңа карап...

Флүс Латыйфи «Хыянәт» исемле романын язгач кинәшер-табышыр өчен Нурихан Фәттах янына китә.

— Тиз генә укый алмам, энем, ике-өч айданмы, бер ярты елданмы килеп карарсың,— ди әдип.— Эшем бик күп чак...

Әмма бер атна үтәр-үтмәстән чакыру хаты килеп тә төшә.

— Казый янына хөкемгә килгәндәй, йә батам, йә калкам, дип килдем. Сез ни әйтсәгез шуңа риза,— ди Флүс кергәч тә.

— Язганыңа карап язганы булыр,— ди өлкән язучы сабыр гына һәм роман турында ләм-мим әйтмәстән кунагын табын янына чакыра. Ашыйлар, эчәләр... Ипләп кенә дөнья хәлләре турында гәп куерталар. Ә роман турында һаман бер сүз дә юк. Әдәп саклап түзеп утырган Флүс китәр алдыннан әсәренең язмышын сорыйсы итә.

— Әйттем, аңлаттым лабаса,— ди әдип.

— Ничек?— ди телсез кала язган Флүс.

— Язганыңа карап язганы булды, энем,— ди Нурихан Фәттах.— Язганыңның рәте булмаса, синең белән табындаш булыр идеммени?..

## Мин гел шулай инде...

Зөлфәт, Камил Кәримов һәм Сәйдә Зыяның «Яшь ленинчы» гәзитендә эшләгән чаклары. Мәктәпләрдә укучылар белән очрашулар үткәреп йөриләр. Аларны, гадәттә, Сәйдә ханым ачып җибәрә дә:

— Кадерле укучылар! Сез белемле, тәрбияле, әдәпле, әхлаклы булып үсеннәр өчен «Яшь ленинчы» бик тырыша,— дип сөйләп китә икән.

Чираттагы очрашу башлана. Сәхнәдәге өстәл янына тезелешеп утыра болар. Сәйдә ханым трибуна янына чыгып басуга Камил Кәримов борын астыннан гына:

— Бер ярты сәгать дежур сүз сөйли инде бу. Күз ачык килеш кенә черем итеп алырга да була,— дип мыгырдап куя да аякларын сузып җибәрә.

Һич көтмәгәндә Сәйдә бөтенләй башкача башлый:

> Гашыйк идем сиңа,
> Гашыйк идем...
> Унөч яшьтән бирле гашыйкмын...

Черем итәргә дә өлгермәгән Камил:

— Ә-ә?!— дип кычкырып җибәрүен сизми дә кала һәм янындагы Зөлфәткә китереп төртә. Урындыгында атынып утырган Зөлфәт исә үзе белән Камилне дә ияртеп идәнгә тәгәри. Аннан ашыкмый гына тора да, чалбарындагы тузанны каккалап, берни дә булмагандай:

— Сәйдә сөйли башласа, мин гел шулай инде,— дип куя.

Моны үзенә күрә бер уен дип аңлаган тамашачы рәхәтләнеп кул чаба.

## Асия Минһаҗева кем ул?

Асия Минһаҗева дигән шагыйрә турында ишеткәләсәләр дә, аны төскә-биткә танып белүчеләр аз икән. Шигырьләре ешрак чыккан елларны мактау сүзләрен йөзе-күзлеге белән аңа шактый охшаш галимә Флера Ганиевага, йә булмаса исеме белән охшаш журналист Асия Юнысовага килеп әйтәләр икән. Шуңа үпкәләпме, яки башка бүтән сәбәп беләнме, соңгы елларда матбугатта бик үк күренми башлагач, Асия фамилиясен алыштырган икән дигән сүз чыккан. Хәзер инде аны музыка белгече Асия Рахман түгел микән дип шикләнәләр, ди.

## Фәтхи Бурнаш

(1898—1942)

Күренекле драматург, шагыйрь һәм публицист, җәмәгать эшлеклесе Фәтхи Бурнашның тууына 100 ел тулды.

Аны күреп белгән өлкәннәребездән Риза ага Ишморатның: «Фәтхи олпат гәүдәле, кыю-гайяр кеше иде»,—дип сөйләгәне хәтердә калган. Кызганыч, бу үзенчәлекле шәхеснең тормыш юлын да, иҗатын да хәзерге буын татар укучысы бөтенләй белми диярлек.

Фәтхелислам Закир улы Борнашев (Фәтхи Борнаш) Чувашстанның Батыр районы Бикшик авылында 1898 елның 13 гыйнварендә ишле балалы мулла гаиләсендә дөньяга килгән.

Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә җиде ел укыганнан соң, үсмер Фәтхи 1915 елда аны ташлап, урысча «учительская школа»га имтихан тота. Тамак ялына төрле вак-төяк эшләр башкарып йөргән ярлы шәкерт бервакыт «Сәйяр» труппасына барып юлыга. Язуы матур булгангадыр, күрәсең, аны пьесаларның рольләрен күчерүче итеп алалар. «Сәйяр» җитәкчесе Габдулла Кариев белән драматург Кәрим Тинчурин, яшь егетнең сәләтен сиземләп, тәрҗемә эшенә тарталар. Уналты яшьлек Фәтхи Бурнаш урыс драматургы Сергей Найденовның шул заманнарда шаулаган «Ванюшин балалары» пьесасын (1914) тәрҗемә итә. Тәрҗемә уңышлы чыга, сәхнәдә уйнала. Яшь егет дәртләнеп китеп иҗат эшенә чума. Бер-ике ел эчендә Фәтхи Бурнаш «Гарәп кызы Ләйлә» (1914), «Язмыш» (1914), «Сукбай» (1915), «Саташкан кыз» (1915) кебек әсәрләрен яза, аларның сәхнәдә уйналу куанычын татый. Татар театрына нигез салучыларның берсе булган Габдулла Кариев Фәтхине дәртләндергәннән дәртләндереп тора. Фәтхи Бурнаш аны үзенең рухи атасы итеп саный. Үлеме уңаеннан «Кари каберенә» дигән (1920) шигырь дә яза:

Әйләнә тормыш һаман тукталмыйча,
Тормый тарих бер сәгать тик язмыйча;
Шул сәхифәләр аңарда, кайсы ки
Калды бер тамчы кара кан таммыйча...
Әй туган, актар аңардан бер читен,
Күр укып шул мәңге онытылмас, авыр
Кайгылы матәм көненең билгесен.
Сәҗдәгә кил, әй нәфасәт дөньясы,
Мондадыр татар театр кыйбласы:
Монда «Сәйяр»нең сөекле мәгънәви
Әткәсе — даһи Кари Габдулласы.

Фәтхи Бурнашның башлангыч иҗатына бер күз салу да аның искиткеч эшчән-тырыш, мул җимешле әдип булып үсеп килүен күрсәтә. Ул 1915 еллардан «Ак юл», «Аң» журналларына актив язышa, шигырь-поэмалары бер-бер артлы басылып кына тора. Инде 1918 елда ук Ф. Бурнашның берьюлы ике китабы — «Айсылу» һәм «Шәрыкъ гөлләре» дигән поэмалар мәҗмугасе басылып чыга.

1917 ел. Октябрь инкыйлабын Фәтхи Бурнаш Сембер шәһәрендә каршылый. Аның күңеле күтәренке. Чөнки ул әле генә «Яшь йөрәкләр» драмасын язып тәмамлаган, «Таһир-Зөһрә» трагедиясе дә очланып килә. Һәркайсысы бишәр пәрдәле, зур күләмле әсәрләр болар. «Таһир-Зөһрә» исә әле җитмәсә шигырь белән язылган. Әйе, егет дөрес сизенә: шушы ике әсәр Фәтхи Бурнашны татар театр сәнгатендә мәшһүр драматурглар рәтенә бастыра.

Сембердә Ф. Бурнаш 1918 елда «Көн» газетының мөхәррире була, бик күп эшләрдә башлап йөри, ялкынлы публицистик мәкаләләре белән чыгышлар ясый. Егетнең дәрт-җегәре ташып тора. Әй дөнья, бел: татар әдәбиятына гаять үзен-

чәлекле талант килгән ел булыр бу! Шулаен шулай да... Озакламый Сембердне аклар камап ала, Ф. Бурнаш башта Самарага, аннары Уфага качып китәргә мәҗбүр була. Уфада — Г. Кариев, анда — дуслар... Әмма аны, бик тиз танып кулга алалар һәм Уфа төрмәсенә илтеп тыгалар. Габдулла Кариевлар егетне коткарырга күпме генә тырышмасыннар, йолып ала алмыйлар. Кызыллар Уфага һөҗүм итә башлагач, тоткыннарны үлем вагоннарына төяп Себергә озаталар. Алда, һичшиксез, үлем көтә... Чынлап та гайяр була Фәтхи Бурнаш! Бер кат күлмәк-ыштаннан гына килеш, көзге салкын төннәрнең берсендә ажгырып чапкан поезддан сикереп төшеп кача ул. Егет, төрле куркыныч маҗаралар кичеп, Бөгелмә тирәләренә кайтып житә һәм кызыллар ягына чыга. Аны, тикшереп, кем икәнлеген аныклагач, яңадан Сембер шәһәренә эшкә җибәрәләр. Ф. Бурнаш анда «Таң» исемле яңа газет оештыра, аның мөхәррире була. 1919 ел башыннан Фәтхи Бурнаш — коммунист, татар язучылары арасында беренче һәм яшь коммунистлардандыр, мөгаен. Ах, белсә-сизенсә икән кайнар йөрәкле 21 яшьлек егет нәкъ тагын 21 елдан Сталин корган үлем тегермәне аны да сытып ташлаячагын! Юк шул... Язмышны алдап булмый...

Озакламый Ф. Бурнаш Казанга кайта. «Кызыл Армия» һәм «Татарстан» газетларына мөхәррирлек итә. Г. Ибраһимовлар белән берлектә «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») һәм «Чаян» журналларын оештыручылардан була. Иҗаты да гөрләп бара. Аны хәтта «поэмалар шагыйре» дип тә йөртә башлыйлар. Чөнки бер 1919 елда гына да ул тугыз (!) поэма яза.

Әмма Фәтхи Бурнаш үзен нигездә драматург итеп саный. Аның иҗаты искиткеч күпкырлы һәм бай. Сәхнә әсәрләре генә дә өч дистәгә якын.

1922 елда Ф. Бурнашны Татарстан Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы һәм Казан шәһәр Советы депутаты итеп сайлыйлар. Шул рәвешле, әдип, иҗат эше белән берлектә, җәмәгать эшләренә дә тартыла.

Гөрләп торган егерменче-утызынчы елларда Ф. Бурнашның иҗат эшчәнлеге һич сүрелеп тормый: бер-бер артлы яңа әсәрләре языла, китаплары дөнья күрә. Ул Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Фатих Сәйфи-Казанлылар белән берлектә, совет чоры татар драматургиясенә нигез салучыларның берсе булып танылa. Игътибар итегез: соңыннан аларның дүртесен дә бер язмыш көтә — үлем җәзасы...

Ә хәзергә — тулы канлы иҗади тормыш. Уңыш арты уңыш! Тантана!

Менә Ф. Бурнашның «Камали карт» комедиясенә Гадел Кутуй биргән бәя: «Камали карт»та кайнап тора торган тормыш бар. Ул Татар дәүләт театрының быелгы сезонда булган иң отышлы комедияләреннән берсе». («Кызыл Татарстан», 6 дек., 1925 ел.)

Утызынчы еллар Ф. Бурнашның «Лачыннар» исемле героик драмасы СССР күләмендә үткәрелгән конкурста зур уңыш казана. Инде утызлап сәхнә әсәре, шул исәптән биш опера либреттосы иҗат ителгән. Бераз тына төшәргә дә булыр иде шикелле. Юк, Фәтхи Бурнаш ару-талуны белми. Ул яңадан-яңа колачлырак эшләргә алына тора. Аның тарафыннан биш йөзгә якын публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре язылган. Алар татар әдәбияты, драматургиясе, театры, сәнгате өчен ялкынлы көрәш рухы белән сугарылганнар. Ф. Бурнаш, беренчеләрдән булып, Фатих Әмирхан иҗатын төрлечә бозып күрсәтүчеләргә каршы чыга, аны яклап зур мәкалә яза. Г. Тукай иҗатын тәфсилләп өйрәнә, совет чорында аның беренче зур күләмле басмасын төзеп, сүз башы язып бастырып чыгара.

Ф. Бурнаш — житди һәм оста тәрҗемәче дә. Аның каләме аша татар укучыларына Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты», А. Толстойның «Зәңгәр шәһәрләр», М. Горькийның «Ана», И. Тургеневның «Аталар һәм балалар», Л. Толстойның «Хаҗи Морат», А. Пушкинның «Евгений Онегин» исемле мәшһүр әсәрләре барып ирешә. Соңыннан әдәбият белемендә «Онегин строфасы» дип аталган катлаулы стиль үзенчәлеген саклаган хәлдә шундый зур күләмле романны тәрҗемәләү Пушкин иҗатын яхшылап өйрәнүне дә, урыс шигырен татарча бирә белү осталыгын да, зур шигъри талант та сорый, әлбәттә. Әлеге тәрҗемәсе уңае белән Ф. Бурнаш «А. С. Пушкинга» дигән шигырь дә яза (1938). Шигырь «Онегин строфасы» белән язылган. Менә бер үрнәк:

Александр Пушкин, сиңа бирәм
Иң кайнарын бүген тойгымның.
Җырлыймын мин туган телем белән
Иң матурын синең җырыңның.

Кичер мине кыю сүзем өчен,
Үзем өчен түгел, илем өчен —
Сөйгән өчен халкым җырларын,
Сөйгән кебек данлы улларын.
Балкыр хатирәңнән рухланып,
Бөек илһамыңа күңлем тегеп,
Халкым теле белән юллар чигеп,
Кояшыңнан синең нур алып,
Онегинның җырын җырладым,
Татьянаның зарын тыңладым...

Фәтхи Бурнаш иҗатының иң бөек үрләрен яулар дәрәҗәгә җитеп килгәндә генә һәлак була... Нибары 44 яшендә...

1940 елның августында әдип «халык дошманы» дип гаепләнеп кулга алына һәм 1942 елның 1 августында атып үтерелә. Озак еллар аның үлгән елы җәмгатьчелектән һәм туганнарыннан яшереп киленә. Хәтта «Совет Татарстаны язучылары» дигән биобиблиографик белешмәдә дә (1986) «Фәтхи Бурнаш 1946 елда вафат була» дип язылган. Үзе канатланып-очынып кабул иткән совет хакимияте аның канатларын әнә шулай иртә кыеп төшерә...

Ф. Бурнаш иҗаты — күпкырлы һәм катлаулы. Шәхес буларак та, ул — үз чоры баласы. Шул чор көрәшеннән, шул еллардагы шаукымнардан һич тә азат шәхес түгел. Әмма ул чын мәгънәсендә талантлы, күренекле әдип.

Үзе исән вакытта Ф. Бурнашның 24 китабы дөнья күргән. Аннары, шәхес культы фаш ителеп, исеме акланып халкыбызга кайтарылганнан соң, нибары өч басма: ике томлык сайланмалары (1959), янә бер сайланма (1969) һәм «Әдәбият һәм сәнгать турында» исемле мәкаләләр тупланмасы (1978).

Болар бик аз...

Күренекле әдип Фәтхи Бурнашның иҗаты әле һәрьяклап өйрәнүне көтә.

**Марс ШАБАЕВ.**



*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

### ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — ИЧКЕРИЯ

Моннан өч ел элек, Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев инициативасы белән, элеккеге СССР территориясендә низаглы хәлләрне җайга салу буенча Гаага консультатив «Түгәрәк өстәл»е чакырылган иде. Сәяси лидерлар һәм халыкара экспертларның формаль булмаган әлеге очрашуларында элеккеге Советлар иле киңлегендәге хәлләрнең торышы анализлана, тынычлыкка һәм татулыкка бару юллары тикшерелә.

Гаага консультатив «Түгәрәк өстәле» Чечня Республикасы — Ичкериядәге хәлләрне җайга салу мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирә. Шушы максатларда үткән елның 20—21 декабрендә «Гаага инициативасы — IV» кысаларында «Россия Федерациясе — Чечня Республикасы-Ичкерия: конструктив диалог» дигән темага консультатив «Түгәрәк өстәл» оештырылды. Грозныйда (Җәүһәркалада) башланган, Назраньда дәвам иткән әлеге очрашуның йомгаклау өлеше Казанда узды. «Түгәрәк өстәл» эшендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, Чечня Республикасы-Ичкерия Президенты А. Масхадов, Ингушетия Республикасы Президенты Р. Аушев, Россия Федерациясенең Иминлек Советы сәркатибе И. Рыбкин, күпсанлы халыкара экспертлар катнашты.

Соңыннан массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен матбугат конференциясе үткәрелде.

### ХАЛЫКАРА ӘДӘБИЯТ ФОНДЫ ФОРУМЫ

28—30 ноябрь көннәрендә Казанда Халыкара Әдәбият фондының II конференциясе булып үтте. Татарстан Язучылар оешмасы һәм Әдәбият фонды идарәләре инициативасы белән оештырылган әлеге форумда элекке СССРның барлык республикаларыннан һәм кайбер чит илләрдән килгән делегатлар, Артем Анфиногенов, Роман Солнцев, Марат Тарасов, Николае Русу, Габиден Кулахметов, Михайло Шевченко, Ариф Ибраһимов кебек ил күләмендә танылган язучылар катнашты.

Иң элек залдагылар ике конференция арасында үлгән язучыларны бер минутлык тынлык белән искә алдылар. Аннары үзләрен иң авыр елларда да намуслы-гадел, гаярь көрәшче итеп таныткан каләм осталарына Халыкара Әдәбият фондының «За честь и достоинства таланта» дип исемләнгән премияләре бирелде. Алар арасында Виктор Астафьев, Дмитрий Лихачев, Василь Быков, инде мәрхүмнәрдән Булат Окуджава, Алесь Адамович та бар.

Конференция барышында соңгы биш ел эчендә башкарылган эшләргә йомгак ясалды, ревизия комиссиясе отчеты тыңланды, фикер алышулар булды. Әлеге форумда Халыкара Әдәбият фонды Уставына кайбер үзгәртүләр һәм өстәмәләр кертелде, Президиум турында яңа положение расланды. Аннары Халыкара Әдәбият фондының яңа составы (идарә рәисе итеп — яңадан Владимир Огнев, директор итеп — Роман Гюлумян) сайланды. Фондның идарәсе рәисе урынбасарларының берсе итеп Татарстан Язучылары оешмасы җитәкчесе Ринат Мөхәммәдиев күрсәтелде, ревкомиссия составына Татарстан Әдәбият фонды директоры Данил Салихов кертелде.

Конференциядә Татарстан Язучыларының Әдәбият фонды (идарә рәисе — Әхсән Баян) эшчәнлегенә уңай бәя бирелде.

Конференция эшендә Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Ренат Харисов, вице-премьер Илгиз Хәйруллин катнаштылар һәм чыгышлар ясадылар.

### ПЕН-ҮЗӘК УТЫРЫШЫ

Республиканың Милли китапханәсе бинасында Татарстан ПЕН-үзәгенең чираттагы утырышы булып узды. ПЕН-үзәк әгъзалары узган елда башкарылган эшләр турында исәп-хисап тоттылар. Көн тәртибендәге мәсьәләләрнең берсе — яңа әгъзалар кабул итү иде. ПЕН-үзәк идарәсе Башкортстанда яшәүче әдипләрнең (Н. Нәҗми, С. Поварисов, М. Нәзиров, Ф. Габдрәхим, Р. Әмиров) гаризаларын карады һәм аларны бу иҗтимагый оешмага кабул итәргә мөмкин, дип санады. Утырышта катнашучылар оешма әгъзасы — язучы М. Хәбибуллинны 70 еллыгы уңаеннан кайнар котладылар. Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча җыелышта Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, М. Госманов, Р. Мостафин, Р. Вәлиев, М. Галиев, М. Хәбибуллин, Г. Рәхим, Р. Кутуй, Н. Гыйматдинова, Ә. Мушинский, Т. Бариев һ. б. чыгыш ясады. Җыелыш эшендә Татарстан Президенты киңәшчесе, Тарих институты директоры Р. Хәкимов та катнашты.

### Ф. ЯРУЛЛИН МУЗЕЕ САФТА!

6 декабрьдә Мамадыш районының Кече Сөн авылында мәшһүр композиторыбыз Фәрит Яруллинның музее яңадан ачылды. (Билгеле булганча, агач материалларыннан эшләнгән элеккесе, янгын чыгып, көлгә әй-

ләнгән иде). Хәзергесе исә ак-кызыл кирпечләрдән яңа гына төзелгән мәһабәт мәктәпнең беренче катына урнашкан. Аны тизрәк сафка бастыруда район хакимияте башлыгы, Татарстан халык депутаты Ә. Гобәйдуллин, Вахитов исемендәге күмәк хуҗалык рәисе Ф. Мөхәммәтҗанов, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Дәүләт музее хезмәткәрләре зур тырышлык-фидакарьлек үрнәкләре күрсәттеләр.

Музейны ачу тантанасына Казаннан олы кунаклар — ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Мәдәният министры М. Таишев, Татарстан Дәүләт музее директоры Г. Муханов, Ф. Яруллинның энесе — атаклы композитор М. Яруллин, Татарстан Композиторлар һәм Язучылар берлекләре җитәкчеләре Р. Кәлимуллин, Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев, Ф. Яруллин турындагы романхроника авторы Р. Низамиев һ. б. килгән иде. Соңыннан Р. Халитов җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры чыгыш ясады.

*ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНДА*

### ЧАЛЛЫДАГЫ ОЧРАШУЛАР

Узган елда журналыбызның иҗтимагый яңгырашы көчәйде, абруе артты, дип әйтә алабыз. Бөтендөнья татарларының II Конгрессы көннәрендә басмабызның 75 еллык юбилее гөрләп узды. Соңгы елларда тираж күзгә күренеп үсә бара, авторлар һәм укучыларыбыз саны ишәя. Юбилей уңае белән байтак төбәкләрдә «Казан утлары» көннәре уздырылды. Ел ахырында журналга багышланган кичәләр, махсус очрашулар Чаллы шәһәрендә дә узды. Чаллы педагогия һәм укытучыларның белемен өзлексез күтәрү институтларында, 52 нче мәктәптә, педагогия көллиятендә, 2 нче гимназиядә үткән «Казан утлары» көннәрендә журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов һәм язучы-галим Тәлгат Галиуллиннар катнашты. Бу очрашуларның нәтиҗәле узуында Чаллы мәгариф идарәсе башлыгы И. Шәрипов, ректорлар Г. Сәмигуллин, З. Шәрәфетдинов иптәшләрнең зур ярдәме булды.

### К. ТИМБИКОВАНЫҢ КОЯШЛЫ КИЧӘСЕ

К. Тинчурин исемендәге Драма һәм комедия театры бинасында «Казан утлары» журналының элекке хезмәткәрләренең берсе — күренекле язучы, матбугат ветераны, республика журналистларының Х. Ямашев исемендәге бүләге лауреаты Кояш Тимбикованың иҗат кичәсе булып узды. Әдибәнең 60 яшьлек гомер бәйрәменә багышланган кояшлы бу кичә күпләрнең күңелләренә илаһи нур өстәде. Юбилярны Татарстанның халык язучылары Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, «Казан утлары»ның бүлек мөхәррире — шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Мөдәррис Әгъләм, шагыйрә Лена Шагыйрьҗан, «Сөембикә» журналыннан Роза Мулланурова, Филисә Хәкимова, Чистайдан килгән якташлары, күпсанлы дуслары, сәнгатебез йолдызлары кайнар котлады.

### ИЯЛӘР ИЯСЕН ДАНЛАУ

Узган елның 13 декабрендә Түбән Камада танылган сынчы-рәссам, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әхсән Фәтхетдиновның иҗат кичәсе үтте. «Ияләр Иясе ул безнең Әхсән!» — дигән фикерләр еш яңгырады ул көнне. Чыннан да сәнгатьтә «Ияләр» циклы («Йорт иясе, Су иясе, Урман иясе»...) белән дан казанган рәссамне котларга республикабызның төрле тарафларыннан әдәбият-сәнгатьнең күренекле вәкилләре, якын дуслары, туганнары җыелган иде. Бу кичәдә «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин да чыгыш ясады.

### ШИГЪРИЯТ МӘҖЛЕСЕ

11 декабрьдә мәркәзебезнең Г. Тукай музеенда «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Наис Гамбәрнең 50 яшьлек юбилеена багышлап, шигырь бәйрәме үткәрелде. Шагыйрьне котларга шигъри мәҗлескә остазы Рәдиф Гаташ, сабакташлары Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм һәм башка каләмдәш дуслары, аның иҗатына баш иючеләр күпләп килгән иде.

### ХӘТЕР КИЧӘСЕ

Бакалы районының Куштирәк авылы мәдәният йортында күптән түгел генә арабыздан киткән талантлы каләмдәшебез — «Идел» журналының баш мөхәррире Ф. Зөлкарнәй рухына багышлап, «Хәтер кичәсе» үткәрелде. Анда Фәизнең әти-әнисе, булачак әдипне укыткан мөгаллимнәр, хуҗалык җитәкчеләре, күпсанлы дуслары, Казаннан килгән язучылар һәм Ф. Вәлиәхмәтов җитәкчелегендәге сәнгать осталары катнашты.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен, **Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов (Әхсән Баян)** Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен, музыка белгече **Йолдыз Нәкый кызы Исәнбәткә** «Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Кубрат хан хәзинәсеннән: зөбәрҗәтле ике алтын беләзек; бил каешының өч алтын тәңкәләре.

# ЯҢА КИТАПЛАР





Таныш өянкеләр *(Сибгат Хәким турында истәлекләр)*. Төзүчеләре: Мөршидә Вилданова-Хәкимова, Рафаэль Хәкимов. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1997 ел. 295 бит. Тиражы — 3000 данә.

Бу җыентыкта Татарстанның халык шагыйре, Россиянең М. Горький, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким турында истәлекләр тупланган. Кырыкка якын авторлар арасында Н. Арсланов, Г. Ахунов, Г. Афзал, Н. Нәҗми, М. Мәһдиев, И. Юзиев, Н. Фәттах, Ф. Яруллин, М. Шабаев, Р. Мостафин, Ш. Галиев, М. Хәсәнов кебек олуг әдипләр дә, Г. Кайбицкая, Ә. Бакиров, З. Хәйруллина, В. Гыйззәтуллина кебек күренекле сәнгать әһелләре дә, шулай ук, якташлары — Күлле-Киме авылындагы С. Хәким музее директоры — педагог Л. Шәмсиева, танылган фоторәссам Р. Касыймов, күрше республика вәкилләре: Башкортстаннан — Г. Рамазанов, Чувашстаннан — М. Юхма кебек танылган галим-язучылар бар.

«Һәр милләтнең олуг шәхесләре була. Исән чакта алар биниһая сәләтләре, эш-гамәлләре белән чордашларын куандырып, сокландырып яшиләр, ә инде дөньядан киткәч, сагындыралар, һәрвакыт искә төшеп торалар. Алар белән аралашып яшәгән замандашлары аеруча бәхетле: бергә күргән, бергә кичергән хәл-вакыйгаларны ядкарь итеп горурланып сөйлиләр. Сибгат Хәким — әнә шул онытылмас, телдән төшмәс шәхесләрнең берсе...» диелә кереш сүздә.

Китапта бирелгән фоторәсемнәр шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын ачыграк һәм төгәлрәк күз алдына китерергә ярдәм итә. Җыентыкның мөхәррире һәм искәрмәләр авторы — язучы Фәнзаман Баттал.

Индекс 73210



Шагыйрь Әхмәт Гадел

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)